ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

7.1997



## *КАДЕРЛЕ УКУЧЫБЫЗ!*

Сез, беренче яртыеллыктагы кебек, икенче яртыеллыкта да «Казан утлары»н күңелегез маягы итеп сайладыгыз, аңа карата хисләрегезне суытмадыгыз.

Кунак ашы — кара-каршы, дигәндәй, без дә Сезнең өчен үзенчәлекле бүләк әзерләдек — **1998 елга язылу өчен, шушы елның 1 июленнән 29 августына чаклы, льготалы подписка** игълан иттек. Ягъни шул чорда язылсагыз, Сезнең өчен ярты еллык подписка фәкать 15 мең сум гына тәшкил итәчәк.

75 еллык бай тарихлы «Казан утлары» Сезне яңадан үз яктысына чакыра. Күпьеллык эчкерсез дуслыгыбыз элеккечә матур дәвам итсен — киләчәктә дә бергә булыйк!

***«Казан утлары»ның индексы — 73210. Аңа барлык элемтә бүлекчәләрендә чикләнмәгән күләмдә язылып була.***



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИЖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**7**

**(897)**

**1997**

КАЗАН

## *Бу санда*

Сыналабыз — сынмыйбыз. *(Мәгълүмат һәм матбугат министры И. ӘХМӘТЖАНОВның журналның баш мөхәррире Р. ФӘЙЗУЛЛИН белән әңгәмәсе)* ............... 3

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Г. РӘХИМ. Уйдык-уйдык уйлар. *Шигырьләр* ............... 12
Т. ГАЛИУЛЛИН. Элмәк. *Роман* ............... 18
ТАҢЧУЛПАН. Мәңге чишмәс табышмагым. *Шигырьләр* ............... 59
З. ХӘКИМ. Гөнаһ. *Роман* ............... 63
И. ФАЗУЛИ. Таллар таяна жиргә. *Шигырьләр* ............... 133
Рәшит ГАТАУЛЛИН. Дым булып жиргә сеңмәм. *Шигырьләр* ............... 136
Ф. ГАТИНА. Моңлы жан кошы. *Шигырьләр* ............... 154

ПУБЛИЦИСТИКА

М. ЗАРИПОВ. Яшел чишмәләр ............... 140

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Проза турында сөйләшү ............... 158

ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Г. ФӘЙЗРАХМАНОВ. Азатлык рухы ............... 162

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

Ш. ӘХМӘДУЛЛА. Үткәннәрдән гыйбрәт ал! ............... 171

Г. НИГЪМӘТИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Г. Нигъмәти һәм эстетик фикер ............... 176

РӘИСӘ ИШМОРАТОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Л. ИХСАНОВА. Матур язмыш ............... 181

СӘНГАТЬ

Ф. ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ. Болгарый кылыр күнене ............... 185

Котлыйбыз ............... 188
Ижтимагый-мәдәни тормышыбыздан ............... 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
*(җаваплы сәркатип)*
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Беседа министра информации и печати РТ И. АХМЕТЗЯНОВА с главным редактором журнала «Казан утлары» Р. ФАЙЗУЛЛИНЫМ.
«Проза и поэзия»: продолжение романов Т. ГАЛИУЛЛИНА «Петля» и З. ХАКИМА «Грех»; Стихи Г. РАХИМА, ТАНЧУЛПАН, И. ФАЗУЛИ, Раш. ГАТАУЛЛИНА, Ф. ГАТИНОЙ.
«Публицистика»: статья М. ЗАРИПОВА «Зеленые родники».
«Литературная критика»: Разговор о современной прозе.
«К истории народа»: статья Г. ФАЙЗРАХМАНОВА «Дух свободы».
«Страницы истории»: Ш. АХМАДУЛЛА. «Извлеки урок с прошлого!»
«К 100-летию Г. Нигмати»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА «Г. Нигмати и эстетическая мысль».
«К 80-летию Р. Ишмуратовой»: статья Л. ИХСАНОВОЙ.
«Искусство»: статья Ф. АХМЕТОВОЙ-УРМАНЧЕ «Булгарская кожа».
«Дневник общественно-культурной жизни».
«На наших обложках»: У ручья (родник в поселке Джалиль Сармановского района); писатель Флюс Латифи.

## In our issue

The conversation between the Minister of Intornation and Press of RT I. Akhmetzyanov and editor-in-chief of magazin «Kazan Utlari» R. Phaizullin.
«Prose and Poetry»: the sequel of noveis «Loop» by T. Galiullin and «Sin» by Z. Khakim; the verses of R. Rakhim, Tanchulpan, I. Phazuli, Rash. Gataullin, Ph. Gatina.
«Publicism»: M. Zaripov's article «Green Springs»
«Literary Criticism»: the conversation about modern prose.
«To the History of Nation»: G. Phaizrakhmanov's article «The Spirit of Freedom».
«History Pages»: Sh. Akhmadulla
«Learn a Lesson from the Past»
«Commemorating the 100 th Anniversary of G. Nigmati»: Ph. Galiullin's article «G. Nigmadi and acsthetic Hought.
«Commemorating the 80 th Anniversary of R. Ishmuratova»: L. Ikhsanova's article.
«Art»: Ph. Akhmetova-Urmanohe article «The Bulgarian Skin».
«The Diary of Social and Cultural Lite»
In our covers: by the stream (the stream in the village Djalil of Sarman District); the writer Phljus Latiphi.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 5.06.97 ел. Басарга кул куелды 8.07.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 ¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 847. Заказ Н-297.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1997 ел.

# СЫНАЛАБЫЗ — СЫНМЫЙБЫЗ



Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министры **Ислам ӘХМӘТҖАНОВның** «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** белән әңгәмәсе.

**Р. Ф.** *Хөрмәтле Ислам әфәнде!*

*Сезнең министр булып эшләвегезгә дә инде биш ел икән. Бу еллар илләр тарихында, халыклар язмышында, хәтта аерым шәхесләр өчен дә гаять гыйбрәтле, истәлекле — бер яктан рух өчен демократик иркенлекләр ачылса, икенче яктан, икътисад өлкәсендә, катаклизмга якын хәл-вәзгыятьләр туды. Сез шушы чор эчендә, үз вазифагызны үтәү елларында халык өчен, басма китаплар, газета-журналлар өчен, һәм дә аларны иҗат итүче язучылар, журналистлар, каләм ияләре өчен нинди уңай үзгәрешләр кертүгә ирештегез дип саныйсыз?*

**И. Ә.** Эшкә тотынган көннәрдә матбугат өлкәсендә азау тешен чыгарган күптәнге танышым: «Һай, братук, акчаның дәрманы кән дә кысылган болгавыр заманда гәҗит-журналларың ябылып бетеп, япа-ялгызың ярык тагарак алдында утырып калмассыңмы?» кебегрәк сорау дип әйтимме инде, киңәш дипме, юллаган иде. Ачыклап китү максатында, 1992 елда республикада 127 гәҗит-журнал нәшер ителүен дә әйтим. Бүген, замананың ай-ваена, вакытлы мәшәкатьләренә илтифат итмичә, 377 басма, сайлаган кыйбласына тугрылыклы калып, халыкка үз сүзен, хак сүзен җиткерүдә хәлдән килгәнчә тырышып эшли. Хәбәрдарлыкның, демократик җәмгыятькә таба йөз тотуыбызның бер бизәге түгелмени бу? Кайдадыр матбугатны тезләндерергә, гаярь, туры сүзле журналистларны эзәрлекләргә тартынмаган бер заманда (андый мисаллар күп — хәтерегезгә генә төшерегез) Татарстанда ай саен диярлек яңа басмалар «борын төртә». Яңгыравык сүз рәвешендә кабул итә күрмәгез: сүз иреген, матбугат ирекен соңгы елларның зур казанышы дип бәялр идем. Моның бөтен асылын-мәгънәсен аңлау максатында яшьләр өчен «Идел» журналын чыгару теләге белән Мәскәүдәге күн

белән тышланган дәү ишек бусагаларын егерме еллап таптарга туры килгәнлеген, өстәге цензорларның күңеленә хуш килмәү сәбәпле, күпме кыю әсәрләрнең кәрҗингә ташлануын, күпме каләм әһеленең йөрәген тотып мендәргә авуын искә төшерергә кирәк.

Моны эшләдек, тегене булдырдык дип сөйләү, дөресрәге, лаф ору, ихластыр, табигатемә каршы. Куелган сорауларның берсе дә җавапсыз калмас, әңгәмә барышында һәркайсын бәйнә-бәйнә тикшерербез, әлегә рәхим итеп, сорауның чираттагысына күчик.

**Р. Ф.** *Матбугат иреген үзегез ничегрәк аңлыйсыз?*

**И. Ә.** Матбугат иреген, сүз иреген, хәбәрдарлыкны соңгы елларның, демократик җәмгыятькә күчү елларының иң зур казанышы дип әйтә алам. Икътисадта хәл ителергә тиешле булып та, хәл ителмәгән мәсьәләләр, чишеләсе төеннәр аз түгел. Сәясәттә дә кул кушырып утырырга вакыт юк — өлгергән мәсьәләләр байтак. Ә менә матбугат ирегең, сүз ирегең, теләгән фикереңне курыкмыйча әйтү ирегең һәркайсыбыз тоеп, укып, ишетеп, шуның шаһите булып яши. Матбугат ирегe һәм Россия, һәм Татарстан Конституцияләре тарафыннан гарантияләнә. Үзегез шаһит: безнең күптәннән инде «менә бу язманы басыгыз, тегесен төшереп калдырыгыз» ише фәрман-боерыклар белән мавыкканыбыз юк. Теге яки бу басма уңаеннан өстәл төюләр, «партбилет белән куркытулар» да бетте. Дөрес, редакцияләр белән без даими элемтәдә. Әлбәттә, ниндидер тәкъдимнәр, юл күрсәтү очраклары, «менә бу мәсьәлә республика өчен мөһимрәк» кебек киңәш тотулар булмый тормый. Әгәр дә теге яки бу язма белән килешмибез икән, безнең бик көчле коралыбыз бар; хокукый дәүләт шартларында ул төп чара булачак — судка мөрәҗәгать итү. Әйтик, кемнеңдер шәхесен кимсеткән, йә булмаса милләтләр арасындагы дуслык-туганлыкка чөй кагарга тырышкан, канкоешка яки конституцион хакимиятне бәреп төшерергә чакырган язмалар була икән, без, һичшиксез, чаралар күрергә тиешбез.

Матбугат ирегe һәм җаваплылык хисе журналист өчен аерылгысыз принцип булырга тиеш. Тиеш, әмма булып бетми. Карагыз безнең кайбер басмаларны. Беренче битеннән алып дүртенче битенә кадәр — үтереш, кыйнау, көчләү, ягъни бүгенге болгавыр заманның гел кара, житешмәгән яклары... Менә бу берьяклылык күңелне әрнетә. Әгәр дә иртәгә «Казанский телеграф» яисә «Крис» ише гәҗитләрдә «Татнефть» берләшмәсендә егерме бишенче миллион тонна «кара алтын» суыртылды» (димәк, нефтьчеләр тотрыклы эшли, димәк, бюджетның керем өлеше үтәләчәгенә өмет арта) яисә «Балтач районы хуҗалыкларында эш хакын түләүдә тоткарлыклар юк» (димәк, авыл кешесенә дә акчаны үз вакытында биреп барып була икән!) кебегрәк хәбәрләр басылып чыкса, ихластыр, аларның әбунәчеләре: баш мөхәррирне алыштырмаганнардыр бит дип, гаҗәпләнүдән иңбашларын сикертәчәкләр. Чөнки аларның кыйблалары башка — бармактан суырып язу, дөньяга «кара күзлек» аша карау... Дөрес, бүгенге тормышта проблемалар бар. Алар элек тә булган, киләчәктә дә булачак. Тормыш проблемаларсыз булалмый. Ләкин тормышның якты яклары да бар бит. Сүз — ул бик зур, бик көчле корал. Әйтер сүзеңне даруга да, агуга да манып әйтергә, сүз белән кешеләрне берләштерергә һәм сүз белән үк бәрелештерергә дә мөмкин. «Шаккатризм» чире татар телендә нәшер ителә торган кайбер басмаларга да хас. Юкны бар дип ышандырырга теләүчеләрнең гомере озын булмый. Ник дигәндә, бүгенге заманда кеше тәгәл һәм туры сүзгә, хакыйкатькә мохтаж.

Укучының, бу иптәш тәнкыйть язмаларын өнәп житкерми, күрәсең, дип уйлап куюы ихтимал. Дөрес түгел. Тәнкыйть кирәкле шәйдер, дип шагыйрь белеп әйткән. Тик ул нигезле, кире каккысыз дәлилләргә нигезләнгән тәнкыйть булсын.

Аннары, форсаттан файдаланып, шуны да әйтәсем килә: безнең басмалар чамадан тыш сәясәт белән мавыгалар. Социологик тикшеренүләр шуны күрсәтте: гәҗитләребез 30—40 процент мәйданнарын сәяси язмаларга бирә. Ә дөнья стандарты бер — 10—12 процент. Дөресен әйтик, халыкны сәясәт туйдырды. Халыкны тынычландыра торган, аның рухи дөньясын баета, базар шартларына яраклашырга өйрәтә торган язмалар күбрәк кирәк безгә. Тагын шуңа да игътибар итәсе килә: безнең матбугатта сәясәт берьяклырак яктыртыла. Сәяси, экономик проблемаларыбызны күтәрәбез, житешсезлекләрне нык камчылыйбыз. Әмма шул төеннәрне чишү юлларын күрсәтмибез, эзләмибез...

**Р. Ф.** *Хәләл акчаңны түләп язылган журналның үз вакытында килеп җитмәвен матбугат ирегенә селтәнү рәвешендә кабул итәргә кирәктер?!*

**И. Ә.** Кайбер журнал-гәҗит редакцияләре — сүз Мәскәү басмалары хакында барганлыгын искәртим — әбунәчеләрдән акча җыеп алалар да, ни хикмәт, алар хакында «оныталар». Янәсе, саллы сәбәпләр теге яки бу басманы үз вакытында, бүтәнчәләтеп әйтсәк, айныкын-айга бастырып барырга һәм таратырга мөмкинлек бирми. Әлеге әңгәмәне әзерләгәндә агымдагы елның апрель уртасына «Искусство кино», «Фотомагазин», «Трамвай», «Костер» ише журналларның бер генә саны да чыкмаганлыгы мәгълүм иде. Ике еллап «Театр» журналының бер санын да күрмәдек. ИТАР-ТАСС ике-өч көн элек аның яңадан чыга башлавын хәбәр итте. Бездә соңарып чыгу очраклары бөтенләй юк түгел, әмма ул бер-ике атнадан узмый. Дөрес, «Казан» журналының күпкәрәк соңарган чаклары да булды. Моның сәбәпләрен ачыклап, министрлыкта басманың баш мөхәррире белән жилле генә сөйләшеп тә алдык. Киләчәктә «озын тәнәфес»ләр булмас дип уйлыйм.

Инде сорауга әйләнеп кайтыйк. Әйе, мондый очракны үз укучыңны санга сукмау, алай гына да түгел, аларны алдау, төп башына утырту дип кабул итәргә кирәк.

**Р. Ф.** *Сез элеккерәк бер чыгышыгызда ике йөзләп яңа нәшрият ачылды дигән идегез. Әйтегезче, шуларның күпмесе татар телендә? Тиражлары? Кәгазь-күләмнәре буенча?..*

**И. Ә.** Итәгатьлек саклап туктап калдыгыз шикелле. Дәвам итегез, яңа ачылган, буын ныгытып килгән яисә күплелеге белән сез шапырынган нәшриятларның кайсысы газиз халкыбыз файдасына эшли соң, диегез. Кулга тотардай китаплары бармы дип тә сорый аласыз.

Нинди генә яссылыкта карасак та, яңа нәшриятлар ачылуны заманның уңай бер төсмере дип карыйм. Бездә теркәлгән 176 нәшриятның байтагында татар китаплары басыла. «Заман», «Иман», «Тан-Заря», «КамАЗ», «Татар китабы», «Мирас», «Идел», «Абак», «Шура», «Раннур», «Фест», «ГЖИ», «Дело», «Еникеева нәшрияты», «Хәтер китабы», «Фән»... Исемлекне тагын да дәвам иттерергә мөмкин. Хуш, исемнәре матур икән, ә менә узган ел, аннан алдагысында ниләр бастырдылар соң алар, дип сорыйсызмы? Санап үтелгәннәрдән «Абак» нәшрияты, мисалга, теләсә нинди халыкара күргәзмәдә куелырлык һәм дә шикләнмичә әйтәм, саллы бүләк алырлык «Әлмәт җырлый» дигән җырлар китабы бастырып чыгарды. Унбиш мең тираж белән! Йә булмаса, тәүге адымнарын ясый башлаган «Татар китабы» нәшриятының Мөхәммәт Мәһдиев турындагы истәлекләрдән һәм дә әдип әсәрләреннән торган «Кеше китә — җыры кала» җыентыгын (тиражы — 10 мең), Фәнис Яруллинның «Мирас» нәшриятында дөнья күргән өч томлы әсәрләрен алыйк. Әлеге китаплар рухи тормышыбыздагы олы бер вакыйга рәвешендә кабул ителергә тиеш иде һәм, шөкер, ул шулай кабул ителде дә!

Шулай итеп, узган елда Татарстандагы нәшриятларда (ә алар хәзер читтә дә бар, әйтик, Мәскәүдә, Төмәндә, Уфада) татар телендә 241 китап дөнья күрде. Күпме бу, азмы? Чагыштырып карау өчен: 1988 елда — 186, 1989 елда — 184, 1990 елда — 208, 1991 елда 127 исемдә татар китабы басылган. Димәк ки, бәрәкәтле хәрәкәтнең, бәйсез нәшриятларның мәйданга чыгып, хәл җыя башлауларының шаһитлары без! Тиздән, бик тиздән аларның энциклопедик басмалар, балалар антологиясе, күренекле әдипләрнең сайланма әсәрләре, сүзлек-белешмәләр, күз явын алырдай альбомнар чыгару кебек бик җитди эшкә алыначакларына иманым камил.

Сүзең барда сөйләп кал дигәндәй, тагын бер нәрсәгә тукталмыйча булмас. Соңгы вакытларда абруйлы җыелыш-киңәшмәләрдә: «китап басу сүнә, корый», «киләчәктә китапсыз калмагаек» ише «аһ» оруларны еш ишетергә туры килгәли. Берәүне дә сәбәпсез чаң кага, дип гаепләргә җыенмыйм. Әмма хакыйкать хакына бер-ике мисалга тукталу кирәк булыр. Чыгыш ясаучыларның кайберләре өлге рәвешендә 1990 елны атый. Ягъни, рухи азыгыбыз — китап галиҗәнапларының төп «казаны» саналган Татарстан китап нәшрияты 1990 елда җәмгысе 259 исемдәге китап чыгарса, узган ел ул нибары 103 кә генә калган. Бәхәсләшергә җыенмыйм, бу өлеше дөрес. Тик бармакларны бөгә-бөгә менә нәрсәләрне игътибарга алыйк әле. Иң әүвәл 259 санының үз эченә нәшрият чыгарган дәреслекләрне дә «йотуын» әйтик («Мәгариф» милли нәшрияты 1992 елда гына оешты). Димәк ки, алдарак аталган 103 кә «Мәгариф» җимешләрен дә — ә алар узган ел 83 булды — өстәү шарт. Чамалыйсыздыр, барыбер «бил алышуы» авыр — ничек кенә әйләндереп карасаң да минус, артка китеш — 259 һәм 186! Чынлап та «ур-ра» кычкырырлык, лаф орырлык бер нәрсә дә юк икән бит. Шулай

да ашыкмыйк. Татарстан китап нәшриятының 1990 елдагы тематик планын кулга алып, саный башлыйк. Чү, Ленин, партия, ярыш, остазлык, интенсификация, алдынгы тәҗрибә, «әйтер сүзем бар»... Авыл агаен ничек яшәргә өйрәткән китаплар дисеңме, партия вожакларының «акыллы сүз-киңәшләре» дисеңме... Менә кайберләре: В. Ленин «Кооперация турында», С. Чикин «Дмитрий Ульянов», М. Миролюбов «Где у коровы молоко», Коллектив «Без — үзгәртеп коручылар», Р. Алюшев «Водосборные сооружения земляных плотин», Р. Хәйретдинов «Рождение Советской Татарии»... Шушыларга охшаш утызлап китап санадым. Күпме көрпә, күпме кибәк, күпме буш, дөресрәге, ялган сүз! Теге минуслы арифметиканы болай да борып була бит. Тегеләйме-болаймы, бүген берәвебезнең дә мондый китапларга юлыкканы юк. Хуплыйк һәм сөеник шуңа!

**Р. Ф.** *Китап кибетләренә кергәч, безнең дәүләт нәшриятларында чыккан китапларга карагач, татар китабының карап торышка ук төс-кыяфәте, ягъни полиграфик эшләнеше шактый ук зәгыйфь икәнлеген күрәсең. Бу аннан башка да аерым рекламага мохтаҗ татар китабының «тез астына» нык суга. Бу хәлне төзәтү юнәлешендә дәүләт берәр төрле чара күрергә җыенамы?*

**И. Ә.** Әлеге тешле сорауны бер-ике ел элегрәк юллаган булсагыз, белмим, нindирәк җавап кайтарыр идек. Былтырлы-быеллы дөнья күргән китапларның күбесенә төс-кыяфәтенә, бизәлешенә тел-теш тидереп булмый. Яшермим, сыйфат мәсьәләсе байтак вакытлар җанны бәләкләде. Төссезлеге, кулга алсаң таралырга торуы аркасында күпме китап «үтмәс товар» рәвешендә кибет шүрлегендә тузан җыеп ятты икән?! Ниһаять, хөкүмәт ишеген шакый, кулга каләм алып исбатлыйраслый торгач, гәҗит-журналлар нәшриятына Алманиянең «Зиглох» фирмасыннан 3,5 миллион (долларлык — сумнарга әйләндерсәк егерме миллиардлап була ул!) китап басу линиясе сатып алынды. Танылган фирма, техникасы камил, төгәл, ничә айлар эшләсә дә, чыгымчалап караган юк. «Зиглох» машиналары сыйфат мәсьәләсендә революция-борылыш ясады дисәм, хакыйкатькә хилафлык китермәмен. «Татарстан Республикасының Кызыл китабы»н, Татарстан китап нәшрияты әзерләгән «Президент Минтимер Шәймиев», «Һәлакәт» (Вакыйф Нуруллин), «Кояш баер алдыннан» (Әмирхан Еники), «Ишан оныгы» (Атилла Расих), Илһам Шакировка багышланган «Илһам», «Фаҗига» (Рәмзи Вәлиев), шулай ук Сезнең «Кыска шигырьләр» кебек китаплар инде дөнья стандартлары кимәленнән бер дә ким түгел.

Үткән ел Министрлар Кабинеты 1997—2001 елларда республика полиграфиясен һәм китап басу эшен яңа баскычка күтәрү хакындагы максатчан программа кабул итте. Шактый озак әзерләнгән һәм шактый вакыт үз сәгате сукканны көтеп яткан программа ул. Бәһасе аның 279(!) миллиард сумга тигез. Программа нигезендә китап баса торган икенче төп базаны — Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатын яңа машиналар белән җиһазлау да, дәүләт нәшриятларын компьютерлаштыру да каралган.

**Р. Ф.** *Без үскәндә гөрләп торган китап кибетләре хәзер сүнүгә таба бара. Аларның күбесе ябылды да инде. Дөрес, кайбер кибетләр почмагында китап сату бүлекләре күренгәли. Бу күренеш, безнеңчә, китапның халык күңелендә югалатоныклана баруын раслый. Татар китабын югалту — милләтебезнең рухынҗанын да югалту дигән сүз. Бу хакта да Сезнең фикерне ишетәсе иде.*

**И. Ә.** Һәрбер язучының өч җан газабы бар, диләр. Беренчесе — иҗат газабы. Төн йокыларын качырган, көннәр буе тынгы бирмәгән, кайчагында иҗат кешесенең холкын бозган газап. Ләззәтле газап. Азау тешен чыгарган язучы яхшы белә: бу газап әле чын газап түгел. Иң авыры — әсәреңне язып бетергәч, аны бастырып чыгаруга бәйле мәшәкатьләр. Язган, инде басылган китабыңны халыкка житкерү, укыйлармы дигән шиккә җавап эзләү — газапның өченчесе.

Базар капкасын ачып кергәндә төрле гаҗәп нәрсәләргә юлыгабыз. Табышсыз мал сылтавы белән кайчандыр гөрләп эшләп торган байтак китап кибетләренә йозак салыну — шундый гаҗәпләрнең берсе дияр идем. Базар мөнәсәбәтләренә кучкәнче китап сәүдәсе ике юнәлештә: «Татпотребсоюз»га караган кибетләр һәм дә Татарстан китап сәүдә берләшмәсе («Таткнигообъединение») аша барды. Беренчесе, рухи азыкны, нигездә, авыл халкына җиткерсә, икенчесе — безнең министрлыкка караганы — шәһәр җирендә сәүдә итә. Моннан нәкъ ун ел элегрәк республика авылларында 71 махсус китап кибете һәм 540 китап почмагы булуын укыганым бар. Хәзер күпме алар, салада китап сәүдәсенең перспективасы бармы,

дөресен әйтеп сөйләшик, турыдан-туры шөгыльләнмәгәч, мәгълүматым аз, шул сәбәпле сорауның бу өлешен бүтәннәргә калдырам.

«Таткнигобъединение»гә килгәндә исә шуны әйтергә мөмкин: тирә-як өлкә-республикаларда, шул хисаптан, Башкортстанда да, мондый берләшмәләр тәмам таркалып бетүгә карамастан, бездәгесе яши, базар таләпләренә яраклаша, халыкны китапка якынайту юлларын уйлый. Әле күптән түгел Дәүләт Советы депутаты Фәндәс Сафиуллин: «Кибетләрне таратасыз!» — дип дәгъва белдерде.

Фәндәс агага моның белән килешмәвемне белдердем. Ризалашмаска нигез дә бар: расланганнан, ягъни 1992 ел ахырыннан бирле, мәркәзебездәге бер генә кибетне дә елгыр алыпсатарларга, гомумән, чит кулларга биргән булмады. Шөкер, бу мәсьәләдә Минтимер Шәймиев тарафыннан да, Фәрит Мөхәммәтшин ягыннан да яклау бар — берәү дә китап кибетләренә кул сузарга тиеш түгел! Хәер, кайбер яңа байлар купшы сүзләр белән җәмәгатьчелекне «менә бу кибеттә җәннәт ясыйбыз» дип ышандырырга тырышалар. Чистай урамындагы «Төрки китап» кибетен дә җәннәт, рухият җәннәте ясарга вәгъдә иткән иделәр түгелме соң?! Үзәктәге бинаны кулга төшерү өчен башта «монысын эшлибез, тегесен булдырабыз» ише вәгъдә яудыралар. Аннары инде, кибетне кулга төшергәч, китапны төрле яклап кыса башлыйлар. Тора-бара китапны пәрәвезле почмакка таба кысрыклыйлар. Кайчагында әлеге кибетләрне даулаучылар урау юллары белән эш итеп, үз ягына мәшһүр зыялыларны да аударып, «татар» сүзе белән авыз чайкыйлар. Янәсе, без халык өчен чабабыз, биредә гел татар китабы гына булыр, арзан бәягә сатылыр ул. Юк инде, җәмәгать, берәү дә ике тиенгә юнәткәнен бер тиенгә сатарга ашыкмас. Булган хәл түгел ул!

Форсаттан файдаланып, Татарстан китап сәүдә берләшмәсенең узган ел халыкка 15 миллиард сумнан артык китап сатуын әйтеп узыйм. Күңелгә җылы өстәгәне шул: халык акрынлап кибеткә кайта, суынган эзләрне яңарта башлады. Татар китабына булган кызыксыну арту да — уңай үзгәреш.

Узган елгы парламент тыңлауларының — китап язмышына, китап сәүдәсенә багышланган тыңлауларның — шифалы йогынтысын тоеп яшибез. Ихластыр, сырхауның чын диагнозын билгеләргә ярдәм иткән әлеге җитди сөйләшү авыл җирендәге китап сәүдәсен дә җанландырып җибәрде. Эленгән йозаклар ачылды, китап юллап нәшрият сукмакларын таптаучылар ишәйде. Күптән түгел Биектауда китап бәйрәме оештырылганлыгын, анда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 32 миллион сумлык әдәбият сатылуын әйттеләр. Мондый күркәм үрнәк бер район кысаларында гына йомылып калмас дигән өметтә яшибез.

Сәүдә хакында сүз чыккач, кайчагында: «Китап кибетендә китап кына сатылырга тиеш»,— дигән кискен фикерләр яңгырый. Хак, кибетләрнең кайберләрендә юлдаш тауарлар, әйтик, каләм-ручка, калькулятор, глобус, офис кирәк-ярагы, магнитофон-диктофон, картиналар ише тауарлар да сатыла. Сәбәбе мәгълүм: салымнар рәхимсез, аренда бәясе аяктан егарлык, ә егылырга ярамый, димәк ки, заманга яраклашып, үз көненне үзең күрергә өйрәнә башлыйсың. Дәүләтнең дә төпсез кесәсе юк лабаса! Әле кайчан гына Алманиядә нәниләрне кызыктыру теләгендә китап кибетләренең попугайлар белән маймыл тотуын, мавыктыргыч уеннар оештыруын язып чыктылар. Монда кергән сабый китап алдырмыйча чыкмый инде ул. Мәскәү, Санкт-Петербург, Ташкент калаларындагы китап кибетләре дә буш мәйданнан оста файдаланалар: кайсы валюта алыштыру пункты ачып җибәргән, кайсы фотография ясый, кайсы көндәлек матбугат сата. Җыйнап әйтсәк, базарга яраклаша...

**Р. Ф.** *Мөгаен, бу Сезнең өчен иң уңайсыз сораудыр. Дөньяда каләм хакы дигән сүз бар. Сез үзегез дә матбугатта озак эшләп, күренекле журналист буларак, берничә китап чыгарган кеше. Ул вакытларда матбугатта актив эшләгән кешегә, китаплар чыгара торган язучы халкына гонорар дигән хикмәт белән тормыш итәргә, һич югында «җан асрарга» була иде. Ә хәзер? Каләм ияләребезнең гонорары кульязмаларын машинкадан чыгару бәрабәренә тиң дәрәҗәдә. Белүебезчә, Россиядә, байтак регионнарда, шул исәптән күрше Башкортстанда каләм әһелләренә түләү бездәгегә караганда инде ничә еллар буе күп мәртәбәләр артыграк. Былтыр Сезнең дә бу хакта матбугатта ачынып язган мәкалә-чыгышыгыз иста. Ул күпләрнең, бигрәк тә язучылар күңеленә, бик хуш килгән иде. Шул чыгыштан соң хәлләр үзгәрдеме?*

**И. Ә.** Шагыйрь Рөстәм Мингалимнең менә мондый шигъри юллары бар:

Дөнья безне сыный...
Утка терәп сыный...
Суга терәп сыный...

Дөньяны, еламсырак бәбине буш имезлек биреп алдаган шикелле, алдап булмый шул. Икътисадтагы киеренкелек, бәяләрнең котырынуы рухи дөньяга да бәреп керде. «Базар» сүзе иҗат әһелләре өчен беренче вакытларда «каравыл» рәвешендә кабул ителде дисәм, хата булмастыр. Элегрәк һәммәсе көйләнгән, җайлы гына тәгәри иде — яңа басылып чыккан китабың гонорарына рәхәтләнеп берничә ел яши аласың, әдәби фондны да онытып бетермисең, бушлай путевкалар... Ә базар ыгы-зыгысы башлангач? Эш хакы яшәү рәвешенә тәңгәл түгел, гонорарлар түбән, җитмәсә, хәләл эшләп тапканыңны да үз вакытында алып булмый. Базар зилзиләсе каләм осталарының кайберләрен шундый итеп ярга китереп сылады ки, бүгенгәчә хәлгә керә алмыйча интегүчеләре бар.

Ә хәзер сорауга әйләнеп кайтыйк. Сезнең өчен иң уңайсыз сораудыр дип, хәлгә керергә тырышуыгызга рәхмәт. Язмага «җим» туплап, куелган сорауга җавап эзләп йөргәндә гонорарлар да артып куйды бит әле. Күпкә, өч-дүрт тапкырга артты. Моны раслау ниятендә Сез җитәкчелек иткән «Казан утлары» мисалына тукталып узыйк. 16,8 табаклы «Казан утлары» агымдагы ел башына кадәр авторларына бер санга 4 млн. 80 мең сум хисабыннан гонорар түләп килде (чагыштыру өчен: «Сөембикә» — 4 млн. 650 мең сум, «Идел» — 1 млн. 848 мең сум). Ә хәзер Министрлар Кабинетының 1996 ел, 30 декабрь карары белән «Казан утлары»ның бер саны 13 млн. 578 мең сумга бәрабәр («Сөембикә» — 15 млн. 486 мең, «Идел» — 8 млн. 052 мең).

Хәзер «Башкортстанда гонорар күләме берничә тапкыр артыграк» дигән сүзләрегезне ачыклап китик. Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер диләрме әле? Бу юлы да шулайрак килеп чыккан бугай. Күптән түгел генә Алабуга шәһәрендә Башкортстандагы хезмәттәшләребез белән очрашып, бер-беребезнең хәлләрен белешкән идек. Сүзгә-сүз ялганып, гонорарлар хакында да фикер алыштык. Һәм менә ниләр ачыкланды: «Агыйдел» журналының (күләме 12 табак) бер санга гонорары 3 млн. 700 меңгә, «Башкортстан кызы»ның — 1 млн. 540 меңгә, «Һәнәк»нең 2 млн. 125 мең сумга тигез. Күренгәнчә, күршеләрнең хәле күпкә өстен дип раслау өчен җирлек юк. Нәшриятлардагы гонорарлар да артты. Бүген-иртәгә бюджет өлкәсендәгеләрнең, димәк, сүз безнең хакта да бара, эш хаклары арттырылачак.

**Р. Ф.** *Теңкәгезгә тиеп дигәндәй, ай саен, декада саен, без Сездән — Министрлыктан акча сорыйбыз. Сез, үз чиратыгызда, дәүләт бюджетыннан акча юлларга тырышасыз. Кыскасы, без барыбыз да — «бюджетниклар». Рәхмәт, дәүләт безнең ихтыяҗларны күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләндереп килә. Без еш кына Министрлыктан, шөкер, фәлән млн. сум акча күчерәннәр, дип сөенәбез. Әмма шул сумманы бухгалтерия аша бүлә башлагач, шунысы ачыклана: без 20 ләп дәүләт салымы түләргә тиешбез икән. Кыскасы, көч, вакыт һәм финанс ресурсларын болай исраф иткәнче, шушы процессны үтәүче йөзләгән чиновник-хезмәткәрләрдән тыш, тиешле кирәк акчаны турыдан-туры салымнарсыз гына финанслап булмый микәнни?*

**И. Ә.** Тәүге карашка бөтенесе дөрес шикелле: дәүләттән бер кулыбыз белән алсак, икенчесе белән салым рәвешендә кайтарып бирәбез. Әйтелгәнчә, тәүге карашка гына бу шулай. Гәҗит-журнал редакцияләре үз чыгымнарының берникадәр өлешен алынган керем-табышлары исәбенә каплыйлар. Керем подпискадан килә, игълан-белдерүләрдән, рекламадан, алыш-биреш итүдән (мисал рәвешендә, «Сам хозяин» гәҗите редакциясенең узган ел 300 миллион сумлап яшелчә, җиләк-җимеш орлыгы сатуны оештыруын әйтә алам) килә. Һәм әлеге керем күләмнәренең ай саен, ел саен төрле сәбәпләр аркасында үзгәреп, «биеп» торулары ихтимал. Бездә елына рекламадан гына 700—800 миллион сумлап керем алучы шәһәр гәҗитләре бар. Уйлашыйк әле: алар бу керемнән салым түләргә тиешләрме? Әлбәттә! Салым турындагы, бюджет турындагы законнар алдында һәркем тигез. Ә менә кемнең ничек һәм күпме түләргә тиешлеге — монысы башка мәсьәлә. Салым дөньясының үз сәясәте булырга тиеш. Берничә ел элегрәк сездәге — «Казан утлары»ндагы салымнар саны хәмер белән сату иткән кибетнекенә бәрабәр иде. Әлбәттә, моның белән ризалашуы кыен. Мәдәниятә, рухи дөньяга турыдан-туры мөнәсәбәте булган коллективлар салым мәсьәләсендә мөмкин кадәр льготалардан файдаланырга тиешләр дип саныйм. Хәер, андый льготалардан файдаланабыз да. Әйтик, «Россия Федерациясендә

массакүләм матбугат чараларына һәм китап бастыруга дәүләт булышлыгы турында»гы Закон нигезендә, мисалга, «Казан утлары» табышның федераль бюджетка күчерелергә тиешле өлешенә тиешле салымнан азат ителгән. Журнал тәрҗемә кылмыйча да яхшы аңлашылган НДСны да түләми. Болар бит арадагы иң саллы салымнар. Аннары, реклама, коммерция юлы белән килгән акчаның 40 процентын журналда эшләүчеләр мәнфәгатен канәгатьләндерүгә җибәрә аласыз.

**Р. Ф.** *Кызганыч, Сез әйткән бу өстәмә керемгә ирешү безнең журнал шартларында мөмкин түгел диярлек. Коммерция, реклама белән шөгыльләнгән очракта да, файдалы эш коэффициенты бик түбән булыр иде. Үзегез беләсез, реклама оперативлыкка бәйле. Ә безнең журнал яртышар ел диярлек алдан әзерләнә. Әгәр дә без, кайбер басмалар юлы белән китсәк, бүгенге «Казан утлары» татар халкының төп журналы саналган журнал да була алмас иде. Безнең максат укучыларыбызны ишәйтү, тиражны арттыру, шушы юнәлештә матди аякка басу, ныгу.*

**И. Ә.** Сезнең белән өлешчә килешәм һәм башлаган сүземне дәвам итәм. Бүген Россиянең урта гасырлардагы салым фәлсәфәсен алга сөрүен күреп яшибез. Янәсе, салым күбрәк булган саен, казнадагы акча да артачак. Аһ, алай түгел шул! Алга киткән дәүләтләр башка төрлерәк фәлсәфәгә табына: налог та түбән, казнада да акча мул.

**Р. Ф.** *Кайвакыт безнең кайбер зыялы иптәшләребез авызыннан «Бөтен матбугат, нәшриятлар ирекле йөзүгә китәргә тиешләр», дигән сүзләр ишетергә туры килә. Мондый фикер белән һич килешеп булмый...*

**И. Ә.** Мин дә килешә алмыйм. Ни өчен дигәндә, читтә дә, бу очракта Көнбатышны күздә тотам, дотация алып яшәүче басмалар бар. Бу — балалар басмалары, бу — фәнни басмалар, яшьләргә, аз санлы милләтләргә исемләнгән басмалар, бу — дәүләт сәясәтенең асылын аңлатып бирүче рәсми басмалар. Әлбәттә, базар шартларына җайлашканда үз көнеңне үзең күрү әйбәт нәрсәдер, әмма матбугатның абсолют үзфинанслауга күчүе турында сүз алып барырга иртәрәк әле. Аннары медальнең икенче ягы да бар. Әйтик, рус телендә чыккан гәҗитләр бар, татар телендәгеләре бар. Аларның һәрберсе чыгымнарның бер өлешен реклама хисабына каплап барырга тырыша. Әмма бер хакыйкатьне дә онытмыйк: әлегә бүген бизнесмен-эшкуарларның күпчелеге рус телендәге басмаларның ишекләрен шакый. Күпсенеп әйтү түгел. Бу — традиция, бу — телләр турындагы законның тыйнак атлавы... Татар телендәге басмалар партия җитәкчелек иткән заманнарда икенче сортлыраклар рәтендә йөриләр иде. Әле бүген дә бу карашны бөтенләй бетерә алганыбыз юк. Әмма татар телендәге басмаларга мөнәсәбәт үткән еллар белән чагыштырганда нык үзгәрде. Уңай якка, әлбәттә!

**Р. Ф.** *Татар телендә иң күп тиражлы журнал кайда чыга икән дигән уй Сезгә дә килә торгандыр. Ул — Уфада чыга торган яшьләр журналы — «Тулпар». Тиражы — 35 мең чамасы. Ә безнең «Идел»нең, ике телдәгесен дә исәпләп, әбунәчеләр саны 5000 данә дә юк. Бу хәлне Сез ничек аңлатасыз?*

**И. Ә.** Яшермим, тугандаш Башкортостанда яшьләр өчен журнал басыла башлауны куанычлы вакыйга рәвешендә кабул иттек. Өч ел чыгып килү дәверендә абруе торган саен артуга да шаһитбыз. 1994 елда дөньяга килүе хакында «аваз» биргән бу басма баштарак 6—7 мең данә белән таралып, аннан соңгы елда тиражын 15 меңгә җиткерә. Ә былтыр әлеге басманы 36 мең кеше яздыра. Килешик, теләсә кемне кызыктырырлык үсеш. Укучыларыбызда: сәбәп нәрсәдә икән соң, дигән сорау тууы ихтимал. Март ае азагында «Тулпар»ның баш мөхәррире Римат Кашапов белән очрашып, нәкъ менә шушы хакта гәп корган идек. Мәгълүм ки, Башкортостанда бер миллион ярымлап татар яши, газиз телебездә укучылар саны тагын да күбрәк. Монысы булдымы бер. Икенчедән, күршеләребездә «Тулпар» — татар телендәге бердәнбер журнал һәм андый басмага ихтыяҗ зур. Татарстанда исә журналлар байтак: «Казан утлары», «Идел», «Аргамак», «Сөембикә», «Татарстан», «Мирас», «Ялкын», «Мәгариф», «Казан», «Гасырлар авазы», «Чаян», «Салават күпере»... Журнал үзенең даирәсен киңәйтеп, авылда яшәүче гаиләләр, хатын-кызлар, социаль мәсьәләләр хакында

махсус сәхифәләр оештыра һәм бу тиражга шифалы йогынты ясый. Монысы, миңа калса, өченче сәбәп.

**Р. Ф.** *Килешәм, басмалар күп. Әйдәгез карыйк әле: кайсы басма нинди тираж белән чыга? Бу мәгълүматлар сезгә дә, безгә дә яхшы билгеле. Берәүләрнең тиражы, әйтик, йөзләр белән генә исәпләнә, икенчеләрнең исә дистә меңнәр белән. Әмма штатлар дисеңме, эш шартлары (хәтта, кайбер аз тиражлы журналларда эшләүчеләрнеке яхшырак та әле), хезмәт хаклары дисезме, нигездә тигез. Нәкъ тегә чаклардагы «уровниловка» шикелле. Бу, безнеңчә, нормаль хәл түгел. Хәтерегездәдер, 10—15 еллар элек басмаларның иҗтимагый әһәмияте, сыйфаты һәм халыкка таралуын исәпкә алып, гәҗит-журналлар, категорияләргә бүленә иде. Бәлки, шул еллардагы тәртипкә яңадан кайтыргадыр?*

**И. Ә.** Тиражлар саегу белән килешмичә мөмкин түгел. Дөрес, бездә нәшер ителгән басмаларның тиражы мәскәүдәгеләрнеке кебек үк «ишелеп» төшмәде. Туксанынчы еллар башында «Знамя» журналының миллион данә белән басылганлыгын беләбез. Ә хәзер? Бер мең тапкырга (!) кимеде аның тиражы. «Новый мир»ныкы — мең ярым тапкырга! Ә безнең татар телендәге журналларны укучылар саны күпмегә кимеде дип беләсез? Дөрес, кимүен кимеде, әмма бу хәтле үк күпкә түгел, нибары биш-алты тапкырга. Кул астындагы саннар соңгы вакытларда кайбер басмаларның тиражы артуы хакында сөйли. Әйтик, шушы айларда үзенең 75 еллыгын бәйрәм итүче «Казан утлары» журналын алдыручылар саны берничә меңгә ишәйде. Шушы урында берникадәр читенеш ясап булса да татар халкының баш журналы дип йөртелгән мөхтәрәм басма хакында берничә җөмлә әйтмичә уза алмыйм. Баш журнал — ифрат та төгәл һәм дөрес бәяләмә бу. «Казан утлары»н — XX гасыр дәвамында татар халкының рухи дөньясын: тарихын, әдәбиятын, телен, мәдәниятен, сәнгатен чагылдырган энциклопедик басма дип авыз тутырып әйтә алабыз. Журналның иҗтимагый абруе искиткеч дәрәҗәдә зур. Редакция даирәсенә әдәбиятыбызның талантлы әдипләре тупланган. Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев «Казан утлары» редакциясенә юллаган котлау сүзендә билгеләп узганча, татар мәдәниятенең рухи көзгесенә әверелгән басма элеккеге һәм бүгенге матур традицияләрне тагын да баетыр, республиканың мәдәни, иҗтимагый тормышы үзгәндә балкып торыр.

Хәзер башлаган сүзебезгә әйләнеп кайтыйк. Бу хакта сөйләгәндә бөтенесен икътисадка гына әйләндереп калдырырга кирәкмидер. Бүгенге көн әдәбиятының сыйфаты, миңа калса, элекке еллардагыныкыннан берникадәр калыша. Укучыны алдавы кыен, кайда бөртек, кайда кибәк икәнлеген ул бик чамалый. Мәскәүдәге калын басмаларга хас чир атыш-үтереш, талау, җинаятьчеләр, фәхишәләр дөньясын күрсәтүдән гыйбарәт.

Кайберәүләр: әдәби калын журналларның заманы үткәндә калды дип расларга тырыша. Килешмим! Кискен итеп килешмәскә нигез дә бар. Сорос фонды узган ел 2500 китапханәдә «Кайсы өч журналны алдырыр идегез?» дигән сораулы анкета тарата. Һәм бик мәгънәле җаваплар алына: 2500 китапханәнең 2495е — «Иностранная литература», 2100е — «Знамя», 2000е — «Новый мир», 1600е — «Октябрь» белән «Дружба народов» журналларына яздыруларын сорыйлар. Без дә Милли китапханә белән бергәләп шундый хисап-кызыксыну уздырырга йөрибез.

Инде бердәй эш шартларына, хезмәт хакларына әйләнеп кайтыйк. Соңгысын, ягъни хезмәт хакын билгеләгәндә бөтенебез өчен закон бер — бердәм тариф челтәре, шуның нигезендә эшләнгән кулланма. Челтәрдә (уңайлык өчен шулай дип әйтик) журналда эшләүче һәркемнең нинди вазифа башкаруына, стажына, белеменә, эшкә мөнәсәбәтенә, гыйльми дәрәҗәсенә, булдыклылыгына, лаек бүләкләренә карап үз урыны, үз куышы, бүтәнчәләтеп әйтсәк, үз разряды бар. Ил буенча шулай бер канун нигезендә яшибез.

Штатлар республиканың министрлар кабинеты карары белән раслана. Әлбәттә, басманың күләме, әһәмияте, форматы, айга яисә атнага ничә тапкыр һәм нинди телләрдә чыгуы истә тотыла. Хезмәт хакын, эш шартларын тиражга бәйләү хакындагы тәкъдим белән килешә алмыйм. Һәм менә ни өчен. Ярый, шундый карарга килдек ди. Республикабыздагы чуваш туганнар өчен өч ел элек чыга башлаган «Сувар» гәҗитенең тиражы 2 мең тирәсе. Ә «Татарстан яшьләре»неке — 150 мең. Әгәр тәкъдим ителгән принцип нигезендә эшләсәк, «Сувар»га нибары бер бүлмә, 3 штат бирергә туры килер иде. Болай эшләгәндә мәйданда бер-ике басманың гына калачагы көн кебек ачык. Дөрес булырмы бу — уйлашыйк әле.

Инануымча, һәр басма — аз тиражлымы ул, күп меңле укучылары булган басмамы — аерма юк, әйбәт шартларда эшләп, житәрлек акча алып яшәргә тиешләр. Элегрәк барча редакцияләрнең, китап нәшриятының Бауман урамындагы Матбугат йортына сыешуларын хәтерлибез. Аннары барча редакцияләр Пресса йортына күченде. Соңрак булганнарына Чистай урамындагы дәү йортның икенче каты, Язучылар берлегендәге бүлмәләр («Идел», «Салават күпере» журналлары редакцияләре) өстәлде. Шартларны кемнедер рәнжетү бәрабәренә түгел, Пресса йортыннан кайбер редакцияләрне чыгарып, аларга башка жирдән иркенәйбәт бүлмәләр бирү хисабына яхшыртырга исәп. Әлеге юнәлештә берникадәр эш башланды да инде.

**Р. Ф.** *Республикада берничә йөзләп гәҗит-журнал нәшер ителә, нәшриятлар саны артуын күреп-ишетеп торабыз, дип әйттегез. Гомерен матбага эшенә бәйләгән кеше бер-бере белән аралашмыйча, хәл-әхвәл белешмичә, очрашмыйча яши алмый. Аннары алар җылы сүзгә, хөрмәт-олылауга да бик мохтаҗлар бит. Элегрәк елына бер тапкыр булса да аларны җыеп котлыйлар иде...*

**И. Ә.** Тел төбегезне аңладым, Равил әфәнде. Әйтергә теләгән фикерегез белән килешмичә мөмкин түгел. Матбугат көнен без 1922 елдан алып 5 майда — коммунистик рухлы «Правда» гәҗитенең тәүге саны чыккан көндә бәйрәм иттек. Берничә ел элегрәк «Ведомости» гәҗитенең беренче саны чыккан көнгә — 13 гыйнварга — туры китереп, Россиядә бәйсез матбага көне билгеләп үтелә башлады. Моннан соң: «Татарстанның кайчан үз матбугат көне булыр?»ише сораулар ишетә, хатлар ала башладык. Һәм Журналистлар берлегендә саллы сөйләшү уздырдык, матбугат тарихын өйрәнүче күренекле галимнәрне чакырып фикерләштек. Төрле тәкъдимнәр булды. Берәүләр, әйтик, Матбугат бәйрәмен Исмәгыйль Гаспралы мөхәррирлегендә дөнья күргән «Тәржеман» чыга башлаган вакытка билгеләргә кирәк диделәр. Әлеге фикер белән килешеп булмый: гәҗит бит безнеке түгел, ул әзәрбайҗанга якын сөйләктә чыккан. «Тәржеман»ның әһәмияте безнең милләтнең мәдәни һәм фикери үсеше өчен гаять зур, ләкин ул татар гәҗите түгел. Бүтәнрәк тәкъдимнәрне җентекләп тикшергәннән соң, күпчелек Матбугат көнен 1905 елда Петербургта татар телендәге беренче басма гәҗитне — «Нур»ны чыгаруга рәсми рөхсәт алу көнендә — 19 майда билгеләп үтәргә килеште. Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев та хуплады бу тәкъдимне. Хәзер аны Дәүләт Советы аша рәсмиләштерәсе генә калды.

Матбагасыз, китапсыз халык — тарихсыз, телсез, чукрак халык, диләр. Шөкер, безнең бай тарихыбыз да бар, телебез дә исән, гәҗит-журналларыбыз, китапларыбыз да бихисап. Дөрес, бөтенесе ал да гөл генә түгел, хәл ителергә тиешле мәсьәләләр дә байтак. Әмма мөхтәрәм журналны укучылар базар капкасын ачып кергәндә туган кыенлыкларның вакытлыча икәнлеген аңламыйлардыр дигән фикердән ерак торам. Һәм аларның якын елларда хәл ителәчәгенә һич шик юк. Үткәнне — бүгенгегә, бүгенгене — киләчәккә тоташтыручы матбаганың, китапның гомере озын булсын. Рухи азыксыз дөньясы сансыз бит аның.

*Май, 1997.*

# ШИГЪРИЯТ



## Гәрәй Рәхим

### УЙДЫК-УЙДЫК УЙЛАР

### Болгар бабаларга ачык хат

*Бу шигырь 1996 елның 23 январь төнендә Татарстанның Спасс районы Болгар шәһәрендәге кунакханәдә язылды. Мин борынгы болгар бабаларыбыз яшәгән изге җирдә ялгызым төн үткәрдем...*

Сез — Болгар бабалары,
Без — Болгар балалары.
Без бит тарих чылбырында
Боҗралар гына бары.

Сез — Болгарның юл башы,
Ә без — аның дәвамы.
Сездән өлге алабыз без,
Һәм дә рухи дәваны.

Арабызда зур чорлар,
Әмма уртак ич җырлар!
Сездән безгә мирас булып
Калган Иделләр, кырлар.

Болыннарда сез дә күргән
Шул ук чәчәкләр үсә.
Безнең битләрне иркәләп
Болгар җилләре исә.

Кадерлибез сезнең куллар
Корган Болгар оясын.
Таң белән каршы алабыз
Изге Болгар кояшын.

Кемнәр килгән, кемнәр киткән —
Гасыр артыннан гасыр.
Ята милләт маңгаена
Тарих сызган күпме сыр.

Изге Болгар изгелеге
Иманыбыз күгендә.
Сез табынган Тәңребезне
Олылыйбыз бүген дә.

Без мәҗүси... Без мөселман...
Кем сызган аермасын?!.
Ходаем ата йортыннан —
Болгардан аермасын.

Без Болгарның бөеклеген
Саклаган хәлдә генә
Азатлык яулый алабыз
Татарстан иленә.

Сез — Болгар бабалары,
Без — аның балалары.
Бөтенебез бер чылбырның
Тарихи бөҗралары.

*1996*

## Самоед

*(Татарыма каш җыерып әйтелгән сүз)*

Чулманыңда чумганым...
Иделеңне иңләвем...
Чистаеңда чистарып
Чирмешәндә чирләвем...

Татарстан, тар җирем.
Тар күңел татар илем...
Кендек җебем син булганга
Тик сине яклар җирем.

Татарым син, тарым син,
Кендек бавым, ярым син.
«Югым» түгел, «Барым» син,
Борынгы болгарым син.

Болгар өчен көрәштем[1].
Татар өчен көрәштем[2].

---

[1] Татарның беренче тарихи нәфис фильмы «Исә Болгар җилләре» сценарие авторларының берсе булуыма ишарә. (Автор)
[2] «Татар поэзиясе антологиясенең төзүчесе булуыма ишарә. (Автор)

Хәзер: «Син соң кем соң[1],— диләр,—
Син бит,— диләр,— керәшен!..»[2]

Болгардан аермакчы,
Татардан аермакчы.
Шулай тарих һәм халыкны
Вак-ваклап каермакчы.

Алайса әйт: «Кит, мишәрем,
Дуңгызыңны ишәрем!..
Ычкын моннан, татарым,
Ботыңнан тотып атарым!..»

Алай булгач Чирмешәнне
Чирмешнеке диикме?..
Алай булгач Кукмараны
Күк марилар диикме?..

Типтәрен дә, кырымын да,
Себерен дә себерсәң —
Тарихыңда нәрсә калыр,
Кендек бавың өздерсәң?..

Әй, татар, татар гынам,
Татар гынам, тар гынам.
Үз илендә үз булалмый
Интегә татар гынам.

Чын татарның шәм яктысы
Төшми Татарстанга.
Аның каравы балкый ул
Төрле-төрле «...стан»да.

Бәлки вакыт инде безгә
Аз-маз сабак аласы —
Казан булып Казаныбыз
Күптән «Казань» каласы.

Телен оныта татар,
Үзен оныта татар.
Татарның башын ашаучы
Бердәнбер халык — татар...

Болай үз башыңны ашау
Заманы үтәр... үтәр...
Йа, Хода!.. Татарның аты
«Самоед»[3] булып китәр...

---

[1] Минем паспорт буенча исемем Родионов Григорий Васильевич. (Автор)

[2] С. Шәйхетдинованың «Куда дуют ветры древних Булгар» дигән мәкаләсе («Известия Татарстана» газетасы, 2 апрель, 1994 ел), З. Зәйнуллинның Татарстан мәдәният фонды съездындагы чыгышы һәм матбугатта күренгән башка кайбер язмалар күздә тотыла. (Автор)

[3] Үзен-үзе ашаучы. Төньякта яшәүче бер аз санлы халыкны руслар шушы исем белән атыйлар.

* * *

Бу шигырьне файда эзләп
Укый күрмә, татарым...
Йөрәк каны тамган җирдә
Бел бары тик моң барын.

*1996*

## Вафирә җыры

*Халкыбызның яраткан җырчысы*
*Вафирә Гыйззәтуллинага*

Сыйгандыр аңа туган халкымның
Иң асыл моңы, дәвере, чоры.
Күңелгә якын таныш җыр бит ул —
Үзәк өздергеч Вафирә җыры.

Монда туган ил, изге Иделе,
Кара урманы, болыны, кыры.
Туган ил кебек игелекле син,
Изгелекле син, Вафирә җыры.

Халкымның теле, халкымның дене,
Балкыйдыр илнең өмет йолдызы.
Чыңла, тынма син, гел яңгырап тор,
Син халык җыры, Вафирә җыры.

*1986*

## Сездәй ирләр яшәгәндә

*Әлмәт районы Шарлама авылы егете «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Ренат Галиевка һәм нефть якларында туып, бүгенгә кадәр шунда ут уйнаткан күренекле якташ егетләргә*

Җәйрәп ята илем киңлегендә
Әлмәт, Шөгер, Баулы, Бөгелмә,
Азнакае, Зәе, Шушмалары —
Чал тарихны салган иңенә.

Тугайларда яшел әрәмәләр,
Әрәмәдә яшел балтырган.
Шул балтырган шулпасыннан гына
Арык тәндә бер уч җан торган.

Тик тупылдап кына торган җаннар,
Тик сулкылдап кына типкән каннар
Безне исән-имин саклаган.
Чөнки сине, минем бөек халкым,
Үзеңә хас ирләр яклаган.

Туган халкы мул яшәсен өчен
Җирнең маен сыгып ала торган,
Туган халкы инде яңадан да
Ашамасын өчен балтырган —
Бөтен җанын-тәнен фида кылган
Фидакярлар туган бу якта.
...Үз җирендә үз җырларын тапкан
Ирләр алган илне кочакка.

Ватанпәрвәр егетләр сез бүген,
Туган якның патриотлары!
Нефть якларының титаннары,
Алга табан барыр хутлары!

Инде Әлмәт, Шөгер, Баулы, Зәйләр,
Азнакайлар, Шушма, ямьле җәйләр
Артка табан юл алмаячак!
Илдә сездәй ирләр яшәгәндә
Туган халкым югалмаячак!..

*1997*

## Әйдә

Әйдә, киттек!
Менә алтын чана,
Көмеш чаптар җиктем.
Кил, утыр!
Җиз дилбегә кагып,
Җиз кыңгырау тагып
Көмеш чаптар күккә юыртыр.

Әйдә, утыр!
Янәшәмә генә,
Кайнар янтыгыма терәлеп.
Китик бергә!
Сәлам биреп илгә
Галәмнәрне гизеп йөр әле.

Әйдә, йөре!
Минем белән бергә
Йолдызларга кадәр күтәрел!
Айга күзең кысып,
Кояш аша узып
Галәм тыкрыкларын үт әле!

Әйдә, үтче!
Үтче йөрәгемә.
Көмеш чаптар җигеп кер җанга.
Әле син күрмәгән,
Галәм дә белмәгән
Яңа дөнья көтә бит анда.

*1997*

* * *

Сәламәтлек, тамак, ял турында,
Үз хакында тәмам онытып,
Бүген кирәк булган бөтен эшне
Эшли алса кеше,
ут йотып

Йөрүләрен исенә дә алмый,
Әйтерсең ул һич ут йотмады —
Канәгатьлек белән әйтеп куя:
«Бүгенге көн юкка чыкмады...»

Эшли-эшли тәмам эштән чыгып
Чирләп ауга́ч урын өстенә,
Менә-менә җаны чыгачагы
Инде анык булгач үзенә,
Кичкә кадәр әгәр үлми калса
Чакмый калса әҗәл чакманы —
Канәгатьлек белән әйтә тагын:
«Бүгенге көн юкка чыкмады...»

*1992*

## Язга керәм

Язга керәм...
Никтер хәвефләргә,
Борчуларга сала яз ае.
Беләм, юкса, яз ул яшәрүләр,
Саф мәхәббәт, сөю, наз ае.

Тик мин инде шактый өлкән кеше,
Күпме генә гүзәл дисеннәр —
Язның иң-иң матур көннәрендә
Арта илдә үлем-җитемнәр.

Язга керәм...

*1990*

## Уйдык-уйдык уйлар

Урман эчләрендә
Уйдык-уйдык чирәм.
Яшьлегемне уйлап
Урман буйлап киләм.

Хатирәләр тора
Күңелдә туп-тулы:
...Уйдык-уйдык чирәм...
...Язгы урман юлы...

Яз белән ярәштем,
Урман буйлап киләм.
Истә әле, истә
Уйдык-уйдык чирәм.

Булдымы соң алар —
Чын ярәшү... Туйлар...
Дөрләп-дөрләп ала
Уйдык-уйдык уйлар...

*1990*

**Тәлгат Галиуллин**

# ЭЛМӘК

РОМАН

## 13

Уйлар, уйлар... Канатлы һәм фаҗигале, хыялый һәм артык гадәти була аласыз икән сез. Бүген минә Сәетнең бөтен барлыгын бөтенләй үзгә дөньядан килгән шәхес һәм вакыйгалар шаукымы биләде. Бу хатирәләр, яшәү белән үлем тартышкан яссылыктан, зиһен ишегенә, шакымыйча килеп керделәр. Вильсур Садыйков иде бу тозлы-борычлы уйларның төп каһарманы.

Әйе, Мансур Мәүлетовның вакытсыз вафатыннан соң, көндәш фирма белән җитәкчелек аның кулына төште. Бар явызлыкның шуның әмере белән эшләнгәнне Сәет күптәннән белә. Мәгәр бу шәхесне җитди кабул итмичә, чак-чак кына йолдызлар, ай, кояш, саба җиле белән мәңгелеккә саубуллашмады.

Азау теше чыккан, буар елан булып чыкты элеккеге комсомол узаманы. Күп этлек кылды Сәеткә, егетләренә. Алтын коелмага кызыгып үзен пычраткан, үч алудан куркып качкан Гөмбәне дә, Шөреп белән бергә төрмәдә утырган Коротышканы да үзенә сакка алган. Үзе белән бутап, Рафаэльны харап итүдә дә, Садыйковның кулы уйнавын сизенә Сәет. Шулай да ул, Вильсур Садыйков белән очрашып, аңлашып, сөйләшеп алырга кирәк, дигән имаңда яши. Максаты: бурычларын түләтү һәм, беларус урманнары сазлыгы кебек, иге-чиге булмаган канкоешны туктату. Ул очрашуны Сәет ифрат оста оештырган иде. Авыру рәхәтләнеп елмаеп куйды исенә төшереп.

Елга ярларының, тауларының кояшка караган ягында: «без бар, без исән, без яшибез әле» — дигәндәй, беренче үләннәр, чәчәкләр борын төртеп яткан язгы көннәрнең берсе иде. Җиһан җылылыкка тарган. Явызлыкның ни икәнен дә белмәгән гөрләвекләр, бүрәнә ярыгыннан да кызык тапкан, ир-ат кулы тимәгән яшь кызлар төсле, көлә-көлә үзенә юл-ерганаклар барлый.

Табигатьнең менә шундый назлы бер чорында «Эдельвейс» ширкәте башлыгы Вильсур Садыйков Караваево вилаятенең администрациясеннән чакыру ала. «Минем ул район белән алыш-бирешем, югалтыш-табышым юк», дип, бармый калырга да мөмкин иде дә, рәсми кәгазьне алып килгән, яшь булуына карамастан, аксыл чәчләре коелып бетә язган,

---

Дәвамы. Башы журналның 5, 6 саннарында.

омон киемендәге таза гәүдәле егет, борын аша гына: «Вакытында килергә киңәш итәм»,— дип өстәгәч, ризалашты. Яшьлегендә фирка вә хөкүмәт даирәләренә буйсынып яшәргә өйрәтелгән Садыйковның баш тартырга көче житмәде. Каланың кыл читендә урнашкан ике катлы кирпеч йортны көчкә эзләп тапты. Бер ягында хәрби комиссариат, икенче өлешендә вилаять администрациясенең бер җаваплы бүлеге оялаган.

Вильсур үзе белән алган ике сакчысының берсен ияртмәкче иде дә, чакыру кәгазен алып килгән түгәрәк битле, таза егет туктатты:

— Курыкмагыз, сезгә тимәсләр! Чит кешегә керергә ярамый.

Үзе үк кунакны икенче катка озата менде. Мөдир ишеген ачты:

— Егор Николаевич, чакырган кешегез — Вильсур Садыйков килеп җитте.

Курач буйлы, дыңгычлап тутырылган ат казылыгы мәсле тыгыз гәүдәле, конгырт чәчле бүлек мөдире, кара, күн кәнәфиеннән күтәрелеп, Вильсурга саф татар телендә мөрәҗәгать итте.

— Сезнең белән танышуга шатмын. Дөресен әйткәндә, мин сезне күреп беләм икән. Бер комсомол слетында бергә утырдык. Сез президиумда — өстә, мин — начинающий комсомоленок — аста... Сезнең ялкынлы чыгышны дә хәтерлим. Ул вакытта чәчегез кара иде.

Мөдирнең бүлмәсе теләсә кайсы министрның кабинетыннан кайтыш булмас. Байлык вә зәвык белән бизәлгән. Чем кара, ясалма күн белән тышланган тимер нигезле урындыклар иясенең оясында озак утырырга нияте турында сөйлиләр.

— Безнең оешма бирегә күчкәнче, бу бина, ташландык балалар бакчасы иде. Ике ай эчендә менә шундый хәлгә китердек,— дип, мактанып, алмыйча түзмәде бина вә бүлмә хуҗасы.

Кыскасы, җәһәннәм читендә урнашкан офисына җылы мөнәсәбәтен, үзенең ремонт эшләренә керткән «көмеш»ен озын-озак итеп сөйләргә ярата иде мөдир һәр яңа, игътибарлы колак табылганда.

— Ни йомыш? Ни өчен чакырдыгыз, минем сезнең районга, бигрәк тә бу бүлеккә мөнәсәбәтем юк кебек? — дип, бүлдерде Садыйков Егор Николаевичны.

— Хәзер белерсез. Ашыкмагыз. Энта, кечкенә генә киңәшмә уздырып аласы идек. Башка чакырылган кешеләр дә күрше бүлмәдә утыра.

Шул мәлне кабинетның түрдәге бер читеннән, гади күзгә күренми, беленми, дивардан чыга торган ишек ачылды, аннан әүвәл Хәлил Нигъмәтуллинның ярым такыр башы күренде, аның артыннан Сакманов үзе килеп чыкты. Йөзләрендә, буш аракы шешәләрен уңышлы тапшырган малайларныкы мәсле, бәхетле елмаю.

Вильсур җан дошманнарын таныды. Көтелмәгән очрашудан имәнеп китте. Як-ягына каранып алды, әле генә җәелеп сөйләнеп торган бүлек мөдиреннән җилләр искән иде. Чыгу ишегенә күз салды. Анда йомры башлы, төссез табак битле, аны бирегә алып менгән таз егетнең сыны катып калган. Үзенең сөмбаш балыгыдай, җәтмәгә килеп капканын аңлады Вильсур. Егетләре дә аста калды. Кисәү сабың озын булса, кулың көймәс, дип белмичә әйтмәгәннәрдер элегрәк яшәгәннәр. Ник үзе генә күтәрелергә риза булды? Ник килде бирегә?

«Һәйкәлне» төртеп чыгып китәргә омтылу барып чыкмас. Сакмановны кул сугышына бик маһир диләр, куып җитәр.

Вильсур үзе дә күшегеп, төшеп калган кеше түгел иде. Хәле мөшкел күренсә дә, сер бирмәскә, эчке халәтен дошманнарына сиздермәскә тырыша. Йөзенә, елмаю рәвешен хәтерләткән шәүлә чыгарып, йон уңаена сыпыра:

— А, иске танышлар, рәхим итегез! Сезне дә, бу хәйрия оешмасына, җыелышка чакырдылармы? Тик менә Егор Николаевич дигәннәре генә каядыр юкка чыкты, идән астына убылып төшеп китте, дисәң?

«Игелек» җитәкчеләре, нәкъ менә чакырылган җыенга килгән кешеләрдәй, озын кара өстәл артына, тәрәзәле якка барып утырдылар. Адымнары төгәл, чүкелеп төшә. Вильсур тоташ дивар ягында кала.

— Плииз,— дип, инглизчә кыланып, Сәет каршыдагы урындыкларга ишарә ясый.

Садыйковның утыруын көтеп тормастан, Хәлил фикер алышуны башлап ук җибәрә.

— Без сезне усал ният белән чакырмадык. Бурычыгыз бар.

Сәет пырдымсыз урынбасарын кул ишарәсе белән туктатты. Атылмаган ук белән әйтелмәгән сүз Сакманов җәясеннән, аның авызыннан төшәргә тиеш. Беркая да ашыкмаган кешедәй, сәгатьләргә сузылган, буш сафсатага корылган элеккеге фирка җыелышларындагы шикелле, сүзне ерактан алдырды.

— Менә бит нинди көнгә калдык: элек бер җигемдәге кешеләр дошман ягына күчте, баррикаданың каршы ягында торганнар, дуслашып бетте. Хәтерлисезме, Вильсур Мәгъсүмович, без өчәү, тагын Мансур бар иде, Вильнюстан өй җиһазлары, кофе, ликер алып кайтканда, нindidер әрәмтамаклар эзгә төшеп, алардан көчкә, атышып котылгач салкын аракы эчеп, мәңге ташлашмаска вәгъдәләр бирешкән идек. Онытмадыгызмы?

«Андый коточкыч хәлне онытып буламы соң. Әлбәттә, ул вакыйганың һәр детале хәзергедәй күз алдында. Причем монда Вильнюс хәлләре... Истәлекләр кичәсенә җыелдыкмени?»

— Исемдә барысы да! Мансур Мәүлетовичны үтереп, антны сезнең як бозды,— диде Вильсур, кулларын аска төшереп. Тавышы хуҗасының ихтыярына, теләгенә баш бирмичә, сытылып, мескенләнеп чыкты.

— Анысы Фердинанд Нигъмәтҗанов өчен бурыч түләү булгандыр,— диде Сәет, үз өстенә берни алмыйча һәм үзенең бу эштә катнашын катгый инкяр итмичә.

— Нахакка аккан кан җиргә сеңми, йөрәктә кала. Бу бүлмәгә араларны ачыклап, мәетләрне санап, бавырга үч җыеп утырырга килмәдек без. Сүз киләчәктә ничек яшәү турында барыр дип ышанам. Үзара астыртын сугышны, соңгы кешегәчә дәвам иттерәбезме, әллә тыныч тормыш юлын сайлыйбызмы?

— Минем сезгә претензиям юк,— дип лепелдәде Вильсур, ишек төбендәге егетнең тырпайган кесәсенә күз салып. «Монда хәл кылмаслар инде мине. Урыны ул түгел. Ә урамда — охранам көтә».

— Мондый коры сүз Шомбайның шул ук җиләнен кире ягы белән әйләндереп кию генә булыр иде. Мин ялган вәгъдәләрдән туйган,— дип, Сәет кулының кабыргасын муенына тидереп алды. Ясалмарак булса да, хәтәр эффектлы чыкты.

— Кунакка килмәгәнемне аңладым. Капкын яхшы куелган. Мин әлегә берни аңламыйм? Нәрсә таләп ителә миннән? Җаным кирәкме? Каным да җитәме?

Үзенә физик куркыныч янамаганны аңлаган Вильсур кыюланып китте.

— Эш кешеләре арасында, бөтен цивилизованный дөньяда кабул ителгән мөнәсәбәтләр буенча, миңа тигән өлешемне кайтаруны таләп итәм,— диде Сәет, беренче сыйныф укытучысы кебек, һәр сүзен иҗекләп диярлек әйтеп.

Аксыл-соры пинҗәгенең эчке кесәсеннән шытырдап торган кәгазь чыгарып, аны өстәлгә, Вильсур каршына иплән, иркәләп җәеп куйды. Дустына Сөләйман йөзеге бүләк итә диярсең.

Документны алганда, кулының сатлыкларча калтыранып алуын тойды Вильсур. Бик зур сумма таләп итә мәлгунь аңардан.

— Каян җыелган шундый зур бурыч?

— Шикәргә күчергән акчадан процент, коры сөтне бергә озаткан партиядән керем һәм минем үтенеч белән кайтарылып, сез саткан чит ил машиналарыннан табышның биш проценты минеке... Тапшырылган кәгазьдә барысы да аңлатып, шәрехләп язылган.

— Каян алыйм мин бу чаклы миллионнарны?

— Акчасыз калу бу дөньяда иң куркыныч нәрсә түгел. Башка, кыйммәтрәк әгъзаларын җиңел югалталар адәм балалары,— дигән җавап керде кунакның колагына.

«Тозакка каптым тәки»,— дип уйлап өлгерде Садыйков. Булдыра алса, бу мизгелдә ул Сәетне сөяген дә калдырмыйча чәйнәп йотар иде. «Сакманов мин белгәннән күпкә мәкерле, акыллы булып чыкты. Биредә пыр тузынып булмас ахырысы, шартларын кабул итәргә туры килер». Борынына әҗәл җиленең әшәке исе килеп бәрелгәндәй булды.

— Хәзергә кистереп әйтә алмыйм. Тикшерәсе, саныйсы бар.

Мансур шикелле үк, шөлли иде ул Сәет-менттан. Юкса, бурычыңны Мәүлетовтан сора, Мансурны үтерткән өчен мәһәреңне түләү булыр, дип кенә әйтәсе дә, теле әйләнми. Коллык белән куркуны сатып алмыйлар.

— Саналган һәммәсе. Менә бу сумманы «Игелек» ширкәтенә күчерәсе, ә менә бу икесенә гарантия бирәсе,— диде Сакманов, көндәшенең алдына янә ике кәгазь куеп.

— Берничә көн вакыт бирегез!

Ялвару, үтенү төсмере өстенлек итә иде тавышында. Шул вакыт кемдер, өстәл астында, каты иттереп аягына басты. Тартып алырга омтылуы барып чыкмады. Идәнгә кадаклап куйдылармени аягын.

— Имзагызны ике тапкыр менә бу җиргә куегыз! Башкасын күтәрбез. Беразга... Шуннан башка бу кабинеттан исән-имин чыгу турында хыяллану ахмаклык булыр иде. Әнә теге бүлмәгә кереп сөйләшү көненә калмыйк! Миңа кешенеке кирәкми, үземә тиешлесен генә алам. Анда барысы да саналган... Әлбәттә, инфляцияне исәпкә алып...

Документлар белән танышкач, Вильсур Садыйков чучка баласыдай чинап җибәрде.

— Бу бит оятсызларча талау. Сораганыгызны күчерсәм, мин бит фирманы ярык тагарак янында калдырам.

— Бер өйрәнгәч, тәмугтагы тормышың да оҗмах тоелыр, дигән Коръәндә. Бер хәзрәт шулай укыган иде вәгазендә. Мин ике арадагы низагъларны тыныч алым белән хәл итү юлын тәкъдим итәм. Башка чаралардан икебезгә дә туктарга вакыт, дип саныйм.

— Минем ширкәт буенча хокуклы хезмәттәшләрем белән киңәштабыш итәсем бар.

— «Эдельвейс»та кемнең тулы хуҗа икәнлеге безгә мәгълүм,— дип, сүз кыстырырга булды Хәлил.— Астагы боевикларыгызга таянырга уйламагыз, алар бирегә үтеп керә алмаячаклар. Аларны коралсызландырган булырга тиешләр инде безнең егетләр.

Вилсурның башы әйләнеп, йөрәге гөжләп китте. Кәгазьләрне танудан, кул куюдан башка чарасы калмады. Ул кәгазьләргә кул тамгасын салган арада, Сәет кесәсеннән кечкенә япон «төшергече» чыгарып, «тантаналы» процессны берничә кат рәсемгә алды. Садыйков имзасыннан, үзенең кулыннан һәм үзеннән баш тарта калса, арбитраж өчен документ әзер иде. Мондый ук этлекне көтмәгән кунак: «сволочь, мракобес, мин моны гафу итмәм»,— дип кенә сүгенергә өлгерде. Эченнән, әлбәттә.

Ир-ат арасына ике әйбер кермәсен диләр, зиһенле кешеләр. Хатын-кыз һәм кәгазь. Икесе дә авыр нәтиҗәләргә алып китерергә мөмкин.

Сакманов әзерләп килгән исәп-хисап кәгазьләренә кул куюга мәҗбүр ителсә дә, Вильсур аларны үтәү турында уйламый, түләмичә котылу әмәлен таба алуына ышана; иртәгә үк банкка юл тотачак, дусларын эшкә җигәчәк. Әмма бирегә дә соңга калды. Садыйков шомлы, аяныч, күңелендә саркып яткан яралы хәлендә эленке-салынкы, аңгы-миңге йөргән арада, дөресе, шул ук көнне, Сакманов беренче кәгазь буенча акчаны умырып алган булып чыкты.

Әйе, ул көнне Вильсур Садыйковны бик оста итеп черек төп башына утырттылар. Гафу ителмәсен дә аңлады Сәет. Анысы шут с ним. Тик бер нәрсәгә үкенде «Игелек» хуҗасы. Үзе белән Хәлилне алып барганына.

Абзый болай да күп белә, аралары исә, суыткычка куелган сепарат сөте кебек, бозга әйләнә бара.

Хәлил шул көнне: «Вильсур Садыйков кем ул, аның турында сөйлә әле»,— дип сагыз төсле бәйләнде. Акылы туарылырга киңәш итмәде, урынбасарына чишелмәде. Сәетнең уе ашыкмыйча гына артка таба агуын дәвам итте. Ул Вильсур Садыйков дигән затны ахыргача аңларга тиеш. Дошманы, көндәше турыда төрле чыганаклардан, аерым алганда, Мансур Мәүлетов сөйләгәннәрдән, шактый нәрсә белә икән. Чын замана баласы иде Мәгъсүм агай улы...

Вильсурның яшенле яшьлеге илдә милләтләр, лөгать-шивәләр бетүгә йөз тотып, «совет халкы» исемле, зинадан туган «грейфрут» оешып, урыс теле уртак аралашу чарасына әверелгән данлыклы вә сөрсемле торгынлык чорына туры килә. Һич көтмәгәндә, уйламаганда, химико-технология институтының бишенче курсында укыганда, Житомир кызы Лариса Петренкога өйләнеп куя.

Һәр шимбә, ял көнне тулай торакларда була торган тансыда табыша ике кайнар йөрәк. Тышына олы итеп өч жиделе саны төшерелгән портвейнны әтмәлләгәч, Вильсур курсташы, дусты Сергей Фролов белән беренче катка төшә. Икесе дә чыгарылыш курста, икесе дә комсомол комитетының йөзек кашлары, кыскасы, танышканга тел, аркылы төшкәнгә юл бирмәстәй вакытлары. Түбәнрәк курс талиб-талибәләре аларга өстан-өскә карап, артларыннан көнләшеп, өмсенеп калалар.

Аларның килеп житүен генә көткәндәй, магнитофон яңа көй башлый. Колга буйлы, тутыккан кадак кебек жирән-мүк чәчле Сережа тәрәзә кырында сөйләшеп торган кызларның берсенә ымлап күрсәтә.

— Әнә шул танага игътибар ит әле. Безнең студентка түгел, минемчә, Йөзе айдай түгәрәк, тиресе шома күренә. Чакыр әле шуны биергә. Бәлки, язмышыңдыр...

Вильсурга бәхет елмая. Сергейның шаяртуы фәрештәләрнең кешеләр язмышы белән кузлада уйнап утырган вакытына туры килә. Егет тансыга үзенең киләчәген чакыра. Хатын-кыз белән аралашуда шактый тәжрибәле булса да, аның мондый мул, тыгыз, калку күкрәкле, күгелжемшәмәхә төсле, сәйлән сирпеп торган күзле, жигелмәгән колындай урынында басып тора алмаган, дәртле кызны куенында тотканы юк иде әле. Мул иреннәрен ярып чыккан һәр сүзе, «Һ» га басым ясавы, үзен иркен, бәйсез тотуы, үбешә, яратыша белүе — барысы бергә вәйран, кол итте егетне. Лариса, үзләрендә техникум тәмамлаганнан соң, Татарстанга, хәрби заводларның берсенә эшкә жибәрелгән икән. Инде өченче ел тулай торакта яшәп, «илнең оборона куәтен арттыруга өлеш кертеп» ятмыш икән. Әлбәттә, инде эссе, кояшлы, мул ризыклы туган ягын бик нык сагына. Тагын бер ел мәжбүри эшлисе бар икән.

— Ә сезне бөтенләйгә Татарстанда, Казанда калдыруга ничек карыйсыз,— дип сорап куя тел шомарту жәһәтеннән, гәүдә тарафлары ягыннан хатын-кыз кулына кереп, гаилә корып жибәрер өчен өлгереп житкән студент.

— Миңа татарлар ошый. Эшчән, дуслыкка турылыклы халык. Төсбит, килеш-килбәтләре белән безнең як кешеләренә тартым. Иң якын дустым Диана — татарка.

— Сезгә, Лариса Харитоновна, мин бөтен татарны тәкъдим итә алмыйм. Андый вәкаләтем юк. Сезнең игътибарыгызга Уфа татары — Вильсур Мәгъсүм улы Садыйковны гына тәкъдим итә алам.

Егерме дүрт тулганны сизми дә калган, болай да иртә өлгергән көньяк кызының сайланып, кәжәләнеп торырга хуты юк, тулай торакта суган суы суырып яшәү ысулыннан да туйган. Артыннан иснәнеп йөрүче жилкенчәкләр, арзанлы тәкъдимнәр белән теңкәсенә тигән өйләнгән ирләр күп булса да, загска, язылышырга барырга чакырып торучылары арасында чират күренми. Ризалашты. Жилне истереп, яфракны селкетеп, яшьләр туе ясап жибәрәләр. Туй сәяхәтенә хатынының туган якларына

чыгып китәләр. «Ул тарафларда, егетләр, чия агачында алма, грушаныкында кавын үсә, кабак орлыгы карбыз бирә, җиргә таяк тыгып, су сипсәң, минем баш тикле чөгендер калкып чыга»,— дип, гаҗәпләнеп сөйли кияү кунактан кайтканнан соң. Лариса әнисенең үз йорты, зур бакчасы булса да, яшьләр анда торып калырга уйламыйлар. Этнең генә туйган төше бар, туган җире юк, диләр. Вильсур атлы якты йолдыз Казанда кабыначак. Ул шуңа ышана. Киләчәкләрен комсомол, фирка белән бәйләгән яшьләрнең катнаш никахы хуплана, мәртәбә санала, карьера кууны җиңеләйтә торган бер шәй иде ул чорда.

Нацмен кавеменнән берәресен Мәскәү карамагындагы оешмага эшкә алганда, биографиясен өйрәнүне шул яссылыктан башлаганнар, диләр.

— Тәк, өйләнгәнме?

— Әйе, гаиләле.

— Хатыны кайсы милләттән?

— Урыс, украинка, белоруска...

— Хуш! Кайсы якта туып үскән.

— Воронежданмы. Калугаданмы шунда...

— Расларга. Алга табан, иптәшне күз уңында тотарга. Яше комсомолдан чыга башлауга, партия аппаратына яисә КГБга күчерәсе булыр.

Фирка идеологлары, кадрлар өчен җаваплы әһелләр тәгаен белә: башка милләтнең кызын яисә егетен ятагына салган, түр башына утырткан татар кешесеннән милли пәрвар, үз халкының киләчәге өчен җан атып йөргән көрәшче чыкмаячак. Нәселе исә, урыс халкының көчен, куәсен, ким дигәндә, санын арттыру өчен чимал булачак. Аянычлы тарихыбыз шуңа күп үрнәкләр бирә.

Вильсур Садыйковның комсомол баскычлары буйлап тиз үрмәләвенә Житомир кызына өйләнүе зарар китермәгәндер, дип уйларга нигез бар. Химико-технология институтының комсомол сәркатибыннан ул район, шәһәр, өлкә оешмаларына күчерелә. Татарстан комсомолының иң җаваплы әһелләренең берсе дәрәҗәсенә үсә.

Комсомол эшендәге кешеләр арасында язылмаган, әмма мәҗүси кануннар шикелле, мәҗбүри үтәлергә тиешле йолалар яши. Шул кастага үтеп кергән адәм баласы матур итеп сөйли, партия әһелләренә яраша белергә, көн саен диярлек була торган эчү мәҗлесләрендә катнашырга (баш тартсаң: «безнең кеше түгел, өлгереп җитмәгән, жасус, стукач» һ.б. шундый эпитетларга лаек буласыңны көт тә тор), мунча кирә, исерә белергә тиеш... Дөнья мәшәкатьләренә баш бирми торган, җиңелчә романтик булу да хуплана. Чит-ят хатын-кыз белән чуалу, тотылмасаң, гөнаһка, уставны бозуга саналмый. Комсомол элитасында кабул ителгән шартларны үти алмасаң, аңда кабул ителгән таләпләргә хилафлык кылсаң, халык хуҗалыгына озатылуыңны көт тә тор. Син инде беркайчан да, җиңел тормышка, сандугачлы бакчаларга юл ачкан, үзара гына аралашып яши торган иҗтимагый төркемгә керә алмаячаксың. Хатыныңа турылыклы ир булуың берәүгә дә кызык түгел. Кара ипи кимереп яши бир.

Яшьләрнең җитәкчесе кырында исә, һәрдаим яшь, чибәр хатын-кыз булуы лазем. Алар, затлы бияләйләр төсле, алышынып торырга да мөмкин.

Вильсур гомуми фәлсәфи-әхлакый кагыйдәдән чыгарма, ала карга булырга теләмәде. Башкача, җәмәгать эшендә югары дәрәҗәгә күтәрелеп булмасын ул инде аңлаган иде.

Хатыны Ларисаны какмады-сукмады, үзе белгәнчә, яратып яшәде. Каланың уртасында салынган, престиж йорттан, биек түшәмле, олы тәрәзәле, паркет идәнле фатир алдылар. Мохтаҗлык дип аталган әкәмтөкәмнең «м» хәрефен дә күрмәде, сизмәде хохол кызы. Әүвәл тормышлары нәкъ ул теләгәнчә, хыялында йөреткәнчә, майлаган арба сыман барды. Туган ягында берүзе калган әнисен янына алды. Малайлары туды. Аңа апостол Андрей исемен бирде, шыпырт кына чиркәүдә чукын-

дырды. Үз бәхетеннән үзе көнләшеп яшәп ятканда, дустанә йөргән хатыннар сөяленә китереп басты. Авыртырлык итеп. Кызганмыйча. Берсе: иреңне «яшел оек» белән күрдем. Икенчесе: мин дә Вильсурның сөяркәсе бар дип, күптәннән ишеткән идем. Сине кызганып кына әйтмичә йөрдем.

Хатын-кыз тоемы белән җефетенең читтә чирттерү, уҗымга чыгу ихтималы барын белсә дә, имеш-мимешкә колагына кергәләсә дә, гаиләне сакларга, ә үзен, җаваплы кеше хатыны буларак, горур, тәкәббер тотарга тырышты. Үзенә нисбәтән үсә барган салкынлыгын, аерым бүлмәдә йокларга яратуын, эшендә талчыгуы, теләсә-теләмәсә дә, күп эчәргә туры килү белән аңлатты. Вильсурны тәк кенә югалтасы килмәве аңлашылса булыр. «Бәлки, миңа гына шулай тоела торгандыр, аның хезмәте шундый инде, артык нәзберек, бәйләнчек булып киттем»,— дип үзен тынычландырырга, чыгырдан чыкмаска булды.

Кеше сүзен авыр кабул итте. Без капчыкны тишеп чыкты. Элек таныш булмаган кайнар дулкын, түбәннән, тез астындагы чокырчыклардан күтәрелеп, бугазына ябышты, кара томан кебек, күзләрен каплады. Фәхеш белән тулы дөньяны ташлап, әллә кайларга, болытлар арасына чыгып китәсе килде. Көзгегә карап, үзен кызганды, җәлләде. Авызы ярым ай, кашлары — сыерчык канаты, күзләре өлгергән гөлҗимеш иде әле... Бүген иптәш хатыннары иренең сөяркәләрен исемнәре, эшләгән урыннары белән атагач, мин-минлеге, рәнҗүе күтәрелде, ачуы чыкты. Ире белән кичекмәстән аңлашырга булды. Таратсын гайбәт төтенен.

Шомлы хәбәр Ларисаның колагына ирешкән дәһшәтле көнне дә ире, гадәтенчә, соң, лыгыр исерек булмаса да, кызмача кайтты. Ханым ишекне үзе ачты. Сырлы кара драп пәлтәсен чөйгә элгәннән соң, зур күзләрен иренә юнәлтте. Ник күтәрелеп караганына, ник туганына үкенде шул мизгелдә. Аркасыннан салкын дулкын йөгереп узды. Аяк табаннары йомшады. Күзләрендәге тугрылыксыз караклык бер хәл. Бәгырькәенең яңа тарттырган он кебек бәз күлмәгенең сул якасын, күптән түгел генә хатын-кыз ирене калдырган, куян канидай куе кызыл иннек буявы бизи иде. Үпкән кешенең аскы-өске иреннәренең эзләренә хәтле сызылып калган.

— Бу нәрсә? — дип сорады хатын, күрсәткеч бармагы белән җинаять эзенә төртеп күрсәтеп. Тавышы, әле генә елап туктаган баланыкы төсле, өзек-өтек чыкты.

Гаиләне таркату, ир белән хатын арасына чөй кагу максаты белән, фахишә ханымнарның, сыңарларының берәр күрәкле җирендә, аңлы рәвештә, шундыйрак тамга калдырырга яратулары хакында ишеткәне бар Житомир кызының. Бу афәтнең үзләренә килеп җитәсе, иренең шундый сыкылы билге белән өйгә кайтасы, ике ятып бер төшенә дә кермәгән иде.

Вильсур үзе дә, мәсьәләнең «шадра»ланып китү ихтималын чамалады (этлек кылган дуланы сүгеп) һәм, эчендә утырган хәмер пары мөмкинлек биргән микъдарда, йөзенә, кара күзләренә, эчкәрәк тартылып торган иреннәренә, кырау кагыла башлаган чәчләренә чаклы чиксез гаҗәпләнү билгесе чыгарды.

— Чыннан да, хатын, нәрсә икән бу? Үзем дә белмим,— дип, үзенең дә шәхси дошманы булып киткән, большевиклар байрагы төсендәге тапны, кечтеки бармагында үстергән озын тырнагы белән җиңел генә алып ташламакчы иде дә, барып чыкмады. «Чикләвек кортлы», буяусыйфатлы иде.

Комсомол эше кешене шомарта, хәйләгә, алдауга, мәкергә, кыскасы, сыртка әйләнеп төшмәскә өйрәтә. Вильсур бу мәктәпне тулысы белән узган кеше буларак, укучыларын бер җан иясенә дә авыр кагылмаска, рәнҗетмәскә өйрәтеп, вәгазь сөйләп утырганда, чебенне сугып үтергән Лев Толстой мәсле, шап итеп маңгаена китереп суга. Кызганмыйча, үзе дә ышанырлык итеп бәрә.

— Бүген Татарстан комсомолының туган көне ич! Тантаналы җыелыштан соң,— кстати, Беренче үзе дә булды,— тансыда катнашырга туры килде. Бер комсомолка биергә чакырды. Соңыннан гына исерек икәнен сизендем. Музыка туктауга, теге, рәхмәт әйтеп, биттән үбәргә омтылды, мин бит, үзең беләсең, теләсә кемнән ялатып торырга ахмак түгел, башны читкә алып өлгердем, шунда яканы сыдырып узган икән, сволочь, анадан туган нәрсә, мәлгунь,— дип, олы җыелыштагы кебек дәртләнеп сайрарга, ялганларга керешге житәкче иптәш. Сәхнәдә тәмам рольгә кереп житкән артист төсле, онытылып, үз ялганына үзе ышанып, сөйли дә сөйли. Хатынының аны аңламыйча, аңларга теләмичә дә, тораташ булып басып торуын күргәч, юыну бүлмәсенә кереп, бикләнеп, күлмәген салып, якасын юарга керешә. Бу — аның икенче хатасы була. Күлмәген тәмам пычратып, кызылсу төскә буяп бетергәч, өстенә соры, ябык якалы свитер киеп залга чыга.

Иренең мәгънәсез лыкылдавын кабул итмәгән, барысын да аңлаган ханым, җәнҗал күтәреп, тавыш чыгарып, күршеләрне уятып маташмый. Шактый тыныч тавыш белән, тәртәләрне як-якка борырга, тыныч кына аерылышырга тәкъдим кертә. Комсомол, фирка эшендәге кешенең рәсми хатыны булырга тиеш. Аерылышу, судка йөрү кабул ителмәгән ул даирәләрдә.

Киләчәгенә куркыныч янавын сизенгән Вильсур Мәгъсүм улы соңгы адымга бара. Сөякләрен авырттырудан да курыкмыйча, тезләре белән шап итеп идәнгә төшә, кулларын күкрәгенә куя, гафу үтенә. Изгеләрнең изгесе иде ул бу мизгелдә. Хатын үзенекен тәкъварлый, фикерен бирми:

— Без зыялы кешеләр. Тавыш-тәтен чыгармыйча, аерылышыйк. Эшеңә барып, җалоба биреп йөрмәм. Тук тормыш бәрабәренә генә гафу итә алмыйм. Миңа уртак ятактан калган уртак ир кирәк түгел.

Вильсур үтенде, ялынды, хатынын, малаен, әбисен яратуы турында кат-кат сөйләде. «Кылмаган гөнаһлары» өчен ярлыкауны сорады, ипле уелган борын яфракларыннан рәнҗүле авазлар чыгарды.

Лариса Харитоновна үзенекендә торды, мондый пычрак, сатлык ир белән яшәргә теләмәвен кабатлады.

Бөеклек чалымнары бар иде Вильсурда.

— Син дөньяга тар һәм сукырларча карыйсың. Зиннәтле тормыш болай гына килми. Аның өчен түлисе була,— диде, катгый бер карарга килеп Вильсур. Сүрән яктылык шәһәрне тын караңгылыгыннан азат иткәндә, ир-зат кухняга үтте. Капыл-капыл бер чынаяк чәй эчкән булды, ашыкмыйча гына киенде һәм дүртенче сыйныфта укучы уллары Андрей бүлмәсенә үтте.

— Улым, тор! Безне моннан куып чыгаралар.

Улын җилтерәтеп торгызды да, йокысыннан айный алмаган малаенның пижамасы өстенә җылы тунын кидерә башлады. Иренең хәрәкәтләрен бер мәлгә дә күз уңыннан төшермәгән, шулай ук төн йокламаган хатын дерт итеп сискәнеп китте. Ул иреннән барысын да көтте: кыйнап ташлавын, әнисенә чыгып китәргә тәкъдим ясавын, фатирны бүлүен, эшенә шалтыраттыруын һ. б. Мондый адымга барыр дип, күз алдына да китермәгән иде. Караңгы упкынга убылып төшкәндәй булды. Андрейга барып ябышмакчы иде, юлны комсомол вожагы бүлде.

— Балага якын киләсе булма! Сиңа — әниең, миңа — малай. Киләчәккә чын алмаш әзерлим мин аңардан.

Йокысы туймаган малай мышык-мышык елый башлады.

— Киттек,— диде Вильсур, комсомол җыеннарын алып барган корыч һәм үтәлүе мәҗбүри тавыш илә.

— Без кая барабыз?

— Машинага. Үзебезгә яңа дворец салганчы, машинада яшәрбез.

Малайлар өчен шуннан да зур бәхет юк. Ул кулын әтисенең учына салды.

Инде Лариса Харитоновна шап итеп, идәнгә егылды. Аның бердәнбер шатлыгын, сөенечен, йөрәк җимешен алып китәләр ич. Ире йөресен,

кырылсын, себерелсен, теләсә кайчан кайтып-китеп йөрсен, тик парәсенә генә кагылмасын! Шулай килештеләр дә. Ахыр чиктә Вильсур чын ирекка тарды. Малае урта мәктәптә укыганда да, табиблыкка имтиханнар биргәндә дә, әтисе белән дустанә калырга тырышты. Егеттән — тәмле сүз, әттәдән — акча.

— Әтиемне начар кеше, дип раслый алмыйм. Ул һәр яктан килгән, идеал шәхес булмаса да, аны әшәке аталар исемлегенә дә кертеп булмый,— ди торган иде, чынын-көлкесен бер шәкелгә үреп.

Андрейның гомере кыска була. Баш миендә яман шеш үсеп, җирдә чирек гасыр гына яшәп кала. Ата белән ана арасындагы соңгы җанлы җеп өзелә.

Яшьлекнең тиле матурлыгы, каен суы, умырзая чәчәге, кояшлы яңгыр кебек, кыска була, тиз үтә икән шул. «Сизми калдым, белми калдым яшь гомеремнең узганын»,— дип юкка гына моңаймагандыр «агай-эне ак мыек».

Җылыга өйрәнгән иркә гөлдәй, салкын табигать басымына Лариса тиз бирешә, иртә картая. Бигрәк тә, иренең сугым сиеры мәсле, уҗымга чыгып йөргәнен белгәч, үзен кулга алып, гаиләсе өчен көрәшәсе урынга, бар нәрсәгә кулын селтәп, җегәрен эшенә, улы белән анасына бирә, тышкы матурлыгы, бизәнү-ясану турында кайгыртмый башлый.

Малае гүр иясе булгач, Лариса тәмам бетеренә. Як-якка төшкән, буялган чәчләр, заманында нур сирпеп, уйнап торган, хәзер алмалары кызарган, тормыш әшәкелегеннән сагаеп, төссезләнеп калган күзләр, күптәннән сөрмә тартылмаган, дымлы ямьнәрен югалткан керфекләр, коелуга йөз тоткан тешләр — узып барган хәятның аяусыз шаһитлары. Тулыланып, шешенеп киткән бит, яргаланган иреннәр, кечерәеп калган борын, бөгелеш-сыгылыш урыннары тигезләнгән тулы гәүдә, яшьлегендә Ларисаның һәр әгъзасын шашынып яраткан Вильсур Мәгъсүм улын артык әсәрләндермиләр. Шулай да, Ларисаны шыксыз дип раслау хакыйкатькә хилафлык кылу булыр иде. Элеккеге матурлык, чибәрлек эзләрен табып була. Дөньяның үзгә ләззәтләрен татыган комсомол узаманына алар гына аз иде шул инде.

Якыннарын чит-ят туфракка тапшырган Лариса Петренко берүзе торып кала. Дөрес, бушаган араларда, Вильсур беренче хатынының хәлен белергә кереп чыккалый. Матди ярдәменнән ташламый. Читтә, яшь хатыннан, иренең баласы үсүе турында да белә. Белеп, ни кыла ала. Терсәкне тешләп булмый. Үзе эзләп тапкан «социалистик бәхете».

Сәясәттән ерак, иң гади гаилә бәхете турында гына хыялланып яшәгән хатынны ялгызлык, күңелсез картлык көтә. Юанычы — йөнтәс эте. Шул тормышка бәйләп тора. Исеме дә «Вильсур» ди, дөрес булса. Монысын Сәет раслый да, кире кага да алмый.

Шул вакыт аралыгында, заманалар үзгәрде, комсомол белән фирка комнан ишелгән баудай юкка чыкты. Вильсур Садыйков, сизгер вә елгыр кеше буларак, тоталитар режимның, Берлин стенасы төсле үк, җимереләсен алданрак сизенеп, яшьләр оешмасының шактый байлыгын уртлап кала. Банктагы акчаларның бер өлешен шәхси кулларга «бурычка» өләшә. Үзгә исәпкә күчерә, бер район комсомол оешмасының бинасын чыгымга яздыра (аның хәзерге ширкәте шунда урнаша), кичләрен гел аяк арасында буталып йөргән тәкъва егетләренең берсен аракы заводына тәэминат бүлеге мөдире, икенчесен автопаркка баш инженер итеп утыртуга ирешә.

Хакимият барыбер элеккеге фирка әһелләре кулында калу сәбәпле, партия «кирәк» дигәндә, «була ул», «баш өсте» дип, торган елгыр, әрсез, комсомолда теше чыккан егетләргә төшемле кәнәфиләре табыла тора. Вильсур Садыйков турында онытмадылар хуҗалар. Ул олы заводларның берсенә директор урынбасары итеп билгеләнә. Җәмгыять өчен әлләни майтара алмаса да, биредә дә киләчәге турында кайгырта: фәннәр кандидаты булып ала, кыйммәтле ашханә, өй җиһазларын, плитәләрне,

төзелеш материалларын бракка чыгарып, шулай ук бер чорда укыган аркадашы Мансур Мәүлетовка озата тора. Ә тегесе — берничә ресторан, кафе, кибетләр белән җитәкчелек итә, тиздән берничәсен үзенә сатып ала. Заводтан киткәндә, «Эдельвейс» исемле, җаваплылыкның бер өлешен генә үзенә алган оешма төзи. Коммерциясе авырлык белән, шыгырдап бару сәбәпле, Мансур ширкәтенә кушылуны мәгъкуль күрә. Азык-төлек Мансур кулында, элемтәләре киң, дус-ишләре биниһая. Яңа ширкәткә башлык итеп бертавыштан Мансур Мәүлетовны сайлап куялар. Кәефе китмәсен, кикриге шиңмәсен дигәндәй, Вильсурга да, коммерческий директор дигән дәрәҗә бирәләр. Бүре белән куян туенда кемнең хуҗа икәнен чамалый Садыйков. Күңеленә нөктәле үпкә, яшертен үч чорнала.

Утны-суны бергә кичкән иптәшләре ир уртасы булып килгәндә дә, балалык катыш комсомоллыгыннан арына алмавын күрә торып, Садыйковка ширкәт язмышын ышанып тапшырырга шикләнәләр. Гамьсез, кайгы-хәсрәтсез, чая комсомол чоры гадәтләре, туганда ук тәнне бизәгән миңнән төсле, үзләрен сиздереп тора. Вильсур үзен җор телле, төртмәле мәгънәләргә оста кеше дигән ышанычта яши, шул алдавычтан тәм, ямь таба. Эченә хәмер кереп, башына менеп, теленә төшсә, элеккеге комсомол сәркатибына әйләнә дә куя. Бала-чага мәсле, урындыгында уыңа, ашау байдан, үлем ходайдан чакта (эченә вакытында затлы ризыгы кереп торса, елына бер тапкыр Карловы Вары суын эчсәң яисә тозлы диңгез дулкынында чайкалсаң, әҗәле дә чигенә), ваемсыз заманда откан, «Тәмәке тартабыз, эчүне ташламыйбыз», «Пычрак эшне ташладык, дегет сата башладык», «Без ипи ашамыйбыз, без эш кешеләре», «Минем 24 сәгать эшлисем килә» — кебек йомры җөмләләрне, җае чыкса да, чыкмаса да, кыстырмый калмас. Кулларын чәбәкләп алып, чырк-чырк көлә дә башласа, аңа буйсынган мөридләре, Райкинны тыңлагандай, аңа кушылып, авызларын ерырга тиеш булалар. Вильсурның кайта-кайта сөйли торган берничә мәзәге бар.

— Бик кыйммәтле путевка алып, хатынны санаторийга җибәрдем әле. Дөрес, үзен аклады.

Кемдер сорарга тиеш була: — Сәламәтләнеп, тазарып кайттымы?

— Юк, бөтенләй кайтмады.

Әлбәттә, бүлмәне тутырып көлгән кеше мәзәкче үзе. Шул ук вакытта Садыйковның сүзендә тормавы, вәгъдәсен үтәүне мәҗбүри санамавы, мөмкин булганда да, яхшылык эшләмәве, үзеннән түбәнрәк баскычта торучылар белән санлашмавы якыннары өчен сер түгел иде.

Артында аны «демогог», дип йөртәләр. Безнең мәмләкәттә, иң нык сакланган сер дошманга тизрәк барып ирешкән кебек, Вильсур да үзенең кушаматын белә. Мансур кушкандыр дигән гөманында да ялгышмый. Шуңа күрә Мәүлетовны күмүне тиешле югарылыкта оештырса да, бу афәтне йөрәгенә уздырмый. Ул — тулы хуҗа хәзер!

## 14

Шәфкать туташлары, Сәетнең зиһенен талкыган хатирәләр шаукымы агышын, бүлгәләп торсалар да, туктата алмадылар. Фикер йомгагы аны һаман-һаман хастаханә ятагына салган фаҗигале хәлләр ярына өстери. Аңда кереп киттеңме...

Әйе, Хәлил. Ул өч көннән соң гына эшкә чыкты. Бүлмәсенең ишеге биктә торуга игътибар итүче кеше булмады кебек. Дөньяда үзеннән башкага файда да, дөресен ярганда, капшап тотып карарлык зыян да китерә алмый торган затлар була. Халык андыйларга бәясен ике сүзгә сыйдырган: ниултара, ни пултара. Хәер, мондый мөһер әлеге адәми затларга үзләре турында югары фикердә калуга һич кенә зарар итми.

Сакмановның урынбасары уйлап җиткерелмәгән карарлары, үзе белмәгән эшкә кысылулары белән хуҗасының саруын кайнатса да, соңгысын

иске дуслыклары, Бауман урамында, ташландык эт кеби йөргәндә, төн юлының аръягында шәм кабызган, башкода булып, авылда Зөлфиякәйнең туйларын уздырышып йөргән өчен Нигъмәтуллинга күпне гафу итте, җылы бүлмәдә тотты, хезмәт хакын мул итеп түләде. Аннан килеп, үз өстенә чикләнгән җаваплылыкны алган «Игелек» ширкәте вак-төяк селкетүгә генә бирешә торган кораб түгел иде инде. Ягъни, мәсьәләнең эшчәнлегенә, бик теләсә дә, Хәлил Газиз улы артык корткычлык кыла алмаячак имди. Аралары суына баруга Сакманов артык дикъкать бирмәде. Андый ваклыклар өчен вакыты юк иде аның.

Өч көн прогул ясагач, чырае катып калган ак чәерне хәтерләткән Хәлил хуҗа бүлмәсенә сагаеп аяк басты. Һәр адымын, хәрәкәтен алдан уйлап куйган, теләсә нинди борылышка әзерләнгән булып чыкты. Сәлперәйгән, юеш кулын хуҗасына суза-суза, белдерү ясады:

— Үземне бик начар хис итәм. Тиздән үләрмен ахырысы.

— Тагын да начаррак күренәсең, дустым. Нәрсә булды? — диде Сәет, урынбасарына мыскыллы-шаяртулы, төрттерү-кинаяле караш ташлап.— Эшсезлек бик күпләрнең бугазыннан алган чорда, өч көн бикләнеп эчеп яту — морзалар роскошьлыгы түгелме?

Ошбу җөмләне Сәет тавышына, йөзенә кырыслык өлгесе чыгарып әйтергә тырышты. Янәсе, ул бик ачулы, Хәлилдән башка эш бармый... Отыры табигый килеп чыкты.

— Эшкә чыкмавымның җитди сәбәпләре бар. Отгулларым исәбенә булыр.

«Ниткән отгул» дип, күтәрелеп бәрелмәкче иде дә Сәет, үзен тыеп кала алды. Юкка-барга нервы бетереп, вакытны заяга әрәм итеп яши торган чор түгел.

Мәгәр Хәлил өендә яткан арада, үзенең җәмгыятьтәге, ширкәттәге урыны, кимәле хакында шактый уйланган булып чыкты. Һич көтмәгәндә, араларында шактый нәрсыз, чырайсыз, тәмләткечсез сөйләшү булып алды. Бәхәскә утны Хәлил төртте.

— Сәет Яруллович, мин бик начар йоклыйм. Башка әллә ниткән фикерләр килеп йөдәтә. Өч көн чирләп ятуым да шуңа бәйле.

Урынбасары белән бәхәсләшеп утыру иртәнге көн тәртибенә кертелмәгән иде. Сакмановның ачуы чыкты. «Оятсыз, гафу үтен дә, шыпырт кына отвали инде».

— Йөгерешче аттай күбеккә батып, әнчек эт кебек коерыкны сыртка салып, дөнья куганда, һәр тиенне тырышып-тырмашып алганда гына йокы тәмле була диләр, абзыйкай.

Җылы сүз, зарлануына теләктәшлек тапмаган баскак, энәләрен кабартты.

— Син мине һаман бездельник дип, саныйсың инде! Үлгәч кадеремне белерсең әле. Фикерем башка нәрсә хакында иде.

Кабул итмәү, эчке карышу кебек хисләрен бастырырга, җенне шешәгә куып кертергә тырышып, Сәет сүзне иплерәк юлга чыгарырга тырышты. Ике дусның телләре озынаеп, гомерләре кыскарганда, юмор ярдәмгә килергә мөмкин.

— Башкорт кардәшләр әйтмешли, нәмә кайгы-хәсрәтләр башыңны ашый? Нинди борчулар сачләреңне берәмтекләп йолкып бетерде икән? Бичәң йылы куенына иңдермиме? Берәр чибәр түти хафага салдымы үзеңне? — дип, сөйләшүгә җиңелрәк төсмер бирергә тырышты.

Нигъмәтуллин иптәш әлеге аңлашу-сөйләшүгә, «разборкага» алдан әзерләнеп, фикерләрен төенләбрәк килгән шул. Шаян тонны кабул итмәде. Күңелен кантарлы уй бимазалаганы күренеп, сизелеп тора үз-үзен тоту рәвешеннән үк.

— Сәет, мин синең юморны яратканыңны беләм, шаярта белүеңне бәялим. Ачуланма! Мин бүген көлдергечемне кабыза алмыйм. Минем өчен һич тә аңлашылмый, башым җитми торган бер мәсьәлә бар. Кайсы борылышта мине чаптырып узып киттең икән? Шуны сизми калдым.

— Гади сорау. Шәп сөаль. Син, үзеңне саклап, җаяү йөрергә яратасың. Вакыт галиҗанәбләренә үзең хуҗа. Мин исә, дүрт көпчәк өстендә йөгереп тә, көндәлек эшләремне төгәлләргә өлгерә алмый калам. Хикмәт шундадыр,— диде, башлангыч мәктәп укытучысы кебек, җитди итеп, әле һаман да Хәлилнең тел төбендә нәрсә ятканны аңышып җитмичә.

— Син бит миннән белемен, элеккеге дәрәҗәң буенча да әлләни өстен тормыйсың. Ничек итеп җитәкчелекне... байлыкны тулысы белән үз кулыңа төшердең?!

Сәетнең иреннәренә тоnык, кысынкы елмаю чыкты. Ит яхшылык, көт явызлык кебегрәк сүзләрне укуы кыен түгел иде алардан. Шул хәлдә дә, низагны тирәнгә җибәрәсе килмәде.

— Хезмәт хакыңны күтәрүне соравыңмы бу?

Үзе башлаган әшәке иcле уенга тартылган Хәлил, кулларын аркылыга куйды.

— Юк ла! Без фирмабызны бергә, өлешләребезне, ягъни сәмәннәребезне, тигез кертеп башлаган идек. Акрынлап бар байлык синең кулга, бер исемгә күчеп бетте...

«Башын җүләргә саламы, әллә чамадан тыш эшсезлектән, уңышсыз мәхәббәттән ычкынып барамы? Артистланып маташмый кебек. Үзен кимсетелгән, рәнҗетелгән, мәхрүм ителгән, алданган дигән ышанычта яши икән бахыр. Адәм баласының рухына шик-шөбһә корты керсә, бу хистән тиз генә котылып булмый. Иң яман чирләрнең берсе ул. Җанны кимерә бирә. Димәк, «һу из һуны» иренмичә төшендерергә, әгәренки, аңларга теләмәсә, хөкем оешмаларында кабул ителгән йола буенча, иптәшне халык хуҗалыгына озатырга».

Урынбасарының фикер сөрешенә, ниһаять, тулысы белән төшенсә дә, ачыкламыш сорау бирергә булды.

— «Игелек»нең барча мал-мөлкәтен кыл икегә бүлсәк, яртысын үзеңә алыр идеңме?

Хәлил үтә туры сорауга югалып калды.

— Яртысы ук дип...

Сәет, асфальтка төшкән карбыз кебек, шартлап ярылды. Башкача түзә алмады.

— Карале син аны, нинди уйлар, дәүләт борчулары белән интегеп, йокыларсыз калып интегә икән, минем кадерле вә олыклы урынбасарым. Бу мәсьәләгә артык әйләнеп кайтмас өченгә, иренмичә аңлатам, әгәренки моннан соң да, пычрак суда миңгерәүләтелгән балык тотарга уйласаң, безгә, кул бирешмичә генә, аерылышырга туры килер! Үткән гомеребезнең бер буынын гына исеңә төшерәм: ресторанда тапкан акчабызның, агымдагы тормышны рәтләүдән калганын, мастерскойга тыктык. Анда керткән өлешебез тигез иде. Бу очракта — син хаклы. Аны таладылар, җимерделәр. Кстати, ул көнне син, минем агач артыннан районга китәсен белә торып, ни сәбәптәндер, эшкә чыкмагансың,— дип, үтеп барышлый гына ташлы киная ыргытты да, сүзен дәвам итте.

— Шуннан соң, Хәлил бәй, син офыктан югалып тордың, байтак вакытка, бөлгән, хәерче оешма сиңа кирәк түгел иде. Мин КамАЗлар кулга төшереп, аларны сатып, акча туплап,аякка баскач, коры сөт, импорт мебельның, җиңел машиналарның эзенә төшкәч, син пәйда булдың. Әзер бәлешкә... Чакырылмаган хәзрәт төсле... Шул мәлдә ике арадагы сөйләшүне, кызганычка каршы, диктофонга язып алмаганмын, әмма эчтәлегең, мәгънәсен төгәл хәтерлим. Склерозга бирешмим әле, аллага шөкер. Хәтерлисеңме?

Диварга китереп кыстырылган Хәлил, танырга мәҗбүр булды.

— Сәет Яруллович, үз яныңа ал инде мине яңадан. Зинһар, дидем.

— Тагын?

Башка чакта, бигрәк тә телефон аша, сәгатьләр буенча сөйләшеп утыруны сукыр тиенгә дә чутламаган Нигъмәтуллин бу юлы эндәшмәү

алымын сайлады. Тургеневның чукрак Герасимы диярсең. МалныСәеттән тәк кенә умырып алып булмасын аңламаслык кеше түгел иде. Шайтан вә хатын коткысына бирелгәне өчен үзен әрләү дәрәҗәсенә житте. Нөкәтле үпкәсе калса да...

— Онытткан булсаң, хәтереңне яңартам. «Сәет дус, минем ике кыз үстерәсем, иренә үлем элмәге ташлаган юньсез хатынны туйдырасым, киендерәсем» бар, дидең.

Күңеленә, бәлки, «хатынының аңа әләк белән килгәнен әйтергәдер. Нәрсә мин җәлләп торам»,— кебек туң фикер килде. Андый түбәнлеккә төшмәскә булды.

— Туарылып эшләргә яратмаганыңны белгәнгә, сине кочакка алырга ашыкмадым. Соңрак үкендем, син яңача фикерләүгә җайлаша алмадың. Үзеңне кирәкле кишер яфрагына санап йөрүдән ары китә алмадың. Әхмәдиша картның күршесе—хохол карчыгы янына «дипломатик миссия» белән барып та, адәм хурына калдырдың. «Мансур Мәүлетовны табып, по душам сөйләшеп кайт, ул сиңа якынрак, безнең өлешне бирсен»,— дип, күпме үтендем. Юк, үстерелмәгән мыегыңны да селкетмәдең. Ресторан бусагасын саклаган чорда сез якын әшнәләр идегез. Бәлки, фаҗига булмый калыр иде. Ничек җавап бирдең миңа: «Аңа ялынып йөрисем калган, тамагына кылыч булып кадалсын, тыгылсын хәрам малга».

— Мансурны үтерүне миңа сыламакчы буласыңмы әллә? Менә монысы не выйдет.

— Җилне котыртма! Аның үлеме өчен мин зур бәя түләдем: Зөлфиямне югалттым. Хәзер тырнак астыннан кер эзләп утырудан берәү дә отмаячак. Бу сүзгә янәдән әйләнәп кайтмас өчен искәртә́м: «Игелек» мөлкәтенә өмсенеп, үзеңне котыртып, хаталанасың. Хәзер мин сине утырган кәнәфиеңнән азат итсәм, бернинди эш таба алмасыңны чамалыйсыңмы? Шунлык кына башың бардыр ич? Вышибала булып эшли алмыйсың. Аракы мәсьәләсе илдә уңай хәл ителеп, рестораннар шәхси кулларга күчеп беткәч, безнең яшьлек һөнәребезгә ихтыяҗ бетте. Премьер-министр оклады белән җылы бүлмәдә тоткан өчен, һәр көнне минем исәнлеккә, биш тапкыр намаз укып, мыштым гына яшисе урынга, кеше малын, дөресе, фирма байлыгын бүлеп ятасың икән. Ә сине, Хәлил бәй, өч көн сәбәпсез эштә булмаган өчен, статья чәпәп куып чыгарып була. Юристка задание бирсәм, хәзер оештырыр! Гафу итү минем гадәтемдә булмаса да, синең өчен соңгы искәрмә ясыйм. Учти!

Мондый ук кискен вә дәлилле аңлату көтмәгән Нигъмәтуллин чынчынлап югалып, шөлләп калды. «Әгәр эштән куып чыгарса, хәзер совет заманындагы кебек, яклау эзләп, парткомга, профсоюзга йөгерә алмыйсың. Соңгы сүз—аныкы».

Кызган баштан күңелен бушаткан Сәеткә дә җайсыз булып китте. Дегеткә бал кушып җибәрергә булды.

— Хәтта баш бухгалтерымны да кызганмадым синең өчен.

Хуҗасының әхлакый чәпчүен тыңлаганда, йөзенә ваемсыз искитмәүлек иңдерергә тырышып утырган Хәлил, дерт итеп калтыранып, сискәнеп алды. «Димәк, аның ким-хур булуы, оятка калуы турында кайтып сөйләгән теге симез сөйрәлчек. Дрянь хатын булып чыкты».

— Үзенә булсын ул итәк кигән иблисең.

— Нишләп әле кыйблаңны бөтенләй икенче якка борып куйдың? Фираяне күрүгә селәгәең ага торгание. Саф мәхәббәтне саклый белергә дә кирәк дип, укыган идем.

— Үзеңә булсын ул итәк кигән дәджалың,—дип кабатлаудан уза алмады кешелеге пычракка салып тапталган Хәлил Газиз улы.—Давлением күтәрелде. Зинһар, Сәет, илле грамм коньяк салып бирче.

Урынбасарына катырак кагылганы, хисапчыга җылы мөнәсәбәтен көлкеле маҗарага әйләндергәне өчен борчылган Сәет, бик теләп коньяк

агызып бирде. Шоколадын да ачып куйды. Олыгайган саен таныш-белеш арта, дуслар кими бара икән шул. Нишләмәк кирәк.

Дусты Хәлилнең янә бер гадәтен кабул итми Сакманов. Күзгә төтен җибәрергә ярата. Кем алдалый — шул урлый, дип тә әйтә бит халык. Ялганласаң, очын яшереп, үзең ышанырлык итеп алдаш инде.

...Хәлилнең машинасын «Игелек» башлыгы Мусин урамында куып җитте. Үз шөгыльләре белән йөргәне күренеп-сизелеп тора. Нигъмәтуллин, бик ялварып сорап, машинасына телефон куйдырткан иде.

— Хәлил бәй, нихәлләр? Мин әле бу... Ни эшләр бетереп, кайларда йөрисең?

— Северный поселоктагы базада мин, эш күп монда...— дип, авызыннан песнәк очырды да, шул ук урамдагы кибет янына килеп туктады.

Вакыйганы күңеленә киртләп куйса да, Сәет урынбасарын оялтып, әрләп тормады. Бөкрене турайтырга соң иде инде.

«Игелек» ширкәте, тулаем алганда, бертөсле уйлый, бер төрлерәк яшь торган кешеләрдән җыелган иде. Сәет үзенә якын рухлы, эшчән, булдыклы шәхесләрне җыярга тырышты. Башкаларга юл бирмәде. Хәлил искәрмә, үзенә бер коммунистик утрау булып кала бирде.

Берничә көн сөйләшүне күңеленнән кичереп йөрсә дә, Хәлил шоктан бик тиз арынды. Атна ахырында, араларында берни дә аңлашу булмагандай, шефының кабинетына килеп керде. Тырышып кырынган, юынган, спай итеп киенгән. Ир хатынын үзенә йөз сиксән градуска бора алган кеше белән шаярма. Ул — гадәти була алмый. Малайлар язгы тамчы бозын капкан төсле, күзлегенең сөякле башын авызына алып, алдан уйлап килгән фикерен җәеп сала башлый.

— Чабаксардан түләнгән әйберләр килми,— дип сөрән сала хуҗасы колагына, ифрат борчулы кыяфәт илә. Тыңлаучыны ышандыру нияте белән, гел күзлек киюдән чепиләнеп калган соры күзләренә дә кайгы-хәсрәт төсмере сирпи.

Сакманов исә, бөтен җитдилеген китереп, сораган була.

— Без аннан чуаш кызларына заказ биргән идекме әле? Татар хатыннарыннан тәмам гарык булдыңмы, җизнәкәй?

— Сиңа көлергә булсын. Күптәннән бензин бирмиләр. Алынмаган мебель күп. Үзебезгә бармыйча ярамас.

Үзенә кирәккәндә, Хәлил дуңгызга да, «исәнме, кодагый» дип, эндәшүдән оялып тормый, мунчаладай аякка урала, өлгергән кырмавыктай балакка ябыша белә.

— Бер җилләнеп кайтыйк инде, Сәет ахири. Кеше арасына чыкканыбыз юкка биш былтыр.

— Казанда рәтле кеше калмадымы? Аны Чабаксарга барып күрү көненә төштекме?

Кеше кулы белән утлы күмер көрәргә ярата иде Сакмановның урынбасары.

— Минем туган авылым Чабаксардан кырык чакрымда гына. Әни карчык янына сугылырбыз. Рәхәтләнеп бер авыл мунчасында чабынып, коенып, катык ашап кайтырбыз. Сөрсеп беттек,— дип, үҗәтләнеп, каймактан май чыкканчы, кат-кат үзенекен туглады.

Зөлфиясез калганнан соң, җан тынычлыгын югалткан Сәетнең, белмәмче булып, бер әйләнеп кайтасы килә иде анысы. Шаяртырга, үртәшергә тырышса да, кәефе урман агачы төбендәге бозлавык кебек, тынчу, салкынча иде. Әллә нидән, келт итеп, әтисенең: «Бер уйлаем Бохар китәргә, Бер уйлаем дөнья көтәргә»,— дигән иске җыры хәтеренә төште. Көне буенча шул сүзләрне кабатлап, көен шыңшып йөрде. Чабаксар — күрмәгән шәһәре түгел. Аласы малларын да кызыгырлыктан дип булмый. Үзе үстергәнне ашап, үзе ясаганны кабып яшәргә өйрәнгән чуаш кардәшләр, базар мөнәсәбәтләренең нахак, елгыр хәйлә, алдавыч икәнен аңлап, үзләренчә, табигать өйрәткәнчә, дөнья көтәләр. Көйләренә килмәсә, арт белән тәртәгә тибеп алырга да күп сорамыйлар.

Әнисен, бәгырен өзеп бирерлек булып яратса да, үзенең генә олы юлга чыгасы килми Хәлилнең. Туган төбәгенә генеральный һәм кимендә ике машина белән кайтып төшү турында хыяллана. Авылдашлары бак-сыннар, күрсеннәр аның кем икәнен.

Ахыр чиктә Сакманов Хәлилнең артыннан мөркелдәп сөйләнеп, үгет-ләп йөрүенә биреште, сәфәргә чыгарга ризалык бирде. Шуны гына көт-кән Нигъмәтуллин, җанланып, яшәреп китте. Сөенечле хәбәрне, үзе белгән барча элемтә чаралары аша, дус-иш, таныш-белеш колагына элде. Чабаксарга, райүзәккә, авылына шалтыратты. Сатып аласы әйберләр исемлеген йөртүчесенә тоттырып, базарга йөгертте. Мәйсәрә ханым исә, Хәлил мөкиббән киткән, корсакның түренә төшеп ята торган симез иттән өчпочмаклар, пәрәмәчләр пешерү шөгыленә керешге. «Игелек» контора-сында ләчтит сатып утыручы хатын-кызга да әзерләнү эшләре табылды. Кыскасы, уңдүртенче августта, сәгать бердә «Игелек» җитәкчелегенең Казаннан Чабаксар ягына чыгып китү хәбәре, кызыксынган кешеләрнең һәммәсенә мәгълүм иде. Сер саклап, тел яшереп торуны кирәк тапмады элеккеге милиционер.

Кыскасы, бәйрәм эскортын әзерләнеп каршы алырга мөмкинлек вә вакыт җитәрлек бирелде.

Тирәнтен тикшереп караганда, Хәлил башларына бәла-казаны үзе чакырган булып чыкты.

Ширкәттә башка эшкә, тәэминат бүлегенә күчерелгән Замир урынына, вакытлыча, пенсия яшендәге, тәҗрибәле шофер Анатолий Павловичны алып торган иде Сакманов. Ул «Волга»ны, ары-бире генә караштырып, ерак юлга чын-чынлап әзерләмәгән булып чыкты. Сакчылары утырган өр яңа, тугызлы «Жигули» аларны озата барырга тиеш иде.

Сәет иртүк кабинетына килеп, кәгазьләр караштырды, бухгалтерия эшләренә кул куйды. Күңеле тартмый иде юлга чыгарга. Олы бер йомышны онытылып калгандай тоела. Шуның өстенә, тагын бер начар билге, ырым килеп өстәлде. Юлга хәстәрләнеп беттек, чыгып утырабыз гына дигәндә, Мисхәт-Мишаның тормыш иптәше Әлфия ханым күңелсез хәбәр, тамгалы галәмәт алып килде.

— Минем алачыкка фәрештә килеп кердеме дисәм, әллә Әлфия ин-де? — дип, гадәтенчә теленә салышты Сәет, кунакбикәне җиңелчә генә ике җилкәсеннән кочып. Күз төпләренә төшкән кара шәүләләргә, чыраеның төссезләнеп китүенә игътибар биреп өлгерде бүлмә хуҗасы.

— Нинди җилләр ташлады? Мисхәт бер атнага сорап киткән иде. Унынчы көн узды, күренми. Авылында ял итеп ятамы?

— Юк шул, Сәет Яруллович, ул башка җирдә ята.

— Нәрсә булды? Берәрсенә йортка керергә өлгердеме әллә? — дип, шаяртуында булды Сәет.

— Йортка кергәннәр тиз әйләнеп кайта. Ә менә төрмәдән кайтула-ры...

Бүлмәдә сагаюлы тынлык урнашты. Әлфиянең күңел буасы ерылды. Күзләреннән, сабый балаларныкы төсле, үтә күренмәле яшь тамчылары шартлап бәреп чыкты.

— Мисхәт төрмәдә! Оренбург шәһәрендә.

— Ничек төрмәдә? Юкны сөйләмә!

Икесе дә җайсыз басып торалар икән. Сәет, исенә килеп, кулы белән дивар буендагы түгәрәк утыргычлы урындыкларның берсенә ишарә ясады. Үзе дә кәнәфиенә барып бөялде.

— Тукта әле, Әлфия, яхшылап аңлатып бир,— дип бүлдерде хуҗа, Зөлфиясенең якын дустын.

— Үзем дә рәтләп белмим. Аның олы апасы гаиләсе белән Ургенч янында яши. Шул: «Срочно килеп алып кит, монда тормыш калмады»,— дип, кат-кат хат язган, телеграмма биргән, кайтып та киткән бугай. Үзем күрмәдем. Мисхәтне беләсез инде, туган җанлы кеше. КамАЗ машинасы белән, алып кайтырга ниятләп, шунда киткән иде...

Әлфия, нарасый күз яшьләрен тыюны, хәтта сөртеп алуны да кирәк тапмыйча, үкси-үкси сүзен очлап китте:

— Мисхәт бер атнадан артык Оренбург төрмәсендә интегә икән.

— Кем хәбәр итте? Каян белдең?

Сәетнең бөтен тәне буйлап ипсез, җыбылҗык дулкын узды. Төрмәнең кабатланмас сасы исе тешләренә сылангандай булды, тәне чымырдап китте. «Нинди хата җибәрде икән егет. Акылга, төпкә утырып, чын-чынлап кул астына кереп, ышанычлы түмгәкләрнең берсе булып үсеп килә иде».

— Үзем дә югалткан идем. Исәп буенча, әйләнеп кайтырга тиеш иде. Кичә менә хат кисәге килеп төште,— дип, ханым кечкенә коңгырт сумкасыннан бөгәрләнеп беткән кәгазь кисәге алып, Сакмановка сузды. Анда нибары берничә җөмлә төшерелгән иде.

— Укырга ярыймы?

— Әлбәттә. Үзе нәкъ сезне исендә тоткан...

*«Әлфия!*

*Мине Оренбург шәһәрендә милиция кулга алды. ГАИ такталар белән тотты. Каршы әйттем, җавап бирдем. Мине «За попытку дать взятку работнику правоохранительных органов» дигән статья белән гаепләмәкче булалар. Эшне Степной районы прокуратурасына биргәннәр. Прокурор бу як татары, ну бик явыз адәм, диләр. Бар акчаларымны алдылар. СИЗО да утырам. Сәет Яруллович хәбәр ит, үтенеп сора. Мине ул коткарса гына.*

*Үзең килеп китә алмассыңмы? Акча, кипкән колбаса, бигрәк тә сарымсак җибәр, бу якларга берәрсе килсә.*

*Мисхәт».*

Сәеткә барысы да аңлашылды. ГАИ әһелләренең чит-ят машиналарга, ач кандала мәсле ябышулары, аерым бер үҗәтлек белән тикшерүләре сер түгел. Аларга каныгуы җиңел. Арка терәкләре, яклаучылары юк. Күбесе төшемле халык. Ерак юлга буш кул белән чыкмыйсың. Тикшерүченең кесәсенә нәрсәдер сыланып калырга мөмкин. Мисхәт, яшьлеге белән әтәчләнеп, каршы әйткәндер, кулына йә теленә ирек биргәндер. Ә тегеләргә шул гына кирәк. Малдәнең бик әшәкесен, баш чыкмаслыгын сыларга җыеналар.

Уйларыннан арынып, нәтиҗәсен әйтте.

— Оренбургка барырга кирәк. Һәр көне кадерле. Төрмә ул сазлык төсле, үзенә суыра тора. Мин берничә көнгә Чуашстанга чыгып керәм дә, кайткач, шунда юл тотармын. Хәзер кемнәргәдер сораган әйберләрен алып барырга кирәк булыр.

Әлфия җылау-шыңшудан шып туктады.

— Үзегез бара алмассызмы, дип килгәнием. Башка кешедән файда булмасын күңелем сизенә.

— Аңлыйм мин сине, Әлфия. Кайгыңны уртаклашам. Мин бухты-барахты гына чыгып китә алмыйм. Әзерләнергә, таныш-белешне барларга кирәк.

«Бүген, өйләдән соң, Хәлил абзаң илә, кычытмаган җирне кашырга чыгып китәбез»,— дип әйтә алмый ич инде хәсрәтле хатынга.

— Берәр туган-тумачаң белән үзеңә барып кайтырга кирәк, Әлфия. Пока.

— Минем беркемем юк бит, Сәет Яруллович! Мин — ятим бала.

Сакманов аның япанда ялгыз үскән агач икәнен белә иде. Онытып җибәргән.

— Мисхәтнең туганнары бар. Аларга әйтергәме икән? Тавышы, исе чыгар, файдасы тимәс...

Үз бәхетен үз кулы белән табарга өйрәнгән ятимә баланың акылына тагын бер сокланды Сәет.

— Бер дә җибәрәсем килмәгән иде машина белән. Тыңламады,— дип өстәде Әлфия.

— Мин Замир белән Гришага әйтермен. Машина белән, бергә барып кайтырсыз.

Сәет ханымның тозлы су белән юганнан соң, чистарып киткән, керсез, акыллы соргылт күзләреннән: «Ну,без бардык ди, ни файда бездән, якын итсәң, абзыкай, үзең алын инде» мәсле төрттерүле фикерне укыды. Оят булып китте.

— Әйткәнемчә, бүген командировкага китәм. Өч көнгә. Шуннан кайткач, займусь. Сез разведкага барып кайтыгыз әле.

Шул көнне үк Әлфия Замир, Гриша белән «Нива» машинасында, төрки халыкларны бүлгәләп кую өчен махсус салынган дала кальгасына чыгып киттеләр. Аларның Мисхәтне күрә алмыйча, бары тик төенчек тапшыруга ирешеп, буш кул белән кайтуларын Сакманов берничә айдан соң гына беләчәк.

Кемнәрдер өйләнгән, аерылган, йөрәк тотуыннан вакытсыз вафат булган яисә, яшьлек дуамаллыгы белән, башын зинданга тыкканга карап кына тормыш тукталып тормый. Бер генә мизгелгә дә.

## 15

Вильсур Садыйков үзен «рәсми» бүлмәдә шул тиклем мыскыл итүне, бигрәк тә дошманының банктан шактый акчаны суырып алуын, әлбәттә инде, гафу итә алмады. Тәрҗемәи хәленең шәптән түгел икәнлеген үзе генә белә. Әйтерсең лә, кара элмәк каткан бармакларын муенына төшерергә әзер тора.

Сакманов белән очрашуның нәкъ өченче көнендә, шәһәргә караңгылык патшасы пәрдәсе төшкәч, ул мәзһәптәшләрен җыеп алды. «Эдельвейс» башлыгының күзләрендә адаштыргыч җәяүле буран, чырае сытык, күңелсез, кечкенә мыегы явыз тырпайган.

— Җыелышны кереш сүзсез — бисмилласыз башлыйм. Заманасы шундый...

Мин чын демократ буларак, сезгә ышанып, дилбегәне бушаттым, ирек куйдым. Бик зур хата эшләгәнмен, Ышанычымны акламадыгыз, ак кәгазь кебек чиста күңелемә тап төшердегез,— дип сүзен каршысында тезелешеп утырган башкисәрләрен, тән сакчыларын, куштаннарын әрләүдән башлады.

Мәгънәле тукталыш ясап, күз карашы белән барчасын сынап чыккач, рәнҗүле, үпкәчел чыгышын дәвам иттерде. Нык бәдәнле, бүлтәеп торган мускуллы, кыска муенлы, буш күзле, кечкенә башлы егетләр берни аңламыйлар, җыелышның мәгънәсен абайламыйлар. Паханнарын Сакмановның черек төп башына утыртуыннан әле берәү дә хәбәрдар түгел. Аның бу ялгышы, хатасы соңрак мәгълүм булачак.

— Сез кемнәр?.. Тиешле көйне уйнар өчен кирәкле уен кораллары. Флейталар, барабаннар, скрипкалар... Әмма сез мин кушкан көйне генә башкарырга тиешсез... Фирма сезгә мул итеп түли... Шуның өчен аңа акыллы, зирәк ау эте, мылтык эчендәге пуля кебек, турылыклы хезмәт итәргә тиешсез. Шунда гына без Сакманов — Ваһаповларның бүре өерен җиңә алырбыз. Дөресме?

Кабан дуңгызлары кебек, янтауга-янтау терәп утырган таза егетләр, җавапның нинди булырга тиеш икәнен чамалыйлар. «Дөрес», бик дөрес»,— дигән бердәм җавап алына сорауга.

— Артык тыныч, беспечно яши башладык,— ди-ди, сүзен ялгап алып китте хуҗа.— Ир-ат рәхәт, мул тормышка өйрәнсә, сугышчы булудан туктый. Ул борын-борыннан, җир, су, алтын, хатын-кыз өчен яу тоткан, орышкан, сугыш кырында ятып калган йәисә рәхәттә йөзгән. Без үз вазифаларыбызны үтәми башладык. Игътибар иттегезме икән, соңгы вакытта инициатива безнең кулдан китте. Без гел соңга калабыз. Чөнки сүлпән, мыштыр, акрын кыймылдыйбыз, үсешебездә катып калдык, безнең көрәш алымнарына яңалык җитешми. Без кизәнәбез — алар суга. Без яныйбыз — алар куыра.

Чын көннән тегелгән футбол тубы кебек, түгәрәк такыр башлы юньсезнең Вильсурны бүлдерүгә кыюлыгы җитте.
— Максимович, сез ментларны күздә тотасызмы?
Сорау бирүче тотнаксыз бәндә ягына борылып та карамыйча, нотыкчы, бер бал кашыгы абхаз аджикасы капкан кешедәй, чыраен бозды, азау тешен суырып алды. Һавада сул кулын уйнатып төшерде. Олы алтын балдактан төшкән нурсыз яктылык сөальченең йөзен сыдырып, тырнап узгандай булды.
— Тозсыз сорауларга соңыннан вакыт бирелер. Сүз Сакманов бандасы турында бара. Алдан Мансур Мәүлетовичны юк иттеләр. Андрей Северцев белән ничә сыналган, турылыклы хезмәттәшебез янып үлде.
«Хезмәттәшебез» сүзенә басым төшерде.
— Өйгә ут төртүчеләрнең шул җинаятьчеләр шайкасы булуында бер мыскал шигем дә юк. Исбат итә алмадык. Эзләүче булмады. Расих Идрисовны — Боланны югалттык. Аның мәете дә табылмады. Коега төшкән балта кебек юкка чыкты. «Умырзая» ресторанында булган вакыйганы искә төшерегез. Аның иясе Ленар Динмухаметовны көпә-көндез пистолеттан атып үтерделәр. Көнбатыш һәм мөселман илләрендә президентларны һәм шейхларны гына шулай дөмектерәләр.
«Ленар кебек кысмыр, сукыр бер тиененә табынган карун өчен мондый чагыштыру әрәм инде. Эффект өчен кирәк. «Без иписез дә яши алабыз, безгә эш бир»,— дигән шук уен, зиһене аша үткәреп, тавышын акрынайта төшеп, хәтта пышылдауга күчеп, дәвам иттерде.
— Динмухаметов эшен әүвәл безнең дустыбыз, «түбә»без Алексей Трофимов алып барды. Ул җинаятьчеләрнең эзләренә төшкән, кара елан Сакманов — Ваһаповларның коерыгына баскан иде. Үзенең һәм дусларының фаш ителүеннән коты чыккан Гаяров эшне алып баруны үз кулына алды. Аның Йошкар-Олага чыгып, бу үтерүнең шаһиты булган хатыннар белән очрашып, кайсын майлап, кайсын куркытып кайтуы мәгълүм. Тегеләр алдан биргән таныклык-күрсәтмәләреннән дә баш тартканнар. Эшне иплән кенә ябып ятмышлар. Янәсе, Ленар Динмухаметов — төркемнәр арасындагы гадәти сфера бүлешү корбаны. Бетте-китте.
Такыр баш янә калыкты.
— Трофимов тавыш күтәрсен! Министрга керсен.
— Синең шикелле шыр тилемени ул? Аның башы ике түгел. Әле генә майор дәрәҗәсен алды. Гаяров аның турыдан-туры начальнигы.
Озын сүзнең кыскасы, мыегыгыз тычкан исен сизми башлады. Безнекеләрне сукыр куяннар урынына кыралар, ә сездән рәтле-башлы тәкъдим юк. Байбаклар кебек йоклыйсыз.
— Сакмановны «алырга» кирәк! — дип, «уңышлы» тәкъдим белән чыкты киптерелгән мүк иренле куштаны.
Ашыкканлыгын аңлады бугай, тавышы киселеп чыкты. Җирнең кояш тирәсендә әйләнүе, бәрәңгенең безнең якта елына бер генә тапкыр өлгерүе, күз артыннан кыш килүе кебек үк, исбатлауны таләп итмәгән аксиома иде бу. Телеграф чыбыгындагы чыпчыклар төсле рәт булып утырулары да шуның өчен ич. Ничек, ни рәвешле, кайчан кебек сораулар күши иде уйларга өйрәнмәгән миләрен. Шефның шул мәсьәләне кабыргасы белән куюы да табигый яңгырады.
— Риза. Бу изге эшкә кем алына? Нормаль йөрәклеләр бармы әле арабызда?
Табигый ки, берәү дә, хәтта «алырга» дип тәкъдим иткән иптәш тә, бу «дымлы» эшне үз җилкәсенә салуны сорап, кул күтәрергә ашыкмады. Кеше үтерү — премия яисә гонорар алу түгел шул. Сакмановы да гади пуля алмый, пычак шуып төшә торган эт җан бит әле аның. Кулына эләксәң... Барысы да, өстәлнең аргы башында берүзе утырган Вильсур ягына борылырга куркып, каенатасына күтәрелеп карарга оялган тәүфыйклы киленнәр сыман, күзләрен идәнгә, туфли йә адидас аяк киеменә төшерделәр. Бүлмәдә каберстан тынлыгы урнашты.
Ачаңак кушаматлы, экспедитор штатында утыручы Николай Федорович алда торган бурычның мөкатдәслеген аңламаган булып чыкты. Иске гадәте буенча, сызгырып куйды. «Изге дип инде, ментовкага эләксәң, әүлиялегеңне тиз чыгарырлар. Сакманов фликлары да туган ананның

исемен оныттырырлар. Миеңнең буразналары тигезләнер»,— дип, карышты.

Николай Федорович яшь буенча арада иң өлкәне. Хөкүмәт сәүдә оешмасыннан килгән, тәҗрибәле кеше, таныш-белешләре күп. Малай-шалай алдында юк-бар сөйләп утырганы өчен, ачуы күңел күленнән ташып чыгарлык булып кайнаса да, Вильсур түзде, маңгаендагы кечтеки яра эзен (малай чакта егылу галәмәте) капшау белән канәгатьләнде. Аңа кызарга ярамый, иртәрәк әле.

— Николай Федорович, син мәсьәләгә тар киләсең. Причем монда ату, үтерү. Үч алуның алымнары, тормышның үзе кебек, бай һәм төрле-төрле. Без, коммунистлар, Ленин-Сталин бабаларыбыз сызган юлдан барабыз, алар ахырына җиткерә алмаган изге эшне дәвам иттерәбез,— диде Вильсур, хөкемдар кыяфәткә кереп.

— Коммунизмны төзеп бетерү дә безгә тапшырыламы әллә? — дип белешүне кирәк тапты мүк иренлесе.

Төрттерүне, бәгыренә үткәрмичә генә, пахан сүзен дәвам иттерде.

— Абзагыз әйтте диярсез, коммунистлар барыбер хакимияткә киләчәк. Минем исемнең тамырына игътибар итик. Виль — Владимир Ильич Ленин.

— «Суры» нәрсәне аңлата инде? — дип сорады, фәнгә мөкиббән киткән бер ыштыры.

Мондый ук сорауга «Эдельвейс» ширкәте башлыгы әзер түгел иде. «Белмим» дип тә әйтә алмый, хәчтерүшләре алдында абруе төшә.

— Анысы чит ил сүзе, иркәләү, назлау булыр, дип уйлыйм. Анысын әнкәй өстәгән... Читкәрәк киттек. Коммунистлар, шәхси милеккә каршы килешмәүчән сугыш ачып, шул юлда җаннарын фида кылганнар. Без дә, искелек хорафатлары белән, үзебез белгән алымнар ярдәмендә көрәшергә тиешбез. Садыйковның тел төбен, логикасын аңлавы кыен. Әле генә Сакмановны юлдан алып ташлау турында сүз барды. Хәзер әнә кая кереп китте. Коммунизм төзү... Искелек калдыкларын юк итү...

— Фикеремне аныклыйм. Сакмановның Северный поселыгындагы йортына, базасына ут төртү, бомба, граната ташлау турында сүз бара.

Башка вакытта әрсез, гаярь, акча белән хатын-кызга һәрдаим ач күзләр янә түбәнгә, паркет идәнгә, аяк киеменә егылды. Берәүнең дә үз ирке илә ошбу әшәке эшкә алынасы килми.

— Кем яхшы белә ул тирәне?

Тынлыкны бозарга чебене дә юк ичмасам. Янә Ачяңак сүз катты.

— Ренат: «Яхшы беләм мин Сакмановның андый утарын»,— дигән иде.— Бәлки, ул алыныр. Рәнҗүе дә бар.

— Нәрсә сез, Ренат та Ренат,— дип, күтәрелеп бәрелде чүл гарәбе төсле, чем кара егет. Җиде айдан ук дөньяга чыгарып ташлаганы өчен әнисен дә гафу итмәгән Ренат бик үпкәчел. Сакмановка үче көчле булса да, курку хисе куәтлерәк иде шул. Миенә миңгерәү менде. Төрмә ишегенең тимер йозаклары, шыгырдап ачыла торган авыр ишекләре, елау, сыктау, кычкырулар әле дә колагында зыңлап тора.— Миңа гына дөнья килеп терәлгәнме әллә? Юлны өйрәтермен. Этләрен, Туманны агулап үтермичә, анда ничу делать. Зверь. Икенче катта кул пулеметы әзер тора, диләр.

Вильсур күтәрелеп бәрелде. Бар үпкә-ачуларының кайнар, пычрак ташкынын яраннары башына агызды. Ярларыннан чыкты, кар сулары булып ташыды, чоңгылларны тутырды.

— Сез куркак җаннар. Барыгыз, дивана башларыгызны хатыннарыгызның, фахишәләрегезнең итәкләре астына яшерегез. Сакманов бандитлары, артыгызны кисеп алып, шашлык ясасын! Чучка итеннән тәмлерәк булыр. Эшсез ятып, симереп беттегез...

Парын чыгарып, ярларына кайтып төшкәч, ягымлы, игелекле тавыш белән сорап куйды.

— Бәлки, Роман, син алынырсың бу эшкә? Йортны саклаган кеше буларак. Капиталга каршы көрәшеп ал!

— Юк, булмый, минем бабам бай кеше булган, авылда ике ташпулаты булган, аны раскулачивать иткәннәр, диләр. Бабамның якты истәлеге-

нә тап төшерергә хакым юк. Аннан соң, безнең үзгәрәк тәкъдим дә булыр әле,— диде Гөмбә бик солидно гына.

— Ярый, бу мәсьәләне әлегә калдырып торыйк. Әзерләп бетерәсе булыр. Хәзер алар ширкәтнең малына кул сузалар,— дип, тавышына чарасыз өметсезлек төсмере биреп, киная белән тәмамлады фикерен «Эдельвейс» ширкәте хуҗасы.

— Кемгә сүз бирергә? Ниндирәк тәкъдимнәр, теләкләр булыр?

Төймә тишекләре киңәйгән, коңгырт пинҗәкле, очлы иякле, төсен билгеләве кыен күз төпләренә кара дуга төшкән, Васек кушаматлы Василий Яковлевич аякка басты. Ул — утны-суны кичкән адәм, Вильсурның кыек-мыек шөгыльләре буенча уң кулы. Акыллырак сүз көткән иде пахан аңардан. Ул шул ук тозлы селедка башын чәйнәргә керешә.

— Андрей Северцевны, аның белән бергә кара күмергә әйләнгән дусларыбызны харап иткән бәндәләрне табарга иде? Янган җирдә көйгән ис кала барыбер.

— Барып иснәп кайт,— дип, төпле киңәшен бирде Вильсур әүвәл. Аннан соң, бик таләпчән кыяфәт белән, сорап куйды:

— Ничек күз алдына китерәсең бу фашлауны?

— Янгын нәрсәдән чыккан? Берәрсе үчлек белән төрткәнме, әллә исерешеп, сугышып, ут чыгарып, үзләрен-үзләре харап иткәннәрме? Ныклап ачыкларга иде.

— Соң, ачыкла, дустым! Бу мәсьәләдә синең белән килешмәүчеләр булыр дип уйласаң, ялгышасың. Каршылар бармы? — дип белеште элеккеге комсомол узаманы, песи баласы тиреседәй йомшак, иркә тавышка күчеп. Мондый ук «назны», үзен җитди кабул итмәүне көтмәгән Васек, чабуыннан милиция сержанты эләктергәндәй, каушап калды. Йөзе бүселеп чыкты. Аркасы буйлап, кайнар дулкын йөгерде. Аз-маз гына дулкынланса да, Василий Яковлевичның шулай тирли торган гадәте бар. Ертлачлыгы баштин ашкан, этләшүен дәвам итте.

— Прокуратура ачыкласын! Оешма исеменнән хат юллыйк!

— Мәктүпне әзерләүне, тиешле җиргә илтеп тапшыруны, кәгазьнең хәрәкәтен күз уңында тотуны, хөрмәтле Василий Яковлевичка тапшырырга! Янәдән сорыйм. Каршылар юкмы? Юк. Битарафлар безнең сафта булалмый. Килештек.

Вильсур, гомерендә беренче кат күргәндәй, Васекның күз төпләрендәге кара сызыкларны олы дикъкать, иң җитди кыяфәт белән өйрәнде. Нәтиҗәсен утыручыларга җиткерде.

— АОның идарә утырышы карары нигезендә, Василий Яковлевич, иртә таңнан шул мәсьәлә белән шөгыльләнә башлыйсың. Милициягә барып гауга чыгар, тавыш күтәр, яна, өркет, гаепле, сатып ал! Фараоннар белән аралашуның алымнары төрле. Син төрмә академиясе үткән кеше, аларны миннән яхшырак беләсең.

Васек, аягы капкынга эләккән ерткыч мәсле, як-якка каранды. Теләктәшлек табу турында хыялланмады да, киресенчә, таныш йөзләрдә, тимер битарафлык битлеге астында яшеренгән эчке сөенү, тантана сизде. Бите, гарьләнүдән, бурлаттай кызарды. Аяк бармакларыннан күтәрелгән кайнар кан күз төпләренә, чәч тамырларына килеп җитте. «Дугаларына» чаклы кызылга манчылды. Милициянең инде аны өченче ел бер хатын белән яшәп, соңыннан аның фатирын чистартып чыккан өчен, рәсемнәрен чатларда элә-элә, эзләгәне барысына да мәгълүм.

— Ә ни өчен мин? Мин бит болай гына әйттем.

— Карталар синең кулда. Андрей Северцев «тәп-ләп» буенча якының,— дип, бу юлы тавышын кырыслыкның кыска дулкынына күчереп, дәвам итте алып баручы.— Бергә утырдыгыз да бугай, хәтерем ялгышмаса. Тәртәне читкә бору килешмәс.

Бәлки, башка берәрегезнең, Василий Яковлевич урынына, милициягә барырга теләге бардыр? Мин каршы түгел.

Кырмыска оясы таякны кабул итмәде.

— Дәшмисезме?

Вильсурның итле яңагы аша да, бит сеңерләренең биеп алганы күренде. Пахан сөйләшүнең төп юлдан читкә чыгуыннан канәгать түгел иде. Северцевлар фаҗигасенең кан саркып торган вакыты узган. Шау-шу куптарып тикшергән булып кылансалар да, очына чыгарга теләүче булмады, янгынга нисбәтән бер вәсвәсә дә расланмады. Әйтерсең лә, авыл клубы тикле йорт янмаган, анда җиде кеше күмергә әйләнмәгән.

Сөмсере коелган, тәкъдиме әрәм киткән Василий Яковлевичның күңелен бер нәрсә тынычландыра. Ул иртәгә үк, бүгенге җыелыш турында, барысын да төкми-чәчми, үзеннән өстәп, Сакмановка бәян итәчәк. Бу тиле-миленең кушканын үтәмичә, судан коры чыгу юлын да өйрәтер «Игелек» хуҗасы.

Садыйковның бер үк фикерен кайта-кайта үстерә торган гадәте бар.

— Ярый. Анда кемдер Сакмановны юлдан алып ташларга, дигән «акыллы» бурыч куйган иде. Мин үзем, әлбәттә, совет чорында тәрбия алган кеше буларак, кеше канын коюга каршы. Адәм каны — су түгел,— дип, янәдән балдаклы кулын уйнатып алды.— Тик Сакмановның азуы җитте. Урынына утыртырга, тәртәгә кертергә вакыт. Ач ерткыч кебек, намуслы кешеләр өстенә сикерә башлады. Ярый, Сакмановны «саклауга» куелган әфәнделәрне тыңлап карыйк. Алар хет хәзер аны таныйлармы икән?

— Да, энесен бер дә юкка харап иттек,— дип, сүз кыстырырга булды Василий Яковлевич, бу юлы инде башкаларның хатасы өчен шатланып.

— Анысын да кызганып торасы юк. Бер үк кан. Эткә — эт үлеме,— дип сүзгә катнашырга булды Сакмановтан качкан Гөмбә.

Җигелмәгән үгездәй таза, уртача буйлы, сары йөзле, кечкенә йөгерек күзле егет торып басты:

— Без, тәкъдим-фикерләребезне үзегезгә генә, соңрак әйтер идек.

Икътисадый, алыш-биреш, сату-алу мәсьәләләре буенча шактый озак фикер алышып, баш хисапчыны тыңлагач (акчаларын «күчерү» турында әле ул да белми иде), Садыйков җыелышны ябып, берничә егетен генә алып калды.

Василий Яковлевичның бәхетлеләр арасында буласы, сүзнең нәрсә хакында барасын беләсе килеп эче күгәрсә дә, Садыйков аңа, баш кагып кына, чыгып китәргә боерды. Табигый ки, сөйләшүнең бу өлеше Сакмановка барып җитә алмады.

— Йәле, Роман, нинди сөенечле хәбәрең бар анда.

Кабул ителгән тәртип буенча, Гөмбә аякка басты.

— Менә,— диде, янында утырган, борчаны хәтерләткән чапкын күзле, төп кебек таза, агылҗым чәчле егетнең җиңеннән тотып,— Котдусның телефонистка подругасы бар. Ул Сакмановның замы, Хәлил Нигъмәтуллинның Чувашстанга, туган авылына шалтыратканын тыңлап торган. Ундүртенче август көнне, Сакманов, Нигъмәтуллин һәм тагын берничә кеше шунда кунакка барырга җыеналар. Авылда яшәүче энесе белән бик озак сөйләшкән Нигъмәтуллин: «Генералның үзен алып кайтам, мунча ягылган, чөгендерле катыгың әзер, кичке сәгать алтыларга, җиделәргә бәлешең, тутырган тавыгың пешкән булсын, дигән... Әнисенә, энесенә, киленнәренә нинди бүләкләр алып кайтуына чаклы әйткән... Икенче көнне Чабаксарга...»

Мәгъсүм аганың бердәнбер улы Вильсур Роман-Гөмбәне тыңламый иде инде. Нәфрәт, күралмау белән ачытылган киеренкелеге, сөзәк маңгаеның җыерчыкларына, борын билендәге кара сызыкка, күперенке иреннәренә, күзләренә бәреп чыккан. Корбанын куып җиткән тилгәнне хәтерләтә иде Вильсур читтән карап торучыга. Ниһаять, үч алу көне килеп җитте. Бу юлы Сакманов аның акыллы куелган җәтмәсеннән ычкына алмас. Аны, XX гасырның иң зур җинаятьчесе кебек, атып үтерәсе, үле гәүдәсен машинасында яндырасы... Аның хыялында дошманы дөньяда яшәп киткән танышлары исемлегендә иде. Җитте, чибәрләнеп, көязләнеп, типтереп озак яшәде. Тырнаклары учына кергәнче, бармакларын чытырдатып кысты. Ул Сакмановны күмүдә катнашачак, элеккеге комсомол җыелышларындагы шикелле, төкерекләрен чәчә-чәчә, ялкынлы чыгыш ясаячак.

Вильсур якыннары белән бик озаклап, булачак вакыйганың һәр сызыгын нечкәләп, тәфсилләп өйрәнде. Бу орышны ул, Сакманов белән шәхси исәп-хисаплары булган, кансыз, шәфкатьсез Гөмбә, Коротышка кебек сыналган гамәлдәшләренә, тәҗрибәле катыйльләргә тапшырды.

Егетләр, «язмыштан узмыш юк», дигән булып, пычрак эшне үз өсләренә алдылар. Гөмбә, авыр вә куркыныч операция өчен, алдан ук бәяне билгеләүне кирәк дип тапты.

— Бишәр мең бакса алырсыз! Соңыннан. Гадәти бер прогулка, сез бит әле зарплатада утырасыз,— дип, саранланды Вильсур.

Гөмбә белән Ренат алдан сөйләшкәндәй, кадакның очлы ягына утырган кешеләрдәй, урыннарыннан сикереп тордылар. Янәсе, бу аларны ут яктысында рәнҗетү, мыскыл итү, кешелекләрен бер ел юылмаган агач идәнгә салып таптау.

Карун хуҗага тагын өстәргә туры килде. Вильсурдан да кысмыррак Гөмбә, явызланып, аванс мәсьәләсен кабыргасы белән куйды. Паханга тимер шкафны ачып, һәркайсының, аерым-аерым кулларын кысып, акча тоттырырга туры килде. Терсәкне тешләп булмый, булачак туй өчен башка түләр кеше юк.

Киллерләр канәгать. Йөзләренә рәсми буйсыну, тыңлаучанлык рухы инде.

Вильсур егетләрен өркетеп алырга булды.

— Сезгә нинди җаваплы бурыч йөкләгәнне аңлыйсыздыр?

— Соң, үзебез сорап алдык,— диде Гөмбә, ваемсыз гына.— Без әйтмәсәк, Сакмановның Чувашстанда типтереп кайтуы хакында белмичә дә калыр идегез, босс. Рәхмәт әйтегез!

Сары ат тешләрен күрсәтеп алды. Аның бөтен көлүе шул иде.

Садыйков Гөмбәнең тәрттерүле сүзләрен ишетмәмешкә салышты. «Бу болачы хәбәре өчен түләү сорый башларга мөмкин»,— дип, фикеренең төп өлешенә күчте.

— Алдашырга, хәрәмләшергә уйлый күрмәгез! Куркытмыйм, кисәтәм. Вәгъдәдә тормау, беребезнең дә исәнлегенә файдага китмәс. Бу очракта инде төрмә дә коткарып кала алмас,— дип, фикерен тач өздереп, теләсә нинди диванаының миенә барып җитәрлек итеп әйтте. Тавышы да дәһшәтле, янаулы чыкты. Берәүнең үзе, икенченең сүз батыр, диләр шул. Уйланып торгач, өстәп куйды: «Латынча «капут», баш дигән сүзне белдерә»...

Мунча ташыдай, соң чиккәчә кызган ачуы, нөктәле үпкәсе башын яхшы эшләтә. Вильсур үч алуның һәр ягын, һәр борылышын, бигрәк тә ахырын исәпләп чыгарырга тиеш иде. Уйлана торгач, шундый анык карарга килде. Сакманов илә аны озата баручыларны җәһәннәмгә озаткач, бу чибәр егетләрне исән-имин калдыру дөрес булмас, бик зур сумма чыгарып саласы була. Бусы әле — байракның бер ягы. Тикшерү, эзләү башланачак, Гаяров, якын дустының якты истәлеге өчен, тиресеннән чыгып, дөньяның астын-өскә китерәчәк. Киллерларның эзенә төшәчәк, кулга алып, үзе «сорау» алачак. Үз гаепләрен җиңеләйтү өчен йәисә кыйнауга, җәзага түзә алмыйча, бәгъзесе әлбәттә инде, аны, паханнарын, сатачак. Көпчәк бөтенләй икенче якка әйләнә башлаячак.

Ачяңакка үзен көтәргә, күрше бүлмәдә посып торырга кушкан иде. Машинага ясалма шартлаткыч, мина, граната кую кебек эшләрнең алласы инде ул. Сәркатип кыз — Сара, Ачяңакны чакырып кертте дә, кабинетта затлы ислемай тәме калдырып чыгып китте. Ул әле соңрак керәчәк, ап-ак, тулы беләкләрен паханның арыган муенына салып, тезенә менеп утырачак. Мәхәббәт уенын башлаганчы, кыйммәтле коньяк эчәчәкләр.

— Николай Федорович, без синең белән бик якын кешеләр бит. Шулаймы?

— Кирәк түгел, хуҗам. Йомышыңны ярып сал. Мин әзер. Кемне буып үтерергә,— дип, шүрәленекедәй озын, горилланыкыдай көчле бармакларын өскә күтәрде. Вильсур хәтта шөлли калды.

— Юк, юк! Бирәүне дә үтереп, гөнаһлы буласы түгел. Дүрт көпчәкле арба, то бишь минем БМВ машинам, үндүртенче августта, кичке сәгать алтыларда ут салюты биреп, анда утыручылары белән бергә күккә, фәрештәләр янына очарга тиеш.

— Эшләрбез,— диде, күп сүз — чүп сүз, дигән иманда торган Ачяңак һәм ач күзләрен сейфта туктатты. Янә ачкычны кулына алырга туры килде Вильсурга.

Алдан бирелә торган өлешне куртка кесәсенә салгач кына, өстәп куйды:

— Рәхәтләнеп һавага очырам. Мин йөрисе машина түгел.

Вильсур Садыйков август урталарына чаклы өмет белән яшәде: мәкергә дә, чәчәкнеке кебек нечкә сабаклы булса да, ышаныч кирәк икән...

## 16

Үткән белән бүгенгене бәйләп торган зиһенле кичерешләре Сәетне, күпме генә карышса да, үзәк вакыйга ярларына сөйриләр. Хатирәләр — урында яткан кешенең төп таянычы икән. Бу фаҗигале көн турында аның онытасы, онытыласы килә... Мәгәр хәтердән качып котылып булмый икән. Нәрсәләр булды әле ул мәхшәр көнне?

Әйе, алар нәкъ алдан билгеләнгән вакытта юлга чыгып киттеләр. «Алга утыр» тәкъдимен Хәлил теләп кабул итте. Бар иде аның шундый йомшак ягы. Ярата иде, машина йөртүче янына утырып, тәрәзәне ачып, терсәкне чыгарып йөрергә. Таныш-белешләр күренгәләсә, хатын-кыз чуалып мыж килсә шул тирәдә, бигрәк тә канәгать кала торган иде.

Көне дә юлда йөрү өчен махсус сайланган диярсең. Җәй бик коры килеп, эсселек туйдырган иде. Ә бүген, сайрар кошлар тынып, үләннәр саргая, яфраклар җир-анабыз тартуына бирешә башласа да, җиләс җылы җил исеп тора, яктылык алласы — кояш көз бабай басымына бирешмәскә тырышып, җиһанга нурларын шактый мул сибә. Йомшак, назлы музыка кәефне күтәрә. Гаярь ирләрне сәфәргә алып чыккан хәл итәсе шөгыльләре дә ташка үлчим: «булса ярый, булса ярый» гына. Буш кул белән, мунчада чабынып кына кайтсалар да, хәсрәт дәрьясына чумасы түгел.

Вакыт һәм эш узганнан соң барчабыз да акыллы, барыбыз да «пәйгамбәр». Сәет һаман үзенекен тәкърарлый «Күңелем яманны сизенгән иде, изге кеше булмасам да, барасым килеп юлга чыкмадым».

Күңелсезлекләр Татарстан җирен узып, күршеләр юлына төшүгә башланды. Әүвәл «Волга»ның бер көпчәге «тын җибәрде». Инде аны алыштырып, Анатолий Павлович тиешле тизлекне алырга да өлгермәде, каршыларына, яшәп килгән барча кагыйдәләрне бозып, юлның кыл уртасыннан баручы, КамАЗга охшаган, олы, биек машина килеп чыкты. Читлектән качкан ерткыч кебек ыжгырып, улап, әллә нинди сәер тавышлар чыгарып, ифрат зур тизлектә бара. Бу очрашу шул чаклы көтелмәгән хәл булды ки, барысы да, бәла-каза сизенгәндәй, сагаеп, тартылып куйдылар, гәүдәләрен көтелмәгән хәлгә әзерләгәндәй иттеләр. Кемдер утыргычка ябышты, Хәлил кулларын бардачокка терәде. Табигый саклану сиземләве хәрәкәткә килде. Теге машина, иң гади мантыйк кагыйдәләре буенча, уң якка алып, үз агымына төшәргә, һич югында тизлекне кискен киметергә тиеш иде. Аждаһа каршыга яман үкереп килүен дәвам итте. Ул гына да түгел, «Волга» ягына, каршыга ук чыга башлады.

— Шайтан алгыры! Әллә исерек инде? — диде Анатолий Павлович, рульне, кискен рәвештә, Хәлил ягына борырга мәҗбүр булып. Машинаның уң як көпчәкләре асфальттан төште, сул якныкылар да таза юлга аз-маз гына эләгеп калды. Бару тизлеген җәһәт кенә киметеп булмый, дөресе, ярамый, йомшак кара җир аны үзенә суырып алачак. Юл кимендә биш-алты метрга күтәрелгән, аста иңкүлек җәйрәп ята.

Олы машина Сәетләргә якынлашкан саен, сугыш очкычларының бомба ташлагандагы тавышын хәтерләткән, иләмсез гүләү көчәя барды.

Мотор үкерүе генә түгел иде бу. Тимерне тимергә бәреп, чаң сугалар, диярсең. Тәҗрибәле күзле Сакманов, каршыга ыргылган машинаның алар ягындагы кузовының ачыклыгын һәм аннан, шабыр-шабыр килеп, төрле авазлар чыгарып, нәрсәләрнеңдер асфальтка, җиргә тәгәрәп-тәгәрәп төшүләрен шәйләп алды. Тимер мичкәләр иде бугай алар. Барыр юллары шулар белән тулды. Ике олы гаскәр орышуына тиң шау-шу тудырган мичкәләр буш иде. Мендәрдән ычкынган каз мамыклары кебек, алар һавада очып йөриләр, төрле якларга тәгәриләр, үзара бәрелешәләр...

Шул арада, җир тетрәгәндәй куркыныч тудырып, түгәрәк калайларын сибә-сибә, олы машина, «Волга»га орынып диярлек, кайнар җилен битләренә сылап узып китте. Ул, күрәсең, Сәетләр автомобиленә бәрелеп, аска төртеп төшерергә тиеш булгандыр. Анатолий Павлович читкәрәк «сикереп» өлгерде. Мичкәләрнең берсе машиналарының түбәсенә эләкте. Әлләни зарар китермәде. Аларның төп бурычы — куркыту, тизлекне киметү, юлны бикләү иде, күрәсең. Үзләренә йөкләнгән вазыйфаларын төгәл үтәделәр. Сәер тавышлардан колагы талган, беркадәр югалып калган йөртүче, олы машина белән аралары бер-ике сантиметрга калгач, кискен рәвештә тормозга баса. Барган җайга «Волга» алды белән асфальт юлга борыла, арткы көпчәкләре чак-чак җиргә тиеп тора.

Дию пәриен күзләре белән озаткан арада, кинәт, җир астыннан үсеп чыккандай, каршыларына килеп чыккан БМВ маркалы җиңел арабаны юлчылар игътибарга алмадылар, шәйләми калдылар, усал ниятен башларына да китермәделәр. Хәлбуки, җиңел машинада, тимер мичкәләр ахыргача җиткерә алмаган мәкерне дәвам иттерергә тиешле кешеләр утыра. Алгы тәрәзәне җиңел ватып узган беренче пуля, Хәлилнең муен — кан тамыры аша үтеп, шактый тирән ерганак ясап, арттан чыгып китә. Нигъмәтуллин, бизгәк тоткандагыдай, бөтен гәүдәсе белән калтыранып ала да, үткен чалгы илә киселгән яшел үлән тесле, утыргычка бөгелеп төшә.

— Куала машинаны, безгә аталар! Артка бир, аска төш! — дип кычкыра-кычкыра, ни кылганын, нәрсә әйткәнен аңышып та бетермичә, Сәет Хәлилне урынына күтәреп куярга, утыртырга тырыша. Шул мәлдә уң як чигәсендә юеш җылылык тоя. Гаҗәпләнеп, аптырап, сәерсенеп, күзләрен күтәреп карарга өлгерә. Кукрәгеи пуля актарып чыгарган Анатолий Павлович, сирәк, кылган чәчле башын, иплэп кенә, ашыкмыйча гына руль өстенә куеп ята. Ирекке чыккан машина, азгын тулпардай, бар көченә аска мәтәлә, бушлыкка сикерә, ике тапкыр әйләнеп, янәдән дүрт көпчәгенә баса; тимер елый, ыңгыраша, сыктый, бар дөньясын кара упкын үзенә ала... Җиһанга караңгылык пәрдәсе төшә.

Аннан соң булган вакыйгаларны Сәеткә түкми-чәчми берничә кеше бәян итте. Һәркайсы үз каланчасыннан, акыл казаны мөмкинлегеннән килеп, әлбәттә.

Кораллы нүкәрләр утырган тугызлы «Җигули», барган көйгә, пычрак суда адашып нәрәтәгә капкан балык кебек, буш калай мичкәләр ташкынына эләгә. Машинага зыян килмәсә дә, ул тизлеген югалта. Шул кечтеки генә тоткарлану, хәстәрен күреп, әзерләнеп көтеп торган Вильсур сунарчыларына «Волга»га һөҗүм итәрлек вакыт, төгәллек җиһазлары, якынайту әсбаплары куелган мылтыклардан төзәп атарга һәм Калашников автоматыннан бер обойма чыгарырга мөмкинлек бирә. Явызлык кылу өчен күз ачып йомарлык вакыт та җитә.

Кинәт пәйда булу, мәргәнлек белән уңышка ирешкән дошманнар үзләре дә төзәтеп булмаслык хата эшләп ташлыйлар. Килгән юнәлештә хәрәкәт итеп, тизлекне тагын да арттыра барып, калай мичкәләр өеме эчендә югалып, беркадәр каушап калган «Җигули» кырыннан, бәлки, выжт итеп, исән-имин узып та киткән булырлар иде. Көтмәгәндә, уйламаганда, БМВ килгән юлыннан кирегә борыла башлый. Чит илдә эшләнгән таза тимерле машинаны, калай мичкәләр вата-җимерә алмаса да, янга, артка чигенүчегә комачау ясарлык кына «явызлык» бар иде ул шалтыравыкларда. Бу — Сәет Сакманов егетләре өчен якутларга торырлык кыйммәтле вакыт була. «Тугызлы»ның ачык ян тәрәзәләреннән ике кара көпшә сузыла. Шоферның иңбашына яткан утны «төкерә» үк башлый. Аңа эре калибрлы автомат тавышы кушыла. Озата килгән машинаны «Игелек» дошманнары исәпкә

алмаганнар иде, күрәсең. Каушап калалар. Арткы утыргычтагы озын буйлысы, үтә кызыксыну күрсәтеп, гәүдәсе белән борыла. Җиһанга соңгы кат күз ташлавы була бахырның. Хәлил Нигъмәтуллин төсле үк, аска сыгылып төшә... Тизлекне алган «Җигули», кирегә борылу маневры белән кыйммәтле секундларын югалткан БМВга бик тиз якынлашты. Салонда утыручыларның, йөртүчедән башкалары, аска ятты, рульдәге егетне буеның, бәдәненең кыскалыгы коткара. Ташбака кебек утыргычка сеңгән, машинаны идарә итү белән бәйле рәвештә генә, берәр хәрәкәт ясап, мультфильмнардагы рәсемнәр алышынгандай, күренеп ала да, янә югала. Җитмәсә, артка махсус кара пыяла куелган. Шоферны ян тәрәзәдән генә «алып» була. Сакмановның иң кыйммәтле, оста сунарчысы, элеккеге биотлонист (кушаматы да шул ук) аны мүшкәгә алды. Берничә пуля бушка киткәч, машинаны БМВ белән тигезләргә кушты. Биотлонист, дошман машинасындагы башның чираттагы селкенүе вакытында, кара ноктаны приборга эләктерде, тыныч кына төймәгә басты. Туры барган машина, давылга юлыккан көймәдәй, як-якка чайкала башлады. Әмма аңа юлдан читкә төшәргә бирмәделәр; асфальт катламының әле сул, әле уң ягына чыга-чыга, БМВ юлын дәвам иттерде. Рульне алда яткан икенче берәү алды.

«Җигули» өчен җаваплы Биотлонист машинаны туктатырга әмер бирде. Аста, уйсулыкта, аягында басып торган «Волга»ны күргәч, «алар тәртиптә», дип фараз кылып, фәрманын кискен үзгәртте.

— Куа киттек! Тиз бул!

Шул мәлдә берничә йөз метрга алгарак китәргә өлгергән БМВ, эзәрлекләүчеләрен көтәргә уйлагандай, шып итеп туктап калды. Бер адәми зат машинадан йөгереп чыкты алгы, арткы ишекләрне ачып, мәетләрне җиргә сөйрәп төшерде дә, йөгереп барып рульгә утырып, газ бирде.

«Җигули» җансыз гәүдәләр янына барып туктады. Иске танышлары Гөмбә белән заманында Шөрепне йөрткән, Мансурны «хәл кылган» өчен өстәмә түләү таләп итеп Сакманов кырына дәгъва белән килгән Ренатны таныдылар. Биотлонист, җылыларын югалтып өлгермәгән гәүдәләргә, тәртип өчен, янә берәр кургаш сеңдерде.

— Нишләп пуляңны калдырасың? Эзеңә төшсәләр?

— Аларда болай да минекеләр,— дип, мәсьәләне япты да, колга гәүдәсен алгы утыргычка ташлады.

— Тиз генә, мылтыкларны сүтеп, чүпрәкләргә төреп, урыннарына яшерегез...

Акрын гына «Волга» янына төштеләр. Моторы эшләп тора. Тирәякта тынлык. Биотлонист, алгы тәрәзәдән кулын тыгып, машинаны сүндерде. Ишекләрне ачып, гамәлдәшләрен янәшә, чирәмгә җәеп салдылар. Капшый, тикшерә башладылар.

Анатолий Павловичта тормыш билгеләре сизелмәде. Егетләрен шатландырып, Сәет авыр итеп ыңгырашып куйды. Хәлилне сынудан, имгәнүдән саклау каешы коткарып калган булса кирәк. Алгы ишекнең утыртма тимеренә чигәсен бәреп, аңын җуйган. Муенындагы ярадан каны шактый аккан булса да, соңыннан сул як күзендә зарары калса да, сәяхәтне оештыручы Нигъмәтуллин иптәш Чувашстан җирендәге орыштан иң җиңел котылучысы булып чыкты. Мәгәр ул үзе, башкарак фикердә калып, хәлен бик хөртигә санады: «Мине үтерделәр бугай. Әйе, мин инде теге дөнья кешесе. Тиздән салкын, кара җир астына, тар ләхет ясап, тыгып куярлар. Сакманов, гәүдәмне күмгәннән соң, купшы речь тотар. Фәлән, фәлән кеше иде, авыр туфрагы җиңел булсын, дияр. Кадеремне белерләр шуннан соң. Юк, юк, аның үләсе килми. Кызы ятим кала». Кычкырырга, ярдәмгә чакырырга тырышып карады, тавышы чыкмады. Кулларын, аякларын тоймады, әйтерсең лә, машинада калганнар. Керфекләрен күтәреп карады. Бер күзе исән, хәтта ачыла икән ләбаса. Як-ягына каранды да, керфекләрен аска төшерде: «үлгән дип, шатлансыннар». Аяныч хәлендә дә, Хәлил хәйлә вә мәкерсез булдыра алмады. Сул күзе ачылмаудан, тән әгъзаларын хәрәкәткә китерә алмаудан, «үлмәсәм дә, гомерлеккә гарип-гораба калдым», дигән гоманыннан янәдән һушын җуйды... Хастаханәдән Хәлил ике атнадан терелеп чыкты. Муены бәйләнгән килеш Фирая Симатовага күренергә ашыкмады. Бер айдан артык

больничныйда йөрде, аннан ял йортына юл алды. Сакмановның хәлләре авыррак иде. Башындагы ярасын сөрткәләп, әвеш-тәвеш китереп, марля белән бәйләп куйганнан соң, Сәет кыска гына вакытка аңына килде.

— Хәлил ничек? Анатолий исәнме?

Сорау һавада асылынып калды. Икесе дә «оҗмах кошлары», дип әйтергә берәүнең дә теле әйләнмәде. Исән-имин калган егетләрне башка нәрсәләр ныграк борчый: аларга үзләрен ничек тотарга, эзәрлекләүне дәвам итәргәме, яралы паханны, җиһанны ташлап киткән аркадашларын кая озатырга, кемгә хәбәр бирергә?

Биотлонист үзен борчыган мәсьәләгә ачыклык кертергә ашыкты:

— Тегеләрнең икесен сыладык. Минем эш — Гөмбә белән Коротышка. Аларны яткан урыннарында калдырыргамы?

Үле дошманнар өчен баш катырырлык хәле юк иде Сәетнең. Тизрәк орыш урынын ташлап китәргә, эзне югалтырга!

— «Волга» кабынамы? Кабынмаса, буксирга алыгыз, машинадан конторага, Ваһаповка, полковник Гаяровка шалтыратыгыз. Замир үз машинасы белән каршы алырга чыксын. Тиз кузгалыгыз... Казанга...

Вакыйгаларның алтабан агышын ул хәтерләми. Егетләре машиналардагы чыбыксыз телефоннан тиешле кешеләрне эзләп таптылар. Сәет белән Хәлилне (соңгысының исәнлеген орынтын гына күз уйнатып алуыннан чамаладылар) Казанга кертмичә, кала читендәге хастаханәгә салып, атаклы табибларны алып килеп, башындагы ярчекне алдырдылар. Машина әйләнгәндә кабыргалары, кулбашы имгәнгән, бер аягы каймыккан булып чыкты «Игелек» хуҗасының. Хәлилне дә янәшә палатага салып, муенындагы ярасын тектеләр. Сакмановка озын-озак дәваланырга, «капиталь ремонт» узарга туры киләчәк...

Мәгъсүм улы Вильсурның үҗәтлеге үзенең ике турылыклы егетен корбан итүгә, гөнаһсыз Анатолий Павловичның житкән кызларын, карчыгын ятим калдыруга китерсә дә, аңа җан вә кан дошманының үле гәүдәсе өстендә кайнар нотык тотып, каберенә бер уч туфрак ташларга насыйп булмады. Ярал арсланны — Сакмановны Казан, Чаллы, Йошкар-Ола, Чабаксар хастаханәләреннән дә эзләтеп таба алмады. Каһәрне җир йотты диярсең.

Элеккеге танышы, дөресе, үзе эзләп тапкан дошманы — шәфкать туташы Фәридә белән дуслары, ярдәмчеләре фидакарьлеге илә Сәет Сакманов барыбер аякка басты.

Күрше Чувашстан җирендә урын алган канлы җинаятьне полковник Салих Гаяров үзе тикшерде. Районның хөкем оешмаларыннан да ярдәмчеләр алды. Бәйләнерлек җанлы билгеләр, гаепләрлек «дәлилләр» табылмады. Гөмбә белән Коротышканың үле гәүдәләре, чәүкәләр күтәреп киткәндәй, юкка чыкты. Төнлә килеп яуган август яңгыры кан эзләрен җиргә сеңдергән, күрше авыл булдыклылары, тимер мичкәләрне өйләренә ташып, яшереп өлгергәннәр.

«Жигули»да Сәетләрне озата барган егетләр, үзләре шаһит булган хәлләр турында түкми-чәчми сөйләп бирәләр. Тик хикәяләүдән иң заманча мылтыкларда БМВ машинасына ут ачулары, ике яшь кешене үтерүләре, Гөмбә белән Коротышка мәетләрен үз күзләре илә багулары турындагы өлешне генә төшереп калдыруны мәгъкуль күрәләр. Сөйләүләре буенча алар — нахакка бәла-җәфа күргән, куркытылган, өркетелгән, гөнаһсыз нарасыйлар. «Волга» машинасына юлбасарларча һөҗүм иткән, Сакманов белән Нигъмәтуллинны каты яралаган мәлгуньнәрне эзләүне, катгый җәзага тартуны таләп иттеләр.

Вакыйга-хәлләр агышын тәгаен күз алдына китергән Салих Гаяров, Биотлонистның үзен генә калдырып, «аталарча» киңәшен иңдерә:

— Ә син, егетем, суерлар, урман тавыклары яшәешенә күч. Кирәк булсаң, терелеп чыккач, хуҗаң эзләп табар.

«Жирафка» авыр барып җитә. Берни аңламый, ахмак сораулар яудыра.

— Горизонттан югалып тор. Җир тишегенә кер, яфраклар астына сыен, — дип, полковник иренмичә аңлатып, тәфсилләп бирә.

«Игелек» ширкәте шактый вакытка хуҗасыз кала. Югалган пычакның сабы да алтын тоела дип, Хәлил үз җаен карый. Фердинанд вазифаларын

өстенә алып, кул астына керә башлаган Мисхәт Маликов Ырымбур төрмәсе тоткынына әйләнеп, коткаручысын көтеп ята. Григорий үз вазифаларын илләм тырышып башкарса да, аң-белем ягы сыеграк булу сәбәпле, буразнаны тирәннән сөрә алмый.

Ике карга сугышканда, саесканга ит була дигәндәй, иясез һәм «түбә»сез калган «Игелек»нең майлы калҗасыннан авыз итеп калырга ашыккан шома вә елгыр оятсызлар артканнан-арта бара. Берсе — ниндидер бурычын түләүне таләп итә, икенчесе — кәгазьләргә имза салуны сорый, бәгъзесе — Сакманов биргән вәгъдәләрне катгый үтәүне дәгъвалый. Ширкәтне талаудан баш хисапчының акыл белән эш итүе, тәвәккәллеге коткарып кала. «Кайчы белән кәгазь бәхәсләшми», — дип, «күбәләк»ләрнең, «ак болыт»ларның таләп кәгазьләрен күз явын алырлык чибәр дә, ушны алырлык ямьсез дә булмаган бухгалтер папкага тегеп кую белән чикләнә, бер ишесенә «директорның үзенә килерсез» дип, ширкәтнең барча алыш-биреш, түләү операцияләрен тулысынча диярлек туктата, хәтта хезмәт хакын түләүне дә (үзеннән башкаларга), «хәзер бирәү дә зарплатаны вакытында алмый», — дип кичектерә килә.

Янаучыларга, бөердән сөйләшүчеләргә дә җавабын бирә белгән:

— Чокырны икене казы, үзеңә дигәнен тирәнрәк яса.

Аның арка терәге, яклаучысы табылды. Ул — Сакмановның элеккеге йөртүчесе, хәзерге тәэминат бүлеге начальнигы Замир иде. Кыскасы, Фирая Симатова фирманың мөлкәтен саклауга зур көч куйды, акчасын бәгыреннән өзеп кенә чыгарды. Вазифаларын үти башлаган Сакманов баш хисапчының төгәл, аек акылына, кыюлыгына шаклар катты...

## 17

Больницаның алан хәтле палатасыннан Сакманов Әхмәдиша картларга, «төп йортларына» төшәргә булды. Озаклап уйлана, һәръяклап тикшерә торгач, эшкә кереп китү, дәвалану өчен дә, шулай җайлырак булыр, дигән катгый карарга килде. Аны алмага килгән дус-ишләре Ваһапов, Башорин, полковник Гаяров, Гриша, Замир, Фирая Симатова — барысы да аның бу адымын хупладылар. «Күпме кеше...» — дип сөенде Сәет, балаларча ихласлык белән. — Үлгән булсам, шатлыксөенечләрен яшерә алмыйча, дошманнарым кереп тулар иде зиратка, ә биредә барысы да аркадашлар, якыннар», — дигән нәтиҗәгә килеп, Гаяровның милиция машинасына кереп утырды.

Соңгы бер-ике ел эчендә шактый бирешкән булса да, яшәешкә аек карашын саклаган Әхмәдиша картның куанычы йөзенә, юан бармакларына, кыска сакалына чыккан. Хуҗаның үзе белән генә хәл кылырдай мәсьәләләре дә баштин ашкан иде. Хәерниса түти, алтын йомырка салган тавык мәсле, көне буенча чирле янында кыткылдап бөтерелде. Пешермәгән, эчермәгән нәрсәсе калмады.

Алдан килешү буенча, яраларын чистартырга, бәйләргә, энәләрен кадарга Фәридә килеп-китеп йөрергә булды. Сәетнең машинасына утырып төшә дә, «Йәле, карап карыйк, безнең баһадирның хәлләре ничегрәк, әйбәт, тиздән космоска очырырга була, мин сезнең уңышлар өчен бик шат», — кебек, бу очракта әйтелә торган гомуми сүзләр белән, вазифасын үти дә, кайтып та китә. Сәеттән акча алудан, үзгә ярдәмнән баш тартты; миңа егетләрең җитәрлек бирделәр, рәхмәт, әлегә миңа берни кирәкми», — ди. Вакыты белән Сакманов соңгы чорда сырхауханәдә яткан көннәрен сагынып куйгалый; Фәридә анда ягымлы, буйсынучан, назлы вә тәрбияле иде.

Бер үк кешегә нисбәтән, авыру чакта бертөрле, терелә башлагач бөтенләй үзгә, башка мөнәсәбәт булырга мөмкин дисәләр, Сәет ышанмас, изүләрен ертып, бәхәсләшер иде. Үз башыңа төшкәч кенә, башмакчы буласың икән. Палатада ярым мәет хәлендә, чалкан ятканда, үз сулышын өреп диярлек, яшәүгә кайтарган Фәридә «тыныч тормышта» үзгәрде дә куйды. Чистый җен алыштырган диярсең үзен.

Шәфкать туташы, аңлашылмый торган, сәер сәбәпләр табып, ераклаша, аралары суына барган саен, Сәет үзенә таныш чир белән авырый башлавын сизде. Үз-үзе белән сөйләшеп алганын, онытылып китүен, таркаулык кебек гадәтләренең көчәюен тойды. Кемнеңдер кулын кысты, сөйләште, киңәшен бирде, мәзәк сөйләсәләр, көлгәндәй итте, акча кәгазьләренә кул куйды, ә күңеле әллә кайларда гизде. Шәраб эчкән исерек кебек йөрде. Яңа халәтенә шатланырга да, кайгырырга да белмәде. Сынау һәм шикләре, шатлыгы һәм каһәре белән күңеленә, жанына, тәненә үтеп кергән хисси ялкын аңа тынгы бирмәде, яра-авыртуларын онытгырды. «Миңа шул гына житмәгән иде, тулы бәхет өчен»,— дип үзен мәсхәрәләп, мыскыл итеп карарга ниятләгән иде дә, юморы артык арзанлы, үзешчән чыкты. Көләсе килмәде. Еларлык яше узган иде.

Зөлфиянең якты рухына турылыклы калырга дип, Әлфиягә биргән антын искә төшереп, үзен битәрләп карады. Мәгәр үзе белән берни кыла алмады. Яшәешнең үз кануннары бар шул. Фани дөньяны ташлап киткән кешене хөрмәт итеп, ясин, корьәннәр укытып, корбаннар чалып, көннәрен уздырып, каберен тәртиптә тотып, өстенә мәрмәр ташлар куеп була, әмма аның белән яшәп булмый. Тәнендә сихәте, жаны булган кешене хисси, женси, рухи табигате үзе артыннан ияртә: язгы ташкын чоңгылларына ташлый, йолдызстанга алып менә һәм вакыты, сәгате житкәч, йомшак төше хәтерләрлек итеп, шып иттереп жиргә утырта.

Сәетнең Фәридәгә мәхәббәте дә борчулы, жәфалаулы, жәберсетүле булырга охшый. Ул — Зөлфия генә түгел, утны-суны кичкән ханым кебек күренә.

Сәет үзен оста аучыдай эзәрлекләгән кичерешләрдән котылырга, арынырга, күңел киштәсеннән куып чыгарырга тырышып карады. Әмма яңа мавыгуы аны бер дәкыйка да тынычта калдырмады, туктаусыз бимазалады, чем-кара күзләрен елтыратып алдына килеп баса торган булды.

Үзе юкта ул Фәриденең житешсез якларын, кимчелекләрен эзләп иза чикте. Таба алмый интекте. Дәртлелек билгесе — кабарынкы ирennәре, күпереп торган янтаулары, куппы, зиннәтле күкрәкләре, һаман да нечкәлеген саклаган биле — һәммәсе үз урынында иде шул шайтан алгырысы.

Хатын-кыз үз килеш-килбәтенең, сынының серләрен яхшы белә. Камыш судан, чибәркәйләр матурлык өстәүдән туймас. Кием-салым, бизәнү әйберләре белән ул гәүдәсенең «яңгырашына» ярдәм итә. Сәетнең йөрәгенә котырынган жил-давылны, ут-ялкынны ныграк дөрләтү өчен юри шулай киенгән диярсең бүген Фәридәне. Аякларының тулылыгын, төзлеген киң коңгырт каеш белән буып куелган кыска кара итәге ассызыклап тора. Ак ефәк кофтасын, күкрәкләренең өмсендергеч муллыгын, кыскарак муены астыннан ук, гажәеп килешле булып, тирәнгә төшеп киткән түш елгачыгын күрсәтү өчен махсус тектергән диярсең. Сәет, аңа сүз әйтергә куркып, сокланып карап торды. Ә ул, берни булмагандай, ак халатын киеп алды, энәләрен өстәлгә чыгарып куйды.

Шәфкать туташының, өйгә килеп-китеп йөргән табибларның ярдәме, хужаларның затлы өй ризыклары Сәетне тиз аякка куйды, ярасы ябылды, жөйләре тигезләнде, чыраена элеккеге төсе кайта башлады. Беренче каттагы спорт мәйданчыгында күнегүләр башлап жибәрде. Бүген ул Фәридә белән аңлашырга, киләчәкләре турында киңәш-табыш итеп алырга ниятләде.

— Мине бөтенләй ташладың, Фәридә. Машина ике көн буш кайтты: ишегең бикле. Ничек аңларга моны?

— Хәлегез яхшы якка үзгәрде. Хәзер яныгызда медсестраның даими булуы мәжбүри түгел.

— Болай ук ташлашмыйк инде. Миңа кыен.

— Форсаттан файдаланып, ике көнгә апам янына, авылга кайтып килдем. Өч ел булганым югие,— дип, ни өчендер тәрәзәгә карап жавап бирде ханым.

— Син кайсы районнан әле? — дип, ялгыш сорау биреп, хатынның күңел ярасына тоз сипкәнен соңыннан гына аңышты Сәет. Кара күзләрдә усал чаткылар биешеп алганны ир күрми калды. «Теге вакытта» Сакманов авыл советыннан, мәктәптән, колхоздан төрле таныкнамәләр,

бәяләмәләр таләп итеп, Мотыйгуллинаның туган төбәгенә әллә ничә рәсми хат юллаган иде. «Онытткан булып кылана. Юк, абзыкай, ул хәлләрнең тамгасы һаман йөрәктә кара каргадай каркылдап утыра»,— дигән уен күңеленнән куарга тырышты ханым, бигүк җиңел булмаса да.

— Кайсы төбәктән икәнлегемне генә түгел, авылымның адресын да беләсез кебек,— дип, йомры кулбашларын сикертеп алу белән чикләнде.

— Машина биргән булыр идем.

— Без халык транспортында йөрергә өйрәнгән инде. Рәхмәт.

— Хуш! Анда нинди яңалыклар күрдең? Авылыгыз урынындамы? Апаң исән-саумы?—ди-ди, чүп өстенә чүмәлә өйгәндәй, бер рәт сорау тезеп китте ир-зат, Фәридәнең күңеленнән узган хисләр өермәсенең юнәлешен чамалап. Ханым йөзендәге, рух көзгесе — күзендәге үзгәрешләрне күрсәтмәскә тырышып, бу юлы бөтен гәүдәсе белән тәрәзә ягына борылды. Җилкә аша гына җавап бирде.

— Татар авылы бик нык үзгәргән шул.

— Яхшы яккамы?

«Зәңгәр томан» чорын узган, тормышны ничек булса шулай кабул итәргә өйрәнгән Фәридә үзен бик тиз кулга алды, тойгыларын урынына утыртты.

— Тышкы яктан авыл ныклап аякка баскан, яңарган. Кирпечтән салынган менә дигән йортлар, коттеджлар үсеп чыккан. Машина белән җилдереп узып китсәң, күңелең нурланып калырга мөмкин. Тукталыш ясап, өйләрнең эченә кереп, кешеләре белән аралашсаң, яхшы кәефеңнең эзе дә калмаячак.

— Өйләрендә су, газ юкмы? Пычрак яшиләрме? Клублары эшләмиме?

— Алары бар,— диде ханым, Сәетнең куалавын хупламыйча. Кыяфәтенә караганда, Фәридә җаны белән хәзер дә әле туып-үскән авылында иде.

— Әдәп, әхлак, итәгать кебек нәрсәләр беткән. Янгын ялап алган диярсең. Сүгенү, мат, перемат белән сөйләшү, исерек ир-атның, яшьләрнең урам уртасында, картлар, карчыклар янында акырып, бакырып аңлашуы гадәти хәл булып киткән. Болай явызлану без үскәндә юк иде. Өлкәннәрне олылау, санга санау беткән. Татар теле бозылган, тупасланган, чуарланган, вакыты белән бөтенләй ят сөйләш төсле тоела. Яшьләр урамда көпә-көндез кочаклашып йөрергә дә күп алмыйлар.

«Шулай шул, чибәрем, элек, без яшь чакта, авыл кызлары, шәһәргә килеп, исәп белән, карт түрәләр бүксәсе астына кереп ятмый торганнарие»,— дип, үҗәтләнеп, усалланды Сәет.

Фәридә исә, саф күңел белән авыл язмышы, аның киләчәге турында сөйләвен дәвам итте. Ихластан ачынудан, дулкынланудан кызарынган шәфкать туташы бу мизгелдә гаять тә чибәр иде. Сәет аңа сокланып, яратып карап торды. Ит куна башлаган битенә алсулык типте. Ул, тиз генә барып ишекне япты, Фәридә янына килде, бер тезен идәнгә чүгеп, яралы башын ханымның ак халат чите яшергән аякларына куйды.

— Без бу тормышны үзгәртә алабызмы? Юктыр. Һәр күргән-белгән әшәкелек өчен картаерга кирәкме икән? Үзебезнең киләчәк турында уйлашып алыйкмы әллә, болытлар арасында йөзгәнче.

Бу сөйләшү-аңлашуны Фәридә дә көткән иде күрәсең, кулын иплән кенә Сәетнең җилкәсенә урнаштырып, турыдан-туры ярып салды.

— Сәет Яруллович, сез минем өчен бик якын кеше булып барасыз!

— Нинди мәгънәдә?

— Мәгънәсен әйтә алмыйм. Ну... факт. Сез миңа кирәк.

— Ни өчен?—дип төпченде, Сәет.

— Мин үзем генә җиңә алмыйм.

— Үткәнеңнеме? Элеккеге дошманнарыңнымы?

Авызыннан чак кына, «җинаятеңнеме», дигән әшәке сүз төшмәде. Акылы теленә йозак салырга өлгерде. Төзәтеп булмаслык бәла килеп чыгасы иде. Үткәннәре өчен дә гарьләнеп бетә алмый.

— Сәет, хатын-кыз белән... Үзегезне, үзеңне... Шулай якын иткән кеше белән алай ук явыз кыланмас идең.— Үзе дә сизмәстән Фәридә «син»гә күчте.

— Мин тылсымлы таяк булырга тиешме? Булдыра алырмынмы соң? — диде Сакманов, бу юлы чын күңелдән.

— Һәркемнең үз кайгысы, үз хәсрәте бар. Үткәне үзенеке генә. Киләчәге кемсә беләндер уртак булуы хәерле. Ә тормыш дәвам итә, ике килми,— дип, Фәридә инде аягына баскан Сәет ягына өлгергән эре карлыганнарыннан раушан нурлар сирпеде.— Үлгәннәр артыннан үлеп булмый,— дип өстәде, сүзләренә һәркем үзенчә аңларлык мәгънә салып. Бераз уйланып торды. Хәрәкәтчән, җегәрле, тормышчан ханым өчен артык басынкы, сөремле, бастырыклы тавыш белән өстәп куйды: «Икебезне дә язмыш җитәрлек сынады».

Сәет хатынны мондый яссы чагыштыруы, икесен янәшә куюы өчен әрләргә, битәрләргә тиеш булгандыр, бәлки. Теле әйләнмәде. Кешене үткәндәге хатасы өчен күпме рәнҗетеп, ярасына ачы агызып була. Адәм баласының гомере болай да бер мизгел. Ә Фәридәнең кешелек ихтыяры, рухи җегәре ифрат көчле икән. Бик күбебезгә җитешми шул әйберләр.

— Сәет абый, син үз бәяңне белмисең!

— Кешенең кыйммәтен бездә, Фәридә, үлгәч кенә... бәялиләр. Шәхес үзенең дәрәҗәсен, кимәлен, күпме, ни хак торганын үзе белергә тиеш. Чит инсан да аңа бәһане шуннан чыгып бирер,— дип, «Игелек» хуҗасы ханымның башын катырды.

Мәгәр иптәш Мотыйгуллина югары дәрәҗәле сүз алып барырга да әзерлекле булып чыкты.

— Бәяләр базарда гына түгел, әдәп-әхлак тирәсендә дә үзгәрә тора шул.

«Синең кебек, тормышын рәтләү, фатирлы булу өчен, тәнен саткан, баласын үтергән фәхешләрне күздә тотасыңмы?» — дип уйлап алды Сәет, янә әшәкеләнеп. Теле башка сөальне әйләндереп чыгарды.

— Нәрсә димәкче буласың?

— Арт ягыңа энә кадарга вакыт җитте димәкче булам.

Ул көнне «Игелек» сәрвәре Фәридә белән сырхауханә мохитында туган рухи якынлыкларының шактый өлешен кире кайтара алды. Ханымга да ул ошый. Көтмәгәндә ачылып, актарылып китә, күңелен биләгән хисләре, суы тулы чиләк чайкалган мәсле, тышка бәреп чыга. Әмма аны барыбер ниндидер эчке богау тота, чабуыннан тартып тора, кыскасы, тулы бәхетләренә нәрсәдер комачаулый. Дөрес, бүген Сәет Фәридәне, бөтен тәне белән бизгәк тоткандагы төсле калтыранганчы, битеннән, күзләреннән, иреннәреннән үпте. Кунарга калмады. Сәбәбен бик җиңел аңлатты.

— Сиңа хатын-кыз белән йокларга иртә әле. Өзлегүең бар. Гомер озын... Тәкъдирдә язган булса, җитешербез. Бездән калмас.

«Игелек» ширкәте башлыгы, тешен кысып булса да, ханым белән килешергә мәҗбүр булды.

Артык хискә бирелүчән, шашып, дөньясын онытып гашыйк кеше дә, мәхәббәт көймәсендә генә чайкала алмый. Андый тормыш әкият-дастаннарда, риваятьләрдә һәм чит ил фильмнарында гына була ала. Мәхәббәте, тирән яра төсле, үзе турында гел искә төшереп, җанын парә-парә телгәләп торса да, фирма белән шөгыльләнәсе, элек бирелгән вәгъдәләрен үтисе, дошманнары белән көрәшәсе бар иде. Берсе генә дә чал чәчле Сәет Сакмановның йөрәген яңа мавыгуы кисәкләргә телгәли дип, көтеп торырга теләми.

Шул ук кичне, Хәерниса апага чәйләр, мәйләр әзерләргә вакыт калдырып, алдан сөйләшелү буенча, Салих Гаяров килеп керде. Полковник дәрәҗәсе, бүлек мөдире кәнәфие килешкән үзенә. Күзләрендә канәгатьлек балкышы. Тазарып, тулыланып киткән; эреләнүен элек тә килештерә иде. Тәмам хәтәрләнеп җиткән.

— Эш күп, Сәет Яруллович, арка кашырга да вакыт калмый,— дип, килештереп зарланып алды.

— Анысына түзеп булыр. Минем шикелле, бер уйламаганнан өчәр ай караватта аунарга туры килмәсен.

— За все надо платить.

— Аллам диген! Кайгы-хәсрәт, төрмә, бурыч кеше башыннан йөри.

Салихның аз гына да тәүбә кылырга, дилбегәне кулдан ычкындырырга исәбе юк. Үзенең өстенлеген һәрдаим сиздереп, кешене киеренкекуркулы халәттә тотарга ярата.

— Сез аны үзегез эзләп йөрисез. Синең катнаш белән оештырылган өч «юеш» эш өстәлемдә кычкырып «елап» ята.
— Аңламадым?
— Хәзер аңлатып бирәм. Урмандагы өйне кешеләре белән яндыру — бер. Ресторанда Ленар Динмухаметовны атып үтерү — ике. Һәм Чабаксар юлындагы фаҗига...
Сакмановның түземлек канатлары сынды. Ул ярдәмчесе Фердинандны, хатыны Зөлфияне, шоферы Анатолий Павловичларны нахакка үтерүләрен искә төшереп, милицияне эшсезлектә гаепләүгә барып җитте.
— Нервыларың бушаган, абзыкай, сиңа ял кирәк,— диде Салих тыныч кына. Сәетнең вәсвәсәле, борчулы, дәгъвалы, пошынулы чыгышына исе китмичә.
— Нервылар тәртиптә,— диде Сәет, тынычлана төшеп.— Ярый, гафу ит, артык кызмам. Йошкар-Ола белән аралашулар ничек булып бетте? Синең зам шул көнне ресторанда утырган хатыннарны эзләп табып, тикшерүне бик нык куерткан, дип ишеткән идем?
— Хәлләр булды анда. Хәзер искә төшерәсе дә килми. Хәтерлисеңме, мин анда бер ханымны танцыга чакырып, муеныннан әп иткән идем.
— Ничек хәтерләмим, ди. Андагы әрсезлегең, нәфесең котыруы тарихка кереп кала язды.
Сәетнең төрттерүен һич кенә дә җитдигә алмыйча, Салих, үзе өчен күңелле бер хәятны исенә төшереп, тупас иреннәренә елмаю чыгарып, башлаган кәлимәсен дәвам итте.
— Ул ханымны эзләп киттем, малай, мин сиңа әйтим. Әкияттәге каһарман кебек. Таптым.
— Танысымы соң?
— Тану гына түгел, муенга асылынды. Бер күрүдә шулай, унҗиде яшьлек кызлар кебек, гашыйк булганым юк иде әле, ди апаң.
Сәет тынычланды. Гаяров, эшләр җайда барганда гына, Шаяров тиресенә керә.
— Димәк, ул спектакльдә безгә начар роль бирмәсләр.
— Пьесаның авторы мин булам түгелме соң,— дип, Салих җаваплылыкны үз өстенә алды.— Тынычланырга иртәрәк әле. Мин инде Чабаксар хәлләрен күздә тотам. Министр үзе кызыксынды. «Мафиянең кыланышлары туйдырды инде. Берсен-берсе атып бетермәсәләр, аларны үзебезгә җыеп алырга туры килер, «глухарь» эшләр күбәйде», ди.
Гаяров Әмәт калавылында, дүрт кешедән торган гаиләне алдан суеп чыгып, аннан соң ут төртеп яндыруларын, йөрәкне боздай катыра, җанны өшетә торган ваклыклары белән сөйләп китте.
— Халык азынды. Кеше гомере — су бәясенә дә тормый,— дип, өстәргә кирәк тапты Сакманов.
— Шулай булуына рәхмәт әйт, әфәндем.
— Ник алай дисең?
— Чөнки бер җинаять өстенә икенчесе өстәлә тормаса, син, Ваһапов, Садыйков кылган явызлыклар белән ныграк шөгыльләнергә туры килер иде.
— Салих, шаяртма. С такими вещами не шутят, диләр урыслар.
Ул Гаяровның хаклы икәнлеген таный. Әмма хәлләр алай ук хөртидән түгел икән. Сакманов, яралары төзәлеп, үзен аңлый, таный башлагач, БМВ машинасындагы мәетләр өчен җавап бирергә туры килмәгәе дип, бераз шөлләгән иде. Куркыныч нәрсә күренми кебек. Менә-менә кылны өзеп төшәм дип, баш очында Дамокл кылычы эленеп торса, полковник аны эзләп килмәс иде. Яңа урындыкта үзен тапты бугай. Абыйлары, фирка заманындагы мәсле, арба биреп ат ала алмасалар да, төшеп калган кешеләр түгел. Яңартып кору, демократия кебек хикмәтле зәхмәтләргә бик тә тиз җайлашып, хакимият бәлешеннән барыбер артык читкә тибәрелмәделәр.
Гаяровның өстәл артында сайрап утырып, бер шешә коньяк эчү йәисә Сакмановны сагынган өчен генә килмәгәнлеген аңлый хуҗа. Үзе сорарга ашыкмый. Кыйммәткәрәк төшәчәк.
— Минем олы малай юрфакта, өченче курста укый бит инде. Без картаймый, кем картайсын,— дип, көрсенде өлкән әфисәр.

— Кара син аны гомернең агышын. Аккан судан да уздыра. Әле генә Айрат өчен борчылып йөргән идек,— дигән булды Сакманов.

— Малай машина сорый.

— Аңлашыла. Ул бит полковник улы. Дөрес эшли.

Гаяров алдан уйланылган, күнелендә күптәннән расланган «тәртип» буенча, күтәрелеп бәрелергә тиеш иде. Шулай итте дә.

— Син аның оятсызлыгына игътибар ит әле. «Чит илдә эшләнгәнне алыйк инде, әти. Көн саен машина алыштырып торып булмас»,— дигән була.

Аркасы буйлап әшәке дулкын узып, үзен ялгыш нәжескә баскан кешедәй хис итсә дә, Сәет сер бирергә тиеш түгел иде. Котә белә.

— «Джип кирәк», ди, сукбай.

— Иң ышанычлы машиналарның берсе инде,— диде «Игелек» хуҗасы, булган бар ваемсызлыгын кырып-себереп, тавышына җыеп.

— Хикмәт шунда, аны баксаларга гына саталар. Бер фирма егерме өч мең сорый. Яртысын таптым... Калганын, Сәет Яруллович, синнән бурычка алып тормакчы идем.

«Бурыч» сүзенең чылбырга ялгыш эләккәнлеген, үз мәгънәсен белдермәвен, акчаларның мәңгегә кире кайтмасларын Сакманов яхшы белә. «Түбә» өчен һәркем түли. Санны азмы-күпме киметү турында гына хыялланырга мөмкин. Мечтать не вредно, диләр урыслар.

— Хәлләрем шәптән түгел. Үзем чирләп ятканда, запас акчаларны әрәм-шәрәм итеп бетергәннәр. Бальнисны ремонтлый башладым. Бер гыйбадәтханәгә ярдәм итәргә обещайть иткән идем. Налог инспекциясе кыса.

— Яңа байларның зарланырга яратуларын, саранлыкларын беләм. Моң-зар тыңлар өчен килмәдем. Сүз әҗәткә биреп тору хакында гына бара.

— Биш-алты баксадан арттыра алмам!

Полковник дәрәҗәсен урамда каты боз тибеп йөргән өчен бирмиләр. Гаяров, Сәетнең соңгы җөмләсен тыңламыйча диярлек, җитез хәрәкәтләр белән кечкенә күн сумкасыннан диктофон чыгарды.

— Онытып торам. Хатыннар кебек тел чайкарга килмәдем. Ресторан официанткасының, анда күңел ачып утырган хатыннарның допроста биргән җавапларын тыңлау сиңа файдалы булыр дип уйлыйм... Вакытым аз. Монда мин дә бар, син дә в наличии.

Төймәгә басты. Чыннан да, аш-су биреп торучы ханым белән туган көнен уздырган хатын «Умырзая»да кәеф-сафа корып утырган өч ир-ат, атыш турында шактый кызыклы мәгълүматлар биргәннәр. Шерлок Холмсларга абзыйларны санап чыгару, эзләп табу әллә ни кыен булмас иде.

Гаяров пленканы ахыргача тыңлатып бетертүне кирәк тапмады. Төймәгә басты. Иң мөһим өлеше тыңланмады дигән куркыныч, кара төндә кара урманда бер ялгызың калгандай, шомлы хис туарга тиеш иде. Җитмәсә полковник, өстәл яныннан торып китеп, яны белән тәрәзә буена басты (яраткан позасы), чыраена борчулы-кайгыртулы, хәтта хәсрәтле төсмер чыгарды.

— Миндәгесе өчен курыкма! Еракка җибәрмәм. Тик минем зам Алексей Трофимов язманы үзендә дә калдырган булуы ихтимал. Ул напрямую министрга, аның бәрәр замына керсә? Яисә материалны синең якын «дустың» — Җәүдәт Габдулловичка бирсә... Пенсионерның вакыты күп. Безнең оешма шундый бит: җепнең бер очын эләктерсәләр, шуны тарталар да тарталар. Бер җинаять икенчесен өстерәп чыгара.

Сакманов артык сузарга, җенне котыртырга ярамаганны аңлады.

— Унны табарга тырышырмын.

Салих шып туктады. Өстәл янына кунып, кулына чәркәсен алды.

— Ярый, мин ашыгам. Иртәгә, обедка килеп китәрмен. Әзер булсын. Синең егет кеше булуыңда шигем юк иде. Башына ярчек эләккәч, миңа зарар китермәгәнме икән дигән шигем генә бар иде. Ярый, мин йөгердем. Сал тагын берне. Ладый...

Кулга шап-шоп... Язмыштан узмыш юк.

Шактый иркә үскән, яшьли акчалы тормышка өйрәнгән Мисхәт-Мишаның чит-ят шәһәр төрмәсендә алты айга якын кандала симертәселәре ике ятып бер төшенә керә алмаслык хәл иде. Зарыгып, көтеп алган кунактай озак тоталар бичараны. «Кунаклыгы» шул: уналты кеше йоклар өчен җайланган изоляторда ул алтмыш өченче тоткын. Дала каласында, әби патша заманында, башкисәр төркиләрнең кайнар канын суыту, казакъ, татар, башкорт, нугай, мишәрләрне бер-берсеннән аерып кую өчен салынган зинданда табигать баласы-Мисхәтне шулай озак әсирлектә асрауның әсас сәбәпләрен аңлавы да, аңлатуы да кыен. Күрәләтә нахак бәла ягуның бер үрнәге. Язмышка сыларга гына кала. Нәтиҗәсе мәгълүм: бәхеткә тарган ирне Әлфиянең кайнап торган балавыздай кочагыннан тартып алып, рәтле-башлы тикшерүсез, судсыз-чуртсыз ничәмә кояшлы көннәр, айсыз төннәр төрмәдә интектерәләр. Хуҗасы терелеп чыкканны көтәргә мәҗбүр була гаярь егет. Үз аягы белән йөрерлек хәлгә җитеп, ширкәтнең салым-чыгым, табыш-югалтыш, отыш-оттырыш кәгазьләрен өйрәнеп, тиешле карарлар кабул иткәннән соң, Сакмановның беренче гамәли эше Мисхәт Маликовны төрмәдән йолу булды.

Бу авыр, билгесезлеге белән катлаулы шөгыльгә алынмыйча булдыра алмады Сәет. Дуслар адәм башына авырлык килгәндә, кайгы-хәсрәт ишелеп төшкәндә сынала. Аяк астында гөнаһсыз тәүфыйклы песидәй бутала, кирәк вакытта җилкәсен куя белгән якты йөзле Маликовны Сәет энесе кебек якын итте. Соңгы чорда, Әлфия белән танышканнан соң, егет җитдиләнеп китте, акыл ягыннан дисеңме, тормышны алып бару тарафыннан аласыңмы, һәрьяктан үсте. Буш вакыты булдымы, спортзалга төшә; үзен кызганмыйча, иренмичә шөгыльләнә; Мисхәт күзгә күренеп шәбәйде, мускуллары күлмәк җиңенә сыймый башлады. Кыскасы, Маликов ширкәттә киң колач белән эшли башлаган ышанычлы хезмәткәрләрнең берсе булып киткән иде.

Мәгәр, яшәешкә барыбер җиңелчәрәк карашы, билен бөгәргә яратмавы (Сакманов мәктәбе), арканы туры тотуы һәм физик җегәренә күбрәк таянуы егетне кыен хәлгә куйган булса кирәк.

Корсагы авызына җиткән булса да, тапканны югалтырга яратмаган Әлфия, Сәет эшкә чыккан көннәрдә үк, аның чикләвек агачыннан ясалган яңа мебель куелган офисында пәйда булды. Фил сөяген хәтерләткән шома тәнле, чибәр йөзе сытык, борчулы, кайгылы. Әмма тавышы — хуҗасының колы — кәрәзле чәчәк балыдай, татлы, ягымлы.

— Сәет Яруллович, сезне, туачак баламны көткәндәй, көтеп алдым. Мисхәт һаман утыра бит тегендә. Сез генә коткара аласыз минем иремне. Сездән башка безнең берәүгә дә хаҗәтебез юк икән. Зинһарлап, ярдәмегезне сорыйм,— дип үтенде, чын күңелдән ялварды ханым.

Хатын-кыз күз яшен авыр күтәрә иде Сәет. Тумыштан акыллы Әлфия елау-сыктау, ыңгырашу-иңрәү белән генә ерак китеп булмасын аңлый. Ханымның хәйлә пәрәвезен, ефәк корты кебек тукый белүенә күпне күргән Сакманов та шаклар катты.

— Минем вакытым да җитә инде, бала табарга. Шуңа чаклы Мисхәтем кайта алса иде.

Оялгандай итеп, килешле генә сүзен ялгап китте: «Кыз тапсам, иң якын дустым хатирәсенә Зөлфия, дип кушачакмын».

— Миңа үсеп өлгермәс инде ул,— дип шаяртырга көч тапты үзендә Сәет. Тавышы моңсу чыкты. Сөеклесен искә алуны ул һаман авыр кичерә иде.— Сезне тыңламыйча, малай туса, нишләрсез?— Тозлы суны «йотып» җибәрергә өлгергән, алмалары алгарак чыгып торган соры күзләрдә Сәет гаҗәпләнү, аптырау укыды: «Аяз, якты көн кебек ачык, ике икең дүрт төсле, мәгълүм хакыйкатьне белми утырасың, янәсе».

— Рөхсәт итсәгез, улыбыз Сәет атлы булыр. Сезгә ошатырга тырышып тәрбияләрмен.

— Белмим тагын,— дип, чал чәчләре ишәйгән башын сыпырып алды хуҗа.— Минем кебек булмасын инде ул. Бәхете белән, күлмәктә тусын. Үземнән генә тормаса да, берничә кат өйләнергә туры килде. Иң газиз кешемне саклый алмадым...

Күңеле тулып, үзе дә сизмәстән, Әлфиягә йөрәк серләрен ачып салды.

Тырнаклары буялган кулларын түгәрәк корсагына куеп утырган миһман ханым, иплән кенә Сәетне бүлдерде. Ирнең тормыш юлын, хаталарын «ярлыкады».

— Минем әбием, минем өчен дөньяда иң изге җан, «һәркем, үзенә аллаһы тәгаләбез, җиргә кендек каны тамганчы ук, тамгалап, билгеләп куйган үз яртысын табарга, кавышканчы аны эзләргә хаклы»,— ди торганые.— Берәүләр аны сразы таба, икенчеләре гомере буенча эзли.

— Тәңребез тапканны югалтмаска ярдәм итсен иде дә,— дип, сабыйларча көрсенеп куйды Сәет.— Мине бит әле мафиозник, пахан, босс фәлән-төгән, диләр. Сезнең улыгыз да минем юлдан китсә? — дип кыйшаерга итте ширкәт хуҗасы.

Әлфия нәтиҗәсен көттермәде.

— Сездәй дөньяви кеше булып үссәме? Бик шәп булыр иде әле. Алар үсеп җиткәнче әллә нинди заманалар килер әле.

— Сезнең туачак балагыз, нәсел-нәсәбегез хакына, берничә көннән, мондагы эшләрне аз-маз җайга салуга, юлга чыгам,— диде «Игелек» хуҗасы беркадәр тантаналы пафос белән.

Әлфия торып басты. Гәүдәсен матурлап куеп, җиңелчә генә башын иеп, ишеккә юнәлде. Оят вә хурлык булса да, хатынның тагын да тулыланып киткән гәүдә шәрифләренә күз ташлап алудан үзен тыя алмады Сакманов. Менюга күз салган өчен акча алмыйлар. Гаеп тә саналмый.

Вәгъдә бирү — тауга каршы капчык ташуга караганда, күп тапкыр җиңелрәк. Әлфияне: «Ярдәм итәрбез, артык борчылма, татар халкын арттыруга әзерлән»,— дип, иплән кенә өенә озатып җибәрсә дә, гозерне үтәве салават күперен чыгудан җиңел булмады.

Татарстан белән Ырымбур хакимиятләре арасында бәйләнеш юк дәрәҗәсендә икән. Дала шәһәренең хөкем оешмаларында эшләүчеләрнең күпчелеге Екатеринбург, Өфе, Себер якларында белем алу сәбәпле, араларында таныш-белешне табуы кибәннән энә эзләү кимәлендәге бер нәмәстәкәй икән. Әзерлексез, бухты-барахты сәфәр гизеп, әллә ни майтарып булмасын чамалый иде Сәет. Уйлана-сораштыра торгач, Ырымбурдан Казанга күчкән, газ җиһазлары буенча белгеч, бизнесмен, әзмәвердәй таза гәүдәле, бары тик кара шевиот кәстүмне генә ир-атка лаеклы кием дип санаган Илдар Хисмәтуллинны эзләп тапты. Үзенең алшартларын куеп, «бурыч белән төрмә адәм баласын ике яктан сагалап тора, безләр бер-беребезгә ярдәм итәргә должны»,— дип, теленә салышып, әҗер турында да онытмыйча, ярдәм итәргә алынган мишәр егете элек тормыш иткән якларыннан зрә кәефе кырылып кайта.

— Кырык алты яшемә йитеп, андый тирес адәмне бакканым юк иде. Прокурорны атьәм. Үзе шул як татары. Якын йибәрми. Яшь адәм булса, аңлариең, карьера куа дияриең. Илленең өске ягында. Ну, зверь. Ерткычың бер якта торсын. Мин үзебезчә, мишәрчә сүлим, ул урысча бәрә. Кул селтәдем дә, бирёдә укыган танышымны эзләп киттем. Ул нормаль каршы алды, милиция, суд работниклары белән таныштырды. Алары, дивана прокурор кебек, ломатсә итеп тормадылар. Сумманы атьтеләр. Үзебезгә тегел, диләр. Мин аңламыйм что-ли. Хоть чертыма дим, егетне чыгарыгыз, дим. Короче, менә шул сумманы алып, шунда барасы...

Илдар Хисмәтуллин, җыйган мәгълүматларын олыдан тапшырып, үзенә тиешле «сәдаканы» кара шевиот пинжәгенең эчке кесәсенә салып, дәүләт эше башкарган кешедәй, эре генә саубуллашып, үз юлын тотты. Мисхәтне йолу эпопеясында, яхшымы-яманмы, беренче адым ясалган иде.

Үзенә юл чыкмыйча, Төньяк Калавылы тавыннан әмсенеп карап кына мәсьәләнең уңай хәл ителмәсен аңлаган Сакманов, әлегәчә, суер кебек, качып-посып яткан Биотлонистны, Гришаны үзе белән алып, рульгә Замирны утыртып, дала якларына чыгып китте. Ырымбур аны кабырганы санап, сөякләрне үтәли чыгып йөри торган көзге җилләре, комлы,

буранлы тузаннары белән каршы алды. Табигатьнең иң әшәке вакыты. Өйләр, биналар ягыла гына башлаган. Адәм баласы беркая да рәхәтлек таба алмый. Тәнеңдә җылың тормаганда, күңел тыныч, ирекле була, зиһен тулы көчкә дөберди алмый. Иң затлы, кояшлы якка караган бүлмәләрне базарчы кавказлылар, үзбәк кардәшләр алып бетергән булса да, кунакханәләрдә буш урыннар җитәрлек иде. Кыйммәтчелек, ач бүредәй улаган дәвердә, теләсә кем яши алмый бәһале бүлмәләрдә.

Төрмә әйләнәсендә буталып, «яктырып» йөрүдән мән чыкмасны чамалаган Сәет, егетләрен хәмер, азык-төлек, җиләк-җимеш кебек кирәк-яракны алырга базар тарафларына озатты да, телефонга утырды. Илдар калдырган саннарны җыярга кереште. Эзләгән табар, тырышкан ташка кадак кагар, дигән агай-эне. Заманында Казанда югары белем эстәгән, өлкә хакимият оешмасында эшләүче Владимир Степанович урынында булып чыкты. Телефоннан теләсә нинди гозерне кире кагуы җиңелрәк булуны исәпкә алып, йомыш төенен ахыргача чишмичә, җаваплы кешедән үзен кабул итүен үтенде: «Кечтеки генә йомыш, киңәшәсе бар»,— дигән булды. Сакмановтан яшьрәк, үзенә югары белем биргән Казан кешеләренә ярдәм итәргә әзер, ачык чырайлы, аралашуга омтылып торучан зат булып чыкты Илдарның белеше. Кунакханәдә озаклап гәпләшеп, кәефләнеп утырдылар. Сәеткә эчәргә ярамаганга бик исе китеп, кыланып тормады. Үзенә кирәген уртлады. Күчтәнәчләр белән машинада озатып кую да күңеленә хуш килде.

Икенче көнне Владимир Степанович, «Маликов эше» буенча шактый төпле мәгълүматлар «күтәреп» килде: «Егетнең делосын алып баручы прокурор белән, татар кавеменнән булса да, борчак пешмәс, пенсиягә чыгарга ел ярым калган, кәнәфиеннән колак кагудан куркып, ярарга тырышып, чәче белән җир себерә икән. Иңенә янә бер йолдыз өстәтү бәрабәренә туган анасын төрмәгә илтеп тапшырырга сәләтле адәм диләр аның хакында. Сезнең халык бер үҗәтләнсә, чыгымчы ат кебек, ахыргача торачак. Үпкәләмәгез, алты ел КАИда укыдым»,— дип тә өстәде. «Кыскасы, прокурорга юл эзләп, вакыт уздырасы түгел. Шул эшне алып баручы майор белән район казые турында фикерләр уңай. Ярдәмчел кешеләр, диләр».

Зәңгәрсу күзләренә өмет вәгъдә иткән, хәйләкәр елмаю иңде. Сәет аны аңлады, «ярдәмчеллек»нең бирелеш рәвешен вә күләмен ачыклыйсы калды.

Сакманов баш бармагын калган дүртесенең йомшаклары өстеннән ышкып уздырды.

— Күпмерәк кирәк булыр?

Ир уртасы, аксыл чәчле башын як-якка чайкап алгандай итте, кулларын өскә күтәреп, аркылыга куеп, хач сынын чыгарды.

— Юк, юк! Ришвәт бирү турындагы хыялыңны башыңнан чыгарып ташла. Егетең шул гамәле өчен гаепләнә. Беләсеңдер?

— Алайса, мул итеп өстәл әзерләрбез. Базардан сарык алып, кышкы табигать кочагына, шашлыкка чыгарга мөмкин.

— Бәлки, анысы да кирәк булыр... Соңрак...

Чәчләре хөкем оешмасында агара башлаган Сакманов әлегә берни аңламый. «Ничек инде тоткынны болай гына төрмәдән чыгарсыннар ди, тузга язмаганны. Безнең заманда да, җитди мәсьәләләр, кулга кытыршыны салмыйча, хәл ителми иде. Ришвәт алу, ришвәт бирү — Русиянең элек-электән килгән яшәү рәвеше. Земеля нәрсәдер бөгештерә. Сырхауханәдә озак ятып, тормыштан шулай өметсез артта калынганмы әллә?»

Владимир Степанович Сакмановны артык интектермәде, ачыкламыш кертте.

— Мондый арзан алымнарга авыша торган егетләр түгел минем танышларым. Маликовны әманәткә чыгарып тору (бәлки, шартлы рәвештә) хакында гына сүз алып барырга мөмкин.

Яңа танышының фикер сөрешенә бу юлы тиз төшендә «Игелек» хуҗасы. Карале син аны, нинди җайлы, хәтер калдырмаслык, үпкәләтмәслек, отышлы алым табылган. Әманәт... Залог... под залог. «Умырзая» ресторанында утырганда Нургали Ваһапов сөйләгән мәзәктәге ке-

бек, сало ул кайда да. Африкада да сало инде ул. Тозлы, борычлы, тәтенле дуңгыз маеның сыйфаты гына төрле була. Бирәү дә взятка алмый, һәрхәлдә, синең алдыңда куен кесәсенә салмый, папкада тота, ник дисәң, яхшылык, изгелек юлында ул арадашчы гына. Сәвит системасы адәм баласына михнәт күрми яшәү өчен ничаклы мөмкинлекләр ачып калдырган. Ә без, әтрафсыз балалар, ыштыр битләр аны каһәрләргә җөрьәт итәбез. Әманәт... залог... бурыч... сало... Вәссәлам. Кояш нурларында, әллә ничә төрле төсләргә кергән затлы асыл таш кеби, тирән мәгънәле сүзләр.

— Сез, Владимир Степанович, аларга әҗерне диимме, үзегез илтәсезме? Әллә мине таныштырасызмы? Күләм шәрифләрен чама беләнрәк билгеләсеннәр инде. Егет байлар токымыннан түгел. Йшле нәселдән, яңа гына гаилә корды. Хатыны — көмәнле. Нияте дә бик изге булган: чит-ят җирдә адашып калган апасына ярдәм итү. Шәригать кануннарыннан килеп бәяләгәндә, Маликовның түшенә орден тагасы. Игелекле эштә йөргәч,— дип, Сәетнең ясканып сөйләнүен Владимир Степанович кыйммәтле коньяктан алсуланган колагының әченә үткәзеп тормады.

— Урынлы сөаль,— дию белән чикләнде.

«Җавап» атлы тулпарын тезгеннән ычкындырырга ашыкмады. Сакманов үзе дә сорау кәлимәнең дөрес куелуында шикләнми. Аны сумманың күләме белән бер үк дәрәҗәдә, гарантия мәсьәләсе борчый. Исрафчылык заманасы түгел. Шул ук вакытта бәгъзесе дә: «Мин Сакмановтан фәлән-фәлән сум сәмән алдым, шуның өчен Мисхәт иптәш Маликовны төрмәдән чыгаруны үз өстемә алам»,— дигән язма заминлек кулына тоттырмаячак. Шыр тиләләр, агач диваналар чоры үтте. Ришвәт алу өчен әнә нинди яшертен тычкан тишеге табылган. Черки борыны да сыймаслык.

Владимир Степанович Сакмановны җаваплы майор белән кавыштырды. Тәмәке төтене «эчеп» керәм дигән булып, машинада икесен генә калдырды. Яше кырыклар тирәсендәге, тулы гәүдәле, чокырлы иякле, аралашыр өчен ипле кеше булып чыкты хөкем әһеле.

— Мин Маликов Мисхәтнең абыйсы булам. Туганнан туган. Аның ярдәм кулын сузарлык башка кешесе юк. Заманында үзем дә милициядә эшләп чыккан кеше. Миннән шикләнмәскә мөмкин димәкче булам.

Майор бүселеп чыкмады, тигез ак тешләрен уйнатып, рәхәтләнеп, шарлавык агызып көлде.

— Юкка вакыт уздырмыйк. Владимир Степановичка ышанам. Ул теләсә кем белән таныштырмас. Миннән ни-нәрсә сорала?

— Егетне коткару иде хыялым. Бәясеннән тормабыз.

— Сез дә, Маликов шикелле, ришвәт тәкъдим итмәкче буласызмы? Минем кәҗәм ит ашамый диләрме әле?

Шаяртуыннан канәгать калып, бу юлы да колаклары селкенгәнче, кычкырып көлде. Иң михнәтле заманда да җиңел яши белә торган кешеләрнең берсе иде бугай майор.

— Кемгәдер кирәк булган бу карачкы процесс. Егетнең сәдәбенә пальто такканнар.

— Үткән — беткән. Хәзер сүз Маликовны судан коры чыгару турында барырга тиеш бугай. Мин сөйләшкән кешеләр: «әманәткә чыгарып булыр», кебегрәк фикер әйттеләр. Тик әүвәл гаепләнүченең ришвәт бирү фактын танып, беркетмәләргә кул кую шарты бар.

— Бу хакта мин сөйләшермен. Ул — риза булыр,— дигән фикере белән бүлеште Сәет.

Мәҗбүри булмаган сөйләшүләр, нинди генә озын-озакка бармасын, барыбер «под залог»ның күләмен яисә кимәлен билгеләүдән коткара алмый. Кар белән аралашкан вак комлы, салкын җил зиһенне начар эшләтә. Икесе дә котәләр. Әманәт хакында сүзне Сакманов башласа, бәһаның зуррак куелачагын кот тә тор: «Синең үтенеч, үзең башладың, гафән». Сүздән гамәлгә күчү җиңел түгел.

Озаккарак киткән тынлыкны хөкем оешмасы әгъзасы өзде. Тавышы, каз бәбкәсе тиресеедәй йомшак, нурлы, үзенә тартып торучан килеп чыкты.

— Кырык лимон сорыйлар, притом баксаларда. Мин — арадашчы гына. Сумманы санап алам да Владимир Степановичка бирәм. Ул — җаваплы кешеләргә тапшыра...

«Тегесе нәкъ шуның киресен талкыган иде. Эзне яшерәләр»,— дип, эчтән көлемсерәп куйды Сәет. Ә аңа кемгә бирсә дә барыбер түгелмени? Егетне генә тизрәк азат итсеннәр. Дуганы артыграк бөгәләр бугай. Бәхәсләшеп карыйсы булыр.

— Кырык күбрәк булыр. Егет барча мөлкәтен, хәтта йөкле хатынын сатса да, ул чаклы акчаны җыя алмаячак,— дип кабатлады.

Майор иреннәрен бөрештерде. Уртасы буш түгәрәк клиндер килеп чыкты.

— Мин арадашчы гына. Башка ягы — сезнең проблема. Миңа шул санны атадылар. Риза булмасагыз, кулларны соңгы кат кысышабыз да, ничек диләр әле, диңгездәге кораблар мәсле, төрлебез төрле якка... Әллүк...

— Алай ук кырыс сөйләшмик инде. Ничек диган әле җәллад Сталин: «Кеше бар — мәсьәлә бар, кеше юк — проблема юк». Егет нахакка утыра, өлкәннәрдән ярдәм көтә. Миһербанлы булыйк инде шул мескенкәйгә...

— Шул ният белән сезнең машинада сөрсенеп утырабыз түгелме соң? — диде милиция майоры, бераз йомшара төшеп. Сиздермәскә тырышып кына, утыргыч кесәләрен капшап алды. Сәет күзеннән бу хәрәкәт читтә кала алмады: сөйләшүне язып баручы нәмәстәкәйләр эзли.

— Зинһар, шикләнмәгез, курыкмагыз. Без — җитди кешеләр. Сораганның яртысы җитмәсме? Бигрәк юк эш өчен интегә бит егет.

— Сөйләшеп карармын. Утыздан да төшмәсләр. Мин — таныштыручы функционер гына. Ничек әйтерләр.

Машинаның алгы утыргычына шыпырт кына Владимир Степанович кереп чумды. Ул, янәсе, берни белми, берни ишетми, аңа арадашчы вазыйфасы гына йөкләтелгән.

— Сәет дус, яхшы коньягың булса, аз-маз тәмлик тә, мин киттем. Зря вакытым юк.

Әлбәттә инде, машинада затлы шәрабы да, кыйммәтле шоколады да табылды. Күңеле йомшап китеп, әманәт бәясен төшерүдән куркып, майор эчүдән баш тартты. Һәрхәлдә, аның бу тәртибен Сәет шулайрак юрады.

Хакимият вәкиле исә, бераз салып алгач, Сәетнең колагына пышылдады: «Бәяне төшертәм мин бу фараоннардан. Барыбер утыз кирәк булыр». Берәү дә акчаны үзенә алмый, берәү дә бушка килгән малдан баш тартмый.

Якынча аңлашудан соң, Сакманов Казанга кайтып, кешеләрен акча алыштыру бүлмәләренә йөгертеп, тиешле тәңкәләрне, яшел шайтаннарны җыештырып килде. Дөя сыртының икенче өркәчен үтәсе калды. Анысы да «Гордей бабай төенен» чишүдән җиңел булмады. Әҗерне алуга берәү дә каршы түгел. Җиһан халкы бу яссылыктан килеп бәяләгәндә кыл икегә бүленә икән: берсе — бирүче, икенчесе — алучы. Нәкъ җәллад һәм аның корбаннары кебек. Тик үзен хөрмәт иткән, җиңел яшисе килгән берәүнең дә, үз фамилиясен кабул итүчеләр исемлегендә күрәсе килми. Бу эшне башка кеше, үзгә зат аша башкару җайлырак. Кемәсенеңдер бөкере булуыннан аңа ни зыян? Ахыр чиктә, аяк чыланса да, борынга томау төшмәсен.

Янәдән кунакханәгә килеп урнаштылар. Пошымлы көтү өч көнгә сузылды. Кунакханәгә Владимир Степанович үзе шалтыратты.

— Бүген сезгә Маликов белән күрешергә рөхсәт алынды. Сәгать унда төрмә янында көтегез. Сезнең кырга таныш майор белән үзем килермен. Үзегез генә булыгыз! Артык сораулар бирмәгез. Әфисәр белән икәүдәнikәү генә калгач, теге көнне сөйләшкәннәр хакында сүз катыгыз. Минем белән бу хакта фикер алышу булмады. Аңыштыгызмы?

Алдан килешелгән шартнамә тулысынча диярлек үтәлде. Дала каласының, иләк аша уздырылган он кебек вак тузанын әллә ничәнче тәүлек үпкәгә тутырганда, Сәет Мисхәт Маликовны күрү бәхетенә ирешә. Очрашуга үсмерләрчә дулкынланып барды. Нияте: әүвәл Маликовны мондый ахмаклыгы өчен эттән алып эткә салып сүгү, иң әшәке сүзләр

белән әрләү. Әмма Мисхәтне күргәч, бар ачуын онытты. Әлфиянең бәхет сандугачын танырлык түгел иде. Сөяккә генә калган. Элек сәламәтлек аңкып торган алсу яңакларына җир төсе менгән, сирәк сакал-мыек баскан йөзе тартылып, кечерәеп киткән. Борыны белән колаклары гына тырпаеп тора. Төссезләнеп калган коңгырт күзләрендә яшьлек ялкыны, яшәү дәрте, иман рухы сүнгән. Битараф ваемсызлык өстенлек алган. Дөресе, капкынга эләккән ерткыч җанварныкына охшап калган кайчандыр сөйкемле күзләре. Элеккеге шук, шаян, иркәләнеп артистланырга яраткан Мисхәт-Мишаны алыштырганнар диярсең. Үз-үзен тотышында, карашында, тәртибендә Шөреп чалымнарын сиземләде Сәет. «Нәсел, ген, асыллык, затлылык турында күпме сөйләсәк тә, кешене калыплауда тирәлек, мохит кебек әкәм-төкәмне чуттан ташлап булмый икән. Рәсәйле беркайчан да инглиз, француз язучысы төсле фикерли алмас. Гоголь, Достоевский, Толстой кебек каләм ияләре испан, италян җирлегендә туа алмый торгандыр»,— кебек шактый сәер уйлар өермәсе узды күңеленнән.

Бер-берсенә кара-каршы атлап, аралары ике аршынлап калгач, тукталып-төртелеп калдылар. Сакмановның йөрәге янәдән чәнчеп, әрнеп алды. Соңыннан Мисхәт: «Сәет Яруллович терелеп, үзе килеп алмыйча, төрмәдән чыкмаска булган идем»,— дип, кикрикләрен киерсә дә, бүген хәле шәптән түгел иде.

— Сәет абый,— дип кенә әйтә алды егет, хуҗасының куенына ташланып. Сүзенең көче югалды.

Сакманов егетнең тырпаеп торган очлы җилкәләрен кочты, кабыргаларын капшады.

— Нихәл, Мисхәт. Нәрсә булды? Ничек килеп кердең бирегә? Нишләттеләр сине бу мөртәтләр?

— Хәзергә берни сөйли дә, аңлата да алмам. Үзем берни төшенмим. Бик каты кыйнадылар. Синяклар һаман китми. Әлфия ничек анда?

— Исән-сау хатының. Сине көтә. Балаңны көтә.

— Мин нәрсә, сез исән-сау калдыгыз, аллага шөкер.— Мин ахмаклыгым белән килеп каптым. Каты изделәр.

Фикеренең җебе, сүзенең рәте-бите юк. Очрашу сөенеченнән шулай каушап калдымы, әллә чыннан да, дөмбәсләп һушын алганнармы бичараның?

— Баласын табарга да срогы җитә торгандыр инде, мескенкәемнең?

— Аларның срогы билгеле. Синеке кыенрак. Вакыт аз. Сине нәрсә өчен, нинди статья белән яптылар?

Берничә дәкыйка эндәшми торганнан соң, күптән башын катырган мәсьәләне ниһаять калкытып куярга җөрьәт иткәндәй, сөйли башлады. Зиһене ачылып киткәндәй булды.

— Взятка биргән, дөресе, бирергә маташкан өчен, дигән ярлык тактылар, Сәет абый. Рәтләп тикшермәделәр, ике кат следовательгә, бер тапкыр прокурорга алып бардылар. Шуның белән бетте. Безнең камерада судсыз-нисез өчәр ел утыручылар бар. Әйтерсең лә, андый кеше дөньяда юк. Бер аббай күрше сарыгын урлап суйган өчен икенче ел инде шунда ята. «Мин аны үземнеке белән бутаганмын. Ичмасам, итен дә тәмләп карый алмадым, шунысы үкенечкә калды»,— ди.

— Үзең турында гына сөйлә!

Сүз куәсе ачылып киткән егет, ифрат җиңел күчеш ясады.

— Взятка бирү фактыңны таны, шуннан соң сразы суд булыр, условно срок биреп, иреккә чыгарырбыз, диләр. Мин аларга ышанмыйм. Мәкер ятьмәсенә килеп кабудан куркам. Кул тамгасын салуга, биш-алты елны чәпәрләр. Бу статья буенча сигез елга чаклы утыртырга була икән.

Мисхәтнең күңелендәге моң-зарын ата казга булса да сөйләп, бушанасы килүен аңласа да, вакытның иләмәгән чи тире кебек кыскара баруын хәтерендә тоткан Сәет, яшь дустының кайнар нотыгын бүлдерде.

— Мисхәт, мине игътибар белән тыңла, туң баш булма, аңларга тырыш. Сиңа барча кәгазьләргә дә, «риза» дип, кул куясы булыр.

— Соң бу бит ялганны раслау, үзең гариза язып төмугка керү була түгелме?

— Әле генә радиодан ишеттем, Пушкин бабабыз, шыр тиле генә үзгәрми, фикерен яңартмый,— дип акка кара белән язып калдырган икән.

— Мин взятка бирмәдем. Андый уем да юк иде. Сез дә минем муенга элмәк салырга ярдәм итәсез түгелме?—дип, Мисхәт карыша, үпкәли башлады. Тәне җәрәхәтленең рухы тиз сына икән.

Җәелеп сөйләп, тәфсилләп аңлатырлык арасы да юк ичмаса.

— Синең гаишникларга акча тәкъдим итү фактың өлкә хөкем оешмалары өчен кирәк, диделәр. Соңгы өч елда әлеге маддә буенча берәүне дә каптыра алмаганнар. Мәскәү канәгатьсезлек белдергән. Синең имзаң аларга язгы, күптәннән көтелгән яңгырдай тансык. Шылдымы?

Яшьлеге белән кәҗәләнеп, ябык чыраен чалшайтып торган егеткә Сәет соңгы дәлилен китерде. Билдән түбәнрәк тондырырга туры килде.

— Бер беркетмәгә син, ришвәт бирүеңне танып, кул куйган булгансың икән инде. Хәзер нәрсә киребеткән булып кыланасың?

Мисхәт балаларча көрсенеп куйды.

— Булды андый хәл. Бик нык кыйнаганнан соң. Аңгы-миңге хәлемдә идем. «Су бирербез», диделәр. Анда да алдадылар.

Соңыннан имзамнан баш тарттым.

— Җитди булмаган. Хәзер намусыңа, гамәлеңә каршы булса да, имзаңны янәдән сырла. Шуннан соң сине под залог, сразы чыгарачаклар. Әлфияң янына алып кайтып китәбез.

— Чынлапмы? Судсызмы?

— Кәмит уйнап торырлармы, юкмы, ул хәтлесен әйтә алмыйм. Тик зур сумма сорыйлар. Бер өлешен ширкәт күтәрер. Безнең йомыш белән эләккән булсаң, барлык чыгымнарны да үз өстебезгә алыр идек. Бу очракта үткәреп булмас. Шәхси мәнфәгатьләре белән йөргән, диярләр.

Мисхәт мәсьәләнең асылына төшенә башлады.

— Күпме сорыйлар?

Сакманов дүрт бармагын өскә күтәрде.

— Дүрт миллионмы?—дип пышылдады сөенечле тавыш белән Мисхәт.—Әлфиядә бар ул чаклы гына, китереп бирер.

—Кырык,—диде Сәет, акрын гына.—Дүрт белән пычранып тордылар, ди сиңа.

Әле бу хәтлесен дә долларларда, бары тик туксан өченче ел һәм аның соңрак басылганнарын гына бирү шартын куюларын мәхбүскә чишеп тормады.

Маликов анык карарга килде: «Машинамны сатармын, әлегә җәяү йөреп торырбыз».

— Свидание окончено,—диде ала-кола киемле сакчы.

— Соңгы сүзем шул. Кирәкле «кәгазьләрне» мин инде алып килдем. Син барча беркетмәләргә хәзер үк кул куй. Укыган бул, хатын-кыз кебек, исем өчен генә карышкан бул...

Егетнең ничектер күңелен күтәрәсе килде.

— Түз, Мисхәт, түз, күп калмады. Минем әткәй: «Кәҗә үзе пырдымсыз булса да, аның тиресе чыдам»,—дип, безне үртәргә ярата иде, тал чыбыгы белән «иркәләгәннән» соң.

Тиешле әманәтне майор вә Владимир Степанович, үзләре әйтүенчә, шәлпек кулларга илтеп тоттыргач, Сим-Сим агай, нәкъ әкияттәге шикелле, казаматның җиде йозаклы ишекләрен каерып ачып, аннан Бухенвальд әсиредәй ябык бер егетне тарткәләп ирекккә чыгарды. Әйтерсең лә, ул үзе теләп төрмәгә кергән дә, чыгып китәргә теләми, карыша. Ул мәхбүс— Мисхәт Маликов иде. Барча беркетмә кәгазьләрен, гаепнамә-шартнамәләрне Сакмановның кулына тоттырдылар. Теләсәң яндыр, теләмәсәң— сатып эч. Төрмә ишеге белән бергә мәсьәлә ябылды. Ләкин аның кошмарлары әле байтак еллар дәвамында Мисхәтнең төшенә кереп йөдәтәчәк. Зиндан — ял йорты түгел икән шул.

Мисхәт үзе өчен нәтиҗә ясады: бу тормышта үзеңне раслый, җәмгыятьтә урыныңны билгели алмасаң, таптап китәселәрен көт тә тор; үзеңә кирәген кулың белән суырып алмасаң, аякны сузарга туры киләчәк.

Алар урамга чыкканда, кыш бабай килеп җитеп, йолдызлар сыман эре кар бөртекләрен уйната башлаган иде. Мисхәт өчен анысы да тансык. Кәчәя барган ап-ак карга ул битен, күзләрен куйды, «ябалак»ларны күкрәгенә кертте. «Бу кар минем өчен ява, мине тәбрикли» — дип, бала-

ларча сөенеп, энҗеләрне тотарга, кулына җыярга керeште. Шулай да җилгә каршы барасы килмәде. Ул инде элеккеге Мисхәт түгел иде. «Азатлыкның кадерен белмибез, аның һәр мизгеле төрмәнең алты аена торырлык икән»,— дип уйланып, Маликов машинага кереп чумды. Юлны җиңел үттеләр.

Аның өчен икенче олуг сөенеч — Әлфиясен кочагына алу бәхете иде. Мәхбүснең төссезләнеп калган күзләрендә кайнар очкын кабынды. Өзелепләр ярата икән хатынын. Сүзләренең мәгънәви төсмеренә игътибар итмичә, лепелдәвен, үзенекен тукуын белде.

— Әлфиякәем, бик сагындым үзеңне. Анда да... тегендә миңа син җитмәдең.

Иренең ташландык бакча казыклары мәсле тырпаеп калган иңбашларын сыйпый-сыйпый, Әлфия төрттереп куйды: «Мине үзең белән төрмәгә аласың булган. Дөньяның күпме олуг улы, кызы зинданда туган».

Маликов шаяртуны кабул итәрлек хәлдә түгел иде әле.

— Синең акыллы киңәшләреңә мохтаҗ идем мин. Хәер, мин гел синең белән сөйләшеп-табышып яшәдем. Төрмәдә бит үзең теләгән дусларны сайлап алып булмый. Базардагы шикелле кыланып, нәзберекләнеп йөри алмыйсың. Камерага кемне китереп ташлыйлар, шул синеке. Анда, Әлфиякәй, кемнәр генә утырмый. Жуть... Акылдан язарлык. Шунысы кызыклы: яңа утырган кеше әле, шыксыз үрдәк баласы төсле, башкалардан аерылып тора. Ә берничә айдан... ул шул ук мунча пәриенә әйләнә. Җылы якта озак яшәп, пылау ашап, үзбәккә охшый башлаган татарлар төсле.

— Мунча пәриен күргән кешедәй сөйләнәсең тагын.

— Ул миңа, хәзерге килеш-килбәтемә ошагандыр, дип уйлыйм, матурым.

Шаяртырга тырышса да, Мисхәтнең авыр һәм күңелсез үткәне күзалдына килдеме, күзләре дымлана. Мәгәр, булып узган хәлләр кара тамга булып артында торса да, аңа рәхәт иде. Зарланыр кешең булу үзе бәхет икән.

— Мин кыйнауны, авыртуны авыр күтәрдем. Шуңар да миңа «интеллигентик» дигән, мыскыллы кушамат тактылар. Күнектем анысына да.

— Кыйналган урыннарыңны үзем иркәләп, үбеп төзәтермен, кочагымда барысын да онытырсың,— дигән вәгъдә бирде ханым.

— Прокурорга допроска алып килгәндә, аркам, янтауларым кара күмер төсле иде. «Мине милициядә тукмап үтерә яздылар»,— дидем.

— Уйлап чыгарма, сине берәү дә кыйнамады,— ди тегe.— Син әле безнең губерна кешеләренә яла ягарга җыенасыңмы? Провокатор, сексот.

Ачуым, үпкәм, рәнҗүем бугазыма килде. Ачык тәрәзәдән сикерергә, дигән уй узды миемнән. Өченче кат, аста сөңге төсле очлы, тимер рәшәткәләр. Шуларга барып төшәм дә, котылам бу рисвайдан, дим. Шунда колагыма синең тавыш килде: «Мисхәт, җаным, тилермә. Мин, Әлфияң, бар. Сине яратам мин. Тиздән туачак балабызны ятим итмә!». Уемнан кире кайттым. Юк, мин түзәргә, яшәргә, җиңәргә, Әлфиямне бәхетле итәргә тиеш дип, тиле хисемне йөгәнләдем. Ачуым кабынды. Шунда, күлмәгемне изүдән каерып, ертып төшердем. Прокурор урындыгыннан сикереп торып өстәл төеп, кычкырынырга тотынды: «Алып китегез бу хулиганны. Арт сабагын укытыгыз. Артык күземә күрсәтмәгез!»

Милициягә алып кереп, тагын изделәр, үзләре арыганчы дөмбәсләделәр. Дөресе, иреннәремнән ак күбекләр бәреп чыга башлагач кына туктадылар. Бөтен тәнем ялкын. Башта тоташ гүләү. Кайсы җир авыртканны да белмәссең, чөнки сызламаган, сыкранып еламаган бер әгъзам дә калмаган иде. Үтереп эчәсе килә, су сорадым. «Әүвәл менә бу кәгазьләргә кул куй, аннан бер графина салкын чишмә суы китерәбез, ди берсе. Мин, иләндә аунап яткан килеш, укымыйча ук, ниндидер кәгазьләргә фамилиямә охшаш тамга салдым да, аңымны җуйдым».

— Су бирделәрме соң? — дигән соравына җавап ишетәсе килде Әлфиянең.

— Хәтерләмим әчкәнемне. Алдаганнардыр. Иң кызыклы ачышым шул булды, Әлфиякәй, мине тоткан ГАИ дәһрие дә, иң әшәке кыланган прокурор да, икесе дә милләтләре буенча татарлар икән.
— Алар безнең якныкылар түгелдер?
— Гаиныкын белмим. Прокуроры Оренбург өлкәсенең көньягында туып-үскән җаһил, ди. Татарча белә, ну сөйләшми, ди. Озын торыклы, олы башлы, пинҗәгенең кыска җиңеннән тырпаеп чыгып торган кызыл, йөнтәс куллы, мәче күзле абзыйны мин күрүгә үк яратмадым.
— Дөрес эшләгәнсең! — дип хуплауны кирәк тапты хатын.
Мисхәтнең эчендә кайнаган нөктәле рәнҗүен, үчен, саруын чыгарырга кирәклекне аңлап, алдан уйланылган, нәүмизле ялагай фикерен Әлфия дәвам итте: «Ул кылый авызлы, кыек күзле, бит сөяге тәкә мөгезедәй алга чыгып торган, җирдәй тиреле, йоны кырылган куркыныч убырга охшаган сволочьның кирәген бирермен әле. Минем кулга килеп кенә керсен».
Ир-зат хатынының, аны ирештереп, шаяртуын аңышып җитмәстән, өстәп куярга кирәк тапты: «Нәкъ менә шундый ифрат ямьсез адәм иде ул. Дөрес, хәзер мин аның йөзен артык хәтерләмим дә инде».
Нәсел дошманнарыннан үч алгандай, рәхәт булып китте икесенә дә. Ирен киеренке халәтеннән коткару әмәлен тапкан Әлфиянең иреннәрендә кояш нурларыдай иркә елмаю балкый.
— Шуннан инде, аяк куллары сызлаусыз булсын, мең рәхмәтләр үзенә, Сәет Яруллович килеп җитте. Бу юлы, аның үтенече белән, кыек-мыек имзамны сырладым. Минем өчен акчаны ул түләде. Күпме, ничек, нәрсә, миңа ләм-мим...
— Ахыры хәерле булсын, Мисхәтигем. Батырлыкка кайда да урын бар, диләр иде мәктәптә укыганда. Тик ул урыннан ераграк торырга кирәк,— дип, Әлфия вәгазь уку, акыл сату гадәтенә, «старосталыгына» тугры калып, нәтиҗә ясады.
— Һәркем язмышына үз маңгае белән бәреп керә, диләр.
— Маңгай адәм баласына «поштучно» бирелә, аны саклый һәм горур йөртә белергә кирәк,— дип өстәде хуҗабикә, «мәсьәләне» ябып.
Мисхәт иркәләнеп, чытлыкланып, колагын, иреннәрен Әлфиянең корсагына куеп, тыңлаган булды.
— Нәрсәдер сизеләме? — дигән булды ханым, Мисхәтнең йомшак чәчен сыйпап.
— Аягы белән китереп сылады, эттәм, бар әле урыныңа утыр, болай да кысан,— ди.
— Кит аннан, шаяртма,— дигән булды, канәгать ханым.
— Валлаһи дим.
— Шул чаклы ябыккансың, коры сөяккә калдырганнар.
— Син җибәргән продуктлар, акча исәбенә генә исән калдым. Тешләр селкенә башлаган иде. Синнән килгән сарымсак коткарды. Шуны саклап тотып, һәркөнне аз-мазлап ашарга тырыштым.
— Ашказаның ничек? Син бит гастритмы, язвамы борчый, дигәниең.
— Иркә тормыштан килгән чир булгандыр ул. Үзе турында бер тапкыр да искә төшермәде. Шул файдасы тиде.
Әлфия фил сөяге төсендәге тиреле битен сыйпап алды, дымлы иреннәрен бөрештереп, әйтте:
— Сине, Мисхәтем, Оренбургка ашказанын дәваларга махсус барды, диярбез, малаебызга йә кызыбызга.
Мисхәткә, җанашы белән килешеп, баш кагудан үзгә юл калмады.

*Дәвамы киләсе санда*



## Таңчулпан

### МӘҢГЕ ЧИШМӘС ТАБЫШМАГЫМ

* * *

Рөхсәт ит, калыйм күзеңдә
Тын гына, моңсу гына.
Күздә шифа табам сыман
Җанымның ярсуына.
Булыймчы бер сары яфрак
Кушкаен чукларында,
Бәлки, алып җылытырсың
Син дә бер учларыңа.
Китерерсең иреннә,
Үбәрмен шаша-шаша,
Ничә еллар җанда йөрткән
Хыялым чынга ашар.

Рөхсәт ит, калыйм күзеңдә
Ваз кичеп язларымнан.
Пыскак яңгыр булып явам —
Таныйчы назларымнан.

* * *

Төн
Серле иде.
Ул хатын булды.
Ал йөзләрен,
Күкрәкләрен
Яндырды ла кайнар ирен...
Онытылып сөелде ул.
Ә шулай да,
Күңелендә шөбһә иде.

Тәннәрендә тетрәү бетте,
Бары
Куенына алгач ире.
Көн туды.
Кояш нурлары
Сөеп хатынның шәрә иңен үпте.
Һәм йокылы тавыш ишетелде:
— Хатын, тор, чәй әзерлә!
Төннең
Серлелеге бетте —
Күзләрендә
Ике бөртек яшь ялтырап китте.

* * *

Өеп калган тәнем.
Уйларымны,
Уйларымны фәкать алмый йокы.
Күз алдымда —
Көзге каршындагы үзем —
Керфегемә сарган сыкы.
Синнән киткән көнем,
Соңгы яшьсез төнем...

## Хыянәт

Төне буе күктән йолдыз яуды,
Кемдер туды, кемдер өзелде.
Күзем алмый тыштан сине көттем,
Иптәш итеп
Көзгедәге ялгыз үземне.
Төне буе күктән йолдыз яуды,
Яңгыр булып юды күңелне.
Җан ярасы әрнеп, сыкрап, сызлап
Йолдыз яңгырына күмелде.
Төне буе күктән йолдыз яуды,
Гөрләвекләр генә акмады...
Әче таңда,
Йолдыз эзләренә баса-баса,
Гашыйк ата мәче атлады.
Нәкъ синеке иде атлавы...

## Рәсем

Ир асылы — табынганым,
Шашып-шашып сагынганым,
Язмышымны урап үткән,
Ялгышыма язылганым.

Гаярь җанлы арысланым,
Ярсып билен алышканым,

Әле кырыс, әле уйчан —
Мәңге чишмәс табышмагым.

## Шәм

Шәм яна төнне яктыртып —
Шәм микән, йөрәк микән?
Безнең кебек адашканнар
Күп микән, сирәк микән...

Шәм яна таңны чакырып —
Күңел ник иләс микән?
Күпме еллар оныталмый,
Чаманы белмәс икән.

Шәм яна сызлап, сызылып,
Таң аткач сүнәр микән,
Безнең сөю, җылы җитми
Бөредә үләр микән?

Шәм яна җанга сарылып
Җылысы булмый икән,
Ялгыз талга беркайчан да
Сандугач кунмый икән.

Миңа синсез, сиңа минсез
Яшәүләр булмый икән.

* * *

Исеңдәме? Икәү йөрдек
Урамда.
Беренче кар ява иде
Буранлап.
Карлар үпте керфегемне —
Күзләрем...
Син-җүләрем, шул кардан да
Көнләдең.
Узмас иде кебек җил дә
Арадан.
Без генәме бу язмыштан
Алданган?..
Без генәме — каерылган
Канатлар...
Карлар түгел, тамчы үбә
Яңактан.
Исеңдәме?
Икәү йөрдек урамда.
Беренче кар ява иде
Буранлап.
Сөйләшмәдек, анык иде
Хыяллар.
Нинди язмыш аерырга
Кыялган?..

Җилләр түгел, еллар ята
Арада,
Без генәме — бу язмыштан
Алданган?..
Беренче кар ява бүген
Буранлап.

* * *

Син югалдың
Кышкы төннең карасында эреп.
Ыңгыраштьі ишек, авыртудан.
Төн күзенә багам,
Юк, эзләмим сине,
Чакырмыйм да —
Бары онытылам.
Буран йота...
Синең арттан ачык калган ишек.
Рәнҗи сыман безгә — икебезгә.
Җанда кыш суыгы,
Кимсенү һәм әрнү,—
Лаекмы без мәхәббәтебезгә?!
Югалдың син
Кышкы төннең карасында эреп,
Эзләреңне куйды буран күмеп.
Төн аерды безне.
Гаҗәпләнәм шуңа —
Тормышымда булмагансың кебек...

## Яшәү өчен

Яшәү өчен җанга өмет кирәк,
Учак кирәк — ерак булса да.
Таянырга ныклы иңнәр кирәк,
Кайтып егылырга — бусага.

Яшәү өчен көтү, сагыну кирәк,
Елау кирәк җанны бушатып.
Табыну кирәк бер гөнаһлы җанга —
Пәйгамбәргә аны охшатып.

Яшәү өчен — алданырга кирәк!
Алда, диеп, күпме елларым...
...Аңладым да шушы хакыйкатьне,
Иренемне тешләп еладым.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

### Зөлфәт Хәким

# ГӨНАҺ

РОМАН

12

— Алло! Исәнмесез! Гафу итегез, Ильяс Хәмитович кирәк иде. Ә кайчан кайта? Ә сез кем буласыз? Кызы? Әлфияме? Әлфия, исәнмесез тагын бер тапкыр. Мин... Сез мине бәлки хәтерлисездер. Мин сезне күрергә телим. Сез мине хәтерләргә тиеш. Мин сезнең яныгызга кергән идем. Казанда. Марат яши торган фатирга. Хәтерлисезме? Армиягә кадәр үк, житмеш сигезенче елны. Фәиз минем исемем. Исегезгә төштеме? Менә шул Фәиз булам инде мин. Минме? Сезне күрергә кирәк кичекмәстән. Соңыннан аңлатыр идем. Трубканы сез алу бик яхшы булды әле, чөнки минем сездән гафу үтенәсем бар. Алло! Нишләптер начар ишетелә башлады. Кычкырыбрак. Автоматтан. Гагарин урамында. Кафе янындамы? Унбиш минуттан? Әйе шул, монда янәшә генә. Көтәм, Әлфия. Рәхмәт! Көтәм. Көтәм!

Ул атылып телефон будкасыннан чыкты. Телефоннан Әлфия белән сөйләшү күңелдә киеренкелек тудырды. Сөйләшүдән бигрәк, Ильяс Хәмитович трубканы алган очракта аның белән ни турында сөйләшермен дип куркудан эчтә ярсу купты. Әлфия, Әлфия... Ярый әле ул өйдә булды.

Көз. Алтын көз. Нинди матурлык соң бу? Югыйсә шиңеп, кибеп, үлеп, бетеп бара торган чор — ә нинди хозурлык! Китүнең матурлыгы. Бетүнең матурлыгы. Бу дөнья белән хушлашу тантанасы. Бу дөньяда саф, гаепсез булсаң гына, матур итеп китеп бару мөмкиндер шул.

Әлфия аны таныды.

— Исәнмесез, Әлфия. Сез мине таныдыгыз, ахры.

— Ә сезне танырлык. Әлбәттә, бераз үзгәргәнсез — олыгайгансыз дип әйтимме? Картаебрак киткән шикелле.

— Сез гафу итегез, Әлфия. Мин теге вакытта Казанда үземне бик дорфа тоткан идем.

— Ярар инде, булган — беткән.

— Мин гафу үтенәм. Чөнки минем халәтем... Мин ул вакытта башкача булалмый идем. Башымнан үткән вакыйгадан соң. Сез бәлки беләсездер инде ул вакыйга турында?

— Нинди вакыйга?

— Мин сезгә түгел, үги әтиегезгә үпкәле.

— Нинди үги әти инде ул тагын? Аңламадым.

— Ильяс Хәмитович сезнең үги әтиегез бит?

Ахыры. Башы 3—6 нчы саннарда.

— Кем әйтте моны! Нишләп ул минем үги әтием булсын. Бу гайбәтне тагын кем уйлап чыгарган?
— Гафу итегез, мин шулай ишеткән идем.
— Ул минем чып-чын үз әтием.
— Минем, әлбәттә, бигрәк тә теге Марат алдында гафу үтенәсем килә. Чөнки аңа да мин теләсә ни әйтеп чыгып киткән идем. Сез Марат белән бергәме һаман?
— Әйе. Без бит өйләнештек. Ул хәзер Ленинградта.
— Нишли ул анда?
— Психиатр булырга әзерләнә.
— Ә сез?
Әлфия аның төпченүеннән бераз аптырап калды.
— Мин Казанда яшим, монда ялга кайттым менә. Миңа нindидер йомышыгыз бар иде шикелле?
— Гафу итегез мине.
— Сезне инде мин дә, Марат та күптән гафу иттек. Юкка борчыласыз.
— Дөресен әйткәндә, миңа сезнең әтиегезне күреп сөйләшергә кирәк.
— Ә нигә кирәк икән ул сезгә?
— Аңардан гафу үтенәсем килә. Хәер, киресенчә, мин аны гафу итмәм, ахрысы.
— Сезгә нинди начарлык эшләде соң ул? Хәлегез тагын начарая түгелме? Сез чирлисезме әллә?
Әлфиянең әйтүе җитә калды — Фәиз, чыннан да, бөтенләй хәлсезләнеп китте.
— Хәзер үтә ул.
— Даруыгыз юкмы үзегез белән?
— Нинди дару кирәк соң миңа?
— Белмим. Скорый чакыртыйммы?
— Юк, кирәкми. Кичә аракы күп эчкән идем. Шунлыктан ул.
Алар йорт каршындагы эскәмиягә утырдылар.
— Җиңелрәк түгелме?
— Бераз җиңелрәк.
— Аракы эчмәгез бүтән.
— Әлфия, теге вакытта мине кайдан, ни эшләр бетереп килеп кергән дип уйлаган идегез?
— Казандамы?
— Әйе.
— Дөресен әйткәндә, ниләр уйларга да белмәдек без анда. Нинди дә булса күңелсез вакыйга килеп чыккандыр да, шуның тәэсире белән психлангансыз дип уйладык. Марат бик нык кайгырды инде. Әтисе үлде бит аның.
— Беләм.
— Марат сине әниең операция вакытында үлгән өчен нәфрәтләнәсең дип бик нык кайгырды. Ә минем әтием нигә кирәк сиңа?
— Мин аннан сорамакчы булам: нишләп ул, кибетне басар алдыннан кереп сорагач, «кибетебездә каравылчы юк», диде?! Нишләп кибеттә ювелир товарлар витринасында ялган балдаклар булган?! Ниһаять, нишләп кибетне баскан өчен бер гаепсез кешеләрне төрмәгә утыртканнар?
— Ә син кайдан беләсең боларны?
— Кыскасы, мин беләм чын каракларның кем икәнен.
— Мин сезгә шуны әйтмәкче булам: гафу итегез, сез бик нык дулкынланасыз, нервыларны, психиканы сакларга кирәк. Сез бит әле яшь. Ул эш булган-беткән, нокта куелган. Ул эшне яңадан кузгату сезгә файда китерерме, юкмы — иң элек шуны уйлагыз.
— Нинди файда! Миңа файда кирәкмени?! Бу эшкә нокта куелган дисеңме?! Бу эшкә, җанкисәгем, беркайчан да, мәңгегә нокта куеп булмаячак. Чөнки бу гөнаһны сөртеп, юып бетереп булмаячак.

— Сезнең сорауларыгызга әтием җавап бирә алыр дип ышандыра алмыйм. Нишләп сезне бу эш алай бик каты борчый соң?

— Чөнки бик зур гаебем, гөнаһым бар минем. Ул ВАКЫЙГА булмый иде. Әгәр мин җаным-тәнем белән каршы торган булсам, Зәбир үлми иде. Мин үтердем аны. Синең әтиең дә әле язмышны үзгәртә ала иде. Әле теге хайван — Сабитов Камил дә үзгәртә ала иде. Бик күп кеше ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ булдырмас өчен көч куя ала иде. Син уйлама, мин өстемнән гаепне төшерергә маташмыйм. Авыр, бик авыр үземә генә бу йөкне сөйрәп бару. Бер рюкзак кашык, көллек, балдак, алка — пүчтәк ул! Аларның авырлыгы ерунда, менә күңелдә асылынып торган хәсрәт ташын күтәреп барулар ай-һай авыр, бик авыр.

— Сез ачыклабрак сөйли алмыйсызмы?

— Син аңламадыңмыни әле?

— Юк.

— Һәм беркайчан аңлый алмаячаксың.

— Ярый, Фәиз, син үзеңне кулга алырга тырыш инде. Мин сиңа берничек тә ярдәм итәлмам шикелле. Бәлки бөтенесен онытып, онытылып, ял итәргә кирәктер сиңа? Шулай яхшырак булмасмы?

— Булмый шул. Син өйгә кайтасыңмы хәзер?

— Әйе.

— Синең белән подъездыңа кадәр барсам ярыймы?

— Үзеңә кара.

Алар әкрен генә көзге урам буйлап атладылар.

Үзләренең йортына җитәрәк Әлфия ишегалдындагы ял итү урынына ымлады:

— Әнә әтием утыра.

Аның башта әйтәсе килмәгән иде, шулай да әйтергә булды, чөнки Фәиз аның әтисен барыбер эзләп табачак, иртәме-соңмы алар барыбер очрашачаклар.

— Кайда? — диде Фәиз, сискәнеп.

Шулчакны Әлфия ник әйткәненә үкенеп куйды, әмма соң иде инде.

— Әнә бит эскәмиядә гәҗит укып утыра.

Ильяс Хәмитович домино уйный торган өстәлгә таянып гәҗит укый иде. Янында бер карт әби ниндидер төргәк тотып утырган. Башка беркем дә юк.

Фәиз Әлфиягә карады. Әлфия нык борчыла иде. Әтисе өчен дә, күбрәк Фәиз өчен, ахрысы. Чөнки Фәиз хисләнеп сөйләшкәннән соң талчыккан, йончыган иде. Шул хәлендә ничек сөйләшергә җыена ул?

— Әлфия, мин барып сөйләшимме әтиең белән?

— Сөйләш, — диде Әлфия. — Әгәр мәгънәсе булса.

Шуннан соң Әлфия кереп китмәде, читкәрәк барып куаклар янында тукталды.

Фәиз, нервылары соң дәрәҗәдә киеренке булганлыктан, кызу-кызу адымнар белән атлады.

— Ильяс Хәмитович! — диде ул, гәҗит артында күмелеп утыручы агайга.

Аның эндәшүе шактый көчле булып чыккандыр, Ильяс Хәмитович сискәнеп китте һәм гәҗитен кырыйгарак алды. Таушалган кыяфәтле, акайган күзле, тузгыган чәчле кешене күргәч, Ильяс Хәмитович каушабрак та калды шикелле.

— Ильяс Хәмитович сезме?

— Мин, — диде Ильяс Хәмитович һәм саклык йөзеннән торып басты.

Әби, ниндидер хәвеф-хәтәр киләсен сизенгәндәй, кинәт торып, аксыйаксый китеп барды.

— Бәлки сез миңа аңлатырсыз кайбер нәрсәләрне? — диде Фәиз таләпчән итеп. Аның бу таләбе җикерү сыманрак килеп чыкты.

— Син кем буласың? — диде элекке директор, туръләргә хас булганча, үз-үзенә ышанган тавыш белән.

— Мин...

Фәиз сүзсез калды. Кем соң ул директор өчен? Ильяс Хәмитовичның буй-сыны, килеш-килбәте каршында Фәиз кинәт югалып калды. Бу кешедә җирдә нык басып торучы кешеләргә хас кыюлык, үз-үзенә ышанучанлык күренде. Фәиз шабыр тиргә батты, эскәмиягә салынып утырды.

— Мине белмисез сез. Ә мин сезне беләм.

— Кем соң син?

Ильяс Хәмитович аның каршысына утырды.

Әлфия читтән карап торды да, аларның кара-каршы утыруларын күргәч, тынычланып, подъездга кереп китте.

Фәиз директорга күзләрен күтәрде, йөрәк ярсып типте. Күптән күрергә теләп йөрде ул аны. Менә ул каршыда. Ләкин ни мәгънә аның каршында утыруыннан?

— Зәбир сазлыкка батты,— диде ул, тәмам хәлдән таеп.

— Нинди Зәбир? Кем ул?

— Син белмисеңдер шул. Хәтерлисең микән, кибетеңне басар алдыннан бер егет синнән кереп сорады каравылчы кирәк түгелме дип.

— Шуннан?

— Ник алдадың?

— Кемне?

— Зәбирне?

— Ни дип?

Сөйләшү бик кызу барганлыктан, Фәиз, туктап, сулышы тигезләнгәнне көтте.

— Ул синнән каравылчы кирәкме дип сораган. Ә син әйткәнсең: «Каравылчы кирәк түгел! Бездә каравылчылар юк!» — дип.

— Шуннан?

— Ә син беләсеңме нәрсә... Әгәр дә син дөресен әйткән булсаң, «каравылчы бар» дип, УЛ ВАКЫЙГА булмый иде.

— Нинди вакыйга?..

— Син башыңны җүләргә салып утырма инде, яме!

— Син нишләп минем белән алай сөйләшәсең, маңка?!

Фәиз шүрләде, ләкин аны инде туктатырлык түгел иде. Бераз курыкса да, ул аның агрессиясенә каршы торырга әзер иде.

— Ә ничек сөйләшергә кирәк синең белән тагын?! Син үзең төрмәдә утырырга тиеш. Бер гаепсез кешеләрне утырткансыз. Синең үз урының төрмәдә.

— Ә синең урының, энекәш, күрәм, психушкада.

— Минем дә урыным төрмәдә,— диде Фәиз, авыр сулап.

Аның кинәт тынычлануы хәлсезлек нәтиҗәсе иде.

— Мин аңламыйм, сиңа ни кирәк соң? — диде Ильяс Хәмитович.

— Сазлыкка батырдым мин Зәбирне. Ничек алай килеп чыкты — аңлый алмыйм, шуны аңларга йөрим. Син: «Каравылчы урынында!» — дигән булсаң, кибетне басмыйлар иде.

— «Каравылчыгыз бармы»,— дип әзмәвердәй шикле егет кереп сорагач, кибет директоры ни дип җавап бирергә тиеш?

— Дөресен әйтергә идең! Әллә син аның кереп алтын урлавын теләдеңме?

— Ә син кайдан беләсең бу вакыйга турында?

— Шул көнне Зәбир үзе сөйләде миңа. Әле сазлыкка батканчы. Аның батуында мин гаепле. Ә син ярдәм иттең батырырга. Нишләп бер гаепсез кешеләрне утырттыгыз?

— Кем утырырга тиеш, шул утыра, энекәш. Син утырмыйсың икән, шуңа куанып яшә, яме.

— Бер генә көн мин булып яшәсәң иде син.

— Юк, туган, һәркемгә үзенеке бирелгән.

— Ә нишләп витринадагы алтын әйберләр чын алтыннан булмаган?!

Директор көлеп җибәрде.

— Син нәрсә, бөтен кеше дә үзең шикелле җүләр дип белдеңме әллә?! Кем инде витринада чын алтын әйберләрне калдыра? Чын алтын сейфка бикләнә ул. Ә витринадагы әйберләр бутафория — махсус заказ белән эшләтелгән товар — ялтыраткач, чистарткач чын алтыннан аеру кыен.

Үпкә, рәнҗү, нәфрәт — барысы бергә килеп тыгылды.

— Ник кирәк булды...— дип ыңгырашты Фәиз.

— Син беркайчан да артың сыймаган ярыкка башыңны тыкма. Ни бу якка, ни теге якка чыгалмый калуың бар.

— Сиңа үзең урлаганнарны һәм алга таба да урлыйсыларыңны капларга, списать итәргә бик уңай вакыйга булган икән.

— Син язмышыңа рәхмәт әйт, исән-имин, иректә йөрисең.

— Исән-имин?! Иректәме?! Нәрсә беләсең соң син?! Мин сине күралмыйм! Ничек шушы кешедән Әлфия туды икән, гаҗәп!

— Пошел вон!

— Мин сине күралмыйм! Әле беркайчан да бу кадәр тирән һәм чиксез нәфрәтләнгәнем юк иде минем. Рәмзияне харап иткән кеше дә син! Зәбирне, мине харап итүче дә син! Әле тагын кемнәрнең язмышында пычрак роль уйнагансыңдыр?!

— Милиция!

«Милиция» дигән сүздән Фәизнең үзәге куырылып китте. Ул, кайсы якка барганын да хәтерләмичә, йөгерде.

Поселокка ул соң гына, инде караңгы төшкәч кенә кайтып җитте — ял көне булу сәбәпле, юлда машиналар сирәк очрады, алары да утыртмыйча выжылдап узып китә тордылар. Ярый әле үзләренең МТСыннан бер ГАЗик куып җитте.

Нишләдем мин, нишләдем? Нәрсә бирде миңа директор белән сөйләшү? Хәзер бит ул мине милициягә тапшыра ала. Милициягә тапшырмас та бәлки, чөнки утыртасы кешеләрне утыртканнар бит. Ул инде сизенгәндер. Ул бит җүләр түгел. Аңлагандыр. Бер файдасыз, нәтиҗәсез, мәгънәсез сөйләшү килеп чыкты. Мин үземнең гаебемне башкаларга да бераз өләшергә җыенам түгелме? Ләкин беркемнең дә өлеш аласы килмәс шул. Әлфия... чибәр кыз. Хәзер инде ул минем турыда ниләр уйлый икән? Җүләр дип саныйдыр. Җүләрләнәм бугай инде чынлап та. Вакыт үтә, егерме ике яшь инде миңа. Армиядән кайтканыма ике ел тулды, ә үземә үзем биргән вәгъдәне үтәмәдем. Хәтта сазлыкка барырга да курыктым бит мин. Ә үзем Ильяс Хәмитовичлардан гаеп эзләргә маташам. Оят! Бигрәк тә никтер Әлфиядән оят! Ильяс Хәмитовичның үз гаепләре, үз гөнаһлары. Минем анда ни эшем бар? Мин бит Зәбирне батыручы. Үләксә мин! Үземне җиңә алмаганны, кибет директорын акылга утырта аламмы инде, йә?! Мин болай үземне-үзем фаш итеп йөрсәм, кемгә файда соң? Ни мәгънә?

## 13

Ильяс Хәмитович белән булган әңгәмә тәэсирендә ул атна-ун көн чамасы каңгыраеп йөрде. Эшкә барасы килмәде, ләкин барырга кирәк... Бик авыр чакларда, инде иртән торып бер адым атларлык хәл булмаганда, ул йөз грамм аракы эчә башлады. Ничек тә үземне кулга алып, аракыдан башка көч табып яши башлармын дип үзен-үзе юатып йөрсә дә, аракы аның бердәнбер кәеф күтәрә торган чарасына әйләнде. Җан газабын бераз басып, тән хәлсезлеген бетереп торучы бу утлы су — бердәнбер юаткыч һәм таяныч иде.

Нәркизә бар. Ярый әле ул бар. Кочаклаган чакта җылы сулышы, кызлардан аңкый торган хуш исе белән ул Фәизнең үлеп барган тәненә җан өргәндәй була. Бу халәтне китапханәнең барлык китапларын укып чыккан сурәттә дә тәгаенләп тасвирлап бирү мөмкин түгелдер.

Нәркизә инде хәзер актык өмет шикелле калды, әйтерсең лә, шул нәзберек кыздан тора аның киләчәге. Мәхәббәт микән бу? Алар берберсен сагыналар, юксыналар. Аны күргәч җиңеллек килә. Нәркизә дә очрашкач очып китәрдәй булып җилкенеп ала. Әлбәттә, аның җилкенүе фәкать күзләрендә генә елтырап чагыла, эчтәге кутәренкелек аның тыйнак йөзенә чибәрлек бирә.

Нәркизә инде аның киноларга барудан баш тартуына да, кеше күп җыелган урыннарда озак торудан качарга омтылуларына да күнегә башлады. Алар очрашкач йә озак итеп китапханәдә утырдылар, йә урамнарны әйләнеп йөрделәр. Фәизнең кинозалда тыны кысылганны кыз белми, ә Фәиз аны төрлечә яшерә — тәмәке тартырга чыгып киткән булып, йә хаҗәтне башкарырга кирәк дип.

Ялгыз калып, үз уйлары белән йөргәндә ул хәйран тынычлана иде. Уйларга комачауласалар, авыр иде. Янәшәдә кеше булуның шунысы авыр — уйлавы кыен.

Аның инде, киресенчә, газаплы уйлардан арынып өчен кешеләр белән аралашырга, коллективта кайнашырга тырышканы да бар. Ләкин, нәтиҗәдә, кеше арасында ул фәкать ялгызлыкка ныграк сусый гына иде.

## 14

Күзге төннең шыбырдап коелырга торган йолдызлары астында ул әкрен генә атлады. Аяк астында кыштырдаган коры яфраклар ничектер күңелгә аваздаш тавышлар чыгарды. Көз, саубуллашу, хушлашу чоры. Бөек күренеш! Чакыра, әйди, ләкин хушлашырга әле иртәрәк!

Тулай торакка якынлашкач, ул кинәт туктады. Тәне эсселе-суыклы булып китте, миллион йолдызлы дөнья чайкалып, аяк астыннан каядыр бөтерелеп гаип булыр шикелле тоелды. Тулай торак тәрәзәләреннән саркыган саран гына яктылыкка «Милиция» дип язылган җиңел машина килеп туктады.

«Менә, ниһаять, таптылар, килделәр», — диде ул үзалдына. Уйламады, әйтте. Чөнки уй булып кына калырлык факт түгел иде бу. Күпме көннәр, ничәмә төннәр буе тынгылык бирмәгән КӨТҮ инде милиция машинасы бүлмәңнең тәрәзәсе каршына килеп туктагач, уй булып кына кала алмады, телгә күчеп, сүз булып чыкты. Газапларның азагыдыр бу бәлки, дигән бер шаян уй гына сызгырып, чыңлап үтеп китте. Шулай тәмамланырга тиеш иде бу матавык. Ул бит инде үзе дә шушыны көтеп, теләп йөрде түгелме? Әмма ләкин хәзер хайвани куркудан тораташ булып басып калды. Күзге урам да, сарылы-кызыллы яфраклар да, хәтта күктәге йолдызлар да юк иде инде. Бары тик милиция машинасы, чиксез курку һәм шул куркуның имәнгеч көенә биеп, тәннең кай төшендәдер сулкылдаган җан гына бар иде.

Качаргамы? Кая? Инде монда килеп җиткәннәр икән, димәк, белгәннәр, төшенгәннәр, тапканнар, алырга килгәннәр. Качып котылу мөмкин түгел инде, юк!

Тизрәк барып әйтергәме: монда мин, мин ул, менә мин!

Ни артка, ни алга адым ясарга үзендә хәл тапмыйча, ул, инде хөкем карарының үтәлешен көтеп торучы кебек, баскан урыныннан кымшанмады.

Милиция УАЗыннан озын гәүдәле милиционер чыкты. Култык астына нindидер төргәк кыстырып тулай торакка кереп китте.

Бер генә милиционер. Бәлки, әйбәтләп сөйләшеп, котылып булыр? Юк инде, аны бит күпме эзләделәр. Ә нигә котылырга тырышам әле мин? Табулары яхшырак лабаса. Бүлмәмнең ишеген шакыйдыр инде. Ачучы юк. Качаргамы әллә? Юк-юк, бәлки бу минем КОТЫЛУЫМДЫР. Нинди төргәк белән кереп китте соң ул? Богаулардыр. Сазлыкка

да алып барырлар инде. Тикшерү озак дәвам итәр. Булсын, булсын, барысын да сөйләп бирермен. Мин сөйләргә тиеш, качарга тиеш түгел. Җәзамны алырга тиеш.

Нәрсә бу?!

Милиционер әнә тагын җәһәт кенә машина ишеген ачып руль артына утырды, икенче яктагы ишекне ачты. Шул вакытны, плащын төймәләмичә генә җилфердәтеп, яланбаш көе Рәмзия атылып чыкты һәм як-ягына каранып, машина эченә кереп югалды.

Ишекләр шапылдап ябылды. Машина артка чигенеп борыла башлады. Фәиз карт тупыл артына качырга өлгерде, тирә-якка куркыныч яктылык сирпеп, машина поселок урамы буйлап китеп барды. Аның тавышы ерагайды, машина калага таба юл тотты.

Фәиз берни дә аңламады.

Ул әле бик озак — ике сәгатькә якын тулай торак тирәсендә йөрде. Бүлмәгә керергә куркыныч — милиция машинасының тагын килүе ихтимал. Шулай да нык ардырды һәм ул керергә булды. Шыпырт кына бүлмә ишеген ачты, тып-тын гына, хәтта караватын шыгырдатмаска тырышып, чишенмичә генә ятты. Гаҗәеп хәл: гадәттә ул йокыга китालмыйча җәфалана, ә бүген, киресенчә, йокысы килә, ләкин йокларга ярамый, ярамый, ярамый.

Димәк, мин әле һаман качарга уйлыйм. Кемнән качарга? Инде йөз тапкыр үземә-үзем исбатладым югыйсә — үзеңнән-үзең качып булмый.

Нишләп Рәмзияне алып киттеләр? Рәмзиядән сорау алалардыр иң элек. Чөнки Зәбир аңа сатты теге йөзекне. Аннары күршесен, ягъни мине сорашачаклар. Әле алар исбат итәргә тиешләр бит — минме, юкмы. Инде шактый вакыт үтте, димәк, мин хәзер баш тарта да алам: берниндә кибетне басканым юк.

Ә Зәбир турында? Аны батырып үтермәдем дип әйтергә кыюлыгым җитәрме? Хакым юк, анысы инде күптән аңлашылды. Минем бит әле көчем дә җитмәячәк, «сазлыкта булмадым, Зәбирне коткармадым», дип әйтергә.

Хәзер алай-болай мине килеп алып китсәләр, Нәркизә моны ничек кабул итәр икән? Төрмәдән кайтканымны көтәр микән? Юк, Нәркизә мине ташлаячак. Барысы да мәгълүм булгач, саф күңелле кыз баш тартачак аннан. Нинди көтү! Бәлки атарлар! Күңелнең бимазалануын, аның газабын белсәләр, атмаслар иде, мөгаен. Ләкин кем белә синең кайгыруларыңны, үкенүләреңне, офтануларыңны?

Ул кинәт сикереп торды. Утны кабызмыйча гына капшап ишекне тапты һәм бүлмәне бикләп тормады, МТСка йөгерде.

Иске вагонда гырлап йоклап ятучы каравылчыны уята алмый интекте. Ниһаять, ул сүгенә-сүгенә торып утырды да бик озак аны-моны аңламыйча күзләрен чекрәйтеп карап торды.

— Фәиз, анаңны сатыйм, нишләп йөрисең?

— Диспетчерскийның ачкычын бир әле, шунда кереп йоклыйм.

— Нәрсә булды, общагаңнан кудылармы әллә? Чирләмисеңдер бит? Кыяфәтең яман, махмыр түгелдер бит?

— Ачкычны бир инде тизрәк. Тулай торакта бүлмәм бик салкын.

— Диспетчерский җылы дип беләсең мәллә!

— Булсын! Мин йоклап калудан да куркам, соңгы вакытта эшкә соңга калам бит гел. Кереп йоклыйм инде.

— Диспетчерский ачык, бикле түгел ишеге,— диде каравылчы абый һәм сәкесен шыгырдатып тагын сузылып ятты да Фәиз чыгып киткәнче үк янә гырлый башлады.

Фәиз диспетчер бүлмәсендә милиция машинасы килгәнне көтеп утырды.

Ләкин милиция машинасы күренмәде. Таң атты, МТС үзенең тимер тавышлары белән тирә-якка җан өшеткеч авазлар таратып, үзенең тере икәнлеген бәян итте. Фәиз бригадирдан рөхсәт алып обедка кадәр генә

эшләде дә төшке аштан соң каравылчы вагонына кереп бераз черем итеп алды.

Көндез дә милиция-мазар күренмәде.

Өйдә кунмаска кирәк бүген. Ә кайда кунарга? Нәркизә янына барып кунаргамы? Юк, фатирының хуҗасы бик яман карчык. Кертмәс. Аннары, Нәркизәгә дә ничектер аңлатырга кирәк булачак бит. Сагындым, синнән башка бер төн дә торалмыйм, дисәм генә инде. Юк, Нәркизә үзе дә читенсенәчәк. «Өйдә алайса, тулай торагыңа барыйк», дисә, нишләрмен? Юк, анда бармыйк диярменме? Мине алырга килсәләр, барыбер Нәркизә белән очрашканны беләчәкләр, барып шунда кулга алачаклар. Нәркизә бит әле белми, бернәрсә дә белми. Кем белән бәйләнешкәнен аңламый бит әле ул. Белгәч нишләр?

Эштән соң тулай торакка кайтып ятарга булды. Ару, йончу үзенекен итте. Ни булса — шул, язмыштан узмыш юк, кем әйтмешли.

Тулай торакның коридорында очраган кешеләр инде барысы якыннан таныш кешеләр булсалар да, хәзер никтер алар ят, ерак һәм хәтта дошманнар кебек иде. Фәизгә алар һәммәсе нәфрәт белән карыйлардыр, һәрберсе күңелендә аңа үз хөкемен чыгаргандыр кебек тоелды.

Фәиз шуны белми — үзенең кыяфәте белән ул кешеләрне шикләнергә мәҗбүр итә. Үзе күршеләрне, бергә эшләүчеләрне ят итеп, алардан шүрләгәнгә күрә кешеләр дә аңа карата шундый ук мөгамәләдә лабаса. Моны Фәиз аңламый иде шул. Ул үзе куркып карагач, аның сәер чыраеннан башкалар да шүрли, моны исә ул күрә һәм тагын да ныграк курка һәм читләшергә тырыша. Шулай итеп, бозра тоташа һәм дә ул бозраны кай төшеннән өзәргә белмисең. Әле бит белмисең — өзеп буламы аны, юкмы.

Күршеләреннән качарга тырышса да, аны барыбер күрделәр һәм инде ничәнче тапкыр аның күңелендә давыл купканны тулай торактагылар чамаладылар.

Белсәләр белерләр, дип уйлады Фәиз караватына авып. Инде кеше күзенә карап, үзеңә карата нинди мөгамәләдә икәннәрен укырга тырышып, күзәтеп күпме яшәргә мөмкин?

Урамда караңгы төште. Бүлмәләрдә гөр килеп эшләп утырган телевизорлар тынып калды, коридорда бала-чага чырылдавы юк булды. Йөрәк тибеше генә калды. Әллә җан сулкылдавымы бу? Куркак җанвар булгач, җанмы ул, йөрәкме — аерма бармы соң?!

Тәмәке күп тартканнан һәм бик озак бер үк нәрсәне уйлаганнан сару кайнап, күңелләр болганды. Ашыйсы киләме? Юк. Бәлки эчәсе киләдер? Юк. Кызыл аракы бар бер шешә, бәлки аны бераз йотаргадыр? Аракы эчим микән әллә дигәндә һәрвакыт эчми калмый иде, бу юлысы шешәне ачып та тормады. Аек булырга кирәк. Коточкыч булса да, зур вакыйгалар башланырга тора.

Котүләре ай-һай авыр. Төрмәгә алып китүләрен көтеп утыру да читен икән! Төн уртасы җитте түгелме? Нишләп килмиләр? Ул, киемнәрен салмаган килеш, саргаеп беткән түшәмгә карап ятты.

Йокылы-уяулы саташып беркавым ятканнан соң күзләрен ачты. Сәгать ике тулган иде.

Салкын көзнең юеш кочагында ятим сыман бөрешеп йокыга талган поселокны сискәндереп кинәт машина тавышы ишетелде. Ерактан тоныкбулып. Фәиз сикереп торды. Ул инде милицияне көтеп ятуын онытты. Аның хәзер качасы килде. Кай тарафларга булса да йөгерергә, качарга, берәр баганага бәрелеп үлгәнче, берәр елгагамы, сазлыккамы батканчы, чабарга да чабарга!

Тулай торакны дөбердәтеп чыгып йөгерде. Һәм гөлҗимеш куаклары арасына кереп ауды. Бүлмәсенә керүләрен карап торырга булды ул. Бүлмәнең утын сүндерергә оныткан лабаса. Кабыздым микәнни дип уйлады ул. Кабызганмындыр инде. Аерма юк. Әнә машина килә. Әллә фаралар яктысына үзем йөгереп чыгыйммы? Мәрхәмәтлерәк булмаслармы? Машина тулай торак каршында, юлда туктады.

Фәиз аның эченнән кораллы кешеләрнең чыгуын көтте. Автоматлар белән чыгарлар кебек иде аңа. Бу мизгелләрдә курку да югалды кебек. Бары тик инде кемнеңдер, нәрсәнеңдер ихтыярына буйсынып, кайда кушсалар, шунда атларга әзерлек кенә калган иде.

Әмма тагын бер могҗиза булды шул мәлне: машинадан кичәге милиционер чыкты, барып уң як ишекне ачты һәм күтәреп диярлек бер хатынны үзенең кочагына алды. Рәмзия!

Рәмзия тулай торактагы күршеләре күрер дип куркып, ахрысы, тиз генә кереп китмәкче булды, ләкин милиционер аны кат-кат кочып үпте: битеннән, чәчләреннән. Ниһаять, ул аңа нидер пышылдады да плащын канатлар кебек җилфердәтеп, тулай торакның тынчу кочагына кереп китте.

Милиционер, никтер кат-кат иелеп, машина астына күз салды, тәгәрмәчләренә типкәләп чыкты, ниндидер көй көйләп машинасына утырды да тирә-якка фара яктылыгы бөркеп, төн үзәгендә гаип булды.

Ул белмәде: көләргәме, еларгамы? Ике куак арасына чалкан ятып бик озак күктәге йолдызларны күзәтте. Йолдызлар, сез бит шаһитлар. Җирдәге һәрнәрсәне, һәр вакыйганы тамаша кыласыз. Җир салкыны тәнгә ныклап үтә башлагач, торды да тулай торакка таба атлады.

Үтеп барышлый Рәмзияләрнең ишеген этеп карады. Ишек бикле булмаган, шыгырдап киң итеп ачылды. Рәмзия сискәнеп китте:

— Фәиз, синме? Уф, котымны алдың.

Хатын өстәлдәге түгәрәк көзгедән үзен карап утыра иде.

Фәиз ишек катында туктап калды, ишекне япты.

— Көзгедән ни күрмәкче буласың? — диде ул баздан чыккан тавыш белән.

Рәмзия аның кыяфәтеннән шүрләп калды.

— Синең хәлең начар, ахрысы? Бар, кереп ят бүлмәңә, — диде Рәмзия һәм көзгене читкә алып куеп, урыныннан кузгалды.

Фәиз аны тыңламады.

— Син көзгегә карап үзеңне акларлык сызыклар, мизгелләр эзлисеңме әллә? — диде ул хатынның куркуына сөенеп. — Көзгедән карап кына үзеңне аңлап булмый бит ул.

Рәмзия ни әйтергә белми карап торды:

— Син ни сөйләгәнеңне үзең аңлыйсыңмы? Саташасың түгелме син?

— Ә тормыш үзе саташу түгелмени?! Теге милиционер минем турыда сорашмадымы?

— Кайсы милиционер?

— Башыңны җүләргә салма. Кызыксындымы минем белән, юкмы?

— Нишләп кызыксынсын ул синең белән?

— Кем ул?

— Син бит беләсең аның кем икәнен.

— Камилме?

— Әйе. Сиңа кем булса да барыбер түгелмени?

— Ә Фәрит?

— Бар чыгып кит!

— Син бит Фәритне яратам дигән идең, аның алдында гаебем бар, шуны юасым килә дигән идең. Үкендең, офтандың бит син.

— Бар чыгып кит!

— Мин бит сине кызганып йөргән идем. Мин бит сине чиста кеше дип уйлаган идем.

— Ә синең ни эшең бар минем чистамы, юкмы икәнлегемдә? Син үзеңнең Нәркизәңне тикшер. Миндә синең ни эшең бар?!

— Ничек инде ни эшем бар?! Хәер, чынлап та. Мондый шлюха белән ник сөйләшеп торам соң әле мин.

— Үләксә! Мә, көзгедән кара кыяфәтеңне! Кешегә охшамагансың да бит. Карачкы. Сөйләшеп торган була тагын?! Кайдан килеп чыккан чиста, әхлаклы кеше.

Фәиз атылып чыгып китте. Бүлмәсенә кермәде, чөнки анда тыны бетеп үләр иде, мөгаен. Ул вак кына сибәләп торган яңгыр астында кая барганын да аңламыйча поселок урамы буйлап атлады. Аяклары аны Нәркизә яши торган урамга алып киттеләр. Бара торгач, ул аңлады: Нәркизә яши торган йортка таба бара. Ләкин ул аның янына кермәячәк. Кире борылачак. Нәркизә белән очрашырлык түгел әле хәзер. Әле Рәмзия әйткәннәрне ачыклап, аңлап, үлчәп нәтиҗә ясарга кирәк. Моның өчен саф һава, ялгызлык кирәк.

Нәркизә яши торган йорт янына җиткәч, ул туктады. Утлары юк. Йоклыйлар. Бик әйбәт. Ул кире атлады.

Чыннан да, минем ни эшем бар Рәмзиядә, Фәриттә, ниһаять, теге... Камилдә? Нишләп әле мин Рәмзиянең әхлаклымы, юкмы икәнлегенә битараф түгел?

Офтану, имеш. Нәрсә бирә соң ул?!

Алданды ул, алданды. Директор, Камил, Фәрит... Фәрит мескен хәлдә, аның өчен кем офтаныр? Нишләп офтану таләп итәм кешеләрдән? Әллә үземнең хәлгә кертәсем киләме барысын да? Гаделлек таләп итәм — өстен булмакчымын. Артык нык гадел булырга тырышу — үземне аңлар өчен һәр нәрсәне үз киштәсенә куярга ниятләү түгелме? Шул ук гөнаһ галәмәте түгелме соң бу? Өстен булырга? Ник өстенлеккә омтылам соң мин? Алар бит вак, түбән кешеләр! Ә минем кайсы төшем бөек соң? Сәбәпләрне кешеләрдән эзлим, юкса сәбәп үземдә бит. Мин бит беркайчан да кеше рәтендә була алмадым. Армиягә кадәр дә. Анда яңа частькә барганда косып, тончыгып оятка калдым. Барып җиткәч тә минем аркада сержантка эләкте. Аннары мин суккан кеше үтерүче булып унбиш елга төрмәгә утырды. Тикмәгә түгел бит бу. Ничек гаеплемендер, белгеле түгел, ләкин күңел сизә — гаебем бар алар алдында да. Тик менә нишләп гел мин гаепле булып калам?

Нәрсә санап утырган булам. ТЕГЕ ВАКЫЙГА бер үзе генә дә җитә бит минем хәшәрәт икәнлегемне исбатларга!

Аның хәтерендә моңарчы җыелып килгән төрле вакыйгалар кайнады. Һәр вакыйгада үзенең нинди дә булса гаебен танырга тырышты. Эзләде. Хәтердә гел куркыныч вакыйгалар гына калыкты. Саргылт түшәм коточкыч авыр пресс сыман тоелды. Менә ул акрынлап төшә, төшә, төшә һәм сытачак. Аның сытуына каршы түгел ул, ләкин куркыта, куркыта!

Ул атылып урамга чыкты һәм никтер беркавым пычрак юл буйлап йөгерде.

## 15

Күңеле сизде — бүген дә килә ул. Эче тулы нәфрәт кайнаса да, аның килүен теләде Фәиз, көтте. Аны күрергә кирәк, сораштырырга, сөйләтергә. Ләкин нәрсә сөйләтергә?

Бер яктан караганда, ул Фәритнең көтмәгәндә командировкадан кайтып керүен теләде. Чөнки ул үзенә карар бирде: Рәмзиянең хәзерге вакытта да хыянәт итүен сөйләргә. Икенче яктан караганда, Фәритнең кайтып керүе комачаулаячак. Камил белән сөйләшергә ул очракта бәлки мөмкин дә булмас. Камил Рәмзияне машинага утыртып маташкан чакта Фәрит кайтып керсен иде!

Фәиз кичә кереп Рәмзия белән әрләшкәненә үкенде. Рәмзияне кызганудан да түгел, үзенең хаксызлыгын аңлаудан да түгел. Мәгънәсез килеп чыкты кичәге ызгыш! Хәер, ничек мәгънәсе булмасын!

Караңгы төшкәч Фәиз урамга чыкты һәм, нниндидер зур вакыйганы көткән сыман, берсе артыннан берсен кабызып, тәмәке тартып арыбире йөренде. Әнә Рәмзиянең тәрәзәсе. Кашагасы ябылмаган, хатынның мәш килеп өй җыештыруы аермачык күренеп тора. Тыз-быз йөренүенә караганда, Камил килергә тиештер. Әнә өстәл артына утырып, күзге

каршында башын кыңгыр салды. Кашларын буйый, ахрысы. Килә, килә, нишләп килмәсен. Кабахәт! Аның килүе кирәк ләбаса, ник ачуым килә соң әле аның килүенә? Фәрит әле тагын бер атнадан соң гына кайтачак ди. Килә, килә, алар әле Фәрит кайтканчы очрашачаклардыр.

Кичәге сөйләшүдән соң Рәмзия саграк булырга тырышыр, машина каршына бәлки үзе чыгар. Шуңа күрә Камилне монда, машинасы туктау белән каршыларга һәм әңгәмәне башларга кирәктер. Ни дип башларга соң сүзне? Һич башка китереп булмый. Ярый, үзе башланыр әле шунда.

Фәиз машина янына ничек йөгереп килгәнен үзе дә сизми калды.

— Мин сине күптән көтәм,— диде Фәиз калтыранган кулы белән майорның җиңен йомарлап тотып.

Камил аптыраушта калды, исеректер дип уйлады.

— Синең белая горячкамы әллә?— диде ул җиңен ычкындырып.— Әгәр дә алай икән, хәзер илтеп ташлыйм тиешле урынга.

— Кая илтеп ташлыйсың мине? Әйдә, мин әзер, нәрсә карап торасың?— Фәиз кычкырып җибәрде.— Әйдә, мә, менә мин, син бит милиционер, әйдә тагын бер йолдыз өстәрләр погоныңа. Илтеп тапшыр мине!

— Фәиз, кит!— Рәмзия аларның арасына килеп керде.— Камил, син игътибар итмә, бу безнең күрше егетебез. Акылга бөтенләй үк тулы түгел ул.

Фәиз белә: аңардан шикләнеп йөриләр — имеш, бераз җитеп бетми. Рәмзия белән Фәрит тә аның сәерлегеннән шүрлиләр, шуңа күрә ул Рәмзиянең болай диюенә ярсымады. Аның майорны җилтерәтәсе, бугазына ябышасы килде.

— Ник бәйләнә соң ул миңа?— диде Камил кешеләрдән качып кына сөяркәсе белән очрашканда мондый тиленең килеп чыгуыннан, милиционер булса да, бераз каушабрак калып.

— Минем сине күптән күрәсем килә инде. Ниһаять, очрадың. Рәмзия, син бар, зинһар, бүлмәңә кереп тор. Мин сөйләшим әле Камил әфәнде белән.

— Кайдан белә ул мине?

— Миңа Рәмзия сөйләде синең турыда.

— Рәмзия?

— Тыңлама аны, Камил.

Фәиз авызын кыйшайтып елмайды:

— Менә Фәрит кайтсын әле. Менә ул тыңлар мине.

— Нәрсә кирәк соң сиңа? Мин бит сине хәзер отделга алып барып тапшырам. Для начала унбиш суткага утыртам.

Фәиз аның әйткәннәрен тиешенчә кабул итмәде — киеренкелек көчле иде. Шуңа күрә майорның янауына зур ригая бирмәде.

— Иптәш майор, синең белән сөйләшәсем бар. Аннары теләсә нишләтерсең.

— Рәмзия, бар, кереп тор алайса,— диде Камил.— Ә син әйдә машинага кереп утыр, машинада сөйләшербез.

Рәмзия тагын бер тапкыр:

— Тыңлама аның сөйләгәннәрен, Камил, авыру кеше ул,— диде дә тулай торакка кереп китте.

— Мин синең машинаңа утырмыйм! — дип кырт кисте Фәиз.

Машинага утырырга курыкты ул. Милиция машинасына утырса, язмышын кулыннан ычкындырыр сыман тоелды аңа. Камил дә көтмәгәндә килеп чыккан бу әрәкнең кыланмышларын төшенергә тырышты.

— Алайса, әйдә, сөйлә, тыңлыйм.

— Әйдә минем бүлмәгә,— диде Фәиз иң кырыйдагы тәрәзәгә ымлап.

Майор бермәл уйланып торгач:

— Әйдә,— диде.

Бераз шүрләсә дә, бу начар гына гәүдәле малайга бирешмәм дигән уй белән аның артыннан атлады.

Бүлмәгә кергәч Фәиз аны беркавым җентекләп күзәтеп утырды.

— Менә нинди икән син,— диде ул озын таза гәүдәле майорны башыннан аягына кадәр күзәтеп.— Мин сине башкачарак күз алдыма китергән идем. Утыр әле, зинһар.

— Нишләп син минем белән «сез» дип сөйләшмисең?— диде Камил урындыкка утырып.— Мин бит синең белән дуңгыз көтүе көтмәдем.

— Чөнки мин сине күптәннән беләм. Мин синең турыда инде бик озак уйланып йөрим,— диде Фәиз үзендә кинәт рух һәм көч тоеп.

Ул майорның бераз каушабрак калуын күрде, шуңа үзендә кыюлык, ышану тапты. Милиционер исә, сөяркәсенең кочагына дип барганда, көтелмәгән матавыкка юлыгудан, чынлап та, югалыбрак калды.

Фәиз икенче урындыкны аңа таба шудырды:

— Шикләнәсеңме миннән?

Фәизнең бу сорауны инде әллә ничә кешегә әллә ничә тапкыр биргәне бар. Майор белән әңгәмәне ул башкачарак башламакчы иде дә, булмады, гадәттәгечә килеп чыкты.

Камил, чыннан да, җүләр, ахрысы, дигән караш белән, сары чәчләре тузып, сирәк сакал-мыегы җиткән, болай да бигүк чибәр булмаган чыраен ямьсезләп күзләре эчкә баткан сәер затка текәлеп торды да:

— Шикләнәм,— диде.

Фәиз елмайган сыман итеп авызын бер кырыйга кыйшайтты:

— Ә нишләп кулга алмыйсың соң син мине?

Камил көлеп җибәрде:

— Кирәгең бар иде.

Аның шаяруы Фәизгә берничек тә тәэсир итмәде. Фәиз сөйлисе фикерләрен бер тирәгә туплап утырды. Аның ташып чыгарга торган уйлары озак көттермәде.

— Ни өчен кулларымны богаулап алып китмәгәнеңне мин беләм. Чөнки синең үз урының төрмәдә.

Майорның түземлеге чигенә җитте.

— Кем син?— дип җикерде ул.— Тилеме?

Фәиз курыкмады һәм тыныч кына дәвам итте:

— 1978 елны Зәбирне урман буенда куып җиткәч ни өчен кулга алмаганыңны да беләм. Хәтерлисеңме? Рәмзияннән көнләшеп син аның җинаятьче икәнен дә аңламагансың. Кибет баскан кешене ник кулга алмадың? Кулга алган булсаң, ычкындырмасаң, фаҗигага юлыкмый иде ул. Исән кала иде. Шуңа күрә, гаеп синдә дә бар!

Камилнең хәтерендә ул вакыйга.

— Аларны тоттылар да утыртып куйдылар инде,— диде Камил тыныч кына.— Ә нигә сине кызыксындыра әле ул вакыйга? Анда синең ни эшең бар?!

— Кибет директорының җинаятьләрен белә торып, аны кулга алмаганыңны да беләм. Алай гына да түгел, Рәмзиянең ирен ЛТПга утыртучы да син. Бигрәк кызык, бернинди җинаять эшләмәгән, чиста кеше булып йөрисең. Инде майор булгансың. Спецкомендатура начальнигы.

— Карале, мин синең иягеңне сугып сындырам хәзер. Аннары үзеңне гаепле итеп төрмәгә дә тыгып куям.

— Мин әзер!

Камил аңардан мондый тәвәккәллекне көтмәгән иде.

— Сиңа миннән нәрсә кирәк?

— Белмим. Фәкать сорауларым гына бар минем сиңа. Син кешеләр язмышында катнашып йөрисең. Бер җәзасыз! Уйланганың бармы бу турыда?

— Син мине оялтырга, намусымны капшарга маташасыңмы әллә? Маңка гына бит әле син, тормышны белмисең. Дөньяны аңламыйсың әле син.

— Син аңлыйсыңмы?

— Мин ничек яшәргә кирәклекне аңлыйм.

— Нишләп ювелирный директорына җинаять эше ачуларын таләп итмәдең?

— Мин бит ОБХССта эшләмәдем һәм эшләмим, мин гомерем буе спецкомендатурада эшлим.

— Син ОБХССтагы танышларың аша Рәмзияне шул директор яккан нахак бәладән коткаргансың. Үзеңә кирәк булгач. Мин Фәритне кызганам. Башка кешенең дә җаны бар бит, башка кеше дә уйлый, кайгыра, көнләшә, газаплана.

Майор урыныннан кузгалды:

— Син Фәритнең адвокатына әйләндеңме әллә, соңга калып кына булса да. Шушы гына идеме миңа йомышың?

— Кабахәт син!

Камил аңа җирәнеп карады:

— Фәләнемне чәйнәмә әле!

— Менә сине мин үтерер идем. Махсус. Һәм мөгаен гомерем буена бер генә тапкыр да үкенмәс идем. Мин сине күрәлмыйм. Мин синең белән сөйләшеп кайбер сорауларга җавап табып булмасмы дигән идем. Юк, синең кебекләр белән уртак тел табып булмый. Бу дөньяга капма-каршы яктан карыйбыз икән без. Миңа синдә фәкать нинди дер үкенү чагылышы гына күрү кирәк иде. ТЕГЕ ВАКЫЙГАДА синең дә өлешең зур бит. Мин гаепне үз өстемнән алып ташларга һич кенә дә җыенмыйм. Авыр миңа, мин күтәрә алмаслык йөк ул.

— Нинди вакыйга турында әйтәсең соң син?

— Зәбир синнән котылгач сазлыкка кереп батып үлгән. Ник ычкындырдың аны?

— Ә синең нинди гаебең бар аның батып үлүендә?

— Кибет басарга мин котырткан идем аны,— дип ялганлады Фәиз.— Ә бер гаепсез кешеләрне төрмәгә утыртулары сиңа нишләп берничек тә тәэсир итми?

— Синең ни эшең бар да, минем ни эшем бар! Кемне утыртырга тиеш булсалар, шуны утырталар. Син нишләп юкка баш ватасың?! Күп белмә, теләсә кая тыгылма, муеныңны сындырулары ихтимал. Кемнеңдер батып үлгәне өчен әллә кайдагы бер гаепсез кешегә бәйләнәсең.

— Юу-у-ук, синең гаебең зу-у-ур. Син бу дөньяда, бигрәк тә ТЕГЕ ВАКЫЙГАДА, иң төп рольләрнең берсен уйнадың.

Майор ишек янына җиткәч тукталды.

— Һич аңламыйм, ник үпкәлисең соң син миңа, нинди начарлык эшләдем мин сиңа?

— Син үзеңдә аз гына да гаеп сизмисеңмени?

— Җүләр! — диде майор инде нәфрәтләнеп.— Син юлымда миңа бүтән очрама!

Фәиз йөгереп барып майорның кулыннан тотты:

— Килмә Рәмзия янына бүтән! Аның ире бар! Фәритне кешегә санамыйсызмыни?

Камил әшәке итеп сүгенеп аны этеп җибәрде. Фәиз мәтәлеп башта караватына барып төште, аннары тәгәрәп идәнгә егылды.

Камил белән сөйләшү дә берниндн ачыклык кертмәде. Киресенчә, үзем тагын да тирәнрәк кереп кенә баттым. Чынлап та, мескен һәм хәшәрәт нәрсәдер инде мин. Әллә мин чыннан да җүләр микән? Җүләр булсам, ник эзләнәм, ник уйланам? Камил үзен гаепсез, чиста итеп хис итә һәм аңа беркем, бернәрсә комачауламый. Ул төкерә Фәриткә дә, миңа да, Рәмзиянең үзенә дә, дөньясына төкерә ул. Һәм дөрес, туры кеше булып, спецкомендатурадагы бәндәләрне тәрбияләү эшен алып бара. Гаделлек эзләп, сорауларыма җавап өмет итеп барган кешеләр мине йә сугып егалар, йә мыскыл итәләр, йә көләләр. Нинди нәтиҗә ясарга? Нинди дә булса нәтиҗә ясарга кирәктер бит. Юк, юк, болай ярамый. Ярамый дип... Ничек итеп көрәшеп карарга соң? Кем белән көрәшергә? Көчем бармы соң минем?

Уйланулардан туктап, ул тынлыкка колак салып ятты. Тып-тын. Уянмасын иде дөнья. Таң атмасын иде. Шушы тынлык кына мәңге хөкем сөрсә иде. Ә бит ул шулай булачак та. Мәңгелек тынлык ерак түгел.

Икенче көнне Рәмзияне очрата алмады. Кич белән бүлмәсендә икәнлеге ишетелде, ләкин керергә җөрьәт итмәде. Кинәт аңарда коточкыч теләк туды: Рәмзияне үтерергә! Ләкин шундук бу уйны куып җибәрде.

Аның нәфрәте һәрвакыт кинәт миһербанлылык белән алышына иде. Минуты белән ярсып, шундук йомшак күңеллегә әйләнә иде ул. Шулай да ул инде белә: Рәмзияне гафу итмәячәк. Рәмзия аңа бәлки беркем дә түгелдер. Шулай да...

Берничә көн узды, Фәрит шушы көннәрдә кайтырга тиеш инде. Беркөнне Рәмзия үзе бүлмәгә килеп керде. Аның кыяфәте горур, тәккәббер иде. Күренеп тора, ул аңа өстән карый.

Фәиз китабын урындыкка куйды һәм яткан урыныннан тормыйча гына:

— Ни кирәк? — диде.

Рәмзия иреннәрен чалшайтып беркавым карап торды.

— Фәриткә сөйлисеңме? — диде ул ниндидер янаулы тавыш белән.

Фәиз торып утырды.

— Сөйлим.

— Син үзеңнең бөҗәк, чүп икәнеңне беләсеңме?

Фәизнең үзәге куырылды.

— Син: «Фәритне яратам, кызганам! Аның алдында бурычым бар!» — дигән идең. Ник үзеңне, аны, мине, барчабызны алдап йөрисең?

— Синең ни эшең бар?! Нәрсә син шулкадәр әүлия булмакчымы әллә?! Синең мескенлегеңдә кем гаепле?

— Мин сине мондый кешедер дип уйламаган идем. Син миңа әллә ниләр әйттең, ә бит мин бу пычрак сүзләрнең барысына да лаек түгел бугай.

— Син кеше тормышына тыгылма!

— Син минем өчен чит-ят кеше түгел. Сез минем, Зәбирнең язмышында зур роль уйнаган кешеләр. Сез моны аңламыйсыз гына.

— Нинди роль? Син үзенең саташуларыңда мине дә катнаштырырга маташма инде, зинһар. Минем хыянәтче булуымда синең ни эшең бар? Мин үзем дә беләм кем икәнлегемне. Син нишләп кешеләрдән булмаслык нәрсәләр, сыйфатлар таләп итәсең?!

— Минем башым авырта,— диде Фәиз тыныч кына.

— Цитромон биримме? — диде Рәмзия шулай ук тынычланып.

— Кирәк түгел. Синең чыгып китүең генә кирәк.

— Фәриткә шулай да сөйләмә, яме.

— Кеше белән саграк булырга кирәк. Кешенең җаны бар, аңлыйсыңмы, җаны бар. Кешедән көлмәскә кирәк. Кешене яратмасаң яратма, ләкин мыскыл итәргә ярамый аны! Авырта бит җан, сызлый бит ул!

— Ә бер караганда миңа инде барыбер: сөйлисеңме Фәриткә, юкмы. Мондый тормыш та тормыш түгел инде. Төкерәм инде мин хәзер дөньясына. Син дөрес әйттең.

— Ашыкма төкерергә дөньяга. Синең хакың юк дөньяга төкерергә. Дөнья сиңа төкермәгәе.

— Сиңа әнә дөнья төкергән бугай.

— Әйе, чынлап та нык төкерде миңа кемдер.

— Фәриткә сөйләмә инде.

— Ярар.

Рәмзия чыгып китте.

Чыннан да, төпченгәндә башкаларга караганда чистарак һәм өстенрәк хис итәм түгелме үземне? Ниндидер бөеклеккә дәгъвам бар түгелме? Төпченүем кешеләрне аңлау өчен түгел, үземне аңлар өчен, ахрысы. Кем миңа хокук бирде кешеләргә бәйләнергә, аларны оялтып

маташырга? Гаепне үз өстемә генә алмас өченме? Бу бит ахмаклык бер уйлаганда.

Кайткан көнне үк Фәриткә барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Озак уйланмады бу турыда. Камил белән булган әңгәмәдән соң ук үзе өчен катгый карар кабул кылды: Фәрит белергә тиеш.

Фәритнең ышанасы килмәде. Ләкин Рәмзия үзе дә яшермәде. Ул көнне бүлмәләрендә каты сугыш чыгар дип уйлаган иде Фәиз, ләкин тавыш-тын чыкмады. Авыр иде аңа ул төнне. Намусы кушты аңа әләкләргә. Бәхетсезлеккә дучар булган бу гаиләнең киләчәге турында да күп тапкырлар уйланды ул. Рәмзиянең беренче мәртәбә сөйләшкәндә ачынып үкенүләре аңа башта соклангыч булып тоелган иде, ул хәтта дөньяда шундый кешеләр барлыгын күреп, илһамланып та киткән иде. Кешеләр арасында бөек хисләр бар икән дигән уй аны яшәргә өндәгән иде. Әмма бу ялган икән ләбаса. Рәмзия дә башкалардан ары китмәгән икән. Фәрит алдында гаебен танымаган. Ләкин гаебе бар микән аның? Гаебе юктыр дип уйлар идең, ул бит Фәритне бик яхшы белә. Ул бит Рәмзиясен гафу итеп, яратып яшәп ята аның белән.

Алар шул ук атнада аерылыштылар һәм икесе дә поселоктан киттеләр. Икесенең берсе генә дә аның белән саубуллашырга кермәде. Берсе дә каргамады да, рәхмәт тә әйтмәде. Фәрит тә кереп хушлашмады бит. Фәритнең киләчәк тормышы кешеләрчә корылсын өчен, аны бүтән мыскыл итмәсеннәр, алдамасыннар, аңа хыянәт итмәсеннәр өчен тырышты ул.

Мең кат үзенә сорау бирде ул соңыннан: дөрес эшләдеме Фәриткә сөйләп, әллә киресенчә яман эш кылдымы? Ни гаҗәп, бер генә тапкыр да бу адымы өчен үзен битәрләмәде. Ләкин һәрвакыт, минем хөкем итәргә хакым юк, дип кабатлады. «Кешедә изге хисләр, изге сыйфатлар, изге төшенчәләр кыйммәтрәк!» — диде ул үзенә-үзе. Фәриткә сөйләп дөрес эшләдем, ләкин шулай да... аларны хөкем итү бит бу. Юк, Рәмзияне хөкем итү бу. Ә Фәриткә җиңелрәк булырмы аннан башка? Башкаларны хөкем итәргә омтылуы аңа гомумән тынгы бирмәде. Бу капма-каршылыкны ул шулай ук чишә алмады.

## 16

Әчке халәтнең тигезлегенә ул фәкать аракы ярдәмендә ирешә башлады. Үзен хәмер ярдәмендә тигез рухта тоту аны хәйран тотрыклы рәвештә эшкә йөрергә, ашарга аппетитын булдырырга ярдәм итте. Нәркизә дә үзе янына гел кызмача килгәне өчен аны әрләмәде, чөнки аракы эчмәгән чагында ул бөтенләй караңгы, уйчан, кәефсез һәм ямьсез. Гаилә тормышы аракыны да ташлатыр, кәефен дә күтәрер дип уйлады ул. Бер-берсенә ияләшкәч, алар бер-берсен ярата, бер-берсендә мохтаҗлык тоя башладылар шикелле. Озаграк күрешмичә торсалар, бер-берсен сагыналар иде. Ярату шул түгелмени инде, дип уйлады Нәркизә. Ә Фәиз Нәркизәсез дөньям бөтенләй караңгыланыр дип, аның янына ешрак йөри башлады. Ул үзен булдыксыз итеп тоеп, кимчелекләр җыелмасын җиңә алмый җәфа чикте. Нәркизә, үзенчә булса да, аның халәтен шактый төгәл аңлады һәм акылыннан килгәнчә аның хәленә керергә, аңларга, ышанычын, бигрәк тә үз-үзенә ышанычын уятырга тырышты.

Алар 1982 елның язында өйләнештеләр. Әүвәле Чаллыдан Нәркизәнең әти-әнисе килеп аның белән танышты. Кияү ошамаса да, кызлары сайлаган кеше булгач, каршы әйтүче табылмады, ризалык белдерделәр. Туй ясап тормадылар. Язылыштылар да шуның белән вәссәлам. Чал-

лыга, Нәркизәләрнең ата-аналарына кунакка барудан Фәиз баш тартты. Нәркизә аптырашта калды, ләкин бергә яши башлагач, ныграк ияләшкәч, барыр, туганнары белән танышыр һәм аралаша башлар дип үзе генә Чаллыга кайтып барысын да тынычландырды.

Гаилә корып яши башлагач, Фәиз «күңел халәтем тигезләнер, үткәннәрнең авыр тәэсиреннән арынырмын» дип өметләнде.

Туган-тумачасы булмаган бер ялгыз карчык үлгәч, аның әле болай бик үк начар күренмәгән алты почмаклы йорты, каралты-курасы калды. Язылышкан көннәрендә үк аларга шул йортны бирделәр.

Яшьләрнең бәхетләре ташып чыкты. Һәм алар зур, якты хыяллар белән киләчәккә өметләр баглап яши башладылар.

Киләчәк хыялдагыча булмый шул ул. Өйләнешүнең шаукымы тиз арада үтеп китте. Чынбарлык кына калды. Шул чынбарлыкта яшәргә дучар ителү калды. Мәхәббәт тә өйләнешкәч башка төскә керә икән. Бармы ул, юкмы, әгәр дә бар икән, арттымы, кимедеме — тормыш мәшәкатьләре арасында аңлавы, абайлавы кыен һәм бәлки мөмкин дә түгелдер.

Газаплы уйлар Фәизне, гүя, якында гына сагалап йөргәннәр. Ул үзенең дүрт ел дәвамында кичергән, вакыты-вакыты белән килеп әсир итә торган халәтенә тагын бирешә башлады. Янәшәдә көн саен кеше булу аның өянәкләренә куәт өстәде шикелле. Хатын бала тапса, тормыш үзгәрер, дөнья яктырак төсләргә буялыр, дип тә уйлады ул. Ләкин вакыт үтә торды, ә балалары тумады.

Нәркизә аның сәерлегенә ияләшсә дә, сәбәбе бардыр дигән пошаманлы уй белән яшәде. Аның шикләнүен Фәиз, әлбәттә, сизенде һәм шунлыктан тагын да эчкәрәк, тирәнгәрәк бикләнде. Хатынының шикләнүен ул үзен гаепләү дип кабул итте. Көчсез, булдыксыз ир ахрысы мин, дип уйлый иде ул Нәркизәнең нәрсә дә булса аңларга тырышып, җентекләп күзәтүен сизенгәч.

Бер урын-җирдә янәшә йоклаучы хатының шикләнгәч, куркырсың да. Югыйсә җинаятенең, гөнаһының ачыклануын, башка берәүнең белүен теләсә дә, нык курыкты Фәиз. Югыйсә бит Нәркизәдән дә якынрак кешесе юк аның бу дөньяда. Юк, курыкты, нык курыкты. Нәркизәгә сөйләсәм, милициягә барып әйтерме? Юк, әйтмәс. Алайса ник болай нык курыкты соң? Әгәренки белсә, Нәркизә нинди адым ясар — шул куркытамы? Яратамы ул Нәркизәне? Шуңа күрә ташлар дип куркамы? Әгәр Нәркизә ташлап китсә? Җәза тиеш түгелмени аңа?

Ләкин аң астында серне ачуга каршы кемдер, нәрсәдер көрәште дә көрәште. Әкренләп көннән-көн коточкыч чиргә әверелеп барган халәтнең шул чир өчен көрәшүче көчләре серне сакладылар, беркемгә аны бирмәделәр.

Аракы, бары тик аракы белән генә үзен юата алды ул. Гаилә корып яши башлагач, аракы эчүне ташлармын дигән хыялы тормышка ашмады. Дөньяны ул тар гына тәрәзәдән, төшенкелек томаннары аша гына күрә башлады.

Гаилә тормышын алып бару бик авыр эш икән. Балалар булмаса да, уртак вазифалар, бер-берең алдында нindидер бурычлар зур бер йөкләмә сыман иде. Уртак тормышка дучар ителү — күңеленә тулган зур пошаманлыкны әкренләп сүтүгә бик нык комачаулады. Шул чишелмәгән зур мәсьәлә аркасында киеренкелек куеруы, йөрәк ярсуы кабынгалый башлады. Ярсу, нәфрәт бөтенләй вак, пүчтәк сәбәпләр аркасында туа иде. Юк кына сәбәпләр белән хатынына бәйләнеп бәйләнде, төрле шикләнүләр белән аны бимазалады.

Авыр булса да, Нәркизә түзде. Табигате буенча сабыр холыклы хатын һәрвакыт үзен кулга алып, иренең бөтенләй аклап булмаслык кыланмышларына түзүне кагыйдә итеп үзенә сеңдерде.

Фәизнең психикасы үзгәрешләр кичерүне дәвам итте. Үткәннәр өчен зур җаваплылык һәм гаеп хисе тою артты. Төшенкелек өянәкләре инде

элегрәк тә абайлана иде, ләкин хәзер өметсезлек, чарасызлык тою нык артты. Чөнки гаилә тормышында котылгысыз рәвештә барлыкка килгән көнкүреш таләпләре өлгерлекне сорады, ә үткәннәр өчен кайгыру аның активлыгын какшатты һәм ихтыярын киметте. Менә шушы капма-каршылык үзенең булдыксызлыгын, көчсезлеген тануны ныграк кузгатты. Элекке вакыйгалар өчен гаеп хисе һәм көчсезлеге тормыш авырлыклары каршында өметсезлек белән кушылды. Нәтиҗәдә, тора-бара, үз-үзен бәяләве түбәнәйде, үз-үзенә ышанычы кимеде.

Үзе дә сизмәстән, аның холкы кинәт кырысланды, әшәкеләнде. Гәрчә үзе аңламаса да, моның зур сере юк иде. Тормыш алдында көчсезлеген, дөньяга җайлаша алмавын ул каяндыр килеп чыккан ярсу холыксызлык белән капларга тырышты. Кирәкмәгән чакта да кычкыручанга әйләнде. Хатынынннан көнләшә башлавы да үзенә ышанмау, үзендә көч тоймаудан, адәм актыгы бит мин дигән хәшәрәт уйдан иде.

Хатынына кул күтәргән чаклары да була башлады. Монсы да үзенең көчсезлеге нәтиҗәсе иде.

Холкы начарлана башлау белән беррәттән, анарда гаделлек хисе, башкаларга карата артык нык таләпчәнлек, һәрнәрсәне идеальләштерүгә омтылу чагылды. Кешеләрдән чисталык, сафлык эзләде, гәрчә үзе әхлак кануннарына идеаль рәвештә туры килмәсә дә, башкалардан тулы гаделлек өмет итте.

Эштә аның белән бөтенләй аралашмый башладылар — ычкынган кешедән ераграк йөрү яхшы дигәннәрдер. Эшенең дә рәте булмады, шулай да аны кызганып тоттылар, кумадылар. Киресенчә, җинелерәк эшкә — капкада дежур торырга куйдылар. Көннәр буе китап укып утырырга бик җайлы булып чыкты яңа эш.

Көненә берничә тапкыр өянәкләре кузгала башлады, моны ул, әлбәттә, аракы күп эчү нәтиҗәсе, дөресрәге, махмыр галәмәте дип уйларга тырышты. Һәм инде әлбәттә «баш төзәтәм» дигән сылтау белән, аракы эчеп, өянәкне вакытлыча куып җибәрүгә гадәтләнде.

Аракы күпмедер дәрәҗәдә балансңа китереп, аны кеше кыяфәтенә кайтара иде.

Эчкечелекнең һәрбер очракта тирәнтен психологик сәбәбе булмый калмый. Юлдан язган бәндә шул сәбәпне юк итү чарасы буларак эчә аракыны. Эчкәч рәхәт икән, димәк, айныгач аңа читен. Яхшы тормыштан читен булмый бит.

Айныгач, тәннең хәлсезләнүен ул үзе күтәп ала башлады. Хәлсезләнүне күтеп алу үзе хәлне бетерә иде. Тора-бара, аракы эчкәннән соң, икенче көнне, шул авыр халәтне көтеп, куркып йөри торганга әйләнде. Курку хисе әлеге начар халәтне китерә, ә инде хәл авырайгач, курку тагын да көчәя, моннан хәл тагын да ныграк начарлана. Менә шундый коточкыч бождадан ул ычкына алмый җәфа чикте.

Йөрәк кысып, хәл бетеп, тәнне салкын тир каплап алгач, Фәизне үлем куркыта башлады. «Куркам микәнни үлемнән?» — дип уйлады ул. Юк, үлемнән түгел, башка нәрсәдән, үлем белән бәйле булган нәрсәдән курка иде ул.

Нәркизә аның чирләвен бары тик аракыдан гына күрде һәм башка хатыннар кебек үк ирен эчкәнгә битәрләде. Хәтта: «Әниләргә кайтып китәм!» — дип тә куркыта башлады.

Фәиздә кешеләрдән, аларның фикереннән курку көчле иде. Өйләнеп хатын белән тора башлагач күпмедер дәрәҗәдә башкалардан ким түгеллеген исбатлады ул. Ләкин балалары булмау, каралты-курасының начарлыгы, башкалар шикелле шабашка эшләп акча туплый алмавы аның кимлек тойгысын арттырды. Ялгыз чагында баш ватыр нәрсә кимрәк икән. Хәзер таләпләр чиксез күп, ә аларны үтәргә рухи мөмкинлек һәм дәрман юк.

Аракы эчкәч кенә күңелдә тигезлек урнашып, тәндәге спазмалар кими һәм депрессияләрнең кечкенә тәнлегеннән күренгән дөньялар ачылып,

яктыра иде. Ләкин айныта бит барыбер. Айнымыйча да булмый. Әмма айнулары ай-һай авыр ла.

## 17

Әберкөнне төнлә йөрәге каты авыртты. Йөрәк дарулары гына куркуны җиңә алмадылар, тын бетүне, йөрәкнең шашып тибүен туктатырлык дару табылмады.

Ашыгыч ярдәм машинасы бик озак килде. Бу вакыт арасында Фәиз инде йөз кат үлеп, йөз кат терелде.

Врачның:

— Нәрсә булды? — дигән беренче соравына Фәиз ничек җавап бирергә дә белмәде.

Күңелдәгеен аңлатып булмый, ә авыртуларны, тын бетүләрне сөйләргә сүз җитмәс кебек тоелды.

— Йөрәк... Тын бетә. Авыз корый. Тир бәреп чыга. Куркыта.

Ул өзеп-өзеп сөйләгән арада врач аның йөрәген тыңлады, пульсын тикшерде, телен карады, кан басымын үлчәде, кыштыр-кыштыр нидер язды.

Врач хатын аның сап-сары йөзенә карап икеләнеп торгандай булды.

— Нәрсә булды? — дип кабатлады ул соравын.

Әмма ләкин бу юлы инде әлеге сорауның мәгънәсе бөтенләй башка иде. «Нәрсәдән болай булдың соң син, япь-яшь егет? — дип сорамакчы иде, ахрысы, ул.

— Аракы күп эчтем мин,— дип пышылдады Фәиз.

Бу исә аның, чирнең төп сәбәбеннән ераграк китеп, аракы галәмәте дип уйларга тырышудан һәм шул ук вакытта врачның шушы коточкыч соравыннан котылырга ниятләнүдән иде. Нәрсә булды? Ул бит үзе дә аңламый нәрсә булганны. Аның врачтан сорыйсы килде: нәрсә булды?

— Ишемия,— диде врач хатын кырыенда шәүлә сыман утыручы япь-яшь шәфкать туташына.— Сине наркологиягә җибәрергә тиеш мин. Тик бу хәлдә анда алып бару дөрес булмас. Синдә — киеренкелек стенокардиясе. Терапиягә салырлар, мөгаен. Алып китәбез сине.

Әнә шундый диагноз белән ул бер айга якын Т. больницасында ятып чыкты.

Симптомнары ишемия чиренеке шикелле булганга күрә, шундый диагноз куйдылар аңа. Асылда исә сәбәп психоневрологик иде. Йөрәк терапиясеннән тыш, төрле тынычландыра торган дарулар кабул иткәч, хәле бераз җиңеләйде.

Тәкъдим ителгән даруларны даими эчеп торды, әмма аларның ярдәме тиешле дәрәҗәдә булмады. Йөрәк авыруы башланган дип нык курыккан иде ул. Дәвалаучы врач: «Нервыларыгызны ныгытсагыз, йөрәгегез начар түгел сезнең,— диде.— Сез әле яшь, яшәү рәвешен үзгәртегез, обстановканы алыштырыгыз, аракыны эчмәгез»,— диде. Бу, әлбәттә, куркуны киметте, чөнки соңгы вакытта, авырткан бер җирен кысып тотып, фәлән җиремдә чир башланды бугай, теге җиремдә ниндидер ялкынсыну, ахрысы, дип үзенең котын үзе алып яшәде. Тиз ышанучан һәм шулай ук шикчел, куян йөрәкле Нәркизә «юктыр» дип тынычландырасы урында, киресенчә, йөзенә куркыну чыгарып, ары-бире чабып дарулар эзләп, елап йөгереп йөрде. Аның шулай кыбырсуы Фәизгә җитә кала: үзе уйлап чыгарган чирләрне, тагын да ныграк фантазияләп, аңында көчәйтә. Больницада ятып чыгу бераз хәл кертсә дә баш, психика шул ук калды. Һәм инде әлбәттә уйлар, күңелдәге төеннәр шул килеш саклandылар. Больницадан нормаль кешеләр сыман чыгу аны куандырды. Димәк, бөтенләй чирләшкә түгел, әгәренки бөтенләй хәлсез кеше булса, әле яткырырлар иде. Чыккач дарулар эчүне дәвам итте. Ярдәме тиядерме, юкмы — аңлашылмады.

Хәлем бөтенләй үк начар түгел икән әле дигән уй белән ул тагын аракы белән «дуслашты». Нәркизәнең зарлануларын ул колагына да элмәде. Нәтиҗәдә, күп тә үтмәде, әкренләп больницага кадәр булган халәтенә кайтты. Нинди чир икәнен әйтерлек түгел — бүген бу җире авыртса, икенче көнне теге төше авырта торган булды. Гомумән, хәлсезлек, йөрәк тибешенең ешаюы нинди очракта, нәрсә ашагач башлана — анысын шулай ук әйтә алмады. Чөнки өянәк теләсә кайчан, хәтта төн уртасында да башлана иде.

Тора-бара аракы эчми калган көне бөтенләй булмый башлады. Аңы белән ул үзе дә, моны аңлап, нык пошаманга калды. Нәркизә кызганса да, кайвакыт кычкырып җикерә торган булды:

— Дәваланырга кирәк, тәмам эчкечегә әйләнеп беттең ич инде.

Аның бу кычкыруларына каршы эндәшмәде ул, чөнки хатыны дөрес әйтә. Үзе дә бу зәһәр еланнан ничек тә ычкынырга кирәклекне бик яхшы аңлый. Ләкин булмый бит.

Шулай да бер көнне кыюлыгын җыеп, наркологка барырга карар кылды ул.

Стационарга ятудан баш тартты. Аны өч елга учетка куйдылар да бер кап дару биреп кайтарып җибәрделәр. Моннан тыш ай саен барып наркологка күренергә мәҗбүр иттеләр.

Хисапта торуын торды, ләкин аракы эчүне ташламады. Унбиш көн генә түзде эчмичә. Алай гына да түгел, аның эчә торган дозалары арткannan-арта барды, ә исерүе кимеде. Соңга таба эчкән саен бөтенләй исерми башлады, бары тик, бертөрле үзгә халәткә кереп, аракы шаукымы чыгып беткәнне куркып көтеп утырырга гадәтләнде. Болай булмый, болай озак дәвам итә алмый иде.

## 18

Бергә тора башлаганнарына өч елдан артып киткәч менә инде, ниһаять, сөйләде хатынына. Шундук ишелеп өстән йөк төште кебек. Җиңеллек тоелмады шикелле, ләкин инде хәзер барыбер җиңелрәк булыр дигән өмет туды. Чөнки бу коточкыч хикәяне тыңлаган Нәркизәнең күзләре акаймады, ул кычкырып җибәрмәде, чыгып йөгермәде һәм иреннән өркеп почмакка посмады.

Күңелен ачып салгач, ул тынычланып китте. Нәркизәдә дә канәгатьлек беленде. Сөйләвен сөйләде, ләкин УЛ ВАКЫЙГАГА бәйле сораулар, мәсьәләләр бихисап һәм дә аларга кем җавап бирер. Нәркизә барыбер ВАКЫЙГАНЫҢ сәбәбенә төшенергә ярдәм итә алмаячак. Нинди сәбәбе бар икән соң — моны ул белми, ләкин күңел эзли, сәбәпне көн-төн эзли.

Нәркизәгә җиде ел буена үзендә асрап йөрткән нәрсә турында бәян иткәч, хатынының гадәттәгечә үзен тыныч тотуын күргәч, Фәизнең хәле яхшырып киткәндәй булды. Аппетиты яхшырды, битенә төс керде. Соңгы вакытта тәмәке тартканда күңеле болганып, саруы кайный иде, хәзер исә тәмәкене дә тәмләп тартты. Баш әйләнүләр бетеп китте.

Шулай да хатынына ул шактый вакыт сынап карап йөрде — ничек тәэсир итте икән сөйләгәннәрем, дип шөбһәләнде. Әле белгән юк, Нәркизә киләчәктә нинди мөгамәләдә булыр, чөнки хикәяне тыңлаганнан соң бит әле, аны тәгаен аңлап, асылына төшенеп үзендә бәя бирергә кирәк. Бу бит гадәти вакыйга түгел.

Хатынының мөнәсәбәте тора-бара үзгәрмәсме дип ул һаман көтә бирде. Нәркизә исә аңа кат-кат кабатлады:

— Кайгырма, Фәиз, гаепле түгелдер син. Коткара алмагач, нишлисең бит инде.

Ирен эчтән ашап йөргән нәрсәгә ул, ниһаять, төшенде. Чынлап та коточкыч вакыйганы кичерергә туры килгән аңа. Билгесезлек яман әйбер, хәзер инде, Фәизнең нәрсә белән чирләвенең сәбәбенә төшенгәч, барыбер күңел тынычрак.

Аның тынычландырырга тырышуына Фәиз гел:
— Коткармадым бит,— дип кабатлады.
— Коткара алган булсаң, коткарыр идең.
— Кулымны ныграк сузмадым. Ул мизгелне мин аермачык хәтерлим, тагын аз гына сузылган булсам, бәлки коткарган булыр идем. Аннары әле мин... торып йөгердем ич. Йөгердем, аңлыйсыңмы?
— Курыккансыңдыр. Вакыт узган инде, бернәрсәне дә үзгәртеп булмый.
— Булмый шул.
— Ә сәламәтлегең турында менә кайгыртсаң ярый. Болай җәфаланырга ярамый. Дәваланырга кирәк.
— Инде күпме больницада ятарга була?
— Күпме кирәк, шул кадәре ятарсың тагын. Гомерләр алда әле. Синең хатының бар. Әле, алла боерса, балаларыбыз булыр.
Әйбәт кеше бу Нәркизә. Ярый ул бар әле.
— Булыр микән балаларыбыз?
— Булыр, булыр. Син тынычлан гына. Барысы да әйбәт булырга тиеш.
— Ә кайда, ничек дәваланырга тиеш соң мин синеңчә?
Нәркизә әйтергә микән, юк микән дип беркавым уйланып торгач, тәвәккәлләде:
— Син психотерапевтка барып кара. Синең кан басымың уйнаклау, калтырану өянәкләре, тирләвең — һәммәсенең сәбәбе бер генәдер, минемчә.
— Мин аның сәбәбен беләм! Психотерапевтка дисеңме?
— Әйе, тикшеренергә кирәк. Әллә нинди профессорлар бар лабаса. Дөрес диагноз кирәк иң элек.
— Дөрес әйтәсең. Ябык биналардан курку, кояш астында йөрәк нык тибү, бер урында озак утыра алмау тикмәгә түгел бит инде.

## 19

Казан чын мәгънәсендә кайный. Казан аңа таныш. Бу кала белән аның күп уйлары, хисләре бәйле.

Психотерапевт, медицина фәннәре кандидаты, өлкән яшьтәге агай — күзлекле битендә бер генә җепселе дә селкенми торган тыныч кеше булып чыкты. Аны йомшак күңелле күршегә дә, нindiдер «чыбык очы» туганга да, танылган артистка да, муллага да, гадел судьяга да охшатырлык иде. Кыскасы, җыелма образлар иясе иде бу абзый. Аның нинди милләттән икәнлеген дә аңларлык түгел, әйтерсең лә, аның милләте гомумән юк. Карап торуга нindiдер якын, үз кеше кебек тоелса да, аңарда җитдилек һәм хәтта кырыслык та күренеп тора.
Психотерапевт күптәнге танышын очраткан сыман ягымлы итеп һәм шул ук вакытта профессионалларга хас җиңелчә корылык белән каршы алды.
— Исәнмесез,— диде Фәиз нык каушап.
Ул ишекне ябарга онытты, шундук исенә төшеп борылды, ишекне япты, ялгыш каты итеп шапылдатты һәм докторга карап гаепле елмаеп куйды. Елмаю килеп чыкмады, менә шундый җебек инде мин дигән сыман чыраенда гафу үтенү генә беленде.
— Рәхим итегез,— диде доктор егетнең каушавына игътибар итмәгән булып. Ә үзе инде пациентны ишек бусагасында пәйда булу белән үк җентекләп күзәтә башлады.— Исәнмесез. Утырыгыз.
Фәиз өстәл янына килеп докторның каршына утырды һәм шундук сикереп торып чыгып йөгерергә теләде. Ул хәтта качарга дип кымшанып та куйды. Психотерапевт та моны сизми калмады.

— Ерактан килгәнсез, ахрысы. Арыгансыздыр, тынычланыгыз, бераз хәл алыгыз. Тәнегезне бераз йомшартыгыз. Киеренке тотмагыз үзегезне.

Врач нәрсәдер язды, әллә Фәизнең бераз тынычланганын көтеп утыруы, әллә, чынлап та, язып бетерәсе нәрсәсе бар иде.

Фамилиясен, каян килгәнен сорагач, күзлеген төзәтеп:

— Тыңлыйм сезне,— диде.

Фәиз нәрсәдән башларга белми аптырады. Инде күпме вакыт бимазалаган чир турында тиз генә ничек аңлатмак кирәк? Шунысы бәла — ул бит үзе дә аңламый үзенең чирен.

Психотерапевт зур дикъкать белән пациентны күзәтте.

— Нәрсә борчый сезне?

Фәиз үзе белән алып килгән авыру тарихын өстәлгә куйды. Монда аның терапиядә һәм наркологиядә ятканда язылган күрсәтмәләр тупланган иде. Врач ул кәгазьләрне тиз-тиз генә актарды һәм үзенә әһәмиятле нәрсә тапмады булса кирәк.

— Хәлем бик начар минем,— диде Фәиз чак кына ишетерлек итеп, аның чыннан да, хәле юк иде. Доктор аның хәлен аңласын өчен, ышанырлык булсын дип, ул бераз ясалмалык белән дә әйтте бу сүзләрне.

Врач шул көе — какшамас һәм каушамас кыяфәттә пациентны «өйрәнеп» утырды.

— Ничегрәк инде ул «начар»?..

Фәизнең кинәт башы әйләнә башлады, чыгып йөгерү теләге тагын туды, ләкин торып йөгерә башласа да, ишек катына җиткәч егылыр иде, мөгаен. Торып китәргә ул үзендә көч тапмады. Докторның күзләреннән курыкты ул. Аның күз карашы бернинди яманлык вәгъдә итми, әмма сораштырып утыручы кешенең күзләренә карарга барыбер куркыныч.

— Йөрәк авырта, тын бетә. Йокы начар. Аппетит юк. Йөрәк нык кага. Куркам мин, куркам. Машинада утырып барганда да, кеше күп булганда автобуска керергә дә куркам. Кояштан куркам. Гомумән, эсседән йөрәк нык тибә башлый. Ябык биналар куркыта.

Фәиз өзеп-өзеп сөйләгәндә докторга карамады, чөнки ачыктан-ачык беркемгә дә боларны сөйләгәне юк иде аның. Кемгәдер бу турыда әйтсә, ул кеше аны гаепләр сыман иде. Доктор икәнен аңлый, ләкин барыбер куркыта — чит-ят кеше бит ул.

Ул сөйләгәндә докторның язып утырмавы Фәизне бераз тынычландырды. Әйткән бер сүзен язып барырлар дип тә курыккан иде ул.

— Хәлегез нишләп начар икәнне үзегез әйтә алмыйсызмы соң? — дип сорады психотерапевт тыныч кына.

Фәиз кинәт башын күтәрде: әллә бу доктор берәр серемне белә микән дигән уй сискәндерде аны.

Врач исә һаман тыныч һәм аның чыраеннан бернәрсә аңлап булырлык түгел иде. Докторга карагач шунысы анык аңлашыла: дошман түгел ул, дошман түгел. Бернәрсәдә дә гаепләргә җыенмый, ахрысы. Киресенчә, ярдәм итәргә телидер ул. Чөнки ярдәм сорап киләләр бит аңа. Әгәр явызлык эшли торган кеше булса, аның янына беркем дә килмәс иде.

Фәиз, уйларыннан көчкә арынып, текәлеп карап утыручы докторга эндәште:

— Нәрсә дидегез сез?

— Хәлегезнең начарлыгын үзегез нәрсәдән күрәсез?

— Сәламәтлегемне аракы эчеп бетердем бугай мин.

— Күп эчтегезмени?

— Күп.

Чирнең каршы торуы иде бу. Газапны яклый торган көчләр Фәизне инде әллә ничә тапкыр чыгып качарга өндәделәр, этәреп карадылар. Чирләвен аракыга сылтавы да чын сәбәпне яшерергә маташудан иде. Каршы тору көчләре бирешергә теләми, алар кешене гүргә керткәнче җәфаларга, изәргә, таптарга әзерләнгәннәр.

— Ә курку? — диде доктор һәм шундук курку турында сораганына үкенеп куйды. Ләкин сорау бирелгән иде инде. Пациент та алай начар реакция бирмәде кебек.

Шулай да үзенең чире турында әңгәмә башлау Фәиздә кызыксыну уятты, аның кинәт үзенең авыруы, интегүләре турында сөйләшәсе килә башлады.

— Куркумы? — диде ул, урындыгында җайлабрак урнашып. Моңа кадәр ул урындыкта бик җайсыз, кырыйга гына утырып тора иде.— Шул үземнең сәламәтлегем өчен куркудыр инде ул. Хәлем әйбәт чакта да менә-менә читен була башлар, авырый башлармын дип хәвефләнеп, көтеп йөрим бугай мин.

Доктор акрын хәрәкәтләр белән, ашыкмыйча гына аның йөрәген тыңлады, пульсын санады. Күзләрен, уч төбен, тән тиресен тикшерде.

Фәиз инде бүгенгә шуның белән тәмам, икенче көнне килерсең дип чыгарып җибәрерләр дип уйлаган иде. Ләкин бу әле башы гына икән. Доктор урындыгында киерелебрәк утырды да:

— Әйдәгез, авыр булмаса, үткән тормышыгызны сөйләгез әле,— диде.

— Ничек инде үткән тормышны?!

— Беркая да ашыкмыйсыздыр ич? — дигән булды доктор.

— Юк.

— Шулай булгач, ашыкмыйча гына, тәфсилләп сөйләгез, балачактан ук алып. Вакыт күп безнең. Ашыкмыйча гына.

— Аңламадым, нәрсә сөйләргә?

Врач бераз елмаерга булды һәм аның йөзе кинәт яктырып китте:

— Сез нинди врач янында икәнегезне аңлыйсыздыр дип уйлыйм. Мин психотерапевт. Безгә, гадәттә, тормыш авырлыкларын сөйләргә, кайгы белән уртаклашырга киләләр. Язмышларын сөйлиләр безгә, гадәттә. Бу сезгә дә, миңа да кирәк. Әңгәмәбезне дәвам итү зарур. Авыр булса, бүген сөйләмәгез.

Фәизнең сөйлисе дә килә, күптән инде кемгә булса да сөйлисе килә иде. Тик нәрсәне сөйләргә соң? Бөтен булган хәлләрне түгелдер бит инде?

— Ничек инде үткән тормышны сөйләп булсын?! — диде ул аптырап.

— Биографиягезне сөйләгез.

— Башыннан укмы?

Доктор тагын да яктырак елмайды:

— Әйе. Психотерапевт биографияне белергә тиеш.

Фәиз зур авырлык белән, аннан-моннан йолкып сөйли башлады. Сөйли башлагач ул кызып китте, үзенең сөйләвеннән тәм таба башлады. Игътибар белән тыңлап утыручы булгач, аңа сөйләү рәхәт тоелды. Сөйләгәннәре шактый алама һәм өзек-өзек булса да, күңелендә ул күтәренкелек сизде, әйтерсең лә, тыгызланган төен урнашкан җиргә якынайды. Гүя, коточкыч чабыштан соң финишка якыная. Хәтердә казынасы да юк иде, ташып чыгар дәрәҗәгә җитеп мөлдерәмә тулган хисләр моңсу һәм урыны-урыны белән куркыныч хикәя булып психотерапевт бүлмәсендә яңгырап торды.

Детдом. Казан. Армия. Гаскәрдән соң эчә башлавы. Шул эчүгә бөтен булган симптомнарын бәйләргә тырышып сөйләде дә сөйләде.

Күп нәрсәләр төшеп калды. Үзе теләп тә түгел шикелле, үзеннән-үзе нindидер иләк аша чыкты хикәясе. Биографиясен эчтә кемдер төзәтеп, йә киресенчә, бозып җибәргән шикелле булды.

Ул тирләп чыкты, бите алсуланды, спазмалардан арынган тәненә җылы булып кан йөгерде. Мускулларның киеренкелеге бетеп китте.

— Шул эчү аркасында чирлимдер инде мин,— дип тәмамлады ул сөйләвен.

— Аракы аркасында дип кистереп әйтмисез инде алайса? — диде доктор, пациентның сөйләвеннән канәгать калып.— Чөнки «чирлим» димисез, «чирлимдер» дисез.

— Аракыдан, аракыдан. Күп эчтем бит мин. Соңгы вакытта көн саен эчә башладым.

Доктор беркавым Фәизгә карап уйланып утырды. Ниһаять, әйтеп куйды:

— Эчүегез — нәтиҗә. Сәбәп түгел.

— Аңламадым?..

— Сез күңелдәге дискомфорттан котылыр өчен эчүгә тотынгансыз.— Ул аның авыру тарихын актарды.— Йөрәк начар түгел. Кайбер анализларда үзгәрешләр бар шикелле, ләкин андый читкә тайпылулар табигый хәл — функциональ үзгәрешләр нәтиҗәсе. Үзегезнең организмыгыздан гаеп эзләп йөрмәгез. Организмыгызда патология юк. Ә халәтегезнең начар булуы — функциональ күренеш.

— Чирдер бит инде ул?

— Функциональ чир,— диде доктор кырт кисеп. Хәбәрне пациент авыр кабул итмәсен өчен шундук дәвам итте.— Аның да сәбәбе бар, әлбәттә. Ә болай күңелегезне нәрсә борчый соң, конкретно?

— Иң беренче чиратта — шом, курку, хафалану. Сәбәбен дә белмим. Куркыныч.

— Шуңа аракыга ябышкансыздыр.

— Бәлки шулайдыр.

— Нәрсәдән дә булса котылырга тырышкансыз бит, шулаймы?

— Аракыны ник эчәләр инде,— дип иңнәрен сикертеп куйды Фәиз.

— Аракыны беркем дә тиктомалга күп итеп эчми. Алкоголизмның беркайчан да психологик сәбәбе булмый калмый.

Врачның кыяфәте, үзен тотышы, хәрәкәтләре, сөйләшүе зур көчкә, хәтта сихри кодрәткә ия иде. Шул ук вакытта аңа ышанып, таянып була шикелле тоелды.

Бик шомлы тынлык урнашты. Иң әһәмиятле мизгелләр иде бу — күп пациентларны күргән доктор өчен дә, дөньяда әле күп яшәмәгән булса да, шактый күпне күргән пациентка да.

Доктор беренче булып тынлыкны бозмаска тырышты. Бәлки бүгенгә җитеп торыр дигән уе да бар иде аның. Фәиз аның көтеп утыруын аңлады һәм сөйләргә булды. Бу кеше сатмас. Бу ак халатлы кеше инде, мөгаен, беләдер дә. Йөрәкне тыңлаганда ук аңлап алгандыр.

Алар шактый вакыт бер-берсен сынагандай карап утырдылар.

— Безне беркем дә ишетми,— дип әйтергә кирәк тапты доктор.— Син миңа ышанасыңмы?

— Ышанам,— диде Фәиз чак кына ишетелерлек итеп.

Фәиз сөйли башлады. Ишетелер-ишетелмәс итеп.

ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ сөйли башлады. Озак сөйләде. Елый-елый.

Үзенең биографиясен кемгә дә болай ук тәфсилләп сөйләмәгән иде әле ул. БУ ВАКЫЙГАНЫҢ һәр мизгелен сәгатьләр буе сөйли ала. Аның өчен инде хәзер тыңлаучы да кирәк түгел иде. Аның өчен доктор әллә бар, әллә юк. Бу — бер адәм баласының тәүбә-истигъфар кылуы иде. Аның бәян итүе кичеп чыккысыз моңлы бер җыр кебек иде. Кайвакыт үзенең коточкыч хикәясе аңа ләззәт тә бирә, иде бугай. Чөнки УЛ ВАКЫЙГА инде мәңгегә аныкы, аның бәгыренә тамыр җәйгән, аны йолкып ташларга маташкан суретта дә, бәгырьләрдән шарлап кан ага башлар, мөгаен. Аны сөйләве коточкыч авыр да, шул ук вакытта аны котылгысыз рәвештә сөйләргә мәҗбүр булу, кем беләндә уртаклашу, ни гаҗәп! — рәхәт тә иде.

Әле сөйләп бетергәч тә ул сулкылдап елавын дәвам итте. Дөресрәге, туктала алмады. Ә доктор аны тынычландырмады. Елау яхшы. Еларга кирәк. Күз яше агарга тиеш.

Фәиз көтте. Каршысында доктор барлыгын исенә төшерү белән көтә башлады: ни әйтер? Бу мәхшәрне ул ничек кабул итәр?

Психотерапевт бер дә аптырап калмады. Гаҗәпләнмәде. Баш чайкамады. Пациентына кушылып еламады. Фәиз бүлмәгә аның янына

кергәндә ничек утырган булса, шундый ук кыяфәттә тыныч кына утыра бирде. Доктор барыбер якын, үз кеше иде. Аның чыраенда да, кыяфәтендә дә берни үзгәрмәде.

Докторның битарафлыгы Фәизне бераз аптырашта калдырды. Доктор игътибарсыз тыңлагандыр да, сөйләгәннәремнең асылын аңламый калгандыр дип ул кат-кат үзен битәрләргә тотынды.

— Зәбирне мин үтердем, мин. Мин гаепле, мин. Аңлыйсызмы? Мин аны үз кулларым белән үтердем дип әйтсәм дә буладыр. Ник дәшмисез? Мин коткармадым аны, коткарырга теләсәм, мөгаен, коткарган булыр идем. Ник дәшмисез сез?

— Ә нишләп әле син бу вакыйгада фәкать үзеңне генә гаеплисең?

— Кемне гаепләргә тагын? Мин инде гаеплеләрне эзләп карадым бугай.

— Гомумән, сез өстегезгә тормышыгыздагы барлык вакыйгалар өчен гаепне алмакчы буласыз. Бөтенесе өчен бер кеше генә җавап бирергә тиеш түгел. Бер кеше генә гаепле булмый. Хәтта аерым алган вакыйгада да бер генә кеше гаепле булмый.

Фәиз шаккатып докторга карады:

— Карагыз әле, мин дә бит еш кына шулай уйлыйм. Минем бит инде әллә нинди конфликтлар булып бетте гаеплеләрне эзләп. Мин инде күп кешене рәнҗеттем бугай бәйләнеп, гаеп эзләп.

— Менә күрәсезме, монда да сез үзегезне гаепле итәргә маташасыз. Алай бөтен гаепне күтәрергә кирәкми. Дөньядагы барлык гаеп-хаталарны күтәреп булмый — шартлап сынасың, энекәш.

— Минем гаебемне беркемнең дә уртаклашасы килми бит.

— Беркем дә үз теләге белән синең гаебеңне бүлешмәс. Ярар, читкә китмик әле. Әйдә, төп вакыйгаңа кайтыйк. Син үзеңне инде кайчаннан бирле кибет басуда, каравылчының башына сугуда, дустыңны сазлыкта батыруда гаепләп җәфаланасың. Әйдә анализлап карыйк әле. Каравылчы исән. Урлаган әйберләр синдә түгел. Зәбир батып үлгән, аны син үтермәгәнсең. Җиде ел вакыт узган. Син шушы вакыт арасында искиткеч озын юл үткәнсең, син инде башка кеше. Үзең ул вакыйгага бәя биргәнсең, җиде ел вакыт узганнан соң шул ук проблема белән монда килгәнсең. Миңа психотерапевт буларак — бу факт бик кыйммәт, бу бик күп нәрсә турында сөйли.— Ул кинәт елмайды.— Шуннан соң бүтән кибет басканың юктыр бит инде?

Фәиз докторның шаяруыннан аптырап китте:

— Юк.

— Шулай булгач! — диде доктор тагын да киңрәк елмаеп. Ул алгарак иелеп тавышын әкренәйтте.— Мин сиңа ант итәм, беркемгә бернәрсә әйтмәячәкмен синең турыда. Курыкма. Кайгырма. Монда бернинди тупыйк юк, инде барысы да хәл ителгән.

— Зәбир исән түгел бит.

— Нишләргә соң инде хәзер?

— Сазлыкта кулымны аңа сузганда, никтер, ныграк сузудан тукталдым. Хәтта кулымны бөтенләй сузасым килмәгән шикелле дә булды бугай.

— Әйдә, бу турыда иртәгә иркенләп сөйләшербез. Казанда берәр туганыгыз бармы?

— Юк.

— Алайса стационарның неврозлар бүлегенә яткырып торам мин сине. Каршы түгелме?

— Каршы түгел. Палатада кешеләр күпме соң?

— Ә син курыкма кешеләрдән. Кешеләр белән аралашмыйча яшәп булмый. Бу дөнья, энекәш, кешеләр дөньясы. Әйдә, бүгеннән башлап кешеләрдән курыкмыйк. Үзең уйлап кара, әгәр кешеләр бер-берсеннән курка башласалар, ул очракта, мәсәлән, синнән дә куркырга тиешләр бит.

— Мин үземнән дә куркам бит.

— Иртәгә дәвам итәрбез бу турыда да. Үзеңнән курыкканга кешеләрдән куркасыңмы, әллә кешеләрдән курыкканга үзеңнән котың алынамы? Монысы да сорау бит әле аның. Күрәсеңме, сөйләшкән саен сораулар туа тора. Ә син берүзең бөтен сорауларга җавап эзләп йөрисең бу дөньяда. Кешеләрнең синең турыда ни уйлавы бүгенге көндә сине борчырга тиеш түгел. Кеше фикере, әлбәттә, әһәмияткә ия була кайчак, ләкин бүгенге халәтеңдә кешеләр синең турыда ни уйлаганы түгел, киресенчә, синең кешеләр турында нинди фикердә булуың үзең өчен алгы планга чыгарга тиеш. Аякка басар өчен. Бернинди фаҗига күрмим, энекәш. Әңгәмәбез дәвам итәчәк. Өч кешелек палатада тыныч кына ят, сиңа тел-теш, җил-яңгыр тидерүче булмас.

Шуннан соң доктор ак халатлы кызга эндәште һәм Фәизне өченче каттагы неврозлар бүлегенә урнаштырырга кушты.

Палатада ике кеше йоклап ята иде. Фәиз үзенең караватына барып ятты. Шул ук кыз аңа нинди дер таблеткалар алып керде, укол кадады. Биш минут яткандырмы-юкмы, ул тирән йокыга талды.

## 20

Икенче көнне иртүк әңгәмә дәвам итте.

Фәиз үзен битәрләгән саен доктор һаман аны яклап утырды.

— Ә курку ул, дустым, рухи биеклеккә ирешкән яисә омтылган кешеләргә хас. Хайваннарча, үзеңне бетереп курку турында әйтмим мин. Аннары, дөресен генә әйткәндә, бу халәтең, ничек кенә куркыныч булып тоелмасын, икенче күзлектән караганда, начар халәт түгел. Мин уйлыйм, синең киләчәгең зур, бөек булачак.

— Ник алай уйлыйсыз?

— Әллә тагы. Миңа сиңа карыйм да, шулай булыр шикелле. Бәлки таң калырлык эшләр гамәлгә ашырмассың, каһарманлыклар кылмассың. Шулай да, үзеңә бирелгән кайбер сыйфатларыңны югалтмассың, киләчәгең якты һәм киң булачак дип уйлыйм.

— Мин бит дустымны батырып үтергән кеше. Ничек яшәмәк кирәк?

— Коткара алган булсаң, коткарыр идең.

— Мин аңа кулымны ныграк суза алыр идем. Мине хәтта нинди дер көч тыйган кебек булды. Мин аермачык хәтерлим. Хәтта кулымны сузасым килмәгән шикелле дә булып китте.

— Боларын үзең уйлап чыгарасыңдыр инде?

— Юк!

— Кул сузу-сузмау мизгеленә бик зур игътибар бирәсең икән, алайса әйдә, ачыклык кертеп карыйк. Моның өчен безнең башыбызга беркем дә кереп сукмаячак, шулай бит. Сез аның белән ахири дуслар булгансыз, шулаймы?

— Әйе.

— Арагызда дошманлашу очраклары булмадымы?

— Юк алай. Дөрес, безнең ызгышкан-талашкан чаклар, хәтта сугышкан вакытлар булгалады. Ләкин беркайчан да ныгытып дошманлашмадык. Детдомда без иң тату, тугры дуслар идек.

— Кибеттән урлаган алтын-көмеш әйберләрне тулысынча үзеңдә генә калдыру теләге булмады диден кичә сөйләгәндә?

— Мин, гомумән, кибет басуга каршы идем. Кирәге юк иде миңа андый байлыкның.— Ул авызын кыйшайтып явыз елмайды.— Мин сезгә әйтергә онытканмын — ул бит чын алтын-көмеш булмаган. Ясалма товар урлаганбыз без. Фальшивый, бутафория.

— Ансында минем эшем юк инде. Бәлки аның чын алтын-көмеш булмавы яхшырактыр да. Әйтүе кыен. Алай кулыңны ныграк сузарга

теләмәвеңне тойгач, бу халәтнең эчке сәбәбен бәлки якынча гына булса да сизгәнсеңдер. Бәлки хәзер сизәсеңдер? Үзеңнең берәр версияң юкмы?

— Белмим инде.

— Шулай да, бәлки нык курыкканга күрә кулыңны ныграк сузмагансыңдыр? Сазлык бит. Андый хәлдә нык каушата бит ул. Нишләргә дә белмисең. Син дә бәлки каушап, куркып кына кулыңны сузмагансыңдыр? Тагын да алгарак, дустыңа табарак сузылсаң, бәлки үзең дә төшеп батар идең.

— Юк, әле тагын да сузылырга мөмкинлек бар иде, батмый идем!

— Аннары... кичә сөйләвең буенча, син торып йөгергәнсең. Куркып качаргамы, әллә дустыңны коткарыр өчен таяк яисә күсәк эзләргәме?

— Белмим.

— Кире килгәнсең аннары ул урынга.

— Әйе, кире килдем. Зәбир юк иде инде.

— Хәтерләмисеңме, кире килгәндә кулыңда таяк бар идеме?

— Юк, бернинди таяк юк иде кулымда.

— Бәлки аның сине берәр кайчан җәберләгәне, кыерсытканы булгандыр?

— Юу-у-ук, киресенчә, ул минем өчен җанын бирергә әзер булып мине яклый, башкалардан да җәберләтми иде.

— Тагын нәрсә әйтә аласың дустың турында?

— Тагын нәрсә инде. Аның турында сөйләүдән хәзер ни мәгънә? Төштә еш күрәм аны.

— Йә, йә, менә монысы кызык, ничек итеп керә төшләреңә?

— Мин гел бертөрле төшләр күрәм. Зәбир озын буйлы, чибәр, бөдрә чәчле илаһи зат булып, зиннәтле киемнәрдән, ниндидер калкулыкта басып тора. Янында чибәр кызлар чәчәк җыеп йөриләр. Үзе аска карап елмая. Минем дә шул калкулыкка менәсем килә, ләкин булмый, көчем җитми. Менә башлыйм, хәл бетә, тын кысыла, аяклар ойый. Шуннан соң мин гел каядыр — шәһәргәме, поселоккамы, кыскасы, ниндидер караңгы йортлардан торган шәһәрчеккә кайтам. Һәм туп-туры мунчага китәм. Сап-салкын мунчада болганчык су белән юынып утырам. Идәннәр дә, утыргычлар да таштан. Кайвакыт әллә нинди шәрә кешеләр йөри мунчада, миңа сәерсенеп карыйлар. Мондый төштән соң уянып киткәч, көне буе авырып йөрим.

— Гел шушындый төшләр керәме?

— Әйе. Гаҗәп!

— Психотерапевт өчен бу аңлашыла торган, күп нәрсәне ачыктан-ачык әйтеп бирә торган гап-гади төш. Мунчадан башлыйм. Салкын мунчада пычрак су белән юынып утыруың — бу дөньяда сиңа җылылык, игътибар җитмәүнең физик чагылышы. Бу дөнья сиңа чит-ят, кешеләре белән уртак тел табалмыйсың. Салкын мунча — җылылык җитмәүдән.— Доктор сораргамы, юкмы дип шактый уйлап торды һәм тәвәккәлләде.— Ул көчле, җитез, абруйлы егет булган, шулаймы?

— Әйе.

— Кызлар аны ярата торган булганнардыр инде?

— О-о-о, кызлар үзләре аның артыннан йөгереп йөриләр иде.

Доктор чак кына алгарак иелеп пышылдады:

— Ачуың килә идеме?

— Кызлар гел аның тирәсендә бөтерелгәнгәме?

— Әйе.

— Бераз бар иде инде.

— Димәк, көнләшү булган?

— Дөресен әйткәндә, ахири дустым булса да, көнчелек хисе кичерә идем, чөнки мин аңардан күпкә калыштым. Күпкә өстен иде ул миннән. Теләсә нинди компаниядә ул үз кеше, телгә дә оста иде. Ләкин бик якын дуслар идек, мин көнләшүемне аңа сиздермәдем беркайчан да. Аннары, мин аңардан бик күп сыйфатларым буенча калышсам да, ул мине үзе

белән тиң күрергә тырышты, беркайчан ким-хур итмәде. Әле миндә өмет бар: бу дөньядан ул миңа үпкәләп китмәгәндер. Чөнки төшләремә елмаеп керә бит.

Доктор бу моментны ычкындырмаска булды:

— Әлбәттә, бу бик әһәмиятле күренеш. Менә бит, үзеңне акларга сәбәп бар. Елмаеп керә. Димәк, син үзеңне бөтенләй үк гаепле итеп санамыйсың?!

Доктор бу җөмләне кат-кат кабатлады, пациентның аңына сеңдерергә, үзен-үзе битәрләмәсен өчен нигез бирү максатыннан аны акларлык һәрбер мәлне файдаланырга тырышты.

— Мин гаепле булмыйча тагын кем соң?

— Ярар, ярар, һаман бер балык башын чәйнәмә инде, энекәш. Миңа тагын бер нәрсә ошамады әле. Син дустыңны тора салып үзеңнән өстен, мин аңардан калыштым, аның кебек була алмадым дисең. Ә бит синә башка кешеләрдә сирәк очрый торган сыйфатлар салынган. Син әле үзеңнең кадереңне генә белмисең. Мин ышанам, тора-бара үзеңә тиешле бәя бирәчәксең, үзеңне бәяләргә өйрәнәчәксең. Төшенкелектә калуың да яман нәрсә түгел. Дөрес, синең өчен авыр, коточкыч халәт, ләкин синең чирең — синең духовность ул, энекәш. Рухи байлыгың. Теләсә кемгә бирелми бит ул. Мин белмим, җәза итеп биреләме ул, бүләк итепме, ләкин шуны беләм — һәркемгә дә бирелми.

— Мин гомер буе авырып йөрермен микәнни?

— Юк, син инде кризистан чыгарга бер адым ясадың, монда килдең. Бергәләп ерып чыгарбыз дип уйлыйм. Бернинди фаҗига күрмим. Яшәргә кирәк. Яшәүнең мәгънәсен табарга кирәк. Дөнья барыбер алай ук начар, пычрак түгел ул. Сиңа бүген дөнья караңгы булып тоела. Юк, дөньяның якты чаклары да җитәрлек, энекәш.

— Көчсез бит мин, терелеп булырмы?

— Ә син чирлемени?

— Үзегез әйттегез бит.

— Мин сине чирле димәдем. Аннары, үзеңне көчсез диюдән тукта. Беренчедән, син көчсез түгел, киресенчә, мин синдә искиткеч зур көч күрәм. Икенчедән, көчсез булган сурәттә дә, нигә көчсез булудан куркырга?! Кем ничек үлчәгән, кем көчле, кем көчсез икәнне?! Син үз-үзеңә бәйләнүне ташла. Болай да инде озак вакытлар үзеңне булдыксыз, бернигә яраксыз дип санап, үзең уйлап чыгарган читлеккә үзеңне бикләп куйгансың.

Фәизнең күзләре тагын яшьләнде:

— Нишләп күптән монда килмәгәнмен.

— Ярый, ярый, хәзер килүең дә әйбәт. Димәк, вакыты җиткән. Әңгәмәне туктатып торыйк. Үзеңнең хәзерге халәтеңне аңлыйсыңмы? Нәрсә бара күңелеңдә, организмыңда?

— Юк, аңламыйм.

— Дәваланырга исәп бармы?

— Шуның өчен килдем дә инде мин.

— Мин сине ун көнгә стационарга салам. Аннары күз күрер. Бергәләп тырышсак, ныгытып аякка басарсың, дип уйлыйм. Чөнки бу дөньяда яшәү җиңел түгел, шуңа күрә аякта нык басып торырга кирәк, ә инде аякта нык тору өчен тотрыклы күңел халәте кирәк.

Доктор якты итеп елмайды, аңа ияреп Фәиз дә елмаерга үзендә көч тапты.

Докторга күп нәрсә аңлашылды. Ләкин саклык кирәк. Пациентның болай да эчке каршы торуы куәтле, аны куркытырга ярамый — үзенә «кереп» бикләнүе ихтимал. Ачыктан-ачык сәбәпне аның әйтеп бирергә хакы юк. Пациент сәбәпне аңлауга үзе якынлашкан, аңа фәкать ярдәм итәргә генә кирәк — үзен аңласын. Әле әңгәмәләр күп булачак. Сазлык тирәсендә йөрүләр, ул коточкыч вакыйга турында уйланулар, пациентка

авыр булса да, әле дәвам итәчәк. Бу очракта ул вакыйгага ачыклык кертү кирәк, чөнки шунсыз егетне аякка бастыру бәлки мөмкин дә түгелдер.

Дустына караганда көчсезрәк, ямьсезрәк булуы пациентны рәнҗеткән, дустына карата көнчелек хисләре кичергән. Әмма ләкин якын дуслар булу сәбәпле, пациент ул хисләрне «куган», юк итәргә омтылган. Көнләшүләрен һәм көрсенүләрен гел этеп чыгарган. Ләкин психиатрия әйтүе буенча, этеп чыгарылган хисләр тышка чыгып гаип булмыйлар, алар аң астындагы «мин»гә җыелып туплана икән һәм теләсә кайсы вакытта теге яки бу формада бәреп чыга. Бәреп чыгар өчен сәбәп яисә мөмкинлек кенә кирәк. Гадәттә, аң астыннан бәреп чыккан андый эмоцияләр агрессив рухта була ди.

## 21

Фәиз урнашкан өч кешелек палатада көне-төне йоклап ята торган бер карт кына бар иде. Күрәсең, аңа махсус шундый препаратлар бирәләрдер, уянгач ашый да тагын йокыга китә, тирә-якка бөтенләй игътибар итми.

Фәиз, ниһаять, докторның исемен белде — Шандыров Рафаэль Марсович. Нинди милләттән икәнен кем белгән? Кирәк микән аның милләттен белү? Әле мондый кешене Фәизнең беренче тапкыр очратуы. Дөньяда бар шул яхшы кешеләр дә. Ул чын психотерапевт икән. Галим. Эчкечеләрне дә дәвалый икән. Фәизнең исенә Гөлүсә төште. Менә аны табып алып килергә иде монда.

Аның үзендә дә, аракыны инде берничә көн эчмәгәнлектән, хәмергә сусау башланды. Башы авыртты, әйләнде. Авыз кибеп, күңел болганулар еш кабатланып торды. Ярый әле йоклата торган дарулар бирделәр, югыйсә төнлә йоклап булмас иде. Бераз тынычлану булса да, курку бетмәде.

Бер атна ятканнан соң Нәркизә килеп китте. Ирен стационарга салуларына сөенде шикелле. Аны күрү Фәизнең дә күңелен күтәрде.

Диагнозны Шандыров әйтте, ләкин ул бик катлаулы латин сүзләреннән торганлыктан, Фәиз аны исендә калдыра алмады. Дөрес диагноз гына билгеләсеннәр инде берүк! Тиешле дарулар гына бирсеннәр!

Әңгәмәләр көн саен үткәрелде. Рафаэль Марсовичка сазлык тирәсендә әңгәмә башлап торырга да кирәк түгел иде, Фәиз үзе һәрвакыт шул сазлык тирәсендә йөрде, гадәттәгечә, үзен битәрләде. Һәм Шандыров отыры аны чын сәбәпкә якынайтты. Фәиз акыллы егет, аналитик фикерле егет, шуңа күрә докторга чын сәбәпне аңа ачыкларга ярдәм итү алай бигүк кыен булмады.

Күп нәрсә ачыкланды. Ул үзе өчен зур ачыш ясады. Беркөнне, ниһаять, докторга ул үзенең иң мөһим соравын бирде:

— Көнчелек нәтиҗәсе булды микәнни?!

— Булуы ихтимал.

Турыдан-туры «Әйе» дип җавап бирергә ярамый. Пациент инде иң кирәкле, иң әһәмиятлесен аңлады. Психотерапевт аңа турыдан-туры әйтергә тиеш түгел, чөнки аның да ялгышуы ихтимал. Пациентның үзенә ышанырга, аның үзенә анализларга мөмкинлек бирергә кирәк. Шандыров бары тик өстәп куйды:

— Шулай шул, кешенең аңы — айсбергның өсте генә. Аның төп өлеше аста, подсознаниедә ята.

Һәм ул уйга чумган булып кыланды, имеш, башка уйлар белән мәшгуль. Ә үзе исә пациентның хәрәкәтләрен, кыяфәтен, гомумән, үз-үзен тотышын күзәтте.

Фәизнең күңеле өчен бу зур вакыйга булды. Соңгы көннәрдә бары тик шул турыда гына уйланды. Чынлап та шулай микәнни? Кулымны ыграк сузарга мөмкинлек булган килеш... Көнләшү булмый нәрсә булсын.

Тикмәгә сәбәбен аңларга тырышып йөрдемени ул? Димәк, дустыннан «калышу» эзсез узмаган, җыелып йөргән.

Ул үзендә акланырлык хисләр тойды. Спазмалар кимеде. Тәен чишелде кебек. Озак вакыт кан кермәгән урыннарга, тәнгә рәхәт биреп, җылы йөгерде — әллә дарулардан, әллә ачыш ясаганнан. Гаепле түгелдер алайса мин, дип уйлады ул. Аңым эше булмаган бит сазлыктагы каушавым. Коткарудан баш тартуым аңлы рәвештә эшләнмәгән икән бит. Подсознание ди бит. Доктордан ул кат-кат сорады, төпченде. Шандыров исә һаман шул тирәдә йөрде. «Әйе» дип тә әйтмәде, «юк» та димәде, хәйләкәр рәвештә, әңгәмәне оста гына корып, тиз генә түгәрәкләп куя торган булды.

## 22

Кайткан көнне үк ул сәер шатлык һәм гаҗәпсенү белән ТЕГЕ ВАКЫЙГАга бәйле уй-кичерешләренең асылы турында Нәркизәгә сөйләргә тотынды. Озак сөйләде. Ләззәтләнеп.

— Кеше үзе аңламыйча да әллә нәрсәләр эшләп ташлый икән бит,— дип тәмамлады ул кызып-кызып сөйләвен.

— Анысы билгеле инде.

— Зәбирдән көнләшүем ТЕГЕ ВАКЫЙГАДА подсознаниедән килеп чыккан, ахрысы.

— Ә кем әйтте сиңа?

— Үзем аңладым.

— Врач нәрсә диде?

— Аның ни дию миңа инде хәзер әһәмиятле түгел. Мин аңладым. Үзем аңладым. Кулымны ник сузмаганымны аңладым мин. Исемә төште. Мин игътибар гына бирмәгән булганмын. Минем инде бу турыда бер китаптан укыганым да бар иде.

— Ышанмыйм, әллә нәрсәләр язалар хәзер,— диде Нәркизә, ире тагын үзен битәрләргә тотынудан куркып.

— Кеше үзенең күпме эшен аңламыйча эшли. Мин соң әллә гаепле түгелме?

Нәркизә аның сүзен җөпләргә ашыкты:

— Юк инде, юк. Гаепле булсаң, врачлар синең белән алай әйбәт сөйләшерләр идеме? Мин бит инде сиңа кайчаннан бирле әйтеп киләм: юкка бимазалыйсың үзеңне.

Фәиз бер ноктага текәлеп мыгырдады:

— Юк шул менә, бимазалануларым тикмәгә булмаган. Кулымны сузып бетермәгәнемне аермачык хәтерлим бит мин. Менә, ниһаять, аңлашылды инде. Аңсыз рәвештә кулымны бирмәгәнмен икән. Ә шулай микән соң? Ялгышмыйм микән мин? Әллә акландым микән? Алай булса, өстән йөк төшәргә тиеш бит. Йөк төшкәндәй түгел бит әле. Аң астыннан боерык шундый булгач, Алла эше түгел микән соң бу? Дөньяда бөтен нәрсә Алла эше ләбаса.

— Тагын башыңны катырырга утырма инде. Хәлең бераз яхшырып кайтканга сөенеп кенә яшә. Аракы эчмәсәң бүтән.

— Эчмим, эчмим.

— Тәмәкене дә ташла.

— Ташлыйм, ансын да ташлыйм.

— Күптән барасың калган психотерапевтка.

— Әйтмә дә.

Хәле барыбер җиңел түгел иде аның. Соңгы вакытта көн саен аракы эчүгә күнеккәч, организм дискомфорт кичерде. Эчтә савыгуга каршы көрәш алып барган көчләр, организмның хәмер таләп итүенә кушылып, барыбер чирләтергә тырыштылар. Ләкин үзәктә өмет кабынды, терелергә, дәваланырга кирәк дигән карар һәм дәрман бирде. Үзеңне-үзең аңларга мөмкин дигән фикер мең шифага ия иде.

Фәиз аракы эчмәде, түзде. Эшкә дә атлыгып йөри башлады, чөнки МТСта да аңарда үзгәреш сизделәр, аларның игътибар белән караулары элек куркытса, хәзер исә Фәиз моны яхшыга юрый башлады. Ул һаман капкада дежур торды. Илһамланып китеп авыррак эш тә сорады, чөнки слесарь булып эшләгәндә ул акчаны күбрәк ала иде.

Аның күтәренкелеген күрше-күлән, таныш-белешләре күрде. Алар барысы да аракы эчүне ташлаганнан дип уйладылар.

Нәркизә дә тынычланды, аның үз-үзен тотышы шулай ук үзгәрде, хәрәкәтләре, хәтта адымнары ныгайды шикелле. Бәлки Фәизгә генә шулай тоелгандыр. Ничек кенә булмасын, иренең терелеп, җанланып китүе аңа да уңай тәэсир итте.

Тик менә ничектер сәерләнебрәк китте Нәркизә. Иренең ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫң чын сәбәбенә төшенүе, бигрәк тә сәбәпнең асылы, ничектер гайре табигый сыман тоелгангамы, шуны уйлап әле тәгаен аңлап бетермәгәнгәме, әллә иренең күпме еллар дәвамында газап чигеп яшәүләрен күзалдына китереп аны кызгануданмы — аңарда уйчанлык арткан сыман булды.

Күзләрендә барыбер шатлык күбрәк чагылды Нәркизәнең — ул да бит үзенең соравына җавап тапты. Менә Фәиз дә аякка басар, аракысын эчмәсә сәламәтлеге ныгыр.

Ләкин Фәиз аракыга каршы көрәшердәй көчләрне әле үзендә тапмады. Тагын салгалый башлады. Күңел күтәренке булгач, аракы да тизрәк исертте. Нәркизә аны кире Казанга барып, эчкечелектән котылырга үгетләде. Моны Фәиз үзе дә күптән аңлап йөри ләбаса.

Газаплы уйлар белән авырып йөргән дәвердә организм нык бетерешкән, бу йончыгуны тиз арада гына җиңәрлек түгел иде. Шулай да инде хәрәкәт башланды.

## 23

Таныш кабинетның ишегендә «Шандыров Р. М.» дигән язу күренмәде. Фәиз кысып кына ишекне ачып карады. Өстәл янында таныш түгел врач белән олы яшьтәге бер хатын (пациент ахрысы) утыра иде. Фәиз авызын ачарга да өлгермәде, врач, кулындагы кәгазьдән күзләрен алмыйча гына, кырыс тавыш белән боерды:

— Ябыгыз ишекне!

Бу кабинетка кергәндә ничәмә көннәр зур өметләр баглап, шатлык белән, ышану һәм бала чакта ук каядыр югалып калган могҗизалар вәгъдә итә торган урынга аяк баскан кебек була иде. Ә бүген бу кабинеттан башка төрле аваз ишетелде. Фәиз югалып калды.

Яныннан үтеп баручы ак халатлы кыздан сорагач, мәгълүм булды: Шандыров киткән. Монда эшләми ди хәзер.

Якын кешесен югалткан хис белән Фәиз кайсы бүлмәгә, кем янына керергә белми аптырап торды.

— Гафу итегез...

Яшь врач туктап борылды:

— Әйе, тыңлыйм сезне?

— Миңа Рафаэль Марсович кирәк иде.— Ул туктап калды.— Минем сезне кайдадыр күргәнем бар, ахрысы.

— Миңа да сезнең йөзегез таныш,— диде врач һәм кашларын җыерып хәтерендә казынды.— Исемегез Фәиз түгелме?

Үзенең исемен ишетүдән Фәиз чак кына сискәнеп китте:

— Әйе.

— Бик яхшы. Мин сезне күптән күрергә телим. Очрашуыбызга бик шатмын. Берәр проблемаң бармы әллә?

— Кем соң сез?

— Син, моннан җиде ел чамасы элек, мин әле студент вакытта мин яши торган фатирга килгән идең.— Врач елмайды.— Егерме биш сум акча тотып. Әтием биргән булган сиңа. Тузынып чыгып киткән идең, хәтерлисеңме? — Ул көлеп куйды.

— Марат?!

— Нәкъ үзе. Әйдә минем бүлмәмә. Иркенләп сөйләшербез.— Алар коридор буйлап атладылар.— Бик шатмын, бик шатмын. Мин бит сине күптәннән эзлим.

Тар, кысан бүлмәдә өстәл, урындыклар, ике тумбочка гына бар иде.

— Әлегә менә шушында кабул итәм,— диде Марат бераз көрсенгән сыман.

— Син дә психотерапевтка укыдыңмыни?

— Мин институтны тәмамлагач Ленинградта тагын укып кайттым.

— Рафаэль Марсович кайда соң?

Марат авыр сулап куйды:

— Яхшы кешеләрне беркайда да озак тотмыйлар шул. Башка җиргә күчерделәр аны.

— Кая?

— Ансын белмим.

— Миңа ул кеше бик кирәк иде.

Чынлап та, Фәизнең Шандыровны һич кенә дә югалтасы килмәде. Ул үзенең иң изге серләрен аңа ачып салды лабаса. Ул гына аңлар кебек аны.

— Кайда соң ул? — дип кабатлады Фәиз.

— Казаннан китте бугай инде ул.

— Ул миңа бик нык ярдәм иткән иде. Ул мине аңлады. Кызганыч. Бәлки, кайтыр?

— Анысын әйтәлмыйм. Нинди ярдәм кирәк сиңа? Бәлки, мин булыша алырмын.

— Мине ник эзләдең соң син?

— Әтием үлде бит,— диде Марат, кинәт караңгыланып.

— Беләм.

— Каян белдең?

— Сезнең поселокка барһач, кереп чыккан идем.

— Әтием ничек тә булса табып, сиңа ярдәм күрсәтүемне үтенгән иде. Әле нык авырый башлаганчы ук. Инде урын өстендә ятканда да кат-кат кабатлады. Аннары мин үзем дә аңлыйм синең алдыңда нинди бурычым барлыкны. Теге вакытта килеп китүең миндә үкенечле тәэсир калдырды, гел синең турыда уйланып йөрдем. Ниһаять, очраштык менә. Нык үзгәргәнсең, җыерчыкларың да бар икән инде. Ләкин мин сине таныдым бит. Хәзер ничә яшь сиңа?

— Егерме биш.

Фәиз бу егетнең ихлас күңелдән ярдәм итәргә омтылуын күрде, чыннан да, эзләгән ул аны. Ярдәм итәргә тели.

— Мин дә очрашуыбызга шат,— диде Фәиз, тынычланып.

— Син бер дә аптырама. Рафаэль абый сине дәвалагандыр, күрәсең. Ләкин сине язмыш кочагына бирүзеңне ташламабыз, әгәр дә проблемаларың бар икән, хәл итәрбез ничек тә. Без болай итик, минем бүген башка пациентларым булмаячак. Әйдә безгә кайтабыз. Әлфия анда тәмле итеп өчпочмак пешерергә тиеш иде. Бездә кунарсың, шунда сөйләшербез, барысын да аңлашырбыз. Әгәр дә инде шушы минутта ук ярдәм кирәк икән, әйтик бирәр төрле даруны, уколмы...

— Нәрсә кирәклеген әйтермен мин. Тик хәзер сезгә кайтып тормам инде.

— Нишләп?

— Ни, яхшы түгел. Мөмкин булса, монда, диспансерда гына кунармын.

Марат аның оялганын да, шуңа күрә барудан баш тартканын да күреп алды.

— Юк, туган, комплексларыңнан арынырга кирәк. Кимчелекләр комплексыннан без синең белән бергәләп арынырбыз.

Фәиз аның кешене шулай тышкы кыяфәтеннән тиз арада «укый алу» сәләтенә шаккатты. Хәер, психотерапевт бит ул!

— Ярар алайса,— диде Фәиз, аларда үзен уңайсыз хис итәсен алдан ук сизеп.

Барырга кирәк, баш тартырга ярамый, чөнки дәваланырга килде ул. Маратның очравы һәм аның ярдәм күрсәтергә әзер торуы бәхет түгелмени?! Ярый очрады әле!

Әлфиянең чалт аяз йөз белән каршы алуы, ярлы гына җиһазланган булса да, җылы һәм матур фатирның үзгә һавасы ярылырдай булып ярсыган күңелне, теләсә кемне, хәтта иң җаһил бәндәне дә тынычландырып, игә китерерлек иде. Фәиз монда үзен уңай һәм тыныч хис итте. Моннан җиде ел элек әллә очрашканнар алар, әллә юк. Маратның әтисе, мәрхүм Тәлгать абый, аның әнисенә операция ясаганмы, юкмы, Әлфия кибет директоры Габдрахманов Ильяс Хәмитовичның кызымы-юкмы — бернинди аерма сизелмәде. Бу турыда уйларга мөмкин дә түгел иде — үзенә карата шулкадәр яхшы мөнәсәбәттә булулары Фәиз өчен гаҗәп тә, рәхәт тә иде.

Кичке ашны ашагач, иркенләп сөйләшергә вакыт күп калды. Әлфия йорт эшләре, үзенең көндәлек вазифалары белән мәш килеп йөрде, бу вакытта Марат аның сөйләгәннәрен игътибар белән тыңлап утырды.

ТЕГЕ ВАКЫЙГА шулай ук Маратны да нык гаҗәпләндермәде. Ул аны ничек аңларга тиеш булса, шулай аңлады. Ул аңа фәкать, гомумән, фаҗигале вакыйгага караган кебек карады. Аның да карашы нәкъ Шандыровныкы шикелле булды. Фәиз Маратка барысын да сөйләде, чөнки Рафаэль Марсовичка сөйләгәннән соң хәл җиңеләеп киткән иде. Аннары, Марат ярдәм итәргә тели икән, аңа күңелдәген сөйләмичә ярамый. Соңгы вакыттагы халәтен сөйләгәннән соң Марат катгый итеп әйтеп куйды:

— Аракыны ташларга кирәк кичекмәстән. Шуннан башлыйк. Атна-ун көн дәвалармын. Бәлки болай гына да ташлый алырсың?

Фәиз моңа куанды:

— Карале, чыннан да, үземне-үзем җиңеп карыйм әле. Гел врачлардан гына үтенеп булмый бит инде.

— Менә болай дип әйтүең миңа ошый.

Марат һәм Әлфия белән очрашу аңа бик уңай тәэсир итте. Иң якын кешеләрен очраткан кебек булды. Мөмкинлектән файдаланып Әлфиядән сорыйсы итте:

— Ильяс Хәмитович минем турыда берәр нәрсә әйттеме?

— Юк,— диде Әлфия. Ничек кенә булса да бу акыллы яшь хатын барыбер шулай дип җавап бирер иде.— Сезнең арадагы нәрсәләр белән мин кызыксынмыйм. Үзегез аңлашыгыз шунда.

— Бәхетле кешеләр сез,— дип куйды никтер Фәиз,— берегез психотерапевт, икенчегез экономист. Фатирыгыз, эшегез бар, гаиләгез бар.

Барысы да тып-тын калдылар.

— Ә без синең белән дә уртаклашырбыз бәхетебезне,— диде Марат.— Нинди ярдәм кирәк, һәрвакыт мөрәҗәгать ит. Шулай бит, Әлфия.

— Шулай,— диде Әлфия ягымлы итеп.— Без сине еш искә алабыз Марат белән.— Теге вакытта нык куркыттың безне.

Шуннан соң ул көлә-көлә кухняга чыгып китте.

— Сез мине кызганасыз.

— Сиңа өстән карап кызгану түгел ләбаса.

— Әгәр үзеңне мәрхүм Тәлгать абый өчен минем алдымда бурычлы саныйсың икән, мин сиңа шуны әйтергә телим: әнием операция өстәлендә үлгәнгә мин Тәлгать абыйны гаепләргә һич кенә дә җыенмыйм. Чөнки хакым юк.

— Син алай артык турыдан-туры гына аңлама инде минем һәм Әлфиянең сиңа карата булган мөнәсәбәтне.

— Әлфия дә, минемчә, әтисе өчен ничектер минем каршымда акланырга тырышкан сыман. Бәлки мин ялгышамдыр.

Марат елмайды:

— Ялгышасың, Фәиз. Ләкин шул ук вакытта синдә хаклык та бар. Бу дөньяда озак яшәмибез. Берәр кайчан тагын очрашырбызмы, юкмы. Ничек аңлатырга икән? Кешенең яхшы мөгамәләдә булуының сәбәбен эзләргә кирәкми, минемчә, моңа табигый нәрсә итеп карарга кирәк.

— Ә начар мөнәсәбәтләргә?

— Дөресен әйткәндә, алары да табигый инде. Кеше әйберләрне, төрле төшенчәләрне изгеләштерергә маһир. Табигате буенча кеше шундый. Шуңа күрә, әгәр мин сиңа ярдәм итүне изге бурычым дип кабул иткәнмен икән, син моңа каршы килмә һәм, зинһар, бу хакта төпченмә.

— Тик менә мин лаекмы соң кеше ярдәменә?

— Син үзеңдә кемгә дә булса ярдәм итәргә ихтыяҗ тоясыңдыр бит?

— Тоям.

— Димәк, лаеклы.

— Бик гади, җайлы фикер йөртәсең.

— Ә нишләп әле гап-гади нәрсәләрне катлауландырырга?! Яшәргә кирәк, яшәргә ашыгырга кирәк хәтта. Вак-төякне катлауландырып болай да күпме вакыт заяга уза.

Фәиз кинәт җитдиләнде:

— Мин шулай да белмим үземне акларгамы, әллә, киресенчә... Кеше үзенең подсознаниесе өчен дә җавап бирергә тиештер бит.

— Ник алай сорадың әле?

— Әгәр Зәбиргә аңсыз рәвештә кулымны сузмаганмын икән, барыбер гаеп миндә бит.

— Менә син нәрсә турында...

— Әгәр көнчелек хисләре шундый вакытта аң астыннан калкып чыгып җинаятькә этәрә икән, кем җавап бирергә тиеш соң?

— Һаман «җинаять» дисең син. Подсознаниедән мотив булганда калкып чыккан көчләр өчен, әлбәттә, кеше үзе җавап бирергә тиеш. Әгәр инде син бу хакта сүз катасың икән, әгәр син үз өстеңә җәза алырга әзерсең икән, алай гына да түгел, инде син шактый гына җәзалагансың икән, димәк, син зур үсеш кичергәнсең. Синең җәзалануыңда, димәк, мәгънә бар.

— Үтергәннән соң кайгырып... үсеш кичерер өчен җинаять кылырга кирәкмени шулай да? Үтергәнче үсеш кичерсә иде кеше. Үсеш кичергән кеше— үтерүгә бара алмаган кешедер, минемчә. Үтергәннән соң чистарынып рухи биеклеккә менәләр, имеш. Юк, килешмим мин.

— Синең мисал башка төрле бит, Фәиз. Аннары, бөтен җинаятьләрне, барлык кешеләрне уртак тамырга китереп булмый. Һәм маташырга да кирәк түгел. Бу дөньяга, минемчә, һәркем үз миссиясе белән килә.

— Син, психотерапевт буларак, һәркемгә хезмәт итәргә тиешме?

— Әлбәттә. Минем вазифам шул.

— Ә кеше үтерүчегә, мәсәлән?

— Ул да минем өчен пациент бит. Бәлки, кеше үтерүче белән күбрәк эшләргә тиештер мин. Кешегә үзен аңларга ярдәм итүче бит ул психотерапевт. Минем өчен кеше ашаучы да пациент. Кешенең психикасында ниләр кайнаганын белмибез ич. Җинаять эшләгәндә нинди халәттә була ул, нинди көчләр өстенлек ала аңарда? Хөкемдарлар да хөкем карарларын чыгарганда нык ялгышалардыр. Тегеяки бу җинаятькә нинди җәза бирергә тиеш алар? Аны кем үлчәгән? Аны үлчәп буламыни?

— Минемчә, үз акылында булган һәрбер кешенең вөҗүдендә, бер мәлне, чистарыну башланадыр. Тәкъдирендә ниләр генә язылса да, әллә нинди гөнаһлар кылынган сурәттә дә, адәм баласы офтану, үкенү, ярлыкау сорау халәтен кичерәдер.

— Ай-һай, шулай микән?

— Кемгәдер гомернең башыннан туры, хак юл насыйп һәм ул сабый чактан ук әшәкелекләрдән, бозыклыклардан чит-ят була. Ләкин бит ул барыбер инсаннар дөньясында гөнаһсыз кала алмый. Табигате буенча саф калырга тиешле кеше моны барыбер аңлыйдыр һәм офтанадыр, гафу үтенәдер. Кемгәдер олыгайгач зирәклек белән бергә чистарыну киләдер, башкача булуы мөмкин түгел. Дөньяны караңгы золмәт каплар иде шулай булмаса. Кемдер, хөкем ителгәч, аңында инкыйлаб кичерәдер, чистарынырга омтыладыр. Берәүләр иң якын кешесен югалткач. Кемдер афәт килгәч.

— Миңа сине тыңлап утыруы кызык. Синең белән сөйләшүе күңелле. Аның бу бәясе Фәизгә дәрт бирде һәм ул илһамланып дәвам итте:

— Мин күп уйландым бу турыда. Гомере буе ачу, нәфрәт асрап йөргән кеше дә үлгәндә, һич тә булмаса, җаны чыгып очкан мизгелдә, офтанадыр.

— Бәлки, әйткәнемчә, дөньяга һәркем үз урынына, үз миссиясе белән килә. Бәлки, чынлап та, менә шул чистарынырга, котылырга, тәүбә итәргә омтылу һәммәсен дә уртаклаштырадыр. Ләкин моңа ышануы кыен, әлбәттә.

— Син бик матур әйттең. Үзең дә сизми калдың — чистарынырга дигәннән соң «котылырга» дидең. Бездә «котылу» — чистарыну, хак юлга басу мәгънәсендә дә кулланылган. Гөнаһлардан, әшәкеләрдән котылу турында бара сүз. Ә мин ышанам, җинаятьләр кылган җаһил бәндә дә котылу хыялын үзендә тоядыр. Ә инде бу хыялны гамәлгә ашыра аламы, юкмы — анысы башка мәсьәлә. Мисаллар күп, атарга хөкем ителгән рецидивист та инсаниятне ярата башлый лабаса!

— Син бит мин әйткән сүзне — һәркем үз урынына килә дигән фикерне хуплап утырасың. Мин сокланам — син искиткеч озын һәм авыр юл үткәнсең. Кыска вакыт эчендә күп нәрсәгә ирешкәнсең. Шуңа күрә, акылың белән, яхшылыкка омтылучы күңелең белән, син әйтмешли, «котылырсың». Инде котылып киләсең, мин моны күрәм. Син үзеңә дөрес бәя бирәсең. Үзеңне кызганмыйча, хәтта мазохистларча. Шул ук вакытта син тирә-якка да игътибар белән күз сал. Тирә-яктагы ыгы-зыгыга да тиешле, тәңгәл бәя бир, ул чагында тагын да күбрәк нәрсә аңлашылыр.

— Мине соңгы вакытта бер сорау борчый. Нишләп соң кешенең җинаять кылыр алдыннан, ниндидер эчке киртәсе биек булып калыкмый, коткармый?! Соңыннан үкенүдә, тәүбә итүдә бәлки киләчәк өчен мәгънә бардыр. Әмма ләкин үткәннәр өчен мәгънәсе юк түгелме соң?

— Мин сиңа кызыклы китаплар бирермен әле. Психиатрлар өчен булса да, сине бу нәрсәләр кызыксындыра икән... Беләсеңме нәрсә, Фәиз. Җан иясе бу дөньяга килә икән, ул бит ирексез, кол булып килми. Күк тарафыннан ул ирекле итеп яратылган. Килешәсеңдер. Ул ирекле! Мәсәлән, кеше үтерүченең үтерергә хакы бар.

— Син нәрсә инде.

— Ашыкма. Тыңла. Ул ирекле. Дөресрәге, аның сайларга хакы бар: үтерергәме, юкмы. Сайлау иреге бирелгән бит аңа, берни эшләтеп булмый — сайларга ирекле ул. Кеше ирекле. Әмма шуның белән бергә аның тагын бер хокукы барлыкка килә — кылган җинаяте өчен җәзалы булу иреге.

— Син, әлбәттә, судлар, прокуратуралар, трибуналар җәзасы турында түгел, бәлки кешенең үзенә җәза бирүе турында сүз алып барасыңдыр?

— Әйе. Ләкин хакимнәр хөкем итсә дә, үзеңә-үзең җәза бирү дип аңлатырга була түгелме?

— Юк, бу очракта тәгаен алай дип әйтеп булмас.

— Шулайдыр. Мин дә үз-үзеңә җәза бирү турында сүз катмакчы идем. Кешенең вөҗдендә үз хакиме һәм җәллады бар — ВӨҖДАН. Син моны бәлки миңа караганда да яхшырак аңлыйсыңдыр.

— Вөҗдан, гадәттә, соңга калыбрак күтәрелә. Вөҗдан газабы соңрак, еллар үткәч көчәя түгелме? Вөҗдан, кинтә буларак, бик сирәк очракта калкып чыга, шулай түгелме?

— Вөҗдан, минемчә, хаким генә түгел. Ул бит мәгънә органы да. Теге яки бу шартта нишләргә кирәк икәнне ВӨҖДАН әйтә! Мәсәлән, җинаять алдыннан: үтерергәме, юкмы. Әгәр вөҗдан үтерергә куша икән — кеше үтерә. Һәм беркемнең дә ул үтерүчене хөкем итәргә хакы юк. Чөнки шул ук ВӨҖДАН аны хөкем дә итә. «Һәрбер кеше тәүбә итү ихтыяҗы тоядыр кайчан да булса» дигән сүзеңне куәтләп әйтәм бу фикерләрне. Ничек хөкем итәдер кешене аның вөҗданы, аның психикасында ниләр кайный, шайтан белсен. Аның, кем әйтмешли, күңеленә кереп булмый бит. Бихисап күп сәбәпләрне мизгел эчендә анализлап, уртак тамырга китереп, вөҗдан һәрбер конкрет хәлдә кешегә нинди адым ясарга кирәклеген куша. Аннары нинди җәза бирә — анысында башка беркемнең дә эше юк. Бәлки, син әйткәнчә, һәркемнең газабы, җәзасы үзгәдер һәм төрле вакытта буладыр. Син элегрәк әйткән белән килешәм: тәүбә итәргә һич югы аз гына теләге барлыкка килмәгән кеше яралмагандыр. Әгәр дә шулай түгел икән, бу дөньяны ничек атарга да аптырар идек.

— Бу фикерләр дә тынычландыра алмый шул. Зәбирнең үлүендә кайсыдыр «минем» гаепле булу үземне аклый алмый. Җәзаларның әллә ниндиләренә әзер мин. Ләкин кылган эшеңә тәңгәл микән соң син кичергән газап? Күбрәкме ул, азракмы?

— ВӨҖДАН турында уйлаганда, дөресен әйткәндә, адәм баласының ирекле булуына шикләнә дә башлыйсың. Вөҗдан колы түгел микән кеше? Миңа иптәшләрем Ленинградта әйтәләр иде: син бу теорияләрең белән акылдан язасың инде дип. Чисталык, пакълек, гаделлек төшенчәсе буларак, акылга һәм аңга сеңгән вөҗдан йөртә кешене тәкъдир сызган бормалы, тайгак юллардан. Монда минем һич шигем юк.

— Әйе, сорауларның, гомумән, әйтәсе сүзләрнең бетәсе юк. Шунысы куркыныч: мең-мең кат дәшсәң дә, әлеге дә баягы ВӨҖДАН аваз салмый. Әллә юкмы соң ул? Җан ачысы белән кычкырган сорауларга да аңардан җавап ишетмәссең.

— Юк, юк, син нәрсә! Колак сала белергә генә кирәк. Син ВӨҖДАН авазын ишетергә телисең икән, димәк ул синдә бар. ВӨҖДАН кычкырып йөрми ул. Ул бары тик кешенең яшәешендә, барлыгында, аның яшәү мәгънәсен эзләвендә генә беленә. ВӨҖДАН — бөек хаким буларак — көн саен, сәгать саен, мизгел саен боера, шуннан соң үзе бәя бирә һәм, ниһаять, үзе үк хөкем итә.

— Гомерлек җәза бирүе дә ихтимал.

Марат, психотерапевт буларак, «ихтимал» дип әйтергә җөрьәт итмәде.

— Фәиз туган, ул бит газапның авырлыгыннан, тирәнлегеннән торадыр.— Ул аны тәмам тынычландырырга тырышты.— Син сөйләгән вакыйгаларда гаеп-гөнаһларың — ташка үлчим. Син моны тиздән аңларсың. Син тереләчәксең. Күреп торам, бу әңгәмә сине ардырды бугай.

— Мин юлда арыган идем.

— Ярар. Хәзер Әлфия урын җәеп бирер. Рәхәтләнеп йокла. Синең симптомнарны мин аермачык күрәм. Ничек, нәрсә белән дәваларга икәне дә аңлашыла. Аракыдан, тәмәкедән котылырга кирәк. Психиканы әкренләп тотрыклы итү өчен көрәшәчәкбез.

— Син Шандыровтан аерыласың, күренеп тора — син яңа буын психотерапевты.

— Буында түгел эш. Һәрбер кеше бу дөньяда үзенчә бердәнбер. Һәрбер кеше кабатланмас шәхес. Хәзерге психотерапия пациентларны да уртак канунчарга буйсынган ысуллардан тайпылып, һәр пациентның үзенчәлекләрен исәпкә алып дәваларга тырыша. Башкача булмый.— Ул көлеп өстәп куйды.— Әле яңа гына һәр кешенең чистарынуы үзгә,

кабатланмас, төрлечә була дидек. Син, Фәиз, тынычлан. Нормаль шартларда яшисеңме?

— Ярый инде болай.

— Хатының белән мөнәсәбәтләр ничек?

— Әйбәт. Минем Нәркизәм бик яхшы, аңлый торган кеше.

— ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ аңа да сөйләдеңме?

— Иң әүвәле аңа сөйләдем.

— Ничек тәэсир итте?

— Ул мине гаепләми.

— Күрдеңме! Әүлия син, туган! Башыңны югарырак күтәр, без әле яшьләр, безнең әле яшиселәр алда. Шулай да берәр атна стационарда хәмергә каршы бераз уколлар кабул итәрсең. Бик шәп таблеткаларым бар — импортный. Әлфия! Урын җәя башласаң әйбәт булыр иде.

— Хәзер.

Фәиз бу гаиләдә үзен кеше дип хис итте. Мондый җылы мөнәсәбәтне аның әле моңарчы беркемнән дә күргәне булмагандыр. Әйтерсең лә, алар алдан сүз куешып Фәизне очратырга һәм мөмкин кадәр аны ихтирам итәргә, яратырга, ярдәм итәргә җыенып йөргәннәр. Бәлки шулайдыр да.

Бер атна дәвамында ул Марат карамагында булды. Моңа кадәр организмның алкогольга күнегүе нәтиҗәсендә, хәзер дулкын-дулкын булып коточкыч халәт кабатлана иде. Фәизгә бу очракта да үзенең организмы белән көрәшергә кирәк булды. Шулай да бу эш махмырдан интегү түгел инде.

Әле яшь белгеч булуына карамастан, Марат инде диспансерда абруй казанырга да өлгергән иде. Аның бөтен персонал белән яхшы мөгамәләдә булуы әллә кайдан күренеп тора. Фәизгә ул яхшы дарулар табып бирде — кайткач кабул итәргә.

— Иң мөһиме — ихтыяр көчеңне туплап, аракыны эчмәскә. Үзеңнән тора. Үз акылың белән аңлап ташламасаң, дарулар да, мин дә ярдәм итә алмаячак.

— Аңлыйм.

— Тагын берәр айдан килерсең, яме. Алай-болай кичектермәс ярдәм кирәк булса, теләсә кайсы вакытта кил. Туп-туры өебезгә кил. Менә монда адресымны, телефоннарымны яздым. — Ул кәгазь бирде. — Шалтырат. Болай гына шалтырат, сөйләшербез, дөнья хәлләрен, тегесенмонысын. — Ул тумбочкасыннан берничә кап таблетка чыгарды. — Монысы психотропный. Монысын депрессия вакытында эчәрсең. Ләкин күп кулланма. Төшенкелектән үзең чыга алмаган очракта гына кабул итәргә тырыш. Монысын йоклый алмаганда бер таблетка кабарсың. Саф һавада күбрәк йөр.

— Төшенкелек гомер буе дәвам итәр микәнни?

— Анысы да үзеңнән тора. Үзеңне гел булдыксыз, бернигә яраксыз дип бетереп йөрсәң, гомер буе дәвам итәчәк. Ә син, дустым, көчле кеше. Син әле үзеңне-үзең дә аңламыйсың.

— Миңа Шандыровның дә әйткәне бар иде шулай дип.

— Чөнки Рафаэль Марсович акыллы кеше. Тиз генә терелермен дип уйлама. Гадәттә, чир күпме вакыт сузылган булса, аны җиңәр өчен дә якынча шул кадәр үк вакыт кирәк. Синең инде алга китеш бар.

— Ярый син очрадың әле, Марат.

— Син гел кешегә генә салынма. Мин сиңа якын дус һәм намуслы психотерапевт кына була алам. Ә калганы үз өстеңә йөкләнә барыбер.

Кайтып китәр алдыннан Фәиз Федосеевская урамына сугылырга уйлады. Гөлүсәне күреп булмасмы дип баруы иде аның. Марат больницасында эчкечелектән дәвалатып булмасмы дип өметләнгән иде.

Тагын кыйнамасалар ярар иде дип уйлады ул кайчандыр үзе кукыраеп утырган чардаклы йортка якынлашканда. Ишегалдын бер абзый аһ-ваһ килеп себереп маташа иде. Шундый матур көзге яфракларны җыеп яндырырга җыена, ахрысы.

— Абзый, исәнмесез!
— Исәнмесез.
— Сез ундүртенче йорттан түгелме?
— Юк, уникенчедә мин.
— Ә ундүртенчедә Гөлүсә яши, шулаймы?
— Яши иде.
— Кайда соң ул хәзер, белмисезме?
— Үлде ул.
— Ничек... үлде?
— Ничек үлсен? Эчеп үлде. Ул хәтле эчүгә...

Фәиз аякларын көчкә сөйрәп ишегалдыннан урамга таба атлады. Артта абзыйның себерүе никтер куркыныч тоелды, себеркесенең чыжылдавы көлү тавышына охшаган сыман иде. Алай гына да түгел, әйтерсең лә, себерке бәгырьне тырный-тырный нәрсәдер эзли — күңелдәнме? Җирдәнме?

Бу ишегалдыннан, бу урамнан тизрәк китәргә һәм мәңге монда кире килмәскә! Ләкин урамы да, йорты да, чардагы да, кешеләре дә хәтер белән мәңге ияреп йөриячәк. Аларны бернинди себерке белән дә хәтер урамнарыннан себереп түгеп булмаячак.

Автобусның тәрәзәсенә маңгаен терәп ул юл буе Гөлүсә турында уйлап кайтты. Кем гаепле икән аның үлемендә? Ник эчкечегә әйләнде икән ул — әллә аның да кичеп чыккысыз кайгы-хәсрәте булды микән? Шулайдыр, чөнки сәбәпсез эчмәгәндер бит инде ул. Бу фаҗига кемгә, ни өчен кирәк соң? Тирәнрәк уйлап баксаң, аның үлеп китүе үзе өчен бәлки фаҗига да түгелдер. Аны коткарып булыр иде, мөгаен. Хәлем, көчем җиткән булса, коткара да алыр идем бәлки. Бичара, котылды инде ул.

Котылды! КОТЫЛДЫ микән! Үлеп котылып булса, бөтен кеше кайгы килү белән үлеп китәр иде. Мин дә үлмәдем бит әле.

Уйлана торгач, чынбарлык барыбер үзенекен итә — аны үзгәртү мөмкин түгел. Үткән, булган вакыйга инде ул мәңгелек мөлкәте, ул синеке дә түгел, беркемнеке дә түгел. Аның белән килешми булмый. Гөлүсәнең язмышы никадәр ачы — белү һәм үлчәү мөмкин түгел.

Уйлар әкренләп яктырак юнәлеш алды. Марат белән Әлфия тикмәгә очрамагандыр. Бу дөньяда кешеләрнең бер-берсенә юлыгуы да очраклы нәрсә түгелдер. Нинди матур, якты күңелле кешеләр алар! Гафу иткәннәр, дөресрәге, бөтенләй ачу тотмаганнар. Олы җанлы кешеләр бар дөньяда. Нәркизәгә кайту белән сөйләргә кирәк булыр алар турында, кунакка да чакырырбыз әле. Бер-беребезгә, гомумән, йөрешербез. Күңелләр күтәрелеп китте. Яшисе дә килә түгелме?! Һай, адәм баласына күп кирәк түгел лә. Кайвакыт якты чырай яки бер җылы сүз генә дә дөньяда яшәүнең рәхәтлеген тоярга ярдәм итә, хәтта яшәргә кирәклеген дә искәртә.

## 24

Өй бикле иде. Китапханәдән кайтмагандыр әле Нәркизә. Тик никтер күңел кинәт шомлана башлады. Нәрсәдер сизенде. Баскыч астыннан ачкычны капшап алды, куллары калтыраганны тойды. Ашыгып өйгә керде һәм — ни гаҗәп! — күңел сизә бит ул, ә?! Өй эчендә Нәркизәнең әйберләре күренмәде. Моны ул шундук абайлады — хатынының киемнәреннән, вак-төягеннән җилләр искән. Башта ул, үзен тынычландырыр өчен, карак-мазар кергәндер дип уйларга тырышты. Ләкин өстәлдә кәгазь кисәге ята иде.

*«Фәиз! Гафу ит, мин әниләргә кайтып китәм. Бергә яшәп без барыбер бәхетле булмабыз. Хәзер чиреңнең сәбәбен беләсең инде. Нинди дарулар*

*кирәк икәнне дә беләсең. Дәвалан, терел. Минем арттан килеп йөри күрмә. Өч ел бергә торып безгә бер дә рәхәт булмады, килешәсеңдер. Син бик яхшы кеше. Безнең гаиләбез таркалуда беребезнең дә гаебе юк. Очрашуыбызда да беркемне гаепләп булмый. Тагын бер тапкыр гафу ит!*

*Нәркизә.»*

Фәизнең ышанасы килмәде. Рәхимсез, коточкыч шаяру буларак кабул итте ул өстәлдәге кәгазьдә язылганны. Шып-шыр булып калган өйдә озак утыра алмады, урамга йөгереп чыкты.

Сул якта яшәүче өлкән яшьтәге Зәйнәп апа сүзсез генә баш кагып исәнләште дә капка төбендәге утыргычтан кузгалып өенә кереп китте. Аннан да нәрсә дә булса ишетәсе килгән иде Фәизнең, ләкин апа дәшмәде.

Һаман ышанасы килмәде. Шаяру дисәң, Нәркизә алай шаярмас.

Менә шушыннан куркып йөрде бит ул соңгы вакытта. Нишләп алдан куркып йөргән нәрсәләр тормышка, гамәлгә котылгысыз аша икән?! Нишләп минем фаҗигале вакыйгаларым һәрвакыт көз көне була икән?! Югыйсә иң яраткан вакытым бит алтын көз.

Китапханәче буларак, Нәркизә Культура сарае директорына буйсына иде. Фәиз түзмәде, директорга барып кайтырга булды.

Гомере буе клубта, аннары Культура сараенда эшләгән Шәйхелислам абый Фәизне чын күңелдән кызганып авыр сулап куйды:

— Расчет алды. Китәм диде.

— Ник расчет бирдегез? — диде Фәиз ни әйтергә белмәгәч.

— Бирми булдыра алмадым. Бик нык ялварды.

Ул өенә ничек кайтып җиткәнен дә хәтерләмәде. Ишегалдында әрлебирле тәмәке тартып йөрде. Күңелләр болгана башлады күп тартудан.

Каты сукты язмыш! Тагын бер тапкыр орды! Нәркизә ташлап китте! Моңа һаман ышанасы килмәде әле. Кайтыр бәлки?

Ямьсезләнеп, салкынаеп калган өй эчен җанландырып, инде күңелнең бер почмагын мәңгегә үзенеке итеп кереп урнашкан Нәркизә менә-менә пәйда булыр да вулкан сыман шартларга торган ярсу тынып калыр кебек иде.

Кат-кат укыды ул өстәлдәге язуны. Ташлавы микәнни мине?! Башта тагын уйлар чуалып бетте. Балаларыбыз юк. Андый ир нигә кирәк аңа? Бәлки балаларыбыз туар иде әле. Чирләшкә бит мин. Ямьсез. Булдыксыз.

Мәхәббәт бар идеме соң безнең арада? Бер-беребезгә шулкадәр иләшкәч, якынайгач, икебез бербөтен булып яшәгәч, мәхәббәт булгандыр! Мәхәббәт булса, ташлап китәр идемени?! Нишләп сөйләшми-нитми китеп барды соң ул? Мине кызганып, алдан сөйләшеп тормаска булгандыр. Мине кызгангач, нишләп китеп барган соң? Бәлки кайтыр әле. Юк, кайтмас ул минем яныма. Нишләп әле кайтырга тиеш ул? Язып калдырган бит инде.

Кинәт ул җан өшеткеч курку тойды. Зәбирне мин батырып үтергәнмен дип уйлыйдыр Нәркизә. Мине гаепли. Сүз белән әйтмәсә дә, ташлап китүе шуны аңлата түгелме? Көнләшеп, дустын батырып үтергән дип уйлыйдыр. Үтерүче белән яшәмим дип китеп баргандыр.

Нык авырган чаклардагы хис-тойгылар яңадан купты. Газап тагын нерв җепселләре буйлап үрмәләде, кая таба үрмәлидер — белгән юк. Вөҗүднең ниндидер иң әһәмиятле өлешен эзлиме? Ул аны беләдер инде, бары тик үрмәләп барып җитәсе генә калгандыр. Куллары салкынайганны тойды. Йөрәк шашып типсә дә, тәннең барлык әгъзаларына да кан һәм җылы барып җитмәде. Таныш, бик таныш халәт. Инде бүтән кабатланмас дип уйлаган иде. Кабатланмыймы соң! Нишләп әле тиз һәм җайлы гына бетәргә тиеш ди ул?

Тын бетә башлады, күз алмалары сызлап авыртты. Тәндә спазмалар яңа көч белән башланды. Курку өянәге аны тагын ишегалдына алып чыгып китте.

Дөнья тагын кап-караңгы. Вак кына булып сибәләгән яңгыр гына аз — коеп яусын иде ул. Шаулап ташу аксын, кай тарафларга булса да алып китсен!

Юк, монда, үз хәсрәтләрең белән басып торган җиреңдә, калырга дучар ителгәнсең шул!

Нәркизә киткән, тикмәгә түгел. Дустымны аңсыз рәвештә коткармаган булсам да, барыбер җаваплылык миңа төшәргә тиештер. Нәркизә шуны аңлагандыр. Ул бит җүләр түгел.

Тирәнрәк уйлап баксаң, мине акларлык нәрсә бар соң? Дустымнан көнләшкәнмен. Ул сазлыкка батканда көнләшү килеп чыккан! Кем мин? Нәрсә мин? Имеш, подсознаниедән килеп чыккан көнләшүләр. Чүбек чәйнәү! Әле курку аркасында гына кулымны сузмаган булсам да, акланырга мөмкин иде. Ә болай... Эчемдә ачу, нәфрәт җыелып йөргән икән ләбаса. Подсознание дененне!

Кыскасы, Нәркизәнең ташлап китүе аның авыруын яңа көч белән кузгатты. Алай гына да түгел, ТЕГЕ ВАКЫЙГАГА ул бөтенләй башка күзлектән карый башлады. Шактый вакыт бергә гомер иткән кешесе ташлап киткәч, ул кинәт бөтенләй беркемгә кирәк түгел мескен, бичара, ахмак хәлендә калды. Элегрәк өмет бар иде — кемгәдер кирәк булып, яшәүнең мәгънәсен бәлки шунда табармын дип яшәде. Ә хәзер Нәркизәнең китүе нык сукты һәм ул бар өметләрне чәлпәрәмә китерде.

Каргыш шулай буладыр инде, дип уйлады ул. Дөнья тагын тар гына төнлектән күренә башлады.

Атна буе эшкә бара алмады. Марат биреп җибәргән дарулар ярдәм итү түгел, хәтта бөтенләй тәэсир итмәде шикелле. Тамагына ашый алмады. Каткан ипи кисәкләрен генә чәйгә манып кимерде. Эзләсәң, өйдә ашарга табырлык, ләкин аппетит бөтенләй юк иде.

Газаплы уйлар тыгыз ятьмә үреп алдылар. Үзенең адәм актыгы икәнлегенә ышандырыр өчен коточкыч уйлар көне-төне тынгы бирмәделәр.

МТСта: «Хатын китте дип эшкә чыкмый ятмыйлар инде»,— диделәр. Ләкин аның кыяфәтен күреп барысы да таң калды — Фәиз урынында бер өрәк кенә кыймылдый иде. Аның беркемдә, бернәрсәдә игътибары калмады. Аракы эчкәннәндер дип уйладылар барысы да. Фәиз үзе нәрсәдән икәнен белә инде. Элек ул үзе дә эчкечелек галәмәте дип үзен-үзе ышандырырга тырышкан иде.

Кыскасы, Нәркизәнең китүе бераз артка чигенергә мәҗбүр булган чиргә яңа куәт бирде. Һәм аңарда икеләнүләр бермә-бер көчәйде, кимсенүләр коточкыч дәрәҗәдә артты. Ул инде урамга чыгарга курка башлады.

МТСтан тагын килделәр:

— Йә больницага барып ят, йә болай булса, эштән куабыз,— диделәр.

— Куыгыз,— диде Фәиз янына килүчеләргә төссезләнгән күзләре белән бөтенләй карамыйча.

Ул беркемгә дә үпкәләмәде. Киресенчә, аны инде хәзер бөтенесе ТЕГЕ ВАКЫЙГАДА гаеплидер, аны барысы да хөкем итәргә җыеналардыр шикелле тоелды.

Нәркизәгә карата да бик кырыс, рәхимсез идем бит мин, дип уйлады ул. Поселокта барысы да беләдер бу хакта. Сазлыкта дустын батырып үтергән кеше икәнлеге дә мәгълүмдер инде. Юлны кыскартыр өчен, сазлык аша үтәргә мин тәкъдим иттем бит. Зәбир түгел. Минем гаебем икеләтә арта шулай булгач! УЛ ВАКЫЙГАНЫҢ нечкәлекләрен Нәркизә поселокта кемгә дә булса сөйләми калмагандыр. Әнә эштәгеләр дә ничек карый, ә күршеләр мине күрү белән йә кача, йә өйләренә кереп китә...

Асылынырга? Булмый.

Өйдә тын бетә. Ачык һавага чыккач, бөтенләй башка төрле, үзгә курку өянәге башлана.

Эштән расчет акчасын да аңа китереп бирделәр. Акчаны биргәч:
— Эчмә бүтән, үләсең бит! — дип чыгып китте кассир хатын.
Эчү дигәннән, аракы эчеп карарга мы әллә? Юк, тагын да начар булыр, ахрысы. Аның хәтта аракыга да аппетиты калмады.
Кассир хатын әле өйалдында аяк киемен киеп маташа иде. Фәиз аның янына чыкты:
— Бер үтенечем бар, Казанга телеграмма бирегез әле?
— Кемгә? Кемең бар анда?
— Хәзер адресны язып бирәм. Зинһар.

## 25

Өч көн үткәч Фәизнең йорты каршына ак «Жигули» килеп туктады. Марат белән Әлфия төште аннан.
Килеп керү белән Марат иске диванда бөгәрләнеп ятучы Фәизгә дәште:
— Нәрсә булды?
Фәизнең куркуы кимеде. Йөрәгенә якын кешеләрнең килүе аны хәтта яткан урыныннан торгызды. Ул шәхси тормышындагы хәлләрне, авыру кешегә хас фаҗигалелек белән бәйнә-бәйнә сөйләде. Шунысы гаҗәп тоелды аңа — алар сөйләшеп утырган арада Әлфия аның инде астыөскә килеп беткән өй эчен җыештырып, тиз генә тәртипкә дә салды. Үзләре белән алып килгән күчтәнәчләрдән табын оештырырга да өлгерде.
Фәиз бераз читенсенү тойса да:
— Ярый килдегез әле, — дип шатлыгын белдерде.
— Телеграмманы алу белән юлга кузгалдык. Узган атнада гына машина алган идек. Иске инде, кулдан алдык. Машина да кирәк бит.
Марат аңа үзенең машина алуы турында, Казандагы хәлләрне сөйләргә махсус тотынды. Чөнки Фәизнең игътибарын каядыр читкәрәк, үзенең бәла-казаларыннан ераккарак юнәлтергә, газаплы уйларыннан ничек тә арындырырга кирәк иде.
— Кризистан чыгып килгәндә хатыныңның китүе, әлбәттә, уңай тәэсир итмәс. Зур удар бу, чыннан да. Син хәзер элеккеге халәтеңә чигендең. Ләкин без бит синең белән, Фәиз туган, акылсыз кешеләр түгел. Әйдә, алайса, аңлашыйк, бу кадәр төшенкелеккә бирелүең дөрес микән?
Фәизнең хәле нык начар булса да, Марат аны бары тик «төшенкелек» дип атады. Шулай кирәк.
— Нишлим хәзер? — диде Фәиз. Аның бу соравы кече бүлмәдә табаксавыт юып маташучы Әлфиягә дә кагыла шикеллерәк яңгырады.
— Яшәргә кирәк! — диде Марат.
— Ничек?!
— Бернинди фаҗига да күрмим.
— Сез, психиатрлар, барыгыз да бер нәрсәне такылдыйсыз. Шандыров та тора салып шуны кабатлый иде — «фаҗига күрмим, фаҗига күрмим».
— Монда гаҗәпләнәсе юк. Сүз бит синең турында бара. Шандыров та дөрес әйткән, мин дә дөрес әйтәм — дөньядан ваз кичәргә бернинди сәбәп юк. Синең фантазияң көчле. Вак кына нәрсәне дә син мең тапкыр үзгәртеп, зурайтып күрәсең һәм үзең уйлап чыгарган нәрсәдән аннары үзең котсыз каласың. Ярар, анысын соңыннан аңлашырбыз. Хатының белән барып сөйләшеп карамыйсыңмы соң?
— Юк. Баралмыйм. Анда барып җиткәнче үләчәкмен мин.
— Үзеңә колак салып, күңелеңне тыңлап кара — әгәр барып үгетләп карыйсың килсә, әлбәттә, барачаксың. Әгәр барырга үзеңдә көч тапмыйсың икән, димәк, барырга кирәк түгел.
— Сөйләшеп утырганда матур сөйләнелә инде ул.

— Минемчә, сиңа ашыгырга кирәкми. Әле бит билгеле түгел — сине ташлап киткәч аңа авырракмы, сиңамы. Бу вакыйганы син үз агымына куй. Вакыт үзе әйтер нишләргә кирәк икәнне.

— Ник китте икән ул?

— Ә син үзең ничек уйлыйсың?

— Хәер, монда уйланып торасы да юк. Кеше үтерүче белән ничек яшәсен инде ул!

— У-у, Фәиз туган, син үзеңә һаман авыр йөк асмакчы буласың — күтәрә алмаслык нәрсә такма инде үзеңә!

— Туктале, тукта, мине якларга маташма! Син бит белмисең безнең ничек яшәгәнебезне. Мин бит үземне генә түгел, аны да бимазаладым. Минем садист икәнемне белмисең бит син.

Марат елмайды:

— Беләм, нишләп белмәскә. Син үзеңне-үзең изеп, үзеңне-үзең садистка әйләндергәнсең. Хатының фәкать арыган — синең холкың туйдырган аны. Син үзеңә-үзең «мин адәм актыгы» дип сеңдергәнсең. Андый кешенең көчле булырга барыбер дәгъвасы кала әле. Бер яктан, шулай үзен хәлсез дип, икенче яктан, үзеннән көч таләп итеп, ул тора-бара холыксызга әверелә, садистка әйләнә.

— Нык укытканнар сине Ленинградта.

Маратка аның болай дип әйтеп куюы ошады — чын күңелдән көлеп җибәрде.

— Фәиз, син акыллы кеше! Бу вакыйгага дөрес кара. Гомерләр алда. Кризистан чыгарга кирәк. Ярдәм итәрмен. Әле гаиләң дә, бөтен нәрсәң дә булыр. Мин сиңа яхшы дарулар алып килдем. Кызыклы китаплар да юнәттем синең өчен. Аракы гына эчмә.

— Нинди китаплар алып килдең?

— Виктор Франклның «Адәм баласы мәгънә эзли» дигәнне, Эрих Фроммның өч китабын алып килдем. Әлегә шуларны укый тор.

— Марат, мин гел шушылай авырырмынмы икәнни?

— Үзеңнән тора. Бөтенләй үк җебемә әле син.

— Ә бу кояштан, биналардан курку бетәрме соң?

— Бетәр, бетәр. Яшәргә өметең булса, бетәр. Карале, әллә тагын стационарга салыйммы сине?

— Юк, кирәкми. Дарулар гына бир.

— Кызганыч, телефоның юк. Эшеңә шылтыратып торсам?

— Эштән кудылар мине.

— Сөйләшимме соң, бәлки яңадан алырлар?

— Кирәкми.

— Хәер, ашыкма. Җитешерсең эшләргә. Мин сиңа почта аша акча җибәрермен. Әлегә ике йөз сум җитәр бит? Ял ит. Хәзер сиңа ирек кирәк. Үзеңне тар кысаларга кертмә, төкереп тор эшенә. Син инде хәзер үз-үзеңне хәйран аңлыйсың бугай. Аң астындагы кичерешләрнең сәбәбен аңлау, асылына төшенү — хәзергә безнең өчен иң әһәмиятлесе бит, Фәиз туган. Хәзер үзеңне бернәрсәгә дә мәҗбүр итмә, тыңлап тор — ни кирәк күңелеңә. Тынычлану кирәк иң элек.

— Болай әйтүе җиңе-е-е-л.

— Үткән тормышыңнан яктырак күренешләрне исеңә төшерергә тырыш. Гел кара төстәге вакыйгаларны гына уйлама. Гүзәлрәк хатирәләр белән башыңны савыктыр.

— Бармы соң алар, гүзәл хатирәләр?

— Бар, бар, нишләп булмасын! Син бигрәк тагын!

Сөйләшеп утыра торгач, Фәиз җанланып китте. Әлфия әзерләгән ризыкны да рәхәтләнеп ашады.

— Дөресен әйткәндә, шулай да, минем хәтеремдә бер күренеш мәңге саклана,— диде Фәиз чәй эчкәндә.— Детдомга кадәр, әле әни исән чакта миңа җиде-сигез яшь булгандыр, малайлар белән җыйналышып урманга бардык. Алтын көз иде. Урман эченәрәк кергәч өрәңгеләр арасында таң

калып басып тордым. Минем әле андый матурлыкны, хозурлыкны беренче мәртәбә күрүем иде. Мин аермачык хәтерлим, сабый гына булсам да, башыма уй-сорау килде: «Кеше кулы белән ясалмаган булса да, нишләп шушы кадәр матур бу төрле төстәге яфраклар?» Мин бу бөек гүзәллектән һушсыз калдым, сулышым капты, мин әлеге алтында коендым, йөздем. Гаҗәпләнүемнең чиге юк иде — кайдан килгән бу матурлык?! Ничек мөмкин бу?!

Һәр елны, көз җиткән саен, мин шул бала чагымдагы матурлыкны күрергә омтылам, җиде яшемдә кичергән тойгыларны, хисләрне яңадан уятып, кабатларга тырышам. Өрәңгеләрдән ел саен бала чагымдагы сихрилекне өмет итәм. Ләкин юк, кабатлап булмый теге мизгелләрне. Хәзер дә яфраклар саргайгач көзнең гүзәллеге сөйләп бетергесез һәм җырлап туйгысыз була. Әмма балачактагы кебек йөзә алмыйм инде алтын диңгездә!

— Гомер узган саен башкачарак булыр инде ул, Фәиз туган,— диде Марат сөйләгәндә аның кызып-кызып китүен чамалап.— Бөтен нәрсә үзгәрә бит, нишләтмәк кирәк! Син барыбер эзлә теге югалган матурлыкны, эзләвең хак булсын. Эзлисең икән, димәк, ул матурлык сиңа кирәк. Матурлык кирәк икән, димәк, өмет яши синдә.

Фәиз елмаеп куйды:

— Син һәр әңгәмәне түгәрәкләп уңай якка борып куясың.

Марат: «Психотерапевт бит мин»,— димәкче иде, тыелып калды һәм:

— Син үзең уңай якка каерылып сөйләшкәнгә шулай ул,— дип тагын «майлап» куйды.

Алар килгәләп йөрергә вәгъдә биреп китеп бардылар. Бик кыен булса да, Фәиз акчадан баш тартмады. Дәвалангач, терелгәч, хәл кергәч, түләрмен, дип уйлады. Ә аякка басарга теләге дә, өмете дә бар иде аның. Марат белән Әлфиянең үзенә карата мөгамәләсе, аларның ярдәм итәргә ашкынулары киләчәккә өмет багларга этәрде.

## 26

Көннәр, айлар үтә торды. Маратлар, чынлап та, гел килеп-китеп йөрделәр. Фәизнең түшенкелек халәте кабатланып дәвам итте. Шулай да аның куркуы кимеде. Ул ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫҢ сәбәбен аңлады, төшенде. Бу турыда уйланырга аның вакыты күп иде. Ачыклык керде, ләкин бернәрсәне дә үзгәртү мөмкин түгел. Инде сәбәпне аңлагач та чарасызлык әсире булу белән һич кенә дә килешәсе килмәде. Үзгәртеп була түгелме?! Үземне үзгәртә алам лабаса! ТЕГЕ ВАКЫЙГАГА мөнәсәбәтне дә үзгәртү мөмкин. Үземне аклау хисабына түгел, киресенчә, үземнең гаепле икәнемне танып, УЛ ВАКЫЙГАНЫҢ сәбәбен, үземнең шул вакыттагы адымымны аңлап, чынбарлыкка ашкан фаҗигане рухымның барлык көчләрен җыеп кабул итәргә тиешмен!

Иң мөһиме — мин аңладым! Киләчәк тормыш күрсәтер — аңлавымның мәгънәсе бармы, юкмы. Зур нәрсә бит ул аңлау. Димәк, киләчәктә ул яман эш минем тарафымнан кабатланмаячак.

Мин үзгәрдем. Мин сазлык аша абына-сөртенә баручы идем. Күңелем сизә — мин аны кичеп чыгып барам. Җаваплылыкны өстемнән алып ташламыйм һәм ташламам. Шул коточкыч җаваплылыкны тою бүген миңа хәтта рәхәт тә шикелле. Куркак җәнлек сыман үземнән качарга җыенмыйм түгелме мин бүген?! Гәрчә хәлем бигүк җиңел булмаса да.

Илдә дә зур үзгәрешләр башланды. Михаил Горбачев җитәкчелегендә үзгәртеп кору дигән хәрәкәт «кузгалды». Дөньяның асты өскә килгәндәй булды. Кискен үзгәрешләр күзгә һәм колакка чалынса да, Фәизнең үз хәле хәл һәм дә үзенең күңелендәге үзгәрешләр белән ул күбрәк кызыксынды. Чыннан да, ирек җиле исеп куйды шикелле. Тормыштагы, кешеләрдәге үзгәрешләр аның кими башлаган чиреннән әкренләп арынырга

өлеш кертте бугай. Бик күп кызыклы нәрсәләр ачыкланды — ил тарихыннан, үзебезнең үткәннәрдән. Күпме ялган фаш ителде! Кыска гына вакытта дөньяга караш кискен үзгәрде. Укырга кызыклы китаплар күбәйде, элек ярамаган, тыелган әсәрләр дөнья күрде. Илдәге үзгәрешләрдән, иң шаккатырганы, Фәиз өчен яңа китаплар иде.

Илдәге үзгәрешләр, тышкы уңай фактор буларак, аның аңындагы, күңелендәге агымнарга сихәтле йогынты ясады. Әлбәттә, «үзгәртеп кору» дигән хәрәкәт башланмаган сурәттә дә, аның вөҗүде үзгәрү юлыннан тайпылмас иде. Илдәге үзгәрешләр белән аның психикасы үзгәрүенең бер вакытта туры килүе кызык һәм куанычлы фал!

Мәчетләр төзергә тотындылар. Плакатлар, лозунглар кубарылып төшерелде. Ленин һәйкәлләрен сүтәргә ябыштылар. Кызык, сәер, шатлыклы иде бу күренешләр никтер.

Фәиз бик яхшы аңлый: үз-үзеңдә үзгәрешләр булу зарур. Үзең үзгәрсәң генә, тормышны үзгәртү мөмкиндер. Һәйкәлләрне җимерү, үзең әле кичә генә изге дип санаган нәрсәләрне таптарга ашкыну әле үзгәреш түгел. Тормышны үзгәртим дисәң, үзеңне үзгәртү мәслихәт. Ә үзеңне үзгәртер өчен синдә коточкыч инкыйлаб булырга тиеш — күңелеңдә, психикаңда, аңыңда! Бу берничә көн эше түгел. Моңа күп вакыт һәм түземлек, рух көче кирәк! Үзгәрергә кирәк дип чакырып кына теләгеңә ирешеп булмый. Әле карар кабул ителгәч тә, күңел үз кануннары буенча организмны ватмыйча, дөресрәге, ватарга теләмичә, төрле юллар эзләп үзенең эшен башкара.

Фәиз менә шул нәрсәләрне дә аңлауга иреште. Һәм күңел халәтенең тотрыклылыгы артканын тойды.

Шуңа күрә тиз арада гына илдәге яшәешне үзгәртеп, тормышны бөтенләй башка юлдан алып китәргә өндәүчеләргә ул көлеп карады. Халык бит ул шул ук бер аерым алган кеше организмы кебек.

Үзенең тормышында булган һәрнәрсәне табигый, димәк, шулай булырга тиеш иде, дип кабул итә башлады ул. Үзенең озак һәм каты чирләвенең дә психик авыру икәнлеген аңлады, ләкин моны аңлагач, ул котсыз калмады. Аңлаган икән, димәк, аңардан котылып була. Аңлашылмый торган нәрсә яман. Андый авыруны неврозлар төркеменә кертсәләр дә, табигате барыбер психоневрология инде аның. Ләкин ул сиңа бирелгән. Ул — синеке, үзеңнеке.

Нәркизәнең ташлап китүен дә ул тиз гафу итте. Аны һич кенә дә гаепләмәде. Һәм, ни гаҗәп, үзендә дә бу очракта гаеп тапмады. Никадәр эзләп казынса да, үзен битәрләрлек нәрсә каезлап чыгара алмады.

Бер елдан артык эшсез яткач, ул МТСка барды. Аңарда зур үзгәрешләр күрделәр. Кыяфәте инде куркыныч түгел. Киемнәре чиста. Казаннан Марат исемле бик зыялы зур бер врач килеп йөри янына. Аракы эчми икән хәзер. Бу инде нинди дер башка кеше шикелле иде.

Чынлап та, башка кеше иде инде ул. Чәчләре майланып тузган, күзләре шашкан җанварныкыдай саргайган йөзле, кешеләрдән куркып качып йөри торган кеше түгел иде инде ул. Әле кыяфәтендә авыруы һаман беленсә дә, аның күзләрендә инде яшәү елтыравы барлыкка килде.

Аны каравылчы итеп алдылар. Фәиз моңа сөенде, чөнки каравылда китап укырга мөмкинлек бар һәм ул төне буе иректә. Барыбер төннәр йокысыз үтә (соңгы вакытта ул көндез йоклауга ияләште). Акчасы аз, ләкин бу бит вакытлыча гына.

Поселокка психология, философия буенча кызыклы китаплар алып килеп сата башладылар: күбесе чит телләрдән тәрҗемә: Ницше, Шопенгауер, Кант, Шпенглер, Фрейд, Кьеркегор һ. б. бик күп төрле, аның күңелен тиз арада яулаган авторларның хезмәтләре сусаган җан иясенә бер йотым су сыман булды.

Акча кирәк, чөнки ул китаплар кыйммәт тора. Сатырдай әйберләрен сатып бетереп ала башлады ул китапларны соңгы вакытта. Кулга эләккәннәрен каравылда төннәр буе рәхәтләнеп укый иде.

Аңа эштә дә, күршеләре дә: «Матурланып киттең эчмәгәч»,— диделәр. Аларның шундый ягымлы сүзләреннән ул тагын да дәртләнебрәк китте һәм күзләрендә яшәү шатлыгы ныграк чагылды. Кеше сүзе көчле тәэсир итә ни дисәң дә!

Акча җитмәүлеге генә нык кыерсытты күңелне. Соңгы вакытта аппетит та ачылып китте. Йокы яхшырды. Тәмле ризыкны, гомумән, ашауны организм нык сагынган иде. Аракыдан соң тәмәкене дә ташлагач, хәл тагын да җиңеләебрәк китте. Марат та бер тапкыр килгәч әйтеп ташлады: «Йә, туган, җуләрләнеп йөрүең тәмамланды, дөньяга дөрес карый башладың»,— диде.

Дөрестән дә, акылдан язып була икән ул!

Шулай да хәвефләнүләр аны тиз генә ташламады әле. Һава торышы үзгәрүләр, эссе көннәр, ябык биналар әле һаман аны өркетә иде. Ләкин аңарда ышаныч туды инде — ул хәвефләнүләр ничек килсә, шулай китеп тә барачак. Моны аңлау да зур үзгәреш иде!

Иң яхшы, уңай, җылы тәэсир кешеләрнең аңарда яхшыга таба үзгәреш күрүләре булды. Аларның сәерсенмичә, шикләнмичә караулары үз-үзенә ышанычын арттырды, шул сәбәпле аның кыяфәте тагын да матурланыбрак китте. Моны, әлбәттә, башкалар сизеп алды һәм тагын яхшы мөнәсәбәт белән карадылар. Фәиздә дәрт тагын да артты. Менә шундый алтын бөҗра барлыкка килде!

Күңел яшәү мәгънәсен эзли икән, димәк, ул аңа кирәк. Әгәренки яшәүнең мәгънәсе кирәк икән, димәк, яшисе килә! Шул яшәү мәгънәсен эзләү үзе мәгънә була ала түгелме? Үзеңнең гаебеңне танып, гөнаһларың өчен тәүбә итеп яшәү мәгънә түгелмени?

Соңгы вакытта Фәиз ниндидер бөеклекнең, мәңгелекнең бер өлеше итеп тоя башлады үзен. Күңеленең хак юлны табуын сизде ул. Кешеләр аны дошман итмиләр — моны абайлавы аңа шулай ук гаҗәп һәм мөһим иде. Гомумән, дөнья аны дошман итми, киресенчә, ярата сыман тоелды.

Иң зур ярдәмне аңа китаплар бирде. Үзен аңларга, кешеләрне танырга иганә алды ул китаплардан. Күп нәрсә ачыкланды, күп сорауларга җаваплар табылды. Хәтта үзен акларлык күп нәрсәләрне мәгълүм кылды. Күңеленә аһәңдәш, авазлаш фикерләр бихисап күп иде философларның, психологларның, бөек язучыларның китапларында.

Күп нәрсәне ул, гәрчә инде алар аңа электән таныш булса да, беренче мәртәбә күргәндәй, ачыш ясаган сыман кабул итте. Табигатьнең матурлыгы белән тагын соклана башлады. Иң мөһиме — аңарда хәзер ялгызлык хисе өстен түгел иде. Күңел ялгызлыгы бетте аңарда. Берүзе үз уйлары белән утырганда да аңа рәхәт була башлады, чөнки ул үзен кемгәдер, нәрсәгәдер кирәк дип хис итте. Җирдәме, күктәме — аны кемдер ярата, кемдер күзәтә, ләкин начар ниятләр белән түгел, киресенчә, аның өчен кайгырып, яхшылык теләп.

Үзенең дөньяда ялгыз түгеллеген аңлады ул! Тормыш күренешләреннән, һәрбер яңа туган көннән ямь-тәм табылды.

Китаплар алып килеп сатучы Гөлҗиһан апа белән ул якыннанрак танышты. Гөлҗиһан апаның уллары Мәскәүдән, Ленинградтан китап ташу белән шөгыльләнә икән. Т.да һәм тагын берничә шәһәрдә, поселокларда шул китапларны махсус сатучылар сата ди. Гөлҗиһан апа, бик тере һәм нык хатын, пенсиягә чыксам да, тик яталмыйм дип, үзе сату итәргә булган. Фәиз инде аның аша үзенә кирәкле китапларны кайтартты. Берничә тапкыр Гөлҗиһан апа аңа китапларын сатарга да тапшыргалады. Фәизгә бу эш бик ошап китте.

— Син, шундый акыллы, укымышлы егет, нишләп монда каравылда ятасың?! — дип сорарга җөрьәт итте беркөнне Гөлҗиһан апа аңардан.

— Мин озак авырдым. Әле яңа гына тернәкләнеп киләм. Әлбәттә, яңа эш турында уйлый башларга кирәк,— диде Фәиз.— Бигрәк тә хәзер. Заманалар үзгәреп бара, акчасы да күп кирәк.

— Шулай булмый. Гел болай йөрмәсәң, өйләнергә дә кирәк булыр бит.

— Әлбәттә. Ләкин иң элек аякка басарга кирәк. Мин яңадан туган шикелле хәзер. Үземне табарга кирәк. Дөрес, мин үземне таптым, әмма бу тормыш-көнкүрештә, чынбарлыкта да үземне табу зарур.

— Карале, безгә бит кешеләр кирәк. Син китап яратучы, әйдә безнең янга. Мин малайларым белән сөйләшермен.

Фәизнең шатлыгы чәчрәп чыкты:

— Яхшы булыр иде, Гөлҗиһан апа! Мин сатарга да, ташырга да әзер! Китап эшен яратып башкарачакмын!

— Ярар, мин иртәгә үк улларым белән сөйләшермен,— диде Гөлҗиһан апа һәм сәгатенә карап куйды.— Бүген мине алырга иртәрәк килергә тиешләр. Карале, Фәиз, мин бер атна-ун көн башка эш белән мәшгуль булачакмын, син минем урынга сатып тор инде китапларны, яме.

— Ярар,— дип шатланып ризалашты Фәиз.

— Сиңа тагын бер әйтәсе сүзем бар минем. Безнең дә бер сатучы кызыбыз бар, ул фантастик китаплар сата, Сания исемле. Бик акыллы, чибәр. Кияүдә түгел. Мин синең турыда әйткән идем инде аңа.

Фәиз кып-кызыл булды:

— Ничә яшь соң аңа?

— Утыз тирәсе. Үзеңә ничә әле?

— Миңа да утыз.

— Сез, минемчә, пар килгәнсез. Берәр ничек таныштырырга иде сезне.

Фәиз бик нык уңайсызланып:

— Сездә эшли башласам, бәлки танышырбыз да,— дип куйды.

Танышу озак көттермәде.

Фәиз махсус корылган киоскта инде бер атнадан артык китап сата иде. Күбрәк детектив алдылар. Акча шактый күп җыелды. Инде ичмаса акчаны да алырга берәрсе килсен иде тизрәк дип уйлады ул.

Ниһаять беркөнне Т.дан җиңел машина килде һәм аннан урта буйлы, джинсы костюмнан мөлаем гына бер хатын-кыз килеп чыкты.

— Мин Сания,— диде ул ап-ак тип-тигез тешләрен ялтыратып.— Гөлҗиһан апа хәлегезне белергә һәм сезгә булышырга кушты.

Фәиз, әлбәттә, бу очрашуга әзер түгел иде, шулай да бигүк коелып иңмәде, үзен кулга алып, кыю булырга тырышты:

— Бик шатмын. Мин Фәиз булам.

— Миңа сезнең турыда Гөлҗиһан апа сөйләде инде. Шул кадәре күп китап укучыны беренче мәртәбә күрүем, диде сезнең турыда.

— Сезнең хакта да миңа Гөлҗиһан апаның сөйләгәне булды.

Җиңел машина шундук кире китеп барды.

Гөлҗиһан апа урынында Сания эшли башлады. Аларны кавыштырыр өчен шулай оештыргандыр хәйләкәр апа.

Күп тә үтмәде, Фәизне төрле сату пунктларына китаплар ташучы итеп эшкә алдылар. Элеккеге «автоклуб» машинасы белән Т.га кайткан китапларны санап, барлап тиешле урынга, сатучыларга тапшыру җиңел эш түгел, ләкин аның хезмәт хакы да шактый зур булып чыкты.

Сания К.дә эшләвен дәвам итте, Фәиз исә көн саен эштән соң Т.дан поселокка, үз өенә кайтып йөри торган булды.

Сания белән аның арасында беренче көннән үк якынлык сизелде. Аларның уртаклыклары күп иде, икесен бербөтен итәрлек сыйфатлар һәм шартлар җитәрлек булып чыкты. Алар бер-берсенә тизияләштеләр һәм бернинди махсус әзерлекләрсез-нисез Фәизнең йортында бергә яши дә башладылар.

## 27

**1990** нчы елны К. поселогында да мәчет төзергә тотындылар.

Фәиз бу күренешне зур кызыксыну белән күзәтте. Чөнки бу изге эшкә ниндидер бер бизнесмен тотынганны ишетте ул. Имеш, махсус фонд бар икән, шул фонд аша ничектер зур һәм затлы мәчет салдырып йөри ди. Имеш-мимешләргә ышанганда, ул кеше мафиозник икән.

Мәчет, чынлап та, поселокның шыксыз фонында әллә нинди галәмәт бер сарай булып аерылып һәм калкып килеп чыкты.

Фәиз әллә ничә тапкыр барасы итте мәчеткә, ләкин никтер күңеле тартмады. Аллага һәрвакыт ышанды ул. Хәтта балачактан ук: теге вакыйгадан соң бигрәк тә, хәтта кирәгеннән артык күккә мөрәҗәгать итте ул кайвакыт. Ләкин һәрвакыт Алланы үзенчә кабул итте. Ул Иләһи Көчне бернинди китапларга сыйдырып, канунлаштыру мөмкин түгелдер дип уйлады. Халыкны төркем-төркем итеп аңа табындыруны да кабул итәсе килмәде аның. Аллага табыну — изге эш, изге халәт, шуңа күрә ул һәркемнең үзенчә һәм үзендә булырга тиеш дип ианды. Ләкин мәчетләргә һәм моңарчы яшәп килгән дин формаларына аның протесты яки тел-теш тигезергә теләге беркайчан да тумады.

Мәчет төзүне оештыручылар үзләренең затлы машиналары, артык тук чырайлары белән башкалардан аерылып торгангамы, әллә үзәк урамда Ленин һәйкәле һаман басып торгангамы, мәчетне төзүгә җыелган акчаның шикле булуыннанмы — ни сәбәптәндер күңел салкынчарак кабул итте бу мәчетне. Халык та анда берән-сәрән генә атлады. Бу күренеш, әлбәттә, пошаманга калдырырлык иде. Чөнки һәркем белә — мәчеткә йөргәне дә, йөрмәгәне дә: мәчет кирәк, дин кирәк! Әмма ләкин «кирәк» дип кенә булмый шул.

Хәер бирергә дип Фәиз беркөнне мәчеткә таба юнәлде.

Мәчеткә керү белән уң якта өстәл янында бер карт йокымсырап утыра иде. Фәиз мөселманнарча сәламләде:

— Әссәламегаләйкем!

— Вәгаләйкем әссәлам,— дип җавап бирде карт тоныкк кына тавыш белән.

— Бабай, мин хәер бирергә кердем. Берничә кеше өчен, зинһар, дога кыл.

Шуннан соң ул кесәсеннән алдан ук әзерләнгән егерме биш сум акчаны чыгарды.

— Әнә шунда яшниккә сал,— диде карт, стенада эленеп торган калай тартмага ымлап.— Кем өчен дога кылырга икәнне мин язып алырмын, аннары җомга көнне дога кылырбыз.

Фәиз акчаны салгач бабайның каршына утырды:

— Зәбир өчен дога кылыгыз.

— Атасының исеме ничек?

— Хәтерләмим,— диде Фәиз уңайсызланып.

— Ярар, тагын кем?

— Стеклов. Урыс кешесенә ярыйдыр бит? Стеклов. Аның өчен, зинһар, дога кылыгыз.

Ул шундук куркып калды — бабай Стекловның кем икәнен сорамаса ярар иде. Кеше үтерүче өчен дога кылу ярый микән монда? Сорамады, язып куйды. Фәиз тезеп китмәкче иде: Зосимов өчен, үзенең әти-әнисе өчен, Гөлүсә өчен, Фәрит һәм Рәмзия өчен... Ләкин күп кешене атаганны яратмас, башка вакытта килеп алар өчен хәер бирермен дип уйлады.

— Ә үзеңнең атың ничек?

— Мин Фәиз, Гыйльметдин улы.

— Ярый.

Бабай язып алды.

Мәчеттән чыкканда арттан пөхтә, матур кыяфәтле карт атлады. Бу — хәзрәт үзе иде. Фәиз аның белән сөйләшергә теләде. Борылып-

борылып каравыннан хәзрәт аның ниятен аңлады һәм беренче булып үзе сүз катты:

— Мәчеткә беренче мәртәбә килүең, ахрысы?

— Әйе.

— Мәчеткә йөрергә кирәк,— диде хәзрәт.

Фәиз затлы кыяфәтле бу руханидан мондый сүзләрне ишетергә теләмәгән иде. Һәм сөйләшергә тотынуына үкенде. Ләкин инде сүз башланган иде.

— Мәчеткә, әлбәттә, йөрергә кирәктер, ләкин чакыру кирәк микән кешене мәчеткә? Минемчә, яратырга кушып яраттырып булмый, табынырга өндәп табындыру мөмкин түгел. Бу бит иман эше.

Хәзрәт гомуми хак сүзләр белән диннең тәртипкә алып баруын, динсезлекнең куркынычлыгын, иман төшенчәсенең ни икәнен озак итеп сөйләргә керешге.

— Куанырга кирәк бүгенге көн өчен,— дип тәмамлады ул сүзен.

— Һәр көн өчен куанырга кирәк, минемчә. Ә дин хакында бик дөрес һәм матур сүзләр әйттегез, хәзрәт. Шулай да, минемчә, һәр кешенең йорты мәчет булырга тиештер. Һәр кешенең күңелендә калкырга тиештер манара. Алай гына да түгел, кеше — үзе манара. Менә шул манарадан әйтергә тиеш ул изге азанны. Иманлы кеше үзенең кешелек манарасыннан әйтергә тиеш үзенең хак кеше сүзен! Күңелендә манараң булмаса мәчеткә йөреп вакыт уздырудан ни мәгънә!

Хәзрәт югалып, куркып калды. Бу ир-егетнең, кечкенә буйлы булуына карамастан, зур басым белән, тәэсирле итеп сөйләве аны нык каушатты. Ул ислам турында тагын берничә сүз әйтмәк булды, ләкин җитешә алмады, Фәиз дәвам итте:

— Мин мәчетләргә каршы түгел, Алласыз кеше түгел мин. Ләкин «ышан!» дип ышандыру мөмкин түгел. «Иманлы бул!» дип иман тудырып булмый кешедә. Иман кешенең үзендә туа. Ул йә була, йә юк. Ишеткәнемчә, бу мәчетне төзегәндә акча урлау, материаллар югалу булгалады, кемнәргәдер җинаять эшләре дә ачтылар. Әгәр дә мәчет төзегәндә дә җинаять кылына икән, аннары мондый гөнаһларны юу мөмкин булырмы? Урланган акчага мәчет салуны, яки шул мәчетне салырга дигән акчаны урлауны кайсы мәчеттә ярлыкарлар икән соң? Тәүбә итәргә кайсы мәчеткә барырга кирәк булыр икән? Гафу ит, хәзрәт, шәхсән сиңа бернинди ачу-үпкәм юк. Ләкин бу турыда синнән башка тагын кем белән сөйләшим!

Фәиз тиз-тиз атлап китеп барды. Җәйге көн эссе иде болай да, ул шабыр тиргә батты. Соңгы вакытта болай кызып сөйләшкәне юк иде аның. Күрәсең, җыелып йөргән. Артка борылып карарга җөрьәт итмәде. Хәзрәт нишләп калгандыр, кая таба киткәндер — аны кызыксындырмады.

Өйгә кайткач, уйланып утырды. Катырак әйтеп ташламадыммы хәзрәткә! Юк, дөрес әйттем! Хакым бармы соң минем алай фикер йөртергә? Бар. Рәнҗетмәдемме беркемне дә? Юк.

Мин һаман үзем колачлый алмаган нәрсәләр белән баш ватам түгелме? Ә кем кайгырырга тиеш соң бу хакта?! Үз фикеремне, үземнең мөнәсәбәтемне әйтергә тиештер мин!

Ул үзенә-үзе гаҗәпләнде — кайдан килде аңа бу кодрәт? Соңгы вакытта, әйтәсе сүзен әйткәннән соң үзен битәрләми башлады ул. Авырып йөргән вакытта да гаделлек эзләп, әйтәсе фикерләрен әйтергә тырышып йөрде. Ләкин ул вакытта күп нәрсәне дөрес аңламаган. Хәзер исә ул инде белә — кайсы вакытта хаклы ул, кайсы вакытта — юк.

Мәчетләр төзелүгә, хөкүмәтнең дингә мөнәсәбәте үзгәрүгә ул чын күңеленнән куанды, ләкин шул мәчетләр тирәсендә йөрүчеләрдән канәгать түгел иде. Мәчетне нинди кешеләр, нинди акчага төзиләр — бу әһәмиятле ләбаса. Бит Аллаһы Тәгаләне кеше үзе «кызыксындырадыр», төзеп куелган манарада түгел бит эш, кешеләрнең үзләрендә!

Беркөнне Т.дан кайтып төшкәч, йорты каршында җиңел машина торганны күрде. Машина тирәсендә, аяк астына карап, кемдер ары-бире йөренде.

Алар бер-берсенә шактый вакыт карап тордылар.

— Ренат?!

— Мин, мин, танымыйсыңмы әллә?

Алар ирләрчә кочаклашып исәнләштеләр. Сания ул көнне калада иде, икенче көнгә китаплар әзерләп куясы бар иде аның. Шул сәбәпле өстәл буйдакларча гына әзерләнде. Чәйне озак итеп эчтеләр, чөнки чәй эчкәндә сөйләшү рәхәт, ә сөйләшер сүзләр галәмәт күп иде.

Армия белән күңелсез хатирәләр бәйле булса да, аларның төп әңгәмәләре шул хәрби хезмәт тирәсендә булды. Учебканы искә алдылар, Кулишны сүктеләр. Ренат, аты-юлы белән сүгенеп, дисбатны каргады.

— Әти әйтте миңа синең монда яшәвеңне.

— Армиядән кайту белән ник килмәдең соң?

— Әй, закрутился!

— Кайда эшлисең соң?

— Мин бер фирманың сакчысы. Түбә дип аталабыз без. Чаллыда яшим бит мин.

— Кайчан кайттың теге аннан?

— Сиксән икенче елның көзендә. Ике ел дисбатта, аннары калган бер елымны хезмәт итеп бетердем тагын.

Фәиз аны җентекләп күзәтте. Үзгәрешләр эзләде. Чөнки күп вакыт узды бит инде. Үзгәрешләр күрде ул аңарда, ләкин ниндидер «этеп торучы» үзгәрешләр иде. Элек тә җан биздергеч кеше иде ул, хәзер бигрәк тә: күзләрендә нур юк, чыраенда — нәфрәт. Тормышы авыр булмаса да, дөньяны күралмый шикелле. Җилкәләре тагын да киңәйгән, кыска итеп алдырган чәче аның суксаң да авыртмый торган чыраена нык килешеп тора. Утыздан узып киткәч, армиядәге шикелле булмассың инде. Ләкин барыбер шул ук Ренат иде бу.

— Үзгәргәнсең,— дип куйды Фәиз.

— Син дә возмужал,— диде Ренат чын күңелдән гаҗәпләнеп.— Интеллигент стал. Син бит дохлый гына бер нәрсә идең армиядә.— Ул авызын кыйшайтып көлеп куйды.

Көлүе шул ук калган аның. Бу ямьсез көлүне Фәиз яхшы хәтерли.

Фәиз үзе турында, каты авырган елларын төшереп калдырып, сөйләде. Беренче хатыны белән аерылуын, хәзер Сания исемле хатыны барлыгын әйтте.

— Китап сатып акча кермә соң бераз?— дип кызыксынды Ренат.

— Ярыйсы болай. Нинди китаплар сатасың бит, аннан да тора.

— Мин сине мондый солидныйлангансыңдыр дип уйламаган идем,— дип кат-кат гаҗәпләнде Ренат.— Син минем батя янына килгән булгансың икән.

Фәиз кинәт караңгыланып китте.

— Әйе. Карале, Ренат, минем синнән сорыйсым килә — синең әтиең мине элегрәк тә белә идеме әллә?

— Белмим, юктыр. Шул, үзең килгәч кенә танышкансыздыр дип уйлыйм.

— Минем турыда нәрсәләр әйтте?

— Бергә хезмәт иткән дустың килеп китте, диде. Шул. Фәиз исемле, К.дә яши икән, диде. И все.

Фәиз сизенде — кунак сөйләшеп туйды, килүенең сәбәбе дә Фәизнең хәлен белү түгел. Башка төрле йомыш алып килгән аны монда, күренеп тора.

— Ничек киләсе иттең?— дигән булды Фәиз, аның йомышы менә-менә билгеле буласын сизеп.

— Служак бит син минем! Сагындым! Күрәсем килде,— диде Ренат һәм башын читкә борып аскы иренен тешләде.— Аннары минем сиңа бер дело бар.

— Тыңлыйм.
— Фәиз, мин беләм, син мине өнәп бетермисең. Армиядә яратмый идең мине. Тик шулай да, служак, якташ буларак, ярдәм ит.
— Минем ярдәмгә мохтаҗмыни син?! Ат хәтле ир кеше!
— Тыңла әле син. Мин бер кешене кыйнадым. Дөресрәге, сугыштык без аның белән. Разборка булды. Мин кыйнамасам, мине кыйнарлар иде, аңлыйсыңдыр инде. Җинаять эше ачтылар, чөнки теге больницада ята. Мин инде акча да төртеп карадым, бөтен элемтәләрне файдаланмакчы булдым. Эшләр бик җитди, туган, һич кенә дә берсен дә игә китереп булмый.
— Ә мин ничек ярдәм итә алам сиңа? — диде Фәиз, чынлап торып бу кансыз кешене күралмыйча. Ул аның армиядә Кравчукны кыйнаганын исенә төшерде. Дошман иде бу. Ләкин кызгануга гына лаеклы дошман.
— Мин Маратны очраттым күптән түгел Казанда. Аның әтисе белән минем батя бергә эшләгәннәр иде Т. больницасында. Каядыр җыенганын белгәч: «Кая барасың?» — дип сорадым. Ул: «К.гә, бер кеше янына», — дип җавап бирде. Һәм синең турыда озак итеп сөйләде. Фәиз, брат, миңа «психически ненормальный» дигән справка кирәк. Марат аны эшли ала бит, сөйләшик әле аның белән. Юкса тагын төрмәгә утыртып куялар бит мине!
— Нишләп соң син үзең Марат белән сөйләшмисең?
— Безнең мөнәсәбәтләр бигүк дустанә түгел. Безнең әтиләр дә гел конфликтта яшәде. Ул сине бик ихтирам итә, зинһар, ярдәм ит. Миңа следователь үзе дә әйтә, шундый белешмәң булса, котыласың, ди.
Фәиз авыр сулап куйды:
— Күңелсез очрашу булды әле бу, Ренат. Утыз яшь бит инде сиңа!
— Фәиз, син бит Марат белән дус, эшләт миңа справка. Минем сиңа әле кирәгем чыгачак. Мин сиңа акчасы-ниенме, кыскасы, җаның ни тели...

## 28

— Сиңа ярдәм итә алырмыныммы соң?
— Аңламадым?
— Төрмәдән бәлки котылып булыр, ләкин андый справка белән син үзеңне-үзең барыбер алдый алмаячаксың.
— Мине төрмәгә утыртачаклар! — дип кычкырып җибәрде Ренат һәм шундук тавышын йомшартты. — Фәиз, брат, әйдә Марат янына.
Фәиз нишләргә дә белмәде. Күренеп тора — Ренатның эшләре мөшкел. Ләкин имгәнеп больницада ятучы кеше дә бар бит, аны шушы миһербансыз бәндә кыйнаган. Служак! Фәиз аңа озак итеп карап торды. Бу кешенең гомере үзенең асылын, үзенең фаҗигасен аңламыйча үтеп китәр микәнни, дип уйлады Фәиз киеренкелектән яңак итләре шыгырдап йөреп торган якташына нинди мөгамәләдә булырга икәнне үзе өчен ачыклый алмыйча. Хәер, ул башкача булдыра алмый, бүтәнчә яши алмый. Башка кеше хәленә кереп, аның халәтен аңларлык зат түгел бу. Аның үз хакыйкате бардыр, күрәсең. Ул башка төрле кануннар буенча яши. Гаепләп тә булмый бит аны, ул бит барыбер үзен хаклы дип саный. Хәтта кыйнап имгәткән дошманын да ул һаман әшәке сүзләр белән сүгеп утыра бит. Моны инде үзгәртү мөмкин түгел. Каршысында кеше кыяфәтле хайван утыра иде. Фәиз аны әлек дошман итә иде, бу минутларда исә ул аны чын күңелдән кызганды. Сәер кызгану белән.
— Сине инде төрмә дә, справка да коткара алмаячак, — диде Фәиз. — Ярар, әйдә Марат янына барып кайтабыз. Мин синең өчен аңардан үтенәчәкмен — берәр ничек коткарсын сине төрмәдән. Ләкин сине үзеңнән коткаруны вәгъдә итә алмыйм.
— Син әллә нинди фәлсәфә белән сөйләшмә инде. Хәлләрем хөрти бит. Бүген үк барабызмы? Нәрсә тагын уйга баттың?
Фәиз сәгатенә карап алды.
— Хәзер китәрбез. Ничә сәгатьтә барып җитәбез Казанга, ничек уйлыйсың?

— Бер сәгатьтә очып барып җитәбез.

Фәиз уйга чумып утырды.

— Син безнең полктагы ЧПны ишетмәгән булгансыңдыр инде,— диде ул, армияне исенә төшереп.— Сине дисбатка утырканнан соң булды ул хәл. Безнең тугызынчы полкта Стеклов фамилияле бер «фазан» Зосимов дигән бер сержантны кыйнап үтерде.

— Шуннан?

— Стекловны унбиш елга ирегеннән мәхрүм иттеләр.

Ул тынып калды.

— Ник кузгаттың соң әле син ул вакыйганы?—дип сорады Ренат.

Фәиз суынып беткән чәен йотып куйды.

— Ул вакыйгада мин үземнең гаебемне, ниһаять, аңладым. Мин ун елдан артык аңларга тырышып йөрдем: Зосимовның вәхшиләрчә һәлак булуы, Стекловның унбиш елга җәзага дучар ителүендә минем нинди гаебем бар соң? Мин бер тапкыр Стекловка суккан идем. Яңагына чалт иттереп. Шулай килеп чыкты инде, армия бит, үзең беләсең. Мин сугарга мәҗбүр булдым. Инде Зосимовны үтергәннән соң, аны унбиш елга хөкем иткәч, котсыз калдым — мин дә өлеш керттем бит бу фаҗигагә. Стекловның күңелендә ниләр барлыгы, нинди хисләр кайнаганын кем белгән? Бәлки аның бу дөньяга нәфрәте зур булгандыр, үпкә, рәнҗү җыелгандыр. Һәм инде минем аның яңагына сугуым соңгы тамчы булгандыр аның мөлдерәмә тулган күңеле өчен. Бәлки аңа сугучылар күп булгандыр миңа кадәр дә, алар барысы да аңарда җыелып йөргәндер — арада минем сугуым да бар. Мин күп уйландым, ниһаять, соңгы вакытта мондый нәтиҗәгә килдем: мин Стекловка сукмасам, бәлки, ул Зосимовны кыйнап үтермәгән булыр иде.

— Аларның мөнәсәбәтләрендә катнашың булмагандыр бит?

— Юк. Мин аларның мөнәсәбәтләрен бөтенләй белми идем. Эш бит анда түгел. Син мине аңламыйсың.

— Мин сине беркайчан да аңлый алмадым.

— Аңламасаң аңламассың. Зосимов та кызганыч, чиксез кызганыч. Ләкин без бит белмибез үлем аның өчен нәрсә — җәзамы, әллә, киресенчә бүләкме. Мин Стеклов өчен нык кайгырам. Хәзер туксанынчы ел. Унбиш елга утырттылар. Тәк, сиксәненче ел. Ун елын утырды инде, тагын биш елы калгандыр. Минем, никтер, аны күрәсем килә, аның язмышына мин битараф түгел. Үзгәрде микән, нишләде икән, аңлады микән? Минем аңардан гафу үтенәсем килә. Инде урыны күккә ашкан Зосимовтан бәлки гафу үтенергә тиештер мин? Юк, никтер Стекловтан гафу үтенәсе килә. Чынлап та, бер кеше генә гаепле була алмый. Кемнеңдер гөнаһлары аркасында яңа гөнаһлар туа. Мин күрәм, сиңа кызык түгел минем сөйләгәннәрем. Син хәтта миннән көләсең, сизәм.

— Юк, юк,— дигән булды Ренат. Асылда исә ул Фәизнең сәерлекләреннән учебкада да туеп беткән иде.

— Мин Стекловның язмышы өчен нык борчылам. Ничек яшәр? Мин тагын шунысын уйлыйм әле. Мин аермачык күз алдыма китерәм Стекловны да, мәрхүм Зосимовны да. Зосимов хәрби хезмәт өчен, армия өчен яралмаган. Ул бит бу дөньяга башка вазифалар өчен килгән. Мәсәлән, сугыш чыга калса, Зосимов кебекләр кеше үтерә алмаячаклар. Андый юаш, йомшак кешеләр эше түгел сугыш. Ә менә Стеклов — коеп куйган хәрби! Армиягә менә шундый кешеләр кирәк. Менә шундый поляр рәвештә капма-каршы, ике төрле кешене бер үк армиягә, бер үк полкка, бер үк бетон дот эченә бер атнага бикләп куйганнар. Иректә бу ике кеше бер-берсенә якын да килмәс иде, мөгаен, аларның бернинди уртаклыклары, хәтта сөйләшергә уртак темалары да булмас иде. Ә монда аларны бер савыттан ашарга мәҗбүр иткәннәр!

— Син учебкада чакта кыйнаучыларны, үтерүчеләрне сүгә идең, хәзер инде үтерүчене яклап утырасың.

— Нишләп аңламыйсың син мине! Үтерүчене һәм үтерүне аклау мөмкин түгел. Ләкин һәр җинаятькә бик күп кеше өлеш кертә. Мин Стекловны акламыйм, әгәр акларлык булса, аның турында уйланып йөрмәс идем. Менә шул шул — аны аклап булмый, шуңа күрә дә мин кайгырам, үземдә гаеп сизәм. Мин аны очратырмын шикелле.

— Аны очратып нишләмәкче буласың?

— Гафу үтенәм. Көлмә, Ренат.

— Көлмим.

— Гафу үтенәм. Аннары нәрсә әйтермен, белмим. Ләкин минем аны күреп иң элек гафу үтенәсем килә. Бәлки бу көлке тоеладыр, ләкин шулай.

## 29

Кичке тугызда алар инде Казанга барып җиттеләр. Ренатның яңа «девяткасы» чакрымнарны санга суга торган машина түгел икән.

Ишекне Әлфия ачты. Марат Мәскәүгә киткән булып чыкты.

Әлфиянең кереп чәй эчәргә кыстауларына рәхмәт әйтеп, алар китү ягын карадылар. Әлфия эчтән генә аларның кереп тормауларына сөенде, чөнки аның әтисе кунакка килгән иде. Аны Фәиз белән очраштырасы килмәде. Фәиз инде элеккечә псих булмаса да, алар арасында конфликт шул килеш калган иде әле.

— Фәиз, Марат кайткач сезгә кунакка киләбез, әзер торыгыз,— диде Әлфия, озатырга чыккач.

— Ярар.

— Саниягә күп итеп сәлам әйт. Шулай да, ник әйтмисез, нинди йомыш бар иде?

— Гафу ит, Әлфия, әлегә бу сер,— диде Фәиз итагатьле итеп.

Инде берничә баскыч аска төшә башлагач, ишек ачылды һәм Ильяс Хәмитович пәйда булды:

— Нинди таныш тавыш дисәм.

Ул тавышны таныды, ләкин Фәизнең үзен танымыйча торды.

— Исәнмесез, Ильяс Хәмитович! — диде Фәиз гаҗәеп тынычлык һәм битарафлык белән.

— Исәнмесез! Әлфия, бу шул Фәиз, ахрысы?

— Әйе,— диде Әлфия.

Фәиз баскычтан кире күтәрелде һәм аста үзен кая куярга белми торучы Ренатка дәште:

— Син бар, чыга тор. Мин хәзер...

Ренат подъезддан чыгып китте. Әлфия Фәизнең менеп килүен күргәч, бераз пошаманга калды, ләкин Фәизнең кыяфәте бернинди куркыныч вакыйга «вәгъдә итмәде».

Алар бер-берсенә карап тордылар.

— Ильяс Хәмитович,— дип башлады сүзен Фәиз.— Мин менә, мөмкинлектән файдаланып, Әлфия монда чакта сездән гафу үтенәм. Гафу итегез.

— Сезне танырлык түгел,— дип җавап бирде Ильяс Хәмитович, «син» дип сөйләшергә кыймыйча.— Шул кадәре үзгәргәнсез. Олыгайгансыз, гомумән, яхшыга таба үзгәргәнсез.

— Рәхмәт.

— Ә нишләп әле гафу үтенергә булдыгыз миннән?

Фәиз тагын аңа карап куйды. Әлфия бер әтисенә, бер Фәизгә күз салды да:

— Мин комачауламыйммы? — диде.

— Юк, юк,— диде Фәиз,— комачауламыйсың. Минем гафу үтенүемнең сәбәбе белән кызыксынасызмы? Мин сезне, Ильяс Хәмитович, күралмыйм. Минем сезгә әле һаман җиңеп бетермәгән ниндидер нәфрәтем бар. Шул нәфрәтем өчен гафу үтенәм мин.

Ильяс Хәмитович авызын кыйшайтып елмайды, велюр халатының путасын кысыбрак куйды.

— Бигрәк катлаулы,— диде ул, ни әйтергә белмәгәч.

— Мин белмим — сезниләр кичерәсездер. Гаебегез нихәтле, икебездән кайсыбыз ныграк гаепледер теге вакыйгада — моны сез дә, мин дә барыбер төгәл әйтә алмаячакбыз. Шуңа күрә мин шикләнәм: минем нәфрәтем ни дәрәҗәдә хаклы һәм аны, гомумән, аклап була микән? Әгәр дә инде миндә нәфрәт яши икән сезгә карата, мин аны тәгаен юк итә алмыйм, бетерергә көчемнән килми. Шуңа күрә гафу үтенәм мин сездән. Аңлыйсыздыр шәт. Әлфия, син дә мине гафу ит.

— Син нәрсә инде, Фәиз, барысы да яхшы, һәммәсе үз урынында. Син бер дә борчылма,— диде Әлфия матур елмаеп.

— Ярый, Ильяс Хәмитович, хушыгыз! — диде Фәиз.

— Хушыгыз! — диде Ильяс Хәмитович.— Сез дә мине гафу итегез,— дип өстәп куйды ул.

— Мин сезне инде күптән гафу иттем. Ярый, Әлфия, сау булып тор.

— Исән-сау гына кайтып җит, Фәиз,— диде Әлфия шатланып.— Марат кайткач ук сезгә киләбез.

— Көтәм! — диде Фәиз һәм кузгалды.

Ул канәгать иде — үзеннән дә, әле генә килеп чыккан кыска гына әңгәмәдән дә.

Баскычтан йөгереп төшкәндә аның аяклары да тимәде. Үзен шулхәтле җиңел, рәхәт итеп тойды ул. Урамга чыккач кына нинди йомыш белән килгәнлекләрен исенә төшерде һәм шундук сөмсере коелды.

— Нишлибез? — диде Ренат аптырашта калып.

— Көтәбез инде. Бер атнадан гына кайта ди ул.

Ренат яман итеп ыңгырашып сүгенде.

— Киттекме? — диде ул сәгатенә карап.

— Син мине К. гә илтеп куясыңдыр бит хәзер?

Ренат тагын бер тапкыр сәгатенә күз салды да:

— Әллә батяның лесхозына кайтып ял итикме? Ерагын ераграк инде, аның карауы, ашап-эчеп, мунча кереп, ял итеп булачак. Анда батя борчылып көтәдер мине.

— Әти-әниең беләме соң синең бу матавыгың турында?

— Беләләр. Мин бит инде батяның связьләрен дә кузгатып йөрим. Кайтып киләбезме безгә?

Фәиз икеләнеп торганнан соң:

— Иртәгә мине илтеп куярсыңмы соң өемә? — дип сорады.

— Базара нет! — дип җавап бирде Ренат.

Ни гаҗәп: Фәизнең лесхозга барасы килде. Ул хәтта Ренатның чакыруына сөенде. Теге урман, теге вакыйга булган теге урын аны котсыз калдырмады, киресенчә, ул анда таба якынаерга теләде. Инде сазлыкны актарып, дустын эзләү нияте юк, әмма ләкин ул тарафларга барыбер күңел тартты.

Тагын бер сәбәп аны урманга әйдәде: Ренатның әтисе Сәлим Сәлмәнович аның турында нәрсәдер белә! Ул инде хәзер аннан курыкмый, үзе турында ниләр генә белмәсеннәр һәм сөйләмәсеннәр — барысын да тыныч кабул итәчәк.

Дөм-караңгы төн уртасында алар С. га барып җиттеләр. Һәм тиздән урман авызына да килеп керделәр. Июль ае коры торганлыктан, юл начар түгел иде. Тып-тын калган агачларны фара яктысы белән «ялыйялый» машина лесхозга таба юл тотты.

Теге урман бу. Кибет басканнан соң алар шушы урманга, ләкин икенче яктан — Т. ягыннан килеп кергәннәр иде.

Урманга кергәч куркырмын дип уйлаган иде ул. Әмма менә инде ике чакрымлап юл үттеләр урман эченнән, алай коелып иңмәде.

Ренатның тавышы аны сискәндереп җибәрде:

— Күп калмады. Менә бу наратлык беткәч — лесхоз инде.
Фәиз сәгатенә карады: сәгать төнге икенче ярты иде.

Биш-алты йорттан, каралты-курадан һәм төрле хуҗалык биналарыннан, складлардан торган лесхозны этләр өрүе дер селкетте.

Сәлим Сәлмәневич Фәизне күргәч һич кенә дә гаҗәпсенмәде, ә газиз улы кайтуына чиксез куанды. Ренатның әнисе Саҗидә апа зарлана-зарлана ашарга әзерләп йөрде, бу вакытта Ренат белән әтисе чоланга чыгып киттеләр, матавыктан ничек качарга дип баш ваттылар, ахрысы. Фәиз сабыр гына табын әзерләнгәнне көтеп утырды. Зур, киң һәм бай йорт иде бу. Монда бөтен нәрсә алпавытларча — келәмнәр дә, җиһазлар да, төрле антиквар вак-төяк һәм тәрәзәдәге чаршаулар да.

— Сез дә милициядән түгелдер бит? — дип кызыксынды Саҗидә апа.

— Юк,— диде Фәиз.— Без Ренат белән бергә хезмәт иттек.

— Ә-ә-ә, дисбатта мәллә?

— Юк, учебкада бергә булдык.

Саҗидә апа иренә караганда күпкә картрак күренде. Күрәсең, улы өчен нык борчылганнандыр. Ренат күп хәсрәт китергәндер анасына.

Гүя, Фәизнең уйларын чамалады — Саҗидә апа хәлсезләнеп өстәл янындагы урындыкка утырды да иреннәренең кыймылдавын тыя алмады, елап җибәрде:

— Вакытсыз гүрләргә кертәчәк бу бала мине! Тагын утыртып куячаклар бит үзен! Тагын кемнедер кыйнаган бит. Инде акыл кермәсме дип өметләнеп йөргән идем.

Чоланнан Сәлим белән Ренат килеп кергәч, Саҗидә кухня ягына шылды, иренең ачулануыннан курыкты булса кирәк.

Өч ир тавыш-тынсыз гына ашарга утырдылар. Өй эчендә күтәргесез авыр тынлык урнашты. Кухнядан Саҗидәнең сулкылдаганы ишетелде. Аның елавы тынлыкка караганда мең кат яманрак иде.

Әнисенең елавын ишетергә теләмәгән Ренат сүз башлыйсы итте:

— Фәиз, мунчаны иртәгә ягарбыз инде, яме. Хәзер ашагач йокларбыз, вакыт соң.

— Мин мунчалар кереп тормам. Иртәгә мине К. гә илтеп куярсың иртәнге якта.

— Иртәгә безгә бер милиционер килергә тиеш, аны көтәргә кирәк, ул безнең якын дустыбыз,— диде Ренат.— Ярдәм итәргә тиеш ул миңа. Сиңа иртүк кайтып җитәргә кирәкмени К. гә?

— Киләсе кешең булгач соңрак та ярый, иртәгә минем буш көнем. Хатыным борчылмасын дип кенә ашыгуым. Кайчан вакытың булыр, шунда илтеп куярсың.

— Марат янына барырга кирәк булыр барыбер,— диде Ренат уйга калып.

— Барырбыз. Кайтсын гына.

Моңа кадәр тыңлап кына утырган Сәлим сүз катты:

— Маратның әтисе белән күп еллар бергә эшләдек. Ярдәм итми калмас.

— Камил абыйга да өмет зур.

— Нинди Камил ул? — дип кызыксынды Фәиз.

— Иртәгә киләсе милиционер. Үзе спецкомендатура начальнигы ул, ә танышлары, элемтәләре бик күп һәм нык. Ул коткарырга да может,— диде Ренат өмет белән.

Сәлим Сәлмәневич кинәт кызып китте:

— Коткарырга может!!! Хайван син! Синең үзеңне бәреп үтерәсе бар! Утыз яшькә җитеп һаман сугышып йөрисең. Башың төрмәдән чыкмаячак бит синең!

Ул шап иттереп улының башына сукты. Тагын кизәнде, ләкин өлгермәде, Ренат аның кулын эләктереп алды да шытырдатып кысты.

— Әти, сукма! По-хорошему әйтәм!

Ата белән улы бер-берсен якаларга тотындылар. Фәиз аларны аерырга маташты. Сәҗидә апа шыр ярып кычкыра-кычкыра алар тирәсендә бөтерелде.

Гауга озак дәвам итмәде. Сәлим сүгенә-сүгенә ишегалдына чыгып китте. Сәҗидә ирен дә, теңкәсенә тигән улын да каргый-каргый зур бүлмәгә кереп китте.

— Менә шулай яшибез,— дип ыңгырашты Ренат, башын куллары белән уып.

Фәиз чак кына: «һәркем үз тормышына лаек»,— дип ычкындырмады.

Йокы килмәде, Фәизнең бу ыгы-зыгыдан качып аулакта уйланып ятасы килде. Чөнки теге сазлык моннан ерак түгел. Уйлануга мохтаҗлык туды. Ләкин элеккечә авыру халәт түгел иде бу. Бары тик тагын бер кат үзенә-үзе берничә сорау биреп, үзен-үзе тыңлап карау нияте иде.

Сәҗидә апа Фәизнең үтенече буенча чоланда урын җәйде. Хуҗалар үзләре, Ренат та өйдә йокларга булдылар.

Фәиз ишетеп ятты: Сәлим ишегалдында корык-корык йөткереп, аратирә сүгенеп йөренде. Өйгә кергәндә ул чолан ишеген ачып эндәште:

— Ренат, синме монда?

— Юк, Сәлим абый, мин бу, Фәиз.

Сәлим чоланга керде:

— Синмени?— Ул караңгыда капшап урындыкны тапты һәм карават янына куеп утырды.— Мин сине күргәч шаккаттым. Нык үзгәргәнсең. Кыяфәтеңә, киемеңә караганда тормышларың шәп күренә.

— Соңгы вакытта эшләр яхшыга таба бара. Үзегез ни хәлләрдә?

— Күрәсең бит инде нихәлләрдә икәнне!

Фәиз торып утырды. «Утны кабызмаса ярар иде»,— дип уйлады ул. Сәлимнең дә яктыда утырасы килмәде.

— Теге дустыгыз Камил ярдәм итәр әле. Больницага эләккән егет кенә терелеп чыксын инде берүк. Хәзер, минемчә, күбрәк аңа ярдәм итәргә кирәктер.

Караңгылык эченнән Сәлимнең уфылдаганы гына ишетелеп куйды.

— Белгән юк инде, нишләргә бу малай белән!— диде ул чарасызлыктан кат-кат уфылдап.

— Аны бернишләтеп булмый инде, үзеннән тора,— диде Фәиз.— Марат кайткач, аның белән дә сөйләшербез. Тик мин шәхсән шикләнәм, Марат андый эшкә барыр микән? Сау-сәламәт кешегә андый белешмә ясау җиңел, җайлы түгелдер ул.

— Марат белән әйбәтләп сөйләшерсең инде. Син аның якын дусты дип ишеттем мин.

— Сез, Сәлим абый, әллә ниләр беләсез, бөтен нәрсәдән хәбәрдар булып торасыз.

— Мәсәлән?

— Хәтерлисезме, җиде-сигез ел элек С. да очраштык.

— Әй, булган-беткән. Син андый нәрсәләр турында күп уйланма.

— Юк, юк, син ачыклык керт. Нәрсә беләсең минем турыда? Мәсәлән, сазлык турында.

— Беләм мин сазлык турында. Нишләп сазлык аша үрмәләп йөрүегезне дә беләм.

Фәиз кычкырып диярлек сорады:

— Күрдеңме әллә?

— Күрдем. Тс-с-с, кычкырып сөйләшмә.

— Зәбирнең батканын да күрдеңме?

— Күрдем.

Фәиз тынсыз калды.

— Ни уйлыйсың, әйт,— диде ул Сәлимнең тып-тын утыруыннан шүрләп.

— Берни дә уйламыйм. Минем үз кайгым кайгы. Булган-беткән. Ул турыда уйлама син. Оныт.

Әмма Фәизнең сораулары әле бар һәм күп иде.

— Мин аны коткарырга тырыштым, аңсын күрдеңме?

— Әлбәттә.

— Ә минем хәрәкәтләремдә сәерлек чагылмадымы?

— Каян хәтерлим инде мин! Коткарырга маташтың, коткаралмадың. Нәрсә инде баш катырасың? Ярар, тыныч йокы. Суык түгелме сиңа монда?

— Юк.

— Ярый, тыныч йокы.

— Туктале, күреп торгач, нишләп син үзең ярдәмгә килмәдең?

— Курыктым. Син беркемгә дә сөйләмә бу турыда.

— Мине ачуланмыйсыңмы? — диде Фәиз, мең сорау арасыннан шунсын сайлап.

— Нишләп мин сине ачуланырга тиеш?

— Мине гаепле дип уйламыйсыңмы?

— Юк. Ә син үзең мине гаепләргә җыенмыйсыңдыр бит?

— Юк.

— Шулай булгач! Тыныч йокы!

— Тыныч йокы,— дип пышылдады Фәиз.

Сәлим өйгә кереп китте.

Менә сиңа мә! Шул коточкыч мизгелләрне тамаша кылып торган кеше бар. Мин шуның белән әле генә сөйләштем. Ул шаһит. Ул сине С. да очрашканнан соң барып әләкли дә алыр иде, ләкин сатмаган бит мине. Күреп торган. Ярдәмгә килмәгән. Карап торган. Гаепләп булмый инде аны. Нишләп йөргән икән соң ул сазлыкта? Нишләп йөрмәсен, аның хуҗалыгы бит ул. Нишләп шул баткак урыннарда йөргән соң ул? Мине гаепләми шикелле, ләкин С. да очрашкач төрттереп, ачуланып, гаепләп сөйләште бит ул. Ә хәзер гаепләми. Нишләп гаепләсен, ул бит минем эчке халәтемне күрмәгән, нинди көчләр мине ул вакытта әсир иткән — ул белми. Читтән карап торганда миндә шикләнерлек нәрсә күренмәгәндер.

Ул сазлык моннан ерак түгел бугай. Нишләп куркыныч түгел соң? Хәтта рәхәт. Нарат исе аңкытып торган такталардан төзелгән чоланда ничек рәхәт булмасын. Күптәнге теләгем гамәлгә ашты — мин бу урманга килдем. Әле сазлыкка да барып җитәрмен. Барыбер барырга кирәк анда. Бәлки ул сәфәрем бернинди яңалык өстәмәс, ләкин бу кирәк, бу мөһим. Нигә кирәк — белмим.

Нишләп тыныч соң минем күңелем? Битарафлыктанмы? Чарасызлыктанмы? Бу галәмдә көчсезлегемне аңлауданмы? Ренатның язмышы белән үземнекен чагыштырып караганнан түгелме? Мин бит аның янында бәхетле күренәм. Бу тикмәгә түгел.

Өй эченнән быдыр-быдыр сөйләшкәннәре ишетелде. Гаилә йокларга җыенмый, газиз улларының киләчәк язмышына бәйле әңгәмә бара анда. Аны төрмәдән коткару турында баш ватып уйланалар. Нинди мескенлек. Нинди фаҗига! Кеше ярдәме генә коткармаячак — моны Фәиз аңлый. Ләкин Ренат үзе моны аңлауга ирешерме?

Иртәгә Камил киләчәк, ди. Милиционер. Шул Камилдер инде. Спецкомендатура башлыгы булгач. Тагын күзгә-күз очрашырга туры килер микәнни аның белән?

Урман һавасы, чоландагы нарат исе, тирә-яктагы искиткеч тынлык үзенекен итте — ул йокыга оеды.

## 30

Уянгач, Фәиз тавышларга колак салып ятты. Урман мең төрле авазлар белән җырлады, сайрады, шаулады. Өй эченнән кичәге шикелле бырдап сөйләшкән тавыш ишетелде. Әллә йокламаганнар да инде?! Ишегалдындагы тавышлар матуррак — тавыклар җырлый,

торымнан-торымга әтәч кычкырып куя. Эт кемгәдер, нәрсәгәдер өреп ала.

Чолан ишеге ачылды, Ренатның тупас чырае күренде:

— Йоклыйсыңмы әле?

— Юк, мин инде күптән уяндым,— диде Фәиз һәм торып киенә башлады.

— Әйдә, чәй эчәбез дә кузгалырга кирәк.

— Камил килдеме соң?— дип кызыксынды Ренат, чөнки бу минутларда аның өчен шунысы әһәмиятлерәк иде.

— Килде. Без инде чәй эчтек. Әйдә, битеңне ю да.

Бу, чыннан да, теге Камил Сабитов иде. Фәиз чәй эчкәндә ул көлемсерәп күзәтеп утырды.

— Мин сине танымый тордым,— диде Камил, гаҗәпләнүен яшермичә.

— Ә мин сезне күрү белән үк таныдым,— диде Фәиз.

— Нык үзгәргәнсең. Хәзер инде хулиганланмассың дип уйлыйм, алайса теге вакытта котымны алган идең.

Фәизнең бу кешегә тагын ачуы кабарды, ләкин ул иң дөрес юлны сайлады, гафу үтенде.

— Сез мине гафу итегез. Ул вакытта мин чынлап та башка кеше идем. Хәзер ул вакыйга кабатланса, мин сезгә бер генә дә авыр сүз әйтмәс идем. Ләкин шуны әйтәсем килә: мин сезнең турыда яхшы фикердә түгел һәм сезне тасвирлар өчен бигүк матур сүзләр сайламас идем.

Ренат аптырашта калды:

— Сез танышлармы әллә?

— Без күптәнге танышлар,— дип җавап бирде Камил.— Синең берәр туганыңмы әллә бу?

— Без — служаклар, бергә хезмәт иттек армиядә.

Ренатның эче поша башлады, чөнки ул күрде: майор белән Фәиз арасында ниндидер дошманлык бар.

Өйдән чыгып барганда Ренат Фәизне туктатып өйгә кире алып керде.

— Сезнең мөнәсәбәтләр начар мәллә Камил белән?

— Минем аның белән бернинди мөнәсәбәтләрдә буласым килми,— диде Фәиз үзен тыныч тотып.

— Син, туган, онытма, ул минем әтиемнең якын дусты. Мине төрмәдән коткарырга йөри ул. Син тып-тын бул инде.

— Ярар, ярар, борчылма,— дип тынычландырды Фәиз аны.

Камилне спецкомендатура машинасы алып килгән иде. Күрәсең, Сәлим Сәлмәневичтан агач материаллар аладыр, үзе килгән бит иртүк, үзенең машинасы белән — Ренатны җинаять бәласеннән коткарырга маташа!

Фәизнең болардан качасы килде. Ят кешеләр иде болар барысы да — Ренат та, аның ата-анасы да, Камил бигрәк тә. Хәтта Камилнең шоферы милиция сержанты да ниндидер караңгы йөзле бер мокыт булып күренде. Дошман да түгел болар, ләкин Фәиз бу төркемнән түгел. Ә шулай да барыбер шул кешеләр белән аралашырга туры килә. Язмыш кат-кат очраштыра, сөйләштерә, төрле мөнәсәбәтләргә керергә мәҗбүр итә.

— Без сине К. гә кертеп китәрбез,— диде Ренат Фәизгә.

Ренатка әтисе нәрсәдер аңлатып торган арада Фәиз белән Камил машина янында көтеп тордылар.

— Син бик аз сүзлегә әйләнгәнсең хәзер,— диде Камил елмаеп.— Сөйләшмисең дә.

— Минем сезнең белән сөйләшер сүзем юк,— диде Фәиз битарафлык белән.— Шулай да бер соравым бар.

— Тыңлыйм.

— Фәрит белән Рәмзия кайда яшиләр хәзер?

Камилнең чырае кинәт җитдиләнде.
— Төрле җирдә яшиләр алар хәзер,— диде ул читкә карап.
— Аерылыштылармы әллә?
— Әйе.
— Рәмзия белән очрашасызмы һаман?— дип кызыксынды Фәиз һәм бу сорауны биргәненә шундук үкенеп тә куйды.
— Без өйләнештек Рәмзия белән.— Ул сәгатенә карап куйды.— Ренат! Әйдә инде тизрәк! — дип кычкырды ул Фәизнең күңелсез әңгәмә башлавына ачуы килеп.
— Хәзер,— дигән тавыш ишетелде ишегалдыннан.
— Ә Фәрит кайда икән хәзер?
Камил Фәиздән тәмам гарык булды һәм җикереп диярлек әйтеп ташлады:
— Юк Фәрит. Үлде! Асылынып үлде!
Фәиз өнсез калды:
— Чын әйтәсезме?
— Әйе. Аерылыштылар да, ай буе авылында эчеп яткан. Аннары асылынып үлгән.
— Сез Рәмзия белән өйләнешкәчме, әллә аңа кадәрме?
Камил усал итеп карады:
— Кайчан булса да барыбер түгелмени сезгә! — диде ул, дистанция ясарга омтылып булса кирәк, «сез»гә күчеп.— Безнең бергә тора башлаганыбызны белгән дә асылынган. Йә, нәрсә әйтерсең? Тагын мине гаепләргә тотынырсыңмы?
Фәиз каушады:
— Юк, беркемне дә гаепләргә җыенмыйм,— диде ул чак кына ишетелерлек итеп.
— Син бит интеллигент хәзер, нәрсә чүп-чарда казынасың! — диде Камил, әңгәмәдәшенең сөмсере коелганны чамалап.— Минем аңлавымча, төзәлеп килә торган җөйләрне яңадан каезлап канатырга маташасың син.
Ренат күренде, аңа ияреп атасы, анасы чыктылар.
Фаиз Камил әйткән соңгы хәбәрдән һушсыз калды, ул Ренатның ата-анасы белән саубуллашырга да онытып УАЗның арткы утыргычына кереп утырды. Камил алга, шофер янына, Ренат Фәиз белән янәшә урнашты.
Камил юл буе шоферы белән сөйләште, Ренат үз кайгысы белән бергә-бер калып, уйга чумып утырды. Фәиз сөйләштермәсеннәр өчен башын ян тәрәзәгә терәп, күзләрен йомып, йокымсыраган булып кыланды.
Фәрит һәм Рәмзия турында ни уйларга да белмәде ул. Үзен гаепләргә омтылып карады күңеленнән, ләкин гаебемне танысам да, башкача булдыра алмас идем, ул очракта да мин үземнең мөнәсәбәтемне белдерми калалмас идем, дип катгый рәвештә билгеләде.
Тар бу дөнья, тар. Күпме язмышлар чуаланып, буталып, болганып, бер-берсенә бәйләнеп беткән. Шушы Камил белән генә дә ничә тапкыр очрашырга туры килде бит. Кешеләр гел бер-берсе белән очрашып яшиләр. Чынлап та, билгеләп кара син — кем нәрсәдә гаепле, ни дәрәҗәдә гаепле.
Зәбир — Ильяс Хәмитович — Рәмзия — Фәрит — Камил — Сәлим Сәлмәневич — Тәлгать абый — Ренат — Марат — Әлфия һ. б. Болар барысы да тегеләйме, болаймы бер-берсенә бәйле ләбаса. Мин дә шул чылбырда. Боларның кайсысы бәхетле соң? Бәхетлеләре бармы соң арада? Һәммәсе теге яки бу матавыкта катнаша. Кайсысыннан башлана гаепгөнаһ? Чөнки һәрберсенең фаҗигасе башканыкына килеп тоташа. Бу дөньяда һәркемнең гөнаһы башка берәүнең гөнаһы нәтиҗәсе. Синең кылган яман эшең икенчесен тудыра. Ни башы юк, ни азагы. Фәрит асылынган. Фәритне кем үтергәнне дә әйтеп булмый бит — Рәмзияме,

Камилме, минме? Әллә тагын башка кешеме? Ничек табарга бу очракта гаеплене?

Уйламаска кирәк, уйламаска. Ләкин уйламыйча да булмый. Салкын акыл белән уйланырга кирәк. Дөньяны үзгәртү мөмкин түгел. Фәкать үзеңне генә үзгәртү мөмкин. Ә моның өчен акыл белән уйлану зарур.

Милиция машинасыннан төшкәч, ул үзен тынчу баздан килеп чыккандай хис итте. Сания аны күреп алды да киосктан йөгереп чыкты:

— Кайда булдың син?

Фәиз аны кочаклап үпте, чем-кара күзләренә озак карап торды.

— Сания,— дип пышылдады ул.— Мин сиңа соңыннан сөйләрмен кая барганымны. Хәзер ул турыда сорама, яме. Мин бик сагындым сине.— Ул Саниянең куе чәч толымына бармаклары белән кагылды.— Мин яратам сине.

Сания читенсенеп як-ягына каранды:

— Әйдә инде киоскка керик. Мин дә бик сагындым сине. Бүген китап алучы бөтенләй булмады.

— Җәй көне күп алмаслар инде.

— Йә, сөйлә инде, кайларда булдың?

— Сания, аннары сөйләрмен. Аптыратма, зинһар.

Алар бер-берсеннән күзләрен алалмыйча карап утырдылар.

— Әйдә кайтабыз,— диде Сания көтмәгәндә.

— Әйдә,— диде Фәиз шатланып.— Бүген ял итсәк тә була.

— Мин бик кайгырдым. Кайттым, ә син юк. Иртәгә шәһәргә барырга кирәк синең белән. Яңа китаплар кайтты, үзебезгә кирәкләрен сайлап алыйк.

Фәиз мәхәббәт тулы күзләрен бер мизгелгә дә читкә алмады.

— Сания,— диде ул сөйгәненең кулын тотып.— Мин куркам.

Сания сагайды:

— Нидән?

— Сине югалтырмын дип куркам. Минем моңарчы югалтуларым күп булды. Дөрес, мин күп нәрсә таптым соңгы вакытта, ләкин минем югалтканым да шактый булды. Син мине ташларсың дип куркам.

Сания аны кочаклап алды, кайнар иреннәре белән пышылдады:

— Инде ничә тапкыр вәгъдәләр бирдек бит бер-беребезне ташламаска. Мин яратам сине, Фәиз. Без синең белән бүген бәхетле, ә башкасын уйлама, курыкма.

Алар кочаклашып үбешкәнне шул тирәдә уйнап йөргән бала-чага тамаша кылып торды. Алар киоскның пыяласына терәлеп чырык-чырык көлә башлагач, Сания белән Фәиз дә рәхәтләнеп көләргә тотындылар.

Чыннан да, бүген бәхетле иде алар.

Киоскны бикләп кайтырга чыккач, тиктормас бала-чага аларны үртәп-көлеп беркавым озата бардылар. Балаларның кыланмышлары мәхәббәттән бераз исергән ике җан иясенә шатлык өстәде, күңелләрдәге бәйрәмне купшыландырып җибәрде.

Өйгә кайтып кергәч Сания серле караш белән Фәизне күзәтте. Фәиз сизенде: сөйгәне нидер әйтергә тели, ләкин кыймый.

Сания озак түзеп торалмады, әйтергә булды:

— Фәиз, мин авырлы бугай.

Һәм бу хәбәр ничек тәэсир итте икән дип Фәизгә төбәлде. Фәиз бу хәбәргә, чынлап та, әзер түгел иде:

— Чын әйтәсеңме?!

— Әйе.

Фәизнең шатлыгын яшереп торырлык түгел иде, аның йөзе балкыды, нишләргә белмәгәч, Саниясен иңнәреннән кысып җилтерәтеп куйды.

— Сания! Җаным! Бердәнберем!

Ул аны кочып кайнар итеп үбәргә тотынды.

— Мин сиңа әйтергә куркып торган идем,— диде Сания тынычланып.— Шуңа күрә кичә син өйдә булмагач, икеләтә нык борчылдым.

Фәиз тәмам телсез калды, аның бәхете ташып чыкты. Ул бары тик:

— Сания...— дип торымнан-торымга кабатлады.

Сания инде сөйләшүнең тагын да җитдирәк өлешенә әзерләнгән иде.

— Фәиз, без инде ир белән хатын шикелле яшибез,— дип башлады ул сүзен.— Ярый ла Т. дагы туганнарым сине яхшы белә, начар яшәмәвебезне дә күреп торалар. Корсагым зурайганчы Оренбургка кайтып килергә кирәк, әти-әниләрдән башка гаилә корып яту дөрес булмас.

Фәиз моны үзе дә яхшы аңлый. Саниянең әти-әнисе Оренбургта яши. Анда, әлбәттә, барып аларның фатихасын алырга кирәк. Моңарчы ничектер җай чыкмады, ыгы-зы[illegible]ш, тормыш матавыклары тын алырга да ирек бирмиләр.

— Син хаклы,— диде Фәиз.

— Оренбургка икәү бергә кайтып килсәк, әйбәт булыр иде. Шулай кирәк тә инде ул, тәртибе шундый.

— Икәүләшеп кайтып килү кирәк,— диде Фәиз.— Без болай сөйләшик. Син иң элек берүзең генә кайтып кил. Аларга минем турыда сөйләп.

— Мин инде хатларымда гел синең турыда язам.

— Барыбер үзең генә кайтып аларны «әзерләп» куй, психологик яктан. Мин нык каушыйм. Башта үзең сөйләшеп, кәефләрен чамалабрак торсаң, әйбәт булыр. Аннары инде икәүләшеп барырбыз.

Сания каршы килмәде, Фәизнең борынына йомшак кына чиртеп куйды.

— Куркак. Ярар инде, шулай итәрбез. Алайса мин озакка сузмыйм. Иртәгә Гөлҗиһан апа белән сөйләшәм дә билет алып кайтып китәм. Киоскта үзең торасың инде берәр атна чамасы.

— Киоскта мин торырмын. Тик менә синнән башка атна буе нишләрмен? Үлмәм микән?

— Мине яратсаң, үләргә тиеш түгел син!— Ул эчен тотты.— Сиңа үләргә ярамый, без хәзер икәү генә түгел, без хәзер инде өчәү!

## 31

Ул ике-өч көн ял итәргә булды. Сания кайткач алар бергәләп яңа китаплар сайлап алачаклар. Озакламый алар Т. га бөтенләй күчеп китәрләр инде.

Әлегә акча бар, кызыклы китаплар сатылып бетте диярлек, бераз ял итеп алсаң да ярыйдыр дип уйлады ул.

Бу көннәрдә Фәиз үзенең үткән утыз еллык гомеренә күз салып гаҗәпкә калып йөрде. Ун елга якын чирләп йөргән кеше бит мин. Мин идем микән ул?! Теге вакыйга нишләп мине элеккечә эзәрлекләп йөрми икән? Нишләп гаҗәпләнергә! Ул вакыйга, димәк, инде үз эшен башкарды. Ул газапның да ахыры бар икән ләбаса. Моны тою, бер караганда, шатлыклы булса да, шул ук вакытта сәер һәм үзенчә моңсу да иде. Онытыла гына күрмәсен бөтенләй үк вакыйга. Бөтенләй гафу итәргә ярамый үземне. Әгәр бүгенге халәтем яхшы икән, димәк, шулай тиеш. Үземне яңадан сазлыкка сөйрәү кирәк микән?

Аның күптән инде Каенсарга барасы килеп йөри иде. Зәбир кибеттән чыккач кереп качкан лапасны, гомумән, шул йортны, шул йортның иясе Закирә әбине күрергә күптәннән хыялланып йөрде. Зәбир бик озак итеп (хәтергә мәңге уелсын дип микән) сөйләде ул әби турында. Хәер биргәнен, әбинең дога кылып калганын сөйләде. Кайчан да булса аңа яңа йорт салып бирү турында хыялланган иде Зәбир. Әле сазлыкка җитәрәк тә шул әбине телгә алды бит ул.

Беркөнне Т. дан Гөлҗиһан апаның уртанчы улы үзенең «Волга»сы белән яңа китаплар алып килде. Ялвара торгач, Фәиз аны Каенсарга барып кайтырга күндерде.

Машинаны кибет янында туктатып һәм шунда көтеп торырга кушып Фәиз, Закирә әби йортына таба атлады.

Иң кырыйдагы йорт. Калкулыкта. Аста буа ялтырап ята. Әнә урманга таба сузылган юл. Зәбир шушы юлдан йөгергәндер урманга.

Күз алдына җан сыкраткыч күренеш килеп басты. Йортны да, лапасны да сүткәннәр, хәтта морҗасы да инде җимерелеп, таралып, тузан булып җилгә очкан. Йорт урынында кирпеч ватыклары, иске такта калдыклары, тиз генә күз иярләшмәслек чүп-чар гына калган. Әйтерсең лә, тирән булып уелып калган баз чокыры йоткан барысын да.

Буада кер чайкаучы апа киерелеп карап торды. Фәиз авыз ачарга да өлгермәде, чәрелдек тавыш белән апа үзе кычкырды:

— Кемне эзлисең?

Сәер сорау. Кемне эзлисең??? Шайтан белсен, кемне эзлим, Закирә әбинеме? Зәбирнеме? Үземнеме?

— Бу Закирә әбинең йорты идеме? — диде ул, ниһаять, һәм буага таба атлады.

Хатын да аңа каршы берничә адым атлыйсы итте:

— Әйе. Өч ел элек җирләдек без аны. Урыны җәннәттә булсын.

Апа тагын нидер әйтмәкче иде, килгән кеше белән иркенләп сөйләшергә нияте бар иде бугай, ләкин Фәиз тизрәк читкәрәк китәргә ашыкты. Ялгызлык кирәк, уйларга, эшкәртергә кирәк бу хәбәрне. Янда кеше булганда иң мөһим нәрсәләрне аңлау кыенлаша, ялгызлык кирәк кайбер нәрсәләрнең асылына төшенергә.

Кайчандыр капка баганасы булып хезмәт иткән черек агачка утырып ул урман ягына карады. Зәбиргә нык тәэсир иткән Закирә әби. Миңа нишләп шулкадәр йогынты ясады соң бу йорт һәм монда яшәгән Закирә әби? Югыйсә бит Зәбир сөйләгәннән генә беләм, аны бер генә мәртәбә дә күргәнем юк.

Зәбир аның дога кылып калганын кат-кат әйтте бит аңа. Нишләп соң ул алайса батып үлде? Әллә Закирә әбинең догалары кабул булмаганмы? Әллә соң догалары кабул булганга сазлык йоттымы? Юктыр, батып үлсен дип дога кылмагандыр бит инде.

Сорауларга җавап тапкан саен яңа сораулар туа. Мәңге җавап биреп булмастайлары туа тора.

Шушы йорт белән бергә нәрсәдер югалды. Мәңге кайтарып булмаслык югалту бар шулай да. Ничәмә еллар чирләп, газап кичеп йөрсәң дә, һәркем үз урынына кило дөньяга дип үзеңне юатырга тырышсаң да, акланырга мөмкинлекләр булган суәттә дә, барыбер ниндидер югалту бар. Офтанып та, үкенеп тә, елап та, асылынып та кайтарып булмаслык нәрсәдер әрәм киткән, бетүгә дучар ителгән.

Моңсу, һай моңсу! Еларга иде, ләкин никтер елап булмый. Бары тик инде чишелгәндер дип уйлаган төен каяндыр күтәрелеп тыгылды. Җан сыкравы тәнне чемердәтеп алды. Чүп-чарда казынган саесканнар хуҗа булып калган йорт урынын урман ягыннан искән җил кат-кат сыпырыргә маташты. Гүя, нәрсәнедер, кемнедер юатмакчы була, башыннан сыпырырга тели. Юк, мөгаен ул кемнедер эзлидер.

Фәиз үзен ниндидер котылгысызлыкның корбаны итеп тойды. Утыз ел дәвамында юлында очраган кешеләрне хәтерендә барлап утырды ул. Аның шушында, нәкъ менә шушында барысыннан да — яхшыларыннан да, яманнарыннан да, үзенә карата миһербанлы булганнарыннан, җәберләүчеләреннән, кыерсытучыларыннан да — барысыннан да гафу үтенәсе килде. Чарасызлыктандыр бу бәлки? Ләкин бу аның бердәнбер чарасы иде. Аның күңеле шуны таләп итте. Аның моңарчы да эчтән генә күп кешеләрдән кичерүләрен үтенгәне булды. Әмма бүген ярлыкауны сорамаган кешесе калмасын иде аның! Шулай җиңелрәк булачак.

Күз яшьләре үзләре мөлдерәп тәгәрәделәр. Ярлыкагыл! Ярлыкагыл! Ярлыкагыл!

Ул үзендә җиңеллек тоя башлады. Вакыт җитәрлек. Яшиселәр бар әле. Хәзер инде яшәвемнең мәгънәсе бар һәм дә мин мәгънәне үземдә үзем таптым. Димәк, яшәвем тикмәгә түгел!

## 32

Яп-якты җәй уртасы иде. Күңелдә дә июль иде ул көнне. Шушы көннәрдә Сания килергә тиеш. «Килергә» түгел лә, кайтырга тиеш! Мәңгегә монда, аның белән калырга. Тиздән машина алсак, Т. га барып йөрергә җиңелрәк булачак. Сагындырды Сания, нык сагындырды. Тормыш тагын яңа юнәлеш алачак. Соңгы вакытта якты офыкка таба борылган иде тормыш елгасы, Сания кайткач мәңгелек июль тарафларына агачак ул елга. Алар икесе бер салда йөзәчәкләр. Гомер кояшы баеган тарафка агар ул сал әлбәттә. Булсын! Бу котылгысызлыкка буйсынуның үз рәхәте бар түгелме! Җаваплылык монда инде синең өстән төшә, син буйсынасың — илаһи бөек көчкә. Тәкъдир салны кая алып барса, алар шунда барачаклар. Ләкин бергә, мәңге бергә. Балалары туачак. Шатлыктан, бәхеттән йөрәк ярылмасын инде берүк. Бу кадәр күтәренкелекне, илһамны бик озак вакытлар авыр кайгы асрап яшәгән күңел ничек күтәрер?!

Рәхмәт, хәтер, асра элек булган гаеп-гөнаһларны, югалтма һәм беркемгә дә бирмә! Син саклаган хатирәләрдән башка бүгенге бәхетләр тулы булыр идемени?! Үзең кичергән, үзең кылган эшләрне хәтер сакламаса, үз гөнаһларыңны үзең тоеп, алар синдә яшәүләрен дәвам итмәсә, бүген бәхеткә ирешер идеңмени син?!

Фәиз үзендә галәмәт куәт тойды. Нәрсә дә булса эшләргә кирәк. Әллә ишегалдын себереп куяргамы? Өйгә кереп көндәлеккә фикерләрне язарга утырыргамы? Күңел күтәренкелеге бу мизгелләрдә шулкадәр көчле булды ки, ул хәтта үзен-үзе кая куярга белмәде, кодрәтен нинди эшкә сарыф итәргә икән дип әрле-бирле сугылды.

Кинәт капка ачылды.

Капканың ачылуы ук ничектер гадәти түгел иде. Озынча гәүдәле, ябык булса да, эре сөяклелеге белән киң җилкәле күренгән бер ир кеше ишегалдында пәйда булды. Аның тар соргылт күлмәге төксел чыраена тәңгәл килеп тора иде. Ярымпеләш башында әллә кайдан күренеп торган яра эзе баш урталай ярылмасын өчен тырышып-тырмашып бөрешкән җөйгә әверелгән һәм баш иясенең күпне күргән зат икәнлеген искәртеп тору вазифасын үтидер шикелле иде.

Сәер зат Фәизгә таба атлады. Кем бу? Буй-сыныннан, килеш-килбәтеннән куркырлык булса да, ниндидер бик тә таныш, якын сыман иде чакырылмаган кунак.

Дүрт-биш адым җитәрәк ул туктады.

Алар бер-берсен таныдылар. Әмма берсе дә ни эндәшергә, ни беренче адымны ясарга җөрьәт итмәде. Әйтерсең лә, бу очрашу — дөрес түгел, ялган. Әгәр дә моны чынбарлык дип кабул итсәң, тагын ниндидер зур хата китәр сыман иде.

Фәиз таң калды. Бер генә хәрәкәт тә аның көченнән килерлек түгел иде бу мизгелләрдә. Каршысында басып торучы кеше, күренеп тора, коелып иңәрдәй зат түгел, ләкин хәтта ул да телсез, өнсез калды.

— Фәиз, синме? — диде ул күкрәгенең тирәнлегеннән зур авырлык белән шушы ике авазны чыгарып.

Фәизнең коты очты.

— Зәбир!

Фәизнең ышанасы килмәде. Әгәр дә Зәбир җитмеш сигезенче елгы кыяфәтендә килеп басса, төшләргә кергәндәгечә күренсә, әлбәттә, моңа ышанмас идең. Әмма ләкин каршыда йончыган, тормыш йөген сөйрәп арыган мосафир басып тора. Унике ел эчендә ул коточкыч нык үзгәргән.

Ләкин бу — Зәбир! Чын кешене ничек кенә төш итәргә теләсәң дә, барып чыкмас! Чынбарлык ул шунысы белән котылгысыз һәм куркыныч та — аны инкарь итү берничек тә мөмкин түгел.

— Исәнме,— диде Зәбир әле һаман бер урында торып.

Фәиз дә баскан урынында шакраеп катып калды.

— Исәнме! Син Зәбирме? Юк, юк, охшагансың гына!

Көтелмәгән кунак сары металлдан корылган тешләрен ыржайтып елмайды, ләкин күзләре барыбер салкын, усал булып калды, көлмәде.

— Мин — Зәбир.

— Син бит...— Фәиз ни әйтергә һәм нишләргә белмәде.— Син теге дөньядан мәллә?!

Зәбир аның каршысына килеп басты:

— Теге дөньядан дисәң дә була. Исәнме! — Ул татуировкалар белән шәмәхәләнеп беткән кулын сузды.

Фәиз әле һаман аңышмыйча торды: әллә, чыннан да, яңа гына сазлыктан калкып чыкканмы, әллә... Бу уйны уйлап бетерергә дә өлгермәде, Зәбир аның кулын кысып, ирләрчә кочаклап алды.

Бу төш түгел!

Аның каршысында ахири дусты Зәбир басып тора иде. Фәиз белән бер елгы булса да, аңа инде кырык-кырык биш яшьләр бирерлек — нык картайган, каты таушалган иде ул.

— Син исәнмени?! — диде Фәиз, һаман ышанасы килмичә.

— Исән калдым. Син минем исән калуыма шат түгел, ахрысы,— диде Зәбир тагын теге төрмәдә утырган кешеләрдә генә була торган сары тешләрен ялтыратып.

— Мин шат. Син нәрсә... Зәбир... син гафу ит. Мин әле һушыма килә алмыйм. Мин бит сине сазлыкта батып үлде дип йөрдем...

— Нинди сазлыкта? — диде Зәбир җыерчыклар белән сырланып беткән маңгаен тагын да ныграк җыерып,

— Теге... Алтын урлап качканда... Җитмеш сигезенче елны...

— О-о-о, мин ул вакыйганы инде күптән оныттым, туган.

Чынлап та, аның өчен теге вакыйга берни түгел сыман иде, күрәсең.

— Ничек оныттың! — диде Фәиз, өсте-өстенә шаккатырлык мәгълүматлар башына ишелеп төшүдән тәмам югалып.— Мин бит синең шул сазлыкта батып үлгәнеңне күрдем.

Зәбир аның хатирәләрендә һәм үзенең уй-кичерешләрендә адашып, очрашуга тиешле бәя бирә алмыйча катып торуыннан тәмам туйды.

— Чәең бармы, туган? — диде ул Фәизнең иңеннән кагып.— Тышта эссе, бәлки өеңдә салкынчарактыр. Чәең булса, каты иттереп чәй эчәргә иде.

Фәизгә кинәт барып җитте: җан дусты Зәбир бит бу! Исән икән бит. Ышанасы килми, ләкин бу — чынбарлык. Исән ул. Могҗиза булса да... Менә бит ул — монда.

— Әйдә тизрәк, әйдә, син арыгансың, күренеп тора. Әйдә, кергәч барысын да сөйләрсең,— дип кабалана башлады Фәиз.— Әйдә, тизрәк. Күпме вакыт узгач, көтмәгәндә... Төш түгелме соң бу?

Әгәр берничә ел элек Зәбир капкадан килеп керсә, моны Фәиз үзе дә күземә генә күренә, чир галәмәте, дип кабул итәр һәм бәлки тәмам акылдан шашар иде. Бу очрашу аңа саташу буларак тәэсир итәр иде. Ул хәзер дә әлеге могҗизалы очрашуны саташудыр дип үзен ышандырырга тырышты, инде кара-каршы чәй эчеп утырганда да үзен төрлечә никтер алдарга омтылды. Әмма ләкин каршыда исәнимин килеш Зәбир утыра иде.

Аның моңарчы, хыялланып, дустының исән калуын күз алдына китерергә тырышканы булды, инде әллә ничә тапкыр шул ук хыялларында җан дусты белән күп еллар узгач очрашуын фантазияләде. Тик хыялларында аларның очрашуы башкачарак күз алдына килә торган иде. Шатлыклары чәчрәп чыгып, кочаклашып, бәхетләре күккә кадәр ашар сыман иде.

Менә, очраштылар. Әллә нык үзгәргәннәрме — араларында элеккеге туганнарча жылылык юк шикелле. Әллә ышанып житмиләрме бер-берсен табуларына? Әллә уникe ел вакыт ниндидер җепләрне өзәргә житешкәнме? Әллә соң вакыт туганлык хисләрен дә юк итүгә сәләтле микән?

Зәбирдә шатлык юк түгел сыман иде. Фәиз бу очрашудан мөкиббән китеп куанды дип әйтеп булмас, мөгаен. Нәрсәдән бу? Куркуданмы? Үзенең җавап бирергә тиешлеге шүрләтәме? Нинди җавап бирү ди инде тагын? Көнелләр катканмы әллә олыгая торгач?

Алар бер-берсен озак һәм җентекләп күзәттеләр. Ниндидер таныш сызыклар, якын сыйфатлар, үсмер чакны искә төшерердәй мизгелләр эзләделәр. Ләкин тантана булмады. Инде шактый гомер үтеп, азмы-күпме дөнья күреп, күп кешеләр белән аралашырга өлгергән бу ике ир-егет бер-берсенең нык үзгәрүенә дә, икесенең дә инде элеккеге Зәбир белән Фәиз түгеллегенә дә артык нык гаҗәпләнмәделәр. Аларның икесен дә бер сорау гына борчыды: нишләп аларның очрашуы тантанага әверелмәде, бәхетләре ташып чыкмады? Әйтерсең лә, алар арасында һаман ниндидер кичеп чыккысыз «сазлык» бар иде.

Сөйләшергә сүз табылмады. Бер-берсенә аннан-моннан йолкып сораулар бирделәр. Зәбир каты итеп чәй эчте, Фәиз бу вакыйгага әзер булмаганлыктан, үзен кулга һич кенә дә ала алмады. Ничек инде? Күпме еллар сазлыкта ятып. Аңа барыбер дусты әле яңа гына сазлыктан килеп чыккандыр сыман тоелды.

— Ә мин сине сазлыклардан эзләмәкче булып йөрдем,— диде Фәиз көтмәгәндә.— Куркытты бик нык, барып сазлыкта казынырга йөрәк житмәде. Син бит минем куркак икәнемне хәтерлисең.

Зәбир елмайды. Күзләре гадәттәгечә җитди итеп карап алдылар.

— Хәтерлим. Мин сине шулай да башкачарак күз алдыма китергән идем. Син яшь чактагы шикелле «дохлый» түгел, кыяфәт шәп.— Ул як-ягына карап куйды.— Китапларың күп икән. Үзең генә яшәмисеңдер?

— Хатыным бар. Сания. Шушы көннәрдә кайтырга тиеш. Зәбир, син сөйлә, кайларда булдың, ничек яшәдең? Нишләп моңарчы хәбәр-хәтерең ишетелмәде?

— Сөйли башласаң, бер тәүлек кенә дә житмәс, туган.

— Син кайда идең соң ул гомердән бирле?

Зәбир чыраена гаҗәпсенү чыгарды.

— Төрмәдә утырдым! Кайда булыйм мин тагын! — Аның каты чәй эчүдән саргайган чырае аксылланып ук китте.— Синең аракың бармы?

Фәизнең өендә инде күптәннән аракы булганы юк иде. Ләкин Зәбирнең үтенечен үтәргә кирәк дип ул урыныннан кузгалды.

— Мин хәзер, тиз генә барып киләм. Алып киләм аракы. Син көтеп утыр. Әнә, телевизор карыйсыңмы? Китап укый торсаң да була.

— Мин чыгып бер тартыйм әле, китап укыганчы,— диде Зәбир.

Фәиз тиз генә кибеткә барып ике ярты аракы алып кайтты. Берсен кергәндә чоланда яшереп калдырды. Зәбир, өстәлгә таянып, чигәләрендә кан тамырлары бүртеп торган башын бармак очларына кадәр татуировка каплаган куллары белән кысып утыра иде.

Аракы эчкәч, аның теле ачылып китте. Ике сүз саен әшәке сүгенү, жаргонлы сүзләр аның сөйләгәннәрен куертты, Зәбирне тыңлавы Фәиз өчен авыр булды.

— Син мине батып үлде дип уйлагансың икән.— Ул тагын яман итеп сүгенде һәм шаркылдап көлеп куйды.— Мин үзем дә беттем дип уйлаган идем. Ай-яй сазлык суыруы коточкыч икән.— Ул тагын әшәке сүзләр кыстырды.— Мин синең каядыр читкә тайпылганыңны хәтерлим. Шуннан соң күрмәдем мин сине.

Фәиз нык дулкынлана башлады.

— Шуннан? Ничек чыктың соң син? Мин кире килгәндә син баткан идең бит. Син аннан чыгарлык түгел идең! Упкын иде бит анда!

— Ә мин үзем чыкмадым, мине тартып чыгардылар.
— Кемнәр???
— Шундагы лесхоз директоры.
Фәиз беркавым телсез калып торганнан соң:
— Сәлим Сәлмәневичме? — диде.
— Әллә тагын. Сәлим иде ахрысы. Отчествосын хәтерләмим, ә менә исеме Сәлим иде бугай.
— Шул инде, шул, ул вакытта Сәлим Сәлмәневич эшли башлаган анда лесхоз директоры булып.
— Бервакыт мине кемдер кулымнан тарткан сыман булды. Соңыннан гына аңладым — кулыма, элмәк ясап, бау ыргыткан да тарта икән бу. Шул бауның үзендәге очын ниндидер агачка тартып бәйләп куйды да, каяндыр көч табып, миңа шуны ыргытты, өстәвенә, үзе дә мине баягы бавы белән сөйрәргә тотынды. Шулай итеп, икәүләшеп тырмаша торгач, көч-хәл белән чыктым. — Ул тагын бераз аракы салып эчте. — Мин бит үзем дә сине батып үлгәнсеңдер дип уйлаган идем.
— Шуннан? Син сазлыктан чыккач? — диде Фәиз түземсезлек белән.
— Аның белән икәүләшеп сине эзләргә тотындык. Ул безне күзәтеп торган булган икән.
— Анда нишләп йөргән соң ул?
— Сазлыкта ниндидер җәнлеккә капкын куярга кергән булган. Синең кулыңдагы рюкзакка нык игътибар иткән ул. Күңеле сизгән аның анда ниндидер байлык барлыгын. Рәхмәт йөзеннән булгандыр инде — мин үзем дә аңа капчыкта алтын бар иде дип әйтеп ташладым. Сине табасы килде, мин нык курыктым батып үлгәнсеңдер дип. Шуңа күрә бәлки аңа серне ачарга булганмындыр. Озак эзләдек, кычкырдык, акырдык, тавышың ишетелмәде. Баткансыңдыр дип уйладык. Шуннан соң ул мине ташлап юк булды. Хәл җыеп яткннан соң тагын кычкыра-кычкыра шул тирәдә йөрдем. Сазлык тәмамланган урында рюкзакка юлыктым.
— Югалткан идем мин аны, — диде Фәиз ишетелер-ишетелмәс кенә.
— Рюкзак табылган тирәдә сине очратмаммы дип болганып-тугланып йөрдем дә аякларым кая таба атласалар, шунда киттем.
— Менә каян танып калган икән мине Сәлим Сәлмәневич. Белгән икән бит ул вакыйга турында, — диде Фәиз үзалдына.
Зәбир аның сүзләренә бөтенләй игътибар бирмәде.
— Этләр тавышыннан уянып китсәм — өстемә бер мент чырае иелгән. — Шушы урында ул катлы-катлы итеп сүгенеп алды. — Касыкка китереп типте. Башкалары да килеп җиттеләр, бөтен урманны милиция камап алган. Шулай итеп, каптым мин, туган.
— Минем исән икәнемне каян белдең?
— Дөресен әйткәндә, үлүеңә ышанасым килмәде. Исәндер, мәйтәм, юк, җан дустым үләргә тиеш түгел! Зонада утырганда шулай икелемикеле уйлар белән яшәдем. Баткандыр дим дә... Юк, исән булырга тиеш, дип үземне тагын юатам. Аннары, инде азат ителгәч, теге кибет директоры — Ильяс Габдрахманов әйтте, исән диде.
— Ильяс Хәмитовичмы?! — дип кычкырып җибәрде Фәиз.
— Син күп нәрсәне белмисең, аңламыйсың, шулай бит?
— Шулай. Ә сине кибет баскан өчен дип утырттылармы соң?
— Шуның өчен, әлбәттә.
— Ә син беләсеңме соң без урлаган әйберләрнең чын түгеллеген, фальшивка икәнлеген?!
— Беләм, бик яхшы беләм. Кызма әле, карале син дә кызу канлы икән. Тыңлап бетер. Син кибет эчендә такталар арасында ятканда мичкәләр артында тагын бер карак яткан икән бит. Директор Габдрахманов үзе дә кибет басу оештырырга маташкан. Ул карак кибет ремонтлаучы әрмәннәрнең кешесе булган. Габдрахманов оештыруы буенча, шул карак, кибет эчендә качып калып, каравылчыны тавыш-тынсыз гына буып бәйләп ташларга тиеш була. Каравылчы алдан кисәтелгән була, ул

каршылык күрсәтмәскә тиеш була. Аларның нәрсә урларга тиешлеге дә, аннары качаргамы, юри тотылыргамы икәне — берсе дә миңа мәгълүм түгел. Кыскасы, Габдрахмановка кибетне басулары кирәк була. Алар шул спектакльне оештырып ятканда чын карак килеп чыга да, ягъни син, каравылчының башына таш белән орып, витрина астындагы әйберләрне капчыкка тутырып чыгып кача. Милиция килеп җиткәндә теге әрмән мичкәләр арасыннан чыгып кына килгән була, аны шундук кулга алалар. Ул әрмән, бичара, берни аңламый калган. Ул бит сине күзәтеп яткан. Алдан сөйләшкәнчә килеп чыкмагач, ул аптыраган, каушаган. Синең кем икәнеңне аңламаган. Ха-ха-ха!

— Икегезне дә утырттылармы?

— Юк, мине генә.

— Ә боларның барысын да кайдан белдең?

— Тыңла. Әллә тартып керикме?

— Тарт монда гына,— диде Фәиз, хикәяне дәвам иттерәсе килеп.

Зәбир тәмәке кабызып дәвам итте:

— Теге әрмән милициягә эләгермен дип уйламаган бит инде. Эләккәч, Габдрахмановны сатмаган, падла, молодец. Каравылчы да берни аңламый калган. Әрмән аның кулларын йомшак кына бәйләп, авызына җиңелчә генә чүпрәк тыгарга тиеш булган. Ха-ха, ә син аның маңгаена тарткансың. Каравылчы да следовательгә Габдрахманов турында берни әйтмәгән. Һәм мин урманда рюкзак белән тотылдым. Габдрахманов теге әрмәнне коткарырга тели бит инде ничек булса да, чөнки үзенең рисвай ителүе ихтимал. Минем эләгүем директорга зур шанс бирә. Следователь аша ул минем белән очраша.

— Кем, Габдрахмановмы?

— Әйе. Мин инде тикшерү астында утырам бит. Камерага алып керделәр үзен. Озак итеп сөйләштек. Безнең икәү булганыбызны белделәр, ничек белгәннәрдер, анысы әһәмиятле түгел. Габдрахманов миңа кибет басуны үз өстемә алырга кушты, шулай барыбызга да әйбәт булыр диде. Срокның яртысын гына утырырсың, диде, төрмәдән чыккач, акча бирермен дип вәгъдә итте. Мин уйлап-уйлап тордым да, сине эзәрлекләп йөрмәүләрен үтенеп, ризалык белдердем. Мин, әлбәттә, баш тартып, рюкзакны урманда таптым дип ялганларга маташып карасам да булыр иде. Тик алайга китсә, җентекләп тикшерә башларлар, сине дә эзләп табарлар иде. Ә болай үзем генә утырып чыгыйм дидем. Тиз-тиз генә ябык суд әтмәлләделәр, өч ел бирделәр. Судтан соң Габдрахманов яныма килеп пышылдады: ярты срогыңны гына утырачаксың, диде.

— Теге кибет басуны «уйнарга» тиешле әрмәнне очратканың булдымы әллә?

— Кызык килеп чыкты. Дөнья тар икән ул. Ярославль зонасында ул үзе минем янга килде. Аны да утыртканнар, ләкин башка эш буенча. Мин өченче отрядта идем, ул — алтынчыда. Ничектер белгән дә минем нинди эш буенча утыруымны. Ул миңа барысын да сөйләде. Ә үзе ул ниндидер башка эш буенча утыра иде, мин кызыксынып та тормадым.

— Мин Габдрахмановның кем икәнлеген аңлый идем, ләкин бу кадәр үктер дип һич кенә дә...

— Ул мине, падла, ярты сроктан азат иттерәм диде. Ике ел утырдым, өченче елым китте, өч елга тула башлады — азат итәргә теләүче дә юк. Бер матавык килеп чыкты. Мин бит Н. да «четверкада» усиленный режимда утырдым беренче срогымны. Вәт, матавык килеп чыкты, туган. Инде срок тәмамланып килә дигәндә бер прапорщикның башына өч литрлы банка белән бәрдем. «Раскрутка» белән киттем — сигез ел бирделәр.

— Ник суктың соң син аңа?

— Миңа әшәке сүз әйтте.

— Түзәргә идең инде.

— Түзеп булмады шул. Зонада ямьсез сүзләр башкачарак кабул ителә бит ул. Менә, «от звонка до звонка», кем әйтмешли былтыр гына котылдым.

— Былтыр? Кайда яшисең хәзер?

— Казанда. Бер хатынга йортка кердем. Бигүк яхшы тормыйбыз, шулай да әлегә бергә яшәп ятабыз шуның малосемейкасында.

— Габдрахманов сине коткарырга тырышмады да микәнни?

— Тырышып карадым дигән булды, падла! Былтыр, азат ителү белән, мин аны эзләп таптым. Бераз акча бирде бирүен. Акланды, тәүфикълы песи булып кыланды. Акча тагын бирергә вәгъдә итте. Бирмәсә, үтерәм мин! Ә син кайдан белдең урлаган әйберләрнең «туфта» икәнен?

— Син бер йөзекне Каенсарда саткан идең бит.

— Әйе.

— Шул сатучы хатын әйтте — Рәмзия. Аннары Габдрахманов белән очрашып сөйләшкәнем булды минем. Ул да әйтте. Барыбер бу эшнең асылына төшенеп җитә алмыйм әле мин.

— Аның нәрсәсенә төшенәсең инде! Кибет басу формально кирәк булган, нәрсәнедер списать итәргә, кайбер кыңгыр эшләрне шул вакыйгага сылтарга, ә нечкәлекләре нәрсәгә сиңа! — Ул җан ачысы белән яман итеп сүгенергә тотынды.

— Әйе шул,— диде Фәиз уйга калып,— казынулар нигә кирәк?! Моны мин күптән аңладым түгелме?

Аның күңелендә элекке дустына карата капма-каршылыклы хисләр кайнады — кызганыргамы аны, гафу үтенергәме, киресенчә, ачуланыргамы? Куе бөдрә чәчле, кара күзле, кара кашлы, ут чәчрәтеп торган, шуклыгы, дорфалыгы белән беррәттән, дөньяны кочып сөярдәй һәм чиксез яратырдай якты хисләргә, сыйфатларга ия булган чибәр егет урынына инде бөтенләй башка кеше утыра иде. Унике ел гына үтте нибары! Нибары? Күпме, азмы бу вакыт? Хәер, эш анда түгел. Нинди юл үтелгән шул вакыт эчендә — шунысы мөһим. Теге ахири дус Зәбир урынында ике сүз саен дөньяны каргап сүгенүче, кыяфәтеннән нур качкан, җөйләр белән берешкән сары чырайлы, күзләре елмаюның ни икәнлеген оныткан бер җанвар барлыкка килгән иде.

Шешә бушады, Зәбир хәйран исерде. Аның сүгенүләре ешайды, куерды. Фәиз өчен артык күп хәбәр һәм бу очрашу гайре табигый сыман тоелды. Бүгенгә аның Зәбирдән котылып торасы килде. Ул аңардан никтер кинәт туйды, гарык булды. Аның ялгызы гына калып, аңы белән бүгенге вакыйганы эшкәртәсе килде, аңлашылмаган нәрсәләргә төшенү ихтыяҗы туды.

Шуңа күрә Зәбирнең:

— Мин хәзер Т. га китәргә тиеш,— диюенә ул чиксез куанды.

— Анда ник барасың? — дип кызыксынды ул шулай да, аның өчен борчылып.

— Зонада бергә утырган дустым яши анда. Шуны күрәсем бар. Киләсе автобус сәгать ничәдә була?

Фәиз сәгатькә карады:

— Бер сәгатьтән.

— Әйдә, саф һавада йөри торырбыз,— дип, Зәбир урыныннан кузгалды.

Поселокның автобус тукталышына җиткәч Фәиз:

— Син Т. да озак буласыңмы? — дип кызыксынды.

— Белмим әле.

— Мин үтенәм, Зәбир, Габдрахманов янына барма. Акча да сорама, гомумән, ул кеше белән араны өз. Теге, җитмеш сигезенче елгы вакыйга белән араларны өзәргә вакыт дип әйтүем минем.

— Юу-у-ук, Габдрахмановтан каерып-суырып аласы нәрсәләр байтак әле минем,— диде Зәбир авызын кыйшайтып.

— Сорама беркемнән бернәрсә! Акча кирәк булса, үзем бирермен. Төкер, ташла!

Зәбир ямьсез итеп карады.

— Сәер кеше син. Хәер, иректә яшәгән кешеләр мине аңлый алмаслар.

— Син миңа ямьсез итеп карама, Зәбир.

Зәбир тагын авызын кыйшайтты.

— Кыяфәтең шәп синең хәзер. Костюмың матур.

Фәиз үзе дә сизмәстән кыза башлады:

— Зәбир! Гафу ит мине, яме, костюмым матур булган өчен дә, кыяфәтем яхшы булган өчен дә. Үзем генә беләм бүгенге халәтемә ничек ирешкәнемне. Мин иректә яшәдем дип уйлыйсыңмы әллә! Мин дә утырып чыктым. Мин үземдә «утырып» чыктым! Бу унике елда ниләр кичергәнемне, нинди уй-хисләр белән, нинди хәлдә яшәгәнемне син белмисең.

Ул кинәт туктады. Аклана башладыммы әллә дип уйлап куйды, ахрысы.

Зәбир битараф иде. Фәиз сөйләгәннәрне аңлый торган кеше түгел иде бу. Фәизнең тамагына бик тә таныш төен килеп тыгылды.

— Мин синең алдыңда акланырга тиеш түгел.

— Нишләп соң аклана башладың?

— Син мине нәрсәдәдер гаеплисең шикелле тоелды.

— Гаепләми-и-им. Язмышларны карале син. Мин утыз яшемә кадәр төрмәдә булдым, ә син?

— Нәрсә «мин»!!!

— Кычкырма, ник кычкырасың.

— Гафу ит, Зәбир. Бер-беребезне аңлый алмаячакбыз без. Икебез дә зур юл үткәнбез. Ләкин төрле тарафларга. Син үзеңнең юлыңнан ерак ара узгансың, ә мин үз юлым белән шактый ерак киткәнмен. Әлбәттә, гаебем зур минем. Кибет басар алдыннан ничек тә булса тыярга иде сине дә, үземне дә. Хәер, алай гына котылу мөмкин иде микән гөнаһтан! Безнең арабызда коточкыч бушлык, арабызда ниндидер «сазлык» ята.

Зәбир чыраен сытты.

— Укымышлы кеше белән ай-һай авыр сөйләшүләре.

Фәиз аның мыскыллавына игътибар итмәде.

— Көлмә, Зәбир. Минем хәтеремдә синең теге әби турында сөйләгәнең.

— Кайсы әби турында?

— Теге Каенсардагы. Лапасына кереп качкансың бит әле.

— Ә-ә-ә, әйе, әйе.

— Мин булдым анда. Ул әби исән түгел инде. Йортын да сүткәннәр. Син аның дога кылып калуы турында сөйләгән идең миңа. Догасы кабул булган бит — сазлыкта батып үлмәгәнсең.

— Батып үлсәм, яхшырак булмас иде микән?

Фәиз аның бу сүзләреннән тетрәнеп китте. Дөрес, бу кешедән андый сүзләр ишетү бераз өметләндерә шикелле. Шулай да, Зәбир аңа бу мәлдә бик кызганыч һәм ярдәмсез булып тоелды.

— Син нәрсә инде! — диде ул аны юатырга тырышып.— Алай димә. Яшәргә кирәк.

Фәизнең күңеле тулды. «Теге вакыйгада Зәбир мине гаепләми микән?» дигән сорау кинәт килеп басты.

— Елыйсыңмы әллә? — диде Зәбир.

— Елармын әле,— диде Фәиз.— Минем синнән сорыйсым килә. Теге вакытта, сазлыкта батканда мин сиңа кулымны сузмадым түгелме?

Зәбир аптырап китте.

— Сузды-ы-ың. Ник алай дисең?

— Ә минем йөгерүемне ничек аңладың? Качу дип түгелме?

— Син нәрсә инде! Таяк яки күсәк эзләп чабып йөрдең бит син!

Фәиз аңа сәбәпнең нечкәлекләрен аңлатып тормаска булды. Зәбирдә ул вакыйгага бәйле шик-шөбһә юк. Аңлату мөмкин дә түгел, кирәк тә түгел!

Зәбирнең күзләрендәге нәфрәтнең бер өлеше, әлбәттә, Фәизгә юнәлтелгән, ләкин Фәиз белә, аңлый: Зәбир белән Фәиз арасында зур аерма хасил булган. Күренеп тора, Фәиз рухи үсешкә, күңел хөрлегенә һәм, ниһаять, тыныч-имин тормыш белән яшәү халәтенә ирешкән, ә Зәбир? Аңа чит-ят бу дөнья, ул адашкан җанвар сыман хис итә үзен. Шуңа күрә Зәбир аңа көнчелек нәфрәте белән карый һәм ул аны хәтта яшерә дә алмый, бәлки, яшерергә теләмидер дә. Фәиз аңа игътибар белән карап торды: әгәр дә менә хәзер Фәиз сазлыкта бата башласа, Зәбир нишләр иде икән, нинди хәрәкәтләр көтеп булыр иде икән аңардан?

Коточкыч сорау! Чөнки кешенең эчке асылы коточкыч! Нәрсә бара анда, ниләр кайный, нинди адымнарга сәләтле бу адәм баласы — кем белгән!

Фәиз элекке дустына карап якын, таныш сыйфатлар, сызыклар, хәрәкәтләр эзләде. Ләкин таба алмады. Аралар ерагайган, алар төрле яклар-га юл алганнар. Бала чактагы, аннары үсмер еллардагы дуслык, туганлык сөртелгән, беткән, югалган. Кызганыч, бик кызганыч.

Автобус килергә әле тагын ун-унбиш минут бар иде. Фәизнең иң әһәмиятле, иң кирәк фикерләрне әйтеп каласы килде.

— Мин сиңа булдыра алганча ярдәм итәрмен. Син гел килеп йөр. Мин шулай да үтенәм: барма Габдрахманов янына.— Ул тотлыгып торды.— Гафу ит барысын да. Кичер һәммәсен!

Зәбирнең күзләре акайды:

— Гафу итәргә! Барысын да?

— Әйе.— Фәиз як-ягына карады.— Кычкырма, кешеләр ишетә.— Гафу ит барысын да, дошманнарыңны да, дусларыңны да.

— Син берәр мулла булып хезмәт итмисеңдер бит?

— Юк.

— Хәшәрәтләрне дә гафу итәргә тиешме мин?!

— Әйе, Зәбир. Чөнки бер алар гына гаепле түгел.— Ул тавышын күтәрде.— Алай күзләреңне акайтып карама миңа! Үзең дә гафу үтен!

— Кем алдында?

— Бөтенесе каршында. Һәм хәшәрәтләр алдында да!

— Кыяфәтең интеллигентный булса да, акылга бераз тулыр-тулмас, ахрысы, син.

— Бәлки мин җүләрдер. Ләкин, Зәбир, син «Сазлыкта батып үлсәм яхшырак булмас иде микән»,— дигән коточкыч уй белән яшәргә тиеш түгел. Мине аңламыйсың, чөнки моңа үзең барып җитәргә тиеш син, үз акылың белән барып ирешергә тиешсең. Мин сиңа нотык укырга җыенмыйм, моңа хакым да юк, ләкин шулай да ярлыкауларын сора. Шундук җиңеллек тоячаксың. Сүз белән генә түгел, күңел, җан белән үтенергә кирәк. Хәер, моңа әзерлек кирәк шул. Эчке әзерлек кирәк!.. Мин бер нәрсәне аңлап зур ачыш ясадым үземә. Гөнаһ — кылган гамәл түгел. «Гөнаһ кылды» дигән төшенчә булса да, гөнаһ — кылган эш түгел. Гөнаһ — шул кылган эшләреңә синең мөнәсәбәтең. Димәк, үзеңә үзеңнең мөнәсәбәтең. Күрәм, син мине аңламыйсың һәм аңларга теләмисең дә.

— Син бит руханилар кебек сөйлисең. Кемнән ярлыкауны үтенергә тиеш мин беренче чиратта, шуны әйт?!

Фәизнең хәле бетеп китте, ул чак кына ишетелерлек итеп әйтеп куйды:

— Беркем алдында да түгел, үз-үзе алдында тәүбә итәргә тиеш кеше. Ахыр чиктә шулай килеп чыга да ул.

Зәбир аны тыңламый иде инде, ул әшәке итеп әле һаман күренмәгән автобусны сүкте.

— Киләме бу, юкмы?!

Фәиз инде үзалдына әйтеп бетерде:

— Дөрес, бөтен җаваплылыкны бер кеше генә үзенә алырга тиеш түгел. Ләкин һәрбер кешегә үзенең өлеше тияргә тиеш барыбер. Офтанмыйча, тәүбә итмичә булмый.

Аның соңгы сүзләренә колак салган Зәбир шаркылдап көлеп куйды.

— Сине кемдер бик каты куркыткан, ахрысы. Син монах сыман сөйләшәсең.

Автобус күренде. Зәбир шатлыгын да ачы итеп сүгенеп белдерде. Фәиз тагын бер тапкыр элеккe җан дустына зур ригая белән карады һәм... аның теге сазлыктан котылып чыгуына үкенеп куйды. Шундук бу коточкыч уйны куып җибәрергә ашыкты һәм Зәбирнең беләген кысып тотты да:

— Кичер мине! — диде. — Ярлыкагыл!

— Син нәрсә, братан! — диде Зәбир аптырап.

Фәизнең бите буйлап мөлдерәп күз яшьләре тәгәрәде. Автобус якынлашты.

— Зәбир, яшәргә җиңелрәк булачак... Нәфрәт белән булмый... Барыбер җиңә алмыйсың бу дөньяны, дөньяны гына түгел, хәтта бер кешене дә җиңеп булмый. Үзеңне җиңәргә омтылырга кирәк. Аңлата алмыйм шул. Син тагын кил, гел килеп йөр. Сания шушы көннәрдә кайта. Теге, үзеңнең хатыныңны да алып кил, яме. Мин үзем дә озак, авырлык белән килдем бүгенге халәтемә. Җиңеллек тоячаксың син дә, теләк кенә кирәк. Чистарынырга беркайчан да соң түгел. Син ачуланма мондый сүзләр сөйләгәнем өчен. Гомерләр алда әле. Вакыт та, мөмкинлек тә бар. Яшәүнең мәгънәсе дә бар!

Алар ирләрчә кочаклашып хушлаштылар.

Автобус артыннан тузан өере купты. Арткы тәрәзәдән Зәбирнең чырае күренгәләп алды. Кул болгый, ахрысы. «Тиздән очрашырбыз»ны аңлатамы бу кул болгау, әллә «Мәңгегә хуш»нымы?

## 33

Зәбирне озатканнан соң аның өенә кайтасы килмәде. Туйдырган икән бу йорт. Монда да үзгәреш кирәк — китәргә, кая булса да күчәргә. Зәбир белән очрашу башта авыр тәэсир итте. Шатланыргамы, кайгырыргамы — белмәде. Болай гади генә уйлаганда аермачык кебек — шатлык булырга тиеш. Әмма ләкин! Бу бит инде теге Зәбир түгел. Анысы ярый, кеше үзгәрә һәм ул үзгәрергә тиеш тә. Ә Зәбирнең киләчәк тормышы нинди булыр? Аның үз тормышы үзеннән торганны, барысы да — нәтиҗәсе дә, сәбәбе дә үзендә икәнне болай әйтеп кенә аңа аңлату мөмкинме соң?

Бу вакыйга бигрәк гайре табигый шикелле булды ла. Кем уйлаган болай килеп чыгар дип. Гаҗәпләнер нәрсәләр күп, алай гына да түгел, гел арта гына баралар кебек.

Күпме кеше белгән икән бит минем серемне! Сәлим, Габдрахманов, бәлки тагын әллә кемнәр белеп йөргәннәрдер. Полкның оперуполномоченные Трошкин тикмәгә генә якын дустым турында кат-кат кызыксынмагандыр, монда запрос ясагач, Зәбирнең төрмәдә утыруын хәбәр иткәннәрдер. Әллә кайдагы Забайкальеда нииндидер Трошкин да белгәч. Хәтта кибет басарга кергәч тә мичкәләр арасыннан нииндидер әрмән күзәтеп яткан үземне. Ай-яй сәер, куркыныч бу дөнья. Үзенең тарлыгы белән куркынычтыр ул. Бөтенесен күреп торалар. Алла да күреп тора, кешеләр дә. Чынлап та, бу дөньяда бернәрсәне дә үзеңә генә яшерү мөмкин түгелдер ахры. Ничә кеше белеп йөргән минем серемне. Газабымны белделәр микән соң? Аларның белеп йөреп тә беркемгә, мәсәлән, милициягә барып әйтмәүләре минем өчен зур нәрсә ләбаса. Төрмәдән курыкканга түгел. Үземнең фаҗигамне үземә тапшырулары өчен рәхмәт. Бүгенге көнем өчен, үзем ирешкән рухи үсеш өчен рәхмәт аларның барысына

да. Белә торып кайгым белән бергә-бер калырга мөмкинлек биргәннәре өчен барысына да рәхмәт!

Зәбир белән очрашканнан соң барлыкка килгән шок бетте һәм әкренләп күңел күтәренкелеге кайта башлады. Чынбарлыкка каршы сугыш игълан итеп булмый. Зәбир исән. Моңа барыбер куанырга кирәктер. Адашкан кешегә ярдәм итү мөмкиндерме-юкмы... тик шулай да аны ташларга ярамый. Ничек кенә булмасын, аларның бүгенге рухи аермалыкларында Фәизнең дә гаебе бардыр. Шулай булгач, дустын «сазлыктан» чыгарырга тырышырга тиеш бит ул! Дөньяда Габдрахмановлар, Сәлимнәр, Ренатлар, Камилләр генә түгел, башка кешеләр дә бар! Яшәешкә яктылык өстәүче Маратлар, Әлфияләр дә бар бит әле.

Гомернең мәгънәсен эзләп җәфаланучылар бар. Тулаем алганда, гомернең гомуми мәгънәсен эзләп табып булмыйдыр. Бербөтен гомернең мәгънәсе бәлки юктыр да. Гомернең аерым алган көннәре, сәгатьләре, мизгелләре өчен генә мәгънә табыладыр. Кеше үзенең тормышын мәгънәле итәргә тырыша, көн саен, сәгать саен, мизгел саен. Шуңа күрә, яшәү мәгънәсе хакында сүз чыкса, гомернең аерым өлешләренең мәгънәсе турында гына әйтү мөмкиндер.

Зәбир исән!

Аны хәзер коткарырга кирәк. Дөресрәге, котылырга ярдәм итәргә кирәк.

Гамәлгә ашардай эш бу, чөнки иң кирәкле төшенчәләр бар — вакыт та, мөмкинлек тә, теләк тә. Зәбирнең үзенең дә теләге туачак! Һәрхәлдә, моңа ышанырга иде.

Аны сазлыктан йолкып чыгарырга кирәк!

Киләчәк гомернең мәгънәсе, бәлки, шулдыр?!

*1995—1996*

*Тәмам*



ШИГЪРИЯТ

## «ДУСЛЫК» ХАКЫ — ШАГЫЙРЬЛӘР ХАКЫ



**1965** елда без, сигез яшь шагыйрь, «Дуслык» исемле күмәк китапта басылып чыгу бәхетенә ирешкән идек. Утыз елдан артык вакыт узган, төрле язмышлар, төрле иҗат юллары. Шигъриятгән китүчеләр дә бар. Сәбәпләре дә юк түгелдер. Тормышның үзе кебек үк катлаулы бит ул әдәбият та!

Илгизәр Фазули (Фазлуллин) — әнә шул сигезнең берсе. Ул югалмады, язудан туктамады (1967 елда «Сабыйлар уянганда» исемле мөстәкыйль китабы да дөнья күрде), әмма күбрәк журналистика, публицистика юлыннан китте шикелле: инде егерме елдан артык Горбунов исемендәге авиация заводының «Алга» исемле газетасына мөхәррирлек итә ул; хикәяләр, мәкаләләр белән дә көндәлек матбугатта катнаша; шигырьләре дә күренгәләп куя. Әмма аның исемен халыкка танытган бер мөһим өлкә бар: ул — җыр. Әйе, Илгизәр сүзләренә утызга якын җыр язылган, алар арасында шактый зур яңгыраш алган «Ветераннар» (Р. Яхин музыкасы), «Юлым илтә гел яктыга» (М. Мозаффаров көе), «Белегез шуны» (Сара Садыйкованың мәгълүм җырларыннан!), «Тормыш матурлыгы» (Риф Гатауллин музыкасы) кебекләр бар. Димәк, шигырь онытылмый, җыр булып дәвам итә.

Зеленодол районының Әрә-Тугай авылында туып үскән (июнь аенда аңа 60 яшь тулып үтте!), аннары техник училище, университетның журналистика бүлеген тәмамлап, эшчәнлеген завод, эшчеләр тормышы, газета, эшче шагыйрьләрнең әдәби түгәрәге белән бәйләгән Илгизәр Фазули бүген дә янып, яңа шигырьләр, җырлар белән дәртләнеп яши: бу санда тәкъдим ителә торган бәйләм дә нәкъ менә шуны сөйли, шуны раслый, безнеңчә. Шулай, шигъри дөньябыз «Дуслык» белән бәйле егетләр бит без!

**Рәдиф ГАТАШ.**

# Илгизәр Фазули

### Таллар таяна җиргә

Таллар таяналар җиргә,
Кеше таяна илгә.
Илләре, таллары юклар
Кирәк булырлар кемгә?

Җиргә таянган талларны
Куптара алмый давыл.
Илләргә — иминлек, дигән
Теләкләр булсын кабул.

Нинди генә сынаулар да,
Сындыра алмас безне,
Сөйгәнгә алсу таңнарны,
Талларны, җиребезне.

## Әрә тавы, әрә үзәне

Әллә нинди шаулы да ул, тын да,
Әрә тавы, Әрә үзәне.
Хисләр ташый искә төшергәндә
Яшьлегемне, серле күзләрне.

Тәүге эзләрем бар монда минем —
Яланаяк чапкан чакларның.
Уянамын бик еш йокылардан,
Кешнәгәнен ишетеп атларның.

Туган җирем — Әрә авылының
Көмеш җыры — Әрә елгасы...
Яшьлегемнән ераклашкан саен,
Якыная авылым дөньясы.

## Түздем

Менә тагын җиргә матур язлар килде,
Син яраткан чәчәкләрне сайлап өздем.
Очрашканда нинди сүзләр сөйләнмәде,
Тик бер сүзне әйтми калдым — түздем, түздем.

Үзем беләм никадәрле көч биргәнен,
Кадерен дә яхшы беләм шул бер сүзнең.
Әйтим, әйтим, диеп күпме канатландым,
Ләкин, барыбер, әйтә алмадым — түздем, түздем.

Инде менә шул язлар да узып китте,
Сизми калдым килгәнен дә җәйнең, көзнең...
Шул чагында аңа карап: «Сөям!» — дидем,
Җитәр, дидем, кай гомердән ничек түздем!

## Ялтырап кояш та чыкты...

Ялтырап кояш та чыкты,
Югалды күздән томан.
Тик агачлар басып калды
Сагышлы кеше сыман.

Тирбәлеп дымлы җилләрдә
Коелган яфракларның
Сибелүен юлларыма
Тын гына карап бардым.

Яфраклар саргайганнар шул,
Яфраклар коелалар.
Ә миңа күзләр дә барыбер
Җәй кебек тоелалар.

Җәй кебек тоела күзләр,
Күңелем яшьлегеннән.
Шул яшьлектә — яшәвемнең
Мәгънәсе яшеренгән.

## Сары яфрак

Күзгә урман сукмагыннан
Узган чакта икәү атлап,
Нигә генә бер ялгызың
Өзелеп төштең, сары яфрак?
Өзелеп төште алдыбызга,
Өзелеп төште сары яфрак.

Кайчан гына син бит әле
Яшел идең, сары яфрак?
Тап булса ул юлыгызда,
Сез китмәгез аны таптап.
Сез китмәгез, сары диеп,
Ялгыз, диеп аны таптап.

Без узарбыз тормыш юлын,
Аерылмый, бергә атлап.
Калырсың син хәтерләрдә,
Сары яфрак — ялгыз яфрак.
Калырсың син хәтерләрдә,
Сары яфрак — ялгыз яфрак.

## Белегез шуны

Иртә таңнарда, карыйм талларга,
Өзә үзәкне кошларның моңы.
Аерылсам сездән, дусларым минем,
Саргаер идем, белегез шуны.

Күзләр җитүен, кошлар китүен,
Күпме кичерде гомерләр юлы.
Кояшлы язым, чәчәкле җәем —
Сез ул, дусларым, белегез шуны.

Ямьләнә күзләр, тәмләнә сүзләр,
Бетә таралып күңелем моңы.
Күрсәм яңадан, сезне, дусларым,
Бәхетем арта, белегез шуны.[1]

---

[1] Сара Садыйкова музыкасы.



# Рәшит Гатауллин

## Дым булып җиргә сеңмәм

Кычкырма, кәккүк, шомланып,
Әйтерсең лә беләсең
Нәрсәнең аз, нәрсәнең күп
Өлешемә төшәсен.

Санама калган гомерне,
Гомерем уртасында —
Юк инде көенәсем дә,
Юк инде куркасым да.

Үтелгән юлларга багам,—
Күңелдә моңсу томан.
Шәүләләр азая төшкән,
Офыклар төсен җуйган.

Санама, кәккүк, санама,
Гомеремне үзем беләм.
Күрәселәрне күрмичә
Дым булып җиргә сеңмәм.

## Сәяхәткә чыктым

Дөнья буйлап сәяхәткә чыктым,
Мин үтәсе күпме илләр бар.
Кереп чыгыйм, күреп китим әле,
Ул илләрдә димен, ниләр бар?
Бу ил — кешелекнең яшәү башы,
Анда истәлекләр, мөнбәрләр.
Һәйкәлләргә кырын күз дә салмый
Яшәп ята икән җүләрләр.
Ә монысында элек гомер иткән
Акыллылар белән уңганнар.
Хәзер фәхишәләр, җанкыярлар
Шул туфракка хуҗа булганнар.
Намуссызлык, ялагайлык яши,
Вөҗдансызлар тулган бер илдә.
...Дөнья буйлап сәяхәткә чыктым,
Шаулый дөнья, шаулый диңгезләр.

Ә кайда соң акыллылар иле,
Гашыйкларның иле кайларда?
Әллә алар йөзмә утрау кебек
Диңгез уртасында чайкала?
Йөзмә утрау йөзәр-йөзәр дә бит,
Вәхшиләрнең иленә бәрелсә?
Үч, нәфрәттән тамырлары корып,
Как кыяга әгәр әверелсә?!
Илләр буйлап сәяхәткә чыктым,
Вөждан иленә соң юл кая?
Мәкерлекне, явызлыкны җиңәр
Акыл иле кая югалган?!

## Бу — туган якларның җиле

Бу — туган якларның җиле,
Җылы җил... Әрем исе...
Кызарып баткан кояш төсе
Мәңге җуелмас төсле.
Назлы җилләр җылысында
Ята кырлар тирбәлеп.
Сөенәмен. Кайтыр җирем
Минем дә бар бит әле.
Таныйлардыр. Юл читендә
Арышлар үрсәләнә.
Әнкәем һаман тын гына
Көтәдер кутәрмәдә[1].
Сагынып кайтыр ягым шул,
Кайтып абыныр җирем.
Берчә сагышларга салыр,
Берчә табыныр җирем.

## Чираттан көтү көтәбез

Чиратлап көтү көтәләр,
Чират шул, мин дә көтәм.
Күнекмәгәнгәме икән
Вакытлар озак үтә.
Инеш буе, әрәмәләр...
Таныйм да, танымыйм да.
Боргаланып агып яткан
Суларга карыймын да
Чәчрәтеп чумасым килә,
Чирәмдә тәгәрисе.
Нинди юләр икән бу, дип,
Әйтер, күрсә берәрсе.
Синең үскән болыннарың,
Һәм үткән сукмакларың.
Сыдырылып калган кебек
Баланның куаклары.
Каеннар алтын күлмәктән,
Синең дә шундый чагың!

[1] Күтәрмә — болдыр (диалект)

Иманнәр әле бирешми,—
Шушымы туган ягың?
Шушымы чираттан чыгып
Көтүләр көткән җирең?
...Чиратлап көтү көтәбез:
Дөньялар әле имин.

## Яңгырлары яшьнәп яуган чакта

Тагын ниләр күрәчәкне белми,
Яшәп яткан чакта бер мәлдә:
Рәхмәт, дуслар, алып калгансыз бит
Китер чакта «теге илләргә».
Сез тотынгач, «кире кайтардылар,
Капкасыннан кире бордылар».
— Җир өстендә эшең бетмәгәндер,
Җир астына керми тор,— диләр.
Мин җир өстен күп таптадым инде,
Күргәннәрем күпкә җитәрлек.
Кабат шушы якты дөньяларга
Алып чыккансыз ич күтәреп.
Яшел җирнең яшел үләннәрен
Калган икән әле күрәсе.
Яңгырлары яшьнәп яуган чакта
Кемнең генә килсен үләсе!
Рәхмәт, дуслар, сезнең җылы куллар
Алып калган — «киткән» чагында,
Мин аңладым: үлем тырнагыннан
Йолыр дусларым бар янымда.

* * *

Яңа көн туа җиргә,
Гөлләрдән чыклар тама.
Әле бит иртә генә,
Күңелем, моңсулама.
Әле төш җитәсе бар,
Чыкларның кибәсе бар.
Кемнеңдер каршы аласы,
Кемнеңдер китәсе бар.
Әле бит иртә генә,
Күңелем, моңсулама.
Җилләр искәч, чәчәкләр дә
Иелә, дулкынлана.
Әле кич җитәсе бар,
Гомерне сүтәсе бар.
Кемнедер яратасы бар,
Кемнедер көтәсе бар.
Әле бит иртә генә,
Күңелем, моңсулама.
...Нишләтим соң син йөрәкне,—
Сызлавыңа дәва, бәлки?—
Гөлләрдән чыклар тама.

*1996 ел. Уфа.*

# ПУБЛИЦИСТИКА

*Татарстан нефтьчеләре белән «Казан утлары» журналының әдәби-мәдәни бәйләнешләре бик күптәннән — Татарстан нефте чыгарыла башлаганнан бирле килә. Димәк, ярты гасырдан артык вакыт, диген сүз! Шул чор эчендә журналыбыз сәхифәләрендә «кара алтын» осталарының фидакарь хезмәтләренә, тормыш-көнкүрешләренә, аерым батырларына багышланган дистәләрчә роман-повестьлар, хикәя-очерклар, йөзләрчә шигырь-поэмалар дөнья күрде. Нефть тәбәге журналның даими авторлары булган байтак язучыларыбызның иҗат бишеге булды. Алар шунда канат ярдылар, каләм чарладылар, күренекле әдипләр булып җитештеләр. Барысын да санап тормастан, татар укучысына яхшы таныш кайбер исемнәргә генә тукталып үтик. Иң әүвәл, әлбәттә, Татарстанның халык язучысы, Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Почетлы нефтьче Гариф Ахунов исемен телгә алырга кирәктер. Ул, ун елдан артык нефтьчеләр арасында — Әлмәттә яшәп, әллә никадәр очерклар, публицистик мәкаләләр, хикәя-повестьлар, романнар иҗат итте — аларның күпчелеге «Казан утлары» битләрендә басыла килде. Гариф Ахунов Татарстан язучылары берлегенең Әлмәт бүлеген ачу-оештыруда да башлап йөрде. Соңыннан бу эстафетаны «Казан утлары» журналының хәзерге баш мөхәррире, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм М. Җәлил исемендәге бүләге лауреаты Равил Фәйзуллин дәвам иттерде.*

*Татарстанның халык шагыйре Гамил Афзал, Саҗидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин, Шамил Бикчурин, Мәхмүт Хәсәнов, Җәмит Рәхимов, Әдип Маликов, Сәет Кальметов, Юныс Әминов, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова, Изаил Зарипов, Марсель Зарипов, Альберт Хәсәнов, Азат Ганиев, Энҗе Мөэминова, Үзбәк Саттаров, Кәшшаф Әмиров, Нур Әхмәдиев, Разим Вәлиуллин, Илдар Әхсәнов һ. б. прозаикларыбыз, драматургларыбыз, шагыйрьләребез Татарстандагы нефть сәнәгатенең татар халкы тормыш-көнкүрешенә китергән зур үзгәрешләрен һәрьяклап яктыртырга, реаль һәм әдәби геройларның образлары аша ачарга омтылдылар. Алар яңача шартларда төрле буын һәм төрле һөнәр кешеләре арасында күзәтелгән социаль-әхлакый мөнәсәбәтләрне сәнгатьчә гәүдәләндерергә тырыштылар. Шулай итеп, нефтьчеләр тормышы татар әдәбиятына яңа исемнәр дә, яңа төсмерләр дә алып килде. Язучыларның Әлмәт бүлеге үзе дә нефтьчеләрнең Техника сараенда мәрхәмәтле җылы урын тапты. Рәхмәт нефтьчеләребезгә!*

*Әле санап кителгән язучылар арасында Марсель Зарипов исеме, мөгаен, аерым урында торырга лаектыр. 1955 елдан ук нефтьчеләр сафына баскан эшче егет тора-бара кулына каләм ала, үз хезмәттәшләренә багышланган язмалары белән матбугат битләрендә күренә башлый. Бүген Марсель Зарипов урыс һәм татар телләрендә басылып чыккан ике дистәгә якын китаплар авторы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты. Бу — татар әдәбиятында очерк-публицистика жанрында бирелгән беренче шундый мәртәбәле бүләк. М. Зарипов китапларының барысы да диярлек нефтьчеләр тормышына багышланган.*

*Хәзер Марсель Зарипов, ничәмә дистә еллар буена нефть осталары белән аралашып туплаган зур тормыш тәҗрибәсенә таянып, Татарстан нефтьчеләренең эш-гамәлләренә багышланган зур күләмле әдәби-документаль китап яза. «Казан утлары» журналына шул китапның кайбер бүлекләрен тәкъдим итеп, автор болай диде:*


*— «Казан утлары» журналы — иң абруйлы журнал, аның битләрендә минем байтак әсәрләрем дөнья күрде. Менә хәзер дә үзем өчен бик мөһим санаган зур хезмәтемнең бер өлешен булса да татар укучыларына сезнең журнал аша ирештерәсем килде.*

*Профессионал язучы булып киткәнче, мин Татарстан нефть промыселларында эшләдем. Инде аннан соң утыз елдан артык вакыт үтсә дә, мин үземне һаман да нефтьче дип саныйм, чөнки бөтен тормышым-иҗатым нефтьчеләр белән бәйләнгән. Язучы буларак минем иҗат мәйданым — нефть. Шуны сөрәм, шунда чәчәм, шуннан уңыш җыеп алам. Язылa торган китабым — документаль. Дөньяларны шаулаткан Татарстан нефте ничек башланган, ничек дәвам итә, киләчәге ничек булачак — менә шуларны бәян итеп бирмәкче булам.*

*Нефть — бүгенге Татарстанның мул-имин тормышлы бәйсез киләчәге ул. Икътисади бәйсезлек булмаса, урамнарда яшел әләмнәр болгап: «Азатлык! Азатлык!» — дип кычкырып йөрү белән генә суверенитет алып булмый. «Бал, бал» дигәннән генә авыз балланмаган кебек, ярлы-ач халык та коллыктан-изелүдән алай гына котыла алмый. Нефть — табигатьнең безгә биргән зур бүләге-байлыгы ул. Республикабызның халык хуҗалыгын, шул исәптән, барыбыз өчен дә зарури булган авыл хуҗалыгын нефтьтән башка һич үстерергә мөмкин түгел, дип саныйм. Кыскасы, суверен Татарстан өчен нефть — гарант ул!*

*Марсель Зариповның бу сүзләренә без дә тулысынча кушылабыз һәм укучыларыбызны аның яңа китабының аерым бүлекләре белән таныштырып барырга ниятлибез. Бу санда — шундый бүлекләрнең берсе.*

**Марс ШАБАЕВ**



## Марсель Зарипов

# ЯШЕЛ ЧИШМӘЛӘР

*Акыл иясенең гамәлләре чәчәккә зыян китерми генә ширбәтен эчеп киткән бал кортыныкы шикелле булсын.*

Дһамманада.

* * *

Әйтергә кирәк, нефтьчеләрнең табигатьне саклау буенча үз төбәкләрендә үткәрә торган чаралары турында тәфсилле тасвирланган төрле-төрле документларны, эш кәгазьләрен мин шулкадәр кызыксынып укыдым ки, әле бер генә матур әдәбият әсәрен дә алай мавыгып укыганым булмагандыр. Нефть осталары кылган эш-гамәлләрнең нәтиҗәсе өчен борчылу-дулкынлануларымны бары тик, Робинзон Крузо маҗаралары турында укыгач, аның язмышы өчен балачагымда булган борчылу-дулкынлануларым белән генә чагыштырырга мөмкиндер.

Аһ, нефтьчеләрнең башкара башлаган бу уй-ниятләре, матур хыяллары тулысы белән тормышка ашсачы иде! Чөнки аларны язучы хыялы белән елгаларны кирегә боручы, океан төпләренә төшүче, ерак планеталарга күчеп китүче әдәби геройлар түгел, ә бүгенге тормышыбыздагы гади кешеләр — нефтьчеләр гамәлгә ашыра бара бит. Бу инде сиңа Робинзон Крузоның кешесез утрауда ялгызы калып яшәү өчен көрәшүе генә түгел. Хәер, нефтьчеләрнең куйган максатлары да шундыйрак түгелме соң? Робинзон Крузо үз тормышы өчен көрәшсә, нефтьчеләр, үзләре яшәгән һәм эшләгән төбәкләрнең табигатен һәлакәттән коткарып, йөз меңнәрчә кешеләрнең — ватандашларының тормышы өчен көрәшәләр ич. Табигатьне саклап калу — тереклекне саклап калу дигән сүз ул!

Нефть төбәгәндә чыгып килә торган «Хәзинә» һәм «Нефтяник Татарстана» исемле күптиражлы газетларда «Азнакайнефть»нефть һәм газ чыгару идарәсенең икенче цехы эшчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләренең җәмһүриятебездәге барлык нефтьчеләргә, төбәктәге авыллар һәм шәһәрләр халкына мөрәҗәгате басылган. Мөрәҗәгать безне, табигатьнең җелеген суырып кына яшәүдән туктап, барыбыз бергә, бердәм булып, әйләнә-тирә мохитне сәламәтләндерүгә керешергә чакыра.

«Ни кызганыч,— диелә ул мөрәҗәгатьтә,— җир асты байлыкларын озак еллар буенча ничек кенә булса да күбрәк суыртып алу сәясәте Татарстанның көньяк-көнчыгышында экологияне җитди бозу-җимерүләргә китерде: чишмәләр корыды-кипте, сулар тозланды, һава сәламәтлеккә зарарлы төрле калдыклар белән пычратыла тора. Җирнең үпкәләре булган урманнар елдан-ел кими — юкка чыга бара. Без эшләгән, без яшәгән җирләрдә шәрә тау буйлары, коры елгаерымнар, ишелә торучы текә ярлар бик күп, аларны җил-сулар ашый, юа-җимерә, байтак урыннар чүплек башын хәтерләтә. Алар барысы да безнең кулларның ярдәмен — агачлар һәм куаклар утыртуыбызны көтә.

Безнең хезмәт коллективы үз җирләрен яшелләндерүне намус эше дип карый. Без язын-көзен һәр эшләүче унар төп агач һәм 15—20 төп куак утыртыр, җирләребезгә үлән чәчәрбез дип карар кылдык.

Нефть төбәгендә яшәүче барлык кешеләрне дә бу изге эштән читтә калмаска чакырабыз. Агачлар утырту ул туган Татарстаныбызны чүлгә әйләндермәү дигән сүз. Нефть төбәген яшел оазиска әйләндерик! Бу җирдә без һәм безнең балаларыбыз яши һәм яшиячәк бит!»

Әлеге мөрәҗәгать 1995 елның 24 мартында игълан ителгән. Нефть чыгара башлап, Татарстан нефте елъязмасының беренче сәхифәләре ачылуга 52 ел үткәч!

Янә бер эш кәгазе — «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең администрациясе һәм профсоюз комитеты «Чишмәләрнең сафлыгы өчен» дигән махсус конкурска йомгак ясаган. Бу ярышта җәмгысы 28 предприятие, шул исәптән 13 нефть-газ чыгару идарәсе, 2 бораулау эшләре оешмасы, 3 автомобиль юллары идарәсе, 3 катламнарның нефть бирүен арттыру һәм скважиналарга капиталь ремонт ясау идарәсе катнашкан. Нефть чыккан якларда 178 чишмә тәртипкә китерелгән, матурлап бизәлгән һәм теркәп исәпкә алынган. Иң зур эшчәнлекне «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе коллективы күрсәткән — 27 чишмә, «Елховнефть» — 15 чишмә, «Азнакайнефть», «Актүбәнефть», «Прикамнефть» идарәләре 13 әр чишмә чистарткан. Бигрәк тә «Сөләйнефть», «Азнакайнефть», Лениногорскнефть», «Баулынефть» идарәләре җирләрендәге чишмәләр яхшы сакланганнар. Шунысы әһәмиятле — болар җөмһүриятебезнең иң беренче нефть промыселлары җирләрендәге чишмәләр.

Конкурс нәтиҗәләрен йомгаклап, мондый карар чыгарыла:

I. Пычратылган чишмә суларындагы хлоридларны киметү юнәлешендә табигатьне саклау чараларын нәтиҗәле үткәргәннәрә өчен:

1 нче урын «Әлмәтнефть» идарәсенә — 50 миллион сум һәм җиңел автомашина, 2 нче урын «Елховнефть» идарәсенә — 40 миллион сум һәм җиңел автомашина, 3 нче урын «Баулынефть» идарәсенә — 30 миллион сум һәм җиңел автомашина бирелә.

II. Чишмәләрне эстетик яктан матур итеп бизәгән-җиһазлаган өчен: 1 нче урын «Актүбәнефть» идарәсенә — чит ил җиңел автомашинасы, 2 нче урын «Җәлилнефть» идарәсенә — 15 миллион сум, 3 нче урын «Иркеннефть»идарәсенә — 10 миллион сум бирелә.

III. Иң саф сулы чишмә өчен:

1 нче урын «Сөләйнефть» идарәсенә — 20 миллион сум, 2 нче урын «Азнакайнефть» идарәсенә — 10 миллион сум, 3 нче урын «Лениногорскнефть» идарәсенә — 5 миллион сум бирелә.

Болардан тыш, бу гадәти булмаган ярышта катнашучыларның бик күбесенә, исем-фамилияләрен атап, төрле бүләкләр тапшырыла. «Азнакайнефть» идарәсе башлыгы Әхтәм Фәсхетдинов, мәсәлән, эшчеләрне бүләкләү өчен скважиналарны җир астында килеш ремонтлау цехына, 2 нче нефть-газ чыгару цехына, энергетик корылмаларның прокат-ремонт цехына һәм технологик транспорт идарәсенә һәркайсына 15 әр миллион сум акча бүлеп бирә. Ул цехларның җитәкчеләре,— чын мәгънәсендә табигать сакчылары,— И. Шәрипов, М. Максютов, Ә. Маликов берәр айлык хезмәт хакы белән бүләкләнәләр.

Әлбәттә, әгәр дә урманнар утырту, инеш-чишмәләрне саклап калу-яңарту кебек, табигатьне саклау хәрәкәте Татарстандагы нефть ятмаларын үзләштерү, беренче нефтьне чыгару буенча үзенең масштаблары белән искиткеч зур һәм күләмле эш-гамәлләр белән бер үк вакытта башланган булса — нур өстенә нур гына булыр иде. Нефтьне эзләп табу, скважиналар бораулау, табылган нефтьне суыртып алу кебек эш-гамәлләрне башлаганчы ук, «ничек итеп тирә-юньдәге табигатьне саклап калырга икән?» дигән борчылулар өстенлек итсә, ни әйтер идең дә бит... Аек акыл, хуҗаларча исәп-хисап белән эш итә белүчеләр нефть чыгару эшенең котылгысыз рәвештә табигатькә зарар китерәчәген искәртергә-кисәтергә, иң өстәге түрәләрнең дә колагына индерергә тиешләр иде югыйсә. Әмма булмаганны бар дип әйтә алмыйбыз шул. Булмаган...

Дөрес, бер Җир шары гына түгел, хәтта бөтен галәм күләмендә табигатьне саклау программалары бар, алар галимнәр тарафыннан исәпләнгән-саналган, җентекләп әзерләнгән, төрле Конвенцияләр, килешүләр, берләшүләр, шартнамәләр рәвешендә кабул ителгәннәр. Мәсәлән, 1971 елның 2 маенда төрле илләрнең 2200 галиме Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль секретаре У Танны, «кешелек дөньясына моңа кадәр күрелмәгән гомуми куркыныч яный» дип, Җир шарында яшәүче барлык халыкларга мөрәҗәгать белән чыгарга тәкъдим ясыйлар. СССР белән АКШ арасында тирә-юнь мохитне саклау буенча хезмәттәшлек итү турындагы Килешү дә бар. Һаваны аэрокосмик ераклыкларда пычратуны чикләү буенча Европа илләре, Америка һәм Канада кул куйган гамәлдәге Конвенцияне дә искә алып үтик. Мондый зур күләмле, яхшы ниятләргә кагылышлы үзебездәге (СССРдагы һәм Россиядәге) күп санлы документларны саный китсәк тә, исәбенә чыга алмаслыктыр. Мәсәлән, вак елгалардан акыллы файдалану турында хөкүмәт карары, Идел һәм Урал яклары елгаларын пычратудан саклап калу турындагы шундый ук карар бар. Соңгысын Россия хөкүмәте үз исеменнән яңартып та куйды. Кәгазьдә аны эшләгәнче, башта иске карарларны искә төшерергә, аларда күрсәтелгән чараларның күпмесе үтәлгәнен тикшерергә, күпмесе онытылган, кайсы түрәләрнең өстәл тартмаларында, шкаф шүрлекләрендә тузан җыеп ята — шуларны барлап чыгарга кирәк иде юкса. Мин әле үземнең дә «Советская Россия» газеты әләме астында оештырылган «Иделне коткару җәмәгатьчелек комитеты» әгъзасы булып торганымны хәтерлим. Табигатьне сакларга чакырып чаң суккан башка бик күп һичшиксез файдалы башлангычлар, уйниятләр шикелле, ул Комитет та яңа хакимиятнең чуалыш-буталышлары өермәсендә юкка чыкты, чөнки бу хакимият тә үзенең эшен, кайчандыр хакимият башында булган большевистик партия-дәүләт номенклатурасы үрнәгендә, илдәге үзгәрешләрне гаҗәп зур җимерүләрдән башлады. Мәгълүм пролетар гимнындагыча, «... нигезенә кадәр җимереп, аннары...» шигыре белән эш итү, ай-һай ла, юньлегә илтерме икән?

Инде ничәмә-ничә дистә еллар буена, берничә буынның тормышы дәвамында табигатьне саклау чаралары, шуңа кагылышлы уй-ниятләр иң соңгы чиратта гына, калдык-постык принцибыннан чыгып кына гамәлгә ашырылып килә. Гомумкешелекнең уртак йорты — җиребез үзенең әйтеп бетермәслек гүзәллеген җуя, пычрак бер чүплек башына әйләнә бара, академик Яншин сүзләре белән әйткәндә, «ул инде тормыш мохите түгел — җир үлем мохитенә әверелеп килә».

Әйдәгез, бу борчулы уйлардан арынып, нефтьчеләребезнең үз төбәкләрен чәчәк атып утыручы яшел оазис итү өчен башлап җибәргән изге-игелекле эшгамәлләренә кайтыйк әле. Әнә бит, «Азнакайнефть» идарәсенең икенче нефть промыселы цехы эшчеләре, инженерлары, җитәкчеләре — һәркайсысы язын-көзен 10 ар агач һәм 15—20 төп куак утыртырга алынганнар. Әгәр дә бу эш киләсе елда да, өч ел, биш ел, ун елдан соң да дәвам итсә?! Куачып: «Булдырасыз, афәрин!» — диярге генә кала. Чынлап та, төньяк елгаларын корылык янаган төбәкләргә борып җибәрергә, дип баш ватканчы, һәр кеше һәр елны үзе яшәгән төбәктә берәр агач утыртса, һәр авылда, һәр шәһәрдә яшәүчеләр, җыелышып, берәр

чишмәне рәтләсә-яңартса, берәр нәни генә инешне мул сулы итәрг тырышса — нинди изге эш булыр иде! Юкса бик авыр эш тә түгел бит инде...

Нефтьчеләрнең әлеге матур башлангычын, барлык нефтьчеләрдән тыш,— әлар 80 мең кеше чамасы,— шушы төбәктәге кала-салаларда гомер итүче халык та бердәм күтәреп алса, ул бит миллионнарча пар ышанычлы-таза эшче куллар дигән сүз. «Нефть төбәген яшел оазис итик!» — дигән чакыруга һәр ике кешенең берсе кушылса да, ул бит табигатьне яклаучы-саклаучы бихисап фидакарьләр дигән сүз. Ел саен, әйтик, яңа утыртылган биш миллион агач яңа урманнар булып күкрәп үсеп китсәләр, шатланмас идекме? Әле бүген зәгыйфь кенә утырган яшел үсентеләр, «кара алтын» осталарына рәхмәт әйтеп, тирә-юньгә ямь биреп шаулап торырлар. Кешеләр дә автомобильләрдән, төрле морҗа-торбалардан чыккан төтенне-газны иснәмәсләр, ә «кислород фабрикалары» — урманнарның саф һавасын суларлар.

Бу матур башлангыч үзе дә, саф сулы чишмә кебек, астан-төптән, халыкның кайгыртуыннан бәреп чыккан булуы белән кадерле. Җирнең яшел йөзе өстеннән пычратылмаган саф сулы инеш-елгалар агармы, алардан башка Идел-Чулман шикелле иң зур елгалар да кибеп-корып бетмәсме, кешеләр ярдәм итмәсә, тирә-юньдә болай да сирәкләнә барган урманнар да үлеп бетмәсме, тормыш бүләк итәргә тиешле һава тоташ агуга әйләнмәсме — менә шундый борчулы уйланулардан соң, халык тиз ватылырга, тиз җәрәхәтләнергә торган табигатьнең язмышы өчен үзен җаваплы тоя башлаган икән — бу бик яхшы, куанычлы фал.

Карагыз әле, күп кенә файдалы теләк-ниятләр, табигатьне саклау буенча ныклап исәпләнелгән-уйланылган программалар ни өчен тормышка ашырылмый калалар соң? Юри эшләгән шикелле, барысы да киресенчә килеп чыга: никадәр күбрәк яклау чаралары уйланылса, урманнар шул кадәр азрак кала, җәнлек-җанварлар, кош-кортлар, бөҗәк-күбәләкләргә яшәү урыны юкка чыга бара. Борын-борыннан чисталык-сафлык чыганагы булган, халык һәрвакыт изге итеп караган елга-чишмәләр ничек кирәк алай тереклек итү, суын эчү, аш-су пешерүгә тоту, юыну-кер юу өчен дә яраксызга әйләнә бармыймы? Эчкән суына кайчандыр, ата-бабалар ырымына буйсынып, җептер-фәләндер генә салып киткән кешеләр хәзер суларга дуңгыз фермаларының шакшысын, мал-туардан калган тиресне, көндәлек тормышта җыелып килгән чүп-чарны ташларга-түгәргә дә тартынмыйлар. Билгеле, табигатькә карата булган бу вәхшилекләр закон-кануннар белән тыелган санала, әмма, намус-вөҗданың белән үзеңне тыя белмәгәндә, ул законнарга кем карап тора соң?! Шуңа күрә дә өстән төшерелгән директив күрсәтмәләр халык тарафыннан күтәреп алынмый. Бер мәзәктәге кебек: урман өстендә шаулый, аста исә яфрак та селкенми!

Менә гадәти нефть промыселы: скважиналар, бер күтәрелеп-бер төшеп нефть суыртып утыручы сиртмә — «торналар», төрле-төрле торбалар, су җыйгычлар, бер катлы кечерәк кенә контора бинасы, аның стенасына беркетелгән «Тәмәке тартырга ярамый!» дигән искәртү... Дөрес, хәзер элеккеге вышка-манаралар, каланчалар юк, аларны бер утыз еллар элек алып бетерделәр, алар урынына хәзер йөк автомашиналары кәпчәкләренә утыртылган күчмә мачталар кулланалар. Ә гадәти булмаганы — базаның барлык мәйданында яшелләнергә тырышып утыручы зәгыйфь үсентеләр, киләчәктә матур-мәһабәт буласы агачлар. Үсентеләр тернәкләнеп тә киткән инде, димәк, үсәчәкләр! Аларны операторлар Нурия Хажиева, Нияз Сәйфиев, Ирек Хәлиуллин, Газинур Габдерәшитов, Нәфис Юнысов, Тәлгать Газизуллин, Рамил Измайловлар утырткан. Кем соң изге эштән баш тартсын? Фикер тусын да, башлап җибәрүче генә булсын! : башлап җибәрүчеләр нефть суырту цехы башлыгы Илгиз Шәрипов, мастер Әбүзәр Гыйлфановлар... Менә шулай, барысы дәррәү көрәккә тотынганнар алар.

Үрнәк эшнең көче зур аның! Мин ул елны бу якларда күп йөрдем, кайда гына барсам да, беренче эшем итеп, урманнар үстерүдә башлап йөрүче фидакарьләрнең чакыру сүзләре уңдырышлы туфракка төшкәнме дип, күпме агач утыртулары белән кызыксына тордым. Һәм чын-чынлап куанычлы мизгелләр кичердем, чөнки күреп йөрдем — изге эш җавапсыз калмый.

Кара көз кергәч, Актаныш нефть ятмаларын тәкъдир итүдә катнашкан идем. Гадәттә, нефтьчеләр яңа мәйданнарны үзләштерә башлау уңаеннан алай шаушулы тантаналар үткәрү белән мавыкмыйлар. Бездә шулай бит: суга берәр яңа кораб төшерсәләр — галәмәт тантана — һавага баш киемнәре чөяләр, корабка бәреп, бәхет юрап, шампан шешәсе ваталар. КамАЗ автогигантын эшләтеп җибәргәндә дә заводның беренче һәм икенче чиратларында икe митинг булган иде. Тантанага килгән кунаклар төзүчеләр-эшчеләрдән дә күбрәк булмадымы икән әле? Казаныннан, Мәскәвеннән махсус самолетлар белән зур түрәләр,

дисеңме, төрле газет-журнал, радио-телевидениеләрнең көтү-көтү хәбәрчеләре, дисеңме! Галәмәт инде! Кызык бит: завод сафка баса — митинг, яңа мәктәп ачыла — митинг, мәчет күтәрелә — митинг...

Ә нефтьчеләр яңа ятмаларны эшкәртүне тын гына, тыйнак кына, көндәлек эш итеп кенә башлап җибәрәләр, борыны сизгер журналистлар гына, эләктереп алып, язып чыксалар инде. Җөмһүриятебездә илледән артык ятмалар эшкәртелә, калганнары әле чират көтә, ә тантаналы тәкъдир итү Актаныш җирләрендә генә булды. Бу «кара алтын» хәзинәсе беренче Ромашкино ятмаларына тиңләшә алмаса да, еллык табышы 100—120 мең тоннага гына исәпләнсә дә, бәйрәмтантана истә калырлык итеп үткәрелде. Район үзәгендә — ярминкә: нефтьчеләрнең сәүдә итәргә килмәгән кибете дә калмагандыр, товар төягән КамАЗлар кәрванына исләрең китеп карап торырлык иде. Мәйданда — үзешчән артистлар фестивале: җырчылар, музыкантлар, биючеләр һ. б. һ. б.... Хәттә Президентыбыз Минтимер Шәймиев тә вакыт тапкан, бәйрәмгә очып килеп җиткән иде.

Беренче нефтьне суырта башлаган промысел биләмәсендә митинг булды. Президент Минтимер Шәймиев, Татарстан нефтьчеләренең генераль директоры Ринат Галиев, бәйрәмчә матур теләкләрен белдереп, чыгышлар ясадылар, бергәләп торбаның биген ачтылар һәм нефть төп нефтьүткәргечкә юл алды. Хәерле юл!

Минем күз алдымда әле язын Азнакай якларында күргән яшел үсентеләр торгангамы, биредә — Актаныш якларының уңдырышлы кара туфрагында да күз карашым җирдән төртеп торган яшел башлы нәни чыршыларны абайлап алды. Әле промысел эшли башламаган, ә агачларны утыртып та өлгергәннәр! «Афәрин!» — диме, ни диярсең?! Баксаң-күрсәң, өч йөз төп чыршы, унбиш алмагач, илле төп карлыган икән — үзе бер бакча! Бакча гынамы, һәйбәт урман! Актаныш промыселы операторларының башлап йөрүчесе мастер Илгиз Раянов: «Бу әле эшнең башы гына», — диде. Монда бит әкренләп скважиналар саны да арта барачак, димәк, яшел бакча-урманнар да ишәячәк, кешеләр углеводород парлары суламаслар, ә ылыслы урманнарның шифалы-фитонцидлы һавасын сулап киенерләр.

Мин әле тагын Норлат нефть ятмаларыннан алынган нефтьне комплекслы әзерләү җайланмасы булган Күтәмә җайланмасын карарга да барган идем. Аның башлыгы Тәлгать Һилалов миңа, бу зур һәм катлаулы корылманың ни өчен төзелгәнлеген аңлатып, технологик процессларның нечкәлекләренә кадәр төшендереп бирде. Башкача ярамый икән. Нефтьтә су бар, төрле тозлар бар, ә аны чиста булса гына, төрле кушылмалар юк дәрәҗәсендә булса гына кабул итәләр икән. Шуңа күрә, нефтьчеләр катламнардан алынган ике миллион тонна «кара алтын»ны башта җитмеш градуска кадәр җылыталар, махсус реагент — химик матдәләр кушалар, мичләр-деэмульгаторлар аша үткәреп, җыеп тондыралар, шул рәвешле генә чит илләргә — экспортка җибәрерлек дәрәҗәгә җиткерәләр. Әгәр сыйфаты тиешле шартларга җавап бирмәсә, начар нефть өчен шундый зур штраф салалар, аны чыгарып азапланунын мәгънәсе дә калмый. Аннары Тәлгать Һилалов җайланма тирәсенә көздән утырткан агачлары белән дә мактанып алды...

Бер мисал очраклы булырга мөмкин. Ике үрнәк инде уйланырга, фикер тупларга мәҗбүр итә. Ә өч үрнәк-мисал нәтиҗәләр чыгарып, йомгак ясарга мөмкинлек бирә. Карагыз әле, нинди бөек һәм матур гадәт-йола туып килә түгелме соң? Тege яки бу җирне үзләштерү-эшкәртү урманнар кисүдән башланмый, ә агачлар утыртудан башлана! Юкса, урман кисүченең балтасы күп кенә ил-халыкларның милли фаҗигасенә әйләнгән заман бит. Кызганыч ки, бу җәһәттән Татарстаныбызда да эшләр мактанырлыктан узган. Ә ни өчен, нефтьчеләребезнең әлеге башлангычын үрнәк кагыйдә итеп алып, Россиянең һәр төбәкләрендә үтәлергә тиешле эш-гамәл итеп, аны дәүләт документлары белән законлаштырмаска, аннары хуҗалык итүнең бу үрнәген башка илләргә, башка кайтгаларга да таратмаска икән?

* * *

Нефть төбәкләрендәге чишмәләр янына барып йөри башлаганчы ничектер «чишмә» сүзенең мәгънәсе хакында уйланганым юк иде. Ә бит ул чишмәләр, мең булмаса да, дистәләр-йөзләрчә: берәүләре җир астыннан шундый көчле бәреп, ургылып-ташып чыга ки, суын торбалар аша авыл йортларына, фермаларга, остаханәләргә кудырырга буладыр хәттә; икенчеләре тау-

таш токымнары арасыннан тавышсыз-тынсыз гына саркып-тибеп, нечкә агым булып кына сызыла, бу агым кибәр, юкка чыгар, янадан жир астына китәр төсле, куркынып куясың. Чишмә, чыгыш, кизләү... Төрки-татар телендәге бу сүзләрнең тамырлары-мәгънәләре шактый ачык тоемлана. Азмы чишмәләр зур-зур елгаларның башы — чыгышы булып тора, күлләрне тутырып-тулыландырып тора. Тверь ягындагы Волгино Верховье чишмәсеннән бөек Волга, үзебезчә әйтсәк, Иделебез башлана. Иделнең жир йөзендәге унбиш мең кушылдыгының һәркайсысы шулай бер чишмә-чыгыштан юл яра бит! Алар арасында Кама-Чулман, Ока-Ука, Свияга-Зөя, Сура кебек мул сулы озын-озын елгалар да бар. Алар да, чишмәләрдән башланган вак инеш-елгачыкларны жыя-жыя, шулай үскәннәр. Әйе, әйе, һәр зур гамәлләр кечкенәдән башланган шикелле, алар үзләренә эреле-ваклы инеш-елгачыкларны ияртә-куша килеп, зур елгаларга әйләнгәннәр. Мин ышанам: нефтьчеләребезнең матур башлангычы да, үз үрнәгенә башкаларны ияртә-куша килеп, илкүләм зур, изге эш-гамәлгә әйләнер әле.

«Чишмә» сүзенең урысчасына — «родник»ка килсәк, «род», «родить» тамырына барып чыгарбыз. Димәк, «тудыру» дигән сүзгә барып тоташа икән бит ул! Нәрсәне тудыру? Әлбәттә, суны! Ә суны тудыру — ул тормышны, тереклекне тудыру. Су булдымы, аның янында яшел үлән тәртеп чыгар, берәр куак-агач тамыр жибәрер, ә аннары инде, чишмә көч алып инеш-елгаларга әверелгәч, аның ярлары яшел хәтфә болыннар-тугайлар белән бизәлер. Зур сулар янына кешеләр тартылыр, авыллар нигезләнер, зур-зур шәһәрләр күтәрелер, завод-фабрикалар төзелер. Су бар жирдә тегермән буалары, гидростанцияләр калкып чыгар, сусыз икмәк тә пешереп, сыра да кайнатып булмый, сусыз нефть тә чыкмый, тимеркорыч та эреми. Су юкка гына иң гади һәм иң алыштыргысыз минерал, иң серле һәм иң могжизалы матдә булып саналмыйдыр! Һәркайда су кирәк, су, су, су...

Әмма без жир астының караңгы катламнарыннан кояш яктысына яңа гына тибеп чыккан чишмәнең көчсезлеген-зәгыйфьлеген, яклаучысыз-саклаучысыз, әле туып кына килгән сабый бала хәлендә икәнлеген онытмаска тиешбез. Менә ул тернәкләнер, алдындагы тау-ташларны тишеп йә әйләнеп үтеп, диңгез-океаннарның зур суларына кушылырга юл эзләп сәфәргә чыгар. Кешеләрнең иң тәүге ярдәмчесе булган чишмәләргә без дә мәрхәмәтле ярдәмче, аны яклаучы-саклаучы ышанычлы юлдаш булырга бурычлыбыз. Без — кешеләр бит!

Фашист Германиясе белән сугыш елларында Югары Башкомандующий Иосиф Сталинның эш кабинетында сугыш хәрәкәтләрен чагылдырган карта эленеп торган, ул карта фронт сызыклары, саклану чаралары һәм һөҗүм юнәлешләрен күрсәткән уклар белән, тагын бик күп төрле билге-тамгалар белән чуарланып беткән булган. Бик табигый, бик аңлаешлы: армия һәм флотлар белән житәкчелек итүче кешенең күз алдында шундый карта булмыйча, нәрсә булсын?

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең эш кабинетында Идел, Чулман, Нократ, Агыйдел, Зөя кебек елгаларның зәңгәр челтәренә уралган Җөмһуриятебез картасы. Шунда ук йөзләрчә вак елгачыкларның нечкә тамырлары, авыл-шәһәрләрне күрсәткән кара төртке-түгәрәкләр. Монысы да гадәти, табигый күренеш. Илбашы икән — шулай булырга тиеш.

Ә менә «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Ринат Галиевнең эш кабинетында иң түрдә... чишмәләр картасы! Ул картада 434 чишмә билгеләнгән, аларның 78 е өстенә хәвефле тамга — кызыл флагчыклар кадалган. Мин юри игътибар иттем: анда запас нефть ятмаларының урыннары да, Татарстан промыселларыннан «кара алтын» белән тәэмин ителеп торучы Россиядәге, якын чит илләрдәге, Европа илләрендәге «ноктала́р»га сузылган үзәк нефтьүткәргечләр дә, нефть суыртып утыручы скважиналар да түгел, ә нәкъ чишмәләр генә төшерелгән. Гаҗәбрәк хәл бит: нефть генералы юкса үзе, мин бераз сәерсенеп тә калдым.

— Ә нәрсәсе аңлашылмый соң моның? — дип сүз башлады Ринат Галиев.— Әгәр дә без, нефть, нефть дип, чишмә-инешләребезне һәлак итсәк, үзебезнең жиребезне нефть Чернобыленә әйләндереп бетерербез, анда яшәргә дә мөмкинлек калмаячак бит. Җир шарының бер пар үпкәсе бар: урман белән су. Шулар безгә тормыш-тереклек бирә, шатлык һәм ләззәт китерә, матурлык һәм сәламәтлек бүләк итә. Нефть өчен шундый бәя түләсәк — бик кыйммәткә төшәр, шундый табигать байлыкларын исраф итеп бетергәнебез өчен балаларыбыз-оныкларыбыз безне гафу итмәсләр. Шуңа күрә, нефтьчеләрнең иң беренче кайгылары табигатьнең көчен-куәтен саклау, матурлыгын-гүзәллеген арттыру булырга тиеш. Шуннан соң гына инде нефть чыгару мәсьәләләре турында уйланырга мөмкин. Табигатьне саклау һәм табигать байлыкларын үзләштерү-эшкәртү — бу ике эш-гамәлне бер-берсеннән һич аерып карарга ярамый. Һәр чишмә — ул табигать бүләге.

Кешеләр, әгәр дә әйләнә-тирәдәге матурлыкны сакларга, шул матурлык-сафлык эчендә үзләре яшәргә телиләр икән, ул чагында җир өстенә бәреп чыккан һәр нәни чишмәнең, инеш-елгаларга әверелеп, диңгез-океаннарга бару юлында үләннәргә-чәчәкләргә, болыннарга-урманнарга, кошларга-киекләргә тереклек биреп, күбрәк файдалы-игелекле эшләр эшләвен кайгыртырга тиешләр. Нефть чыгару эшен нефтьнең үзеннән түгел, ә, кайберәүләргә никадәр сәер тоелса да, әнә шул урманнар-чишмәләрдән, табигать-анабызны саклаудан башларга кирәк.

* * *

Бер диңгез тозлы су бер кувшин төче судан арзанрак исәпләнә. Мондый югары бәһа тозлы суның, диңгез-океаннар булып та, эчәргә-сугарырга, башка хуҗалык эшләренә яраклы төче суның гомуми су күләменнән нибары ике процент кына булуы белән генә дә аңлатылмый. Тозлы океан-диңгез суларын эчеп булмаудан гына да түгел бу. Ахыр чиктә, суны төчеләндерә торган махсус җайланмалар төзергә, шул рәвешле авыл-шәһәрләрнең сусавын басарга мөмкин. Жюль Верн романындагы капитан Немоның су асты көймәсе океанның тозлы суын файдаланган бит әнә. Казагыстан нефтьчеләре шәһәре Мангышлак та диңгездән алып төчеләндерелгән су эчә. Табигатьнең бөек минераль байлыгы булган төче сулы чишмәләр әйләнә-тирә мохитне яхшырта-сафландыра, аларны карап-тәрбияләп тоту өчен, физик көч-куәт һәм рухи кичерешләр өстенә, зур чыгымнар да таләп ителә. Шуңа күрә дә зур кадер-хөрмәт ул чишмәләргә.

Нефтьчеләрнең югарыда әйтеп үтелгән конкурс-ярышында исәпкә алынып, махсус схема һәм карталарга төшерелгән чишмәләрнең барысын да күреп бетереп булмады, әлбәттә. Моның өчен, асфальт юлдан җилдереп кенә түгел, ә хуҗаларча ягымлы куллар кагылган һәр чишмәгә илтүче сукмаклардан йөреп чыгарга, Татарстанның ярты җирен диярлек аркылыга-буйга гизәргә кирәк булыр иде. Шулай да мин байтак чишмәләрне күрдем, аларга сокланып карап тордым, тешләрне сындырырлык шифалы салкын суларын эчтем.

Актүбә поселогы. Технологик транспорт идарәсендә чишмәләр башлыгы итеп Наил ага Кәлимуллинны куйганнар. Гомеренең иң матур елларын нефть эшенә багышлаган ветеран, әле пенсия яшенә җиткәч тә мастер булып эшләгән, соңгы елларда гына гомерен үзенең тугрылыклы карчыгы Зәйтүнә әби белән бергәләп өйдә уздыра башлаган. Әмма барча халык кузгалганда, ничек тыныч утырасың,ди?! Идарә башлыгы Петр Баязитов Наил аганы чакыртып ала да әйтә:

— Тәҗрибәң бар, әйдә, чишмәләр командиры бул әле! — ди.

— Ә эшчеләр, техника, материаллар?..

— Беренче чиратта — синңа. Синең кайчан, кайда, күпме кирәк икәнен әйтүең житә. Килештекме?

— Килештек.

Мин килгән көнне Наил ага Кәлимуллин үз кешеләре белән урман чишмәсен рәткә китереп ята иде. Шимбә — ял көне, ә алар, колхоз бәрәңгесен алырга баргандай, дәррәү кузгалып, чишмәгә килгәннәр. Механиклар, слесарьлар, балта осталары... һәм, әлбәттә инде, хатын-кызлар: техниклардан Гөлйөзем Хуҗина белән Зәфинә Сабитова, операторлар Резеда Ибраһимова, Лилия Гарипова, Наталья Усольцева. Эш һәркемгә җитәрлек иде: күперчекләрне, киртә-коймаларны буядылар, юл-сукмакларга вак таш җәйделәр, чишмә алды мәйданчыгын асфальтлап куйдылар.

Скважиналарга капиталь ремонт ясау идарәсе коллективына катлаулырак һәм житдирәк бурыч куелган — Микулино авылы чишмәләрен коткарырга кирәк.

Бик күптән инде, крестьяннар патшасы Пугачев пәйда булганчы ук, Микулино ир-атлары Урал таулары итәгендәге яшел калкулыклар ышыгына — шушында беренче йортларын нигезләгәннәр. Тау, урман, аста — инеш, аңа тау өстеннән берьюлы берничә якты чишмә су коеп тора. Ул чишмәләрнең агымнары берберсенә янәшә генә кебек, ә менә суларның тәме төрлечә икән. Су булгач, крестьян агаена нәрсә кирәк тагын? Җир, дисәң, әнә ул — тирә-якта уңдырышлы кара туфрак. Вакытлар үтү белән авыл үскән-зурайган, чиркәү калкып чыккан, халык мәктәбе ачылган, крестьян хуҗалыкларында кешеләрнең күплеге белән бу авыл тирә-як авыллардан аерылып торган һәм волость булган.

Әмма аннары төрле аграр үзгәртеп корулар, буталчыклыклар башланган. Крестьяннарның ялгыз хуҗалыкларын бетереп, үзләрен колхозга куып кертkәннәр, иң хәлле-тырыш һәм мул тормышта яшәгәннәрен, «кулак» мөһере сугып,

авылдан сөргәннәр. Аннары инде Никита Хрущевның колхоз-совхозларны эреләндерү сәясәте, картаеп беткән генсек Леонид Брежневның эшкә ашмас азык-төлек программасы, Михаил Горбачевның социализмны җимереп үзгәртеп кору шаукымы һәм, ниһаять, үзен реформалар остасы дип санаган Борис Ельцинның төрлечә көчәнүләре — боларның аяныч нәтиҗәсе шул: ахыр чиктә Микулино авылы, бетәшеп, үлеп бару хәленә килеп җиткән. Берәүләре зур коммунистик төзелешләргә чыгып ычкынган, икенчеләре, акчасына кызыгып, «кара алтын» осталарына әверелгән, тузган иске йортларда үлем көтеп ятучы карт-коры гына торып калган.

Көтелмәгән бәла аяк астында ята, диләр. Кинәт кенә авыл чишмәләрендәге суның тәме үзгәргән, аны эчеп булмый башлаган. Бу инде колхозлашу-фәлән эше генә каза түгел! Микулино халкына суны, гарәп чүлләрендәге бәдәвиләргә ташыган шикелле, цистерналар белән китереп эчертә башлыйлар. Бәхетсезлек, фаҗига...

Моннан дүрт ел элек авыл халкының өмет йолдызы кабына: Микулинону нефтьчеләр шефлыкка ала. Фермаларны торгызалар, авыл урамнарына, ферма юлларына асфальт җәяләр — сыер савучы чибәрләр эшкә туфли киеп кенә йөрешле! Өйләргә газ кертәләр, утын кайгысы бетеп, җылыда яшәгәч, оҗмах инде бу!

Ләкин менә — су, су, су...

Ниһаять, 1996 елның җәендә Микулинонын кайчандыр тирә-якта дан тоткан чишмәләренә дә чират җитә. Эшне скважиналарны капиталь ремонтлау цехына тапшыралар. Ни әйтсәң дә, аларда иң куәтле техника, белгечләре җир асты катламнарының серен яхшы аңлый: кирәксә, ача да, ябып, томалап куя да беләләр.

Шулай итеп, бер шимбә көнне ремонт эшчеләре, цех башлыгы Владимир Пестриков җитәкчелегендә килеп, чишмә суларының сафлыгы өчен көрәш башлап җибәрәләр. Бер таудан берьюлы биш чишмә челтерәп агып ята, һәркайсының тәме, температурасы үзенчә — ремонтчы осталарга гаять катлаулы бурычны үтәргә туры килә: тау эчендәге «тишек-тошыклар»ны эзләп табып, ямаргатомаларга кирәк, чишмәләр суына шулар аша төрле зарарлы минераль тозлар саркып кушыла икән бит. Шул «тишек-тошыклар»га бер вак ташны гына да 150 (!) самосвал китереп тутыралар. Әлбәттә, башка эшләргә дә тоталар.

— Җиңеп чыгарбыз дип уйлыйм,— диде миңа Владимир Пестриков, җир астында үткәреләсе катлаулы «хирургик» операциянең нечкәлекләрен аңлатып.— Саф сулы чишмәләрсез авыл халкы да бик интегә, безгә дә даны юк. Пычранган чишмәләр — һөнәреңне рәтле-юньле белмичә, аннан-моннан гына, пычрак итеп эшләүгә тиң инде ул.

Чишмәләргә нефтьчеләр кушкан исемнәрнең шигърилеген тыңлагыз әле сез: авылына-урынына карап, татар, урыс, чуваш, мордва телләрендәге иң матур, иң төгәл сүзләрне сайлап ала белгәннәр бит! Барысын да санап бетерә алмасам да, кайбер татарча исемнәрен генә әйтеп күрсәтим әле: Якты чишмә, Салкын чишмә, Баллы чишмә, Кызыл чишмә, Татлы чишмә, Каенлы чишмә, Урман чишмәсе, Кыр чишмәсе, Нури бабай чишмәсе, Самаварлы чишмә...

Азнакай хакимияте башлыгы Әнәс Исхаков, яшьлегендә шигырьләр язып йөргән чакларын исенә төшереп, нефть төбәкләрендәге чишмәләр турында «Чишмәләр иле» дигән поэма иҗат иткән хәтта! Ә менә шагыйрь Марс Шабаевның бер шигырендә мондый юллар бар:

Таш астыннан сызылып кына  
Чыкса да салкын суы,  
Туктамый — кайный,ургыла...  
Син тыеп кара шуны!  
Нигә тынсын, кайнамасын,  
Тереклек тынамыни?  
Чишмәсез, каен, миләшсез  
Бу дөнья дөньямыни?  
Булганыгыз бармы сезнең  
Шундый чишмә янында?  
Суы бик салкын булса да,  
Яндыра ул, яндыра...

Мин шагыйрь телгә алган шундый чишмәләр янында күп тапкырлар булдым һәм үзем дә халык күңелендәге шигъри дулкынга кушылдым шикелле — бу язмамны «Яшел чишмәләр» дип атадым. Ни өчен яшел? Чишмәләр челтерәвенә кушылып, тирә-юньдә яшел урманнар шаулап утыруын күрәсем-ишетәсем килә. Яшел ябалдашлы агачлар булганда, чишмәләр мәңге корымаячак-кипмәячәк бит алар!

Вакытлы бараклар салып маташмыйча, япан кырда чиста-саф матур шәһәр булып күтәрелгән бердәнбер шәһәр — нефтьчеләр шәһәре Җәлил булыр. Менә шунда тар гына сукмак мине каен урманына алып чыкты. Урман эче чиста, бер янган учак эзе, бер тутыккан консерв банкасы, бер ертык-портык полиэтилен пакет сәләмәсе күрмәссең. Шундый рәхәт! Кошлар сайрый, күбәләкләр оча. Гөлчәчәкләр өстендә — умарта кортлары, төклетуралар гөжләшә. Яшел үлән арасыннан ялт итеп кенә яшел кәлтә үтеп китә. Ирексездән, күңелгә янә шигырь юллары килә:

Каеннарда һаман яшьлек күрәм:
Яшьлек аның сылулыгында,
Аклыгында — яшьлек, яшеллектә...
Таң җилендә сыгылуында.
Каен урманнары шундый якты!
Якты сафлык бии... Туйны күр!
Җиһан нигә шундый яктылыкка,
Инсан ак бәхеткә туймыйдыр?!

Бу шигъри юллар да — Марс Шабаевтан. Ә бирედә — оҗмах! Күңелдәге куанычны тагын да тулыландырып, ике торбадан ак ялкын шикелле салкын чишмә суы агып тора.

Булса булыр икән матур урын! Каен урманының салкынча күләгәсендә уч төбе кадәр җирдән берьюлы ике чишмә бәреп чыккан... Куш чишмә... Ярлары ишелеп, чишмә агымын томаламасын өчен аларны зур-зур ташлар тезеп ныгыткаңнар, каеннар астына утыргычлар ясап куйганнар: утыр, ял ит, тыныч уйларыңа тал. Шәһәрдән бирегә, мөгаен, ике чакрымнар бардыр, ә бәлки, артыграктадыр. Сукмак әйбәт тапталган, димәк, шәһәр халкы чишмәләргә юлны белә!

Җәлил — зур шәһәр түгел. Халкы ун меңләптер, нигездә, нефтьчеләрнең беренче-икенче буыны. Аргы очтан яки аннан да ары китеп булса да, иң тәмле чишмә суы алып кайтып самовар кайнату гадәтен халык монда да онытып бетермәгән — чыгышлары белән авылныкылар бит. Идәнен-керен юарга, башка кирәк-ягракларга суны өйдәге краннан гына агызып алалар, ул тәмсез хлорлы суны кемнең эчәсе килсен — берәр көн торса, графиның каралып чыга, чәйнекләргә сары юшкын утыра. Шуңа күрә дә чәйлеккә чишмә суына йөри булыр Җәлил халкы.

Чишмәләр административ бүленешләрне, ил-дәүләт чикләрен белмиләр, алар җир асты суларына һич уйламаган урыннардан юл табалар: ерым-ерганак ярларыннан, калкулыклар-тау битләреннән, караңгы, тын урман ешлыкларыннан бәреп чыгалар да, үз тормышлары белән яши башлыйлар.

Җәлил шәһәреннән без Сарман якларына китеп бардык. Утыз чакрымнар ары. Район үзәге Сарманның бер читендә нефтьчеләр шулай ук куш чишмәне чистартып-төзекләндереп ясап куйганнар. Табигатьнең шуклыгымы бу, әллә көтелмәгән сөенечме — бер җирдә эзләп тә таба алмыйсың, икенче җирдә — ике, биш, хәтта ун чишмә! Шагыйрь Сибгат Хәким дә «Бер тауда ун чишмә» дип юкка гына язмагандыр шул. Чишмәләр — хикмәтле дә, серле дә алар.

Мине «Җәлилнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең табигатьне саклау буенча баш инженер урынбасары (нефтьчеләрдә хәзер шундый вазифа да бар!) Марат Фәсхетдинов озатып йөрде. Мин аңа:

— Кайчандыр «әби патша» Екатеринага яки партсовэлита түрәләренә «Потемкин авыллары» гына күрсәтеп йөрткән шикелле, миңа дә әйбәт-төзек чишмәләрне генә күрсәтеп мактанмыйсызмы? Картада кызыл флагчыклар белән билгеләнгән «авыру» чишмәләр кайда соң? Нигә без цистерналар белән су китерелгән авылларга бармыйбыз? Яшерәсезме әллә? — дип бәйләнмәкче дә булган идем.

— Андыйларына да барып чыгарбыз,— дип тыныч кына әйтеп куйды Марат Фәсхетдинов.— Һәр пычратылган-тозландырылган чишмәгә махсус паспорт булдырылып, нәрсә эшләтергә икәнлеге тәгаенләнгән, җаваплы кешеләре билгеләнгән икән — аны кемнән яшереп торасың, ди? Суы саф-тәмле чишмәне төзекләндерү-бизәү, аңа матур исем бирү, әлбәттә, изге эш, әмма иң җиңел эш. Авыры — бәланең башы булган, тузып челтәрләнгән-куышланган җир асты катламын эзләп табу, чишмәләрнең саф суларына шуннан кирәкмәгән зарарлы тозлар саркып үтә, аны пычрата. Башта менә шул җир асты куышлыгын-тишеген эзләп табасың, ә ул өстә генә — уңдырышлы туфрак катламында гына да, өчәр йөзбишәр йөз метр тирәнлектә дә булырга мөмкин, аннары шуны яхшылап ямыйсың-томалыйсың. Буралы Чишмә авылында шундый тозланган ике чишмәне

сафландыру эше җәй буена сузылды, чишмә суы берничә йөз миллион сумга төште. Ул кадәр чыгым ясау өчен бер генә мең тонна нефть суыртмыйсың. Менә шулай ул чишмәләр арифметикасы!

Сарман чишмәләрен карарга барганда, ярты юлга житкәч, Яхшыбай авылы аша уздык. Марат Фәсхетдинов, шоферга ым кагып, асфальттан яшел әрекмән яфраклары, кычытканнар каплап киткән тын тыкрыкка борылырга кушты. Борылмаларны ышанычлы күрсәтеп баруына карaганда, бу юл аңа шактый таныш иде булса кирәк. Бара торгач, без бәрәңге бакчалары артына килеп чыктык та, биек тау битеннән үзенә юл салып, зур елгаларга кушылырга ашыккан исемсез бер инешкә килеп төртелдек. Инештән өстәрәк ярдан тагын су саркып тора иде, чистартсан — чишмә буласы юкса. Әмма суы тәмсез икән, минераль тозлар белән бозылган — мин татып карадым, ләкин эчмәдем.

— Чишмәләрнең төрлесе бар,— дип аңлатты Марат Фәсхетдинов.— Нефтьчеләр аяк басмаган җирләр дә күп, ә менә эчәргә әйбәт, йомшак су табып булмый, чәй дә кайната алмыйсың. Бу төбәкләр нефть яклары булып исәпләнгәч, җаваплылык барыбер безнең җилкәгә төшә. Чарасын күрергә кирәк була.

— Слесарь-сантехниклар шикелле, мондый чишмәләрне томалап-ябып куясызмы?

— Анысы кыен эш түгел: начар су юлына скважина тишәсең дә, шуннан цемент тутырасың, ләкин бит башта кайсы урыннан скважина тишәргә икәнен табарга кирәк әле. Менә бу тозлы чишмәгә дә чират җитәр, насыйп булса...

Сарман читендәге куш чишмәгә, шоферлар туктап ял итсен, озын сәфәргә чыгар алдыннан саф чишмә суы алып китсен өчен, асфальт юл да сузганнар. Юл уңай район газеты мөхәррире Дамир Гарифуллинны да үзебез белән алган идек. Ул сәләтле генә шагыйрь, әмма бик тә тыйнак инде — мең бер йөз робагый язган, шәрекъ шигыренең бөек остасы булган Гомәр Хәйямнекеннән дә күбрәк, тик бастырып чыгарырга җөрьәт итми икән үзе.

— Әлегә бу җирләр шәрә, кояшка-җилгә изүләрен ачып тора,— дип, хужаларча сөйләп алып китте Дамир.— Озакламый куш чишмә тирәсенә урман утыртырбыз. Өйләнүче яшь парларның һәркайсысы, бәхетенә юрап, берәр агач утыртуны матур гадәткә кертербез. Берничә елдан куш чишмәбез агачлар күләгәсендә калыр. Су өчен урманнан да яхшы сакчы бармы соң?

Икенче промыселның урманчы операторлары күтәреп чыккан «яшел» башлангычны — һәр кешегә — 10 төп агач, 15—20 төп куак утыртуны янә искә төшерәм: Корбан бәйрәмендә нәкъ үз вакытында азан әйтелгән шикелле, нәкъ үз вакытында, изге сәгатендә башланган игелекле эш дими, нәрсә диярсең? Чишмәләрсез инеш-елгалар булмаган кебек, агачларсыз урманнар да була алмый. Хәзер бу матур башлангычның «яшел ялкыннары»на сүнәргә генә бирмәскә, аны яңа эш-гамәлләр белән гел дөрләтеп торырга гына кирәк.

Мин әле бу язмамны тәгаллəп тә бетерә алмаган идем, икенче җәйдә «Татар-информ» республика агентлыгы чишмәләр һәм инешләр айлыгы турында газетлар аша хәбәр таратты. Саба районында — 35, Кукмара районында — 27, Балтач районында 20 чишмәне төзекләндереп-матурлап ясап куйганнар. Бер айда җәмгысы 110 чишмәгә куллары җиткән бу як кешеләренең. Әлбәттә, Татарстан күләмендә әллә ни күп сан да түгелдер, әмма саф, тәмле суның файдасын-шифасын аңлаган кешеләр, елга бер үткәрелгән айлыкларда гына түгел, теләсәләр, ел әйләнәсе, гомер буе ул чишмә-инешләрне карап-кайгыртып торачаклар бит. Су исә һәр ходай бирмеш көн кирәк ул!

* * *

Миңа кадәр бу чишмәләр юлыннан Татарстан нефтьчеләре генералы Ринат Галиев узган. Ул инде, минем кебек, кызыксынучан турист сыйфатында гына йөрмәгән, үзе белән нефть эшенең командирларын да ияртеп чыккан. Тәмле сулы чишмәләр булдыручыларны: «Менә ничек эшләргә кирәк!» — дип мактаган, ә инде чишмәләрнең тирә-юнен бизәп-матурлап кына, суын авызга алмаслык итеп калдыручыларны: «Без бит килмешәк варяглар түгел! Без шушы җирдә мәңгегә йокыга таласы, шушы җирдә балаларыбыз-оныкларыбыз яшисе бит!» — дип, оялткан да, шелтәләгән дә ул.

Дөрес эшләгән. Табигатьне, аерым алганда, чишмә-суларны, урман-кырларны, сулый торган һавабызны саклау турында сүз бара икән — үрнәк булырлык эшләрне күрсәтеп, ярамаган яманнарына гаепләреләрне борыны белән төртеп тә

өйрәтергә кирәк. Мактулганнары, дәртләнеп китеп, яхшы гамәлләрен ишәйтерләр, шелтәләнгәннәре оялырлар, кабат ярамаганны эшләмәскә тырышырлар.

Татарстан нефтьчеләренең тәҗрибәле, кайгыртучан генералы Ринат Галиев, командирларча ашыктырып, ирексезләп кенә, уңга-сулга шелтәләр сибеп кенә нефть төбәкләрен яңарту-яшәртү мөмкин түгеллеген бик яхшы аңлап алган. Максатлар зурдан, бурычлар авыр! Җөмһүриятебезнең нефть чыккан якларында ярты гасыр дәвамында актарып-бозып, пычратып бетергән җирләрне төзәтү, кешеләр файдаланып яшәрлек итү — бер максат булса, нефть чыгаруны тормыш-яшәешнең «кендеге» итеп, суыртылган фәлән миллион «кара алтын» башка хилафлыкларны каплар әле, дип ышанып йөрү шикелле, үлемгә тиң зарарлы гадәтләрне кешеләр аңыннан бәреп чыгару — икенче максат, җир асты хәзинәсендәге байлыкны суырту белән табигать мәнфәгатьләрен бергә кушып алып барырга өйрәнү — өченче зур максат. Кешеләр: «Табигатьне җиңдек!» — дип мактанмаска, ә: «Табигатьне үтерәбез...» — дип көенергә тиешләр. Чөнки аның кәсафәтен һәр вакытта да җиңүче үзе түләячәк. Авыл-шәһәрләрендә бер миллион халык яшәгән нефть якларындагы җирләрне савыктырырга юнәлтелгән бу изге максатлар, әгәр дә бу көрәшкә, нефтьчеләр белән берлектә, республиканың газет-журнал, радио-телевидение журналистлары, язучылар да дәррәү күтәрелсә, тагын да тизрәк, тагын да нәтиҗәлерәк тормышка ашырылыр иде. Каләм тотып яза белгән, фотоаппарат яки видеокамера белән төшерә белгән бер генә журналист та бу изге-игелекле эштән читтә калмаска тиеш, минемчә. Бар кыйтгаларга ишетелерлек итеп чаң сугарга кирәк безгә, каләмдәшләр!

Тирә-юнь мохитне: җирне-һаваны, чишмә-елгаларны, һәр яшел үләнне, һәр яшел агачны саклау бурычы шул кадәр катлаулы, шул кадәр зур һәм авыр чишелешле ки, моны тик халыкка тулырак-тәфсиллерәк итеп аңлатып, һәр кеше бу изге эшкә теләп кушылганда гына тормышка ашырырга була. Кеше, табигатьнең матурлыгын саклау белән генә чикләнмичә, аның табигый байлыкларын арттыру-ишәйтү гамәленә дә керешергә тиеш. Табигатьнең бүгенге хәл-халәтен, ул нинди генә хәвефле-җитди булса да, яшермичә-шомартмыйча кешеләргә ирештерү — гомуми һәлакәтне булдырмый калу юлында беренче адымдыр. Шуңа күрә дә, нефтьчеләрнең җәмәгать оешмалары белән бәйләнешләр бүлеге башлыгы Ришат Әбүбәкеров, көндәлек мәшәкатьләрдән теңкәсе корып беткән булуга карамастан, нефть төбәкләрендәге журналистлар чирүен даими җыеп әңгәмәләр кора, аларны экологик әһәмиятле эш урыннарына алып бара. Берәүләрнең кулында — микрофон, икенчеләрендә — видеокамера, өченчеләре блокнотларына нәрсәдер сырлый. Журналистлар төялгән автобус «дәваланган» чишмә янына килеп туктый, үзе тешне сындырырлык салкын, үзе гаҗәп тәмле чишмә суын эчеп кинәнә журналистлар. Аннары күп урынлы автобус хәйләкәр борылыш ясый да, кунакларга генераль директор һәм, кабинетта бикләнеп кенә утырмыйча, көннәрен-төннәрен «кара алтын» суырткан эш урыннарында үткәрүче аннан түбәнрәк дәрәҗәдәге командир-башлыкларның карта-схемаларында кызыл флагчыклар белән тамгаланган «авыру» чишмәләрнең суыннан авыз итәргә тәкъдим ясала. Аерма тик шунда гына: берәүләр үз эшен җиренә җиткереп намус белән үти, аларның скважиналары, резервуарлары, хастаханә палаталары шикелле, ак буяулары белән күзеңнең явын алып тора; икенчеләре исә эшенә салкын карый, шапшак, кая карама — нефть, мазут таплары...

Иң мөһиме — кешеләргә куелган бурычның әһәмиятле булуын аңлату, аларны бәллүр шикелле тиз ватылучан, тиз җәрәхәтләнүчән табигатьне саклау эшенә тарту. Табигатьне саклау мәсьәләләренең котылгысызлыгын аңлау нефть якларындагы һәр йортка үтеп керергә, нинди һөнәр иясе булуына карамастан, һәр кешенең шәхси эшенә әверелергә тиеш. Игелекле башлангыч учагына үз вакытында мактау һәм, кирәксә, тәнкыйть чыбык-чабыкларын даими өстәп торырга да кирәктер, шәт!

* * *

Чишмә-инешләр бер нефтьчеләр кайгысы гына түгел, җөмһүриятебезнең башка районнарында да алар шундый ук кайгыртуга, игътибарга мохтаҗ. Чиста-саф сулардан тыш, сау-таза яшел урманнар, төтен-газ белән пычратылмаган һава өчен дә үзебез борчылырга тиешбез. Ашамыйча кеше — биш атна, сусыз — биш көн, ә һавасыз биш минут кына яши ала. Шуңа күрә, кешелекнең, һәр кешенең иң беренче мәнфәгате шул өч төп мәсьәләгә кайтып кала: иң

әүвәл нинди һава суларга, аннары — нинди су эчәргә, иң соңыннан — нәрсә ашарга?

Мин үзем, икенче промысел хезмәтчәннәренең игелекле «яшел» башлангычы зур яңгыраш табар, нефть якларын яшел оазиска әверелдерик, дигән бу мәрәкәгать нефтьчеләрне генә түгел, һаванын сасы газлы булуына зарланып яшәүче авыл-шәһәрләр халкын да кузгатыр, табигатьне саклау җәмгыятьнең урындагы бүлекләре (ә бит бар шундый җәмгыять!), уянып, чаң кага башларлар, дип уйлаган идем. ЮНЕСКО карары белән һәр елның бер матур яз көнендә «Җир көне» үткәрелә, дөньяның барлык кыйтгаларында кешеләр уртак йортыбыз булган Җиребезне җыештыра-чистарта, Татарстанның авыл-шәһәрләрендә яшәүче меңнәрчә халык, чиләк-көрәкләр күтәреп, агач утыртырга чыга. Олысы-кечесе дәррәү кузгалса да, һәркемгә эш житәрлек, ялкау гына үзенә эш таба алмас!

Җөмһүриятебез җирләрендәге урманнарның хәле бик мөшкел. Без халыкка зарлану-шыңшулар белән генә һаваларның сафланмаячагын үтемле итеп аңлатып бирергә тиешбез, халыкны шелтәләргә-оялтырга да тиешбез. Бу — без журналистларның бурычы. Ни өчен без әле халык хезмәтчеләре — депутатларыбызны бераз төрткәләмибез, ни өчен алар Татарстанны экологик хәвефле зона дип игълан итмиләр? Урыннарда эш башкаручы җирле түрәләр хуҗалык итүдә күп еллар буе урманнарны саклау-үстерү эшенә бармак аша гына карап килделәр. Дәүләт хакимияте башында кем генә утырса да,— коммунистлармы, демократлармы,— барыбер, Софокл әйтмешли, эш-гамәлләр белән сүз идарә итә. Ниһаять, каләм ияләре шуны да аңларга тиеш: хакимлекнең дүртенче тармагы дип аталабыз икән — бу зур дан гына түгел, ә зур җаваплылык та. Җаваплылык исә безгә олуг бурычлар йөкли.

Әйе, хәлләребез бик хәвефле. Удмуртия, Башкортстан, Мари Эл җөмһүриятләрендә урманнар барлык җир мәйданнарының иллешәр процентын тәшкил итсә, Татарстанда ул — уналты процент кына. Безнең җирләрдә Урал-Идел буе нефть ятмаларының иң эре промыселлары, Түбән Кама нефть-химия комплексының дистәләрчә заводлары, КамАЗ гиганты (аңа әле тагын Алабуга автомобиль заводы да килеп өстәлде), Казандагы «Оргсинтез», Менделеевскидагы ике химия заводы, Европада иң эреләрдән булган Зәй ГРЭСы агрегатлары... Бу галәмәт зур гигантлар, индустрия китлары — монстрлар һавага углекислота газларын, башка төрле зарарлы матдәләрне ташкын-ташкын чыгарып торалар, шул әшәке, сасы һаваны сулап яшәргә мәҗбүрбез. Бик рәхәтме әллә? Әле ярый, Татарстан өстендә даими рәвештә циклоннар һәм антициклоннар өермәсе уйнап тора: алар йә башкорт урманнары ягыннан исәләр, йә мари ешлыклары-чытырманлыкларының саф һавасын алып киләләр дә, күкнең җиде катын бутапболгатып, без сулыйсы һаваны да чистарта төшәләр. Юкса, чынлап та, нәрсә сулар идек? Үпкәләребез нишләп бетәр иде?

АКШ вице-президенты Альберт Гор, Ак йорт администрациясенә хезмәткә килгәнче, экология мәсьәләләре белән шөгыльләнгән. Зәңгәр планетабызны нинди һәлакәт-катаклизмнар көткәнен сурәтләргә омтылып язган бер китабын ул «Җир — үлчәү тәлинкәсендә» дип атаган. Китап урысчага да тәрҗемә ителгән, Мәскәүдә басылып чыккан, теләгән кешеләр аны табып укый алалар. Альберт Гор үзенең китабында: «Бер американ һаваны елына 20 тонна углекислота белән пычрата»,— дип яза.

Әлбәттә, бер кеше шул кадәр углекислотаны сулышы белән генә чыгара алмый, моның өчен аның үпкәсе урынында күп тонналы, дизельле йөк машинасы моторы булырга тиеш. Бер кеше үпкәсенең еллык нормасы гадәттә бер тонна чикләрендә була. Америка вице-президенты көтү-көтү автомобильләр, электр станцияләре, завод-фабрикалар, сервис индустриясе, органик ягулык яндырып энергия кулланучыларның барысы бергә чыгарган углекислотаны җыеп саный. Галәмәт зур хуҗалыкның авыр көпчәген вак көпчәкләр-шөрепчекләр бары бер максат белән әйләндерә — америка милләтенең, димәк, һәр американның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү максаты белән. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Җир шарындагы халыкның нибары алты процентын гына тәшкил итүче американнар барлык энергетик запасларның өчтән берен исраф итәләр, үзләренең икътисад учагында утын, торф, күмер, нефть, мазут, уран белән бергә бихисап кислородны да яндырып юкка чыгара торалар. Американың барлык үсемлекләр дөньясы биргән кислородка караганда, алар аны бер ярым тапкыр артыграк файдаланалар. Шулай итеп, бу милләт башкалар җилкәсендә яшәүче, кешелек цивилизациясе тәнендәге паразит, әрәмтамак милләт! Мөгаен, башкача әйтеп тә булмыйдыр. Биредә исәп-хисап бик гади. Әгәр дә бу ил, дөньяның өчтән бер энергия чыганагын яндырып, һавага шул кадәр үк өлеш зарарлы калдыклар

чыгарып тора икән — димәк, ул шулай ук өчтән бер өлеш күләмдә пычратылган һаваны сафландыру фабрикалары да булдырырга тиеш. Фабрикалар дигәндә, әлбәттә, иң элек урманнар күздә тотыла. Ләкин Америка үз урманнарын бик нык кыра-кисә, кайчандыр урманнары 900 миллион гектар булган булса, илнең «яшел үпкәләре» хәзер өч мәртәбәдән артыкка кимегән һәм нибары 250 миллион гектар гына тәшкил итә. Җир шарындагы урманнарның уннан бер өлеше генә бу! Кешелек цивилизациясе тәненә ябышкан бу паразит милләт Галәмгә миллиардларча тонна углекислота һәм башка төрле зарарлы матдәләр ыргытып тора, ә үзе Амазониянең тропик урманнарыннан, Атлантик һәм Тын океан киңлекләреннән искән җилләр алып килгән кислородны сулап яши.

Кешелек дөньясы, аның эшче штаблары булган Берләшкән Милләтләр Оешмасы, ЮНЕСКО, «Яшелләр» конфедерациясе кебек оешмалар берләшеп, Америкага карата җитди чаралар күрсә, санкция-штрафлар салса да, начар булмас иде, минемчә. Теге яки бу милләтне оешканлыгы, үҗәт тырышлыгы, эшлекле-булдыклылыгы өчен, үз тормыш-көнкүрешен башкалардан яхшырак итеп кора алганы өчен шелтәләү, әхлакый яктан караганда, бик үк ярап бетмәстер. Дәгъва башка: ни өчен шул үҗәт тырышлыкларын янкилар зур чыгымнар сорый торган табигатьне саклау чараларына да юнәлтмиләр, ни өчен башкалар хисабына туй итәләр? Коточкыч хәл: планетабызның кислородын талау уйсыз-гамьсез, җиңел тормыш алып баручы аерым ил-халыкларның гына түгел, ә бөтен кешелекнең көндәлек гадәтенә әйләнеп бармыймы соң?!

Яман гадәттән дә йогышлысы юктыр, диләр. Американча яшәү шул кадәр кызыктыргыч-ымсындыргыч икән ки, байтак илләр, хәтта кыйтгалар, үзләренең кислород фабрикалары булган урманнарын кыра-бетерә барып, читтән бушка кергән һава хисабына яшәргә исәп тоталар. Бөтен планетада урманнарны уйсызнисез кисү, юк итү дәвам итә, һәр секунд саен җир йөзендә ярты гектар урман харап була. Һәр секунд саен! Кеше ике тапкыр керфек кагып алган арада бер гектар агач юкка чыксын әле! Кайчандыр чәчәк атып утырган Хәбәшстан (Эфиопия) җирләрендә кешелек дөньясы барлыкка килгән. Оҗмахка тиң ул җирләр хәзер нишләп беткән? Урманнары нибары ил мәйданының бер процентын гына тәшкил итә, калганнары кырып салынган, кая карама — кояш өткән җансыз чүлләр, корылыктан ачлыкка дучар ителгән хәлсез хәбәш халкы... Шушы фаҗигале мисал да бик җиткән югыйсә, әмма уйланучы-борчылучылар күренми. Һәр елны җир йөзенең 0,8 процент тропик урманнары киселә тора. Әгәр дә бу гамьсезлек шулай дәвам итсә, планетабызны кислород белән туендырып торучы яшел табигатьне кырып бетерсәләр, күп кенә илләр әнә шул Хәбәшстан чүлләре кебек чүлләрдә утырып калачаклар.

Америка вице-президенты Альберт Горның исәпләп чыгарган нәтиҗәләрен кабат тикшереп торуның кирәге юктыр. Безгә үзебезнең Татарстаныбызда яшәүче бер кешенең, аерым алганда сәнәгать эшчәнлеге, социаль инфраструктурасы Американыкына якынрак торган Кама-Чулман арьягында яшәүче кешенең елга уртача күпме кислород яндырып, күпме углекислый газ чыгарганын исәпләп табарга кирәк. Минем, язучы буларак, чама белән генә исәпләвемчә, нефть төбәкләрендә бу аяныч хәл бер дә Американыкыннан ким булмаска тиеш. Ә, бәлки, артып та китәдер әле.

Кама-Чулман арьягы — дөнья күләмендә бик эре нефть-газ чыгару төбәге, биредә җир астыннан өч миллиард тоннага якын «кара алтын» суыртып алынган. Мондый күрсәткеч тагын Көнбатыш Себер төбәгендә генә бар. Үзебезнең исәпхисап дәфтәренә органик ягулыкта эшләүче Зәй һәм Урыссу электр станцияләрен салыйк, аларның гомуми куәте ике миллион киловатт булыр. Шул ук мәйданда Түбән Кама нефтехимия комплексының ике дистәләп заводы көкне «җылытып» утыра, әле СССР таркалганчы ук бу комплекс илне 60 процент ясалма каучук белән тәэмин итә иде. Бөтендөнья автомобиль төзелешенең әйдәп баручысы булыр дип, ике конвейрдан елына 150 мең йөк машинасы чыгарырга тиешле КамАЗ автогигантын да китереп кушыйк. Озакламый Чаллы белән ярыша башлаячак Алабуга җиңел автомобильләр заводы да бар. Менделеевскидагы ике химия заводының берсе инкыйлабка кадәрле үк эшлекле-тырыш заводчы Ушков тарафыннан нигезләнгән булган, икенчесе — минераль ашламалар эшләп чыгаручысы — заман таләпләре тудырган «бала». Күрдегезме, күпмегә җыелды болар?! Бер төбәктә генә!

Социаль инфраструктураны да онытмыйк: ашханәләр, кибетләр, хастаханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары, клуб-театрлар, сөт һәм ит комбинатлары... Аларда эшкә яраклы шәһәр халкының кайда — өчтән бере, кайда биштән бере хезмәт итә. Ә һәр квартирдагы газ плитәләре, алар да кислородсыз янмый бит.

Нәрсә ул ут? Химия буенча мәктәп дәреслеген ачып карыйбыз: ут ул ягулыкның углероды белән һавадагы кислород кушылудан барлыкка килә, нәтиҗәдә кайнар ялкын хасыйл була һәм углекислый газ бүленеп чыга. Кислород никадәр күп тотылса, ялкын да шул кадәр кайнар була. Шуңа күрә дә, мартен мичләре, энергоагрегат топкалары, нефтьне җылытучы промысел җайланмалары горелкаларына, кайнарлыкны арттыру өчен, көчле компрессорлар белән саф һава кудырыла, әмма,— ни аяныч! — атмосферага углекислый газ чыгару да шул ук күләмдә арта.

Юк, болар белән генә бетмәде әле. Автомобиль, трактор, комбайн, самолет, пароход-теплоход, паровоз-тепловоз, ракеталар һ. б. һ. б. китергән зарарны да исәпкә алыйк. Җөмһүриятебез нефтебазалары кулланучыларга елына бер миллион тонна бензин һәм дизель ягулыгы озата. Моторда бер литр ягулык яндыру өчен унбиш литр һава исраф ителә, аның егерме проценты — саф кислород. Бу саннарны тапкырлап карасаң, автомобиль — татлы хыял һәм рәхәтлек түгел, ә зур зыян китерә торган бер албасты булып күз алдына килә.

Ниһаять, җөмһүриятебезне тоташ газлаштыру — сәнәгать предприятиеләрен, электрстанцияләрен, авыл һәм шәһәр йортларын күмер белән мазутка караганда күпкә арзан газ белән җылыту-эшләтү бу зәңгәр ягулыкны елына унбиш миллиард кубометр тотуга китерде. Галәмәт зур сан бу! Әмма газ кислородсыз янмый, димәк, шул кадәрле үк кислород та яна, шул кадәрле үк углекислый газ да бүленеп чыга.

Ярты гасыр эчендә Кама-Чулман арьягында яшәүчеләрнең саны бер миллионга арткан. Минем якынча исәпләүләремә караганда, тотыла торган энергиянең яктылык һәм җылылык калорияләрен, киловаттларын шул кешеләр санына бүлсәң, бер кешегә туры килә торган углекислотаның Америка нормасы бер дә алай «буй җитмәслек» түгел икән.

Кыскасы, шагыйрь Равил Фәйзуллин әйтмешли:

Татарстан — Төтенстан...
Дәүләт тимерчелеге!

*Ахыры бар.*



# ШИГЪРИЯТ



## Флера Гатина

### МОҢЛЫ ҖАН КОШЫ

#### I. Алтыюллыклар

* * *

Салдым салымны
Дулкын читенә,
Алмый салымны —
Дулкын чигенә...

Калды ак җилкән
Ярның читендә.

* * *

Тәрәзәм ачтым
Барча Җиһанга.
Күкнең ялкыны
Җанымда яна...

Тәрәзәм ачык —
Кил, ябып кара.

* * *

Күк җәясеме
Тартылып сынган.

Күктә яна эз,
Йолдызмы сызган,
Күкне ташлаган
Бер ятим сыман.

* * *

Манарам биек,
Чиксез баскычы.
Күкләр кулында
Аның ачкычы...

Читлек эчендә
Моңлы җан кошы.

* * *

Тәгәри дулкын,
Ул һаман юлда,
Бөдрә тал гынам
Чайкала суда.
Талпына шулай
Агарга ул да.

* * *

Ач хәятеңнең
Нурлы ишеген.
Бу газиз җаным —
Синең җисемең:
Син, Рухың өреп,
Сөйгән кешемен.

* * *

Күпме адәмнәр
Сукыр йөрәкле
Һәм ачык күзле.
Бир син адәмгә
Йә, Бөек Тәңрем,
Бу Җирдә күзге.

## II. Бишьюллыклар

* * *

Агыла комнар
Сусыз чүлләрдә,
Сибелә йолдыз
Көмеш күлләргә.
Агам чүлләргә.

* * *

Кыялар биек,
Кырыс ул, текә.

Упкын куера
Тирәндә — төптә,
Ялкыны өтә.

* * *

Дәрьялар — утта,
Күкләр — суларда.
Җаным талпына
Агымсуларга.
Язмы соңара?..

* * *

Куера болыт,
Куера таңда,
Боз-яңгырлары
Коела җанга.
Кем йөри анда?..

* * *

Дөрләми — сүнгән
Ярның учагы.
Авырдыр аңа
Томан кочагы —
Пыскыган чагы.

* * *

Очам биеккә,
Киң зәңгәрлеккә,
Каерылып читкә,
Җанны ыргытам
Караңгы чиккә.

## III. Дүртьюллыклар

Болыт куера,
Җирне күгеннән,
Күген җиреннән
Таңда аера.

* * *

Диңгезләр кичтем,
Дулкындай йөздем.
Ак җилкәннәрне
Тартып җил өзде.

* * *

Дәрья-су ярсый,
Үче бармы соң,
Әллә бу Җиһан
Аңа тармы соң?..

* * *

Күзге әче җил
Көлен очырды.
Ялкынлый хәзер
Күктә очкыны.

* * *

Ачамсың биген?—
Ябык читлегем.
Зәңгәр киңлектә
Очам берүзем.

* * *

Өзелмә, кылым,
Тынмасын җырым,
Моңлы былбылым,
Җанымда җылын.

* * *

Җиһан тын таңда,
Давыллый җанда:
Кайный өермә
Юл сорап анда.

* * *

Дәрья-дулкыннар
Сибелде җанга.
Зәңгәрлек инде
Чиксез Җиһанга.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

* * *

**1983** елда «Казан утлары» битләрендә татар прозасы турында җитди сөйләшү булып узган иде. Быел исә журнал шундый сөйләшүне яңадан башлап җибәрде. Игътибар үзәгендә — шул ук мәсьәлә: Бүгенге прозабыз нинди хәлдә? Кайсы ягы белән ул сөендерә, нәрсәсе көендерә? Аны үстерү өчен нәрсә эшләргә кирәк?

1983 елда узган сөйләшүдә күренекле шагыйрь һәм әдип Әхсән Баянов мондый теләк белдергән иде: «Гыйбрәт яки үрнәк булып халык телендә йөрерлек образлар күрәсем килә». («Казан утлары», № 4, 1983). Әдипнең бу теләген бүген дә хаклы рәвештә кабатларга мөмкин. Әйе, ул күрергә теләгән образлар бүгенге прозабызда да әлегә тудырылмаган. Сәбәпсез түгел.

Мәгълүм ки, зур тәэсир көченә ия булган әсәрләр иҗат итү өчен язучыдан кимендә ике нәрсә таләп ителә: талант һәм зур шәхес, олы шәхес, бөек шәхес булу. Талант — табигать бүләге, шәхес исә җәмгыятьтә формалаша. К. Маркс сүзләрен хәтерлик: «Адәм баласының эчтәлеге аерым бер кеше өчен генә хас булган абстракт нәрсә түгел. Чынбарлыкта ул эчтәлек иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең чагылышы булып тора». (К. Маркс. Тезисы о Фейербахе. Т. 3, ст. 3).

Димәк, шәхеснең зурлыгы, олылыгы, бөеклеге аның җәмгыятьтәге бәйләнешләрына, элемтәләренә, аралашуына бәйле. Шуңа күрә язучылар идарәсе талант ияләренең җәмгыять белән бәйләнешләрын оештыру, җанландыру буенча кирәк булган барлык чараларны күрергә тиеш. Бу — әсәрләребезнең идея-эстетик сыйфатын күтәрүгә хезмәт итүче ышанычлы юл. Тагын шунысы әһәмиятле: язучы хезмәте — үзенчәлекле хезмәт, физик көч, рухи киеренкелек сорый торган хезмәт, дөньяда иң катлаулы хезмәт. Язучыга бүген ирешелгән биеклек иртәгәсе өчен җитенкерәми. Яңа баскычка күтәрелергә кирәк. Ул көн саен үз вакытын иҗатка багышларга тиеш. Шунсыз талант тутыга, сафтан чыга, бетә. Ләкин мондый режимда иҗат итү өчен бер шарт бар: язучы үз хезмәте китергән гонорар хисабына яши алсын, гонорар тормыш ихтыяҗларын — ашау-эчү, кием-салым, гаилә, торак һ. б. өчен кирәкле чыгымнарны капларлык булсын. Башкача иҗат эшчәнлеген өзлексез алып барып булмый. Бу — закон. Тормыш законы. Бу турыда Ф. Энгельс әйткән сүз бар: «Маркс кешелек җәмгыяте тарихының үсеш законын ачты. Бу закон бик гади. Кешеләр сәясәт, фән, сәнгать, дин һ. б. белән шөгыльләнә алсын өчен иң элек алар ашау-эчү, кием-салым һәм торак урыны белән тәэмин ителгән булырга тиеш». (Ф. Энгельс. Похороны К. Маркса., т. 19).

Шушы хакыйкатьне истә тотып, татар язучыларының бүгенге хәленә күз салыйк: бүгенге авыр заманда алар гонорар хисабына яши аламы? Һич юк. Чөнки китап бастыру егылып китәрлек дәрәҗәдә авырлашты, аннан килгән акчага җан асрарлык түгел. Шуның өчен язучыларыбызга әсәр язарга багышлыйсы вакытны башка хезмәткә сарыф итәргә туры килә. Хәтта халык шагыйре исеменә лаек булган зур талант иясе, пенсия яшендәге Илдар Юзиев та җан асрарлык акча табыштыру өчен «Сабантуй» газете редакциясендә эшләргә мәҗбүр! Көн саен аңарга яшь көчләрдән килгән дистәләрчә кульязманы укырга кирәк.

Әгәр дә без татар әдәбиятының, шул җөмләдән прозабызның да, үсүен тәэмин итәргә телибез икән, талантларга зур шәхес булып формалашырга һәм беренче чиратта иҗат белән даими шөгыльләнергә шартлар тудырылырга тиеш. Мондый ярдәм — яңалык түгел. Ул борын-борыннан килә. Мәсәлән, Александриянең фән һәм мәдәният эшлеклеләре тулысынча дәүләт тәэминатында яшәп иҗат иткәннәр. Урта гасырдагы талант ияләре герцог сарайларында ашау-эчү, кием-салым кайгысын белми гел иҗат белән шөгыльләнгәннәр. Аннары Франция

җөмһүриятенең ярдәмен алып, үзенең үлемсез әсәрләрен иҗат иткән Виктор Гюго истә. Дәүләт хисабына 30 дан артык бүлмәле йорт тотып яшәгән бөек немец Гете истә. Ниһаять, мәшһүр П.Чайковский да бары тик гонорар хисабына гына яши алмаган. Ярдәм килеп торган. Кыскасы, ярдәм бер вакытта да кызганылмаган: кардинал Ришелье (XVII гасыр) заманында да, П. Чайковский (XX гасыр) заманында да. Чөнки талант — ул халык байлыгы, халык даны, шөһрәте, халык үлемсезлеге!

— Кемнәр халыкка шөһрәт һәм дан китерә?
— Талант ияләре: язучылар, рәссамнар, архитекторлар, галимнәр.
— Кемнәр халыкны үлемсез итә?
— Шулар!
— Кемнәр иҗтимагый аңда тирән үзгәрешләр тудыра?
— Шулар ук!

Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә язган шигырьләрен беренче мәртәбә немец теленә тәрҗемә иткән Франц Лешницер үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Иске бозык гадәт татарлар турында пычрак фикер тарата. Янәсе татарлар — җимерүчеләр, кан эчүчеләр, вәхшиләр. Татар шагыйре Муса Җәлилнең каһарманлык тулы тормышы, тиңсез иҗат батырлыгы әлеге шовинистик уйдырманың көлен күккә очырды». («Зоннтаг», № 34, 1964)...

Аңлашылса кирәк: бердәнбер шагыйрь күрсәткән гражданлык каһарманлыгы, нибары бер шагыйрьнең иҗат батырлыгы! Аның кешеләр аңына тәэсире нинди зур, нинди көчле! Шагыйрь берүзе гасырлар буе килгән «шовинистик уйдырманың көлен күккә очыра». Әдәбиятның шушы көчен истә тотып, Татарстан хөкүмәте үз язучыларының иҗат шартларын яхшыртуга кирәкле финанс чыгымнарын юлларга әмәлен табар, дип уйлыйм. Бүгенге шартларда шундый ярдәмнән башка әсәрләребезнең сыйфатын күтәрү мөмкин түгел.

**Шәрәф ӘХМӘДУЛЛА,**
филология фәннәре
кандидаты, доцент.

* * *

**П**роза турында сөйләшүдә катнашкан әдипләр — Г. Ахунов, Б. Камалов, Ф. Яруллин, Ә. Сафиуллин, Ф. Галимуллин, Р. Фәизов, Р. Фәтхерахманов, Р. Шәрәфиев һ. б. фикерләре белән тулысынча килешәм. Һәм: «Прозабызны үстерү өчен хәзер нәрсәләр эшләргә кирәк?» — дигән сорауга мин мондый җавап бирәм:

— Татарстан Язучылар берлегендә берничә атналык әдәби курслар оештырырга кирәк. Чөнки һәрьяктан житеш, өлгергән, киң колачлы, тирән сулышлы әдәби алмаш әзерләми торып, прозаны да үстереп, алга чыгарып булмый! Минем үземә исә, төрле сәбәпләр аркасында, университетта уку бәхете тәтемәде. Әмма ләкин миндә язасы килү теләге һәрвакытта көчле булды! Бу — тормыштагы уңайсыз хәлләрдән, четерекле вакыйгалардан килеп чыга иде шикелле. Урысның бөек әдибе М. Горький бер әсәрендә: «Мин дөньяга килешмәскә килдем», — дип, юкка гына әйтмәгән бит...

Шулай да, мин яшь чакта (совет чорында) әдәбиятка килү юлы бераз генә иде. Ә хәзер — юллар күп: «Алай язма, болай яз!» дип, башка сугып, мингерәтеп, йөдәтеп торучылар да юк! Мәгәр барыбер язучыга таләп элеккечә кала: яхшы итеп язарга кирәк! Бу таләп — бер генә заманда да үзгәрмәгән һәм үзгәрмәячәк тә!

Ә яхшы итеп язу өчен нишләргә, нәрсәләр белергә кирәк соң яшь иҗатчыларга? Минемчә, иң элек тарихны вә сәясәтне аңлый һәм аңлата белергә кирәк! Әйтик, Достоевский тарихны вә сәясәтне тиешенчә аңламаса һәм аларны тирәннән сөреп аңлата алмаса, «Җинаять һәм җәза», «Бертуган Карамазовлар» кебек даһи әсәрләр иҗат итеп калдыра алыр идеме? Юк, билгеле. Бу — безнең әдәбиятыбызда каһарманнарча иҗат иткән Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимовка да хас иде.

Икенчедән, әсәрнең уңыш казанында детальләр мөһим роль уйный. Әйтик, Пушкинның «Убийца» хикәясендә бер карт иптәшен үтереп өенә кайтып яткач,

бераздан башын калкытып, тәрәзәдән карый һәм елга аръягында ут күреп ала. Хатыныннан: «Кара әле, елга аръягында ни күрәсең?» — дип сорый. Хуҗабикә карый һәм: «Эңгер-меңгер төшеп килә»,— ди. Ир икенче мәртәбә карый, утның өйгә таба якынлашканын күрә, ыңгырашып җибәрә: әнә-әнә, ул инде тәрәзәдән керде, ди, аннары тынып кала. Хуҗабикә барып, кулын маңгаена куя, ир инде үлгән була... Бу күренешне шулай үтемле итеп бүтән бер ничек тә язып һәм тасвирлап булмый. Монда инде Пушкинның деталь таба белүенә һәм аны төгәл, уңышлы куллану осталыгына сокланырга гына кала.

Янә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романыннан бер мисал.

«Акбай ялгышмаган икән: тирән чокырның төбендәге үләннәр, киң яфраклы кыска агачлар арасыннан Фәхрине табып чыктылар»...

Шушы кыска гына җөмләдә күпме хәрәкәт, кешеләрнең кайгылы йөзләре, авыр кичерешләре чагылып китә. Гәрчә язучы аларны турыдан-туры әйтмәгән, тасвирламаган булса да! Менә шул инде ул — аз сүз белән, ягъни төгәл детальләр белән әллә ничаклы мәгънә төсмерләре бирә алу осталыгы, талант!

Әлбәттә, диалогларда да детальләр булырга тиеш. Аннан әдәби әсәрләр ота гына. Әйтик, М. Мәһдиевнең «Мәңгелек яз» романында ике хатын сөйләшә:

«— Беренче ирең эчте. Икенчесе саран ие. Ә менә өченчесе әйбәт ие ич?!

— Анысының... бүрек эләргә чөе җук ие!..»

Минем кыска гына бер хикәямдә ике ир-ат болай сөйләшә:

«— Син ник утырып чыктың соң?

— Шул инде... Бер чибәр туташның кәләпүшенә төкергән өчен!..»

Бүгенге тәнкыйтьчеләр, һәм гомумән, тәнкыйтьчеләр, һәр яңа әсәрнең уңышлы һәм йомшак якларын, күпшәк вә җыйнак детальләр сорап торган урыннарын, бәхәс-фәләннәргә урын калдырмаслык итеп, ачып бирә белергә тиешләр! Шунсыз, ягъни детальләрсез, әсәрдәге характерларның да, киеренке психологик моментларның да асылына төшенергә мөмкин түгел! Мисал өчен, Л. Толстойның «Сугыш һәм дөнья» эпопеясында мондый эпизод бар. Бородино сугышы кичендә урыс армиясе генераллары Филедәге крестьян йортына, маршал Кутузов янына, хәрби киңәшмәгә җыелалар. Һәрберсенең йөрәген: «Мәскәүне французларга калдырыргамы, юкмы?» — диган катгый сорау борчый. Әнә шундый хәлиткеч мизгелдә Толстой үз әсәренә урыс халкының көчен күрсәтә торган деталь кертеп җибәрә.

«...Твердое, красивое и доброе лицо Коновницына светилось нежною и хитрою улыбкой. Он встретил взгляд Малаши и глазами делал ей знаки, которые заставляли девочку улыбаться...»

Детальләр турындагы фикерләремне мин тагын классик дөнья әдәбиятыннан меңнәрчә мисаллар китереп дәлилли алам. Ләкин, кызганычка каршы, безнең бүгенге татар әдәбиятына килгәндә, детальләр байлыгы белән әллә ни мактанып булмый. Бу — минемчә, сәләтсезлектән, талантсызлыктан түгел, ә пошмаслыктан, ялкаулыктан, эзләргә, өйрәнергә теләмәүдән генә... Әйе, әйе, шулай, тик шулай гына аңлатып була бу хәлне! Чөнки безнең әсәрләребез күп очракта гади генә итеп сөйләп бирү стилендә язылган булып чыга. Мондый әсәрләрне укыганда, әлбәттә, колак ишетә, ләкин күз күрми. Ә күз күрмәгән хәбәр — икенчел, ягъни гайбәткә якын тора. Димәк, билгеле инде, гайбәтне күпчелек юньләп тыңламый да, аңа ышанып та бетми! Аннары мәктәпләр безне: күз беренчел, колак икенчел, дип өйрәтте ич. Бәс шулай булгач, безнең әсәрләребез тоташлый күрсәтеп, тасвирлап бирү стиленә корылырга тиеш. Хәтта эчке кичерешләрне, монологларны да матди дөньяга бәйле рәвештә, төп-төгәл детальләр белән «цементлап», күрсәтеп, тасвирлап язарга кирәк! Бары тик шулай эшләгәндә генә әсәрләр яратып укылыр, андагы образлар — һәммәсе дә хәтердә сакланыр, онытылмас! Болар — минем сүзләр генә түгел. Моның мисаллары безнең классик әдәбиятта да, дөнья әдәбиятында да — буа буарлык! Тик аларны яхшылап күрә һәм күрсәтә белергә генә кирәк!

Өченчедән, без инглиз, француз, алман, урыс, төрек әдәбиятларыннан үрнәк алып, аларча «ирекле» итеп язмакчы булып азапланабыз. Ләкин тирән ялгышабыз, җәмәгать! Чөнки без бүген дөньяның бөек халыклары арасында нинди урын биләп торганлыгыбызны төгәл белмибез! Багып карыйк әле: урыс, алман, инглиз, япон, төрек — кем дә, без — кем?! Без бит алар кебек бүтәннәрне изеп түгел, ә колониаль-кыргый шартларга дучар ителеп һәм үзебез изелеп, сытылып яшәгән милләт! Безгә хәзер белорус, украин, поляк, чех һәм Латин Америкасы халыкларының әдәбиятларын өлге итеп алырга кирәк! Чөнки бу илләрдә яшәүче төп халыкларның язмышы белән безнең милләтебез язмышы арасында уртак яклар күп!

Мәгәр кемнәрдер әйтер: безнең бит, кайчандыр ки, үз дәүләтебез булган, дияр. Ярый, хуш... Ә 1552 елдан соң?.. Ә хәзер?.. Кайда соң ул бөек дәүләт? Кайда соң ул мәшһүр татар халкы?..

Тукай әйткәндәй, тәмам мескен хәлгә төшерелеп, упкын читенә китереп терәлгән халык бөек инглиз, алман, француз, урыс, япон халкы белән тигез дәрәҗәдә була аламы инде?!

Безгә хәзер, телибезме-теләмибезме, мескенлегебезне — бизәмичә, каралтмыйча, ничек бар, шулай язарга һәм мескенлеккә төшүебезнең сәбәпләрен, тамырларын ачыклап бетерергә һәм дөнья җәмәгатьчелеге каршында, чынында кем булуыбызны, асыл йөзебезне күрсәтеп бирергә вакыт. Бары шул чакта гына без янә бөек булып, инглиз, алман, француз, урыс, япон, төрек халыклары биеклегенә күтәреләчәкбез! Димәк, өлешебезгә тигән тарихи олы бурычны үтәп чыгар өчен, безгә... язарга да язарга гына кала!

Моңа сөенергә генә дә бит, әмма редакциянең проза турында зур сөйләшү башлап җибәрүе — сагаерга мәҗбүр итә. Әллә... Юк, юк, ышанасы килми. Чөнки әдәбиятның саегуы, ваклана башлавы — узган гасыр азагында да нык сизелгән бит һәм олы урыс әдипләрен дә борчуга төшергән. Әнә, Л. Н. Толстой хәтта: «Литература была белый лист, теперь она вся исписана, для того, чтобы продолжить, нужно ее перевернуть»,— дип, бер мәкаләсендә язып та чыккан булган. Күпмедер вакыттан соң В. И. Ленин шул мәкалә белән танышкач, «Правда» газетасында мәкалә бастырган. Анда язылган: «Л. Н. Толстой почувствовал запах революции»,— дигән канатлы фикерләрне хәзер бездә кем генә белми икән! Әйе, хак, берничә революция булган, шул җирлектә совет әдәбияты планетага аваз салган!

Әмма... туксанынчы еллар башында, торгынлыктан чыгар юл таба алмыйча, бу кызыл дәүләт тә һәм аның кызыл әдәбияты да тәмам ишелде. Хәлбуки, бәхеткә, Татарстан җөмһүрияте бетмәде, киресенчә, ярыйсы ук кыю адымнар белән мөстәкыйльлеккә таба атлап китте. «Кызыл албастыдан» котылгач, татар әдәбиятына да үсәргә, киңәергә, дөнья әдәбияты мәйданына чыгарга зур мөмкинлекләр ачылды. Әлбәттә, бүген үк дөнья әдәбияты мәйданына иске багаж белән чыгып булмый. Ә яңа, чын, хак әдәбиятыбыз әле — юк! Күрәсең, безнең җөмһүриятебез XXI гасырга тарихи олы сикереш ясарга әзерләнгәндә, әдәбиятыбыз да йоклап ятмас, хәлиткеч мәгъмүр ыргылышка әзерләнә булыр дип ышанырга кирәк. Чөнки Кол Гали, Сәиф Сараи, Котби, Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Г. Кандалый, Акмулла, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Җәлил һәм башка бик күп титан шәхесләрне тудыра алган «тарихта эзле халык»ның олуг әдәбияты бит бу!..

Казанда 1977—78 елларда иҗат яшьләренең конференцияләре гөрләп узды. Ул конференцияләрдә мин дә катнаштым. Шул конференцияләрнең берсендә КПСС Өлкә Комитеты секретаре Ф. Ә. Табеев, чын зыялы кешеләргә хас булмаган рәвештә, шактый ук кызып китеп, тәкәбберләнеп, һаваланып, иҗат яшьләрен сүлпәнлектә гаепләп һәм алар алдына тау чаклы таләпләр куеп, чыгыш ясады. Аннары ул, залдан килгән язуларның кайберләренә генә уңай җавап биреп:

— Менә... Яшьләр миннән фатир, дача, машина сорый! Булыр! Тик иң элек сез миңа Толстойның «Сугыш һәм дөнья», «Анна Каренина» романнарына тиңләшердәй әсәрләр язып китерегез! — диде. Бу инде Ф. Ә. Табеевның: сезгә — иҗат яшьләренә — беркайчан да фатир, дача, машина тәтемәячәк, дигән сүзе иде, ахрысы.

Һәм шулчакта бер урыс егете басып, президиумда бик бирелеп нидер язып утырган Язучылар берлеге рәисенә мөрәҗәгать итте:

— А Вы сначала, Гариф Ахунзянович, научите нас писать романы! — диде.

Гариф абый шундук урыныннан торып, җавап кайтарды:

— Романы нельзя учить писать, романы можно только научиться писать! — диде.

Һәм... талантлы әдип бик дөрес әйтте!..

Мин бүген шул вакытларны искә төшерәм дә, уйлап куям: ә бит дөнья әдәбиятында Нобель бүләгенә ия булган 70—80 битле повестьлар да яшь!..

Бүген безнең президентыбыз Минтимер Шәрип улы һәм аның даирәсендәге мөхтәрәм әфәнделәр гомумән татар әдәбиятын ничек бәялиләр һәм аның киләчәктә үсү, киңәю юлларын ничегрәк күз алларына китерерләр икән?! Беләсе, бик беләсе иде...

**Мансур ШАҺИМӘРДӘН.**

# АЗАТЛЫК РУХЫ

## XVII ГАСЫРДА КӨНБАТЫШ СЕБЕРДӘ ҺӘМ ИДЕЛ-УРАЛДА МИЛЛИ-АЗАТЛЫК СУГЫШЛАРЫ

Мәскәү дәүләте XVI гасырда ук дөньяның иң агрессив дәүләтләреннән берсе иде. Ул башта үзенә урыс кенәзлекләрен, аннары Укадан Уралга кадәр зур мәйданнарда яшәүче угыр-фин халыкларын буйсындырды.

Урыс дәүләтенең Казанны җимерүе, аның халкын, шул исәптән, балаларны һәм хатын-кызларны кыруы дөнья тарихында иң канлы вакыйгаларның берсе. Бу вакыйганы тарихчы Михаил Худяков «урыс тарихының иң авыр сәхифәләреннән берсе» дип атады.

Казанны алган көннән урыс дәүләте тарихында колонияләр яулау чоры башлана. Ул 1556 елда Әстерхан ханлыгын басып ала һәм җимерә, халкын кылычтан үткәрә. Себер ханлыгы Мәскәү тарафыннан җимерелгән өченче дәүләт. Үз агрессиясен аклау өчен Мәскәү татарга каршы идеология, бу халыкны урысларның һәм башка халыкларның дошманы итеп күрсәтү идеологиясен барлыкка китерә. Бу эш православие чиркәве белән бергә алып барыла.

Казан ханлыгы халыклары үз дәүләтләре җимерелү, аны басып алу белән килешми һәм аларның үз дәүләтен торгызу өчен сугышлары XVI гасыр ахырына кадәр дәвам итә. Бу сугыш урыс, хәтта кайбер татар тарихчылары тарафыннан бозып аңлатыла, «фетнә», татар феодаллары оештырган сугыш яки феодалларга каршы сугыш дип атала. Татарларның һәм ханлыктагы башка халыкларның Казан дәүләтен торгызу өчен сугышы чын мәгънәсендә Бөек Ватан сугышы иде һәм ул Идел буе тарихының якты, героик сәхифәсе. Кызганыч, бу сугышлар әле һаман аз өйрәнелгән, аңа тиешле бәя бирелмәгән.

Себер татарлары һәм Көнбатыш Себернең башка халыклары — вогуллар, истәкләр, ненецлар, силкупләр, телеутләр дә дәүләтләрен — Себер ханлыгын Мәскәү тарафыннан яулап алу белән, урыс агрессиясе һәм үзләренең коллыкка төшүләре белән килешмиләр. Көнбатыш Себер халыкларының XVII гасырдагы милли-азатлык сугышлары да үткәннең әһәмиятле сәхифәсе булып тора. Әмма ул да әле тарихта гадел бәясен алмаган.

Себер татарларының илбасар урыс дәүләтенә каршы баш күтәрүләре XVII гасырның күп кенә документларында чагыла. Бу вакыйгалар Себер воеводалары һәм приказчикларының Себернең баш воеводасы булган Тубыл воеводасы һәм Мәскәү хөкүмәте белән язышкан эш кәгазьләрендә. Березов, Пелым һәм Мангазея истәкләре арасындагы сүз берләшүне ачу буенча 1663 елгы эзләнү-тикшерү язмаларында, воевода кәнсәсе һәм патша сарае арасындагы язышуда һәм башка документларда сакланган.

Идел-Урал халыкларының XVII гасырдагы милли-азатлык сугышлары Казан приказы документларында, Мәскәү хөкүмәте белән Мәскәүнең Казандагы, Уфадагы колониаль хакимиятенең үзара язышуларында тасвирлана[1].

Себер татарлары һәм Көнбатыш Себердәге башка халыкларның баш күтәрүләрен, азатлык өчен сугышларын иң әүвәл Г. Ф. Миллер һәм И. Э. Фишер яктырта. Әмма алар милли азатлык сугышларын «фетнә», «явызлык кылу», «әшәкелек» һәм «кыргыйлык» күренеше дип тамгалыйлар[2].

Көнбатыш Себер һәм Идел-Урал халыкларының XVII гасырдагы милли-азатлык сугышлары урыс тарихчылары Н. М. Ядринцев, П. А. Словцев, С. В. Бахрушин, В. И. Огородников, П. И. Буцинский, С. М. Соловьев, Н. А. Фирсов һәм башка тарихчылар хезмәтләрендә теркәлгән[3]. Совет чорында

К. А. Волкова, А. П. Уманский, И. Г. Акманов, Н. В. Устюгов һәм башка тарихчылар да бу проблеманы азмы-күпме яктырттылар. Ләкин совет чорындагы кайбер хезмәтләрдә Көнбатыш Себер һәм Идел-Урал халыкларының милли-азатлык сугышларын «башкорт восстаниеләре» дип ялгыш бәяләү сизелә[4].

Новгород дәүләтенең Печора һәм Урал буенча, аннан төньяк-көнбатыш Себергә агрессиясе XI гасырда башлана. Моны Мәскәү дәүләте дәвам итә. Комилар, төньяк удмуртлар, Печора һәм Урал буе истәкләре, Урал буе ненецлары һәм вогулларының җирләре тартып алына, үзләре буйсындырыла. 1499 елда урысларның кенәз Курбский, Ушатый һәм Гаврилов җитәкчелегендәге 4000 кешелек чирүе Урал тауларын үтеп, Себергә чыга, җирле халык белән сугышып, Себер йортының 41 шәһәрчеген ала, җирле морзаларны әсир итә[5].

Оешканнан бирле агрессив булган Мәскәү дәүләтенең һәм урыс православие чиркәвенең карашы XVI гасырда төрки-мөселман дәүләтләренә юнәлә һәм бу дәүләт чиркәү белән бергәләп төрки-мөселман дәүләтләрен басып алу, ислам динен юк итү өчен ныклап әзерләнә.

1552 елда Казан ханлыгын җимерүне Мәскәү дәүләте һәм урыс чиркәве башка төрки дәүләтләрне яулап алып, тагы да көньяккарак бару өчен юл ачу дип хисаплый. 1556 елда Әстерхан ханлыгын җимергәннән соң Мәскәү Себерне буйсындырырга карар кыла. Мәскәү түрәләре Себер аркылы Төркестанга барып чыгарга ниятли. Әмма бу юлда Себер татарларының монгол явыннан күп алда төзелгән дәүләте — Себер йорты тора.

Күршесен яулап алу өчен урыс дәүләте Казанның үз җирендә ныгытылган хәрби база — Зөя шәһәрен сала. Себер татар дәүләтен басып алу нияте белән Мәскәү тагын да куәтлерәк хәрби база — промышленник Строгановлар биләмәләрен төзергә булыша. Монда берничә кальга, хәрби гарнизоннар, сугыш кирәкяраклары һәм азык-төлек саклау урыннары кора.

Себер ханлыгын яулап алу өчен патша чирүе сугышчылары түгел, ә Мәскәүдән алып көнчыгыш илләргә кадәр яманаты таралган тәҗрибәле юлбасарларның бандасы җибәрелә. Шул юлбасар казакларның атаман Ермак җитәкчелегендәге басып алу явы 1581 елның сентябрендә Строгановлар биләмәләреннән оештырыла. Ермак белән килгән 540 баскынга Строгановлар үзләренең 300 сугышчысын кушып, көймәләр, утлы кораллар, азык биреп, татар дәүләтенә каршы сугышка җибәрә. Туплар һәм башка төрле утлы кораллар белән коралланган Ермак баскыннары Себер халкын исәпсез-хисапсыз үтереп, мал-мөлкәтен талап, шул ук елның 26 октябрендә Себер йорты башкаласы Искер («Кашлык», «Себер» дигән исемнәре дә мәгълүм) шәһәре янындагы Чуваш борыны дигән җирдә килеп туплана. Алдан әзерлек чаралары күрүгә карамастан, нигездә ук-җәя белән коралланган Күчем хан гаскәре җинелә һәм үзенең башкаласын калдырып китәргә мәҗбүр була. Ермак илбасарлары буш башкаланы «алалар». Ләкин әле бу Күчем ханның тулы җиңелүе түгел иде. Аны урыслар 1598 елда гына җиңә алдылар. Мәскәү дәүләтенә Күчемне тулы җиңәргә 17 ел вакыт кирәк булды. Сугыш нинди авыр булса да, Күчем урыс илбасарларына бирелми, сынмый, горур кала. Агрессив урыс дәүләтенә каршы көрәш байрагын тагын 70 ел буена аның уллары һәм оныклары күтәреп бара.

Басып алу сугышларында урыслар Себер татарларының 90 процентын үтерә. Себернең башка халыкларының да югалтулары шуннан ким булмый. Бу вәхшәт документлар белән раслана.

Күчемгә кадәр хакимлек иткән Себер ханы Ядкәр вакытында, 1555 елда урыс патшасы Мөһдиш Иван, Ядкәрнең Мәскәү каршында баш июеннән файдаланып, аны урыс дәүләтенә ясак түләргә мәҗбүр итә һәм ясакны күбрәк җыю максаты белән Себергә илче итеп җибәрелгән Иван Непейцынга халык санын алырга куша. Иван Непейцын Себер ханлыгында ясак түләргә тиешле, ягъни 18 яшьтән 50 яшькә кадәр сау-сәламәт ирләрнең саны 30700 кеше дип хәбәр китерә. Ә инде XVII гасыр башында кан коюлы басып алу сугышларыннан соң элекке Себер ханлыгы җирләрендә ясак түләргә тиешле ирләрнең саны 3000 кешедән артык булмый.

Яулап алганнан соң татарларның ыруг башлыклары, феодаллары йомышлы татарлар итеп беркетелә, ә гади халыкка ясак салына, аның күләме төрле урында төрлечә була, нигездә, бер ясаклыдан 5—7 кеш тиресе, аерым олыслардан 10 га кадәр кеш тиресе исәбеннән була. Ләкин ясакның бу күләменә күп санлы «истәлек бүләкләре» (поминкалар өстәлү, тиренең сыйфаты начар дигән сылтау белән арттырып түләтү һәм ясак җыюда оятсыз талау ысулы) куллану нәтиҗәсендә Себер халкы өчен бу ясак түләп бетерә алмаслык салымга әверелә.

Ясак елга бер тапкыр җыела һәм аны җыеп алу алдан яхшы әзерләнә, җирле халыкны куркыту, алдау һәм талауга корылган була.

Ясакны җыю аны түләүчеләрнең тору урыннарына бәйле рәвештә ике төрле итеп оештырыла. Шәһәрләргә якын җирләрдә яшәгән халыктан ясакны ыруг яки авыл башлыгы җыеп берничә ярдәмче белән шәһәргә алып килә. Ясак җыю көнендә шәһәрнең үзәк мәйданына казаклар кылычларын, утлы коралларын тагып, ике саф булып тезеләләр. Ясакны китерүче башлыклар үзләренең ярдәмчеләре белән шул кораллы казаклар сафы уртасыннан узганда шәһәр үзәгендәге кальгадан туп залплары гөрселди, казаклар пищальлардан атып ясак китерүчеләрнең котын алалар. Казаклар сафыннан үтеп чыккан ясакчыларны мәйданда зиннәтле кафтаннар кигән, коралларын таккан воевода һәм аның приказчиклары каршы ала. Воевода каршында кисмәк-кисмәк ачы бал һәм шәраб, алар янында кулларына агач чүмечләр тоткан урыслар. Алар ясак китерүчеләрне «сыйлый-лар» — эчү мәҗбүри. Алкогольгә күнекмәгән Себер кешесенә ачы бал яки шәраб тиз тәэсир итә.

Шул мыскыллауга-куркытылуга корылган тамашадан соң ясак җыю башлана. Аны воевода үзе башкара. Иң яхшы тиреләрне сайлап бер читкә алып куя — ул аларны үзенә «сатып ала». Аннары ул мехларны патшага, тәхет варисына, үзенә һәм приказчикка ясак түләүчедән «истәлек бүләге» итеп сайлап ала. Шулай сайланганнан соң начаррак тиреләр ясак түләү өчен кала. Аларны сыйфаты начар дип, тиешле саннан артыграк ала, 7—10 урынына 10—15 тире китә.

Шәһәрдән ерак урыннарда ясак авылларда җыела, ул да алдау, исертү, куркыту юлы белән башкарыла. Ясак җыеласы авылга приказчик белән бергә сәүдәгәрләр, промышленниклар һәм коралланган казаклар килә. Сәүдәгәрләр, промышленниклар вак-төяк бизәкле әйберләр, тимер-бакыр кисәкләре, балтапычак кебек әйберләр алып киләләр. Монда да кисмәк белән эчемлек тора. Приказчик һәм сәүдәгәрләр башта «сыйлау» үткәрәләр, халыкны исертәләр. Аннан соң шәһәрдәге тәртиптә ясак җыела. Ясак җыелып беткәч, тагын «сыйлау», аннан сәүдә оештырыла. Бер аршин буе тимер кисәгенә кеш тиресе, бер пычакка берничә тире, балтага тагын да күбрәк алына. Иртәгесен махмырдан җан бирергә торган халыкка тагын «сәүдә» оештырыла, исерткеч белән «баш төзәтү» башкарыла, ләкин бушка түгел — мехка алмашка. Ясак җыючылар баеп кайтып китә, бичара халык таланып кала[6].

Җирле урыс властьлары вакыт-вакыт ясак түләүчеләрнең санын алу үткәрәләр, ләкин аларның арасы озак еллар була. Халык үлгән авылдашлары, качкан, киткән кешеләр өчен дә ясак түли. Законда каралган ясак күләмен халык ике-өч тапкыр артык түләргә мәҗбүр ителә. Шулай оятсыз талау, алдаудан халыкның тормыш алып бару өчен мехы калмый. Бу турыда патша түрәләре белә, ләкин талау дәвам итә. Ә ул чорда Себердә мех акча вазифасын башкара.

Себердә ясак түләү белән бәйле коточкыч хәл — аманәт тәртибе яши. Һәр ыруг яки авыл киләсе елда ясак түләүнең вәгъдәсе — гарантиясе итеп үзләренең бер яки берничә кешесен бирергә тиеш була. Бу кешеләр — аманәтләр ел буе төрмәдә тотыла яки авыр эш башкара һәм киләсе ел ясак җыйганда гына икенче кешегә алмаштырыла. Аманәтләрнең күбесе соңыннан элекке күргән газаплардан үлә.

Себердә Мәскәүнең төп максаты кыйммәтле мех җыю була, аның бөтен сәясәте халыктан мулрак мех каерып алуга юнәлдерелә. Русия өч гасырга якын бөтен тышкы сәүдәсен Себер мехы белән алып бара. Шул ук вакытта ясак җыюда воевода һәм аларның якын чиновниклары байый.

Ясак җыю вакытында байлык туплауга гына риза булмыйча, воеводалар, приказчиклар Себер татарларының һәм башка халыкларның терлеген, йорт әйберләре, мех киемнәрен алып китәләр, балык тоту, ауга йөрү, кондыз аулау урыннарын, җирләрен тартып алалар.

Кайвакыт табигый бәла-казалар була — җәнлек кача яки күпләп үлә, ау, җигү этләре, боланнар йогышлы авырулардан үлеп, ау бармый. Җирле урыс хакимияте бу хәлне белсә дә, ясак таләп итә. Түләнмәгән ясак бурыч булып өстәлеп җыелып бара, ул недоимка дип атала. Недоимкалар зур саннарга җитә, аларны түләп халык бөлеп бетә.

Ясактан башка Себер халкына төрле мәҗбүри йөкләмәләр салына. Иң авыры — Верхотурье, Тура, Пелым, Том, Енисей татарларына салына торган патша җирен сөрү, иген үстереп, җыеп бирү була. Халыкның, бөтен гаиләсе белән эшләп, үзенә көн итәргә вакыты да калмый, ачка үлүчеләр күп була.

Шулай ук Себер халкы ям хезмәтенә, юл-почта эшенә ат биреп тору, юл карауга тартыла. Алардан урыс башлыкларының, сәүдәгәрләрнең, промышлен-

никларның һәм башка түрәләрнең йөкләрен хак түләмичә ташыталар. Хатын-кызларны нарта-чаналарга төягән йөкне өстерәргә, елга буйлап аркан белән көймәләрне, баркаларны тартырга — бурлак хезмәтен башкарырга мәҗбүр итәләр. Воеводалар ирләрне Себер халыкларына каршы сугышларга, басып алуларга, азатлык сугышларын бастырырга алып китәләр.

Себернең яулап алынган халыклары хокуксыз була, аларның хокук һәм бурычларын воеводалар билгели.

Воеводалар яллы кешеләр тоталар, алар авылларга барып җирле халыктан әсирләр ала. Әсир алу белән воеводалар гына түгел, башка килмешәк урыслар да шөгыльләнә. Әсирләрне кол итәләр, саталар. Әгәр әсирне чукындырса, ул әсир урысның милке — колы булып кала. Воеводалар, казаклар хәрби яуларда яки баш күтәрүләрне бастырганда әсирләр алып, үзләренең колы итәләр, чукындырып үзләрендә калдыралар.

XVI гасыр ахырында ул Көнбатыш Себердә татарларның, вогулларның, истәкләрнең күп кенә кызлары, хатыннары һәм үсмер егетләре урысларда кол булып торганнар, аларны Себердән Русия базарларына китереп сата торган булганнар. Өстен катлау урыс йортларында сатып алынган татар, истәк һәм башка коллар аз булмаган.

Себер халкының җир биләмәләре, ауга йөрү, балык тоту урыннарының кагылгысызлыгы турында патша фәрманы булуга карамастан, воеводалар, чиркәү, монастырьлар, килмешәк урыслар халыкны кысрыклыйлар, җирләрен, ауга йөрү, балык тоту биләмәләрен тартып алалар, татар һәм башка халыкларның җирләренә кереп утыралар. Татар авыллары арасында урыс авыллары һәм кайбер татар авылларында урыслар яши торган урамнар барлыкка килә.

Себергә күбесенчә ир урыслар килә, алар татарларның һәм башка халыкларның хатыннарын, кызларын, хәтта улларын тартып алалар, аларны хатын урынына тоталар, өйләнәләр яки азгын женси тормыш өчен файдаланалар. Җирле халыкның күп егетләре өйләнә алмый, гаиләсез, гомерлек буйдак булып кала. Бу хәл XVII гасыр ясак кенәгәләрендә ачык күренә. Өйләнгән кешегә урыс колониаль хакимияте ясакны арттыра, бу турыда ясак кенәгәсендә язма була. XVII гасыр ясак кенәгәләренә 18 яшькә җитеп исәпкә кертелгән татар, вогул, истәк, ненец, селкүп егетләренең күбесе гомер буе буйдак булып калган. Бу хәл җирле халыкның үрчүенә комачаулаган, санын киметкән.

XVI йөздән Себер сөргенгә җибәрү урыны булып китә, анда күп җинаятьчеләр җибәрелә. Себергә килгәч тә аларның күбесе җирле халыкны җәберләү белән шөгыльләнә.

Урысларның үтеп китүе юл өстендәге халыклар өчен олы бәла-казага әйләнә. Халык өйләрен бикләп, хатыннарын, кызларын яшерә, терлеген урманга куа һәм урыс урдасының үтеп китүен коты чыгып көтә. Аларны тизрәк үткәреп җибәрү өчен ашаталар, эчертәләр, хәтта акчалата, азыклата бүләкләр бирәләр. Кайвакыт Себергә урыс йомышчыларының шундый урдалары килә — алар бөтен өязне талап чыгалар.

XVII гасырда Себердә бер урында тупланмаган, эшләмичә талауны төп кәсеп иткән урыс кешеләренең саны нык арта. Алардан котылу өчен җирле халык тынычрак урыннарга кача, яшәгән урыннарын, җирләрен ташлап урманнарга китә. Урыс тарихчысы С. Ядринцев: «XVII гасырда Себер һәр эстәүче Руська әверелгән иде»,— дип яза. Шулай итеп татарларны һәм башка халыкларны урысның казаклары да, воеводалары да, шәһәр урыслары һәм качкын караклары да талый. Халыкның тормышы чыдап булмаслык авырая.

«XVII гасырда Себергә килеп яшәүче урыслар әхлаксыз бер җәмгыятьне тәшкил итә»,— дип яза И. Э. Фишер үзенең «Себер тарихы» дигән хезмәтендә. Анда казаклар һәм башка урыс килмешәкләре арасында күп хатынлылык киң тарала. Казаклар, сәүдәгәрләр, башка урыслар да берничә, кайбер очракларда дүртәр-бишәр хатын белән яшиләр. Урыс ирләре ерак юлга чыгар алдыннан хатыннарын башка ирләргә закладка биреп, акча алалар. Кайткач хатынын кире түләп алырга акча булмыйча яки алып калган ирнең кире бирергә теләге булмаса, хатын шул кешедә кала. Бу хәл Себердә шул кадәр киң тарала, моннан балалар бик җәфа күрә. Себер бистәләре, авыллары исерек урыслар белән тулы була, аларның күбесе хатыннары өстенә үз кызлары белән женси тормышта яши. Бу гадәти күренешкә әверелә. Башта бу хәлне күрмәмешкә салынган православие чиркәве бу гадәткә каршы көрәшеп карый, ләкин нәтиҗәсе аз була, чөнки чиркәү әһелләре эчүчелектә, женси азгынлыкта алардан калышмыйлар.

XVII гасырда Көнбатыш Себердә берничә шөгыле булмаган урыс бистәләре, авыллары барлыкка килә, аларның халкы тирә-як Себер авылларына барып

әсир алып, мал-мөлкәт талап кайта да, бер-ике ай эчә, азгынлык кыла, аннан яңадан яуга китә. Мәскәү хакимияте дә, урыннардагы колониаль хакимият тә бу хәлләрне яхшы белә, чөнки патша кәнсәсенә, воеводаларга җирле халыктан чиксез күп хатлар, жалобалар, гаризалар, халыктан вәкилләр килә. Ләкин хәл үзгәрми, чөнки колониаль хакимият кешеләре дә шулай яши, ә үзәк хакимияткә Себердән мех килеп торса — шул җитә.

Урыслар Себергә аңарчы анда булмаган чәчәк һәм башка бик күп йогышлы авырулар алып килә. Себер халкы, бу авырулардан иммунитеты булмау сәбәпле, күпләп кырыла. Хәтта тулы авылларның үлеп бетү очраклары була. Ә медицина ярдәме урысларның үзләренә дә булмый диярлек. Соңыннан чәчәккә каршы прививка оештырыла, ләкин бу эш ерак авылларга барып җитми. Азгын тормыш урыслар арасында сифилис һәм башка венерик авырулар таралуга китерә. Бу чирләр җирле халыкларга да йоктырыла, чөнки аларның хатын-кызларын көчләү урысларның шөгыленә әверелә. Венерик авырулар Себер халкы өчен бәла-казага әверелә.

XVII гасырда Себер татарларын һәм башка халыкларны көчләп чукындыру көчәя. Себердә чукындыру Казан җирендә чукындыру үрнәгендә башкарыла, әмма Себердә ул башкачарак үткәрелә. Чукынган татарларны казан җирендәге кебек тоташ авыл итеп калдырмыйлар, аларны урыс авылларына таратып утырталар, кызларын урыска кияүгә бирәләр, улларын урыс «кызларына» өйләндерәләр. Кайбер очракларда, татарлар җир биләмәләрен ташлап китүгә нык каршы торганда, чукындырылган Себер татар авылларына урысларны шыплап тутыралар. Теге очракта да, бу очракта да чукындырылган татарлар тиз урыслаша. Татарларны чукындыру көчле булса да, Себер татарларының Казан җирендәге кебек керәшеннәре юк, чөнки алар урыслашып беткән.

Себернең урыслар тарафыннан колонизацияләнүе, ясак түләү, төрле мәҗбүри хезмәтләр башкару, талану, җирләре тартып алыну, урысларның әхлаксыз исерек тормышы, җирле халык исәбенә көн итәргә тырышуы элекке ханлык җирләрендә яшәүчеләрне һәм аларның көрешләрен иң соңгы чиккә җиткереп хәерчеләндерә, аларның гасырлар буе килгән йолаларга, гадәтләргә нигезләнгән, табигать шартларына яраклашкан тормыш тәртибен үзара җимерә. Күп гаиләләр җирсез, биләмәсез, торак урынсыз кала, халык тынычрак, ерак җирләргә күчү сәбәпле шактый зур миграция башлана. Яңа җирләргә күчкән халык башкача тормыш итәргә тиеш була.

Моның өстенә Көнбатыш Себердә борынгыдан килгән халыкара сәүдә-алмашу системасы җимерелә. Себер ханлыгы башкаласы Искер һәм башка шәһәр урыннарын казып тикшерү нәтиҗәсендә археологлар ханлыкта халыкара сәүдәнең нык үскән булуын раслыйлар. Анда Кытай, Төркестан, Идел буе товарлары сатылган, ул халыкара тәртипләр нигезендә алып барылган. Урыс колонизациясе башлангач, сәүдә алар кулына күчә. Халыкны оятсызларча алдау, җирле халык товарына, бигрәк тә мехка бик аз бәя биреп, үзенекен коточкыч кыйммәт бәяләү гадәти хәлгә әйләнә.

Бу хәлләр бөтен Көнбатыш Себер халыкларында көчле ризасызлык һәм кискен протест китереп чыгара. Ясак түләүдән, төрле йөкләмәләрне башкарудан баш тарту, воевода яки башка урыс түрәләре белән очрашудан качу, Мәскәүгә төрле шикаять яки гариза белән кешеләр төркеме яки бөтен халык исеменнән аерым вәкил яки вәкиллек җибәрү, үзен-үзе үтерү, аерата гомуми төстә үзләрен яндыру (истәкләр арасында), баш күтәрүләр һәм азатлык сугышлары башлана.

Себер халыклары XVII гасыр буенча үзләренең чыдап булмаслык хәлләрен үзгәртү яки авыр урыс баскынлыгын бөтенләйгә алып ташлау өчен көрәшәләр. XVII—XVIII гасырларда Тубыл, Тара, Саз татарлары еш кына үзара сүз берләшеп, округ, өяз исеменнән патшага гаризалар юллыйлар. XVII гасырда азатлыкларын коралны көрәш, баш күтәрүләр юлы белән кайтарырга тырышалар. Баш күтәрү өчен иң кулай вакыт итеп Русия XVII гасырның беренче чирегендә кичергән «Бөек чуалыш» елларын сайлыйлар. «Русиядә әле патша югында Себерне Русиядән азат итү» һәм «Күчем хан заманындагыча» мөстәкыйль дәүләт төзү омтылышы Себернең барлык халыкларының уенда, гамәлендә була.

Әле 1607 елда ук Пелым вогуллары Березов шәһәрен туздырырга ниятлиләр һәм Березов истәкләре белән сүз берләшәләр, ләкин бу килешү хәбәре урысларга да барып җитә. Чөнки Себер халыкларында бик үзенчәлекле бер гадәт була: дошманга каршы нинди дә булса сугыш башлаганчы алар авылдан авылга «явыз рухларның» сурәтләре ясалган «сугыш угын» күтәреп йөртәләр. Сугышта кат-

нашырга риза булган авыл, кабилә яки халыклар бу ук алдында баш ияргә тиеш була.

1609 елда татарлар, истәкләр, вогуллар зур баш күтәрүгә әзерләнә. Алар Код кенәгинәсе Аннан Игичева житәкчелегендә бергәләп Тубыл шәһәренә барырга килешәләр. Восстаниега хәзерлек барышында Анна зур эшчәнлек күрсәтә. Әмма истәкләргә җибәрелгән «сугыш угы» урыс казаклары кулына эләгә һәм баш күтәрүгә хәзерлек ачыла[7].

1606—1607 елларда истәкләр күршеләре белән килешеп, Березов шәһәрен җимерергә кузгалалар. 1608 елда Нарым һәм Кет кальгаларында баш күтәрүләр була. 1616 елда Сургут истәкләре 30 урыс казагын үтерәләр. Баш күтәрүнең сәбәбе — колониаль хакимиятнең халыкны талавы һәм изүе. Бараба татарлары Тара шәһәрен яндырырга ниятлиләр, ләкин аннан күчеп китәләр.

1614 елда теленгүтләр көтмәгәндә Томск шәһәренә һөҗүм итәләр, урысларны үтерәләр, көтүлектән атларын алып китәләр, сөйләшү өчен килгән урыс илчеләренең берсен үтерәләр, икенчесен кире җибәрәләр.

Көнбатыш Себердә азатлык өчен көрәшүчеләрнең Идел-Урал халыклары белән элемтәләре турында тарихи чыганаклар сакланмаган диярлек. Ләкин бу төбәк халыкларының да Көнбатыш Себердә азатлык сугышлары барган заманда (1605—1617) колонизаторларга каршы күтәрелүе мәгълүм.

1605 елда башкортлар һәм алар белән янәшә яшәгән татарлар урыс баскынчыларына каршы көрәшкә чыга, ул 1606 елда да дәвам итә. Элекке Казан ханлыгы җирләрендә һәм аның тирә-ягында яшәгән татар, чуваш, мари, удмурт, мордва ясаклылары Идел буеның урыслар яшәгән өязләрендә 1606 елда башланган, тарихта Болотников восстаниесе дип аталган баш күтәрүдә катнашалар. Мәскәү хөкүмәте аларны 1607 елда урыс өязләрендә бастыра, әмма Казан ханлыгы җирләрендә бу сугыш 1611 елга кадәр дәвам итә.

Элекке Казан ханлыгының Тау ягында 1615 елда татар игенчеләре Җангали житәкчелегендә урыс изүенә каршы күтәреләләр, хәрәкәткә чуваш, мари, удмурт крестьяннары да кушыла. Азатлык көрәше Сарапулдан Алатырьга кадәр мәйданны иңләп, көньякта Сембергә һәм Нугай урдасына кадәр тарала.

1628—1631 елларда элекке Себер ханлыгы территориясенең зур өлеше урыс баскынчылыгына каршы гомум баш күтәрүләр белән тетрәнә. Бараба, Тара, Том татарлары, Том керәшеннәренә Күчем хан оныклары һәм калмыклар ярдәм итә. Бу баш күтәрү вакытында күп урыслар үтерелә, ә Себердәге шәһәрләр тулысынча баш күтәрүчеләр кулына төшү хәвефе астында кала.

1628—1631 еллардагы милли-азатлык сугышы Мәскәү хакимияте белән православие чиркәвенең Себер татарларын һәм башка җирле халыкларны икътисади һәм рухи изүнең тагын да көчәюе нәтиҗәсе иде. Алар урыс илбасарларын куып җибәреп, Себер татар дәүләтен торгызуга юнәлдерелгән була.

Баш күтәрү бастырылып, күп кешеләр җәзага тартылуга карамастан, халыкның илбасарларга каршылыгы кимеми. Урыс дәүләтенең XVII гасырның 50—60 елларындагы финанс-икътисади кризисы Себернең басып алынган халыкларының тормышын тагын да авырайта.

Бу елларда шулай ук Идел һәм Урал буе халыкларының тормышы түзә алмаслык дәрәҗәдә авырая. Аларны ясакның һәм башка колониаль йөкләмәләрнең туктамый үсә баруы, үзәк һәм җирле колониаль хакимиятнең башбаштаклыгы, чиркәүнең мыскыл итүе, җир биләмәләренең өзлексез кими баруы җәберли.

Иделдән алып Обь елгасына кадәр арада яшәгән төрки һәм угыр-фин халыклары түзеп булмаслык коллыкта газаплана. Бу шартларда Көнбатыш Себер халыклары үзләренең өметләрен Күчем оныкларына юнәлтәләр, татарлар гына түгел, башка җирле халыклар да аларны Себер тәхетенең төп варислары дип саныйлар һәм шулар янына киләләр. Күчем оныклары үзләре дә Русиягә каршы көрәшләрен туктатмый.

XVII гасырның 30 елларындагы азатлык сугышларында Аблайкәрим белән бергәттән Күчем оныгы Дәүләтгәрәй дә зур каһарманлык күрсәтә. Ул ныклы ихтыяр көченә, зур сәяси сәләткә һәм оештыру осталыгына ия булып, үзенең дошманы — илбасар Русиягә каршы хәлиткеч һөҗүм ясарга җыена һәм мона зур хәзерлек башлый.

Тарихи чыганаклар шулай ук бу чорда Күчемнең башка торыннарыннан Ишем улы Абугай һәм мәшһүр Аблайкәрим улы Көчекнең Себер халыкларының азатлык өчен көрәшендә зур эшчәнлеген күрсәтә.

Көнбатыш Себердә урыс хакимиятен бәреп төшерү, Себер татарларының һәм башка халыкларның дәүләтен торгызу максатыннан чыгып, Дәүләтгәрәй вогуллар, истәкләр, ненецлар һәм селкүпләр белән элемтәгә кереп, урыс хакимлеген бәреп төшерү турында сүз берләшә, башкортлар, Казан татарлары, марилар, удмуртлар белән бергәләп көрәшү турында сөйләшүләр алып бара. Ул үзенең игътибарын көнбатышка — берничә ел Русия белән сугыш алып баручы Кырым ханлыгына һәм Польшага юнәлтә. Кырым ханы белән килешү төзи. Соңгысы Русиягә каршы азатлык сугышына 20 меңлек гаскәр җибәрергә вәгъдә бирә.

Баш күтәрүне 1602 елның маенда Кама аръягында яшәүче татарлар башлый. Май ахырында аларга шул тирәдәге башкортлар, мордвалар, чувашлар, марилар килеп кушыла. Алар «Руська каршы безнең патша күтәрелде» дигән чакыру белән Сылва елгасы буендагы урыс авылларын туздыралар, Көнгер шәһәрен яндыралар, аның урынына яңа кала төзи башлыйлар. Баш күтәрүчеләр яхшы коралланган була, аларның хәтта аңарчы немецларда гына була торган эче тутырылган («чинный») туплары булганлыгы да мәгълүм.

Хәрәкәт бик тиз башкорт җирләренә тарала, башкортлар гына түгел, анда күчеп утырган урыс булмаган башка халыклар да сугышка чыга. Алдан сөйләшү буенча, Күчем хан оныклары җитәкчелегендә Себер татарлары һәм Көнбатыш Себернең башка халыклары колонизаторларга каршы күтәрелә. Себер ханлыгын торгызу өчен зур сугыш хәрәкәтләре башлана.

Уралда баш күтәрүчеләр Исәт елгасы буена утырган Катай кальгасын чолгап алалар. Сугышка башкортларның яңа отрядлары һәм калмыклар кушыла. Аларның берләшкән 2 меңгә якын кешелек гаскәре Долмат монастырен чолгап ала. Баш күтәрүчеләр 1662 елның сентябрендә Белосуд һәм Усть-Эрбет бистәләрен ала.

Шулай итеп, 1662 елда Каманың урта агымы буйлары, бөтен башкорт җирләре диярлек һәм элекке Себер ханлыгының күп өлеше милли-азатлык сугышы белән чолгап алына.

Казандагы, Пермьдәге, Уфадагы колониаль администрация хәрби көчләр белән сугышны Кама ярларыннан чыгармаска бик тырышалар, ләкин максатларына ирешә алмыйлар. Казан өязендә милли-азатлык сугышы җәелә.

Тиздән сугыш хәрәкәтләре Идел буеның башка халыклары арасында да кызып китә. 1663—1664 елларда милли-азатлык сугышы дәвам итә.

Көнбатыш Себердә милли-азатлык сугышы Себер татарлары яшәгән олысларда башланып, аңа истәкләр, вогуллар һәм башка халыклар кушыла.

1662 елның августында баш күтәрүчеләрнең нигездә Себер татарларыннан торган Күчем оныгы Бочай-Солтан җитәкчелегендәге 4000 кешелек гаскәре сугыш белән Төмәнгә, Туринскига, Верхотурьега һәм Пелымга барырга җыена. Алар Верхотурье вогуллары белән берләшеп, Мурзинский бистәсен туздыралар, тирә-яктагы бөтен урыс авылларын яндыралар, терлеген, мөлкәтен алып китәләр, халкын әсир итәләр. Сугыш хәрәкәтләре Исәт, Чусовая, Пышма елгалары бассейнын чолгап ала. Бу тирәләрдә дә баш күтәрү зур сугышка әверелә, анда татарлар, башкортлар, истәкләр һәм ул җирләргә күчеп утырган мари, чуаш, мордвалар катнаша.

1663 елның язында Соликамск өязендә актив сугыш хәрәкәтләре башлана. Июнь аенда баш күтәрүчеләр Реж елгасы буендагы урыс авылларын алалар. Аромашево бистәсенә һөҗүм итәләр, июльдә вогуллар, татарлар һәм башкортлар Невьян волостен туздыралар, Невьян монастырен алалар.

1664 елда сугыш яңадан башлана, яңадан урыс бистәләре, авыллары яндырыла. Шул елның язында Күчем оныклары татарлар, вогуллар һәм истәкләр белән бергә Төмән өязенә килә, Пышма елгасына барып, андагы урыс авылларын туздыра[9].

Иделдә Обь елгасына кадәр булган мәйданда яшәгән төрки, угыр-фин халыкларының Мәскәү басып алуына һәм изүенә каршы бердәм күтәрелеп чыгуы Русиянең үзәк һәм җирле хакимиятләрен куркуга сала. Бу кадәр мәйданда, үзләре басып алган халыкларга каршы торырга көчләре җитмичә, каушап калалар. Әлбәттә, кораллануның сыйфаты, саны һәм хәрби осталык, оешканлык буенча өстенлек урыс дәүләте кулында була. Әмма Идел-Урал буйларының һәм Көнбатыш Себернең икътисади һәм рухи изүнең соңгы чигенә җиткерелгән халыклары дин, тел, ыруг, кабилә чикләрен исәпләмичә, үз халыклары, үз ил-җирләре өчен аяусыз сугышлар, урыс хакимиятеннән азат булу максаты аларны зур

корбаннар бирүдән дә куркытмый, Себер һәм Казан татарлары, вогуллар, истәкләр, селкуплар, теленгүтләр, ненецлар, башкортлар, марилар, чувашлар, удмуртлар һәм мордвалар үз җирләрен басып алып анда урысларны китереп утырткан, тормышларын һәм ирекләрен бозган, рухларын изгән Мәскәү дәүләтенең һәм православие чиркәвенең нинди куркыныч дошман икәнен аңлап сугышалар.

Көтмәгән хәлдә урыс хакимиятенең Идел-Урал буйларында һәм Көнбатыш Себердә азатлык сугышларында катнашучыларга каршы торырлык куәте булмый.

Бу хәл урысларны иң әшәке рәхимсезлекләргә этәрә. Аерым урыс чирүләренең баш күтәрүчеләргә каршы ярсулы һөҗүме башлана. Басып алган җирләрен, Себердәге, Идел-Уралдагы хакимлеген саклап калу өчен Мәскәү дәүләте бөтен көчен куя. Ләкин җәза гаскәрләре баш күтәргән халыкны сындыра алмый. 1664 елның җәендә Көнбатыш Себердә, Башкорт җирләрендә, Кама буенда Минзәлә һәм Казан өязләрендә милли-азатлык сугышы тагын кабына.

1663 елның җәендә Күчем оныгы Көчек урыс колониаль хакимияте белән сөйләшүләр алып барырга тиеш була. Ләкин Көчек килми. Мәскәүгә сатылган кайбер башкорт феодалларының башкортлар арасында төрле ызгыштарткалашулар оештыруыннан файдаланып, урыс хакимияте азатлык сугышы алып баручы башкортларның көчләрен сындыра. 1664 елның октябрендә башкорт җирләрендә сугыш хәрәкәтләре тына бара, 1665 ел башында туктый. Бу исә җәза гаскәрләрен Минзәлә, Казан өяләренә күпләп җибәрергә мөмкинлек бирә[10].

Идел-Урал һәм Көнбатыш Себер халыкларының Русия хакимлегенә каршы 1662—1664 еллардагы милли-азатлык сугышларына кагылышлы байтак документлар — воеводаларның язышу кәгазьләре, донесениеләр, сугышта катнашучылардан сорау алу беркетмәләре архивларда тупланган. Ләкин шулай да бу чыганаклар милли-азатлык сугышының күп якларын ачып бетерми. Сугышның ахырын ачыклаучы документлар җитми. Минзәлә, Казан өязләрендә милли-азатлык сугышы көчле барса да, күп нәрсә кәгазьгә теркәлмәгән, кайбер вакыйгалар күрсәтелмәгән. Мәсәлән, Көнбатыш Себердә баш күтәрүчеләр Төмән һәм Тубыл шәһәрен алганмы? Дәүләтгәрәй үзенең сугышчылары белән ул шәһәрләргә килгәнме? Кырым ханы вәгъдә иткән 20 меңлек гаскәрен җибәргәнме? Бу турыда тарихи чыганаклар дәшми.

Җиңелүгә карамастан, 1662—1664 еллардагы милли-азатлык сугышы уңай нәтиҗәләрен бирә. Халык азатлык өчен көрәшергә сәләтле икәнен, үзендә көч һәм гайрәт барлыгын күрсәтә. Дәүләте җимерелгән, җирләре тартып алынып, кол ителеп, икътисади һәм рухи изүгә дучар ителгән халыкларның бердәм күтәрелүе килешеп хәрәкәт итүе, бердәм конкрет таләпләр куюы урыс хөкүмәтен нык куркуга сала. Басып алынган халыкларның Мәскәү хакимиятеннән бөтенләй азат булу, үз дәүләтләрен торгызу максаты патша хөкүмәтен зур ташламалар ясарга мәҗбүр итә. Көнбатыш Себер, Идел-Урал халыкларының җир, җәнлек аулау, балык тоту биләмәләрен тартып алу кими. Башкортларның һәм Себер халыкларының монастырьлар, воеводалар һәм башка килмешәк урыслар тарафыннан басып алынган кайбер биләмәләре кире кайтарыла. Иделдән алып Обька кадәр мәйданнарда көчләп чукындыру зәгыйфьләнә. Салымнарны, төрле йөкләмәләрне арттыру туктатыла.

Колониаль изүне йомшарту буенча биргән вәгъдәләрен Мәскәү идарәчеләре тиз оныта билгеле. XVII гасырның 70 елларында яулап алынган халыкларны икътисади кысу яңадан көчәя, 80 елларда көчләп чукындыруны тизләтүгә омтылыш арта.

Башка антиколониаль һәм милли-азатлык сугышлары кебек, 1662—1664 еллардагы кузгалышның да күп кенә йомшак яклары абайлана: кораллану начар була, оешканлык, сугыш хәрәкәтләрен әйдәп алып баручы җитәкчеләр, гаскәр башлыклары җитешми, урыс дәүләтенә сатылган, аңа хезмәт итәргә яраклашкан аерым феодаллар үз халкына хыянәт итә, кайвакытта сугышта катнашучыларның җирле мәнфәгатьләре өстен чыга һ. б.

Идел-Уралда һәм Көнбатыш Себердә XVII гасырда барган милли-азатлык сугышлары анда катнашкан халыклар тарихының якты һәм героик сәхифәсе булып тора. Халыклар төрмәсе булган Русия империясендә һәм аннан аз аерылып торган совет империясе заманында халыкларның урыс илбасарлыгына һәм колониаль изүенә каршы алып барылган милли-азатлык сугышлары тарихы оныттырылды, яшерелде. Мәскәүнең Казан, Әстерхан, Себер ханлыкларын җимерүе, аларның һәм башка бик күп халыклар җирләрен басып алуын урыс тарихчыларының күбесе һәм аларга ияреп яки уздырып та милли тарихчыларыбыз «прогрессив күренеш», «зур тарихи әһәмиятле вакыйга» дип бәяләп, халыкның аңын томаларга омтылдылар.

Милли-азатлык, мөстәкыйльлек өчен көрәш көчәйгән безнең көннәрдә бу тарихны өйрәнү Евразиянең соңгы империясе богауларын җимереп, милләтләрнең үз тормышларын, киләчәкләрен үзләре билгеләүдә зур әһәмияткә ия.

**Габделбәр ФӘЙЗРАХМАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ:

1. Акты исторические (АИ). том IV, Спб, 1841, 300 б.; Дополнения к актам историческим (ДАИ). т. IV, Спб., 1853. 282, 301, 302 битләр.

2. Миллер Г. Ф. История Сибири. т. II. М.-Л., Фишер И. Э. Сибирская история. Спб, 1774.

3. Ядринцев Н. М. Сибирь как колония в географическом, этнографическом и историческом отношении. Спб., 1892; Словцов П. А. Историческое обозрение Сибири, кн. I. Спб., 1886; Бахрушин С. В. Очерки по истории колонизации Сибири в XVI—XVII вв. // Научные труды. М. 1956, т. III, ч. I; Огородников В. И. Из истории инородческих волнений в Сибири. Заговоры и восстание западно-сибирских инородцев в 1658—1663 гг. Чита, 1922; Соловьев М. С. Сочинения. История России с древнейших времен. кн. III, М., 1991; Фирсов Н. А. Инородческое население прежнего Казанского царства в новой России до 1762 г. и колонизация Закамских земель в это время. Казань, 1869.

4. Волкова К. А. Восстание татар Тарского уезда 1628—1631 гг. // Экономика, управление и культура Сибири XVI—XVII вв. Новосибирск, 1965; Уманский А. П. Телеуты и сибирские татары в XVII в. (очерки внешнеполитических отношений). // Уч. записки Барнаульского педагогического института. Барнаул, 1972. Устюгов Н. В. Башкирское восстание в 1662—1664 гг. // Исторические записки, т. 24; Акманов И. Г. Башкирия в составе Российского государства в XVII — первой половине XVIII в. Свердловск, 1991.

5. Огородников В. И. Очерк истории Сибири до начала XIX столетия, ч. II, вып. I Завоевание русскими Сибири. Владивосток, 1924, 14 бит.

6. Бахрушин С. В. Ясак в Сибири в XVII в. // «Сибирские огни», 1927, № 3; Шунков В. И. Ясачные люди Западной Сибири XVII в. «Советская Азия», 1930, № 3, 4.

7. Тышкы эшләр министрлыгы архивы, Сибирский приказ, 2 китап, 131 бит.

8. Россия дәүләт хәрби тарихы архивы. ф. 20, тасвирлама 1/47, 61 эш; Россия дәүләт борынгы актлар архивы, ф. 248, 1236 китап, 52 бит.

9. Пермская летопись, вып. 3, Пермь, 1881. 770 бит.

10. Рычков П. И. История Оренбургская. Оренбург, 1896, 16 бит.

Шәрәф Әхмәдулла

# ҮТКӘННӘРДӘН ГЫЙБРӘТ АЛ!

## М. КАРАТЕЕВНЫҢ «РУСЬ ҺӘМ УРДА» КИТАБЫН УКЫГАЧ ТУГАН УЙЛАР

Мәгълүм ки, Чыңгыз хан үзенең озакламый гүр иясе булачагын истә тотып, алдан ук теге дөньяга күчү хәстәрен күрә башлый. Барыннан да элек, ул үз карамагындагы очы-кырые күренмәс биләмәләрне дүрт улына бүлеп бирә. Иң зур өлеш өлкән улы Жучига тия. Хөрмәтле ата кушуы буенча Жучи Енисейдән Дунайга кадәр сузылган, ә көньякта көнбатыш Төркестанны, Хәрәземне, Кавказ һәм Кырымны эченә алган җирләрнең хуҗасына әйләнә. Бу кадәрле байлык аның гаскәр башлыгы буларак күп санлы бәйгеләрдә күрсәткән батырлыгына бәя бирү булып тора. Чөнки ул заманда, хәзерге кебек, орденнар бирү юк, яугир хезмәтенә бердәнбер бәя — җир, мал-мөлкәт.

Жучига карата күрсәтелгән зур игътибар бер дә арттырып җибәрү түгел. Дөрестән дә, ул — бәйгеләрдә зур казанышларга ирешкән гаскәр башлыгы. Чыңгыз хан җитәкчелегендә гамәлгә кертелгән «Өермә» тактикасын иң уңышлы, иң оста тормышка ашыручыларның берсе. Ул җитәкләгән атлы гаскәр нәкъ менә өермә сыман тизлек, куәт белән дошман өстенә ябырылган һәм аны пыран-заран китергән. Беренче һөҗүм тулы җиңү бирмәгән очракта, гаскәр тиз генә чигенгән, аннары көчләрне ашыгыч рәвештә яңадан туплап, өермәдәй зил-зилә куптарып, бар тавышка кычкыра-кычкыра кабат дошман өстенә ташланган. Өстәвенә Жучи үз заманы кысаларыннан калкып торган гуманист. Ул — җиңелгән дошманга карата мәрхәмәтлелек күрсәткән кеше, кирәкмәгән, акылсыз җимерү, вату, яндыруга каршы чыгучы, гаделлекне яклаучы, кыю, туры сүзле җитәкче. Ул кырыс холыклы әтисенең күзенә карап, аның кимчелекләрен әйтүдән дә тартынып тормаган. Ләкин аңарга озак яшәргә туры килми. 1226 елда ул үзенең туган энесе Чыгытай әләкләренә ышанган Чыңгыз хан тарафыннан үтертелә. Моннан соң аның карамагындагы биләмәләр Жучиның өлкән улы Ичан-Урда кул астына күчә. Ләкин монысы Урта Азиягә караган җирләрне, Урал таулары буйлап сузылган далаларны гына үзендә калдырып, калган биләмәләрне кече энесе Батуга тапшыра. Ул моны Батуның хәрби талантын, нык куллы оештыручы, акыллы дәүләт эшлеклесе булуын истә тотып эшли.

Хәрби походларны тәмамлап, 1243 елда Бату Алтын Урда дәүләтенә нигез сала. Бер халыкның да өлешенә кермичә, буш яткан көньяк кыпчак даласында дәүләтнең мәркәзе — Сарай-Бату күтәрелә башлый.

Бату — күпкырлы шәхес, үзе төзегән империянең беренче бөек ханы. Аның турында төрле ил вәкилләренең язмалары бар. Әрмән галиме Киракос Гондзакеци «Монголлар тарихы» исемле китабында болай яза: «Бату ханга даими рәвештә патшалар, кенәзләр, сәүдәгәрләр, нахакка рәнҗетелүчеләр, ватанын, мал-мөлкәтен югалтучылар килә иде. Ул аларның гозерләре белән чын игътибар күрсәтеп таныша, хаклы булсалар, аларга кенәзлекләрен, биләмәләрен кайтарып алырга булыша иде. Шулай ук ярлыклар, файдалы таныклыклар биргәндә дә Бату юмартлык күрсәтте һәм беркем дә аның ихтыярына каршы килмәде». (М. Каратеев. «Русь и Орда», М., 1992 г., т. 2, ст. 51).

Әфганлы Әл-Журжани: «Бату бик гадел кеше иде. Ул хакимлек иткән елларда аңа бәйле ислам илләренә аның үзе тарафыннан да, кешеләреннән дә, гаскәрләреннән дә бәла-каза килмәде. Безнең сәүдәгәрләр һәм башка һөнәр ияләре

һәрвакыт иминлектә, хәвеф-хәтәрсез, аңардан файда күреп яшәделәр». (А.—Джурджани. «Табак-и-Насири, 1259, в к-ге Каратеева т. 2, ст. 52).

Михаил Каратеев: «Әлбәттә, Бату хан яхшы кеше үрнәге түгел. Ләкин төрле кабиләле зур империяне идарә итүдә ул үзен акыл иясе, зирәк кеше, оештыру остасы итеп таныта. Кирәк чакта Бату кырыс һәм шәфкатьсез була, күп вакыт исә ул — тәмле телле, нәзакәтле һәм юмарт. Аның өчен барлык диннәр тигез хокуклы, шулай да үзе православие динен якынрак күрә. Бәлки шуңадыр, улы Сартак православие диненә күчә, әти буларак Бату моңа каршы булмый». («Русь и Орда» китабы). Ниһаять фарсы тарихчысы Галәветдин Жувәйни: «Бату — акыллы, гадел хан иде. Ул бигрәк тә шәһәр төзүгә, сәүдә эшләренә зур игътибар бирде. Аның мәркәзенә төрле яктан товар агылды, Бату аларны кире какмады, кабул итте, юмарт кул белән бәясен түләде. Эшкә килүчеләр булсын, сәүдәгәрләр булсын, Батудан зыян күрмәде, киресенчә һәркемгә файда тиде». («Русь и Орда», т. 2, бит 51).

Әйтергә кирәк, Бату хан үзен бигрәк тә гаскәр башлыгы буларак таныта, дан казана. Аның хәрби концепциясе шундый: сугышта җиңеп чыгу, аныңча, сугышчыны сугышчы итеп тәрбияләүдән башлана. Максат шул: син, сугышчы, сугыш осталыгын камил үзләштер, физик яктан таза, көчле бул, оста ата бел, нык тәртип сакла, бирелгән әмерне берсүзсез үтә, һәр очракта башкалар белән бер җан, бер тән булып эш ит! Бату җитәкчелегендәге сугышчылар әнә шундый сыйфатларга ия булалар. Гомумән, ул сугыш хәрәкәтләрен оештыруда зирәк акыл, нигезле тәвәккәллек, ышанычлы кыюлык, оригинал чишелешләр күрсәтеп эш итә һәм бик хәтәр бәйгеләрдә дә җиңүгә ирешә. Аны замандашлары «Җиһангир» дип атап йөртәләр. Бу исем, дөньяны үзенә буйсындыручы мәгънәсендә, Бату ханның титулына әйләнә.

Хәрби походлар тәмамлангач Бату хан үзе төзегән биниһая зур империянең мәркәз шәһәрен — Сарай-Батуны төзекләү, зурайту эшенә алына. Бу шәһәр үзенең тәүге чорында хәзерге Әстерханнан җитмеш чакрым төньяктарак урнашкан була. Бату хан аны берничә ел эчендә сәүдә һәм һөнәрчелек үзәгенә әйләндерә.

1256 елда Бату хан үлә. Тәхеткә Батуның өлкән улы Сартак утыра. Йомшак күңелле бу хан әтисенең либерал карашларына ияреп, үзен тагын да либералрак итеп күрсәтә башлый. Александр Невский белән дуслаша, аның ахирәт дустына әйләнә, хатыны белән бер булып, православие диненә күчә.

Мондый гамәлләр Ислам кануннары нигезендә яшәүче Бәркәнең ачуын чыгара, аңарда нәфрәт тудыра һәм ниһаять Сартакның язмышы хәл ителә. Ул күп эшләр башкара алмый, аны Бәркә агу эчерттереп үтертә. Моннан соң хан итеп Сартак улы Улагчы игълан ителә. Бу вакытта Улагчы балалыктан да чыкмаган булганга, хан вазифаларын малайның дәү әнисе Бату ханның өлкән хатыны Баракчы гамәлгә ашыра. Ләкин озак түгел. Тиздән Улагчыны да Бәркә «теге дөньяга» олактыра.

Ниһаять, Бәркә 1259 елда үзе тәхеткә утыра. Абыйсы Батуны либераллыкта гаепләп, аңа каршы ачу саклап, көнләшеп яшәгән Бәркә, бөек хан исемен алгач, империянең үзәге итеп Иделнең сул ягында яңа шәһәр төзергә керешә. Бу үзәк Сарай-Бәркә исемен ала.

Бәркә хан — катлаулы шәхес. Аңарга ике капма-каршы сыйфат хас: бер яктан ул — явыз, усал кеше. Бату улы Сартакны, Сартак малае Улагчыны үтертү — моңа беренче дәлил. Ул үзенең абыйсы Бату ханга ачу итеп, аның беренче хатыны Баракчыны, мәчеләр белән бер капчыкка тыгып, суга батырып үтертә. Бу — аның явызлыгына икенче дәлил. Шул ук вакытта Бәркә — коручы, иҗатчы, яңаны тудыручы, талантлы оештыручы, җитәкче. Өстәл кебек тип-тигез кыпчак даласында бөтен дөнья халыкларын сокландырырлык Сарай-Бәркә шәһәренең калкып чыгуы — аның әнә шул соңгы сыйфатларына бәйле. Ул яңа шәһәрне кору, матурлау эшенә бөтен көчен, сәләтен, тырышлыгын, оештыру осталыгын сала, калган гомерен тулысынча шуңа багышлый. Барыннан да элек, ул көнүзәк эшләрнең берсе итеп, яңа шәһәрне язгы Идел сулары басып китүдән саклау чараларын гамәлгә ашырта. Моның өчен шәһәрне балчыктан өелгән киң, биек дамба белән әйләндереп алдырта. Аннары йортлар, кәрвансарайлар, мәчетләр, мәдрәсәләр, хан сарайлары, хан төрбәләре салу киң колач белән җәелеп китә. Бу эшкә Алтын Урдага бәйле бар илләр, төбәкләр үзләреннән өлеш кертәләр. Төньяктан төзелешкә бер дигән сыйфатлы агач-саллар килә, Уралдан зәңгәр гранит, башка төзү-бизәү кирәк-яраклары төялгән кәрваннар юл ала, Кырым — Мәрмәр, Иран затлы паласлар, нәфис савыт-саба юллый.

Төзелештәге корылмаларның архитектура ягыннан камиллеген тәэмин итү иң әһәмиятле мәсьәлә итеп карала. Шәһәр корылмалары матурлык кануннары буенча төзелсен! — хакимиятнең төп омтылышы шундый була. Әлбәттә мондый максатка ирешү өчен югары осталыкка ия төзүчеләр, һөнәрчеләр кирәк. Андый көчләр дә шәһәрдә житәрлек дәрәжәдә туплана. Аларны җыю хәрби походлар дәвам иткәндә үк башланып китә. Әсиргә төшүчеләр арасыннан беренче чиратта кору осталары сайлап алына. Шуларның иң сәләтлеләре — рәссамнар, архитекторлар, скульпторлар һәм башка бик күп һөнәр ияләре кон-төн шәһәр төзиләр, бизиләр, матурлыйлар.

Ләкин Бәркә хан үзе ниятләгән эшләрне тулысынча башкарып чыга алмый. Вакыты житми. Ул 1266 елда вафат була.

Мәгәр Бәркә хан башлаган кору эшләре тукталып калмый, аны башка ханнар, бигрәк тә Үзбәк хан зур уңыш белән дәвам иттерә. Нәтиҗәдә аның хакимлеге чорында Сарай-Бәркә чын мәгънәсендә матурлык һәм мәгърифәт, камиллек һәм яңарыш, сәүдә һәм һөнәрчелек үзәгенә әйләнә.

Үзбәк — Алтын Урданың тугызынчы бөек ханы. Аның турында тарихчылар бик уңай фикер әйтәләр.

Әл-Бирзали (XIV гасыр): «Үзбәк хан — Ислам диненә тирән инанган булуы, үзенең чибәрлеге, көяз-ыспай гәүдәсе һәм бигрәк тә акылы белән кешеләрне үзенә әсир итә иде». («Русь и Орда», т. 1, бит 175).

«Батыйдан соң Үзбәк — Алтын Урда ханнары арасында иң күренеклесе, иң талантлысы, дисәк дөреслеккә хилафлык булмас, мөгаен. Ул хакимлек иткән елларда Алтын Урда иң зур үсешкә ирешә, көчен-куәтен, байлыгын арттыра. Үзбәк — каты куллы, ләкин акыллы монарх. Ул үзенең күп кабиләле империясендә үрнәк тәртип урнаштыра, гражданнарның кануннар нигезендә дустанә яшәвенә ирешә. Сәүдә эшләрен җанландыру, тормыш уңайлыкларын арттыру, шәһәрләр төзү, аларны бизәү, матурлауга ул даими кайгыртучанлык күрсәтә. Бигрәк тә Сарай-Бәркәне камилләштерүгә зур игътибар бирелә. Шул ук вакытта аның чит илләр белән эшлекле, тыныч мөнәсәбәтләр урнаштыру буенча эшчәнлеге дә югары бәягә лаек. Нәтиҗәдә Алтын Урданың дөнья күләм абруе үсә, дәрәҗәсе күтәрелә. Византия белән дуслык, якынлык ныгый, Мисыр хәлифе, заманның башка бик күп монархлары Алтын Урданы үз итәләр. Каһирәдәге мәйданнарның берсенә Үзбәк хан исеме бирелә. Кытай императоры Тогон-Тэмур Үзбәккә үз кызын ярәшә, Азия, Аурупа Үзбәк фаикерләрен, Үзбәк гамәлләрен исәпкә алып эш итәргә тырыша», ди Михаил Каратеев. («Русь и Орда», т. 1, бит 178).

Үзбәкне үз халкы да якын күрә. Аның турында халыкта сүз йөри: Үзбәк — гадел хан. Үтенечең чын икән, аның яныннан ризасызлык күрсәтеп, аңа ачу тотып китмисең. Әгәр инде ялган, уйдырма эш белән йөрсәң,— үзеңә үпкәлә. Сиңа рәхим, шәфкать булмас.

Югарыда Үзбәк ханның шәһәр төзелешенә зур игътибар бирүе билгеләп үтелгән иде. Әйе, ул Бәркәдән калган мирасны баетырга, арттырырга, камилләштерергә акчаны да, вакытны да кызганмый. Аның тырышлыгы белән төзелештәге корылмалар яңа төс, яңа бизәлеш алалар, биналарны бизәкләүдә мозаика, майолика кулланышка керә. Төзүче архитекторлар, рәссамнар, һөнәрчеләр кулланган бизәкләү чараларының сыйфатына белгечләр югары бәя бирәләр. Мәсәлән урыс галиме Г. А. Федоров-Давыдов үзенең «Искусство кочевников и Золотой Орды» (М., 1976) исемле китабында болай яза: «Алтын Урдада архитектураның «майолик мозаикасы» дип аталган ныклы стиле барлыкка килә. Ачык зәңгәр, фирүзә һәм башка шундый матур төсләрдән торган бизәкләр, гарәп язуының ап-ак хәрефләре, сары һәм кызыл чәчәкләр... Менә шушындый мозаика төрле төсләрдәге керамик тактачыклардан хасил була. Аеруча кызыл төс өстенлек итә. Эпиграфик орноментлар белән бергә караганда мондый мозаика үсемлекләрдән һәм башка үрелмәләрдән хасил булган матур күренеш тәшкил итә... Алтын Урда мозаикаларының декоратив яктан сыйфатлары гаять югары була. (122 бит).

Әлбәттә, мондый бай төсләргә ия булган мозаика тыштан зәңгәр гранит белән тышланган хан сарайларын, кызыл, сары төсләргә манчылган хан төрбәләрен, күп санлы җәмәгать биналарын тагын да матурлаткан, гүзәл иткән.

Үзәктән читтәрәк урнашкан һөнәрче бистәләрендә дә матурлык турында кайгырту булган. Бирегә һәр һөнәр төренең үз бистәсе була. Әйтик гранит-мәрмәр эшкәртүчеләрнең, тимерчеләрнең һ. б. һәр бистәгә һөнәрченең, хәзергечә әйтсәк, милләтенә карап архитектура стиле сайланган. Гарәпләр — гарәпнекен, урыслар — урысныкын. Шушы төрлелек аша матурлыкка ирешелгән. Чөнки төсләр, формалар төрлелеге — ул матурлыкның аерылгысыз компоненты.

Бистәләрнең тагын бер үзенчәлеге була: аларның һәркайсында базар эшләгән. Өстәвенә барлык сәүдәне бергә туплаган үзәк базар да шаулы, шанлы тормыш белән яшәгән.

Әйтергә кирәк, сәүдә буенча Сарай-Бәркә үзенең унайлы географик хәле аркасында Азия белән Аурупаның үзәк базары булып танылa. Монда товарлар төрле илләрдән килә: Һиндстаннан — тәм-том, Иgranнан — затлы паласлар, Себердән — мех, Фландриядән — постау, Венециядән — йорт кирәк-яраклары, Дәмәшекътән — корал, Алтын Урданың үзеннән — атлар, дөяләр, кымыз, киез, тула, керамика...

Сарай-Бәркәдә һәр илнең үз кәрвансарае була, базарында — бихисап товар. Җаның ни тели, шуны сайлап ал! Һәм алалар да. Чөнки тормыштан зарланырлык түгел, һөнәрчеләр хан казнасыннан яхшы хезмәт хакы ала, сугышчыларның үз әүкате җитәрлек. Иң ярлы дигәненең дә кимендә ике аты, төрле мал-мөлкәте бар. Ат исә сугышчы өчен иң кадерле хәйван. Ул үз хуҗасын ашата-эчертә, яшәү өчен кирәкле азык-төлек, мал-мөлкәт китерә, бәйгеләрдә — тугрылыклы ярдәмче.

Җәмәгать тәртибе өлкәсендә дә Үзбәк чорында Урда күп бозыклыклардан азат булган.

«Урлау, алдашу,— дип яза М. Каратеев,— Урдада бөтенләй диярлек булмаган. Башка халыкларда гадәти күренеш дип саналган кечкенә генә намуссызлык өчен дә татарны Урдада рәхимсез җәза көткән. Намуслылык, дөреслек, туры сүзле булу — болар татар кешесенең иң күркәм сыйфатлары. Аның бу сыйфатлары гасырлар сынавын үтеп, безнең көннәргә кадәр килеп җитте. Революциягә кадәр акча эшләр өчен читкә чыгучы Идел буе кешеләре үз әртилләренә ничек булса да бер татарны кертергә тырышкан. Акча, ашау-эчүне оештыру шул татарга йөкләтелгән. Бу очракта акчаның бер тиене дә әрәм-шәрәм китмәячәк, беркемгә дә зыян-зәрә тимәячәк. Татар кешесе монда гарантия дип танылган». («Русь и Орда». Т., 1, бит 160).

Кешеләр арасында әхлакый күркәм мөнәсәбәтләр урнаштыру Үзбәк хан хакимлеге чорында тормыш, яшәү шартларын яхшырту юнәлешендә алып барыла. Ул чагында җәмгыятьтә кешелекле караш яши: бозыклыкны, җинаятьчелекне беренче чиратта тормыш авырлыклары китереп чыгара. Димәк, бозыклыктан, җинаятьчелектән котылырга телисең икән, яшәү шартларын яхшырт! Үзбәк хан шулай эшли дә. Ул тәхеттә утырган елларда Алтын Урда үсә, ныгый, баый, дөньякүләм абруй казана. Әгәр дә Бату «Җиһангир» дип аталган булса, хәзер Үзбәккә «Җир йөзе кояшы» дигән исем бирелә.

Ләкин 1342 елда Үзбәк хан вафат булгач, татар дәүләте Алтын Урданың хәле үзгәрә — кирегә китә башлый. Бердәмлек бетә, оешканлык юкка чыга. Алтын Урданың уникенче бөек ханы Туктамыш әйткәнчә, «Урда аллаһы тәгаләнең сөекле кызы булудан туктый». Туктамыш бу хәлнең сәбәпләренә тукталa. «Элек безнең хакимебез — бер кеше иде,— ди ул.— Аның каршында Җунгар тауларыннан алып Узу (Днепр) ярларына кадәр сузылган җиһан калтырап тора иде. Ә хәзер нәрсә? Менә инде ничә дистә ел улус ханнары бер-берләре белән чиратлашып хакимлек өчен, тәхет өчен талашалар» («Русь и Орда». Т. 2, бит 281).

Туктамыш шушы ызгыш-талашларга, таркаулыкка чик куярга теләп, Алтын Урда белән Ак Урданың берләштерелгән бөек ханы булуга ирешә. Ләкин аңарга да Алтын Урданың таркалуын туктатырга насыйп булмый. Бер яктан урыс иле, икенче тарафтан Аксак Тимер гаскәрләренең аяусыз һөҗүме астында татар дәүләте таркала, җимерелә. Татар шәһәрләре Сарай-Бату, Сарай-Бәркә, Үкәк... ватыла, юкка чыга.

Мондый аяныч нәтиҗә беренче чиратта татар ханнарының тормыш агышын алдан күрә белеп эш итәргә сәләтсез булуларыннан килә. Мәсәлән, Мәскәү кенәзләре астыртын да, ачыктан-ачык та үзләренә көч җыялар. Үзбәк монда ярдәм күрсәтеп тора. Ул Иван Калитаның Тверьне буйсындыруын тәэмин итү өчен, аңа үз гаскәрен биреп тора. Гомумән, кенәзләр татар ярдәмендә ныгыйлар, көчәяләр, бергә тупланалар. Үзбәк исә әлеге көчләрнең киләчәктә татарларга каршы чыгачагын башына да китерми.

Алтын Урданың таркалуын китереп чыгарган сәбәпләрнең тагын берсе шул: Үзбәктән соң тәхеткә килгән ханнар соң дәрәҗәдә хакимлек, тәхет яратучан булалар. Әйе, аларга син хакимлек бир, тәхет бир! Чөнки алар өчен тәхет — ул теләсә-ничә хатынга өйләнү, эчү, кәеф-сафа кору мөмкинлеге. Башка максат юк, халык язмышы, дәүләт язмышы турында уйлау юк.

Бу уңайдан урыслар тарафыннан әсир ителгән Казан ханбикәсе Сөембикәнең Казан белән саубуллашканда әйткән сүзләре гыйбрәтле. Алар ханнарның яшәү рәвешен күзалларга ярдәм итә.

«Кайгы-хәсрәт биләп алды сине, Казан! — ди Сөембикә.— Тажың төшерелде, даның тапталды. Хан кәефен табу өчен оештырылган сый мәҗлесләрең юк инде, Казан! Уен-көлке, җыр-бию белән узган күңел ачу кичәләрең дә бетте, Казан! Баллы эчемлек елгаларың туктады, мәҗлесләреңне ташу сыман басып китә торган шәрабләрең акмый хәзер!» (Спутник по Казани. Казан, 1895. бит 67—68).

Әйтәсе дә юк, мондый тормышта кая инде ул халык язмышы, дәүләт язмышы турында уйлау?

Хәлбуки, урыс кенәзләрендә идеясезлек, коры практицизм күзәтелми. Куликово кырындагы сугыш алдыннан Дмитрий Донской аллага ялварып, мондый теләк белдерә: «И, Ходаем! Ишетсәнә минем ялваруны! Бар өметем — Синдә! Күреп торасың, Тәңрем, үз дәрәҗәмне, үз данымны арттыру өчен кылыч алмадым. Туган җирне саклау өчен, туган җирне яклау өчен ул минем кулда. Ирек бирмә Русьны һәлак итәргә!» («Русь и Орда». Т. 2, бит 371)

Ә менә гади рус сугышчылары ничек уйлый: «Бу — кенәз белән кенәз сугышы түгел. Андый сугышта ни өчен үләсеңне дә белмисең. Бусы — үз йорт-җирең өчен сугыш, изге Русь өчен сугыш!» (Русь и Орда. Т. 2. бит 391)

Ни кызганыч, татар ханнарына мондый аңлы идеялелек җитмәде, ә халыкта милли үзаң, татар җанлылык тәрбияләнмәде. Хан — тәхет өчен, сугышчы — мал-мөлкәт өчен сугышты!

Бүгенге көндә дә татар халкының үз җитәкчеләренә хаклы дәгъва белдерергә нигезләре җитәрлек. Менә шуларның берсе: Татар халкының әле һаман тулы милли белем системасы юк. Дөрес, бу системаның башлангыч буыны — балалар бакчалары барлыкка килә башлады, аның урта буыны — мәктәпләр дә начармы-яхшымы эшли. Ә менә системаның югары буыны — милли университет, милли институт юк! Хәлбуки, татар халкын саклап калу, аны юкка чыгармау — тегәлләнгән, очланган милли белем системасыннан башка мөмкин түгел. Димәк, милли университет, милли институт ачу — ул халык язмышын хәл итү, дигән сүз. Татарстан хакимияте менә шушы уку йортлары өчен әлегә кадәр лаеклы бина төзеп биргәне юк. Акча юк, диләр. Шул ук вакытта үзләре Казан Кремлен реставрацияләү эшен башлап җибәрделәр. Сорау туа: боларның кайсы беренче чиратта башкарылырга тиеш? Шөбһәсез, милли югары уку йорты өчен бина! Әйе, бина! Чөнки ул безнең язмышны хәл итә, без — татарлар киләчәктә булырбызмы, юкмы? — шуны хәл итә! Кремльне реставрацияләү исә ашыгыч эш түгел. Аны 5 елдан, 10 елдан соң тормышка ашырсаң да, зыяны юк. Кызганыч ки, хакимнәребез шушы хакыйкатьне аңларга теләмиләр, дәүләт сәясәтен үткәрүдә вакыты-вакыты белән буталып калалар, милләтнең үсеш перспективасын куллан ычкындыралар.

Борчу тудыручы тагын бер мәсьәлә бар: хәзерге заманда Русия Федерациясендә яшәүче аз санлы милләтләрне бетерү, юк итү өч юл белән алып барыла. Беренче юл: аларны кыру, үтереп бетерү. Чечен халкына каршы сугыш — менә ачык дәлил. Икенче юл: катнаш никахларны арттыру. Өченче юл: аз санлы милләтләр арасына урыс телләрне урнаштыру һәм шул рәвешчә төп халыкны сыегайту, аны үзенең туган җирендә азчылыкны тәшкил итүчегә әйләндерү.

Безнең җитәкчеләр беренче юлга аз-маз каршы чыкса да, калганнарына битарафлык күрсәтә. Хәлбуки, аларның өчесе дә аз санлы милләтләрне бетерүгә хезмәт итә.

Тарихта да шулай булган: заманында зур абруй казанган Алтын Урда таркала, татар дәүләте юкка чыга, аның шәһәрләре, бистәләре җир белән тигезләнә. Татар халкы үз исеменнән оялып, ятсынып яшәргә мәҗбүр ителә. Тарих боларның барын да үзенә теркәгән, барына да ул — шаһит!

Теләк шул: хәзер ул хаталарны кабатламыйсы иде. Үткәндәгеләрен дә, бүгенгеләрен дә!

# Г. НИГЪМӘТИ ҺӘМ ЭСТЕТИК ФИКЕР

Ушы елның 26 июлендә татар әдәбият фәне, тәнкыйте өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәткән Галимҗан Нигъмәтинең (Галимҗан Әмирхан улы Нигъмәтуллин) тууына йөз ел тула. Башкортстанның хәзерге Чишмә районы Үрдәкбаш авылында туып, ике яшеннән Уфада үскән Галимҗан Нигъмәтигә язмыш тарафыннан совет чоры эстетик фикеренең нигезен салышу вазифасы йөкләнгән иде. «Галия» мәдрәсәсе аңа шактый нигезле белем һәм төрле яклап әйбәт хәзерлек бирә. Гражданнар сугышы вакытында, фронт газеталарында эшләп, ул үзенең журналистлык юлын башлый. Инкыйлабны үз иткән Г. Нигъмәтигә яшьтән үк зур ышаныч күрсәтелә. Ул Көнчыгыш фронтның Бишенче армиясендә чыга торган «Кызыл яу» газетасында — әдәби хезмәткәр, 1919 елның азагыннан «Азат Себер» (Омск) газетасында җаваплы сәркатип була. 1921 елда Көнчыгыш хезмәт ияләре университетының (Мәскәү) берьеллык курсларында укый. Үзәк Башкарма комитет аппаратында да эшләп ала. Егерме тугыз яшьлек Г. Нигъмәти Татарстан җөмһүриятенең үзәк газетасы булган «Кызыл Татарстан»ның мөхәррире итеп билгеләнә. Ә 1928—1930 елларда Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир була.

Г. Нигъмәти хезмәт куйган икенче юнәлеш — укыту өлкәсендәге эшчәнлек. Ул, әле үзе шәкерт кенә булуына карамастан, «Галия» мәдрәсәсендә үк әдәбият дәресләре бирә. Шундый ук хәл Көнчыгыш университетында да була, үзедәй курсантларга татар әдәбиятын укыта. Татарстан китап нәшриятында хезмәт итү белән бергә ул 1929 елдан Казан Көнчыгыш педагогия институтында (хәзерге Казан дәүләт педагогия университеты) эшли башлый. Тагын дүрт елдан ул биредәге татар теле һәм әдәбияты кафедрасына җитәкче итеп билгеләнә. 1934 елдан ул инде профессор дәрәҗәсе алуга ирешә. «Инкыйлаб миңа профессор кебек мактаулы исем алу дәрәҗәсенә үсәргә мөмкинлек бирде», дип яза ул горурланып[1]. Бер үк вакытта ул 1930—1932 елларда «Яңалиф» журналының мөхәррире дә. Көнчыгыш педагогия институты җитәкчелеге СССР хөкүмәте органнарына Г. Нигъмәтинең уңай сыйфатлары хакында болай дип яза: «милләте буенча татар, журналист, әдәбиятчы, татар газеталарында эшләүче, татар әдәбияты буенча күп кенә хезмәтләрнең авторы, партиянең күптәнге әгъзасы»[2]. КПИда шундый кешенең эшләве ихтыяҗны канәгатьләндерә дигән нәтиҗә ясала.

Шулай да Г. Нигъмәтинең аеруча тәкъдир ителергә тиешле хезмәте — аның әдәбият фәнен үстерүгә керткән өлеше һәм фәнни кадрлар хәзерләве. Әдәбият тарихын һәм әдәбият теориясен өйрәнүгә ул керткән хезмәт Х. Госман, М. Мәһдиев, И. Нуруллин, М. Гайнуллин, Җ. Вәзиева, Г. Кашшаф, М. Фәйзуллина һәм башкаларның мәкаләләрендә тәкъдир ителә. 1931 елда институтта аспирантура ачуы һәм яшь гыйльми кадрлар хәзерләүгә керешүе үзе бер зур игелекле эш булды. Мөхәммәт Гайнуллин, Маһинур Фәйзуллина, Җамал Вәзиева, Солтан Байков, Афзал Кудашев, Мөхәммәт Мамин, Якуб Агишев, Гази Кашшаф, Гали Халит, Хәмит Ярми — һәммәсе Г. Нигъмәтинең лаеклы шәкертләре иде. Аның укучылары Сәләй Вагыйзов белән Рәмзия Вәлитовалар озак еллар буена «Әлифба» төзеп килделәр, педучилищеларда укыту өчен методикага караган хезмәтләр бирделәр. Әлбәттә, Г. Нигъмәтинең шәкертләре арасында С. Хәким, А. Алиш, А. Әхмәт, С. Рәфиков, И. Туктар, И. Салахов, Г. Мөхәммәтшин, С. Урайский, Х. Рахман, В. Мифтахов кебек шагыйрьләрне һәм язучыларны да күрәбез. Олы галимнең мирасы булып аның фәнни хезмәтләре һәм

[1] За педагогические кадры, 1987, 21 октябрь, 2 б.
[2] Казан утлары, 1965, № 10, 149 б.

шәкертләре кала, диләр. Г. Нигъмәтине бу яктан бәхетле кеше дип санарга мөмкин.

Ул боларны шактый кыска вакытта башкарырга өлгерде. Әмма 1937 елның 16 сентябрендә ул кулга алына. Моның сәбәбен ул 1940 елның 20 февралендә хатыны Җиһан ханымга язган хатында болай аңлата: «милли кадрлар үстергәнмен»[1]. Ләкин ул моның нигезе булмавын яхшы аңлый. «Миннән укыганнар,— ди ул,— чын совет кадрлары булып эшлиләр (ягъни милли кадрлар булып түгел — Ф. Г.). Бу хәл миңа һәм миндә укучыларга яла ягарга теләүчеләрнең үз пычракларын ача торган факт түгелме?» 1919 елдан Коммунистлар фиркасе әгъзасы Г. Нигъмәти үзенең аспирантларын, студентларны «милли» итеп кенә тәрбияли алмый иде. Дөрес, теге яки бу милләтнең теле һәм әдәбияты белән шөгыльләнүчеләр, телиләрме-юкмы, яхшы мәгънәдә күпмедер милләтче дә булалар. Ягъни алар үз милләтенең рухи кыйммәтләрен башкаларга караганда күңелләренә якынрак алалар. Әмма Г. Нигъмәти үзенең аспирантларын утызынчы елларның рәсми идеологиясе рухында тәрбияли. Х. Госман язганча, «әдәбият-сәнгать мәйданына революцион-демократик идеяләр белән килгән һәм революциядән соң фәнни социализм юлына чыккан яшь Галимҗан Нигъмәти... «марксизм-ленинизм философиясен, аның эстетик кыйммәтен үзләштерә»[2]. Аның аспирантларының берсе Мөнзир Исхаков исә болай ди: «Г. Нигъмәти татар әдәбияты тарихы һәм әдәбият теориясен марксизм ноктасыннан чыгып тирән аңлаучы һәм киң катлау укучыларга аңлатып бирүчеләрнең беренче сафында торган коммунист-галим иде»[3]. Мондый шәхес, галим яшь кадрларны бары тик шушы рухта гына тәрбия кыла ала иде. Без моны аның әдәби эшчәнлегендәге күп кенә сәхифәләр белән дә раслый алабыз.

Әйе, утызынчы елларда әдәбият фәнендә һәм тәнкыйтендә марксизм-ленинизм карашларын эзлекле үткәрүчеләрнең берсе, әйтергә кирәк, иң үзәктә торучыларның берсе Г. Нигъмәти иде. Ник дигәндә, ул бу мәсьәләдә әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче каләмдәшләренең хезмәтләренә дә бик игътибарлы булды. Әйтик, бу елларда Х. Вәли әдәбият теориясе буенча байтак хезмәтләр бирә, ягъни сүз сәнгате фәненең төп көчләреннән берсе булып тора. Аның «Әдәби типлар механизмы», «Татар шигырь төзелеше» дигән китаплары чыга. Көндәлек матбугатта да шигырь техникасына, стиль мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре басыла килә. Г. Нигъмәти әлеге Х. Вәлинең бу хезмәтләре белән танышып бара, ләкин аларга үтә тәнкыйди якын килә. «Әдәби типлар механизмы» дигән хезмәтен «формалистлар, психологистлар, биологиячеләр карашын бергә җыярга тырышудан гыйбарәт» дип бәяли. Г. Нигъмәти карашынча, Х. Вәлинең язганнары «иң яхшы дигәндә, Жирмунский һәм башка шундый формалист галимнәрнең аерым әсәрләрен кыскартып тәрҗемә итеп тә, шул тәрҗемәләргә татар матур әдәбиятыннан үрнәкләр китереп ялгау гына. Урыс формалистларының эше белән Х. Вәлинең «татарчалаштыру» практикасы арасында аерма шунда: беренчеләр үзләренең карашларын әзме-күпме әзәрле (эзлекле — Ф. Г.) үткәрсәләр, Х. Вәли, алар карашын җитәрлек үзләштереп тә тормастан, укучыларга бирергә ашыга һәм, башка күп төрле карашлар белән бутап, «әкиятизм боткасы» пешерә һәм шуны марксизм тикшерүе дип тәкъдим итмәкче була»[4]. Әйе, Г. Нигъмәтинең гаме аңлашыла, фәндә үзен тикшергән һәм инануың булып әверелгән нәрсәләр турында гына язарга кирәк. Әмма, шул ук вакытта, ул үзе дә субъектив карашларын укучыга бирергә «ашыга», әле генә телгә алынган «формалистлар», «психологистлар», «биологиячеләр» агымнарының асылына тирәнрәк үтеп керүдән үзен азат итә, үзенә ошамаган якларны марксизм ысулы дигән иң «көчле дәлил» белән читкә этәрә. Сүз дә юк, ул бу мәсьәләләрдә ялгыз түгел иде. Шуны ук Хисмәтуллинга карата да әйтеп була. Ул да, әдәби агымнар пролетариатка хезмәт итәме, әллә алар башка идеология карашларына өстенлек бирәме, дигән сорау куя да, әдәбияттагы бер агым булган футуризмга карата катгый хөкемен чыгара: «футуристлар һәм гомумән футуризмның төп пролетариат агымы түгел икәнен яхшы беләбез»[5]. Шунысы кызык, аның каравы Г. Нигъмәтинең үзендәге шул ук «гөнаһларны» күрсәтеп чыгыш ясаучыларга да юлыгырга туры килә. К. Нәҗми, мәсәлән, аның «ата формалистлардан Ейхенбаумның тикшеренүләрен лирик әсәрләрне» бәяләгәндә нигез итеп файдалануын күрсәтте[6].

---

[1] Казан утлары, 1965, № 10, 150 б.
[2] Казан утлары, 1977, № 7, 170 б.
[3] Казан утлары, 1967, № 7, 113 б.
[4] Яналиф, 1930, № 4, 65 б.
[5] Яналиф, 1931, № 2, 55 б.
[6] Совет әдәбияты, 1936, № 4, 33 б.

Әдәби әсәргә иң әүвәл сыйнфый күзлек аша гына карау Г. Нигъмәти кебек әдәбият теориясен тирән белгән, аның эчке кануннарын хөрмәт иткән, сәнгатьлелекнең нечкә хасиятләрен сизгер тойган галимне дә берьяклы фикер йөртү юлыннан алып киткәли. Әйтик, аныңча, «Эшче» поэмасында М. Гафуриның хезмәт кешесен ничек итеп сурәтләве авторның сыйнфый аң дәрәҗәсенә бәйле икән. Г. Нигъмәтинең бу карашын тулысы белән кабул итсәк, «Гафури эшчегә авыр хезмәткә хөкем ителгән, эшләп-эшләп тә рәтле көн күрә алмаган һәм тормышын яхшырту юлында бер эш тә булдыра алмый торган зәгыйфь бер сыйныф итеп караган. Гафурича, эшчене кыен хәлдән чыгаруның юлы юк»[1]. Моның сәбәбе нидә? Г. Нигъмәти өчен монысы да тәмам аңлаешлы нәрсә. «Шушы караш, идея, әлбәттә, Гафуриның вак буржуа тормышы нәтиҗәсендә туган күренеш. Бу караштагы әдип «Эшче» поэмасын биргәндә үзен күрсәтә дә. Эшче сурәте мескен, көчсез итеп бирелгән. Әсәрнең башка сурәтләре, бөтен сурәтләү чаралары да шул фикергә тапкыр китерелгән. Әйтик, М. Гафури завод-фабрик тормышын дошман күргән. Аның бу тормышка «мөнәсәбәте — аңы шундый. Шушы аң буенча эш итеп, завод-фабрик тормышын художество формасында биргәндә дә караңгы, ямьсез буяуларда бирә». Монда инде, күрәбез, сыйнфый караш хәтта «дошман күрү» дәрәҗәсенә җиткерелеп карала («М. Гафури завод-фабрик тормышын дошман күргән»). Әлбәттә, бу шул сыйнфыйлыкка артык игътибар итүнең, аны бөтен фикерләүгә нигез итеп алуның бер чагылышы гына. Завод-фабрикны дошман күргән очракта М. Гафури хезмәт кешесен сурәтләргә алынмас та иде. Ул бары тик тормышны хакыйкатькә тугры калып сурәтләп кенә бирә. Бераз соңрак, 1928 елда, «Шагыйрьнең алтын приискасында» повестенда үзенең эшчеләргә уңай мөнәсәбәт белдерүен тагын да көчлерәк итеп күрсәтүе шуңа дәлил була ала. Дөрес, Г. Нигъмәти күрергә теләгәнчә, ул бу очракта да «эшчене кыен хәлдән чыгаруның юлын» сурәтләп бирә алмады. Монысы, дөресен әйткәндә, язучы бурычы түгел бит, бәлки сәясәтчеләр эше.

Әдәбият белгечләре, әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнешендәге үзенчәлекләр турында сүз алып барудан бигрәк, язучыларның үзләрен сәяси яктан төркемләүгә игътибар юнәлттеләр. Бигрәк тә «кем ул пролетариат язучысы?» дигән сорауга җавап эзләү үзәккә куелды. Аңа шактый тулы җавап Г. Нигъмәти тарафыннан бирелде. Ул пролетариат язучысын нәсел-нәсебе, тумышы буенча гына түгел, бәлки аның карашлары буенча билгеләргә тәкъдим итә. «Пролетариат язучысы исемен күтәрү, шул исемне йөртү өчен чыгышың яки торышың белән эшче булу гына җитми, бәлки пролетариатның алдынгы катлау идеяләрен үзләштергән була белү дә кирәк. Пролетариат шагыйре турында да шулай, аның иҗатында да төрле җитешсезлекләр булуы һәм вакытында шулар күрсәтелмәсә, ул җитешсезлекләрнең үрчүе дә мөмкин»[2].

Г. Нигъмәти шундый кирәкмәгән якка үзгәрүгә бирелгән авторлар арасыннан С. Баттал, Т. Госманов, М. Крыймовларны аерып күрсәтә. «С. Батталда кайвакытта өметсезлек, үз-үзенә реклама ясаучылык мотивлары күрсәтелмиме? Т. Госманов әсәрләрендә кайвакыт психологик реализм авышы, шулай ук төзүче сыйныф кешесен бирүдә йомшаклыклар очрамыймы? Пролетариат шагыйре М. Крыймов шигырьләре арасында вак буржуа карашларыннан арынмаган шигырьләр ятмыймы?»[3] Кемдә-кемдә, М. Крыймовта вак буржуа карашларының булмавын ачу өчен, әлбәттә, Г. Нигъмәтигә аның әсәрләрен генә күздән кичерергә кирәк булгандыр. Бу юлы тәнкыйтьче үзе телгә алган өч каләм әһеленең берсеннән генә булса да мисал, өзек китерми, үз фикерләрен дәлил белән ныгытмый. Аның «Т. Госманов әсәрләрендә кайвакыт психологик реализм авышы» булуын кимчелек итеп күрсәтүе үзе генә дә шактый сәер яңгырый. Димәк, ул пролетариат әдәбиятында психологизмның булырга тиешлеген гомумән кире кага. Шулай да аңарда хакыйкатькә тугры булу сыйфаты үзен сиздерә. «Яңа бурычларга дип борылыш ясаганда», ягъни егерменче-утызынчы елларда, әдәбиятта артык уңышлар булмавын әйтә. Монда ул әдәбиятка аңа хас булмаган бурычлар куюны сәбәп итеп алмый, бәлки бу хәлгә идеологик каршылыкларның киртә булуын искәртә[4].

Шулай да Г. Нигъмәтидә эстетик тәфтишләүгә омтылыш өстенлек ала, ул әдәбиятның үзенчәлегенә — сурәтлелегенә килеп чыга. Шуның белән кайбер вульгар социологизм тарафдарларыннан сәнгатьлелек ягына таба китеп баруы белән аерылып тора. Бу аның өслүбенә дә йогынты ясый. Ул сабыррак, уйлабрак һәм

---

[1] Яңалиф, 1931, № 1, 36 б.
[2] Яңалиф, 1931, № 1, 36 б.
[3] Шунда ук, 36 б.
[4] Шунда ук, 34 б.

фикерен жиренә житкеребрәк яза. Бу турыда К. Җаманаклы да билгеләп үтә. Аңа Ялтада ике Галимҗан — Ибраһимов белән Нигъмәтиләрнең сөйләшүләренә шаһит булырга туры килә. Г. Ибраһимов тәнкыйтьче замандашына болай ди: «Әдәби тәнкыйть әсәрләре дә талантлы каләм белән язылырга тиеш дип саныйм мин. Рус әдәби тәнкыйте тарихында моның матур мисаллары күп. Белинский, Добролюбов хезмәтләрен алып карыйк. Алар тирән мәгънәле»[1]. Г. Ибраһимов, шул рәвешле, тәнкыйтьнең публицистика белән сугарылуында өстенлек тә күрә. Дөресен әйткәндә, Г. Нигъмәтинең тәнкыйть хезмәтләре дә шушы таләпләргә туры килә. Ләкин шунысы әһәмиятле, ул моны эстетик нигез белән табигый үрә белде. Бу яктан замандаш тәнкыйтьчеләргә үрнәк, буталып калган чакларында билгеле бер сукмакка юнәлтүдә остазлык хезмәтен үтәде.

Социологизм һәм идеологиячелек — алар икесе дә бер-беренә якын, әчтәлекнең кайсы да булса катламның, фирканең карашларына нигезләнгәнен аңлаталар. Дөрес, социологизм идеологияләштерүнең үтә шәрәләндереп бирелүе белән аерылып тора. Тәнкыйтьче Х. Наум, мәсәлән, боларны аңлатуда буталып кала. «Г. Ибраһимовның соңгы иҗаты булган «Тирән тамырлар»ның идеологик ягы пролетариат карашына авыша. Ләкин әсәрнең социологик әһәмияте судебный проблема белән сугарылган. Болар икесе бер нәрсә түгел»[2]. Бередә, гомумән, теоретик яктан буталчыклык, авторның хәтта терминнарны аңламаганлыгы күренә. Сорау туа: «судебный проблема белән сугарылган» пролетариат карашы кимчелекмени? Югыйсә, ачык бит инде, теләсә ничек сугарылсын, әмма пролетариат идеологиясе генә үткәрелсен. Х. Наум кебек социологизм тарафдарларына шунысы мөһим булырга тиеш иде кебек. Шулай да социологизм белән идеологияне «икесе бер нәрсә түгел» дип әйтеп чыгуы Г. Нигъмәтинең каршылыгына очрый. «Бу караш чуалчык һәм дуалистларча караштан башка нәрсә түгел. Димәк, Наумча, әсәрнең ике ягы бар: берсе идеологик ягы, икенчесе социологик ягы. Һәм болар житмәсә икесе ике нәрсә»[3].

Х. Наумның әдәби әсәргә бәя биргәндәге эшчәнлеген аның менә бу сүзләре аша шактый тулы итеп күз алдына китереп була: «Әдәби әсәрнең иң элек идеологиясен ачып салырга кирәк. Моны ачып салу өчен иң элек ул идеяне каплаган художество пәрдәләрен тәнкыйть пычагы белән рәхимсез «ертып» җибәрергә кирәк»[4]. Әдәби әсәргә мондый рәхимсезлек белән якын килүне хәтта «үтә марксист» тәнкыйтьчеләрнең берсе булган Г. Нигъмәти дә өнәп бетермәде. Аның җавабында хәтта көлемсерәү чаткылары чагылып үтте. «Күрәсең, чикләвек төшен алу өчен чикләвекне вату кирәк булган кебек, әсәрнең идеологиясен табу өчен дә марксизм «пәкесе» белән әсәрнең ... «кабыгын» ертырга кирәк була. Әйдә, Наум үзе теләсә нишләсен дә иде, ә соң нигә аны, марксизм исеменнән сөйләп, башкаларга да тәкъдим итеп, кешенең башын бутарга?»[5] Бу мисал Г. Нигъмәтинең әлеге чор тәнкыйтьчеләре арасында сәнгатьнең үзенчәлеген аеруча яхшырак тойган булганлыгын күрсәтә.

Шул ук вакытта Г. Нигъмәти каләмдәшләренең сәясәттән аерылган фикерләре очраганда да битараф калмый. Әйтик, шул ук Х. Наум бер чыгышында болай ди: «Бетховен музыкасы кебек көчле музыкалыкка ия булган шигырь яки художестволы образлар белән җырлап бармаган шагыйрьнең яки әдипнең нинди «кыйммәте бар?»[6] Ягъни Х. Наум бередә шигырьнең музыкаль булырга тиешлеген, әсәрләрнең (тезмәме ул, чәчмәме) художестволы образлар белән җырлап бирелергә тиешлеген хуплый. Ягъни «саф эстетик» планда фикер йөртә, сәясәткә керми. Г. Нигъмәтигә бу ошамый, шуңа күрә ул Х. Наумга кискен бәя бирүдән тотылып кала алмый. «Наумовның тәнкыйть карашларының тагын бер ялгышлыгы сыйнфыйлыктан тыш, тик эрудиция белән генә билгеләнә торган эстетик категорияләр барлыгын тануда булып, бу хәл аны башка сыйныфларның культура, художество мирасларына бәя бирә алмаучылыкка китереп чыгара. Бередә Наумов бер омтылышта берничә хата ясый». Бу хаталар Г. Нигъмәти карашынча, нәрсәләрдә күренә? Иң әүвәл Бетховенны «сыйныфтан тыш эстетика кыйммәте бирүче итеп алуы»нда. Икенчедән, «символистларның «беренче нәүбәттә музыка!» дигән лозунгларын раслый, ә чынлыкта «бу лозунгы төбендә мистицизм яшеренгән», ди.

Мондый эстетик карашы өчен Х. Наумга коллегасы Г. Нигъмәтидән әнә шулай кискен тәнкыйть сүзе ишетергә туры килә. Каты бәрелүен үзе дә сизгән

[1] Г. Ибраһимов турында истәлекләр. 1966, 316 б.
[2] Яңалиф, 1931, № 11, 72 б.
[3] Шунда ук, 72 б.
[4] Октябрь (Уфа), 1931, № 1, 3 б.
[5] Яңалиф, 1931, № 11, 68 б.
[6] Шунда ук, 73 б.

булса кирәк, ул инде сүзне иптәшләрчә киңәш бирү рәвешендә очлый. «Ә соң, Наум иптәш, без бүген ударникларны әдәбиятка тартырга кирәк, әдәбият көчле сәяси караш белән сугарылсын, дибез, әдәбият партияле булсын, саф эстетизм таләпләре күтәрелү реакцион омтылыш ул, дибез. Ә син киләсең дә Бетховен музыкасы кебек көчле музыка «бирмәгән» шагыйрьнең яки әдипнең нинди кыйммәте бар, дисең»[1]. Бу өзектән Г. Нигъмәтинең пролетар әдәбиятка карашын шактый тулы итеп күз алдына китерәбез, бу аның социалистик әдәбиятны ничек аңлавының нигезе булып кабул ителә. Кайчакта Г. Нигъмәти сүзе фирка фикере буларак кабул ителү шуннан килә иде.

Мәсәлән, шул елларның иң актив тәнкыйтьчеләреннән берсе Ф. Мөбар өчен дә иң зур абруй — фирка сүзе иде. Татар язучыларының, галимнәренең фикерләрен ул бары тик шул яктылыкта гына бәяли. Ул «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» җыентыгындагы Г. Нигъмәти мәкаләсеннән, әйтик, бер өзек китерә дә, аны фирка сүзе дип аңлавын белдерә. «Без, иске буржуа әдәби мирастан баш тарту, аннан файдаланмау кебек юл тотып, комчванлыкка бирелмәскә, шулай ук иске буржуа әдәби мирасы алдында йомшарып китеп аңа баш-аягыбыз белән чуму, аны тәнкыйтьсез һәм сайлаусыз кабул итү, аңа капитуляциягә бирелүдән дә сакланырга тиешбез». Бу фикерләр дөресме-юкмы, Ф. Мөбар үзе дә әлләни уйлап баш ватмый. «Бу тезис та Г. Нигъмәти иптәш карашы гына түгел, партия карашы буенча да шулай»[2], дип раслап кына куя.

Иҗатта реализмны бердәнбер иҗат ысулы буларак урнаштыру — бу чорның төп юнәлеше. Каләм әһелләрен шушы рухта тәрбияләүгә көч аз сарыф ителмәде. Мондый йогынты бигрәк тә Һ. Такташка күп ясалды, аны символистлыктан реализмга күндерү бурычы куелды. Һ. Такташның символист булганлыгы — Г. Нигъмәти өчен дә хәл ителгән нәрсә. Ул бу турыда икеләнмичә яза: «Такташның «символистлык» дәвере бар иде. Иске дини хорафатлардан сюжет алып язылган «Җир уллары» әсәре аның бу дәвере өчен бик характерлы. Бу вакыт Такташ иске әдәбиятның нык тәрбиясендә. Аңарда мистиклык үзенең йогынтысын күрсәтеп тора. Югарыдагы шигырь (сүз 1923 елда язылган «Кояш күктә мәңге йөзәр» шигыре турында бара — Ф. Г.), бердән, шагыйрьнең, космизмга бирелеп, фәлсәфә сатуын кисәтсә, шуның белән бергә бу фәлсәфә мистикадан да азат булмаганын күрсәтә. Чөнки ул бөтен эшне канунга китереп терки. Ә бу канунның нәрсә икәнен күрү өчен Такташның «Җир уллары»на гына күз салырга кирәк. Чөнки анда «канун Җәбраил» аерым символик сурәт итеп алына, «Алла хөкеме» бирелә дә үз хөкемен йөртә»[3].

Күрәбез, Г. Нигъмәтигә, шагыйрь Һ. Такташның символист, мистик шагыйрь булуын раслар өчен, аның (Һ. Такташның) «бөтен эшне «канунга китереп терка»ве нигез була икән. Бөтенгаләм күләмендәге тартылу кануннары тәгълиматына таянып язган Һ. Такташ өстенә мистиклык (саташучанлык) күләгәсе ябыла. Күк җисемнәре өчен шушы каннуннан тыш бернинди дә ирекле хәрәкәт була алмый. Була икән, ул теге яки бу җисемнең, җисемнәр төркеменең һәлакәтенә китерә. Иҗтимагый тормышта гына, субъективлыкка юл куелып, кануннар бозылырга мөмкин. Бу да җәмгыятькә зыян сала, аны шулай ук һәлакәткә китерә. Моның шулай икәнлеге күп тапкырлар расланды инде.

Без боларны язганда, һич кенә дә Г. Нигъмәтинең татар әдәбиятын үстерүгә керткән өлешен киметеп күрсәтүне күздә тотмыйбыз. Әдәбият белемен һәм тәнкыйтен профессионализм дәрәҗәсенә күтәреп, киләчәктә аларның үсеп китүенә үзе тәрбияләгән шәкертләре эшчәнлеге нәтиҗәсендә дә зур йогынты ясаган шәхесебезгә карата күңелләребездә бары тик рәхмәт хисләре генә яши. Социологизмга, фиркалелеккә басым ясау егерменче-утызынчы елларның гомуми тенденциясе иде. Алардан Г. Нигъмәтинең генә читтә кала алмавы көн кебек ачык.

Г. Нигъмәти хезмәтләрен инанып язды. Фикерләрен ихлас бәян кылды. Яңа чынбарлыкның күпчелеккә бәхет, тигезлек, гармония китерәчәгенә ышану аның эшчәнлегенең дә нигезенә ятты. Чөнки үткәннең каһәрле яклары алар буынының үзәгенә тәмам үткән иде. Кызганычка каршы, Г. Нигъмәти һәм аның каләмдәшләре таянган идеология үзенең яшәүчәнлеген раслый алмады. Моңа каләм әһелләре гаепле түгел иде. Г. Нигъмәтинең эстетик фикер үсешендә үз урыны бар. Алар буыны калдырган мирас бүгенге һәм киләчәктәге тикшеренүчеләр өчен гыйбрәтле сәхифәләр булып хезмәт итәр.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

---

[1] Яңалиф, 1931, № 11, 73 б.
[2] Атака, 1930, № 3, 26 б.
[3] Яңалиф, 1931, № 11, 73 б.

# МАТУР ЯЗМЫШ

Кеше организмында төрле авыруларның чыганагы булган кирәксез күзәнәкләр, баш калкытыр вакыт житкәнне көтеп посып яталар, әмма күп очракта алар шулай йомылып та калалар һәм адәм балалары гомерләрен сау-сәламәт, тыныч үткәрәләр дип ишеткәнем бар. Шуның кебек ходай бәндәләрендә «Язучылык чире»нең дә яралгысы буладыр, ижади фикерләүче кешеләрнең кайберләрендә ул бик иртә уяна, ә кайберләрендә соңгарак калып булса да үзен сиздерәдер кебек.

Рәисә Ишморатовада ул нәкъ менә үз вакытында уянды дип әйтергә мөмкин. Чөнки аның беренче әсәре «Бай кияү» дөньяга чыкканда аңар әле 35 яшь кенә була. Утыз-кырык яшьләр ул кешенең тәмам өлгергән, белем туплаган, фәлсәфи уйланырга өйрәнгән, шактый зур тормыш тәҗрибәсенә ия булган чагы. Йөрәгенә ижат уты кабынган кеше өчен күләмле әсәрләр язар вакыт кына.

Яшь чагында Рәисәнең тормыш сукмагы әдәби-ижат дигән тылсымлы, серле утраудан ерак ятса да, шул юллардан үтүенә үкенми ул. Бу елларда аның дөньяны танып белү сәләте, кичерешләре, тойгылары катлаулана, тирәнәя бара. Тегерменче әтисе янында лаборант хезмәтен үтәгән кыз колашадан агып төшкән кершән кебек ак, җылы агымга учын куеп торган чагында игенченең шатлык белән тулы йөрәк тибешен ишеткән кебек булгандыр. Сугыш елларында госпитальдә эшләгән вакытында яралы сугышчыларның яргаланган иреннәре аша саркып чыккан кайнар сулышлары йөзенә бәрелгәндер, фронт узган җирләрдә дәүләт куркынычсызлыгы органнарында хезмәт иткәндә илен саткан хыянәтчеләрнең, коралын ташлаган куркак җаннарның чирканыч йөзләрен күреп бәгыре каткандыр. Илгә кайткач халыкның эш белән үткән тыныч, һәрвакыт бертөрле яшәү рәвешеннән гыйбрәт алгандыр.

Ул вакытларда Рәисә язучы булам дип уйламый әле. Әмма, нәкъ менә шушы елларда, үзе дә сизмичә, язучы өчен бик кирәк булган тормыш хәлләрен күңеленә сеңдерә бара. Бал кортының нектар җыйганы кебек. Нектардан бал ясаган кебек, күңел байлыгын да әдәби әсәр кысаларына урнаштырасы гына кала.

Рәисә кайбер башлап язучылар кебек, «Америка ачарга» теләп, зур темаларга үрелмәде. Үзе белгән, көче житкән хәтлесенә алынып, бер пәрдәлек пьесалар яза башлый. Һәм шуның белән ота да. Аның беренче әсәре, «Бай кияү»дә сугыш һәм сугыштан соңгы тормыш авырлыгыннан гаҗиз булган кайбер кешеләрнең эчке дөньялары шактый оста сурәтләнә. Рәисә бу әсәре белән яшь драматургларның Мәскәүдә уздырылган семинарында катнашып, уңай бәя ала, пьеса авыл сәхнәләренә тәкъдим ителгән репертуарга кертелә. Аның кыска күләмле башка пьесалары да озак еллар буе сәхнәдән төшми уйнала.

Билгеле, таш өстендә гөл үсми дә, чәчәк тә атмый. Әгәр тәкъдире кушып, атаклы драматург Риза Ишморат белән тормыш корып җибәрмәгән булса, Рәисәнең юллары әдәби мохиттән читтә дә үткән булыр иде. Ә кем белә, бәлки бернигә дә карамыйча язып та киткән булыр иде. Яшь чагында Чистай шәһәренең үзешчән спектакльләрендә алыштыргысыз суфлер булган бит ул. Ни дисәң дә, драматургиягә якын шөгыль. Шулай да була тормышта. Ул вакытта әдәбиятка килү юллары озагырак, авырырак булыр иде. Рәисәнең язучылар даирәсенә килеп керүе, Риза Ишморатның ижат лабораториясенә якынлыгы, Тажи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт кебек олы драматурглар белән еш кына очрашып торуы, ижат секцияләренә йөрүе, куелган һәр спектакльне карап бару һәм алар турында фикер

алышуларны тыңлавы андагы иҗат потенциалын кузгатып җибәрә дип ышанып әйтергә мөмкин.

Рәисәне мин яза башлаган елларыннан ук беләм. Була бит шулай: кайбер кешеләрне аңлар, якын итәр өчен еллар кирәк була. Ә кайберәүләр беренче очрашуда ук күңелеңне яулап ала. Зәңгәр күзле, көләч йөзле, җор телле ханым белән без илленче еллар башында таныштык та тиз арада гаилә дуслыгы башланып китте һәм берничә еллардан соң иҗади дуслыкка әйләнде. Темперамент һәм холкыбыз төрле булуы дуслыгыбызны ныгытты гына. Артык хискә бирелеп киткән чакларында бераз суына төшәр өчен ул минем яныма килә иде. Тормыш мәшәкатьләренә бирелеп, язу эшем икенче планга кала башласа Рәисәнең ташып торган энергиясеннән мин гыйбрәт алам. Озак еллар шулай яшәдек без. Бер вакыт Риза абый белән Шәрәфнең туган көннәрен бергә үткәрдек. Ул көнне Риза абыйга 58, Шәрәфкә 42 яшь тулган иде. Шул уңай белән Шәрәф «Безгә йөз яшь» дигән шигырь язды.

«Абый» димим сиңа, «Энем» димим,
Кемгә күпме — дуслар сизмәсен,
Икәү бергә тагын йөзне җыеп
Ургытырбыз иҗат чишмәсен,

дигән юлларны Риза абый ул кичтә берничә тапкыр кабатлады.

Рәисәнең бер гадәтен ошата идем мин. Ул бер вакытта да әсәре сәхнәгә куелу белән тынычланып калмый, тамашачы фикерен белү аның өчен бик кыйммәт. Шуның өчен республиканың теләсә кайсы районына барып чыгарга әзер. Аны әле Сабада, әле Әлмәттә, Балтачта йә Актанышта күрергә була. Тамашачы белән бергә утырып спектакль карый, аларга кушылып көлә, алар кебек үк борчыла, автор һәм режиссер җибәргән хаталарны күрергә тырыша.

Халык арасында йөргәндә аның журналистик сәләте дә ачыла. Тикшерергә, күзәтергә, мәсьәләнең асылына төшәргә яраткан әдип колхозлардагы яхшы һәм яман хәлләрне күреп йөри, алар турында мәкаләләр язып бастыра.

Бер вакыт Саба районы колхозларында йөреп кайткач борчылып сөйләгән иде.

— Ферма малларына азык җитми. Сөтне киметәсез дип савымчыларны тиргиләр. Мәрфуга атлы Ленин орденлы савымчы бүләкләрен идарә рәисе алдына китереп сала. Йә азыкны җитәрлек бирегез, йә бүләкләрегезне кире алыгыз, оят миңа аларны тагып йөрергә, ди.

— Рәисә, пьеса язарга була бит, уйла әле,— дим.

— Мәкалә язып, тизрәк бастырырга кирәк. Пьеса халыкка озак бара,— диде.

Беренче уңышлар, беренче куанычлар аның башын әйләндермәде, зурырак күләмле әсәрләр язарга дәртләндерделәр, илһам бирде. Бу вакытта ул сәхнә серләренә өйрәнеп җиткән, драматик әсәрләр язу алымнарын үзләштергән язучы иде инде. 1955 елда студентлар тормышыннан дүрт пәрдәлек «Тормыш юлында» дигән драма язып, Татарстан республика күчмә театрында куйдыра. Бу аның профессионал сәхнәгә аяк басуы була. Пьесада сурәтләнгән медиклар тормышы аңар һич тә ят булмый. Арча госпиталендә эшләгәндә бу профессиянең төрле характердагы вәкилләрен күреп белә, алар өстенә төшкән физик һәм психологик йөкне үзе дә күтәрешә. Шулар барсы да яңа әсәр язганда ярап куя. Соңга таба язылган «Әйтер идем йөрәк серемне» һәм «Яшьлек канат җәйгәндә» пьесалары да заманча һәм тормышчан булулары белән тамашачы игътибарын җәлеп итә. Алар башкорт, чуаш, мари театрларында, Оренбург шәһәр театрында да уңыш казаналар. Үзе дә яшь күңелле, яшүсмерләр белән уртак тел таба, аларны аңлый белгән авторның күзәтү объекты — яшьләр тормышы булып, ул аның бөтен якты һәм күләгәле якларын җентекләп өйрәнергә тырыша. Олы яшьтәге кешеләрнең күбесенә бикле булган үзенчәлекле дөньяга үтеп керергә омтыла. Үзенең гаиләсендә малайлар үсеп килүе, аларның күп санлы танышлары, дуслары автор кулына тылсымлы ачкыч бирә. Яшьләрнең мөстәкыйльлеккә омтылулары, олылар канаты астында яшәүне тарсынуларын, ә зурларның һаман да баласытып карауларын, шуның аркасында аталар һәм балалар арасындагы мәңгелек каршылыкның безнең көннәрдә дә дәвам итүен һәр әсәрендә үзәккә алырга тырыша. «Яшьлек канат җәйгәндә» драмасында һөнәр сайлау кебек бик җитди мәсьәләне алып, аның дәрәҗәсен төшемле урын, кода-кодагый, дус-иш арасында кирәкле кеше булу максатыннан гына бәяләгән әти кеше белән, тормышка яңача, заманча карый белгән кызы арасындагы конфликтны уңышлы чишә.

Балалар язучысы буларак миңа да Рәисәнең күзәтүләре, фикерләре, уйлары кызык тоела иде. Ә ул сөйләргә ярата. Кичләрен урамда кеше азая төшкәч, алдан

сүз куешып, очрашабыз да сәгатьләр буе сөйләшеп йөрибез. Ул эшләнеп бетмәгән кульязмасын да, әле бер калыпка салмаган, башында гына йөргән, темаларны да инде, тәмамланган әйбер кебек итеп, дулкынланып сөйли. Шул очрашуларның берсендә:

— Чехов урамындагы йортның бер фатир тәрәзәсендә бик матур ваза белән чәчәкләр торганын күреп йөрим, дип сөйләгән иде.

— Бик еш алыштырып торгангамы, әле генә өзеп алган кебек, алар һәрчак тере була.

Ә бер вакыт вазадагы чәчәкләр шиңеп төшәләр, аннан саргаеп ук бетәләр. Бу күренеш язучы кешене тыныч калдырмый, ни булганын белергә теләп Рәисә әлеге йортка килә һәм подъезд төбендә утырган карчыклардан сораша башлый. Күп еллардан бирле түшәктә яткан авыру карчыгының күңелен күрү өчен гомер иткән карты алып кайта торган булган ул чәчәкләрне. Ләкин шушы арада гына йөгереп йөри торган карт, көтмәгәндә йөрәге тотып, дөнья куя. Карчыкның ахирәтләре кереп, булышкалап йөри икән дә бит, тәрәзә төбендәге сулган чәчәкләргә берсенең дә күзе төшми икән. Бу сөйләшү бераздан «Чәчәкләр» дигән моңсу хикәя язылуга сәбәп була.

Йөзәргә өйрәнгән кеше яр буенда гына чупылдамый. Аңар суның тирәнерәк җире кирәк, ераккарак китеп, көчен сынап карау кызык. Рәисә дә үзен нәкъ шул йөзүче кебек сизә башлый. Ольгая төшкән саен күңел күзенең күберәкне күрә башлавы да сәбәп була моңар. Тормыш чуалчыклыгы язучы алдына очына чыгуы авыр булган сораулар куя. Дөньяда күпне күргән, тәҗрибәле Риза ага белән дә бу турыда сүзләр күп була, драматургия кысаларына сыеп бетмәгән уй-фикерләрен Рәисә аның белән уртаклаша. Геройларының катлаулы язмышларын ачар өчен зуррак мәйдан кирәклеген үзе дә тоя. Аның күңелендә үзенә якын булган, пьесаларында кабат-кабат үзәккә куелган, бер вакытта да тыныч калдырмаган, уйландырган, борчыган темасы — яшүсмерләр тормышыннан повесть язу теләге уяна. Ни сәбәпләр беләндер барыр юлында сөрлеккән, адашкан, югалып калган адәм балаларына ихлас күңелдән әйтелгән язучы сүзләрен җиткерәсе килә. Күз алдында булып торган гыйбрәтләр ана һәм язучы йөрәген тыныч калдырмый. Повестьның үзәгендә авыр язмышлы яшүсмернең күңелсез язмышы булырга тиеш дип уйлый. Кем аңар ярдәм кулы сузар да, кем һәм ничек итеп аның язмышын рәткә салыр?

Күңелендәге уйлары белән уртаклашыр, киңәшер өчен милиция органнарына мөрәҗәгать итәргә була. Анда яшүсмерләр белән эшләү бүлегенең инспекторы, үзе дә яшь лейтенант белән таныша. Яңарак кына олы тормышка аяк баскан, шунлыктан көн дә аралашып торган малайлар, кызларның холкын яхшы белгән лейтенантның тәҗрибәләре, эш алымнары Рәисәгә кызыклы тоела. Бирелә үзенең күп төрле сорауларына җавап таба. Алай гына да түгел, лейтенантны булачак китабының төп герое итеп тә күрә башлый.

Сюжет кору, вакыйгаларның үсешен эзлекле алып бару осталыгына ул инде сәхнә әсәрләрен язганда шактый өйрәнгән була. Материалның характеры һәм динамикасы әсәрне шанлы һәм укырга кызыклы итә. «Милиция лейтенанты» дигән бу повесть Татарстан эчке эшләр министрлыгы игълан иткән конкурста да җиңеп чыга.

Чир китә, гадәт китми, диләр бит. Рәисәнең бер башлаган эшне ахырына хәтле башкарып чыгу гадәте гомере буена барды һәм көндәлек эшләрдә генә түгел, иҗат мәсьәләләрендә дә үзен сиздерә килде. «Милиция лейтенанты» китабы басылып чыккач та андагы геройларның алдагы язмышы туктаусыз уйландырды. Тормыш хакыйкате белән язучы фантазиясе арасында гел бәхәс барды. Повестьның героена әйләнгән лейтенант белән дуслык та дәвам итә иде. Һәм менә шул шартларда повестьның икенче китабы «Язмышлар» дөнья күрде.

Шулай итеп, Рәисәнең иҗат мөмкинлекләре елдан ел ачыла барса да, бу аңар җиңел бирелде дигән сүз түгел әле. Беренче хикәяләрен яза башлаганда драматург Рәисәнең прозаик Рәисәгә комачаулаган вакытлары да булды, бу ике жанрның үзенә иң хас үзенчәлекләрен баштарак күреп бетерә алмады. Сәхнә әсәрләрендә гадәттә сурәтләү чаралары тамашачыга күберәк декорация һәм костюмнар аша җиткерелсә, геройларның кичерешләрен бирү артистның талантына һәм режиссерның тапкырлыгына бәйләнгән булса, проза әсәрләрендә исә болар барысы да сүз дигән хикмәтле төшенчә өлешенә кала. Прозаикның тел байлыгы әсәрнең яртысы уңышын тәшкил итә. Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел, дип әйтәләр бит. Тырышлык һәм үҗәтлек Рәисәгә бу авыр йөкне дә күтәрергә көч бирә. Соңрак елларда язылган «Сүз», «Фирая» повестьлары, яңа хикәяләре шактый ул җанлы, сыгылмалы тел белән язылды.

Хатын-кыз язучыларның үзенчәлекле бер ягы бар — ул иҗат кешесе булу өстенә ана да, гаилә учагын сүндермичә саклап торучы да бит әле. Бигрәк тә ирең Риза ага кебек хөрмәтле, зур язучы булганда бу җиңел вазыйфа түгел. Ә Рәисә бөтен яктан дип әйтерлек Риза аганың олы таянычы булды. Чын иҗат кешесе кебек Риза Ишморат язудан башка мәшәкатьләрне белмәде дип әйтергә мөмкин. Йортны алып баруны гына түгел, иренең иҗатына бәйләнгән йомышларны да Рәисә үз өстенә алды. Ул Риза аганың барлык язганнарын машинкада басучы, беренче тәнкыйтьчесе, драматурглар секциясендә фикер алышырга кирәк булганда аның әсәрләрен кычкырып укучы булды. Командировкаларга барган җирендә беренче эше өенә шалтырату иде.

— Риза, мин килеп җиттем. Хәлең ничек?

Рәисәгә Язучылар берлегенең әдәби фонды идарәсендә зур җаваплы эш тапшырылган иде. Күп еллар буе ул язучыларның тормыш-көнкүреш дәрәҗәләрен күзәтеп торды. Фатирсызларның фатир алулары, телефонсызларның телефонлы булулары кебек четерекле мәсьәләләр каралганда да аның сүзенә колак салалар иде. Авыруларның өйләренә барып хәл белергә дә иренмәде ул. Шуңар күрә каләмдәшләре арасында абруе зур булды.

Риза абый белән шулай бер-беренә ярдәм итешеп, бәхетле, матур гомер кичерделәр алар. Моннан ике ел элек Риза Ишморат вафат булгач кына Рәисә югалып калгандай булды. Сәламәтлеге кинәт какшады. Хәзер ул ире турында җырлар чыгарып, күңеленнән җырлап йөри. Элеккечә яза алмавына бик офтана. Ә мин аны:

— Рәисә, эшләгән хәтле эшләрең дә бик житәрлек. Бурычыңны тулысы белән акладың, бер дә борчылма,— дип юатырга тырышам.

Менә инде аңар сиксән яшь тулды. Гомернең матур чаклары үтеп киткән. Ләкин онытылмаслык истәлекләр бар бит. Шуңар куанып исән-сау яшәвен телим мин аның.

**Ләбибә ИХСАНОВА**

**P. S.**

Бу мәкалә драматург исән чакта язылып, аның белән үз вакытында Рәисә ханым танышып өлгергән һәм бик яратып калган иде. Әмма ни кызганыч, мәрхәмәтсез үлем сөекле каләмдәшебезне арабыздан алып китте.

Мәкаләне шул көйгә бастыруны мәгъкуль күрдем.

**АВТОР.**

# БОЛГАРЫЙ КЫЛЫР КҮНЕНЕ

*Уңган хатын билгесе:*
*Игә кертер тирене,*
*Болгарый кылыр күнене,*
*Тунлы кылыр ирене.*

Татар халык мәкале.

Халыкның үткәнен һәм бүгенгесен тулырак күз алдына китерим дисәң, кайчак аның көндәлек тормышына, көнкүрешенә, ашау-киенү рәвешенә күз салу да җитә. Әйтик, сафьян читекләре язмышы-тарихы белән дә хәл шулайрак тора.

Кызык кына килеп чыга түгелме соң. Бер яктан борын-борыннан чәмчәле читек, чәчәкле читек, чуар читек, парчалы читек, чәкәнне читек, чиккән читек, чигүле читек, каюлы читек, каймалы читек, итәкле читек, бизәүле читек, турлы читек, уйулы ату, хәтта урыс сүзләре кергән минзәләви читек (вензелевый), бирхәле (верх) читек, пулузур читек (ярым бизәкле) кебек исемнәр белән аталып йөртелүче бу көяз аяк киеменең, ягъни болгарый кылган күненнән ефәк җепләр белән чигелеп эшләнгән ерак тарихлы эчитекне (ул тыштан кәвеш белән киелгән) — гамәли сәнгать әсәрен — сагынып кына сөйләргә кала. Өзелгән буыннар, киселгән тамырлар галәмәтедер инде бу. Югыйсә, ул урыс патшалары аяк киеме буларак, Эрмитажларда сакланган, хәтта урыс җырларына да кергән («привези мне из Торжка два сафьянных сапожка»), шулай ук төрле аппликация-бизәкләргә күчеп, башка халыклар мәдәниятенә дә сәнгати йогынты ясаган. Икенче яктан, бүген дә электән чигелгән әлеге читекләрне татар әбиләренең аягында күргәч, горурланмый да мөмкин түгел. Ак мамык шәле, каюлы читеге булса, күңеле бөтен, тормышы түгәрәк була Ак әбинең. Чын сәнгать, югары гамәли сәнгать әсәре булганга шулай ул. Биреп кара син татар әбиенә чигеп түгел, буяп яисә ябыштырып кына әмәлләнгәнен читекне, ул аңа борылып та карамаячак!.. Юк, татар әбисенә бары шул уннарча атамасы булган чигүле читек кенә кирәк. Һәм ул һәркайда шулай: Себердәме яки Сембердәме, Ижаудамы яки Касыймдамы, Сарытауда яки Өркеттәме — бөтен дөньяга сибелгән татар әбиләренең хыялында әнә шул Казан читеге булыр, аларның сандык төпләрендә тетелеп беткән ефәктәй читек китеге ятыр. Алар, әлбәттә, Казаннан, Эрбет, Мәкәрҗә, Кяхта, Торжок ярминкәләреннән алдырыла торган булганнар. Чөнки һәркайда да шулай ефәк белән күнгә чигә алмаганнар.

Себер татарлары арасында «уюлы ату» дигән атама бар. Ул Касыймдагы кебек, баштагы «к» авазы төшеп калып «кату» (аякка элү) сүзеннән ясалган бик кадими атама. Мөгаен, иң борынгыларыннандыр әле. Эчитек тә, тышкысы да булмаган чакта ук тугандыр, уймалы, бизәүле аяк киеме катып йөрүне аңлатадыр. Югыйсә, гади күннән тегелеп, әле дә булса киелә торган аяк киеме Себердә царык, чарык, кунычлы чарык дип йөртелмәс иде. Итек тә, читек тә соңрак кергән атамалар, ләкин алары да бар Себердә. Әнә ич, җырда ничек җырлана:

Сәхтиян ла читек, савырый башмак,
Бас, йәникәм, йирләрне уйгынча...

Ихтимал, элегрәк тирене уймалап, уеп, чигеп хәстәрләү эше үзе дә булгандыр, йә онытылгандыр гынадыр. Асылда исә бу бизәкле күн мозаикасы тарихы Себер аша, моннан 2500 еллардагы Алтайның Пазырык курганнарына барып тоташа. Шунда — мәңге туңлык катламнарында сакланган мондый сәнгать үрнәкләре.

Аларның нәкъ татар хатын-кызлары мәхәббәте һәм зәвык ихтыяҗлары буларак дәвам итүе дә, шагыйрь әйтмешли, «юкка түгелдер». Әнә бит «болгарый кылыр күнене» диелә борынгы мәкальдә хатын-кызларның уңганлыгына ишарәләп, «болгарый» дип аталырлык икән, димәк, татарларда затлы итеп күн иләү, дуплау эшләрендә хатын-кызлар да катнашмый калмагандыр. «Әниең нишли? Тире иләп күн эшли» такмазасы да шуңа бер дәлил булып тора. Тагын бер мисал, белгәнебезчә, украиннарда, көньяк Россиядә кызыл төстәге итекләр бар, әмма аларга карата олугъ сәнгаткяр Игорь Моисеев: «Төсле аяк киеме — татар халкына гына хас сәнгать әсәре ул»,— дигән.

Чигүле читек дигәннән, бу очракта үзем белән булган кыйсса хакында сөйләп үтәргә телим. Андый читекләрне бер йөз генә пар алып таратмаганмындыр мин үз гомеремдә. 1990 елны Америкага барганымда, аларның бәясе 150 сумга күтәрелгән иде инде. Шулай да мин океан артындагы ханымнарыбызга бүләккә биш пар читек сатып алдым. Берсен үзем киеп, Мәскәү метросына төшеп килә идем, арттан сулуы кабып берәү чаба: «Апа, зинһар миңа сатыгыз бу читегегезне! Әнием Пензада тора, каян да булса табып кайтырга кушты»,— ди бу. Мин: «Казанга барып, Арчадан алыгыз»,— дидем. Америкада исә мине каршы алучылар, әле мине танып та өлгермәстән, читекләремә карап: «Син Флора буласынмы?» — дип эндәштеләр. Анда инде, тәки аягымнан салдырып, бер кыргыз рәссамы Бишкәгына алып кайтып китте читекләремне.

Шулай, халкыбызны дөньяга танытучы бу борынгы гамәли сәнгать әсәре татарда тиктомалга гына килеп чыкмаган. Буыннар өзелүе аның онытылуына бер сәбәп булган шикелле, килеп чыгуы үсешенә дә менәр еллар чарланган дәвамында табигый зәвыгы, милли характеры, икътисади-мәдәни ихтыяҗлары, әйтик, малчылык үсеше, исраф итмәү, камиллеккә омтылу кебек дин, гореф-гадәт йолалары да ярдәм иткән. Күнчек (сумка), күпчек (мендәр), котыйчык (тартма) кебек күн әйбер исемнәре дастаннарда сакланган һәм аларның читек бизәкләү техникасы белән эшләнгән булуы бик ихтимал.

Кыскасы, күн эшкәртү осталыгы белән безнең әби-бабайлар бик күптәннән таныш булганнар. Шуңа күрә дә яхшы эшкәртелгән, иң сыйфатлы күн һәм күн әйберләре башка халыкларда «болгарый» дип атала. Үзебездә исә ул гомуми билгеләмә әдәби телдә дә, күнче-һөнәрчеләр телендә дә очрамый диярлек. Бары җырлардагы:

Базарлардан алган читегеңнең
Болгар микән, җаныем, олтаны,—

кебек сүзләргә карап кына, иң яхшы күн кирәк булган олтанлык өчен «болгарый» күне файдаланылганын белергә мөмкин. Махсус үрчетелгән мал, билгеле үсемлек сыгынтылары белән эшкәртү-иләү (иеләү) хәзерге химия заманында онытыла да булыр. Археологлар тапкан кызыл төстәге күн кисәкләренә анализ ясап карагач, аларның үсемлек сыгынтылары белән эшкәртелүе мәгълүм булды.

Сактыян (сафьян) һәм сауры дигән күннәр өч яки алты айга хәтле сөт имгән кәҗә, сарык, сыер, ат тиреләреннән эшләнгән. Сауры — ат янбашы, ягъни иң таза өлешеннән ясалып, үкчәгә куела торган булган. Мәшһүр шагреневая кожа да шул сүздән килеп чыккан, дип саный тюркологлар. Савыр сүзен татар теленең иң борынгы сүзләре сакланган себер диалектларында әле дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, бер атка ике кеше атланса, «савырлашып менгән» диләр, ягъни берсе ат янбашына утырган була. Шевро да нигездә шул сүздән ясалган, тик аның мәгънәсе үзгә: өч ай сөт имгән кәҗә тиресеннән эшләнгән йомшак күн була ул.

Әйтергә кирәк, бу сәнгать бүген дә исән. Шөкерана кылыйк. Арча милли аяк киемнәр фабрикасы директоры рәссам Илдус әфәнде Гайнетдинов, мәсәлән, үзенең коллективы белән шушы гамәли-декоратив сәнгатебезне һич төгәнмәүче әбиләребез ихтыяҗын гына канәгатьләндерер өчен түгел, миллионлаган читекләрне бөтен дөньяга тарату эше белән бүген дә армый-талмый шөгыльләнә. Рәссам С. Н. Кузьминых бу сәнгать өлкәсендә үзенең кызы белән бергә эшли, мәктәп, техникумнарда сабак бирә. Тел галиме Резеда ханым Рәхимова айлар, еллар буенча Арча, Кылачы, Урта Сәрдә, Өнсә авыллары осталары янында яшәп, бу һөнәр атама, исем, термин, технологиясен өйрәнде, китаплар чыгарды.

Ә менә яшь рәссам Наилә Кумысникова Кремль сарайларында ике ел элек «Болгарый» дип аталган сәнгать остаханәсе ачып җибәргән. Шул остаханәне таныту, таныштыру, үзенең иҗат кабилиятен күрсәтү йөзеннән күптән түгел М. Горький музеенда күргәзмә дә ясап алды.

Монарчы мин ул рәссамны театр сәхнәсен бизәүче һәм Казан сынлы сәнгать училищесында укытучы дип белә идем. Хәзер ул шушы хезмәтләре өстенә 12 кешедән торган остаханә белән җитәкчелек итә. Кисүче, тегүче, чигүче, итекче кебек осталары бар икән инде үзенең. Аларның хезмәте сәнгать әсәрләренең үзе кебек бер ансамбль, тату иҗат коллективы көчен күрсәтә. Моңа җитәкченең уңганлыгы да таләп ителә, чөнки иҗат ул үзе үзгә, нәзек, индивидуаль хезмәт бит. Әлеге татар әбиләре урамда киеп йөри торган читек сәнгатебезне яңартып, үстереп, музей диварларына куюга зур эш. Читек кунычлары заманга яраклаштырылып, тезгә җитә торган итек ясалган. Төсләр кычкырып тормаган тынычкы тоннарда. Гомумән, татар халкының үзе кебек сабыр-салмаклык, йомшак нык-лык хөкем сөрә остаханә хезмәтләрендә. Читек, күнчек, камзул, башлыкларны Наилә ханым бер ансамбль итеп бирә һәм «Зөбәрҗәт», «Әлфия», «Флүрә» кебек татар хатын-кыз исемнәре белән атый.

Бу катлаулы, борынгы һөнәри сәнгатьне иҗади үзләштерү генә түгел. Камил сәнгать югарылыгына күтәрү өчен Наилә ханым күп укыган, галимнәр белән аралашкан. Хәзерге көндә сәхтиле, болгарый күннәре әзерләп бирүче осталарга юлыккан. Аларның да берсе хатын-кыз — күн берләшмәсендә эшләүче Надия Кәрим кызы Мәмәдова икән. Наилә Кумысникова эзләнү-тикшеренү нәтиҗәләрендә тупланган бизәк төрләре арасында үсемлек, бөҗәк орнаментлары гына түгел, борынгы әкият, дастаннарыбызда чалымлана торган скиф җанвар стиле дә чагылып китә.

Күргәзмәдә Наилә ханым Кумысникованың нәкыш әсәрләре дә куелган иде. Туган ягыбызның сөеп туймаслык пейзажларын сурәтләүгә рәссам ире хезмәтләре дә җәлеп ителгән. Әллә нинди ак киемнәргә төренгән серле хатын-кыз силуэтларны күргәч, мин аларны киләчәктә шушы кадими сәнгатькә нигезләп эшләнгән милли киемнәр, бизәкләр белән дөньяны аһ иттерәсе затлар итеп күрдем.

Бер иҗади эше белән Наилә ханым президентыбыз Минтимер Шәймиевне дә шаккатырган икән. «Сөембикә» журналы юбилее уңае белән редакциягә килгәнендә Илбашына истәлеккә Наилә Кумысникованың күн мозаика сәнгатендә бизәп ясалган «Сөембикә» әсәре бүләк ителгән.

Күптән түгел Наилә ханым Мәскәү мәчетеннән дә яңа заказ алган: Урманче шәмаилләреннән берсен затлы итеп чигеп җибәрүен үтенгәннәр икән. Чыннан да Урманченың шәмаилләренә нәкъ менә шушы күн мозаикасы белән дә бизәлү соралып тора сыман. Мин аны бик күптән бер Илдус әфәнде Гайнетдиновка тәкъдим иткән идем. «Ля тәгъзәб» — «Ачуланма!» дигәнен Казан музыка инструментлары фабрикасында фанера-шпоннан ясатып, журнал өстәлчеге өстенә дә куйдырып карадым. Мәскәү мәчете өчен «Аллаһе җәмилен хөббел җәмал», ягъни «Аллаһе гүзәл, гүзәллекне ярата» диган шәмаилне һәм «Әлхәмделиллаһ»ы алтынлап чигүгә ярашлы булыр иде. Бу соңгысы инде ксерокслар аркылы да күбәйтелде, Җ. Зәйнуллин китабында басылгач, аны фотога алып та зурайталар икән. Пыялалы рамга куелган кәгазь вә фольга «Әлхәмделиллаһ»ны Казан, Түбән Кама, Һельсинки мәчетләренә, Америка татарларына бүләк итеп биргән идек. Ул инде чын фольклор әсәре кебек, подносларга да ясалды. Екатеринбур ювелирлары кечерәйтеп, асма алтынайга да чокып ясаганнар. Берәү хәтта кабер ташына да төшергән шуны (?), ә икенче кеше (рәссам), зурайтып, ясап Урманче урынына үз фамилиясен куйган. «Әлхәмделиллаһ» шәмаиленә! «Плагиатның андый төре дә була икән», — диде бер язучы бу хакта ишеткәч. Әнә шундый хәлләр фонында борынгы сәнгатебезне тернәкләндергән, камилләштергән Наилә ханым Кумысникова иҗаты тагын да күңелләргә якын, саф, теләсә нинди мактауларга лаеклы хезмәт булып тора.

Ул сәнгать белгече, профессор Халит әфәнде Кумысников һәм актриса, Тукай бүләге лауреаты Асия ханым Хәйруллина гаиләсендә туган кыз. Яшьтән театр сәнгате атмосферасында үскән. 1983 елда Мәскәүдә Суриков исемендәге институтны тәмамлап, унбишләп спектакль бизәргә өлгергән. Туктаусыз, ару-талуны белмәс иҗат эзләнүләренә яшүсмер улы Җәмилне тартуы да уңганлыгын күрсәтә аның.

Наилә ханымга яңадан-яңа уңышлар теләп каласы килә.

**Флора ӘХМӘТОВА-УРМАНЧЕ,**
филология фәннәре кандидаты.

# Рәшит Ибраһимовка — 70 яшь

Бар бит шундый бәхетле кешеләр! — нәрсәгә генә тотынсалар да, җырдагыча итеп әйтсәк, «кулларыннан гөл тама» — һәр эшне бер дигән итеп ахыргача башкарып чыгалар. Җитмеш төрле һөнәрне үзләштереп, дөньяны матурлау уе белән гомерләре буе янып яшиләр алар. Кылган изге гамәлләре исә, иман нуры кебек, халык күңеленә сеңә бара...

Мәркәзебез Казанда яшәүче очучы-әдип Рәшит Ибраһимов та — әнә шундый тирән хөрмәткә лаек, эшчән-тыйнак милләттәшләребезнең берсе. Сайлаган төп һөнәрендә иң югары биеклекләргә ирешкән шәхес ул! Язучы буларак та, Язмышка рәхмәтле — һава юллары аша бик күп җирләр-илләр гизгән очучы үзе күргән-кичергәннәр турында туган телебездә мавыктыргыч итеп яза белә. Алтмышынчы еллардан башлап бүгенге көнгәчә аның үтемле язмалары даими рәвештә төрле газета-журнал битләрендә дөнья күреп килә, китаплар булып чыга. Үткән тарихыбыз, сугыш елларында батырлык үрнәкләре күрсәткән очучы якташларыбыз турында да, бүгенге көн каһарманнары, авиация өлкәсендәге яңалыклар хакында да кызыклы итеп сөйли белә әлеге талантлы каләмдәшебез. Бигрәк тә аның балаларга атап иҗат иткән язмалары отышлы. Р. Ибраһимов «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасы, «Ялкын» журналы битләрендә «Көмеш канатлар», «Очучы булам, дисәң...», «Канатлыга — зәңгәр биеклек», «Күктә нилләр булмас» кебек рубрикалар булдырып, йөзләрчә язмаларын бастырды — балалар өчен өр-яңа дөнья ачты. Аның әнә шундый үзенчәлекле дәресләрен тыңлап-укып үскән малайларның һәм кызларның кайберләре, соңыннан, гомерләрен авиациягә багышладылар...

Очучы-әдипнең үткән тормыш юлы белән дә кыскача таныштырып үтик.

Рәшит Габдерахман улы Ибраһимов 1927 елның 28 июлендә Ульяновск өлкәсенең хәзерге Чынлы районындагы Кәшә авылында крестьян гаиләсендә туа. Бөек Ватан сугышы башлангач, яшүсмер егет, укуын ташлап, колхозда эшли. Җиңү таңы аткач, 1946 елда ул Ульяновск шәһәрендәге тимер юл училищесен тәмамлый. Куйбышев, Казан шәһәрләрендәге авиация заводларында электрик хезмәтен башкара. Шул чорда аэроклубта укып, радист һөнәрен дә үзләштерә. Кичке урта мәктәпне тәмамлагач, Богырыслан шәһәрендәге очучылар мәктәбенә кабул ителә. Очучы таныклыгы алгач, Р. Ибраһимов, 1953 елдан алып 1979 елның ахырына кадәр, Казан аэропортында эшли. ПО-2, АН-2, ЛИ-2, ИЛ-14 самолетларында оча. 1966 елдан алып, лаеклы ялга чыкканчы, ТУ—124 реактив самолетында корабль командиры була. Рәшит Габдерахман улы — гомеренең егерме мең сәгатен һавада уздырган I класслы очучы, «Аэрофлот» отличнигы. Зәңгәр күктә ул барлыгы 6 миллион километр юл үткән (ә бу исә Җир шарын 150 мәртәбә әйләнеп чыгуга тиң!). Хезмәттәге фидакарьлеге өчен, Р. Ибраһимов Татарстан Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы белән дә бүләкләнде.

Очучы-әдип, күктән җиргә төшкәч тә, халык өчен игелекле хезмәтен матур дәвам иттерә. Инженер-төзүче булып эшли, яңа аэропорт корылмаларын сафка бастыруда турыдан-туры катнаша. Аэропорт музеен ачу буенча да башлап йөрүчеләрнең берсе булды ул. Тынгысыз каләмдәшебез бүгенге көндә «Мәдәни җомга» атналык әдәбият һәм сәнгать газетасында эшли...

Р. Ибраһимов — 6 китап авторы. Аның Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Көмеш канатлар» (1971), «Крылья Татарстана» (1984), «Алтын йолдыз-

лы Лачын» (1987), «Көмеш канатлар, зәңгәр хыяллар» (1989), «Ерак илләргә сәяхәт» (1990), «Канатлыга — зәңгәр биеклек» 1995) исемле китаплары үз укучысын тапты. Хәзер исә очучы-әдип «Болытлар арасында без салган юл» дип исемләнгән күләмле өр-яңа автобиографик әсәрен тәгәлләде. Остазы — очучы-язучы Салих ага Баттал хаклы юраганча, яңа роман иҗат итү өстендә дә эшли ул...

Рәшит Габдерахман улы — 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.

Без каләмдәшебезне олуг юбилее белән ихлас күңелдән кайнар котлыйбыз, аңа нык сәламәтлек, бәхетле иҗади гомер, пар канатларының армавын-талмавын телибез!

**Шаһинур ӘХМӘТСАФА.**

## Әмир Мәхмүдовка — 50 яшь

Әмир Гобәй улы Мәхмүдов 1947 елның 28 июнендә Башкортстанның Әлшәй районы Габдрәшит авылында туган. Әлшәй районы үзәге Раевка поселогы урта мәктәбен тәмамлагач, 1965—1969 елларда Бөре дәүләт педагогия институтының рус филологиясе бүлегендә белем ала, Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1970—1973 елларда Мәскәүдә Н. К. Крупская исемендәге педагогия институтының эстетика кафедрасы каршындагы аспирантурада укый һәм, М. Җәлил иҗатының идея-эстетик үзенчәлекләре турында фәнни хезмәт язып, диссертация яклый.

1974—1981 елларда Ә. Мәхмүдов СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр булып эшли, аннары ул Казан дәүләт педагогия институтының татар әдәбияты кафедрасы доценты була.

Ә. Мәхмүдов алтмышынчы елларда яза башлый. Беренче шигырьләре район газетасында 1963 елда чыга. Шуннан бирле шигъри әсәрләре белән Башкортстан һәм Татарстанның республика матбугатында, соңга таба русча тәрҗемәдә үзәктәге газета-журналларда даими катнашып килә. 1983 елны Татарстан китап нәшриятында «Матурлык тантанасы» исемле җыентыгы һәм соңрак башка китаплары дөнья күрә.

1972 елдан башлап Ә. Мәхмүдов әдәби тәнкыйть, әдәбият белеме өлкәсендә дә актив эшли. Аның М. Җәлил, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Г. Камал, К. Насыйри кебек классик язучылар иҗатына багышланган аерым мәкаләләре, ана теленнән тыш, СССР һәм чит ил халыклары телләрендә дә басылып чыга. Авторның 1980 елда русча дөнья күргән «Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля» («Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал») исемле китабы исә шагыйрьнең эстетик карашларын махсус алып өйрәнгән-анализланган беренче хезмәт буларак кызыклы.

Туксанынчы еллардан башлап, Ә. Мәхмүдов милли-азатлык хәрәкәтендә актив катнаша, берничә ел «Суверинетет» комитетын җитәкләде.

Юбилярны кайнар котлыйбыз!

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

## ПРЕЗИДЕНТЛАР ОЧРАШУЫ

21 майда Казанга Президент Аслан Масхадов җитәкчелегендә Ичкерия Чечен Республикасының һәм Президент Руслан Аушев җитәкчелегендә Ингушетия Республикасының рәсми делегацияләре килде. Халыкара аэропортта олы кунакларны Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин, Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев һ. б. рәсми кешеләр каршылады.

Татарстан Президентының Казан Кремлендәге резиденциясендә һәм Хөкүмәт йортында үткән дустанә-җылы очрашулардан соң, Татарстан Республикасы белән Ичкерия Чечен Республикасы арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы Шартнамәгә кул куелды. Әлеге тантанада Ингушетия Республикасы Президенты Р.Аушев һәм Татарстан хөкүмәте, Дәүләт Советы җитәкчеләре катнашты.

* * *

5—6 июнь көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге рәсми делегация, Ингушетия Республикасы Президенты Р. Аушев чакыруы буенча, әлеге җөмһүрияттә дуслык визиты белән булды. Татарстан Президенты Ингушетия Республикасының 5 еллыгына багышланган тантанада чыгыш ясап: «Кечкенә халыклар юк — һәр халык үзенең саны белән түгел, ә эшләре белән бөек»,— дип искәртеп узды. Бәйрәм көнне Ингушетия һәм Татарстан, Ингушетия һәм Башкортостан арасында дуслык һәм хезмәттәшлек турындагы килешүләргә кул куелды. Аларга әлеге республикаларның Президентлары Р. Аушев, М. Шәймиев һәм М. Рәхимов имза салды.

## ТӨРКИЯ КУНАГЫН КАБУЛ ИТҮ

9 июньдә Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Төркиядән килгән күренекле милләттәшебез һәм якташыбыз, Әхмәтвәли Мәңгәр фонды президенты Сафия Имрене кабул итте. Кунак ханым ата-бабаларының Ватанына килүенең үзе өчен бик әһәмиятле булуын ассызыклап әйтеп узды. Ул Казанга әдәбиятыбыз классигы Гаяз Исхакыйның шәхси архивын, сәгатен һәм медальонын алып килеп, аны Татарстан Президентына тапшырды.

Әтисе Әхмәтвәли Мәңгәрнең һәм Г. Исхакыйның кызы — Сәгадәт Чагатайның васыятен үтәгәннән соң, Сафия ханым ата-бабалары туган Мәңгәр авылын (Арча районы) зиярәт кылды, Казан белән танышты, М. Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында «Аккош күле» балетын карады.

## ОЧРАШУЛАР ДӘВАМ ИТӘ

«Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясе рәисе — язучы Фәүзия ханым Бәйрәмова Төркиядә булып кайтты. Ул Истанбулда төрки дәүләтләр һәм халыкларның V корылтаенда катнашты һәм чыгыш ясады. Аннары Анкарага килеп, Төркия Бөек Милләт мәҗлесендә депутатлар белән очрашты, «Бөек Берлек» һәм «Яңадан туу» партияләре вәкилләре белән әңгәмәләр үткәрде, әлеге җөмһүриятнең радио-телевидениесенә, газета-журналларга интервьюлар бирде, дин әһелләре белән күреште.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА БАГЫШЛАП

Икенче Бөтендөнья татар конгрессын каршылап, Казан шәһәрендәге 1 нче һәм 11 нче китапханәләр (җитәкчеләр — Нурия Яруллина, Галина Ларионова) үзара берләшеп, 6 майда «Татар әдәбияты һәм мәдәнияты көне» уздырдылар. Нигездә, ул «Казан утлары» журналына, аның 75 еллык юбилеена багышланды. Бирегә шул уңайдан махсус күргәзмә дә оештырылган иде.

Әлеге истәлекле очрашуга «Казан утлары»нда эшләүче язучылардан — баш мөхәррир урынбасары Флүс Латыйфи, проза һәм хатлар бүлекләре мөхәррирләре Шамил Маннапов белән Шаһинур Мостафин килгән иде. Алар китапханәгә җыелган өлкәннәргә һәм лицей-гимназия укучыларына журналның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында тәфсилләп сөйләделәр, «Казан утлары»нда дөнья күрәчәк яңа әсәрләргә җентекләп тукталдылар, соңыннан исә үзләренең иҗат үрнәкләре белән таныштырдылар, күпсанлы сорауларга җаваплар бирделәр.

Кичәнең икенче өлеше дә мавыктыргыч-күңелле үтте. Мәркәзебезнең мәдәният һәм сәнгать академиясеннән үзе уйнап-үзе җырлаучы Ирек Усманов, 2 нче татар гимназиясе җырчыларыннан һәм биючеләреннән Чулпан Әхмәтҗанова, Эльвира Рәфыйкова, Зөһрә Фатыйхова, Алинә Сәлахова, 149 нчы төрек-татар лицееннан нәфис сүз остасы — очрашуны алып баручы Гөлнур Вәлиуллина кебек талантлы яшьләр «Казан утлары»н алдыручыларның күңелләрендә якты хатирә калдырдылар.

* * *

Журналыбызның юбилее уңаеннан, шундый ук очрашулар, «Казан утлары» һәм аның даими авторлары» дигән исем астында Казанның Дәрвишләр бистәсендәге Сәедгалиев исемендәге мәдәният сараеның китапханәсендә дә (житәкче-оештыручысы Сәрия Гаязова) үткәрелә башлады. 20 майда булган беренче очрашу танылган шагыйрь-фронтовик Мәхмүт Хөсәеннең якты истәлегенә багышланган иде. Биредәге татар гимназиясе укучылары катнашында үткәрелгән әлеге кичәгә шагыйрьнең бертуган сеңелесе Роза ханым да чакырылды — ул абыйсы турында үзенең истәлекләре белән уртаклашты, аның мәктәп елларындагы кульязма китаплары, үзе ясаган рәсемнәре, сирәк фотолары белән таныштырды. Гимназия шәкертләре исә М. Хөсәен шигырьләрен сөйләделәр, аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

Хәзер китапханәдә язучылардан Атилла Расихка, Габдрахман Минскийга, Әнәс Галиевка багышланган чираттагы очрашуларны үткәрүгә ныклы хәзерлек бара. Мәгълүм булганча, инде мәрхүм булган әлеге дүрт авторның һәркайсы озак еллар Дәрвишләр бистәсендә яшәп иҗат иттеләр, иң яхшы әсәрләрен «Казан утлары» журналы битләрендә бастырдылар.

## УНИВЕРСИТЕТТА — ЯҢА БҮЛЕК

Казан дәүләт технология университетының гуманитар мәгариф кафедрасында гарәп теле һәм мөселман дөньясы мәдәнияты бүлеген тәгъдир итү тантанасы булды. Аны быел, өстәмә белем бирү бүлеге буларак, АКШ һәм Согуд Гарәбстанының «Таибә» дип аталган халыкара оешмасы белән берлектә ачканнар иде. Шулай итеп, Татарстанда да Ислам дөньясының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, телен һәм фәлсәфәсен тирәнтен өйрәнү мөмкинлекләре тудырылды.

## ОЛУГ ШӘХЕСКӘ АТАП

Мәркәзебез Казанда, М. Горькийның әдәби-мемориаль музее бинасында «Борынгы истәлекләрне саклаучы» дип аталган клубның чираттагы утырышы булды. Бу юлы ул күренекле галим, тарихчы, фикер иясе һәм язучы Газиз Гобәйдуллинның тууына 110 ел тулуга багышланды. Шул уңайдан музейда махсус күргәзмә ачылып, анда Г. Гобәйдуллинның тәржемәи хәле белән бәйле фоторәсемнәр, китаплар, шәхси әйберләре, туган-тумачалары турында белешмә-шәҗәрәсе куелды. Аларны музейга галим-язучының улы — биология фәннәре кандидаты, хәзер Мәскәүдә яшәүче Сәлман Гобәйдуллин җибәргән.

## *ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА*

## ЧАЛЛЫ БҮЛЕГЕНДӘ — ЯҢА ЖИТӘКЧЕ

Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә отчет-сайлау җыелышы булды. Бүлек җитәкчесе Рахмай Хисмәтуллин соңгы елдагы эшенә кыскача хисап тотты. Чаллы язучылары һәм Казаннан килгән Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, ТР Язучылар берлеге җитәкчесе Ринат Мөхәммәдиев бүлек эшчәнлегенә кагылышлы үз фикерләре белән уртаклаштылар, уңай һәм кимчелекле якларны күрсәттеләр.

Күпчелек тавыш белән, Чаллы язучылар оешмасының яңа рәисе итеп тарихи романнары белән танылган прозаик Вахит Имамов сайланды.

## КИРОВ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ КАЛӘМДӘШЕБЕЗ ЯНЫНДА

4—5 июнь көннәрендә «Казан утлары»ның бүлек мөхәррирләре Рәдиф Гаташ белән Шаһинур Мостафин һәм Чиләбе шәһәреннән килгән оста тальянчы — ике мәртәбә Бөтенсоюз конкурслары лауреаты, Ф. Туишев исемендәге иҗади бәйгә дипломанты Вазыйх Шәрәфетдинов, Киров өлкәсенең Нократ Аланы районындагы Түбән Шөн авылында яшәүче талантлы язучы Рафаэль Сибат (Хуҗин) янында булып, аның катнашында әдәби-музыкаль очрашулар үткәреп кайттылар. Урта Шөн урта мәктәбендә үткәрелгән классташлар очрашуында Р. Сибатның Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп бертавыштан кабул ителүе турында әйтелде һәм аңа, шуны раслап, 280 нче санлы таныклык тапшырылды. «Казан утлары» журналының иң актив авторларының берсе саналган әлеге киң колачлы әдип адресына кунаклар, мөгаллимнәр һәм сабакташлары тарафыннан күп кенә җылы сүзләр әйтелде, истәлекле бүләкләр, чәчәк бәйләмнәре бирелде. Очрашу барышы видеотасмага да төшереп-яздырып алынды.

## ҮЗ УЛЛАРЫН ЗУРЛЫЙ МАМАДЫШ

6 июньдә Мамадыш районының Кече Кирмән авылы мәдәният йортында, танылган шагыйрь, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы Рафаил Газизовның тууына 50 яшь тулуга багышлап, әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Мамадыш районы хакимияте башлыгы Әгъзам Гобәйдуллин, Татарстан Язучылар оешмасы житәкчесе Ринат Мөхәммәдиев, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов, Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, «Чаян» журналыннан күренекле шагыйрь Зөлфәт, Башкортстанның Дуван районында хакимият башлыгы булып эшләүче авылдашы Миннефәргать Вәлиев h. б. шагыйрь-мөгаллим адресына ихлас сүзләрен-теләкләрен җиткерделәр, бүләкләр тапшырдылар.

Кичәдә яраткан артистларыбыздан Мингол Галиев, Георгий Ибушев, Гөлнәзыйрә Талипованың, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге халык уен кораллары ансамбленең, Чаллыдан Әхмәтшиннар гаиләсе ансамбленең катнашуы нур өстенә нур булды.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары — танылган шагыйрь, про-

заик, кинодраматург һәм композитор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әхмәт Гаделнең 55 яшьлек юбилеен быел Мамадыш районы хакимияте, ТР Язучылар оешмасы белән берлектә, 19 мартта Казанда, К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында, олылап билгеләп үткән иде. Июнь аенда мамадышлылар Ә. Гаделне гаиләсе белән янадан үзләренә кунакка дәшеп, зур кадер-хөрмәт күрсәттеләр. Язучы туган авылы Акчишмәдә, шулай ук Иске Завод, Югары Ушмы авылларында булып, халык белән очрашты, үзенең яңа әсәрләрен укыды, җырларын башкарды. Әлеге онытылмас очрашуларның ныклы хәзерлек-оешканлык белән үтүенә әдипнең авылдашы — «Агроснаб»ның район бүлеге җитәкчесе Рамил Мөбәрәкшин, «Ушмы» күмәк хуҗалыгы рәисе Фаил Әхмәтҗанов үзләреннән лаеклы өлеш керттеләр.

## Ш. БИКЧУРИН ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Һәр елны Лениногорск районы хакимияте (җитәкчесе — И. Садриев) тарафыннан әдәбият, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге уңышлары өчен, үз хезмәтләре белән танылган шәхесләргә күренекле язучы Шамил Бикчурин исемендәге премия бирелеп килә. Быел әлеге мәртәбәле бүләккә Куакбаш авылында яшәүче үзешчән җырчы һәм шагыйрь Әгъләс Шәйхетдинов, Лениногорск шәһәрендәге нефтьчеләрнең техника-мәдәният йорты каршындагы татар драма түгәрәге (режиссеры — шагыйрь Рәшит Шиһапов) лаек булды. Район хакимияте исеменнән, әлеге премияне һәм дипломнарны хуҗаларына хаким урынбасары М. Исхаков тапшырды.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Лениногорск районының Зәй-Каратай авылында, күренекле мәгърифәтче, фольклорчы, шагыйрь, композитор, нәшир һәм җәмәгать эшлеклесе Фазыл Туйкинның тууына 110 ел тулу уңаеннан, искә алу кичәсе уздырылды. Шул уңайдан бирегә Сарман районыннан, Әлмәт, Лениногорск, Оренбург, Уфа шәһәрләреннән кунаклар килгән иде. Ф. Туйкин музеенда үткәрелгән әлеге очрашуда Фазыл аганың кызлары һәм оныклары да чыгыш ясады.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Указы белән, татар театр сәнгатен үстерүдәге казанышлары өчен, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музыка бүлеге мөдире, баш дирижер **Әбүбәкеров Фуат Хәмит улына**, артистлар **Әскәрова (Әхтәмова) Фирдәвес Каюм кызына**, **Әхмәтҗанов Илдус Хәниф улына**, **Шамкаев Рәшид Мирза улына** «Татарстан Республикасының халык артисты» дигән, театрның режиссеркуючысы **Бикчәнтәев Фәрит Рәфкать улына**, театр директоры урынбасары, артист **Ибраһимов Фәридун Нуретдин улына**, театр музее мөдире, артист **Шакирҗанова Луара Галимҗан кызына**, театрның әдәби бүлек мөдире, драматург **Сафиуллин Юныс Габдулла улына** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән, артист **Әкбәрова Фирая Барый кызына**, артист **Юкачев Николай Викторовичка** «Татарстан Республикасының атказанган артисты» дигән мактаулы исемнәр бирелде.


## *Тышлыктагы сурәтләр*

«Татнефть» акционерлык җәмгыяте республикабызның көньяк-көнчыгышында милли һәм рухи яңарышка ярдәм итү йөзеннән «Рухият» фонды оештырган иде. Ул бу төбәкләрдә яшәп иҗат итүче каләм әһелләренә, сәнгатькәрләргә булышу, яшь иҗатчыларны эзләп табу һәм үстерүне дә максат итеп куя. Май аенда бер төркем язучылар, журналистлар һәм рәссамнар фонд чакыруы белән нефть районнарында йөреп кайттылар, нефтьчеләр тарафыннан яңартылган чишмәләр, һәр авылда диярлек калкып чыккан мәчетләр, соңгы елларда аеруча киң колач алган ат спортының торышы белән таныштылар.

Киләчәктә алар әзерләгән язмалар һәм сурәтләрдән «Рухият» фонды аерым китап-альбомнар бастырып чыгаруны күздә тота. Тышлыкның беренче битендә «Чишмә янында» дигән рәсем тәкъдим ителә. Аны рәссам-фотограф **Шамил НАСЫЙРОВ** Сарман районының Җәлил эшчеләр поселогындагы «Тегермән шарлавыгы» исемле кизләүдә төшереп алды.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Флүс ЛАТЫЙФИ, Ринат ЯКУШ. **Тамга.** Фантастик повестьлар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.—320 бит. Тиражы—10 000 данә.




Танылган язучы, «Хыянәт» романы, күпсанлы повестьлар, хикәяләр авторы Флүс Латыйфи һәм Казан университеты доценты Ринат Якуш язган бу повестьларны («Тамга», «Соңгы кисәтү», «Игезәкләр») татар әдәбиятында яңа күренеш дип бәяләргә мөмкин. Катлаулы, тыгыз сюжетка корылган әсәрләр укучыны мажаралары белән генә түгел, ә бүгенгене үткәннәргә тоташтыручы хыял һәм чынбарлык турында фәлсәфи уйланулары белән дә җәлеп итә. Китап бай, йөгерек тел белән язылган, үтә четерекле мәсьәләләргә кагылышлы булуга карамастан, бик җиңел укыла.

«Турысын әйтергә кирәк,— ди әдип-тәнкыйтьче Фәиз Зөлкарнәй үзенең кереш сүзендә,— хәзерге вакытта шушы икәүдән башка татар әдәбиятының фәнни фантастика өлкәсендә җитди эшләүче әллә кем күренми».

Бу оригиналь китап бер тышлык эчендә татар һәм рус телләрендә басылган.

Индекс 73210



Язучы Флүс Латыйфи

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)